ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2006



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

**2006 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында**



*Р. Батуллин*



*Л. Батыркаева*



*Р. Бохараев*



*М. Галиев*



*Н. Индюхов*



*Р. Мостафин*



*Ф. Халиков*

2006 ел Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүен күздә тотып, 2006 елның 26 апрелендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуны игътибарга алып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимен кабул итәргә һәм 2006 елда искәрмә буларак Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге җиде Дәүләт бүләген бирергә.

2. 2006 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

язучы **Батуллин Роберт Мөхлис улына (Рабит Батуллага)** — «Сөембикә» тарихи әсәре өчен, Татарстан китап нәшрияты, 1992 ел; «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», Татарстан китап нәшрияты, 1996 ел; «Яралы бүре», «Идел» нәшрияты, 1996 ел;

композитор **Батыркаева Луиза Миңнегали кызына (Батыр Болгарига)** — патриотик һәм гражданлык лирикасы белән сугарылган югары художестволы җырлар циклы, тарихи тематикадагы җырлар циклы өчен («Кайту», «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Мин сине шундый сагындым», «Ак яулыклы әнием»...);

язучы, шагыйрь **Бохараев Равил Рәис улына** — «Очсыз-кырыйсыз поезд» («Бесконечный поезд»), «Мәгариф» нәшрияты, 2001 ел; «Казан карлары» («Казанские снега»), «Мәгариф» нәшрияты, 2004 ел;

шагыйрь **Галиев Марсель Баян улына** — «Гомер бизмәне», «Рухият» нәшрияты», 2004 ел; «Кайту», Татарстан китап нәшрияты, 2000 ел; шигырь җыентыклары, «Догалы еллар» нәфис-публицистик әсәрләр җыентыгы өчен, «Идел-Пресс» нәшрияты, 1998 ел;

рәссам **Индюхов Николай Петровичка** — Татарстан Республикасының лирик пейзажлар сериясе өчен: («Каенкай» («Березка»), «Кибән» («Стожок»), «Ындыр табагында» («На току»), «Соңгы кар» («Последний снег»), «Җылы көн» («Теплый день»), «Тузганаклар» («Одуванчики»), «Зәңгәр март» («Синий март»), «Шаян март» («Веселый март»), «Болытлы көн» («Облачный-день»), «Кыр чәчәкләре» («Полевые цветы»), «Сукмак» («Тропинка»), «Апрель», «Буранда» («Снегопад»)...);

язучы **Мостафин Рафаэль Әхмәт улына** — «Өзелгән җыр эзеннән» («По следам оборванной песни») китабы өчен, Татарстан китап нәшрияты, 2004 ел;

рәссам **Халиков Фиринат Гаптухай улына** — «Мәңгелек Казан» тарихи картиналар сериясе өчен (1995-2003 еллар).

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

Казан, Кремль
2006 ел, 26 апрель, №ПУ-159

Казан утлары
Qazan utlarы

2006

5

(1003)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**


Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Галәм кисәтүе. *Поэма.* ..... 5
Зиннур ХӨСНИЯР. Козгыннар йолдыз чүпли. *Роман.* ..... 16
Рәзинә МӨХИЯР. Уй кердә—ай күрдә. *Шигырьләр.* ..... 56
Альберт ХӘСӘНОВ. Җанбәт ыруы. *Повесть.* ..... 58
Радик ФӘИЗОВ. Карак. *Хикәя.* ..... 92


**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**


Ленар ШӘЕХ. Син—минем сыеныр кыям... *Шигырьләр.* ..... 90


**ПУБЛИЦИСТИКА**


Солтан ШӘМСИ. Адәмне кем коткарыр? *Тарихи-эзотерик бәян.* ..... 97
Рафаэль МОСТАФИН. Тормыш мизгелләре. ..... 119

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Күңел тәрәзәбездә ут сүнмәсен. ..... 126


**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**


Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Әйдәүче *(Тәүфикъ Әйдинең күптомлыклары чыгу уңаеннан).* ..... 136
Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ. Гамил Афзал иҗатында сәясәт. ..... 142
Фатих УРМАНЧЕ. «Фәрештәләр санап бара күз яшен...» ..... 149


**ФӘН**


Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 161
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 180


**СӘНГАТЬ**


Гали АРСЛАНОВ. «Татар театрының атасы» ..... 166


**КИТАП КҮЗӘТҮ**


Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Рухи биеклек. ..... 174

Укучы сүзе. ..... 182
Юбилейлар. ..... 183
«Казан утлары» архивыннан. ..... 186


**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**


Хәнәфи БӘДИГЫЙ. «Дедовщина». *Шигырь.* ..... 185

Игътибар! Конкурс! «Яңа дәвер кешесе». ..... 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман З. ХУСНИЯРА «Вороны стремятся к звездам», повесть А. ХАСАНОВА «Родословие Джанбет», рассказ Р. ФАИЗОВА «Вор»; поэма Л. ШАГИРЗЯН, стихи Р. МУХИЯР, Л. ШАЕХА.
«Публицистика»: Историко-эзотерическое повествование С. ШАМСИ «Кто спасет Адама?»; статья Р. МУСТАФИНА «Мгновения жизни».
«К 100-летию издательства «Магариф»: статья Муд. ВАЛИЕВА.
«Литературная критика»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА по случаю выхода многотомников Т. Айди; статья М. АХМЕТЗЯНОВА о творчестве Г. Афзала; рецензия Ф. УРМАНЧЕ на поэму З. Мансурова «Ике еглау».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации».
«Искусство»: статья Г. АРСЛАНОВА об актере Г. Кариеве.
«Книжное обозрение»: статья А. ЗАКИРЗЯНОВА «Духовная высота».
Наши юбиляры.
Слово читателя.
Из фотоархива журнала.
«Юмор-сатира»: стихотворение Х. БАДЫГИ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Голубая мечеть"—фото Г. ЗАЙНУЛЛИНА; поэтесса Фаузия Солтан.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by Z. HUSNIYAR «Crows aim to stars»,
Story by A. HASANOV «Djanbet's Genealogy», story by R. FAIZOV «Thief»;
poem by L. SHAGIRZYAN, verses by R. MUHIYAR, L. SHAEH.
«Publicism»: historic-esoteric narration by S. SHAMSI «Who will save Adam?»; article by R. MUSTAFIN «Instants of life».
«To 100th anniversary of publishing house «Magrif»: article by Mud. VALIEV.
«Literary critic»: article by R. FAIZULLIN dedicated to output of T. Aydi's multi volumes; article by M. AHMETZYANOV about creativity of G. AFZAL; review by F. URMANCHE on poem by Z. Mansurov.
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation».
«Art»: article by G. ARSLANOV about actor G. Kariev.
«Book review»: article by A. ZAKIRZYANOV «Spiritual altitude».
Our jubilee celebrators.
Word of reader.
From photoarchive of magazine.
«Humor-satire»: poem by H. BAGYDI.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Blue mosque»—Photo fo G. ZAYNULLIN; poetess Fauzia Soltan.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 2.05.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3-316. Тираж 7100.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Лена
Шагыйрьҗан

# ГАЛӘМ КИСӘТҮЕ

КИНАЯЛЕ ФӘЛСӘФИ ПОЭМА

## I кисәк

### *Кереш*

**Бисмилладан башлыйм сүзне—
борынгылар гадәтенчә,
зурлап Күкләрнең хуҗасын,
җырлап, рухи халәтемчә.
Җан-рухыңа азык тапсаң,
сүзләремнән мәгънә эзләп,
димәк, кердек Элемтәгә—
күңел кылы тора зеңләп.
...Әүвәл заманнардан килә
хәбәрләшү чаралары.
Хатлар язып бер-берсенә,
аңлашкан Җир балалары.
Хат язмаса, җыр чыгарган,
ишетсеннәр өчен җанын.
Җыр-моңында белдергән ул
мәхәббәтен, серен, зарын.
Рухын ачкан көзге итеп,
дастаннарда, кыйссаларда.
Иреккә чыгарган Сүзен,
үзен изеп, кыссалар да.**

**Камилләшә барган һаман
бу багланыш әмәлләре:
радиосы,телефоны—
хыял, гыйлем гамәлләре.
Соңра, уртаклашыр өчен
җан авазын Галәм белән,
сыйдыралмаганын язып
ак кәгазьгә каләм белән—
ачкан Кеше яңа ысул,
юллап йолдызларга «хатлар»:
очырган ул Җирдән Күккә,
күгәрчен күк, мәгълүматлар...
Космик элемтәгә кереп
шул рәвешчә Галәм белән,
«килештерү» өчен гүя
Аллаһыны Адәм белән—
Фән телендә сөйләшергә
юл салуымы бу Җирнең?..
Кинаяле сорау куеп,
берүк, гөнаһ җыя күрмим...**

### Кеше

**...Батып бетсә дә гөнаһка,
барыбер, ул бөек—Кеше.
Күпләр өчен хәзер бу сүз
яңгырыйдыр булып төче.
Узды инде, дияр бәлки
Кеше зурлау заманасы.**

**Яңа мода бүген: аны
хурлау, сатып яманатын.
Имеш, кеше түбән бер зат,
шул ук черки-таракан күк.
Телевизор «теле» хәзер
шундый коткы тарата күп.**

---

*Лена ШАГЫЙРЬҖАН—шагыйрә, публицист, тәрҗемәче; унга якын шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Имеш, маймылларга гына
хас ул «гаделлек» хисе дә.
(Оныталар таянганын
бу хиснең Намус көченә...)
Нинди сүзләр языйм икән,
шул циникның авызын ямап?
Кеше—ни ул? (Иске сорау,
каян табыйм яңа җавап?..)
Үзен мыскыл итеп, Кеше
мескенлеккә калмагае.
Шул куркыныч яный аңа,
югалтса йолдыз маягын.
Кеше дигән адәмзатны
күккә чөеп мактаулар да,
тараканга тиңләп аны,
җиргә салып таптаулар да—
һәммәсен дә күрдек инде,
түзсен генә Кеше заты.
Ватып карау кирәк төшен—
бу чикләвек шактый каты...
Иманлы кешеләр генә
чын кешенең кадерен белер.
Чын кешелек сыйфатларын
бөртек-бөртек җыеп төрер.
...Хөкем сөрми Җир йөзендә
Яхшы белән Яман гына.
Яхшының да иң яхшысы
Табигатькә таман гына...
«Безгә ярый уртача да,
җиткән үзебез кебек булса»,—
дип йөри ул түрә генә,
колларына булып хуҗа.
«Үзем кебек камил булсын
Җирдә, диеп, һәрбер колым»,—
Аллаһ кына күрсәткән ул
Җирдә дөрес яшәү юлын...
Һәм Табигать сайлый, барыбер,
аңа «иң яхшысы» кирәк:
иң камиле, иң остасы—
Мәңгелеккә тик шул терәк!
Кеше—бөек, Кеше—даһи,
Кеше бит ул бер могҗиза.
Адәмнән—Кешегә кадәр
Коръән тугры юлны сыза:
Картлар—көлмәслек яшьләрдән,
яшьләр—көлмәслек картлардан,—
төзек чылбыр төзү зарур,
өздермәслек чит-ятлардан...
Кеше бит ул җырлый белә,
көлә белә, җылый белә,
Туңып өшегән ишенә
үзенең йөрәк җылысын өрә.
Баласына гына түгел,
җиде ятка өлеш бүлә...
«Кеше—хайван ул», дип фәкать
үзе хайван гына көлә.
Кеше—дога кыла белә,
Кеше—руза тота белә,
Кеше—корбан чала белә,
Кеше... ипи сала белә.
Изгелеккә омтыла ул,
өметләрен җуя-җуя.
Кеше—мәхәббәт җимеше,
үрчеми ул, бәлки—туа!
Янып көлгә әйләнсә дә,
кабат гөлгә әйләнала,
Канатланып оча-оча,
Җир тирәли әйләнала.
Матдият вә Рухиятне
бер бөтенгә туплаган ул.
Аллаһының шул ниятен
кабул иткән, хуплаган ул.
Әмма,үкенеч, кешенең дә
хәттин ашкан кимчелеге.
Иң яман сыйфаты аның
нәфесе һәм көнчелеге.
Кими бара кешеләрдә
садәлек вә самимилек.
Арта бара эреләнү,
тәкәбберлек вә мин-минлек.
Ни кызганыч, оныта ул
Галәмнең башлангыч Сүзен:
саклар өчен яралганын
Табигатьне һәм үз-үзен.
Торган саен узына ул,
үзен-үзе зурга куеп.
Куылыр чиккә җитеп Җирдән,
кешелек дәрәҗәсен җуеп...

## Элемтә

Җирдән бик тә бик еракта,
Кояштан да аргы якта
бер планета бар ди Күктә,
күзәтә ди безне күптән.
Сигналлар җибәрә, имеш,
алар Җиргә ара-тирә.
Тик Җир әлегә тоталмый—
серләр юлда кала бирә.
Яңгыр тамчысына сеңеп,
кояш нурларында эреп,
мең төрле халәткә кереп,
бу хәбәрләр килә тора,
әмма җилдә «кибә тора»...
Цунамилар, җир тетрәүләр,
давыл-зилзиләләр аша,
ахыр чиктә, бу хәбәрләр
Җир Аңына бер тоташа,
кисәтүле Сынау булып—
хәвеф-хәтәр,бәла-каза...
Иксез-чиксез гөнаһларга
гүя Алла биргән җәза.
...Күкләр Сүзен ишетер өчен

кесә телефоны гына
җитми... Мәктәп малае да
белсә иде моны гына...
Кешенең «күңел антеннасы»
торырга тиеш зеңгелдәп—
әзер булып Элемтәгә
Күкләр белән—һәр мизгелдә...
«Йолдызларда эшем юк», дип
җырлап йөргән кешеләрдән
көтәсе юк зур ачышлар—
сукыр-чукрак ишеләрдән...
Алар «йолдыз белән йолдыз
сөйләшкәнен» тыңлар өчен,
юлга чыкмаячак ялгыз,
ятып йоклаячак кичен...
Уятырга теләп мәллә,
былбыл аңа сайрап дәшә?
«Кешеләрдә эшебез бар», дип
Йолдыз балкып, нурын чәчә...

## Могҗиза

Инде хәзер бер могҗиза
Укучыга ачып салыйм:
Җирнең нәкъ кыл уртасында
яшәп яткан бер зур галим.
Бөтен җаны-тәне белән
Табигатьне өзелеп сөйгән.
Афәтләрен кисәтим дип,
көне-төне янган-көйгән.
Бик күп еллар күзәткән ул
Йолдызларны һәм Күк йөзен,
ишетәсе килеп аның
кешеләргә әйтер сүзен.
Кирәк булган җиһазларның
галим, үзе ясап барын,
әзер тоткан кул астында—
төрле «йолдыз әсбапларын».
Бер төн килеп, бу галимнең
суккан ди йолдыз сәгате:
ул кичергән биниһая
ләззәт-иҗат сәгадәтен...
Көтмәгәндә, дияргәме,
аллә—көтә-көтә аргач,
сәер өн тотып алган ул,
Күккә янә колак салгач.
Җигеп эшкә үзе белгән
махсус ысул, әмәлләрне,
ашыга-ашыга теркәп барган
ошбу аваз-гамәлләрне...
Аннан инде, төшеп тирән
гыйлем-фәннең төпкеленә,
Ул аңлатма биргән аңа,
авыштырып үз теленә,
Бу Хәбәрнең төп мәгънәсе
үз уена тәңгәллеген
белгәч, тагы да дәртләнеп ул,
Бөек эшен төгәлләгән...
...Татар галиме булган ул—
ишетмәсәң, ишет менә!!
Татар кешесе дә ятмас
комнан аркан ишеп кенә...
Иң беренче кемгә димсез
чишкән ул тиңсез серләрен?
Чакырып алган үзе кебек
хыялый дус шагыйрьләрен.
...Гаҗәпләнеп тыңладым мин
Күктән төшкән «хикәяне».
Һәм кызардым Адәм өчен,
аңлап ачы кинаяне...
Укып чыккач ул Хезмәтне,
зур тетрәнү кичердем мин.
Хисләремне түкми-чәчми,
шигъри телгә күчердем мин...

## Хәвеф

Акыл сынамыйлар күптән,
корал сыныйлар Җирдә.
Йолдыз санамыйлар күктән,
акча саныйлар Җирдә.
Саклый алмады Кешелек
үзенең асыл җәүһәрен.
Ялгышмаган микән Алла,
Җиргә Адәм «җибәреп»?..
Кеше уйлый, имеш, Җирнең
ул гына дип патшасы:
утлы коралы бар, имеш,
һәм дә «чутлы» акчасы...
«Саф акча» артыннан куып,
саф мохитен бозды ул.
Чүлмәктән чыккан гыйфритне
инде мең кат узды ул.
Күзгә дә күренми торган
дәһшәтле нурлар чәчеп,
өтә үлән-чирәмнәрне—
Җирнең ямь-яшел чәчен...
Томчыктырып Табигатьне
агулы төтен-газдан,
мәхрүм итә ул үзен дә
хуш-исле хозур яздан.
Әфьюн тартып, хәмер эчеп,
исергәннән исереп,

үзиркеннән, газиз башын
үзколлыкка төшереп,
ташландык чүплек базына
әйләндереп җир йөзен,
«чүп чүлмәгенә» ул тиздән
охшап калмасмы үзе?..
Чишмәләрне, елгаларны
нефть белән «сугарып»,
диңгезләрне, океаннарны
чыгырыннан чыгарып,
килә кеше, янап Җиргә,
«бозык белеме» белән...
Белми Җирнең үч аласын
икмәк телеме белән...
Талый-умыра җир байлыгын—
асылташын, күмерен.
Сыта—изрәп яткан җирне
түшәк кебек күпереп.
Сугыш кырын җәелдереп,
иген кырын изә ул.
Сизми, димә җир-туфракны,
авыртуны сизә ул.
Сыкрана һәр күзәнәге
җиһанның ут-ядрәдән.
Күктә яшен телгәләнә
Җирдәге зар-нагъръдән...

## Нәфес

Адәмзат тик Табигатьнең
гүзәллеген талаучы.
Үзен-үзе урлаучы ул,
үзенә үзе—аучы.
Үзе ерткыч, үзе кыргый,
үзе яман алдакчы,
хокукын—һәрбер мәхлукның,
җанын тартып алмакчы.
Ни кызганыч, ул мәхлуклар
берләшеп-нитеп барсы,
көрәшә белми шул инде
кысрыклаучыга каршы...
Алар—җан иялӘренең
иң гөнаһсыз, изгесе,
абсолют гакылның гәрчә
булмаса да көзгесе...
Аларның «аң» дәрәҗәсе
әһәмиятле түгел,
аларның «гөнаһлары» да
усал ниятле түгел.
Алар, яшәү өчен ашап,
«үзеннән-үзе» яши,—
ашау өчен яшәгәндә
күпме «акыл иясе»...
Тиеннең бар «туплаганы»—
кышлык чикләвек кенә...
ә кешеләр мәңгелеккә
мал җыям дип җилкенә.
Иң мөһиме—эт-кошларда
юк комсызлык, юк нәфес.
Алар бит тамагы туйгач,
ясый белә тәнәфес...
Ә кешеләр туя белми,
алар туклык хисеннән
азып, отыры, котыра-котыра,
тауар-мал дип исергән.
Җирдәге һәр җан иясен,
хәтта адәмнең үзен
кыра, туный адәм заты—
кан баскан ике күзен.
Менә шуннан шомлы уйлар
биләп ала күңелне:
«Кеше» дигән аңлы кавем
Җиргә яный түгелме?!
Җир байлыгын җыяр өчен
урын җитми аларга:
чит йолдызга ашкыналар,
читтән торып таларга...
Ничек чыдый диген Җирне
мондый золым-җәбергә.
Әйләнмәсме ул бер көнне
планета-кабергә?!.

## «Әрәмзат»

Кеше, имеш, килгән Җиргә
сакларга матурлыкны...
Саклар өчен—сизгерме ул,
гакылы аның ныкмы?
Адәмнән тыш Җирдә әле
яши кошлар, җанварлар:
Кешедән башка да җирдә
гаять сизгер җаннар бар..
Матурлыкны күрә аны
хәтта коңгыз-бөҗәкләр.
Күбәләк канатына ник
төшкән чуар бизәкләр?..
Гүзәллекне танымаса,
ул тиккә очмас иде.
Аллы-гөлле чәчкәләрне
иркәләп кочмас иде.
Бал кортлары, кырмыскалар
Адәмгә түгел ятлар.
Коръән сүрәсенә нигә
керде икән бу затлар?..
Җир йөзендә кешедән дә
хикмәтлерәк җаннар бар.

Адәмзатны каргый хәзер
кошлар, гөлләр, җанварлар...
...Җир-туфрактан яралганның
җаны бар... Хәтта таш та
тере... Ул һава сулышы—
җилләр белән тоташкан.
Шуңадыр, нәфис сыннарга,
гүзәл таш-чәчәкләргә
әүрелә алар, чын Кеше
кулы тисә әгәр дә...
Әмма ташны тере сынга
әверелдерүчеләр,
чын Кеше яшәвен Җирдә
Күккә белдерүчеләр—
азая бара дөньяда,
вәхшилек кабат дәшә,
Кыргый адәм урын даулый
Кеше белән янәшә...
Ул инсафлыкны яратмый,
ул инсанлыкка дошман.
Иблис аңа мәрхәмәтсез,
затсыз булырга кушкан.
Ул инде Кеше башына
һичшиксез, таш атачак!
Адәмзат дип түгел аны,
«Әрәмзат» дип атасак,
дөресрәк булыр... Чыннан да,
ул үзен әрәм итә.
Кеше дигән бөек затның
исемен хәрам итә...

## Канун

Күкләр язган Канун белән
Җирдә яшәү кыен дисәң,
Күкләр кайчысы тотар да,
тамырыңны төптән кисәр...
Әмма, Кешем, яшим дисәң,
каршы бер сүз дәшмим, дисәң,
зинһар, Җирдә калыйм, дисәң,
инде гыйбрәт алыйм, дисәң,—
Кал син!
Ләкин үз «кагыйдәң»
белән түгел—Табигатьне
санлый торган Канун белән,
ант ит, язып каның белән!!
Табигатьне әткәң-әнкәң,
газиз балаң кебек ярат.
Кешелекле сыйфатыңны
хайваннарга хәтта тарат...
Табарсың син күктән көткән
оҗмахны һәм бәхетеңне,
таза-имин тотсаң гына
Җирдәге үз мохитеңне.
Мәңге яшәү ихтыяҗы
сүрелмәсә йөрәгеңдә,
Җаның мәңгелек булсынга,
ни эшләргә кирәген дә
хәл ит Җирдә—исән чакта,
тәнеңдә дәрт, ялкын барда.
Калсын орлык-истәлегең
яшь алмашка—оныкларга...
«Камилләшәм» дип акланма,
азынуның аръягына
чыгып бастың инде, бәндә,
табынып иблис байрагына.
Камиллекнең чиге - Аллаһ!
Шул—илаһи «чыгыр» сиңа.
Узып китсәң изге чиктән,
кая барып чыгырсың, ә?!.
Андый космик «цивильлеккә»
ирешкәнче, бетүең артык.
Тыпырчынма эзләп, Адәм,
Галәм «көзгесенең» артын...

# II кисәк

## Үлем

«Яшәү—бәхет», дигән сүзгә
фәкать ияләнелә.
Яшәү—үзе фаҗигадер
акыл ияләренә...
Туу белән, үлә башлый
чөнки адәм баласы.
Шул—аның каның корыткан
иң четрекле бәласе.
Адәмне Кеше итүче
фәлсәфә һәм гүзәллек
җыйалмый барыбер әҗәлне—
бу хөкемгә түзәрлек
нинди көч кирәк Кешегә!!
Үлем кайгысы исә
акыл иясенең бөтен
яшәү шатлыгын изә...
Гомере буе көтә шуңа,
курка-курка, азакны...
...Үлем генә җиңә юкса
тормыш дигән газапны...
Ышанмый ул чөнки җанның
мәңгелек булуына,
ышанмый җанын үзенең
тәрбия кылуына.
Җанны тәрбияләү Җирдә—
хезмәтнең иң авыры...
Шул зур эшкә адәмзатның
җитми бик еш сабыры.

…Ни өчен мәңге яшәүнең,
һич югында—бик озак—
бер шарты юк икән «өстән»,
бу нинди мәкер-тозак?..
«Гөнаһка батмасаң әгәр,
нәфсеңне тыя белсәң,
Аллаһның кагыйдәсенә
буйсынып сыя белсәң,—
туйганчы яшә! …Арыгач,
бер үләрсең—аннары,
теләсәң, кабат терелеп,
яши башла, яңарып…»—
Менә шундый шарт куелса
Күкләрнең Кануныңда,
уйланыр идеме адәм
ничек яшәү турында?..
(Укучым, әлбәт, аңлыйдыр
каһкаһә-кинаяне.
Атылган ук бушата тик
киерелгән җаяне…)
Гөнаһсыз яшәү булмый шул…
Инде, алайга китсә,
сабыйлар, нарасыйлар да
үлә, сәгате җитсә…
Котыла алмый әҗәлдән
бае да, ярлысы да,
патшасы да һәм колы да,
ялгызы, парлысы да.
Бөкресе чыккан гарип тә,
алиһәгә тиң кыз да…
Даһи фикер иясе дә,
надан да, акылсыз да.
Пәйгамбәрләр дә җан биргән,
денсез-имансызлар да.
Шөһрәткә баткан ирләр дә,
билгесез-дансызлар да…
Кыскасы, үлем каршында
тигезләшә һәммәсе.
Газраил өчен—кешеләр—
тоташ әрвах гаммәсе…
Ник бу Күкләр кешеләрне
үлем белән тигезли?
Нәрсә белән аклый моны,
нәрсә белән нигезли?..
Мөһим түгел, димәк, Күккә
кемнең кем булуы да?..
Мәгънәсез, димәк, Адәмнең
Җиргә куылуы да?..
Бәлки, шуңа курыкмыйдыр
бәндә гөнаһ кылудан?
Хөкем уртак ич—ни файда
әйбәт, изге булудан?..
Бәлки, шуңа яшәмидер
вөҗданы яньып-көеп,
хәттин ашып азынадыр,
«барыбер үләсе» диеп?..
Оҗмахның да, тәмугның да
җирдә икәнен күргәч,
кайгырмыйдыр ул, «кайсына
эләгермен?»—дип, үлгәч…
«Мәңгелек җан» дигән хыял
өмет бирүен бирә-ә…
Тик ул мәңгелек булсынга,
нидер эшләргә кирәк…

## Курку

Кеше Галәм каршысында
тота бүген имтихан.
Бу сынауда бик күпләрнең
«батуы» да ихтимал.
Курку баскан Кешелекне,
белә ул үз гаебен.
Гөнаһ җыя-җыя, үзе
батыра үз каегын.
Баш өстендә кара болыт
куерганнан куера.
Бетәсеме? Каласымы?—
Мәгълүм сорау куела.
Шуннан куркып, ахры, кеше
Җирдән качарга тели.
Каядыр китеп, «яңача»
яши башларга тели.
Бик күптән инде талпына
күчү өчен ул Җирдән.
Гарык булган, имеш, монда
һәлакәт, афәт, чирдән,
зилзиләләр, гарасатлар,
террор-шартлатулардан,
утларда янулардан вә
суларга батулардан…
Курка ул: тиз-кинәттән дә
картаеп үлүдән дә.
Кайчан да бер үләчәген
алдан ук белүдән дә…
Үлем дигән шомлы шәүлә
аның җан-котын ала.
Әҗәлгә каршы бер чара
эзли һаман, бичара…
Фиргавен-патшалар кебек,
үлгәч тә, үзен җәлләп,
музейда тотар иде гел,
мумия күк—бәлзәмләп…
Берсе әнә «ачкан» имеш
клонлаштыру серен:
Бәрәңге күк, күзәнәктән
адәм үрчетү төрен…
Тере мәетләр болай да
җитәрлек иде җирдә…
Ходай кушмаган бу каза
килә күрмәсен миргә…

Үз анасын һәм үз телен
оныткан маңкортларның—
кемнәргәдер кирәксә дә,
Җиргә кирәге бармы?!.
Кабатланмас шәхесләр дә
яшәүдән гарык булып
үләдер, бәлки?.. Ник аңа
«Долли сарыгы» булып
кабаттан «туу» дөньяга?!
Бу нинди вәхши җәза?!
«Бер күзәнәкле» белгечләр
әллә акылдан яза?!
Нәсел дәвам итү бәхетен
саклап калырмы Кеше?
Үлемнән түгел—көрәштән
куркумы әллә көчле?. .

Куркак курчаклар әвәләп
куркуын басар өчен,
әкияттәге күк, камырдан
«батырлар» ясар өчен,
көчәнә бәндә—чын көчен
белми эшкә җигәргә...
Үлемсез исем калдырып,
үлемне дә җиңәргә
мөмкин булуын дөньяда
ул инде онытып бара...
«Майда йөзеп» миңгерәүне
«чын тормыш» ди, бичара!
Гамьсез муллыкка табыну
җанны кечрәйтә генә...
Үлемнән курку хисен дә
мең кат көчәйтә генә...

## Табигать

Табигатьне булмый алдап,
алдаласаң—алданасың!
Чын Кешегә алмаш булмас,
булмаган күк—Аллага сын...
Кеше—кеше булып кала,
җуймаса тик табигъ асылын.
Роботларга, курчакларга
тапшырмаса хәләл акылын...
«Җанлы» сыннар, уенчыклар,
«җанлы курчак» белән тулыр
җирнең өсте...Тик аларның
хисе булмас, «кешесе» сулыр...
Һәр селкенгән җанлы булмас,
кыймылдар... тик рухы булмас.
Ясалма кешеләр мәңге
Җирне коткаручы булмас...
Компьютерның «хәтере» булса,
моң дигән җан кылы булмас:
Ул чыгарган коры көйдән
беркемнең дә күңеле тулмас...
Тере булалмыйлар алар,
тынсыз алар—һушсыз, иссез...
Ясалма чәчәкләр төсле,
үле алар—хушсыз-иссез...
...Ата орлык...Ана орлык...
Компьютердан тумый кеше.
Фәнни машина ул фәкать—
шуннан ары китми эше...
...Йоклый Адәм Җир-ананың
күкрәгенә башын куеп.
Кеше булудан туктар ул,
китсә Җирдән, башын җуеп...
Сәйяр булып очса, очар
Аена йә йолдызына.
Тик ямансу булыр анда
Җир улына, Җир кызына...

Галактика томаннары—
Киек каз юллары аша
очса да Кеше космоска,
Күктән кабат Җиргә «аша»...
Җир кешесе калыр Җирдә,
әйләнмичә космик «чиргә»!
Тәңре аңа яшәргә дип
үз җирендә куыш биргән:
утын-суын, ком-туфрагын—
кадерләр дип,—җир бодаен...
Урманнарын, җимешләрен—
онытмыйча бер Ходаен...
...Тәңре—безнең Җир-Иябез,
без Аңа да баш иябез...
(Дерсу Узала*—төркичә
Җир-Су—Үзе Алла» дигән сүз...)
Илаһи мәҗүсилек тә
тансык кайчак кешеләргә...
Кошлар, гөлләр телен белгән
бармас түбән төшүләргә.
Тәңре—күк Алласы, диләр...
Бәлки, ул—җир алласыдыр?..
Бәлки, күптән Табигатька
Алла итеп табынасыдыр?..
Мәҗүсилек дип аңламыйк
буйсынуны Тәңребезгә;
Аллаһ—хуҗа бар Галәмгә,
Тәңре—Туган Җиребезгә...
(Укучым төшенер шаять
ошбу нечкә фәлсәфәне...
Уйларымны белдермичә,
калмады һич түзәр хәлем...)
...Камилләшәм дигән булып
узасы юк чик-чамадан.
Кая китмәк була кеше
үзен тапкан Ата-Анадан?!

*Дерсу Узала—Н. Арсеньев әсәренең төп герое.

Камиллекнең чиге—Аллаһ,
шуны тоялмыйсың икән,
димәк, Кешем, син авыру,
чирең тирәнгәрәк киткән...
Очынсаң да, канат тагып,
күктән биек булмас түбәң.
Китәм-китәм дип җилкенеп,
«оча» күрмә җирдән түбән...
Өйрән борынгылар Сүзен,
шагыйрь, галимнәрен—күбрәк.
Алар Җирдә яшәп киткән,
синнән әүвәл алып гыйбрәт.

Алар тойган, алар ачкан
Җирнең бөек тарту көчен...
Алар күргән—Мәхәббәтнең
тауларны тетрәндергечен...
Алла—Алла булып кала,
кай ягыннан укысаң да.
Ул—эчеңдә, Ул—тышыңда,
бар булсаң да, юк булсаң да...
Очканда да—һаваланма,
күктән биек булмас түбәң.
Үлгәндә дә—хафаланма:
китәлмассың җирдән түбән...

## Уй

Галәм җитди Уйга калган:
Җирне ничек сакларга?
Юлдан адашкан бу Адәм
затын ничек акларга?
Әллә инде Җир йөзеннән
юк итәргә аларны
дәһшәт-зилзиләләр белән,
яисә—алып аңнарын?..
Җир өчен бит Аң-зиһеннән
«файдалырак» гөл-үлән,
Иң мөһиме—Җир чүпләнми
адәм «акылы» белән...
Акыл тамыры бу Җирдә
төпләнде бик акырын.
Әкият һәм хыял җиңде
реаль кеше акылын...
Яшәргә хаклымы Кеше
акыл җиңелгән җирдә?—
«Аңлы» көзгеләр кирәктер
ахмак йөзне күрергә...
Пәйгамбәрләр шәригате
Җир өчен шул уңайсыз.
Кыргый хайван үрнәгенә
иярмәсәң, бик җайсыз...
(Укучым, әлбәт, аңлыйдыр
каһкаһә-кинаяне.
чәнечкеле ачы сүздән
Мәгънә дә киңәйгәнне...)

... Аң-зиһеннән мәхрүм итсәң,
ничек яшәр икән Җир?..
И, Ходаем! Адәмнәргә
гыйбрәт бирдең,—Иман бир!!
Җирнең мильон газабы да
берни түгел иблискә.
Адәм затларына кыен—
аларда хисләр нечкә.
Кеше «бетсә», кая куяр
Галәм аннан калганны?—
Тарихына тупланганны,
хәтеренә салганны?
Дөнья бетеп, туфан купса,
«Нух-көймәгә» кем сыяр?
Һәр тереклек иясенең
ДНК сын кем җыяр?..
Кемнәр бетәр? Кемнәр калыр?
Ахирәттән юл кая?!
Җавап бар да... Җавап юк та...
Кыямәт якыная.
Галәм шулай Уйга калган,
кызганып адәмнәрен.
Ният кора әле һаман
күрсәтергә ярдәмен...
Сизәр хәлдә түгел кеше
Күкләрнең бу Уен да:
Гаме юк аның Галәмдә,
ул бирелгән... уенга...

## Куылу

«Санламасаң Җирне, Адәм,
олак башка бер урынга!
Тәнең белән кайнаш шунда,
оныт Рух вә Җан турында...
Бер «бушлык» тап җисемеңә,
синең «ояң» Җирдә түгел,—
әгәр сиңа харам икән
акыл, вөҗдан, рух вә күңел...
Котылса Адәм затыннан,
Тәңре үзе хуҗа булыр
җир-суына, тереклеккә—

үз иркендә хөкем кылыр...»
Галәм шулай фикер йөртте,
нәфрәтләнеп бер арада:
куалап куркытмак булды,
керешкәнче соң чарага...
«Әйе, тап бер үзгә урын
тән-бәдәнең сыя торган.
Авыр йөк ул сиңа Канун—
нәфес дәртен тыя торган.
Олак, зинһар, бер сөрген тап,
шайтан сиңа хуҗа булыр.

Табалмасаң—Җирдә яшәү
мәңге сиңа нужа булыр,—
гыйбрәт ала белмәгәчтен
пәйгамбәрләр сүзеннән дә;
аңламагач—бетү-бетмәү
торганлыгын үзеңнән дә...
Тәкәбберлек аркасында,
үзең ташлап китәргә дә
риза бит син Җир-ананы,
риза—хыянәт итәргә дә...
Хәер, барыбер, качалмыйсың,
Күк капусын ачалмыйсың,
Җирне рәнҗеткәнең өчен,
Тәңре синнән ала үчен.
Фәрештәгә җиталмыйсың,
шайтан булып беталмыйсың,
маймылга да әүрелмисең—
үз-үзеңнән киталмыйсың!
«Камилләшәм» дигән булып,
денсезлекнең аръягына
чыгып бастың инде, затсыз,
табынып Иблис байрагына...
Бел—син артык бер зат Җирдә,
бу хәлеңә үзең шаһит.
«Дөнья малы» дип җаныңны
корбан иткән мескен «шаһит»...
Бер агач та, бер кошчык та,
бер бөҗәк, бер җан иясе
мохтаҗ түгел сиңа Җирдә,
син аларга баш иясе...
Бер зат сине кирәксенми,
ябалак та, сандугач та,
һәммәсе дә үз юлында—
төн җиткәч тә, таң тугач та...
Яши бирә үз көенә
күбәләк тә, арыслан да:
исе китми—син аларга
җыр багышлап, арысаң да...
Берсе сиңа мохтаҗ түгел,
килмәс синнән «өлеш» сорап.
Киресенчә, һәммәсе дә
кешеләрдән ерагырак
качу ягын карый алар,
сиңа начар карый алар.
Куркып-өркеп беткән чонки,
рәнҗеп, сине каргый алар.
Инде үзеңә-үзең дә
кирәкмисең бит син, бәндә,
«Табигатькә мин хуҗа!» дип,
саташасың, төш күргәндә...
Кит, бар, тизрәк олак Җирдән,
булып ятма «артык кашык»...
Күпкә китте әрсезлегең—
«Юлыңа—ак җәймә!»—ашык...
Комсызлыгың, уйсызлыгың—
топ гаебең һәм топ бәлаң...
Оят, хурлык—Җир йөзеннән
үзе куа сине Галәм!

## Кисәтү

«Шелтә» белдерүләр генә
куркытмады Адәмне.
Соңгы каттый кисәтүен
көтәме ул Галәмнең?
Ниһаять, хөкем карары
хәбәр ителде Күктән...
..............................
(Безнең галим каушамады,
ул аны күптән көткән...)
Хәбәр шундый: «Адәмзатлар!
Аңлый алырсызмы сез?—
Хөкем көне якынлашты...
Җирдә калырсызмы сез?!.
Туктарсызмы пычратудан,
имгәтүдән Җир шарын?
Ишетә белерсезме тыңлап,
Җир-ананың моң-зарын?!
Юкса бушатабыз сездән
тиз арада Җир йөзен...
Уйланыгыз!.. Онытмагыз
Галәмнең актык Сүзен!!!»
..............................
Галимебез—тантанада:
«Болай булгач, бетмибез!..
диде ул дус-ишләренә—
һәлакәткә җитмибез...
Галәм әллә бу дөньяда
без барын да белгәнме?..
Китмибез без беркая да,
хәтта куса да—мәңге!!.
Бу—бөек зирәк Гакылның
каһкаһәле ярдәме.
Кисәтеп куюы белән
уятты Ул Җир гамен...
Уйланырга вакыт бирә
безгә сабыр Күгебез.
Алланың шул мәрхәмәтен
белми әле күбебез...»

## Өмет

Җиргә Адәм ник сөрелгән?
Мәгълүм инде җавабы:
Аллаһ шулай җәзалаган
Адәм белән Хәваны,—
тыек алманы өзгәнгә...
Рәхмәт инде түзгәнгә...
(Бу «гөнаһ» калмады ләкин
Җирдә беребездән дә.)

Аллаһыга баш күтәреп,
исраф итеп җан көчен,
әллә Адәм ала микән
шул сөрелүнең үчен?..
...Ә Җир көткәнме аларны,
Җиргә кеше кирәкме?
Бәлки, «беттек» дигәндә дә
тотынырлык терәкне,
шул сорауга җавап биреп,
табар Алла коллары?
Хакыйкать серен ачарга
җитәрме акыллары?..
Әйе, сорау бүген кискен:
Җиргә кеше кирәкме?
Җисми барлыгы белән ул
тереклеккә терәкме?..
Татыгач җирдә яшәүнең
михнәтен вә ләззәтен,—
үлчәүләр тигезләшкәнен
күрәме Адәм заты?..
«Без монда кунак кына, дип—
бу өч көнлек дөньяда»,—
яшәсәң дә, Җан—мәңгелек,
Өмет шәмен шул яга...
Шул Өмет нуры үлемнән
курку хисен дә баса.
Дөнья күптән бетәр иде,
шул инану булмаса...
Шушы изге Иман хисен
тәрбияләргә ничек?
Нинди яңа теләк кабызып,
нинди сиратлар кичеп?..
Юк!—«яңа теләкләр» түгел,
искеләрен яңартып
Һәм гыйбрәт алып Бүгеннән
яши башларга вакыт!..
Мәхәббәт һәм өмет нуры
яктыртып барса юлын,—
мильон иблис тә җиңәлмас
Җир кызын һәм Җир улын...
Кешедә бар тагын бер көч—
коткаручы бер чара:
Бәхет сакчысы булырлык—
Чама хисе ул,Чама...
Һәрбер азгын уй-теләкне
чикли торган тылсым ул.
Әхлак кысасы сагында
Һәрдәм уяу торсын ул...
Кешелекнең төп байлыгын—
бөек мәдәниятен—
Фәлсәфә, Дин, Фән, Мәгърифәт,
Сәнгать, Әдәбиятен—
әнә шул изге хисләрне
тәрбияләүгә җигеп,
ничәмә гасырлар буе
килгән ул Кеше—җиңеп...
Көч-җегәр алып Җиреннән,
мәхәббәт алып Күктән,
яңадан туарга тели
Кеше үзе дә күптән...
Әнә ул тезләнеп җиргә,
сәлам бирә Кояшка.
Күңел кыллары нечкәреп,
таң нурына тоташкан.
Ул—Җир Улы,
ул—Җир кызы,
ул—Кеше, илгә терәк.
«Җиргә мин кирәкме, белмим,
әмма миңа Җир кирәк»,—
дип пышылдый иреннәре,
үкенә, үзен тиргәп,
үтенә ул ярлыкауны,
күз яшен түгеп җиргә:
«Кичер Син хаталарымны,
гафу ит мине, Җирем!
Сиңа тамган кендек каным,
тамган бит-маңгай тирем...
Нәфес түгел, Намус икән
яшәүнең төп мәгънәсе...
Намус тамыры өзелсә,
Җирдә юк төпләнәсе...»
.....................................
Ачыдан ачы гыйбрәт бу,
сыналу булмый төче.
Өметне өзмик, ниһаять
Чын Юлын табар Кеше...

## Гыйбрәт

Талап түгел—Хезмәт белән
яшәгәнне Җир кичерә...
Итагать ит Табигатькә,
рәхимле ич ул Кешегә.
«Төрле чагы була...» дисең,
ә үзең соң нинди, Кешем?
Җирдә тыныч яшим дисәң,
изге булсын Уең, Эшең.
Саклый белсәң Җирне—яшә,
яклый белсәң Җирне—яшә!
Рәхәтләнеп эшлә, тир түк,
ертлач кына булма, берүк!
...Аллаһ белән элемтәгә
керәлмаган вак бәндәләр
әшнәләшеп—тик үзара
җепләр белән бәйләнәләр...
Алар уйлый: яшәү өчен
нәфес белән «бизнес», имеш,
дәртләндергеч төп этәргеч
булып саналырга тиеш...

Инде җәйге фасылны да
«кысып» файда сава алар.
«Акча янга кала» диеп,
канга агу сала алар.
Вакыт белән шаяруны
Галәм сизми, дип уйлыйлар:
Яз җитүгә, кеше саен
бер сәгать вакыт урлыйлар...
«Вакыт парадоксы» дигән
хикмәт серен белсә һәркем,—
гомер ритмы бозылганын
тоеп яшәр иде һәркөн...
Хәйлә түгел—Намус кына
аклый акыл өстенлеген.
Комагайның бүксәсендә
үсә рухый мескенлеге...
Нәфес түгел—Намус кына
саклап тора Дөнья көен.
Көе киткән мәгыйшәтнең
бәясе сукыр бер тиен.
Эзәрлекләп торса әгәр
бәндәләрне рух коллыгы,
тәмугка әйләнә аның
бар рәхәте һәм муллыгы.
Ни файда бар—бу тормышның
мәгънәсе юк, дип йөрүдә?!
Гомернең мәгънәсе—аңа
үзең бер мәгънә бирүдә...
Яшәү фәнен аңлар өчен,
Дин дә кирәк, Диамат та...
Тереклекнең тылсым-сере
ачылыр фәкать кыяматтә...
Эзлисе юк—күз алдында
Рухы катыш Матдәсе дә:
Шуннан гайре ни эләксен
тән белән җан җәтмәсенә?!.
...Океан бай ул агымнарга—
«сулына» да, «уңына» да...
Хакыйкать тик бирәү генә—
мәңенә дә, унына да.
(Укучым аңлар дип уйлыйм
эчкерсез бу әңгәмәне.
Дин серен дә, Фән серен дә
ача торыр Галәм әле...)
«Күктән иңдерелгән Канун
Нигә, дисәң, Җирдә нигез?!.»—
«Аягың—Җирдә, башың—Күктә,
шуңа күрә—Таләп тигез!..»
Җир дә, Күк тә—уртак Оя.
Җир кешесе—Галәмнән ул...
Җир шарының күчәренә
Нур-җеп белән бәйләнгән ул...
Күкләр «язган» Кагыйдәгә
иярә бел—артыр көчең.
Бәлки ...Җирдә язылган ул,
Күк рәхмәтен татыр өчен?!.

Күкләр Канунын да бозма,
«Миңа җайсыз ул» дип кызма...
Олыла Җир канунын да—
Син бит әле Җир «кулында»...
...Судан көлмә—нык сусарсың,
җилдән көлмә—җилгә очарсың.
Аккаенга якма кара,
юкса, каргышка дучарсың...
Чишмә-суны былчыратма,
җир-туфракны борчыма син.
Каныңны тый—кирәгеннән
артык хәтта үрчемә син.
Күзәт серле сырлар эзен—
ачылыр «өченче» күзең...
Барып җитәр һәр Йөрәккә
тик йөрәктән чыккан Сүзең...
Дуслар белән туганлашып,
туган белән дуслашырга
вакыт сиңа!—Шул хыялны
чынга ашыр бу гасырда...
...Күктән бер сөрелгән идең,
инде Җирдән сөрелә күрмә!
Хәят нурын җиргә чәчкән
даһи Сергә омтыл, үрлә...
Шул бөек Сер сине дә бит
китерә уй-хәрәкәткә...
Уйлан, Кеше! Уйсыз калсаң,
таруың бар һәлакәткә.
Тарат Җиргә сафлык белән
Гаделлек энергиясен!
Шул бурычны үтәсәң тик,
булалырсың Җир иясе...
Ашкынсаң да йолдызларга,
Җирдән кубып китәлмассың.
Икар сыман—Кояшка да
имин барып җитәлмассың...
Сөрелмә дә, куылма да,
сүрелмә дә, суынма да,—
Син үзеңне-үзең яшәрт,
үзең белән Җирне яшәт!
Тазарыр Җир, узар дәһшәт,
күкләр күкрәр, яшен яшьнәп,
явар яңгыр коеп-коеп...
Ял иткәчтен оеп-оеп,
уяныр Җир җегәр тоеп...
Таң-кояшка карап Кеше,
яңабаштан чыгар юлга.
Акыл—башта, хис—йөрәктә,
тормыш—мәрхәмәтле кулда.
Син туарсың өр-яңадан,
гафуланып Җир-анадан.
Җир яралган—Дәвам өчен,
Галәм сыный—Адәм көчен...
Хуҗа булып тик үзеңә,
кал мәңгегә Җирдә, Кешем!!.

*2004—2005.*



Зиннур
Хөснияр

# КОЗГЫННАР ЙОЛДЫЗ ЧҮПЛИ[1]

РОМАН

## Карга көтүе

Очты-очты, каргалар очты, авыллар очты, шәһәрләр очты... алар артыннан кешеләр очты. Кыскасы, авыллап—давыллап очты болар... Кошлардан кала, барысы да берзаманны арып туктадылар. Кара каргалар, ала каргалар, сыерчыклар, чыпчыклар, саесканнар, чәүкәләр исә һаман очтылар да очтылар.

...Кара каргалар бала чыгаруга ук, үзләре арасында сәер хәлләр башлануын сизеп алдылар. Үзләренчә фикер дә йөрткән булдылар, аптыраштылар, шаккатып та карадылар, әмма барыбер уртак бер акыллы нәтиҗәгә килә алмады, бахырлар. Эш шунда иде ки: кукәйдән яңа борын төртеп чыккан бер кара карга баласы үзен гаҗәп сәер тота, ул бер дә башка кара карга балаларына охшамаган. Бу кара карга баласының анасы—зур кара карга да—аптыраган булды, әмма ничек кенә аптыраган булып кыланмасын—ул һич кенә дә эчкерсез түгел кебек, барыбер сере булгандыр аның, төп гаеп ана каргада шикелле иде...

Гаеп шул: менә дигән сөлектәй кара карга егетләре була торып, нигә, нигә әле ул,—жир бит!—башка кош егетләре белән әвәрә килгән!!! Әнә хәзер оясындагы бер җан иясенә карасын: ни кара карга түгел, ни чын чәүкәгә дә, козгынга да, кыскасы, шайтанына да охшамаган!.. Холкы нинди булыр әле тагын! Анысы бераз үсә төшкәч күренер... Әйе, бер караганда, әгәр дә ул адәм затыннан булса, ана карганы шул рәвешле гаепләп тә булыр иде төсле кебек. Ләкин ул бары тик карга гына лабаса! Оясына берәрсе үз күкәен салып киткәндер дә... Бәндәләр карыннарында йөрткән газизләрен чүплеккә яки балалар йортына ыргыткан шикелле...

Чү! Тукта! Кырт кын гаеп ташларга ашыкмый торыйк әле...Бәлкем, ана «Карга грибы» йоккандыр... Белмәссең, белмәссең! Бу замандамы?!! Янкилар

[1] «Терсәк сугышы» роман дилогиясенең икенче китабы. Журнал варианты.

Зиннур ХӨСНИЯР (1961)—*прозаик; «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

котыра-котыра алар очып килгән жылы якларга атом бомбалары ташлый! Грипп кына түгел, яна төрле вирус барлыкка килеп,«Карга сифлисы» дигән авыру килеп чыкса да шаккатырлык түгел бит!!!

Ә хәзергә очты-очты каргалар очты... Авыллар очты, шәһәрләр очты, бомбалар очты һәм кешеләр...

• • •

...Әкбәровнын көне иртәдән жан кыю белән башланды... Алай булырга тиеш түгел иде, югыйсә... Бу эш уйламаганда-көтмәгәндә килеп чыкты. Киресенчә, нәкъ менә бүген буйдак егетнен тормышында зур үзгәреш, борылыш булырга тиеш иде ләбаса! Монда жан ияләре канынын ни катнашы бар сон, Ходаем!

Киче дә бик матур башланган иде бит канә! Энгер-менгер белән үк, май урларга барган ата мәче сыман кача-поса, тол хатын янына килде. Көндез үк сөйләшеп куйдылар. Бүләккә дип бер кочак чүпрәк-чапрак та сатып алды. Бүтән вакыт, «ужымга» кереп чыкканнан сон, һәркайсынын өстәлендә акча гына калдырып киткәли иде. Кичә, гомердә булмаганча, махсус ниятләп, чүпрәк жыйды... Башка чакта култык астына коньяк ише эчемлек кыстыра яки затлы коры шәраб ала иде.

Сонгы араларда сөйгәне Гөлйөземгә карата суынып йөри Барый. Гаепнен кемдә икәнлеген белми, әмма жанын битарафлык пәрәвезе чорнап алуы хак. Бу халәте егетне куркыта, юлын аркылы кисеп чыккан кара мәчедән дә артыграк шүрләтә һәм ул алай булуын үзе дә теләми, ары бәрелә, бире сугыла, күнел күзенә төшә башлаган энгер-менгерне якты өмет нурлары белән тутырып, мен төрле шик-шөбһәләреннән котылырга, арынырга тели, тагын да дөресрәге, тыпырчына, бәргәләнә иде.

Ул үзенен жир өстендә нык басып торганлыгын белә, алдына куйган максатларына ирешәчәген анлый. Ләкин шул ук вакытта байлык-муллыкнын, кесә тулы акчанын һәм хәтта дан-шөһрәтнен генә барыбер күнел тынычлыгы алып килмәячәген дә чамалый.

Адәм баласы үз гомерендә бер генә тапкыр булса да коштай талпынып алырга тиеш... анын яраткан кешесе булырга тиеш. Бәхетле адәм баласынын...

Барый Әкбәров акылсыз малай түгел. Байлык һәм дан-шөһрәт тавынын ин очына менеп утырып та, әгәр Табигать-Алланын ин бөек хисеннән—мәхәббәт тойгысыннан мәхрүм буласын икән, әлеге алтын тау башында сина һичшиксез шыксыз булачак! Әнә шул шыксызлык өркетә дә инде аны. Ә кемне булса да яратамы сон ул? Бәлкем, Табигать-әнкә аны бу хистән мәхрүм иткәндер? Анын тынгысыз, ярсу жанына андый нечкә хис орлыкларын салып вакланып тормагандыр!

Барый кулы белән тотып карамыйча ышанмый. Һәм үз-үзен инандыру өчен төрле ысулларны файдалана. Хәер, төрле дип... бу очракта анын ысулы бер генә бугай инде: Гөлйөземне башка кыз-хатыннар белән чагыштырып карау. Һәм ул карый да: өйрәнә, жентекләп чагыштыра...

Барый Әкбәров үзенен кача-поса «наташалар белән маташуын» әнә шундый фәлсәфә нигезендә анлатырга тырыша. Үз-үзенә инде билгеле... Һәм шулай иткәч, кылган гөнаһлары да акланадыр сыман иде.

Без үзебез сокланган кешеләрне түгел, ә безгә һушлары киткән кешеләрне яратабыз дигән бер акыллы баш. Наташа атлы бу яшь тол хатын, кыз-кыркынны авылда калдыру өчен һәм хатын-кызга эш булсын дип, махсус оештырган колхоз йортындагы тегүчеләр остаханәсенә халләрен белергә Барый абыйсы килеп керсә, каушавыннан ике бармагын бер итеп тегеп куя торган иде. Кулында кайчы тоткан чагы булса, бармакларын турардай булып онытыла, бинадагы электр уты кинәт кенә сүнеп, яктылык һәм нур бары тик анын

зур зәңгәр күзләрендә генә янып кала иде. Моны иптәшләре дә белә, моны колхоз рәисе үзе дә сизә.

Ел ярым тирәсе элек Наташаның Степаны үз каберен Чечня җирләрендә табып, шунда ятып калды. Җаны сагыш белән тулган яшь бикәчнең шул рәвешле ирен юксынуымы бу, әллә инде уенчак күнеленең азынасы килү галәмәтеме? Ул хәтлесен иптәш кызлары да белми, җитәкче абыйлары да тәгаен генә әйтә алмас. Әлбәттә, Наташа үзе дә чамалап бетерми. Шулай да?..

Кем үз гомерендә мәхәббәт татымаган, шул яшәмәгән, диләр. Мәет кенә булган, тере мәет. Әлеге гыйбарә-теорияне Әкбәров яхшы белә, мәгънәсенә дә төшенә. Дөнья белән Мәхәббәт һәм Ачлык идарә итә дигәнне дә ишеткәне бар аның. Әйе, ач эт күзенә карап тора, ачлы-туклы халык сарык көтүе хәлендә... Монысы аңлашыла . Ә мәхәббәт? Гөлйөзем?.. Барыйның әлеге гыйбарәне соңгы шөребенә чаклы сүтеп бетереп, тикшереп карыйсы килә. Дөньяның күп кенә могҗизалары аның өчен балачакта әбисеннән ишеткән матур әкият кенә кебек. Башкортларның арба тәгәрмәче уйлап табуларына ышанмаган шикелле, һәр нәрсәгә дә аһ-ваһ итми, бик шаккатып тормый. Аның өчен бу дөнья сораулардан бигрәк гел җаваплардан гына торадыр сыман иде бит?!.

Ә мәхәббәт?..

Гөлйөзем?..

Аның моңа һаман тәгаен генә җавап бирә алганы юк. Һәм шуңа эче поша да инде. Нәкъ менә шул сәбәпле кичә кич яшь хатын катына килде дә инде буйдак исемен йөртүче Барый абзагыз Әкбәров. Әйе, шуңа күрә чуала ул һәм үзенең «уҗымга йөрүләрен» әнә шундый зур фәлсәфи фикер-нәтиҗәләр ярдәмендә ныгытып та куя.

Ләкин барыбер... барыбер кемнедер яратасы килә егетнең. Шулай диюгә, күз алдына капылт кына Гөлйөзем килә дә баса. Ә Барый аннан курка. Үзеннән түгел, ияләнеп, күнегеп китүеннән курка. Бик гади генә ияләшеп, Мәхәббәтне татымый калырмын, дип курка.

Наташа кич буе Барый бүләк иткән күлмәкләренең әле берсен, әле икенчесен киеп карады. Адәм күрке чүпрәк, ди. Төскә-биткә һәм гәүдәгә болай да сөбханалла гына булган яшь хатын да курчак, курчак та курчак иде. Күз карашларының янып-янып алулары, яңа кием кигәч, өй буенча очынып-очынып йөрүләре Барыйның күңеленә хуш килде. Юк, дөрес аңлагыз, үзен әллә кемгә куеп, үзе алган чүпрәк-чапракка сокланып, аларның нәкъ менә аның бүләге булуына хушланмады Әкбәров. Ул кич буе бары тик матурлык кына карап утырды. Яшь хатынга сокланды, җаны эреп, шулчаклы рәхәт, ләззәтле булып китте аңа кайбер мизгелләр дә... Әллә Мәхәббәт дигәннәре?!.

...Тулып җитешкән түгәрәк Ай төн уртасында тәрәзәдән кереп (пәрдәсен дә тартып куймаган мәхәббәткә сусаган хатын), буяулы идәнгә тәгәрәде. Өй эче гөлт итеп яктырды. Шул яктылык Барыйны да уятты. Ул, борыны белән хатынның ике күкрәк арасына төртелеп, йоклап киткән иде. Уянгач та кинәт кенә һушына килеп җитә алмады, беркавым хәрәкәтсез ятты. Иреннәре хатынның тыгыз күкрәкләренә тиеп алды. Наташаның тәме бүтән, башка төрле иде. Тел белән тоеп булса да, әмма шул ук тел белән әйтеп, аңлатып биреп булмаслык чит, ят тәм иде бу. Ул шундук кискен генә борылып, сары йонлы мари мәчесе кебек тынсыз гына йоклаган кызга аркасын куеп ятты.

Мари авылында песиләр һәммәсе дә бер төрле сары була. Татарларда мәчеләр аклы-каралы. Әллә ягы белән генә шулай микән? Ә урыс авылы Бурянда песиләр нинди төстә соң әле? Барый беркавым шуны исенә төшерергә тырышып ятты да, үзалдына көлемсерәп куйды: алар кечкенә юлбарыс балаларына охшаган, комсызлар, караклар. Бурян урыслары, җиңел тормыш

эзләп, шәһәргә күченеп китә, мәчеләрен үзләре белән алып тормыйлар, тегеләре кыргыйлаша. Әллә ул җан ияләре киләчәк язмышларын алдан ук сизенеп, урман-кырларда япа-ялгыз каласыларын белеп, юлбарыска охшап туалар микән?

Тәмсез тоелган тәмнән соң Наташаны тагын кочарга теләге сүрелгән иде. Шуна күрә песиләр дөньясына кереп китте ул, яна шөгыль тапты. Аннары беркавымнан үзалдына: «Мәхәббәткә бар да мишәйт итә икән»,—дип сукрана-сукрана торып китәргә уйлады. Шул мизгелдә мари кызы, муенына йокы аралаш кайнар беләген салып, аны бастырыклап куйды. Кайнар беләк пешерсә дә жылына алмады Барый, кызнын кулын дорфа гына читкә этәреп, идәнгә сикереп төште. Урамда каргалар тавышы ишетелә, авыл әле уянмаган. Каргалар каркылдавы күнелгә тия. Бигрәк тә бүген. Барыйнын кәефе шәп—мәхәббәттә ачыш ясаган көне. Ул, үзе белән алып килгән мылтыгын кора-кора, урамга чыкты һәм ишегалдына аяк басуга, багана башларында тезелешеп утырган карга көтүенә төбәп атып та җибәрде. Иртәнге тәмле йокысыннан уянасы килмичә тыныч кына изрәп яткан авыл сискәнеп китте, өй түбәләре урыннарыннан кубып, күккә күтәрелгәндәй, тәрәзә пыялалары чатнагандай булды, мари урманы артыннан сыртын күрсәтергә әзерләнгән кояш, куркуыннан, беркавым тоткарланып торасы итте.

Комбайнчы Валерийнын—халык телендәге исеме Бәлүк—хатыны Нәчтә жиде айлык корсаклы булып, тан белән җиңелчә генә кысталып, лапас ишеге артына чүгәләгән иде; ату тавышыннан коты ботына таба тәгәрәп, лап итеп үзе юешләгән җиргә утырды, капылт кына эче борырырга керешә һәм ул, әле беренче бәбиен генә алып кайтырга йөргән Бәлүк хатыны, әллә куркуыннан, әллә каты авыртудан чырылдап кычкыра башлады.

Этләр өрмәдә, аларнын койрыклары бот арасында иде.

Бәлүк үзе дә йокламыйча ята, ана торып, комбайнын кабызырга да вакыт житкән иде. Кичтән Бачылый белән шәп кенә кәгелгән, башын сүтеп алып, анын урынына тегермән ташы кигертеп куйган кебек: мендәрдән күтәреп алып булмый. Аты-юлы белән Бачылыйны сүкте: бу хәлгә ул гаепле иде. Эш болай булды: алар кулга кул сугышып бәхәсләштеләр, имеш, Бәлүкнен малае ничек, ни рәвешле туачак? Дөресрәге, Нәчтәгә хастаханәдән: «Үзен таба алмасан, кесарево ясарбыз»,—дигәннәр. Бәлүкнен мондый ят сүзне монарчы ишеткәне юк иде, сәер булса да бик кызык тоелган иде: кесарово! Әллә нинди чит сүз шунда! Малай дөньяга аваз салуга, бүтән телдә сөйләшеп китмәсә ярый инде дип уйлады ул. Бу шик-шөбһәләрен Бачылыйга да чишә. Ул гыйлемлерәк икән, Бәлүк шулай диюгә:

—Беләсен килсә, кесарево корсакны яру дигән сүз була ул!—дип шәрехләп тә бирде. Нәкъ менә шул нәрсә араларында бәхәс кузгатты да инде: хатыннын корсагын аркылыга ярачакнармы, буйгамы? Бачылый үзенекен әйтә: буйга ди, Бәлүк үз ягына каера, анынча корсак аркылыга ярылырга тиеш. Мин әйткәнчә булырга тиеш бит инде канә, чөнки малай минеке бит, дип уйлый ул. Алар барыбер уртак бер фикергә килеп бетә алмыйча, кул сугышырга булдылар. Кем отыла—шуннан бер читүк көмешкә! Бәхәсне исә бер чирек белән ныгытып, пичәтләп тә куйдылар. Әмма берсе дә соныннан Нәчтәнен Бачылыйга корсагын ачып күрсәтерме, юкмы икәнлеге хакында уйлап карамады.

Ә иртәгесен!.. Иртәгесен бары тик Бачылыйны сүтеп кенә жиңеләеп булыр төсле иде. Тик ишегалдында хатынынын кычкырган тавышы аны шундук айнытып җибәрде—ул караватыннан идәнгә мәтәлде һәм тышка атылды.

Нәчтәне вакытыннан алда тулгак тота башлаган иде. Мондый вакытта нәрсә эшләргә кирәклеген белмәгән яшь ир урамга чапты, бәхетенә күрә, алар урамында аты-юлы белән сүгенә-сүгенә «УАЗиг»ы тирәли әйләнеп

йөргән Әкбәровка тап булды. Тәгәрмәчләрнең дүртесен дә кайсыдыр явызы тишеп киткән. Бәлүк, атылып, аның янына килде һәм сулышы кабудан ашыга-ашыга мәсьәләне аңлатырга кереште. Әкбәров тагын бер тапкыр ачу белән тәгәрмәченә тибеп куйды да:

—Комбайның кайда соң?!—дип кычкырды. Комбайн авыл башында гына булып чыкты. Ул, кызу-кызу, шунда таба атлады.

Барый комбайн кабызып маташкан арада Бәлүкнең хатынын, кул арбасына утыртып, алып килеп тә житкерделәр. Куларба тәртәсенә Бәлүкнең әтисе Сәнүк карт үзе кергән. Бәлүк арттан этә, әнисе Соня апай, авып китмәсен дигәндәй, килененең иңбашыннан тоткан. Сәнүк карт—кечкенә генә буйлы, какча чырайлы, ләкин бик елгыр, тере бабай—атлаган саен башын артка таба кыегайтып, ялварулы тавыш белән килененә эндәшә:

—Нәчтүк, киленкәем! Малай апкайт инде син, яме.

Арттан этүкән Бәлүкнең моңа эче поша күрәсең, ул аңа:

—Житте инде сиңа! Малай кайгысымы соң әле монда! Үзең исән-сау котыл, килен, диген!—дип, шелтә белдерә.

Ләкин картның һаман үз сүзе:

—Әгәр малай булса... Мин аны председатель итеп куйдыртам, Әкбәровны Казанга зур эшкә алгач!..

Аның шулай дип әйтүе юкка гына түгел, чөнки мари авылында колхоз рәисен аеруча яраталар, олысы-кечесе хөрмәт итә. Сүз саен: «Барый Хазиевич безгә авыз тутырып ипи ашата!»—дип мактап кына торалар. Тик... тәгәрмәчләрне кем тишкән менә?..

Участок хастаханәсенә ике төрле юл алып бара: берсе туры юл, ләкин ул таштан түшәлсә дә бик сикәлтәле, икенчесе әйләнечтәнрәк салынган асфальт юл. Әнә шул асфальт юлга кадәр ярты чакрымлап басу аша ат юлыннан чыгасы бар. Барый комбайнны басуга таба каерды. Басуда котырып арпа үскән. Колхоз жирләре түгел бу, фермер Сибгатуллинныкы. Барый эшкә килгәнче үк, аның әтисе өстеннән югары оешмаларга йөри-йөри, талаша-сугыша торгач, Сибгатуллин үзенең фермер хужалыгы өчен жир алуга ирешкән иде. Шул жирендә менә ничә ел рәттән әйбәт арпа үстерә. Үстерү генә түгел бит әле, аны жыеп алып, урнаштырасы да бар. Сибгатуллин моның да жаен тапкан: уңышны Казанның сыра заводына тапшыра, чөнки арпасы аларның таләпләренә туры килә. Әнә, өр-яңа «КамАЗ» алып кайтып куйган. Тик нишләп машинасын басуда калдырган ул? Эшкә чыкканнар дисәң, иртә әле? Төнлә кайтмаганнар дисән—басу юеш.

«Ниемә дип баш катырам соң әле, миңа димәгәе ник чукынып китми шунда Сибгатуллиннары. Барыбер сытып ташлыйм әле мин аны!»—дип, ачу белән сүгенеп куйганнан соң Әкбәровка жинелрәк булып китте. Тик күңелгә этлек дигән нәрсә бер кереп урнашсамы? Ул этлек барыбер үзенекен эшләргә тиеш. Югыйсә, Барый булмый бит ул...

Зур тизлек белән басу юлыннан чапкан комбайнның бер канаты яр буендагы машинаның әржәсе кырыена эләгеп китте. Дынк иткән каты тавыш чыкты, нәрсәдер шатыр-потыр килде, яна машина урыныннан кузгалып, тирән елгага таба тәгәрәде. Бу вакытта комбайн асфальт түшәлгән юлга күтәрелеп маташа иде инде.

Хуш, асфальтка чыкты инде болар, хастаханәгә дә ерак калмады, барып житәрләр әле, шәт. Ә менә өр-яңа «КамАЗ» әлегесе минутларда маңгае белән сусыз елгага төшеп кадалган иде. Руль артында йокымсырап утырган Сәмигулла уяу кеше булып чыкты: машина яр буена житәргә дүрт-биш адым кала, арткы тизлеккә салып, муфтадан аягын алды. Машинаның баруы кимеде кимүен, тик ул барыбер ярдан аска мәтәләсе иде инде.

Сәмигулла үзенең исән калуын балалары хакына, дип уйлады, алгы тәрәзәгә маңгае белән төртелеп алган Гөлйөзем дә берданбере—Әнвәре бәхетенә дип юрады.

Машинага шактый зыян килгән. «Өр-яңа «Нива» белән түлисе булыр инде моны Сибгатуллинга!»—дип офтанды Сәмигулла. Ә Гөлйөзем куркуыннан чытырдап ябышкан, бер кулы белән маңгаен тоткан, икенчесе Сәмигулла муенын кыскан. Муен сөякләре чатыр-чотыр килсә дә, Сәмигулла аралanырга ашыкмады, бу вакытта икесе дә исән калганлыкларына тәмам ышанып беткәннәр, әмма бик каты каушаганлыктан, әле дә булса зур аптырауда иделәр. Ин беренче булып Сәмигулла аңына килде, ул борыны белән хатынның ике күкрәк арасына төртелгән хәлдә иде. Йөзенә яшь хатынның ачык изүеннән кайнар дулкын бәрелә. Бу дулкын әле яңа гына ис-хуш җыйган Сәмигулланың янә аңын алды: ул, әсәрләнеп, хатынның изүен аерып төшерде, халат төймәләре борчак кебек машина тәрәзәсенә сибелде. Теге дулкын тагын да кайнарланды, Сәмигулла, үз-үзен белештермичә, юеш борыны белән ике күкрәк арасына кадалды. Әле генә теге дөньяның капка төбенә килеп җитә язган хатын, кытыклануга түзә алмыйча, чырык-чырык көлә башлады.

Җил исеп куйды. Яр буенда укмашып үскән тал агачлары салмак кына, бер җайга гына тирбәлергә кереште.

Бу мизгелләрдә өр-яңа машинаның ватылу кайгысы да онытылып торды. Ә югыйсә... югыйсә бар да юктан гына башланган кебек иде, шайтан алгыры!..

Сибгатуллинга яңа машина алырга Сәмигулла үзе ярдәм итте. «Сөйләшеп куйган машинам бар, хатын җинел машина дип, авыз суын корыткач, «КамАЗ»га барган җиремнән, «Нива» га атланып кайттым, «КамАЗ» ны син ал»,—диде. Фермерга йөк машинасы кирәклеген ишеткән иде ул... Икәүләшеп барып машинаны алып кайттылар. Кайтуга Сибгатуллинга кереп, яңа машинаның юл тузаннарын «юдылар», аннан соң шул ук машинага утырып Сәмигулла үз авылларына кайтырга чыкты. Бу вакытта төн уртасы җитеп килә иде инде. Мари авылы аша узганда Сәмигулла бер капка төбендә Әкбәров машинасын күреп алды һәм Барыйга булган үче исенә төште. Ул, «КамАЗ»ын авыл башына чаклы чыгарып куеп, кире килде дә, үткен без белән тәгәрмәчләренә төртеп чыкты, аннан соң, ачуы моның белән генә басылмагач, башында яңа план туды. Яшьтәшләр булып, ун ел бер парта артында ыштан төбе туздырсалар да, Барый белән дус түгел алар, хәтта бер-берсен сөймиләр, күралмыйлар. Ләкин моны берәүгә дә сиздергәннәре юк, икесе дә эчтән генә көяләр.

Сәмигулла туп-туры урманга таба чапты. Капкасын дөбердәтеп Гөлйөземне уятып чыгарды. Ике-өч көн элек кенә Барый килеп, сине генә сөям дип антлар эчеп, тиздән өйләнешәчәкбез дигән хәбәр дә калдырган иде, шуңа күрә ул әүвәл исерек Сәмигулланың янагына чылтыратырга уйлады, тик ниндидер эчке хис аны туктатып калды һәм шул мизгелдә үк күңеленә хәерсез шик кереп оялады. Кызыксынуы бик көчле иде, бәлкем, көнчелегедер... Әмма икеләнүе дә юк түгел. Шулай да ул беркавым аптырап торды-торды да, вакыт таңга таба авыша башлаган бер мәлдә, халат өстенә юка куртка гына элеп, «КамАЗ» кабинасына үрмәләде.

Алар дамбадан Сибгатуллинның арпа басуына борылуга, сизгер хатын Чудрасала ягында—тау башыннан төшеп килгән комбайнны күреп алды. Комбайн таң белән кырга кузгалган, димәк, наряд бирелгән диген сүз. Мари кызының җылы кочагыннан нишләп болай иртә торып китәсе итте икән соң бу Әкбәров?

## Гөлйөзем

Үз хисләремнең колы дип уйлый башлаган идем инде үземне.
...Үч минем тарафтан бу юлы алынмый калды. Тагын Барый! Рәхмәт төшкере—коткарды бугай ул мине... Үч алу гөнаһыннан... Ә үзе гөнаһлы булып калды, бахыр...

Сәмигулла хатыны Рәзифәне Мөхәммәт катына җибәргән! Мин үзем дә Сәмигулладагы үчемне аның хатыны аша алырга уйлап тора идем. Рәзифәнең иләс-миләс икәнлеген сизә идем бит. Ләкин исәбем монда һич кенә дә Мөхәммәтне катнаштыру түгел иде!

Чү, туктале, тукта, Гөлйөземкәем!.. Тагын алдашасың бит! Җае туры килсә, син дә рәхәтләнеп Мөхәммәтне файдаланган булыр идең ләбаса! Һәм ничек кенә әле!

Һай, Аллакаем, үзең саклый күр бу бәндәләреңне җир йөзендәге гөнаһлардан!... Юкса, алар муеннарына чаклы батып бетәчәкләр ләбаса!

Хәерле булсын, тагын аклану бугай инде бу... Адәм баласы үз-үзен аклау өчен ниләр генә кыланмый...

Ә Барый?... Ни генә әйтсән дә аның шулай эшләве мине чиксез куандырды: без икебез дә бер үк төрле уйлый башлаганбыз икән.

Хәерлегә булсын, ярабби!..

Барый белән икебез дә бер төрлерәк фикер йөртәбез икән... бу юкка гына түгелдер...

Яше авыша башлаган кыз-хатын мәхәббәт, ярату хакында акыл белән уйлый башлый икән инде ул. Бәлкем, җүләр чакта гашыйк булып, шул вакытта сөйгәненә кушылырга кирәктер кыз балага?.. Тагын сорау инде... Сорау артыннан сорау...

## Җилләр исә, комнар күчә

Яшьрәк чакта, уку йортын тәмамлагач, авылга кайтырмын да, шулай итәрмен, болай итәрмен, дип корган планнарны тормыш һәр җәһәттән үзгәртеп тора. Чөнки үзе дә үзгәручән ул тормыш дигәнең. Шул исәптән кешеләр дә. Кешеләрне тормыш үзгәртәме яисә киресенчә :кешеләр тормышнымы? Гади генә фәлсәфә кебек, югыйсә.

Кайчандыр Ил дигән Ил бар иде. Аннары аны «Республика» дип атадылар. Хәзер—филиал. «Үзәкнең Казан геополитик филиалы...» Кемнәрдер Идел-Кама филиалы дип тә атый. Кыскасы, кем ничек дип әйтергә иренми инде.

Филиал... Бу яна сүзне халык бигүк аңлап бетермәсә дә, әйтелешенең татарча булмавы күпләрнең күңеленә хуш килде. Өстәвенә бер академик-галим, аз-маз тарихта чокынгалаганнан соң, «филиал» дигән сүзнең чын төрки-татар сүзе булуын исбатлаган иде. Исбатлау бик гади, нәкъ халыкча: «Фили» дигән сүздән кыскартылып, чак кына үзгәртелеп ясалган ул. Урыс-француз сугышыннан хәбәрдар булган кеше өчен бигрәк тә гади инде: Фили авылында Кутузов хәл җыеп, французлардан качып яткан. Хәлиткеч тарихи кинәшмә дә Фили авылында узган. Ә Кутузов—татар малае—андый зур кинәшмәне бары тик татар авылында—Филида гына үткәрә ала! Бу аксиома инде! Каршы да килеп маташмагыз! Ин әһәмиятлесе: ул бик гади, аңлаешлы. Шул сәбәпле, «филиал» сүзен Казан халкы үлеп ярата. Казанда урнашкан зур идарәне Дәү филиал дип, аннан да бәләкәйрәкләрен кече филиал яки «фили» дип кенә җиффәрәләр иде. Фили башлыкларын исә «Филләр» дип әйтү гадәткә кереп киткән һәм шул гадәт кайбер тишек күзәнәкләр аша канга ук үтеп керергә өлгерде.

«Филләр булгач, нигә Һиндстан түгел?»—дигән фикерләр дә йөрде. Чөнки

сирәк-мирәк «Татарстан» диючеләр дә очраштыргалый иде әле. Бу фикерне, ягъни Һиндстанны аеруча бер жирән башлы депутат куәтләде. Анын уенча, бу нисбәттән ныклы дәлиле дә булып, ул шуннан гыйбарәт иде: «Һиндстанда кызлар бик матур була, кинолардан күрсәтәләр бит. Жырлары да ярыйсы гына. Без һинд кинолары карап үстек. Безне яшьлегебездән аерырыга бирәүнен дә хакы юк!»

...Кәефе әллә ни шәптән түгел. Берәр куян ише нәрсә атып алса, бәлкем, күнеле күтәрелер. Барыйны тан белән фили башлыгы чакыртып алды. Хәзер анын шуннан кайтып килеше. Урман аша узганда туктап алырга да исәпләде, башлык әйткән яна фикер-идеяләрне дә акылы кабул итә алырлык хәлгә килер кебек.

Фили башлыгы—Барый Әкбәровнын туган тиешлесе. Чакырта дигәч тә, мунча кертергә түгел икәнлеген белеп барды ул. Зәет Вәлиевич өстәвенә өлкән Әкбәров сөйрәп чыгарган кадр да иде әле. Читләргә ышана торган замана түгел. Бар ышанычлы терәк—туганнарда, малайларда, кыз-кияүләрдә.

—Ике колхозынны тиз генә тотып берләштерергә кирәк!—диде Зәет Вәлиевич.—Заманнын нинди икәнлеген сина анлатып торасы юк.

—Нишлим ди мин ул чаклы авыллар белән?

—Тире жыеп, күн эшләрсен!

—Юк, чынлап та?

—Күрмисенмени?! Ишетмисенмени бер дә! Дөнья кая таба бара! Колхозлар юкка чыгачак, жирләр сатылып бетәчәк!

—Ну...

—Күтенне у, энекәш! Файдаланып калырга кирәк! Акча күктән яумый ул! Бетә дигәч тә, ике-өч елга сузылыр әле. Акылы булган кешегә шул вакыт бик житкән инде, зур имчәкнен сөте дә күп була анын.

—Син нәрсә, мине монда тагын өч ел черетергә жыенасын мыни әле! Казанга китәргә йөргәнемне беләсен бит!

—Китмисен син беркая да, энекәш! Син монда кирәк. Озакламый Франциядан яна чабышкылар партиясе кайтачак. Кабул итеп алырга жыен.

—Мина булганнары да житеп ашкан!

—Ә Мәскәү! Мәскәүне нишләтмәкче буласын! Сөйләштек бит: атлар белән Мәскәүне алырга барачакбыз!

—Син дә Һади абый кебек бер хыялый инде, Зәет Вәлиевич! Мәскәү имеш! Мәскәү күз яшьләренә ышанмый ул, беләсен килсә! Исләре китәр бик!

—Как-так син, энекәш! Күршеләрне онытты́нмыни!?.

—Син дә Мәскәүне атлар белән яуларга уйлыйсын инде алайса, кызык... Тик хәзер, Зәет Вәлиевич, самолет ярышлары модада бит инде.

—Мәскәү өчен ат һаман да важно әле. Ат ярышларын уздырып, алар үзләренен элек ничек итеп Казанны басып алганнарын искә төшерергә яраталар. Атлар Казаннан булса, бигрәк тә хушлары китә инде аларнын!

—Ат модасы бетте, самолетлар бит хәзер, Зәет Вәлиевич!

—Ат модасы бетсә, тарих модасы бетмәде.

—Әгәр татар атлары Россиядә беренче урынны алса?

—Алай булмаячак. Беркайчан да...

—Нигә алай дисен әле?

—Дим шул.. Син ин яхшы атларынны барыбер общий казанга салырга тиеш буласын. Икенче төрле әйтсән, сборный командага. Атларнын милләте юк аларнын. Атларнын гынамы?!. Адәм балаларынын милләте дә көчләп юк ителеп яткан заманда...

—Бу сорауны мина бирәсенме, Зәет Вәлиевич?

—Юк, сина түгел. Беркемгә дә түгел. Бу сорау жавап таләп итми, энекәш...

Зәет Вәлиевичның урындыгы шыгырдап куйды. Ул шактый гына авыр гәүдәле кеше: чак кына кыймылдауга, урындыгы һәм өстәле берьюлы селкенгәндәй була да, читтән карап торган кешегә хәзер үк урыныннан кузгалып китәр төсле тоела. Аның бу гадәтен белмәгәннәр, хуҗаның сүзе беткәнгә исәпләп, үзе дә кузгалып китәргә әзер торыр, тик әйтеп каласы сүзе бетмәгән очракта кызу-кызу сөйли башлар шикелле иде. Барыйга Зәет Вәлиевичның һәр хәрәкәте таныш булганлыктан, ул урыныннан кымшанмады.

—Теге авылларны да миңа кушып, бака боткасы ясамакчы буласың мыни! Беләсең бит, болай да эшем муеннан ашкан минем: тау башына күченәсебез бар.

—Нием калган сиңа ул тау башында?!

—Уйланган бит инде ул. Халыкны да күпме ризалатып йөрдем, беләсең бит.

—Беләм, энекәш, беләм, яхшы беләм. Тик шуны аңламыйм: нигә кирәк ул сиңа?!

—Миңа гына түгел, сиңа да кирәк ул, Зәет Вәлиевич. Халык хәзер элеккеге түгел, грамоталыланды, күп белә, күп күрә башлады. Күтенә утырсын өчен бер бутап алу кирәк аны. Шуннан соң тынычлана ул. Аннары инде синең Казансу буендагы чиркәү чаклы коттеджларыңны да, бүтән гаепләреңне дә күрми башлый. Тикшереп йөрергә просто вакыты калмаячак аның.

—Беләм, беләм. Барый туган, максатың ул гына түгел синең! Шыттырма!..

Барый ирен чите белән елмаеп куйды. «Кемне-кемне, сине хәйләләп булмаганын беләм бит инде мин, Зәет абзый»,—дип уйлап куйды ул үзалдына. Әмма һаман берешәсе килмиме, йә башлаган сүз-фикерен аста калдырасы килмәүдәнме—үзенекен тукыды:—Точно әйтәм мин сиңа! Әнә, кара. Колхозның унтугыз исереген үзем лично автобуска төяп барып айнытып кайттым чуаш карчыгына. Хәзер айныдылар әнә, күпне күрә башладылар. Акыл сатарга остарып киттеләр. Элек мин шуларга бер ярты куеп, тау-таш җимерттерә идем. Хәзер аркылыны буйга алып салсалар да, акча сорыйлар! Менә бит ул!..

Зәет Вәлиевич көлемсерәп куйды. Барый энесенең сүзләре хак булса да, ниятенең бүтәндә икәнлеген чамалый иде ул.

—Анысы шулай да, тик алай гына да түгел икәнлеген белми дип уйлыйсың инде син. Авылны тау башына күчереп тарих ясыйсың килә инде синең. Бабаң кебек.

Барый аңа каршы берни дә җавап бирмәде. Үзен аңламаганга Зәет абзыйсына ачуы да килми аның. Аның бу симез гәүдәле элеккеге спортсмен абзыйсы еракка китәчәк, үсәчәк әле. Һәм үз артыннан энесен дә ияртәчәк. Чөнки Барыйның әтисе алдында аның гомерлек бурычы бар, Хаҗи ага туганнан туган энесен сәнәктән көрәк ясаган кеше бит. Теге чакта ук.

Барыйның артык сүз куертып торасы килмәдеме:

—Ярый, синеңчә булсын,—дип ризалыгын белдерде. Бу сүзләрдән соң элеккеге көрәшче утырган урынында янә кузгалып куйды, аңа ияреп йомшак күн урындык һәм өстәл дә кымшангандай булды.

Фили башлыгы, үзенең җиңгәнлегенә, дөресрәге, хаклы икәнлегенә ишарәле-ишарәле дә, шуңа басым ясап та кызу-кызу сөйләргә керешә. Барый чамалады: Зәет абзыйсы үз сөйләгәненә үзе дә ышанып җитми, бәлкем, шул рәвешле Барыйдан һәр җөмләсенә хуплау да көтә торгандыр, андый чакта кызу сөйли ул—стенага борчак белән аткан шикелле:

—Соң, менә үзең уйлап кара: дөньяларның кая таба барганын хәзер сиңа бирәү дә әйтеп бирә алмый. Бүген болай, иртәгә тегеләй. Киләчәк турында кайгыртып калырга кирәк. Тора-бара ул синең зурайтылган хуҗалыгыңның җирләрен унга-сулга ата, өләшә башлаячаклар. Ә җир ул—дөньяда иң зур капитал! Җирсез пычагым да кырып булмый! Вакыты җиткәч, без аны

үзебезнеке итәчәкбез. Эшләр шуна таба бара бит, энекәш. Ашарына сорамаячак бит ул! Акыллы кешеләр шулай итә. Ә хәрәкәт булсын өчен безгә авылларны күчереп йөртү генә житми әле! Шул чабышкыларын белән шаулап барып, даулап жинеп кайтсан, ә! Әкбәров тик ятмый, Әкбәров эшли, молодец, диячәкләр! Ә авыл күчерү дигәннән... Эшлә син аны, хәрәкәт файдалы нәрсә ул. Нәрсә, халык бик риза түгелме?

—Хәзер сорап та торган юк инде. Тау башыннан бер ун ин шәп участокны сайлап, бүлеп куям да күченү башланганлыгын игълан итәм. Тизрәк әйбәтрәк жирне эләктереп калу өчен талаша-талаша күченәчәкләр. Хәер, кайберәүләр белән аерым сөйләшеп чыгасы булыр әле.

Икесе дә бер-берсенә карап елмаешып куйдылар.

—Колхозны алып бару барыбер жинел түгел хәзер. Койрыкны сыртка саласы булыр.

—Әле хужалык рәисен... и тагын берничә кешене генә туйдырырлыгы бардыр ич?

—Сукыр күздән дә яшь чыгар ди. Әгәр чынлап торып... Беләсен, мин елап йөрергә яратмыйм.

—Белеп тор, энекәш, сине зур тәхеткә бары тик атларын гына илтәчәк!

—Атка атланып дисен инде алайса?.

—Атка атланып... Ниме.... Израэль ничек анда?

—Асфальт салынгач, кышын да шунда гына яшәп ятарга уйлыйлар бугай,— диде Барый Зәет Вәлиевичнын соравына каршы. Өстәп тагын нидер әйтергә уйлаган иде, тик тыелып калды: фикере очланып житмәгән идеме—бу хакта артык сүз куертып торасы килмәде. Югыйсә, икесенен дә бу темага сүз куертасылары килә, хәтта бик килә, тик жепнен очын ничек сузарга гына белмиләр. Израэль Исаевич—күрше яһүдләр бистәсендә җәен яшәп китә торган шәһәр кешесе. Шәһәрдә фәнни институтта галим булып эшли. Күптән түгел генә Барый анын белән умарталыкта корт балы чөмереп утырды. Халык санын алу вакыты иде бу. Шуна күрәдер дә, сүз гел сәясәт хакында барды бугай.

—Әгәр юл салсагыз, кышын монда яшәргә әзер без,—дип куйган иде шул чакта Израэль Исаевич.—Кстати, перепись вакытында мин татар булып язылырга уйлыйм әле. Әнә, керәшен татарларыгыз урыс булып йөрсеннәр!

—Әгәр сезнен бистәгә чаклы асфальт юл салсаммы?—дип сораган иде Барый. Израэль Исаевич әлеге жавапка күптән әзер иде, күрәсен, уйланып, икеләнеп тормады:

—Әгәр юл салсагыз гына да түгел, үзебез теләп татар булып язылырга әзер без.

—Аннан сон гомерегез буе татар булып йөрер идегезме?

—Без урыс булып та, мари булып, чуваш... тагын әллә кемнәр булып әле... хәтта негр булып та языла алабыз. Тик без барыбер еврей булып калачакбыз!!! Ә сез татарлар алай түгел. Әгәр татар кызы урыска кияүгә чыга икән, анын баласы да, үзе дә шундук маржага әйләнәчәк. Татар егете маржага өйләнсә дә нәкъ шундый ук хәл булачак!

—Ничек?

—Тора-бара чукыначак ул барыбер!

Әкбәров, шул сөйләшүне исенә төшереп, көлемсерәп куйды..

Фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Израэль Исаевич Вороновнын яратып әйтә торган бер сүзе бар: «Жилләр исә. Комнар күчә...»

• • •

...Хак булып чыкты: соры карга баласы, чак кына тернәкләнүгә, үзенен ямьсез холкын күрсәтә башлады. Башка балаларга караганда ул ин күп ашаучан

булып чыкты, анасы алып кайткан җимне иң беренче булып каптырып алырга гына тора, җим ин әүвәл үзенә эләкмәсә, дөнья бетереп каркылдый,—ул нәкъ бүтән карга балалары кебек кычкыра, талаша, башкалар авызыннан тартып алмыйча һич кенә дә тынычланмый.

Каргалар ел саен оя кора торган агачлыкта тынычлык бетте. Кара булмаган кара карга баласы, тамагы ачуга, башкалар кебек сабыр гына әнкәләре кайтканны көтеп ятмый—дөнья бетереп кычкырырга керешә. Балаларына җим эзләргә дип киткән каргалар, бәла килгәндер дип белеп, тизрәк агачлыкка ашыга, кайтып керсәләр, бернинди куркыныч юк, кара булмаган кара карга баласының бары тамагы гына ачкан, шуңа күрә дөнья куптарган!

Башка кара каргаларның тәмам үзәгенә үтте инде ул...

Кече Филидан кайтышлый Байтимер юлы урман аша уза. Урманга кергә, Барыйның күнеле кытыклана башлый: кеше башлы теге бүре белән тагын очрашасы һәм бу юлы аны атып үтереп, җанына кереп оялаган хәерсез хистән котыласы килә.

Ләкин бүген никтер аның ялгыз башы гына урманга керәсе килмәде. Капылт борылып, яһүдләр яшәгән авыл ягына каерды. Израэль Исаевич кичә кич Казаннан кайткан булырга тиеш, вакыты булса, ул Әкбәровка утырып басу-кырларны әйләнеп йөрергә ярата, соңыннан алар һәрвакыт умарталыкка туктап, корт балыннан авыз итәләр, вакытлары иркенрәк чакта мунча яктырып, дөбер-шатыр чабынырга яраталар.

Зәет Вәлиевич бая Израэль хакында сүз чыккач, көрсенеп: «Сина ФСБ дан килгәннәре юкмы?»—дип сорап куйган иде. Көтелмәгән әлеге сәер сорау Әкбәровны аяктан ега язды: «Нишләп миңа ФСБ дан килергә тиешләр соң әле? Аларга эшем төшкәне юк минем!»—дип, гаҗәпләнүен белдерүгә, Зәет Вәлиевич, бик тырышып, сүзне икенчегә борып җибәрде. Хәзер Барый шул хакта аптырап уйланып бара һәм бу турыда фили башлыгыннан төпченмәвенә үкенә. Инде ул урман юлына кермичә, Израэль Исаевичка табан борылуына үкенә үк башлады. Әле соң түгел иде, машина капма-каршы якка борылды.

Казанга якын булгач, яһүдләр авылда яшәп яталар. Дөресрәге, аларның барысының да эш урыннары шәһәр җирендә, яшәүләре халык теленә «Тол-Әби» («Тель-Авив») дип кереп калган шушы авылда. Күрше авылларда гына татарлар җир сөреп гомер итә, марилары да шушында. Яһүд белән урыс—шәһәрдә. Тик аерма шунда гына, урыс шәһәргә бөтенләй качты, нигезен төбе-тамыры белән йолкып алып китте, яһүднең исә эше генә шәһәр җирендә. Һич аңлап була торган халык түгел үзләре. Шулчак Мөхәммәтнең дус шагыйре сөйләргә яраткан берничә юллык шигырь исенә төште.

Иван—Абрам Тәхет бүлә,  
Кан чыгарып талаша.  
Гали дәшми, әле һаман  
Ул аларга булыша  
Һәм ярарга тырыша.

Иван—Абрам Бәхет бүлә,  
Тир чыгарып көрәшә.  
Гали дәшми, ул юаш шул.  
Куркып тора янәшә,  
Үксеп тора янәшә.

Иван—Абрам Ил бүлешә,  
Кисәкләп алып тора.

Ә Гали калып тора,
Ул янә калып тора,
Ул һаман калып тора...

«Яһүдттән дә акыллырак халык юк дөньяда»,—дип, сүз кушканы бар Барыйның Израэль Исаевичка кайчандыр, умарталыкта хәл җыеп ятканда булды бугай мондый сөйләшү. Аның бу сүзләреннән карт яһүд рәхәтләнеп көлде, аннары, күз яшьләрен сөртә-сөртә: «бар дөньяны кайнатып яталар дисенме?»—дип гөрелдәде.

—Кайнатса да.... акыл белән.

—Палестинада яшәүче мөселман булсаң, алай димәс идең син, әлбәттә.

—Анысы сәясәт. Пычрак сәясәт.

—Мировая гегемония,—дип өстәп куйды Израэль Исаевич һәм беркавым зур зәңгәр күзләре белән аяк астындагы үләнгә төбәп карап торды, аннары борынын тартып куйды. Нинди дә булса җитди нәрсә хакында уйлаганда аның борыны гел юешләнә иде. Шуннан соң көтелмәгән берәр фикер әйтеп куячагын көт тә тор инде син аның....

—Еврейларның һәммәсенә дә берүк төсле карарга ярамый. Еврей күп вакыт үз башын үзе ашый. Троцкий, Зиновьев, Каменевлар...

—Әйе, аларның үзләрен дә юк иттеләр.

—Хәзер дә шулай әле ул. Киләчәктә еврей халкын олигархлар харап итәчәк! Урыс илендә еврей революция дә ясарга тиеш түгел, олигарх та булырга хакы юк. Рәсәй еврей өчен куркыныч ил. Урмандагы кыргый аюның холкын аңлап булмаган кебек, аның да холкын аңлап бетереп булмый. Еврей үзе уйлап чыгарган яңа тәгәрмәч тора-бара аның үзен дә сытып китәргә бик мөмкин. Олигархлар шуны аңламыйлар. Яңа Сталин килеп чыкмас дип, кем гарантия бирә ала бу илдә!

Умарталык тау битенә урнашып, аннан Байтимернең бәрәңге җирләре дә аермачык булып күренеп тора. Әңгәмәдәшләр икесе дә сүзсез калдылар һәм карашлары таудан түбән тәгәрәп төшеп китте. Байтимер халкы бәрәңге алып мәш килә. Күбесенең бакчасы лапас артында гына, бәрәңге җирләре тау битендә. Әнә берәү уфалла арбасына ике капчык бәрәңге салган да, аны тауга каршы өстери. «Сиражи карт,—дип уйлап куйды Барый эченнән.— Нигә азаплана инде бу алла бәндәсе! Иртәгә, шимбә көнне үк, шәһәрдәге биш баласы кайтып, бәрәңгесен күз ачып йомганчы алып бирәчәкләр бит инде, югыйсә! Юк, ул үзе азаплана, балалар кайтканчы бераз булса да киметим,—ди торгандыр. Тау астындагы капчыкларына караганда, бераз гына казылмаган инде. Таң белән кузгалгандыр».

Урман буендагы кәрдегә чабышкы атларны алып кайтып тотыргач, иң куанган кеше Сиражи карт булган иде. Ул үзе яшь чакта колхоз атларын караган. Хәзер колхозның сыңар аты да калмады. Халык сугыш вакытындагы кебек яңадан уфаллага күчте. Җәй көне бәрәңге араларын да кул белән китмәнли, икенче катын сукага үзе җигелеп, тартып сыза.

—Рәхмәт, улым!—дип сөенде Сиражи карт, чабышкы атларны кайтарткач.— Авыл атсыз була алмый ул! Дөрес эшләдең, маладис!—дип, чын күңеленнән сөенгән иде. Иртән идарәгә бәрәңге ташырга ат сорап та килгән иде картлач. Халык аннан егылып көлде. Аннары:

—Чабышкы атлар бит алар! Берсе-берсе миллион сум тора!—дип, картны өенә кайтарып җибәрделәр. И моңсуланды шул чакта Сиражи карт. Әйтәсе сүзен дә әйтеп китте: «Ат булып та аны җигәргә ярамагач инде... ничек була инде ул? Хуҗа Насретдин ишәге кебек килеп чыга бит инде бу! Үзең ишәккә атлан, үзең капчыгыңны аркаңа ас... Ат була торып та, аны җигәргә ярамагач инде... Ничек була инде бу?»

Израэль Исаевич та шул хакта уйлап тора торгандыр кебек тоелды Барыйга. Иптәшенең уе башкада икән:

—Синең теге чиркәвең.... тау башына салыначак мәчетең ни хәлдә соң әле?—дип сорады ул.

—Чиркәү дә түгел ул, мәчет тә. Бар диннәрне... дөресрәге, төп өч динне берләштерәчәк храм.

—Хаталанасың син, Барый Хаҗиевич.

—Бар диннәр дә үзара тату яшәсәләр... начар булырмы?

—Начар булмаячак булуын. Тик аңла: хәзер Рәсәйдә идеология калмады. Элек коммунизм бар иде. Ул идеология иде әле. Шул идеология белән балалар тәрбияләдек. Идеология булмауның иң коточкыч ягы шунда: тәрбия мәсьәләсенә зыян киләчәк! Ә буыннарны җүнләп тәрбия кыла алмасак, һәммәбезгә грош цена! Цивилизациянең төп эше—үзенә лаеклы алмаш тәрбияләү. Татарларга тәрбия эшендә нигә ислам динен файдаланмаска! Үз динен христиан да эшкә җиксен, башкалары да!

—Вахабизм, дини секталар үрчесен дипме?

—Рәсәй—кампанияләр иле. Чиктән чиккә ташланырга яратабыз. Ә нигә уртадан гына бармаска? Тәрбия эшендә ислам диненең энҗеләрен генә булса да файдаланып була лабаса! Урысны урыс итеп, татарны татарча, еврейны еврей итеп тәрбияләргә кирәк. Бу, туган, аксиома! Һәр халык үз динен эшкә җигәргә тиеш...

Бу сөйләшү аның күңеленә шом салды. Аннан соң карт яһүднең әлеге фикерендә ныклы мантыйк та бар. Гомумән, аңа каршы бәхәсләшү һәрвакыт файдасыз була.

* * *

Урман авызына килеп җитәрәк, Барый, машинасын туктатып, биштән корыла торган мылтыгын күн капчыгыннан салдырып алды һәм әзерләп утыргычка куйды. Ялгыз башы гына урманга мылтыксыз кергәне юк инде аның: һәрвакыт бала башлы бүре белән очрашуны көтә, дөресрәге, ул аны үзе күптәннән, бик күптәннән эзли, әгәр очратып шул хәерсез җанны атып ала алса, бу—Барый өчен гаҗәп зур җиңү булачак, аның шомлы җанына мәңгелек тынычлык индерер әле, бәлкем...

Мылтыкны алдан әзерләп кую күңелен тынычландырды. Япон джибы сикәлтәле урман юлында бала бишеге кебек йомшак кына тирбәлеп бара, Барый үз уйларында. Ә уйлар исә бүген, Зәет Вәлиевич белән сөйләшүне исәпкә алмаганда, бик тәмле, татлы иде чукынчык!.. Гөлйөземгә өйләнәм, дигән катгый карарга килгән мизгелләр бит. Өйләнәсе килгән егет кәҗә сатып өйләнә дигәндәй, Барый ничә еллар инде үз күңелендә бәйдә торган үзсүзле, киребеткән һәм карышкан кәҗә бәтиен башы-аягы белән сатып җибәрде—ныклы фикергә килде: ул өйләнәчәк һәм бары тик Гөлйөземгә! «Малаемның әнисенә өйләнәм!»—дип, үзалдына шаяртып көлемсерәп тә алды. Бу өйләнү түгел, сөйләнү генә булып калмасын өчен, Барый әлеге эшне озакка сузарга ярамаганын да чамалый һәм урманны чыгуга, кесә телефоныннан Мөхәммәткә шылтыратырга, яңалыгы белән уртаклашырга, берочтан Гөлчәчәк хакында аның да фикерләрен тартып карарга ниятләде. Италиядән кайтканнан бирле Мөхәммәт белән күрешкәннәре юк әле. Сәфәрдән кайтуга мин дә өйләнәм, дигән шикеллерәк фикер әйткән иде бит дусты. Барый шулай дип уйлауга, күз алдына капылт кына Сиринә Самуиловна килеп басты. «Неужели, шул Баба Яганың кармагыннан ычкына алырсың?»—дип, дусты хакында борчылып куйды. Өстәвенә узган күрешүләрендә Хәниф Хатыйпович та Мөхәммәт белән ул хатын арасындагы мөнәсәбәтләр хакында бик җентекләп сораштырып торды. Серле дә, шикле

дә иде бу кызыксынулар. Хәниф Хатыйпович Филнең сыртында ук утырмаса да, анын койрыгына тотынган кеше һәм бик каты ябышкан, филнен нечкә койрыгы шартлап өзелмәсә, үз теләге белән генә гомер ычкындырачак түгел ул аны... мәнге ычкындырачак түгел ...

• • •

...Байтак вакыт узуга карамастан, урман Пиратнын эт канын кысрыклап чыгара алмады. Чөнки урман хәзер кыргый түгел, ул кешеләр кесәсендәге шырпы кабы кебек таушалган: таланган, тапталган, аударылган, киселгән. Пират кешеләрне сагынып яшәде. Төннәрен авылга да еш килгәләде, абзаркура тирәләрендә дә йөрде, берзаман хәтта төнлә лапас артларында куна торган булып китте, тан беленә башлауга, урманына кире чаба иде. Монын шулай икәнлеген авылда бер генә кеше сизенде, Пират аны белмәде, авылга килүен дәвам иттерде. Ә теге кеше аны авыл этләре янына йөри дип уйлады һәм авылдагы бәйсез этләрне атуны үзенә максат итеп куйды. Авылда ул кешегә каршы авыз күтәреп беркем бернинди сүз әйтә алмый.

Үзе аркасында эт туганнарына нинди зыян килүен аңлый алса, әлбәттә, ул авылга аягын да басмас иде. Хужаларын тынламыйча, бәйдән ычкынып, бер рәхәтләнеп уйнарга атлыгып торган эт-жаннар кырыла торды. Этсез яшәүгә өйрәнмәгән Байтимер халкы атылган этләре урынына яңаларын (шәһәрдән зур бәяләргә усал овчаркалар, тагын әллә нинди токымлы кыяфәтсез, әмма бик явыз этләр алып кайтып бәйләделәр. Зур акчаларга алынган булгач, бу этләрнең бәйләре бик нык, ансат кына ычкынырлык түгел иде инде) булдырдылар. Акчага алынган этләр чыннан да бик зәһәр, куркыныч һәм дәһшәтле иделәр. Әгәр дә мәгәр аларнын һәммәсе ычкынып, берьюлы урамга чыксамы?!.

Бер дә бер көнне муенчагын салуга ирешкән Актырнак кушаматлы бер чибәр авыл эте Пиратка «кияүгә» чыгып алды. Галәттә, берьюлы бишәралтышар бала китерә торган Актырнак бу юлы бер малай гына алып кайтты. Ул малай бик шук булып үсте, күзе ачылып, аяклары йөгерекләнүгә, капка астыннан урамга чаба һәм шул гадәте бәйдәге әнкәсен еш кына хафага сала иде. Шулай бер чыгып китүендә көчек кире әйләнеп кайтмады. Бик зарыгып, борчылып көтте анын кире кайтуын Актырнак. Вәсвәсәләнгән әнкә соң чиктә түзә алмады, ничек итсә итте: бәйдән ычкынды да, лапас астыннан гына шуып чыгып, баласын эзли китте. Авыл буйлап озак эзләде ул аны, жимерек бәрәңге лабазларына керде, ферма буйларын айкады—көчек табылмады. Бәлки өйгә кайткандыр, дигән ниндидер эчке сиземләү белән авылга таба чапты. Шулчак аяз көнне яшен яшьнәгәндәй булды, нәрсәдер шарт итте, Актырнак, чак кына ял итеп алырга уйлагандай, комлы юлга сузылып ятты. Юл буйлап озын кызыл тасма сузылды...

Малай бу вакытта авыл янәшәсендәге мари урманында куян боты кимерә иде. Куянны үзе тотмады ул тотуын, аны бер зур эт—бүре сыйлады. Алай мәрхәмәтле булгач, ул анын артыннан ук тагылып йөри башлады. Абый-эт сүз әйтмәде, каршы килмәде, киресенчә, ул мона үзе дә бик шат бугай.

Малайларны уеннан, шуклыктан тыеп буламыни соң инде: көчек урманда да үзен бик чос тотты, вакыт-вакыт абыйсыннан аерылып та калгалады. Шундый чакларнын берсендә көчек кешеләргә тап булды, дөресрәге, кешеләр аңа тап булдылар. Урман аланында ялтыравыклы матур машина тора. Ишекләре ачык. Яшь бер кыз үлән арасыннан жиләк эзли. Менә ул машинага сөялеп торган егеткә таба борылды да:

—Син быел мине джунглига алып барам дип обещать иттең!—диде, чытлыкланып.

—Безнен свадебное путешествие Кипрда узачак!

—Юк, юк! Мин джунглига барырга телим! Анда барып Мауглины күрәсем килә!

—Мауглины? Әгәр дә ул чынлап та шунда икән, мин сина Кипрдан сон ул Мауглины тотып алып кайтып бирәм! Читлеккә ябып асрарсын!

—Ха! Сина тагын Мауглины тотарга!

—Мин үзем тотмасам, башкалар тотып бирер! Акча күрсәтсән, Мауглины гына түгел, фил көтүен дә самолетка төяп җибәрерләр!

—Мактанчык син!—дип куйды кыз һәм урман аланын янгыратып көләргә кереште. Анын бу көлү тавышы һәрвакыт егетнен кендегенә генә килеп кадала, ана рәхәт булып китә, каны кызыша башлый. Ул кызны эләктереп алды, жай гына, саклык белән генә йомшак үлән өстенә салды һәм шашып-шашып үбәргә кереште. Кызны әллә аландагы үлән кытыклады, әллә егетнен яна чыгып килгән сакалы—ана рәхәт иде, ул чырык-чырык көлде, иркәләнде, иркәләде.

—Мин үзем Маугли сина, мин—кыргый!—дип сөйләнә-сөйләнә егет кызнын киемнәрен аерып төшерде. Мондый кыргыйлык кызга да рәхәтлек бирә иде, күрәсен, ул чырык-чырык көлүен дәвам итте. Алан кырыенда утырган карт нарат, нәрсәдәндер оялгандай, чал башын түбән иде. Анын ин югары ботагына кара карга баласы килеп кунды. Кара булмаган кара карга баласы текәлеп-төбәлеп аланга, алан уртасындагы үләндә аунаган ике адәмгә карап торды-торды да, каркылдап кычкырып җибәрде. Урман әүвәл карга баласынын тавышын үзенә йотты, аннары беркавымнан аны кайтаваз рәвешендә, Гомәр Хәйәм робагые итеп, алан өстенә сипте:

> —Чынлап та шундый түбәнлекме?
> Каны кайнаган тәненнен колы бул әле!
> Бу дөньяда берәүнен дә хәтта
> Теләгенен сусавын басалганы юк әле!

Кызнын кинәт ачыргаланып кычкырган тавышына карт нарат, куркынып, чал башын югары күтәрде, анын шәрә ботагына кунган кара карга баласы чак кына егылып төшмәде. Алан кырыенда ялтыравыклы машина күреп туктап калган көчек исә куркуыннан чинап җибәрде. Югыйсә, мәсьәлә бик гади, куркырлык, кот очарлык берни дә юк иде: кызнын йомшак җиреннән бер өер кырмыска көтүе генә йөгерешеп узды. Киресенчә, карга баласыннан, карт нараттан һәм көчектән дә бигрәк, кыз үзе курыкты, чөнки аяусыз кырмыска көтүе тешләпме тешли, өстәвенә кызыкай үзенә нинди дошман һөҗүм иткәнен анлап та җиткерми—ин куркынычы әнә шул булгандыр да әле.

Пират якын-тирәдә генә йөри иде, көчекнен ачыргаланып чинаган, җылаган тавышына ул уктай атылып аланга килеп җитте, килеп тә җитте, аны-моны абайлап өлгермәгән егеткә ташланды да. Тегесе куллары белән этнен һөҗүмен кире кага-кага ничек итсә итте, тиз генә машинасына кереп утыра алды һәм ишекләрен шартлатып ябып куйды. Ә эт усал иде, бу мизгелдә анын тамырларын тутырып бүре каны ага башлаган иде, ул машина тәрәзәсенә сикерде. Бу егетнен тагын да котын алды, ул җәһәт кенә машинаны кабызды да, кызны да онытып, урман юлыннан ачыклыкка томырылды. Эт-бүредән, бәлки, ул чаклы ук курыкмаган да булыр иде егет кисәге, ләкин анын да җан җирен нәрсәдер бик каты тешли, үзәкләрен өзепме өзә инде, нәкъ менә шуннан өректе ул. Һе, кырмыска, ин усал, зәһәр ана кырмыска икәнлеген белсә, сыпырып кына төшергән булыр иде дә бит! Әнә шул белмәве, билгесезлек котын алды шәһәр малаенын!.

Пират, көчеген ияртеп, урман ешлыгына кереп югалды.

Ә кыз тәнен кырмыска һөҗүменнән коткару белән мәшгуль иде.

Бу вакытта Бари да аланлыкка житеп килә, каршысына томырылып чабып килгән джипка чак кына юл биреп өлгерде. Юл бирер өчен читкә каерды, машина буявында агач сыдырган урыннар калды. Ачудан, кире борылып, үз биләмәсендә чатыр чабып йөргән чит машина хужасының арт сабагын да укытырга уйлады, ләкин аланлыкта эт өргән тавыш аны бая ук сискәндереп куйган һәм ул, бар ачуларын онытып, шунда ашыкты. Мылтыгы әзер иде инде.

Аланлыкта жүләр кеше кебек сикергәләп йөргән ярым шәрә кызны күреп, Әкбәровыбыз өнсез калды. Теге чакта нәкъ шушы тирәләрдә бала башлы бүре күргәч, һушыннан язган иде. Бүген дә аптырау-гажәпләнүләренең чиге-чамасы булмады, әмма бу юлы кыюланып, машинасыннан төште дә кыз янына килде. Тегесе чит кеше барлыгын абайлагач кына, үзенең ярым ялангач икәнлеген күреп, карт нарат күәсәсе артына посты. Кырмыскалары коелып беткән иде, күрәсең. Барый, кыз янына килеп, аның өстенә үзенең пинжәген япты. Ни булды, дип сорап тормады, каршысына очраган машинаның нилектән томырылып чапканын чамалаган иде инде. Ул кызны машинасына утыртты һәм: «Теге бандитны куып тотыйкмы соң?»—дип сорады.

—Бандит түгел бит ул!—диде кыз. Ана янә жан кергән, бәлки кырмыскалардан котылу сөенеченнәндер, ул чытлыкланып көлә үк башлады:—Булачак киявем ул минем! Атаклы Шаһмәлиев малае! Кабахәт жан! Эттән куркып чыгып качты, артына да борылып карамады! Менә сиңа кияү! Әти иманын укытачак әле аның! Укытмаса, ана үзе кияүгә чыгар!

Кыз бик чибәр, курчак кебек матур. Йөз-кыяфәтенә карап чамалап була: яше егермедән узган, кыланышлары бала-чаганыкы төслерәк булса да, сазаганга охшаган иде..

—Йә, нишләтим мин сине?—дип аптырап сорады Барый.—Кайсы авылдан соң син, булачак кәләш?

—Казан кызы мин! Казанга илт!—диде кыз бер дә тартынып, унайсызланып тормыйча гына. Аннары:—Әти яхшылыгыңны онытмас!—дип тә өстәп куйды.

Барый чарасызлыктан инбашларын сикертеп алды да машинасын кабызды.

—Джип ничего икән синең!—диде кыз, егетне үчекләгәндәй.—Ничего гына түгел ул, ничегоның да ничегосы!

—Анысы ничек була?

—Ничек буламы?—Бу кыз Барыйның эчен пошыра башлады, шуңа күрә ул аны үртәгәндәй.—Жирдә дә йөри, суда да йөзә ала!—дип куйды.

Кызыкай беркавым тын гына барды, аннары барыбер түзә алмады, урман авызына килеп житәрәк янә ачылып китте. Үз хәлен үзе белеп, авызын йомып кына барса да була иде канә!

—Джентельменнар калмады бездә! Ир-ат хатын-кызга караганда да ваграк һәм куркаграк! Их, кайда ул рыцарьлар!

Шушы кыз аркасында тиктомалдан Казан юлын таптарга туры килүенә Барыйның болай да эче пошып бара иде, аның өч тиенлек фәлсәфә сатарга керешүе ачуын гына китерде.

—Ир-атны дуңгыз иткән дә, кондыз иткән дә хатын-кыз! Киресенчә, хатын-кыз калмады бездә! Чүпрәккә әйләнеп беттеләр!—дип куйды ул дорфа гына. Аның бу сүзләреннән кыз жүләр нәрсә кебек чырык-чырык көләргә керешә. Аннары яшь аралаш:

—Дуңгыз диденме?—дип кайтарып сорады һәм урман шүрәлесе кытыклагандай янә чыңларга керешә.. «Көлүе матур икән»,—дип уйлап куйды Барый үзалдына. Тиктомалдан гына аның үзенә дә ничектер кызык булып китте, ләкин барыбер ачылып китәсе килмәде, ирен читләре белән елмайгандай итте.

Кызның көлүе генә түгел, үзе дә гаҗәп чибәр икәнлегенә егетебез бая ук игътибар иткән иде. Ул ара-тирә аерылган изүен каплап куюлары! Үзенең оят җирен болай сәнгатьле иттереп, рәвешен китереп яшерә алу сәләтенә бар хатын-кыз да сәләтле түгелдер!

Тора-бара Барыйның йомык күңеле ачыла башлады.

—Исемең ничек соң синең?

—Аля!—дип җавап бирде тегесе шундук, әйтерсең әлеге сорауны баядан бирле түземсезлек белән көтеп утыра иде.

—Аля гына түгелдер инде?

—Әлфия!

—Исемең матур икән. Мин Барый булам.

—Боря, да?

—Нинди Боря! Барый дидем бит!

—Бааари-и-иии! Звучит!—Ә Боря дисәң ярыймы?

—Бөтенләй әйтмәсәң, тагын да яхшырак!

Бу кыз үпкәли белә торган «нәрсә» түгел иде ахрысы, Барыйның дорфалыгына да, кирле-мырлы җавабына да әлләни исе китмәде. Урман буенда сыер көтүе утлап йөри иде, шуларны күреп, кычкырып җибәрде:

—Кара, кара! Сыерлар!Коровы!

—Ну и что. Үгез дә бар анда!

—Ә үгезләр ничәү? Быков сколько?

—Ничә булсын, икәү генә.

—Два быка! Ике үгез! Шулар бар сыерларны да саклый аламы! Урманда бүреләр бар бит!

—Нишләп сакламасын, саклый...

—Ох! Какой джентельменнар! Настоящий рыцарьлар!

Барый аның әлеге сүзләреннән пырхылдап көлеп җибәрмичә түзә алмады. Тора-бара бу кыз чынлап та аның күңеленә хуш килә башлады. Ләкин Казан читенә килеп җиткәннәр иде инде.

Әлфия, шәһәргә керүгә, төшеп калды.

* * *

Барый туп-туры ат заводына таба юл алды. Үзе оештырып куйган бу утарны «ат заводы» дип ул гына атый. Ат заводы булырга шактый ерак әле. Менә тора-бара кымыз да эшкәртә башласалар... тагын берничә пар гарәп, инглиз-гарәп атлары сатып ала алсалар, авыз тутырып ат заводы дияргә булыр иде аннан соң.

Атларга Гөлйөзем хуҗа. Малае Әнвәр белән көнозын ул атлар янында, урманчылык һөнәрен ташлады.

Урманда үскән кызга, бер караганда, урман-чытырманлыгы, андагы җанварлары: бүре-төлкеләре һәм дә керпеләре якынрак булырга тиеш иде, югыйсә. Юк, Гөлйөземне күбрәк атлар тарта, шулар янында әвәрә килергә ярата, тынгысыз җанына шул рәвешле урын таба шикелле ул. Дөрес, барысын да ташлап, өйдә генә утырасы килгән чаклары да күп була, инде ис-хуш җыя башлаган малаена багышлыйсы килә көннәрен. Әмма бу тулысынча гаилә казанына чуму дигән сүз. Ә алай итәр өчен ул гаиләдә терәк кирәк, дәү мәшәкать—ир заты кирәк. Дөрес, Гөлйөзем башка ир-ат эзләп йөрмәде. Ул барыбер кайчан да булса иләс-миләс Барыеның үз катына киләчәген, китмәскә дип аяк басачагын хатын-кыз сиземләве белән сизенә, күңеле белән шул хәлнең булуын түземсезләнеп көтә иде.

Атлар, атлар... Чиста канлы гарәп атлары үзләренә бер төрле, каннары кушылган инглиз-гарәп чабышкылары алардан аерылып тора. Америка аты... «Американский сэддлбред» дип йөртәләр аларны. Төсе дә үзенчәлекле: туры,

ягъни ялы, койрыгы кара, үзе кызыл. Көрән һәм чем каралары да бар. Бу хайванның холкы бик акыллы, атланып йөрү өчен дә унай, алар атлаган кебек тә түгел, әйтерсең, биеп кенә баралар. Гөлйөземгә бигрәк тә матур итеп бөгелгән муеннары ошый иде.. Холкын аңлап бетереп булмый торган француз юртагы белән чагыштырып булмый инде аны. Ләкин алар бик чыдам. Муеннары да аккош муены кебек озын. Тәртә кебек озын аяклары исә гаять көчле «французларның».

Әнә, гарәп атлары. Болар гаҗәп акыллы атлар, өстәвенә бик чыдамнар да әле! Маңгайлары киң, зур булмаган, тар йөзле. Колаклары кечкенә. Сыгылып торган матур муен белән киң күкрәкләр дә әлеге токымның затлы икәнлеген күрсәтеп тора. Әлбәттә, шуңа да карамастан, «гарәп»ләрнең аяклары искитәрлек көчле түгел.

Әлеге токым атлары койрыкларын югары, дугасыман итеп тоталар.

«Инглиз» белән «гарәпләрнең» каннары кушылгач, инглиз-гарәп токымнары килеп чыккан. Гаҗәп: болары бөтенләй үзгә атлар! Гадәттә, алар туры яки карасу җирән төстә булалар. Аеруча көчле, бик кыю, тик тора белмәс. Ләкин ышанычлы хайваннар! «Инглиз-гарәпләрнең» башлары бик матур, гәүдәләре зур, күкрәкләре киң, әмма чыдам, аяклары озын, нечкә... Гөлйөзем бу атларның күзләрен ярата: матур, мәгънәле, акыллы күзләр.

Кан кушылу нисбәтеннән Мөхәммәтнең үз фәлсәфәсе бар. Италиядә йөреп кайтканнан соң ул һәр нәрсәне чагыштырып карарга өйрәнеп китте әле. Гөлчәчәген дә берәр маржа белән чагыштырып карамаса ярый инде дип борчыла Гөлйөзем. Ышан син ул байтимерләргә! Барый дустына да охшап куйса тагын...

Гөлйөзем шулай уйлый да, тирән көрсенеп куя. Кичә килде бит әнә Барые. Үзе еш-еш сулый, үзе әллә нинди. «Гөлйөзем, без кайчан өйләнешәбез инде?»—ди. Аны бу халәттә күргәч, Гөлйөземнең көләсе килеп китте. Горур Барый исә аның бу көлүен мәсхәрәләү дип кабул итте бугай... Серкәсе су күтәрмәс бәндә! Гөлйөзем аңа бер дә үпкәләми әле, берәү булса, сөйләшеп тә тормаган булыр иде! «Әллә минем хатын-кыз горурлыгым калмады инде?»—дип тә уйлап куйгалый хатын. Әгәр чын ярату үзе булып чыкса!? Бу хакта уйлау күпкә яхшырак, күңеллерәк, рәхәтрәк... Ә уйламыйча гына атларың янында, аларның ялларын тарап, муеннарыннан сыйпап, тыныч кына йөрсәң... тагын да шәбрәге: алдына карап атыңны куаласаң гына?.. Тик нигәдер, гадәттә, атлар янында озаграк кайнашканнан соң, Гөлйөзем һәрвакыт, нилектән икәнлеген үзе дә төшенмичә, Барыен юксына башлый.

Атлар тынычландыру сәләтенә ия, җәя бавы кебек киерелгән нерв җепләре алар янында йомшарып киткәндәй була. Мөхәммәтнең каннар кушылу фәлсәфәсе дигәндәй... Ат белгечләре моны ничек кенә хупласалар да... барыбер Хак тәгалә—Табигать әнкә кануннарына каршы килү ул. Һәр организмга яралганда ук табигый, ыру, кавем дисәк тә була торгандыр,— геннар салынган була, ягъни туганда ук организм туксан процент генофод—байлык белән туа. Ике кавем кушылу аркасында исә әнә шул генофондка зыян килә, алар буталышып бетәләр, ыгы-зыгы һәм чуалыш башлана.

Барыйдан җигәр өчен гарәп аты сорап йөргән, гомере буе атлар янында кайнашкан Сиражи карт та, ат белгечләре дә белми иде бу кадәрлесен! Мондый атларны җигеп булмый, хәтта тимер арбаларга да. Колхоз кырында бәрәңге чүпләргә сәләтсез булган Казан кызлары кебек алар,—дискотекада кәҗә кебек сикерергә, таңга чаклы армый-талмый селкенергә мөмкиннәр,—бәрәңге чүпләүгә килгәндә—нуль! Арка-җилкәләре уклау кебек катачак!

Каннар кушылу бигрәк тә адәм баласының генофондына нык тәэсир ясый: геннар буталышып бетәләр, имгәнешәләр, гарипләнәләр, нәкъ менә шуның аркасында аларның балалары гомер буе рухи яктан да, физик яктан

да зыян күреп яши. Алай гынамы соң әле: элек акыллы бабаларыбыз ул өйләндергәндә, кыз биргәндә милләткә генә түгел, хәтта нәсел-ыруга да бик нык игътибар иткәннәр. Узган гасыр башында һәм аннан да алданрак затлы шәхесләр, генийлар әнә шул татар гаиләләрендә туган. Урыс инкыйлабы һәм төрле репрессияләр аларның башын кисеп бетергән. Шуңа күрә хәзер халык соры массаларга әверелеп бетте!..

Бер караганда, гади генә нәрсә кебек, ләкин алай гади дә түгел икән ләбаса! Халык сарык икән, аның җилкәсенә менеп кунаклаган җитәкчеләре дә шулкадәр оятсыз һәм намуссыз була. Ә «җитәкче» сүзе нәкъ менә шул «җилкә» дигән сүздән алынган да инде! Аксиома...

...Чит ил тормышын күреп кайту үзгәрттеме Мөхәммәтне, әллә Сиринә Самуиловнаның йогынтысы тәэсир итәме шулай, ни генә әйтсәң дә, ул элеккеге кебек Гөлчәчәкнең гүзәл образын тудырам да, сөйгәнем белән кушылып, бәхет дингезенә чумам дип, беркатлы, ләкин саф һәм ихлас уй-максатлар белән яна торган егет түгел инде хәзер. Һай, әйтүче, киңәш бирүче, һич булмаса, колагын борып: «Нишлисең син, егет кисәге! Араңны өз карт хатын белән, яшьлек мәхәббәтең зарыгып көтә ләбаса үзеңне!»—дип кисәтүче юк бит канә! Синең талантыңның нигезендә Гөлчәчәгеңә булган эчкерсез мәхәббәтең ята лабаса!..

Юк шул, тана сөте белән генә керми шул инде ул!..

## «Син—Барый Әкбәров»

Сиражи карт бәрәңге бакчасында җан-тәслим кылды... Уфалласында өчәр кәрҗин бәрәңге салынган ике капчык булган. Кул арбасының тәртә арасында килеш егылып үлгән карт... Йортында гомер буе уфалла тотмаган иде (ат җикте бит, кул арбасының кирәге булмагандыр инде) Сиражи карт... Атын колхозга тапшыргач, каралты-курада арба ише нәрсәнең юклыгы бик тиз үзен сиздерде, кулы балта эшенә дә ябыша иде, арбаны үзе әмәлләде.

Шул көнне ул иртән ат сорап колхоз идарәсенә килгән булган. «Буталып йөрмә әле аяк астында!. Ат юк сиңа!»—дип, аны бригадир кире борып җибәргән. Авыл теленда сүз иясе белән йөрми, Сиражи карт бәрәңге бакчасында кул арбасы тәртәсе астында егылып үлгәч, әлеге, бер караганда бик мөһим дә булмаган вакыйганы,—бригадир сүзен,—бар кеше дә белә һәм һәммәсе дә нигәдер картка ат бирмәгән юньсез бригадирны түгел, ул чакта комбайн белән бала табу йортында йөргән Әкбәровны гаеплиләр иде: «Өчәр миллионлык чабышкы атлар—әрәмтамаклар асрап яткан «перси» авыл кешесенә бәрәңге ташу өчен кәҗә бәтие чаклы гына бер чирле атын да бирә алмаган! Оят кирәк! Сиражи карт рәнҗеп киткәндер әле үзенә! Карт унике яшеннән колхозда кунних булып эшләмәгән булса, бер хәер иде әле! Оят кирәк! Җаны юктыр аның!

Барыйның җаны да, күңеле дә бар! Әмма халык кайгысын урта буын җитәкчеләр генә түгел, хәтта зуррак түрәләр дә киндектән өскә таба җибәрмиләр иде шул инде... Киндек турысына җиткәч, шып тукталып кала ул, киндек чокыры аларның гадәттә бик тирән була!

Барый моның шулай икәнлеген үзе дә яхшы белә, кемдер әйткән яңа ачыш түгел ул. Тик каян белә—анысын тәгаен генә хәтерләми, күпме мәртәбәләр исенә төшерергә тырышып караганы бар инде, һич башына килми. Әллә авыл өстеннән очкан теге кара булмаган кара карга баласы каркылдап—кычкырып узды инде... «Син—Барый Әкбәров. Кеше кайгысын, аларның бетмәс-төкәнмәс моң-зарын киндегеңнән өскә таба җибәреп, йөрәгең белән кабул итмә! Син—Барый Әкбәров бит!»

Барыйның бу хакта уйланганы юк түгел: кендектән өскә китмәгәч, ул йөрәккә генә түгел, акылга да барып житми ләбаса!?

Димәк, шулай кирәктер инде... Өстәвенә, теге кара булмаган кара карга баласы да каркылдагач... Тик ул ямьсез тавышлы карга баласын Әкбәров барыбер атып үтерәчәк әле...

Аристотель адәм балаларының рәхәтен өч төргә бүлгән: рухи, тышкы, һәм тән рәхәте. Өстәвенә һәр кеше дә дөньяга үз күзлегеннән карый. Мәсәлән, елгада тавык батып үлгән ди. Меланхолик өчен бу зур фажига, сангвиникка бу хәл кызык кына, флегматикның ана исе дә китмәстер, мөгаен. Һәр кеше дә үзенең табигый казанында кайный, тышкы тәэсирләр генә аны ул казаннан тартып ала алмый. Күңел киңлегенең каттый чикләре бар. Хәтта бик тырышып жыйган белем дә әлеге чикләрне артык киңәйтә алмастыр. Иң зур рәхәтлек булган рухи рәхәтлек тә һәр кешенең рух көченә бәйләнгән. Бу рух көченең үлчәме гомер буе бер тамга югарылыгында торачак, өстәвенә, томана—гомере буе томана, акыллы исә үлгәнче акыллы булып калачак!.. Кешенең бәхете дә нәкъ менә шуның белән билгеләнә, кыскасы, бәхет кешенең эчке дөньясына үзе туганда ук салынып куелган.

Сәламәт хәерче авыру байдан күпкә бәхетлерәк...

Безнең Барый әлегә сәламәт бай иде.

Борынгы фәлсәфәчеләр фикеренчә, талантлы хәерче талантлы байга караганда хезмәт баскычларыннан күпкә югарырак күтәрелергә мөмкин. Чөнки ул ялагайланудан, тәлинкә тотудан һәм житәкчелеккә ярарга тырышудан тарсынмый. Ул аңа өйрәнгән инде. Ә талантлы бай исә боларның барысын түбәнлеккә санаячак, корсагы кебек бүлтәеп торган горурлыгы аңа, иелеп, башка берәүнең ботинка бавын бәйләргә мөмкинлек бирмәячәк!.. Һәм нәкъ менә шуның аркасында ул арбадан төшеп тә калырга мөмкин...

Безнең Барый яшьтән үк хәерче дә түгел, әлләни череп тә баемаган, әмма түгәрәк башлы, ягъни талантлы кеше иде. Борынгы заман фәлсәфәчеләре, нишләптер, мондый категория кешеләрнең киләчәк язмышлары хакында берни язып калдырмаганнар. Алдагысын күзаллау безнең Барыйга бераз кыенрак булыр инде... Берәр очраклык, язмыш очраклыгы ярдәм итеп куймаса. Белмәссең тагын...

Барыйның дөньяга үз карашы. Мәсәлән, аның уенча, горурлыкның иң арзанлы төре—милли горурлык. Шәхес булган кеше кайсы милләттән булуы белән горурланып, барабан кагып йөрми, чөнки милләттәшләр миллионнарча бит! Шәхес булган зат үз милләтенең житешмәгән һәм көчле якларын күрергә тырыша ул. Ә адәм актыклары, шәхси индивидлары зәгыйфь булу сәбәпле, тизрәк милләт саламына ябышып, быргы кычкыртырга керешәләр, дөбер-шатыр барабан сугып, шуның белән үзләренең табигый көчсезлекләрен һәм дә бушлыкларын тутырмакчы булалар. Мәсәлән, «Кукуруз» күмәк хужалыгына кергән мари авылында ничек «чуваш юкәләре» үсә алсын инде! Ә шулай дип жырлар жырлыйлар бит әле! Менә шул була инде ул иң арзанлы милли горурлык!..

Дөрес, мари халкы юкә үстерергә ярата. Кирәк ул аларга—мунчала ясап саталар, чыпта үрәләр, себерке ясыйлар.

Барыйның үзендә исә табигатьтән салынган горурлык бар. Гәрчә аның бу горурлыгын колхоз рәисе Хажи Әкбәров малае булу белән генә аңлатырга тырышсалар да. Хәер, Барыйның моңа исе китми. Горур дияләр икән, яки түгел дип әйтәләрме, барыбер ләбаса! Гарәпләр коллардан көлеп: «Кол белән шаяртып сөйләшсәң, арты белән борылыр»,—диләр. Шаяртканны кабул итә алмый кол, чөнки горур имеш.

Ул намуслымы соң? Гомумән, нәрсә соң ул намус? Бу хакта моннан меңнәрчә еллар элек тә уйланганнар. Һади абыйлары Барый белән

Мөхәмматкә юкка гына Ницше һәм Шопенгауэр тәгълиматләрен тукымагандыр... Ул фәлсәфәчеләр дә моннан гасыр ярым элек баш катырганнар намус хакында, аның нәрсә икәнлеген аңларга һәм аңлатып бирергә тырышканнар. Тышкы яктан караганда, намус ул башкаларның синең хакында ничек һәм ни дәрәҗәдә уйлавы, күңел байлыгына, мөмкинлекләреңә мөнәсәбәте. Субъектив намус исә кешенең нәкъ менә шул мөнәсәбәтнең ничек булуыннан куркуыдыр.

Бу тормышта кайнар өчен Барый Әкбәровка әнә шуларны белү дә бик җитеп ашкан. Тагын күз күрер әле...

Хәер, Барыйның авылны тау башына күчерергә йөрүе дә үзе хакында фикер тудырырга теләү түгел микән әле?.. Һәм бу фикер аңа болай капылт кына каян килеп кунды соң? Бу фикерне аңа кемдер «төртте» бит?!.

## «Абзый» чакырта

Кара булмаган кара карга баласы бераз тернәкләнә башлау белән үзен күрсәтергә кереште. Сәер һәм бик әшәке холыклы иде ул. Ояда чакта бүтән балаларны кыерсытып тәмам үзәкләренә үтә. Үсә төшкәч, болай да ташка үлчим холкы тагын да бозылды: явыз, усал иде, берәр нәрсә ошамаса, гел чукырга торды, бүтәннәрнең азыгын тартып алды, әллә нинди ямьсез тавышлар белән кычкыра да җитмәсә! Әле монысы баласы гына булган икән. Менә берзаман бала каргалар да әткәләре-әнкәләре белән бергә җим эзләп, басуларга оча башладылар. Юллары авыл өстеннән уза. Карга халкының бер ишесе ияләнгән гадәт буенча юл уңаеннан гына кешеләрнең ишегалларына да төшкәли һәм, хуҗа-фәлән күреп өлгергәнче, тавык бәрәңгеләре белән дә авыз иткәли иде. Менә шундый чакта теге карга баласы иң беренче булып берәр кырый йортның ишегалдына чума һәм, тиз генә томшыгына азык эләктереп, аны кабып йотканнан соң, дөнья беткәндәй каркылдарга керешә. Әлбәттә, бу тавышка өйдән хуҗалар йөгерешеп чыга, әлбәттә, башка каргалар тавык азыклары белән сыйланмыйча кала.

Бу хәлгә кәефләре киткән карга көтүе аптыраганнан басуга юл тота. Ә теге мәхлүк җан шат, канәгать, көтү алдыннан ул да басуга таба оча.

...Яхшы түгел дип, Барый Сираҗи картны күмәргә үзе дә барырга булды. Әүвәл бармам дип уйлаган иде, шундый чакта кеше күзенә күренеп (Сираҗи картның үлемендә авылдашлары картлыкны түгел, үзен гаепләүләрен сизенә ул, халыкның ачуын кабартып йөрисе килмәгән иде. Әммма күмәр алдыннан, җаен табып, мәрхүмнең карчыгы Галимә әбинең хәлен белеп, күмү мәшакатьләре өчен шактый акча калдырып чыкты. Моңа,—акчасыннан бигрәк, авыл хуҗасының аерым игътибарына,—карчык кешенең бик күңеле булды. Төн саклаучы карчыклар арасыннан берсе Барыйга: «Бер атыңны җәлләгәнсең шул бичарага!»—дип төрттереп алгач, Галимә әби ахирәтенә ачулы карап, рәисне читкәрәк алып китте дә: «Үләр алдыннан синең теге... бик каты чаба торган атларың янына барып кайтты. Гөлйөземнән сорыйм әле, берәр атын атланып карарга биреп тормас микән ди. Барды мәрхүм. Кайтканда бик күңелсез иде». «Карчык, малай чактан ат астында үстем. Аннары гомерем буе шулар янында чуалдым, минем күз карашымнан ни теләгәнемне аңлый торган иде ул хайваннар. Ә болар әллә нинди»,—ди. Нинди була соң ул—«әллә нинди», дип сорыйм. «Менә әллә нинди инде»,—ди. Күз карашлары да безнең авыл атларыныкы шикелле түгел, ди. Бик күңелсезләнеп кайтты, мәрхүмкәем. Шуннан җанына урын таба алмыйча, бәрәңге казырга чыгып китте. Югыйсә, каладагы балалар: «Кирәк тә тотасы булмагыз!»—дип, кисәтеп киттеләр. Гөлйөзем атлары яныннан кәефе төшеп кайткач, мин дә каршы килеп тормадым инде, берәр кирәк казыр да, үзе

туеп ташлар әле дип, уйладым. Кая инде ул сиксәнне куып барганда бәрәнге казулар! Чыгып китте бу гайрәтләнеп. Берзаман керми дә керми. Аптырап бакчага чыксам, жан биреп ята иде инде. Теле бар иде әле: «Андагы бер атнын күзе зәп-зәңгәр иде бит, Галимә...—дип пышылдады да күзләрен йомды. Халык, Барый улым, сине гаепләп сөйли, борчылма, синең тырнак очы кадәр дә гаебең юк. Зәңгәр күзле ат күреп сәерләнеп йөрде ул соңгы көннәрдә. Әҗәле килеп житкән булгандыр инде. Авыр туфрагы жинел булсын мәрхүмкәемнең...»

Галимә карчык белән сөйләшкәннән соң Барый жинел сулап куйды, күмәргә баруы да шуннан иде. Тик күнел дигәненне алай гына тынычландырып, ул рәвешле генә алдап буламы соң: авылдашлары ни уйлый икән соң бу хакта? Алар Галимә карчыкның сүзләрен ишеттеләрме икән, юкмы, баксаң, белми дә торганнардыр әле?.. Барый, Барый... әллә нишләдең әле син! Элек халык фикерен санга суга торган кеше идеңме соң син! Ник болай үзгәрдең!.. Дөнья үзгәрттемени?! Әйе, шулайдыр шул, үзгәрткәндер... Әнә бит: көн саен диярлек ауга чыккан буласың, бер аксак куян да атып алганың юк. Ә авылга бүреләр ияләшкән ди. Бүреләре дә әллә нинди аның хәзер, замана бүреләре... Элеккеге бүреләр авылга килгәч, кәжә-сарык очрата алмасалар, бәйдәге этләрне булса да буып ыргытып, күнелләрен басып китәләр иде. Ә болары этләр белән дуслашкан дип сөйлиләр! Шаклар катып үләрсең: бүре белән эт дуслашкан! Замана бүреләре, замана этләре шулай буламы икәнни әллә, дип аптырап сөйләшә халык. Кеше кешегә бүре булган бу чуар, болгавыр заманда диген әле син аны!

Барый әлеге «замана бүреләренең» башында бала башлы теге бүре торганлыгын сизенә иде. Күнеленә шом инде Әкбәровның... Хәерсез, начар шом...

Мөхәммәтнең әтисе Уразмәт агай элек әллә нинди хәйләкәр капкыннар эшли иде, хәзер ул күптән пенсиядә инде. Аның урынына калган телсез Габдерәхим дә яхшы капкыннар ясый белә белүен. Тик ул кире беткән, үҗәт адәм сүзне тынлармы икән соң?.. «Кукуруз»да хуҗалык рәисенең сүзләренә төкереп тә бирми торган бердәнбер кеше ул. Урынына тимерче тапса, Барый аны күптән чыгарып аткан булыр иде, тик хәзер яшьләрнең тимерче булып керәселәре килми, күрек янына кемне бастырасың ди! Әнә, ул бер читтә тракторчы Галләм абзыйга кызып-кызып куллары белән нәрсәдер аңлата. Тегесе әллә аңлап, әллә аңламыйча гына «әйе» дигән кыяфәт чыгарып, башын селкеп тора. Капкыннар турында телсезгә Галләм аша әйттереп карасынмы соң? Барыйны әлеге уйларыннан колхоз идарәсеннән килгән кизү кыз бүлдерде:

—Барый абый, телефонограмма бар!—диде ул һәм учына кәгазь тоттырды. Ул язуны укып та тормыйча, кесәсенә тыкты да, күрше өйнең капка төбендә торган машинасына таба атлады. Быел мәктәпне тәмамлап колхозда эшкә калган кыз,—тракторчы Галләмнең кече кызы Зәринә,—аның артыннан теркелдәде һәм Барыйдан алданрак машинага кереп утырды. Барый, моны күреп, әүвәл машинага утырып та тормыйча, идарәгә җәяү генә китеп бармакчы иде (бу сәер кыз,—үзе бал кашыгына салып йотарлык чибәр, матур кыз бала,—инде берничә айлап булыр, кирәксә-кирәкмәсә дә рәис абыйсы тирәсендә чуалырга ярата, халык телендә теләсә нинди чыш-пышлар китереп чыгарырга менә дигән сәбәп инде! Житмәсә, артта атасы да карап калды!..), аннан соң әллә яхшысынмады, әллә капка төбендә өелешеп торган халыкның: каракның бүреге яна, ләкин сиздермәскә тырыша, дип тел чарлавыннан курыкты—машинаның ишеген ачты һәм дорфа булырга тырышып:

— Мин идарәгә бармыйм бит!—диде. Алгы утыргычка кереп кунаклаган кыз әүвәл шундый матур, самими итеп елмайды, аннары каушаган кыяфәт

чыгарып:—Абау, Барый абый, шулаймыни! Мин белмәдем бит,—дигән булды да, шуның артыннан ук кура җиләге кебек кызарып пешкән калын иреннәрен бүлтәйтте:—Ничек бармыйсыз? Сезгә тиз арада идарәгә килеп җитәргә кушылган бит анда.—Кызның телефонограммага ишарә итүе иде, күрәсең. Хуҗа кеше кесәсеннән кәгазь кисәген тартып чыгарды. Аңа бер сәгать эчендә Казанга килеп җитәргә кушылган, кул куючысы Мөхәммәт, посткриптум белән: «Синең язмышың хәл ителәчәк!» дип тә өстәгән. Барый аптырап тамагын кырып куйды да машинасын кабызды. Янәшәсендә бәхетле елмаеп утырган кыз янә телгә килде:

—Сиражи бабайның үлемендә сине гаеплиләр, Барый абый.

—Мин причем?—дип куйды Барый аңа каршы, ул әле һаман бик тырышып Мөхәммәттән алынган ашыгыч хәбәр хакында уйлана иде. Ләкин кызның әлеге сүзләре аны мизгел эчендә айнытып җибәрде:

—Ничек мине? Мин нишләгән ана!

—Мин үзем дә шулай уйлыйм, авыл халкы әшәке телле безнең! Ә мин үзем менә син... Сез гаепледер дип уйламыйм! Ипидер менә!

Барыйның әлеге сүзләрдән күләсе килеп китте, кыз үзе дә, фикер йөртүе дә артык самими тоелды аңа. Иң кызыгы шул: бу кыз бала ни өчендер Барый абыйсына ярарга тырыша бугай.

Монда нииндидер сер дә булырга охшап торган кебек.

—Ә син нәрсә дип уйлыйсың соң...—Барый беркавым аның исемен хәтеренә төшерегә тырышып торды. Кыз моны сизеп ярдәмгә үзе килде:

—Зәринә мин.

—Әйе, Зәринә?

—Мин нәрсә дип уйлыйммы? Ә мин уйлап та тормыйм, чөнки беләм бит.

—Нәрсә беләсең соң син, Зәринә!

—Төссез күзле ат күргән ул, шуннан курыккан. Аннары шул турыда уйлап йөргән-йөргән дә, куркуыннан йөрәге ярылып үлеп тә киткән бабаең... Менә шул гына...

—Төссез күзле түгел, Галимә апа әйтә, зәңгәр күзле ди... Бәлкем, тозсыз күзледер...

Кыз аның үзен ирештерүен аңламаганга салышып:

—Ул атларның күзләрендә нур юк иде, дигән Сиражи карт,—дип, сүзен дәвам итте. Барый үзенең нигә сүз кыстыруына үкенеп куйды, тизрәк әлеге әңгәмәгә нокта куясы килептер, тамагын кырды, бүтән җавап биреп тормады. Бу кызчык аның эчен пошыра башлады. Шөкер, идарә каршысына килеп җиттеләр. Хәйран кызу барган машина кисәк кенә туктатуга, моны абайламый калган кыз бала, алга таба тартылып, маңгае белән тәрәзәгә төртелеп алды. Чык иткән тавыштан Барый куырылып килде, аның үзенә дә бик уңайсыз булып китте. Ул хатасын төзәтергә уйлады бугай, уң кулын Зәринәнең җилкәсенә салып, үзенә табарак тартты, сул кулы белән маңгаена орынды.

—Бик каты авырттымы?

—Сезнең кул тигәч, авыртуы бетте,—диде кыз күзеннән атылып чыккан яшьләрен сөртә-сөртә. Әлеге сүзләрдән соң Барый дорфа гына кулын тартып алды да машинадан төшеп китте. Ачуы килүен килсә дә, нигәдер күңеле булып, егетнең ирен читләренә елмаю кунып маташа иде. Ул шуны Зәринәгә күрсәтмәс өчен, абына-сөртенә, идарә ишегенә таба атлады.

## Мөхәммәт

Италиядә йөреп кайтканнан соң, Уразмәт абый малаен алыштырып куйдылармыни! Элеккеге Мөхәммәт түгел инде ул, Байтимер малаеннан кабыгы гына калгандыр кебек. Элек сүзгә шактый саран булган егетебезгә

тел керде: хәзер ул кирәксә-кирәкмәсә дә тик тора алмый, сөйләвен белә, ләкин шунысы шаккатмалы, сабыр холыклы, житди Мөхәммәт хәзер бар нәрсә хакында да иркенләп сөйләшергә, вак-төяккә дә игътибар итеп, шул турыда бертуктамый сәгатьләр буе сөйләп торырга мөмкин. Егетнең Гөлчәчәк белән мөнәсәбәте элеккечә калды. Хәер, элеккечә дип... Әйе, алар нәкъ элеккегечә сирәк күрешәләр, шул гына.

Әллә сөюләре платоник мәхәббәткә әйләнеп бара инде? Мөхәммәтнең үз фикере буенча, иҗат кешесенә тегесе дә кирәк, монысы да мөһим дигәндәй. «Тегесе» аңлашыла, ә «монысы» ни була соң аның?.. Сиринә Самуиловнадыр инде?... Кызык бу хисләр дигәнең... «Тегесен» сагыну, юксыну бар, «монысына» исә ияләнеп, күнегеп килә түгелме?.. Бу куркыныч бит, бу коточкыч хис ләбаса! Җәтмәгә эләккән чуртан кебек чәбәләнәсе, бәргәләнәсе генә калган түгелме соң инде?...

Ләкин тормыш болай дәвам итә алмый бит! Нәрсә булса да хәл итәргә кирәк. Башыңны дуракка салып йөрсәң, Гөлчәчәгең дә чыгымлый башлар әле. Хәер, чыгымласа соң... Чебен дулап тәрәзә вата алмастыр. Ул иҗат кешесе бит, ана үсәргә кирәк, тагын да зуррак дәрәҗәләргә ирешергә кирәк. Ул боларның барысын да киләчәк хакына, Гөлчәчәк хакына эшли ләбаса!

Соңгы очрашуларында ул Гөлчәчәккә шундый фәлсәфәсен «төртте». Ләкин кыз да аптырап калмады: «Синең иҗатыңа комачаулармын дисеңмени?»— дип сорады аның бу нигезсез дәлилләренә каршы. «Әлегә мина кайнарга, бөтерелергә кирәк, как белка в колесе! Сина игътибарым житмәячәк. Син үзең үк үпкәләячәксең бит аннан соң».

Мәхәббәт әллә чынлап та сукыр була инде, кыз Мөхәммәтнең бу сүзләренә ышанды һәм хәтта аның белән ризалашуын да белдерде бугай әле.

Тик нәрсә белән ризалашуын үзе дә аңлап бетермәде. Мөхәммәт өчен дә сер бу. Ләкин рәссам егет үз гомерендә беренче тапкыр «серне» аңларга тырышып азапланмады. Шул килеш кенә узды да китте. Чөнки бу аның файдасына иде бит.

Ни әйтсәң дә, Сиринә Самуиловна яшәгән дөнья ана күбрәк ошый. Иҗаты бара, дәрәҗәсе үсә. Тора-бара әлеге мөнәсәбәтләр, дөресрәге, рәссам егетнең мондый яшәү рәвеше, шундыйга әйләнеп китте ки, күнеле, йөрәге Гөлчәчәк белән рухланып, янадан-яна яхшы, уңышлы картиналар яза, ә ул картиналар исә нәкъ менә Сиринә ханым аркасында уңышка ирешә, дөньяга чыгып, зур бәя ала торалар. Тормышта мондый конструкция-төзелешне бик теләсәң дә махсус уйлап чыгарып булмый торгандыр. Ә бу нәрсә исә үзеннән үзе шулай килеп чыкты һәм Мөхәммәткә бик ошаса да, барыбер аны күпмедер дәрәҗәдә куркыта, өркетә. Кыскасы, ике «илһамчысының» берсен югалту уе белән куркып яши башлады егетебез... Тик кайсысын алданрак югалтыр, әллә икесен дә бер юлымы?.. Бу сорауга хәзер генә берничек тә җавап биреп булмый һәм хәзергесе вакытта сорау җавап көтми дә кебек. Мондый очракта адәм баласы башын дуракка салса яхшырак... Мөхәммәт Уразов шулай итте. Теге сорау җавап белән ашыктырмаса да яшәешнең үз кануннары бар: рәхәтлек бушка килми, соң чиктә барыбер аның өчен җавап бирергә туры киләчәк. Мөхәммәт тә икегә бүленеп, ике тормыш белән яши башлады. Ә мондый халәт берәү өчен дә рәхәт нәрсә түгел һәм алай була да алмый. Егет күңеленең ике катлануын ахыр чиктә үзенең һөнәре белән бәйләп аңлатырга азапланды: ул иҗат кешесе, иҗат кешесенә бар да килешә... Һәм, бер караганда, ул хаклы да кебек иде шикелле...

Хәер, бер караганда гына микән... Иҗат кешесе өчен беренче нәүбәттә аның иҗаты тора. Мөхәммәт яшәгән кабәхәт җәмгыятьтә исә тормышның язылмаган кануннары аеруча кырыс. Йә иҗат, йә гаилә баткаклыгы... Чын

талант өчен бигрәк тә шулай бу. Уртакуллар өчен исә чыгарылмалар шактый. Алар трактор кебек бара, шуна күрә артларыннан да, гадәттә, чакыр-чокыр гына кала. Алар шул чокырларны, күл урыннары дип уйлап, гомерләре буе шунда су тутырып интегәләр, үзләренчә төнбоеклы, астында салкын, саф чишмәләр тибеп ятучы күл ясыйлар, имеш, күл тирәли гаҗәп матур камышлар утыртып чыгалар, имеш... Күл әйләнәсендәге шыксыз куаклыклар аларга нәфис тал агачлары булып күренә. Аннан соң шул талларда тырыша-тырыша сандугач сайратырга керешәләр. Андыйларның колаклары бака тавышы белән сандугач тавышын аермый. Һәм аларны тыңлаучылар да бака сайравын сандугач җыры итеп кабул итәргә мәҗбүр ителәләр. Бу шундый ил ки, кемнеңдер әмере, ихтыяры белән бака тавышы сандугачныкына, сандугач сайравы бака тавышы кебек яңгырарга гына түгел, нәкъ менә шулай итеп кабул ителергә мөмкин. Үзең җайлашмасаң, бу ил синең көенә мәңге җайлашачак түгел!..

Әлбәттә, бу фикерләр, мондый уйлар Мөхәммәт Уразовның тормыш фәлсәфәсе түгел, егет әлеге теория белән яшәми. Тик нәкъ менә шул фәлсәфә кысаларына башын тыгып барганлыгын аңлап та, төшенеп тә җиткерми әле ул. Сиринә Самуиловна аркасында аның иҗаты шактый шома юлдан тәгәри әлегесен.

Бүген ул—шактый зур түрә абзыйның шәһәр читендәге коттеджында кунакта. Садыйк Сираевич өч катлы йортының икенче катына Мөхәммәт язган картиналарны гына эләргә карар иткән. Рәссам егет бүген чираттагы эшен алып килде. Хезмәтенә долларлар белән генә түләнә. Тормышта монысы да әһәмиятсез түгел. Үзең язган шәп картинадагы урман һавасы белән тамак туйдырып булмый... Ул болай чын урманга охшап торса да, андагы гөмбә, җиләкләрне авызга кабып булмый...

Садыйк Сираевич менә-менә үзе дә кайтып җитәргә тиеш. Хатыны аны өйдәге ике пешекче һәм хезмәтче ир белән калдырып, үзе тиз генә массажга барып килəм, дип китте. Мөхәммәт, хуҗалар юклыктан файдаланып, мәдәният йортын хәтерләткән ихатаны карап йөрде. Ачуым килмәгәе, мондагы бәдрәф тә аның бер бүлмәле фатиры чаклы гына бар. Кыскасы, шаккатмалы иде бу йорт, ханнар сарае кебек иде. Тик шунысы гаҗәп, өй эчендәге байлыкка сокланып йөрсә дә, Мөхәммәт бу хәлне артык исе китеп, йә булмаса, кара көнчелек белән көнләшеп кабул итмәде, чөнки егетнең күңелендә үзе сәер, үзе шактый кыю булган әллә нинди генә бер тойгы кереп урнашкан: әйтерсең, ул нәкъ шундый ук коттеджыннан чыгып китеп, күршесенә хәл белергә генә керде. Кайдан килде күңеленә шундый мәгънәсез, аңлашылмаслык тойгы—бер Алла гына белә! Хәер, үзе чамалый шикелле: Италиядә бик уңышлы күргәзмә уздырып кайтты бит.

Сиринә Самуиловнага мең рәхмәт: әлеге сәяхәттән соң, Уразов ике башка үсеп китте. Шуның артыннан ук аңа күргәзмә оештыруын, яки катнашуын үтенеп төрле төбәкләрдән кызыклы тәкъдимнәр ява башлады, иң кызыклылары, әлбәттә, Мәскәү, Петербургтан һәм Идел-Кама филиалыннан иде.

Егеткә моңарчы булмаган, бу көнгә чаклы татып карамаган ышаныч иңгән кебек булды! Ләкин бу Ышаныч үзе генә яши алмый, ул Сиринә Самуиловна белән янәшә. Кәкре каенга терәткән терәү кебек, бу хатын аны җил-давылдан саклап тора. Йа, Ходай, мондый хисне нигә син адәм балаларына тәпи йөреп китүгә үк салып куймыйсың соң! Искиткеч зур хис икән бит ул үз-үзенә, иртәгесе көненә Ышаныч булу, алай гына да түгел: үз сәләтеңә ышаныч булу хисе... Бу җәмгыять беренче нәүбәттә бәндәләрендә әнә шул хисне үтерә, сытып изә, таптый бит! Кабыкка әйләндерә адәм балаларын ул хиснең зәгыйфь булуы. Хәер, Сиринә Самуиловна булмаса...

Мөхәммәт, яна алып килгән картинасын эләргә дип, унайлы урын эзләп маташа иде. Ишек ачылып китеп, зал аша икенче бүлмәгә бер күләгә шуышып узган кебек булды. Беркавымнан әлеге «күләгә» юыну бүлмәсендә бик озак су агызды, аннары гына әлеге күләгәнең иясе үзе пәйда булды: ул хужа кызы студент Әлфия иде. Таш курчак кебек матур бу кыз белән Мөхәммәт күптән таныш. Әлфия—Аля да рәссам булырга әзерләнә. Шуна күрәме икән, алар Мөхәммәт белән аеруча дуслар.

—О, как красиво! Нинди матур!—дип, кыз Мөхәммәтнең яна картинасын күргәч телен шартлатты.

—Менә, куярга урын эзлим.

—Ты меня обижаешь, сэр. Бу эштә минем специалист икәнлегемне оныттынмыни! Хәзер, хәзер! Ике тәрәзә арасында буш урын барын бар да... Тик анда ярамый, әти: «ул як кыйбла ягы»,—ди картиналар эләргә кушмый. Слушай, карале, монда урын да калмаган икән бит!

Мөхәммәт инбашларын сикертеп алды да, сүз булсын дигәндәй генә:

—Икенче катта урын юк микән?—дип куйды. Никтер ул бу кыз янында каушый, малайлар кебек кызарырга гына тора. Беренчедән, егетне кызның чибәрлеге каушатса, икенчедән кыюлыгы, холкының алдан аңлап булмаслык кискенлеге, көтелмәгән капризлар чыгарырга яратуы шүрләтә. Әүвәл, танышкан шәпкә, мине шәрә килеш сурәткә төшер, дип, Мөхәммәтнең теңкәсенә тиде. Моны ишетүгә, Мөхәммәтнең күз алдына шундук Садыйк Сираевич килеп басты. Ул аның хәтта күз карашына чаклы тойды. Әлеге бакыр төсендәге караш борын тишекләреннән кереп китеп, ашказаннарын әйләндереп чыгарырдай усал, авыр иде. Мөхәммәт, янынннан бәйләнчек черкине کугандай, үзе дә сизмәстән, кулларын селти-селти, аның тәкъдимен кире какты. Бәхеткә күрә, алай ук бәйләнчек түгел икән.

—А зачем нам второй этаж? Икенче этажның нигә керәге бар?—дип, кыз стенага сөяләп торган картина янына атлады.—Минем бүлмәгә куябыз аны. Гаҗәеп урман сурәте бит! Мин урманны яратам! Тик нишләп синең урманнарың һәрвакыт карурман кебек? Бер киселгән агач юк анда, урманга кереп китүче сукмак-юллар да булмый. Шүрәлеләр генә яши торган серле урман шикелле?

—Әтиеңнең заказы шундый.

—А, понимаю тогда... Аңладым, аңладым...—Аля-Әлфия ике телне дә яхшы белә, тик еш кына аларны чиратлаштыра, яки шуның артыннан ук икенче телнең тәрҗемәсен дә кабатлый иде.—Соңгы вакытта кешеләрдән качасы килә башлады бугай аның. Карурманга кереп булса да... Андый урманнар юк хәзер... Мин бүген урманга бардым... Фу! Мусор оясы! Ну только бүре күрдек! О, нинди усал иде ул!!! Так страшно было!

—Бүре? Ничек сина ташланмады соң ул?

—А меня спасли! Один рыцарь! О, шәп егет!

Әлфия, кесәсеннән фоторәсем алып, Мөхәммәткә сузды. Барыйның Гөлйөзем белән парлашып төшкән фотосурәтен бая машина эченнән эләктергән иде бу ут кыз. Мөхәммәт, фоторәсемдәге таныш йөзләрне күргәч, чак артына утырмады, ана таба бәхетле елмаеп сыйныфташы Барый белән сөйгәненең сынары Гөлйөзем карап тора. Егеттәге үзгәрешне үткен кыз шундук сизде һәм, серне чишүен үтенеп, Мөхәммәткә чат ябышты: «Әйтсәң дә әйтәсең, әйтмәсәң дә әйтәсең!..»

—Бу егетне беләм бугай мин,—диде Мөхәммәт бераз ялындырыбрак. Әлфиягә шуның кадәресе дә бик житкән иде: тагаен белә һәм әйтәчәк!

—Үземә әйтәсеңме, әллә әтигәме?—дип, кыз шундук һөҗүмгә күчте. Бу егеткә рәхмәтле генә түгел, бу егет аның күңеленә үк кереп калган күрәсең. Мөхәммәт, кызның ут кебек ялкынланып яна башлаган күзәренә игътибар

итеп, шүрли үк башлады. «Ни булган болар арасында?»—дип, куркынып уйлап куйды ул. Әлфия дә аның эчке уйларын сизми калмады, ахырысы, шундук мәсьәләгә ачыклык кертергә ашыкты. «Я должна его отблагодарить! Мине бүредән коткарып калды бит ул!»

Мөхәммәт, бераз йомшара төшеп, киеренкелек сүрелә башлады.

—Однокашник бит ул минем. Барый... Әкбәров. Син булган якларның хуҗасы.

Егет сизми дә калды, кыз ни ара йөгереп тә килде, ни ара Мөхәммәтнең муеныннан кочаклап, битеннән үбеп тә алды. Егетнең шул як бите ут кебек, нидидер тәмле, татлы рәхәтлек биреп янарга кереште. Күргән шәпкә үк ул кызда ниндидер үзгәреш барлыгын сизгән шикелле дә иде, артык игътибар гына итмәгән булган, күрәсең. Бу үзгәрешкә Әкбәров сәбәпче икән бит ләбаса! Каян күрешкәннәр дә, ничек табышканнар диген! Берсе авылда, икенчесе Казан кызы, җитмәсә, кемнең кызы әле! Әгәр Садыйк Сираевич боларның кырын эшләрен сизсәме?! Бетте Әкбәровың! Ул аны тереләй җир астына күмдерәчәк! Чөнки бердәнбер сөекле кызының әтисе «партиясенә» туры килгән шәп егет белән танышкан көннәре генә бит!

Тәртә арасыннан чыгып киткән кызының муенына камыт киертергә исәпли бугай!.. Нәкъ шул чакта арага Барый килеп кысылсамы? Һе, тегермән ташы арасындагы кибәккә әйләндерәчәкләр Барыйны... Әлеге уйлардан соң Мөхәммәт үзенә урын таба алмый башлады, җиңелчә генә башы әйләнергә кереште. Тагын кыз үзе ярдәмгә килде, ул яңа картинаны алды да, икенче кулы белән егетнең җиңеннән әләктереп, югары катка таба әйдәде:

—Әти кайтканчы урнаштырыйк әле моны. Сюрприз сделаем ему.

—Ә син Барый белән ничек таныштың соң?

—Алайса, мин сезнең як урманына барып чыккан булам инде? Надо же!.. Танышуын танышмадым әле мин аның белән. Якыннанрак син таныштырсаң гына инде?

Мөхәммәт җиңел сулап куйды: өлгермәгәннәр әле, димәк...

—Не могу жить ни с тобой, ни без тебя, дисең инде алайса?

Бу мизгелләрдә Мөхәммәтнең сүзне шаяртуга борасы килүе аңлашыла иде. Әлфия аңа каршы бары:

—Великая вешь—любовь!—дип кенә куйды.

—Егетең бар бит синең? Шаһмәлиев малаен кайда куясың!

—Шаһмәлиев—чмо!

—Әтиең сизсә?

—Любовь и кашель не скроешь инде.

Словно солнце горит, не сгорая, любовь.
Словно птица небесного рая—любовь.
Но еще не любовь—соловьиные стоны.
Не стонать, от любви умирая,—любовь!

Әлфия дә Хәйямне яттан белә икән, ул, елмаеп, Мөхәммәткә таба күтәрелеп карады да көр тавыш белән шигырь укырга кереште:

В этом мире любовь—украшенье людей,
Быть лишенным любви—это быть без друзей.
Тот, чье сердце к напитку любви не прильнуло,
Тот—осел, хоть не носит ослиные ушей!

—Каты әйттең син,—диде Мөхәммәт. Садыйк Сираевичның кызы таш курчак кебек булса да, ул элек уйлаганча буш кыз түгел. Мондый әңгәмә

рәссам егеткә ошый иде, ул кабат хәтер чарлагында эзләнергә кереште һәм аннан «Тукайны табып алып», янә кызны шаккаттырмакчы булды:

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь,
әйтегез, рухланмаган?
Байронын, Лермонтовынмы,
Пушкинынмы—кайсысы?
Файдасыз бер ит кисәгеннән
гыйбарәттер йөрәк—
Парә-парә кисмәсә
гыйшык-мәхәббәт кайчысы!..

Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,
Ләкин һәрбер йөрәк аны янарта!..

Гаҗәпләнүдән Мөхәммәтнен күзләре мангаена менеп кунаклады.

—Ну ты даешь!—дип, соклануын белдермичә булдыра алмады ул.

—Нәрсә, мине Садыйк Сираевичның юлдан яза башлаган бер иркә кызы дип кенә уйлаган идеңме әллә!

Кыз шулай диде дә сабыйларча ихласлык белән рәхәтләнеп көлә башлады, самими, эчкерсез көлү иде бу. Һәрхәлдә, Мөхәммәткә шулай тоелды. Хәерлегә булсын... Тик хәерле дигәнен... нәрсә була торгандыр инде тагын...

## Козгыннар йолдыз чүпли...

Садыйк Сираевич Мөхәммәтнен килүен күреп бер шатланган иде, картина исә аны икенче кат сөендерде. Картинада зур зәвыкь белән, югары сәнгать дәрәҗәсендә язылган кара урман. Кара урман Садыйк Сираевичның күңеленә иң хуш килгән сурәтләрнең берседер, мөгаен. Ул моның нигә шулай икәнлеген күңеле белән тоемлый, әмма ниндидер мантыйклы калыпка салып, шуннан чыккан мәгънәне әлегесен аңлап бетерми. Әлегесен... Әлегесен дидек, чөнки ул аны кайчан булса да үз аңында калыплаячак һәм гап-гади, әмма үз ачышы итеп ачачак; ул шуна, бер яктан, балаларча сөенсә, икенчедән, бу фикернең шулай соңлап килүе анын бераз гына кәефен дә җибәрәчәк әле... Чынлап та, кара урман сурәте әллә нинди уй-хисләр тудыра...

Мин үзем, автор буларак, Садыйк Сираевичны бик яхшы беләм, анын һәр кылган гамәлен генә түгел, хәттә күнел күзәнәкләренен ни рәвешле сулаганнарын да тоям инде дип, зур канәгатьләнү белән йөри идем. Ник, шулай булмыйни! Алайса анын хакында, бу кешенен Әлфия атлы йөгәнсезрәк кызы хакында язып, укучының башын да катырып торасым юк! Мин... мин бит аларны—мичкә керсәләр, аяк тәпиләреннән таныйм бит инде дигәндәй.

Әлфияне «йөгәнсезрәк» дип сүз уңаеннан гына әйттем. Кияүгә чыкканчы кыз баланың кайсысы «йөгәнле» була инде! Анын белән аралашкан кайбер кызлар фикеренчә, бәхетле йолдыз астында туган кыз бала ул. Бу очракта бәхет дигәнен исә чагыштырмача мәгънәгә ия. Шундый дәрәҗәле, калын кесәле әтиен булып, өстендәге күлмәгенне алыштырырга аптырап йөрмәсән, акча дигән нәрсәнен нинди «басуда» үскәнен белергә дә теләмичә, аны уңга-сулга күзенне дә йоммыйча туздыра алсан, бәлкем, шундый бала бәхетле була торгандыр. Бәхет дигән нәрсә гаҗәеп кызык төшенчә! Бер генә галим яки акыл иясе дә, кыскасы, беркемнен дә бәхетнен ни икәнлеген аңлата алганы юк әле. Язучы буларак, мин дә ул эшкә алынырга җыенмыйм, дөресен әйтәм: үз фикерләрендә буталып бетәсем килми...

Элегрәк басуларда каланчалар була торган иде, аны халык каравылчы

каланчасы дип тә, пожар каланчасы дип тә атап йөртте. Басу никадәр зуррак булса, аның каланчасы да озынрак итеп ясала. Ә кечкенә басуга бәләкәйрәк каланча да бик ярап тора иде. Бу очракта бәхетне дә менә шул каланча белән чагыштырып карарга мөмкиндер, мөгаен. Басуың нинди—каланчаң шундый. Димәк, һәр адәм баласы өчен дә уртак булган бәхет тә юктыр ул. Һәр кеше үзенчә бәхетле. Әмма үз фикерләремә үзем үк каршы төшеп: юк, җәмәгать, ашыгыч нәтиҗәләр чыгармый торыйк әле, уртак бәхет бар ич ләбаса адәм заты өчен! Ул—акча!!!—дип тә әйтә алам. Ләкин бу очракта, башымны ташка бәреп исбатлый алам, мин хаклы да, хаксыз да! Бик әллә кая еракларга китмичә ике генә мисал китерәм. Минем бер акчалы дустым бар, ул үзен бәхетсез дип саный, чөнки яшь чакта кайнарланып китеп өйләнеп ташлаган да, шул хатыны аңа рәттән ике бала алып кайтып биргән дә... Кыскасы, хатынын яратып яшәми ул. Аерылып та китә алмый һәм үзен иң бәхетсез кешегә исәпли. Икенче бай, ягъни акчалы дустым саулыкка туймый. Себер якларында дистә еллар буе үзенең сәламәтлеге бәрабәренә алтын приискаларында сукыр тычкан кебек җир казып кайтты да, монда коттедж салып җибәрде, балаларын зур уку йортларына урнаштырды һәм шуннан соң урын өстенә ятты. Затлы чит ил машинасында студент кызы артыннан селәгәен агызып йөргән бер малай җилдертә, хатыны иртәдән кичкә чаклы биләмдә, чөнки авыл тулы (коттеджны хатынының туган авылында салган иде) туганнары!.. Менә сиңа акча алып килгән бәхет шулай да була ул тагын!

Әлбәттә, акчадан баш тарту дигән сүз түгел бу, бәлки, шул рәвешле бәхет дигән төшенчә хакында уйлану гына.

Ә Садыйк Сираевич уйлы кеше. Уйлы булмаса, ул бүгенгесе көндә шушындый дәрәҗәгә ирешмәгән дә булыр иде. Ләкин дөнья дигәнең һәрвакытта да син дигәнчә генә бармый... Һай, бармый икән шул!.. Ике бала үстергән иде алар—малае моннан ике ел элек самолет ярышында һәлакәткә очрады. Спортчылар очкычларга утырдылар. Фили белән филилар арасында ярышлар башланды. Аның Шамиле дә атна-ай саен яңа очкыч алыштыра-алыштыра, ике ел дигәндә беренчеләр рәтенә менде, гел җиңүче булып килде. Менә шундый ярышларның берсендә Шамил, самолеты-ние белән җиргә кадалып, башын имгәтте. Хәзер, әнә, егерме җиде яшьлек егет, чиркәү кебек пулатның беренче катында, идән уртасында, селәгәен агыза-агыза, уенчык самолет белән уйнап утыра... Югыйсә, улы аның эшен дәвам иттерергә тиешле бердәнбер ир-ат варис иде. Атасы урынына түрә булып утырмаса да, аның эшмәкәрлек эшен Шамил дәвам итәргә, «Гыйфрит» фирмасының башында ул торып калырга тиеш тә бит!..

Дәү филиалда «Гыйфрит» кебек көн күреп, зур табыш алучы фирмалар бихисап. Әлегесен аларның һәммәсенең башында пенсия яшеннән авышкан зур түрәләр утыра, гаиләнең шәхси оешмалары булганлыктан, аларның җитәкчеләре дә һәрвакыт шул нәселдән булырга тиеш иделәр.

Әлеге фирманың исеме Галәветдин лампасындагы бар нәрсәне эшләргә сәләтле Гыйфрит җеннән алынган. Бары тик шушы әкият герое гына барны юк итәргә сәләтле бердәнбер көч бит. Ә әкиятләрдәге геройларның кайдан алынганын беләбез: алар да болытлар артында түгел, алар безнең янәшәдә җиргә басып йөриләр... алар теләге һәм ихтыяры белән усак яфраклары яшел кәгазь—долларларга әверелә, Идел суы кымыз булып кайнарга керешә, каргалар бөркет булып күккә күтәрелә, тизәк чебеннәре умарта балы ташый... Менә шундый заманда яшәгәч,—нәкъ әкияти заманда!—нигә фирмаларның исемнәрен дә «Гыйфрит» яки «Мифрит» дип кушмаска!?. Усак яфракларыннан нигә яшел акчалар ясамаска? Усак күп үсә бит ул, исәпсез-чутсыз үсә, гәрчә ул да гәүдәсен төз тотып кояшка таба үрелү өчен тамырлары аша шыпырт кына, тыйнак кына җир маен суырып утырса да...

Әнә шул рәвешле Садыйк Сираевичка бүген варис, дөресрәге, шуларның барысын да ышанып тапшыра алырлык үз кешесе кирәк. Кызы Әлфияне Шаһмәлиев малае белән кавыштырып, «укмаштырып» шундый таяныч, дәвамчы булдырырыга иде исәбе. Тик Шаһмалиев, коймакны ак ипи белән бергә ашый торган сыек буынлы студент малай, Әлфиянен ин сөймәгән, хәтта күралмаган кешесенә әйләнде. Ә болай начар парлар түгел иде шикелле бит үзләре... Житмәсә, алар Шаһмәлиев белән гомер буе эшләрен бергә алып бардылар, атасына ышанып булгач, малае да төшеп калганнардан түгелдер, дип, фикер йөрткән иде Садыйк абзагыз. Кыскасы, кызына килешле генә пар булырга тиеш иде кебек Шаһмалиев малае... Язмагандыр, күрәсен...

**Тагын автор әле бу...**

«...Садыйк Сираевичны ярыйсы ук яхшы беләм дигән идем мин. Анын жанына ук кереп, каләм тыгарга, каләмемнен карасын анын болай да каршылыклы күнел дөньясында кайнаган хис-мисләренә манып: менә кем бу адәм дип, һич кенә дә чаң сугасым, йә булмаса, берьяклы нәтижә—фикерләр чыгарып, бирәүне дә шаккаттырасым килми. Зинһар, мине дөрес аңласыннар, бер караганда, бу каһарманымны бик яратам, икенче мәлдә исә кызгана ук башлыйм (чынлыкта, анын кулында Иблиснен тәмуг кисәве...) һәм әлеге мескен хис нәфрәткә дә әйләнеп куя. Үзем хисләнеп киткән чакларда шулай була бу гадәттә. Ләкин бик яхшы беләм—бу очракта мина һич кенә дә хисләремә ирек бирергә ярамый, югыйсә, геройларым белән бергә үзем дә буталып, юкка чыгып бетәрмен кебек тоела...»

• • •

...Сиксәненче еллар уртасында инде медицина фәннәре кандидаты булып алган Садыйк Сираевич шәһәрдәге бер психбольницанын баш табиб ярдәмчесе булып тыныч кына эшләп ята иде. Хатыны Тәслимә, элеккеге татар теле укытучысы, шәһәргә күчеп килгәч, урта мәктәптә урыс теле укыта башлады, чөнки ул чакта туган тел дәресләре модага яңа гына кереп барганлыктан, мәктәпләрдә дәрес сәгатьләре житешмәде. Алар түп-түгәрәк малай белән сөйкемле сөякле кызчык үстереп, үз көннәрен үзләре күреп, матур гына яшәп яталар иде. Хатыны татар теле укытучысы булу да тәэсир иткәндер инде—Садыйк Сираевич шактый милли жанлы һәм интернационалист кеше дә. Туксанынчы елларда, гасырлар буе милли һәм рухи яктан изелгән Татарстанның төп халкы, милләт дип авыз ачарга батырчылык итеп, үзәк дилбегәсе чак кына бушый төшкәч, бүтән дәү корсаклы түрәләр кебек ул аларны милләтчелектә гаепләргә ашыкмады, киресенчә, чын күнеленнән, сәламәт рухлы татар малае буларак, күпчелек кебек азатлык дип төшләнә һәм, халкының матур киләчәген күз алдына китерергә тырышып, чын күнеленнән сөенә иде, өметләнә иде.

Әйе, киләчәгенә зур өметләр баглап яши торган кеше иде Садыйк Сираевич. Тик балалары ирәя төшкәч, еш кына төшенкелеккә бирелә башлады бугай. Тиктомалдан гына кәефе китә, тиктомалдан гына күнелен авыр уйлар каплап ала да, кулыннан бар эше киткәндәй була. Күп акча, байлык кына да адәм баласының кәефен һәрвакыт күтәреп, күнелен канатландырып тора алмый икән шул! Кайсыдыр акыллы баш әйткән бит: байлыкның күләме керемнең зурлыгы белән түгел, кешенең яшәеш рәвеше һәм гадәтләре белән билгеләнә дигән. Белеп әйткән бу акыллы баш. Аннан соң: «Урла, йолкы, тупла, ия бул—кайчан да булса, барыбер һәммәсен калдырырга туры киләчәк» дигән әйтемне дә яхшы белә Садыйк Сираевич. Тик кемгә калдырырга? Әлеге

сорауның бик тә четерекле, катлаулы, авыр сорау икәнлеген адәм баласы әүвәл башына да китереп карамый икән шул. Килеп терәлгәч кенә... Шекспир язганча: «В них оправданье старости моей»,—дип җинел генә әйтә алса иде ул балалары хакында!.. Киресенчә, күп вакыт Грибоедовны исенә ешрак төшерә бугай шул ул: «Что за комиссия, создатель, быть взрослой дочерей отцом!» Әйе, Әлфия житкән кыз инде, иртәге язмышы хакында Садыйк Сираевич үзе уйларга тиеш һәм хәл иткән сүз дә аныкы булачак. Әлфиясе ниндидер Барый атлы кеше хакында кайтып сөйләгәч, аның күнелен бер корт кимерә башлады. Ул корт хәерле «корт» булырга охшап тора бит әле менә! Ни әйтсәң дә, Әлфиясенә төпле егет кирәк, ахыр чиктә, ул егет кияү балакайга әйләнеп куеп, Садыйк Сираевичның эшмәкәрлеген дәвам иттерерлек таяныч—терәк булыр иде. Әлфиясе Мөхәммәтнең Барыйны белүен әтисенә әйтергә дип, авыз ачканчы ук ул, Садыйк Сираевич, бу хакта кызыксынып өлгерде... Дөньясы шундый: бер генә мизгелгә дә сизгерлекне югалтырга ярамый. Хәниф Хатыйповичтан әлеге егет хакында үзенә кирәкле шактый ук мәгълүмат тупларга да житешкән иде инде карт төлке...

Төлке булырга тормыш үзе йөрәтте. Югыйсә, югыйсә... медицина буенча докторлыгын яклап, тыныч кына берәүгә дә тимичә, комачауламыйча гына табип булып яшәп ятарга иде исәбе. Ләкин бу тормышның язылмаган, дөресрәге, күз белән күреп, колак белән ишетеп һәм хәтта борын белән исен дә тоеп булмаган үзенең кануннары бар икән шул... Шактый кырыс, күп очракта мәрхәмәтсез кануннар...

Туксанынчы еллар башында татарлар, ниһаять, бер кузгалып алдылар бит әле. Бүгенгесе көндә Мәскәүнең туя белмәгән түрәләре, ул чакларны исләренә төшереп:«хәерчегә якты чырай күрсәтсәң»... дип уйлый торганнардыр, мөгаен. Сабантуй мәйданында чүлмәк ваткан чагында якты чырай күрсәткән иде шул берсе. Соңыннан ямаулык та өләшеп йөрде әле, бахыр. Хәзер аның варислары шул «ямаулыкның» җөйләренә чаклы сүтеп яталар. Күргәннәре-күрмәгәннәре шул булсын иде. Бу халык үзенә ямаулык кына түгел, ниһаять, өстенә төлке тун ябынырга да вакыт житкәнен һәм үзенең шуңа бик лаек икәнлеген тагын бер заман аңлар әле, Алла боерса... Әлбәттә, безнең Садыйк Сираевич бүген болай дип уйламый. Аның хәзер мондый бимаза уйлар белән мавыкланырга һич кенә дә вакыты да, теләге дә юк. Ә теге чакта вакыты да булды... Җүләрләр йортында баш табип ярдәмчесе булып эшләгән чагында... Ләкин аның үзенә уйларга ирек бирмәделәр шул, синең өчен уйланган инде, туган, кушканны эшлә!—дип, кырт кистеләр...

Суверенитет, мөстәкыйльлек... Ирек мәйданы шау итә. Элек фәлән илдә тегән кеше ачлык игълан итте дигәнне телевизордан гына күреп белә иде бахырлар. Хәзер, әнә, Казанның Ирек мәйданында татар зыялылары, урыстан азатлык даулап, ачлык игълан иткәннәр!.. Көне-төне мәйдан тулы халык. Транспарантлар, плакатлар, байраклар. Кемнәр генә юк алар арасында: зур язучылар, атаклы рәссамнар, күренекле галимнәр, танылган артистлар, исемнәре ил теленә кергән башка интеллигенция вәкилләре!.. Мәскәүнең, коты ботына төшеп, Казан артына, мари урманнарына, танклар китереп туплавы турында куркыныч хәбәрләр дә йөри.

Нәкъ шул заманда Күк йөзендә моңарчы астроном галимнәр белмәгән, күрмәгән бер Йолдыз кабынды! Яңа Йолдыз!.. Исеме дә юк иде аның хәтта! Менә шул Йолдыз Күктән тыныч кына Казанның Ирек мәйданын күзәтеп тора башлады, шунысы кызык, хәтта көндез дә сүнеп тормый иде ул Йолдыз. Кызганыч, ул Йолдызны кешеләр күреп өлгермәделәр. Тик шулай да аны күргән бер җан иясе бар иде—ул җан иясе дигәнебез Казан арты урманнарында көн күреп ятучы ике гаярь бөркет иде. Әткә бөркет тә, әнкә бөркет тә үзләренең очлы күзләре белән ул Йолдызны шундук күреп алдылар һәм,

күккә күтәрелгәндә, алар һәрвакыт, куана-куана, шул Йолдызга таба омтылалар иде. Аннан соң, хәлләре бетеп, кире төшәләр, оядагы балаларын җим белән сыйлаганнан соң янә шул Йолдызга таба уктай атылалар...

Ә бу вакытларда татар милләтенең каймагы Ирек мәйданыннан кайтып кермәде, шаулады, даулады.

Нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә Садыйк Сираевич янына психбольницага (баш табип җәйге ялда иде) күн курткалы бер адәм килде, вәкарь белән генә кенәгәсен күрсәтте һәм алар икесе баш табибның кабинетына кереп бикләнделәр.

—Ирек мәйданында булганыгыз бармы!—дип сорады күн куртка кабинетка кереп урнашкач ук.

—Ник булмасын, татарның бар җүнле кешесе шунда бит,—дип җавап бирде аңа Садыйк Сираевич, алдын—артын уйлап тормыйча.

Әлеге бәндә, күрәсең, мондый ук туры җавапны көтмәгән булгандыр, чөнки Садыйк Сираевичка кенәгәсен күрсәтеп, үзенең кайдан килгәнлеген искәрткән иде бит. Шулай да ул үзенең канәгатьсезлеген эченә йотып, янә сүз кушты:

—Нишләп йөриләр дип уйлыйсың син ул халыкны анда?

—Суверенитет даулап, ирек, бәйсезлек...

Күн куртка беркавым кашын җыерып торды да:

—Ирек дисең инде алайса?..—дип куйды һәм бу юлы Садыйк Сираевичка сүз кушарга да ирек бирмичә сүзне үзе ялгап китте:—Ә менә синең пациентларың ирек даулыймы соң? Алар бит әле бигрәк тә тимер бик астында! Карап торышка, сау-сәламәт кешеләр кебек үзләре?

Садыйк Сираевич елмаясы итте, ләкин бу кешенең һич тә шаяртырга җыенмаганын күргәч, иреннәре шундук җыелып, ул житди кыяфәт алды, авыр сулаган булды:

—Минем пациентлар җүләрләр бит алар. Акыллары житешми.—Ул соңгы җөмләсен әйткәндә, урта бармагын чигәсенә куеп, боргычларга уйлаган иде, теге кеше әллә ни уйлар дип шикләнеп, тыелып калды һәм бары:—Минекеләргә ирек бирсәң, бүген үк стеналарны җимереп чыгып китәрләр иде урамга,—дип, кенә куйды.

—Димәк, аларга да ирек кирәк?

Садыйк Сираевич әлеге сорауны аңласа-аңламаса да җавап бирергә ашыкмады, ул акрынлап акылына килә башлап, эшнең бик үк хәерле булмаячагын сизенә башлады. Нишләп теленә салынып, теләсә нәрсә сөйләшеп утыра соң әле ул?! Атасының язмышын онытканмыни!.. Шушы оешма кешеләре, аны һәм өч апасын шыр ятим калдырып, сугыш башланыр алдыннан гына әтиләрен алып чыгып киттеләр бит! Ул халык дошманы малае булып үсте ләбаса! Әлеге оешмадан курку аның канында бит инде, югыйсә!. Күрәсең, соңгы еллардагы вакыйгалар аның уяулыгын, сизгерлеген киметеп җибәргән...

Садыйк Сираевичның иреннәре чатнап кипте.

—Сезнең әтиегез Сирай Габитовны ничәнче елларны акладылар әле?—Бу сорау түгел иде, шуңа күрә, Садыйк Сираевич аңа туры җавап бирмичә:

—Әтинең бернинди гаебе булмаган,—дип кенә куйды. Иреннәрен берберсеннән ничекләр итеп аера алгандыр, үзе дә аптырады соңыннан.

—Гаепсез булмаганлыгын беләм мин,—дип, сүзен дәвам итте теге адәм.—Мин Сезнең янга әтиегез хакында сөйләшергә дип килмәдем, хәзер башка заман. Тик менә мин шуны аңламыйм: сез ничек итеп, нинди күнелегез, ни йөрәгегез белән ул пациентларыгызны дүрт стена артында бикләп тота аласыз?! Урамда көн нинди матур!

—Сез миңа нишләргә кушасыз?

Садыйк Сираевич бик аптыраштa иде. Аның мондый кыяфәтен күреп торган теге адәм үзе ярдәмгә килде:

—Һава сулап керсеннәр!

—Ничек?!

Садыйк Сираевичның күзләре мангаена менә язды:

—Ничек?!—дип кабатлап сорады ул тагын бер кат.

Күн курткалы тәрәзәгә таба ымлады һәм үзенең эч пошыргыч тыныч, ләкин боерулы тавышы белән:

—Анда автобуслар көтеп тора!—диде.—Ирек мәйданын карап килсеннәр, бераз аякларын, тамакларын язсыннар.

Ләкин Садыйк Сираевичка һаман барып җитмәгән иде әле. Ул үзе дә җүләр кеше сымак теге кешегә тик аптырап карап утыруын бел.

Күн куртка, кесәсеннән кәгазь чыгарып, баш табип ярдәмчесенә сузды.

—Менә...

...Шул көннән башлап Ирек мәйданына милләтпәрвәрләр белән беррәткә Садыйк Сираевичның пациентлары да басты.

Күктәге теге исемсез, яна Йолдыз кинәт сүрелә башлады. Әүвәл ул бик көчле яктылык биреп шактый вакыт җемелдәп торды-торды да аннан соң бөтенләй сүнеп күздән юкка да чыкты... Бу хәлгә, Йолдыз югалуга, иң көенгән җан иясе әнкә бөркет булды. Ул бөтенләй кефсезләнеп, хәтта ашаудан да калды. Моны күреп торган әткә бөркет, Сөеклесенең күнелен күтәрү өчен ниләр генә кыланып карамады, әмма файдасы булмады. Ахырда ул, болытлар арасыннан теге югалган Йолдызны табып алып төшәм дип, мең кат вәгъдәләр биреп, бар гаярьлеген, бар булган көчен туплап, югарыга атылды. Бу вакытта, мари урманнарында, Самарадан куып китерелгән танк полкы солдатлары эшсезлектән ни кыларга белмичә гөмбә җыеп йөри иде. Араларыннан берсе, зәңгәр күктә йөзгән бөркетне күреп алып, автоматын салды һәм аңа төбәп атып та җибәрде... Бар урман шау итеп куйды, бөркет, таш кебек, Иллэт елгасына егылып төште. Ату тавышын кара урман үзенә йотты...

Бөркет гаиләсе ятим калды, яклаучысыз калды. Чал наратлар, яшь каен кызлары, йомшак күнелле каен әниләре, купшы чыршылар, ятим гаиләне кызганып, сыкталып-сызланып бик озак елаштылар...

## Бабай буласы кеше кармак сала

Барый Казан читендәге коттеджга барса да барды, бармаса да барды. Бу чакыру бик зур табышмак иде ана. Садыйк Габитовнын Дәү филиалда нинди урын тотканын һәм, гомумән, нинди кеше икәнлеген белмәгән кеше бар микән?

Аның күнелендә мең төрле шик-шөбһә кайнады: Барыйны кайдан белә ул, тиктомалдан гына нәрсәгә дип чакырткан? Һәм ни өчен эш урынына түгел, нәкъ менә өенә дәштерә, өстәвенә кичке якта, эш сәгате тәмамланган вакытта?!. Соңгы очрашуда Зәет Вәлиевич ФСБ хакында авызын ачкан иде, тик анлатып кына бетермәде. Барый үзе дә җентекләп тормады ичмаса. Ник җүнләп сорашмады икән шул хакта?Югыйсә, игътибарга алмаслык, колак читеннән генә уздырып җибәрерлек оешма да түгел ләбаса инде?

Юлга чыгар алдыннан ул телефон аша Зәет Вәлиевичны эзләде, тик төштән соң филиал башлыгының койрыгын тотулары ай-һай иде, кесә телефоны да сүндереп куелган. Барый идарәдә аптырап утырды утырды да, гаражга барып, УАЗик машинасын кара төстәге БМВ сына алыштырды, арткы утыргычка ау мылтыгын салды, пистолет кобурасын киеп куйды. Бала башлы бүрене ауларга барганда гына шулай коралланa торган иде ул. Хәер, бу юлы гранаталарын

алмады, ни әйтсән дә ул «уенчыклары» законсыз бит—курыкты егет. Әүвәл ул туп-туры урманга таба юл тотты, Гөлйөземне, малаен күрәсе килде. Ни булмас анын белән? Кияүгә чыгу хакында тәкъдим ясарга күптән йөри бит инде, хәзер менә шул турыда тагын бер кат әйтеп китсен әле.

Бүген аны урман бик тыныч каршы алды. Барый уенча, әллә нинди серле, хәттә шомлы тынлык иде бу. Әллә курыкканга куш күренә дигәндәй генәме соң? Урман авызына кереп, бераз баруга, туктап, машинадан төште һәм, мылтык көпшәсен югарыга күтәреп, төзәми-нитми генә атып та җибәрде, үзенчә бу хәерсез тынлыкны бозасы килде. Ату кайтавазы кире әйләнеп кайтырга өлгермәде, агач башыннан Барыйның аяк астына, шапылдап, канга баткан нәни тиен баласы килеп төште. Бу хәлне күреп ул авызын ачып катып калды, аптырап яралы тиенгә карап тора башлады. Тиен баласы әле җан биреп өлгермәгән иде, гәрчә бүре ядрәләре аны чәрдәкләп ташлаган, иләк ясаган булса да. «Җүнле фал түгел бу...»—дип уйлады Әкбәров. Чыннан да, бер килмәсә килми бит ул. Габитов та аны юкка гына чакырмагандыр, хәерлегә түгелдер бу эш-гамәл? Әллә барып тормаска инде?! Һе, Габитов чаклы Габитов чакыргачмы?.. Аның бит тән сакчылары да Дәү филиал башлыгыныкыннан күбрәк дип сөйлиләр. Белеп әйтәләрме, белмичә такылдыйлармы—анысы әлегә Барый өчен караңгы. Әллә Мөхәммәткә шылтыратып карарга инде?.. Хәер, ул ни белсен ди...Чү, туктале...ә Хәниф Хатыйпович!!! Бу фикеренә Барый үзе дә сөенеп куйды. Ничек бая ук башына килмәгәндер! Малай-шалай кебек коралланган булып чыгып китәргә әзерләнде бит! Әлеге уйлары Әкбәровны үсендереп җибәрде. Ул, машина алдында яткан тиен үләксәсен аяк башы белән генә читкәрәк эштереп җибәрде дә, руль артына сикереп менде. Әүвәл Гөлйөземне күрергә!..

Гөлйөзем өйдә ялгыз башы гына иде, Әнвәрне әбисе туганнарына кунакка алып киткән булып чыкты. Малайның башыннан сыйпыйсы килгән булса да Гөлйөземнең үзе генә булуына ул хәттә сөенеп тә куйды әле.

Гөлйөземнәрнең капка төбенә килеп җитүгә, Барый ничектер тынычланып калды, Габитов та офык артынарак күмелгән кебек булды, тиен үләксәсе дә онытылды.

Һай, җан тынычлыгы дигән нәрсә! Сине бернинди акчаларга да, тау- тау алтыннарга да сатып алып булмый икән ләбаса! Нишләп адәм баласы шуны баштук аңламый икән? Югыйсә, гел шуңа гына омтылып яшәгән булыр иде канә!.. Һай, адәм баласы...

Гомердә булмаганча, Гөлйөземне күрүгә исә югалып калды Әкбәров: баягы җан тынычлыгы да, өстәвенә монарчы булган кыюлыгы, бәйсезлеге, җыртлачлыгы, гомумән, «барыйлыгы» бер йомгакка җыелды да табан астына тәгәрәде инде менә! «Йа! Мин дә ояла белермен икән!»—дип, үз-үзенә шаккатып басып торды ул беркавым. Тик кайдан белсен: «КамАЗ» кабинасындагы хәерсез хәлләрдән соң яшь хатын да үзе түгел иде бүген. Аның хатын-кыз җанын курку хисе биләп алып, шуның өстенә миен бертуктаусыз җүнсез бер хис кимерә: «Барый белә торгандыр, белә торгандыр, Сәмигулла дуңгыз—Барыйга үчле адәм—мыскыл итеп, мактанып сөйләнеп йөргәндер дә, барып ишетелгәндер».

Югыйсә, әнә бит: элеккеге Барыйны бүген әллә ничек кенә үзгәртеп куйганнар кебек, сәер ул, икенче ул бүген, Барыйга охшамаган да төсле. Ярабби бер аллам, әгәр чыннан да ишеткән булса, белә торган булса... ул аны... ул аны урманга алып чыгып!..

Гөлйөземе каршында уклау кебек катып сүзсез басып тору унайсыз. Күрәләтә үз-үзеңне саткан кебек... Сүз булсын өчен генә ул авызын ачты һәм тел тегермәне аннан сүзләр дә әйләндереп чыгарды:

—Урманнарны бер әйләнеп керикме соң?

Бу сүзләр хатынны пычаксыз суйган кебек булды, ул куырылып килде, тәне аша бер көтү кырмыска чабышып узды, иреннәре дерелдәргә кереште. Ләкин хатын-кыз үзенең «хатын-кыз» икәнлеген инстинкт белән теләсә нинди кыен вакытларда да исенә төшереп, һәр төрле авыр мизгелдә шуны калкан итеп файдалана, организмы җитәрлек микъдарда тиз генә моңарчы табигатьтә билгесез һәм гаҗәеп саклану көченә ия булган сок бүлеп чыгарып, шул аны бар бәлаләрдән саклап кала иде. Гөлйөзем белән дә шулай булды: «Хәзер Барыйның чәченә ябышам? Мари хатыны янына барып йөргәнен исенә төшерәм дә...»

Хатынның иреннәре дерелдәвен буйдак ир үзенчә юрады: «Ярата, сагынган!.. Ә мин, җүнсез, мари хатыннары янына йөрим! Шундый Гөлйөземем була торып!..» Ул хатынны сак кына үзенә таба тартып китерде дә дерелдәгән иреннәренә битен тигезеп алды. Каен җиләге, урман курасы гына үбеп үскән затлы иреннәр!.. Һай, нигә берәр галим, Барый туганчы ук, мәхәббәт, ярату дигән хисләргә аңлатма биреп, адәм баласының йөрәгендәге хисләр микъдарын тәгаен үлчи ала торган җайланма уйлап тапмаган икән соң?!

Мәсәлән, температураны үлчи торган градусник кебек. Йөрәк турысында беркавым тоттың—вәссәлам: шул хатын-кызга карата синең мәхәббәтең нуль яки йөзенче сызыкка килеп җитә язган. Аннан соң бернинди шикләнү-икеләнүләр дә калмас, гаиләләр дә бәхетлерәк булыр, яшьләр дә тотрыкланыр, чәчәктән чәчәккә кунган күбәләктәй саташып йөрмәсләр!..

Барый шундый юк-бар хыяллары белән ишеккә таба атлады, Гөлйөзем аның артыннан иярсә дә иярде, иярмәсә дә иярде инде.

Бу мизгелләрдә икесен дә бер уй газаплады: күңел түрендә ниләр кайнаганын бер-беренә ничек тә сиздермәскә иде. Ләкин алар бәяләп җиткермәделәр—адәм баласының күңеле нәкъ көзге кебек ул—эчтәге хисләр икесенең дә гамәл-кыланышларыннан ук чагылып тора, моны алар бары тик икесе дә берүк халәттә булганга күрә генә сизеп, төшенеп җиткерә алмыйлар, хәзергесе мизгелләрдә икесенә дә уртак булган бер шөгыль табудан да мәслихәтрәк гамәл юклыгын исә җаннары белән тоемлыйлар, тик ул уртак шөгыльнең тәгаен генә ни икәнлеген белмәгәнлектән, аптырап, чал нарат башларына, рәт-рәт булып утырган каен ябалдашларына карыйлар. Әмма ул уртак шөгыль агач башларында асылынып тормый иде. Алар урман эченә табарак уздылар. «Карале, кара!—диде Гөлйөзем шулчак сөенечле тавыш белән бәләкәй генә аланлыкта үскән ике нарат агачына таба ымлап:—Ничек үскәннәр бит!»

Сыенышып үскән ике нарат агачының берсе ничектер янәшәдәгесенә башын салган кебек. Югыйсә, үз йортларыннан әлләни ерак булмаган бу агачларны ул гомере буе күреп үсте, әмма игътибар итмәгән булган икән моңарчы. Менә бүген күрә, беренче мәртәбә күрә!.. Гаҗәп бит инде бер уйлаганда! Агачларның мондый кыяфәтен күрә торып, янәшәндә генә басып торган хатын-кызны кочагыңа алмыйча һич мөмкин түгел бит...

Урман аларның икесен дә кыен хәлдән коткарды, рәхмәт төшкере. Хәер, урманның үз кызына беренче мәртәбә генә ярдәм кулы сузуы түгел инде бу...

...Барый килеп җиткәндә, Садыйк Сираевич өйдә юк иде әле. Ул хуҗаның кайтканын урамда, машинасында утырып көтәргә уйлады.

Өйрәнгән гадәте буенча радионы кабызмакчы булды, ләкин кул хәрәкәтенә кадәр үк радиомагнитоланың юк икәнлеге исенә төште: узган атнада гына джипның ишеген каерып ачып, аны урлап киттеләр, авылда бит әле, үзенең туган авылында ук!.. Бу хәл исенә төшкәч, Барый күңелсезләнеп китте. Соңгы елларда шәһәрләрдәге тәртипсезлек,—кая ул тәртипсезлек кенә булсын

ди! Чын мәгънәсендә бандитлык, хулиганлык, ахыр чиктә аны авыз тутырып «бандитлык һәм оешкан җинаятьчелек» дип атап булыр иде,—авыл җиренә дә килеп керде, тора- бара авыллар шәһәрне дә арттырып җибәрделәр! Баксаң, нинди авыл иде ул! Кемнең казы ничә бәбкә чыгарганны да, кемнең тавыгы тәүлеккә ничә йомырка салганны да бар халык сәгате-минуты белән белеп тора торган эчкерсез, наив авыл иде. Югыйсә, моннан бер дистә ел элек кенә бит әле!.. Бу үзгәртеп кору дигәннәре тыныч кына үз көенә яшәп ята торган кырмыска ояларын бутады да атты: ата улны, ана кызны танымаслык хәлгә китерелде мескен халык. Әлбәттә, Барый заманның үзгәрергә тиешлеген үзе дә яхшы белә һәм ул хәлләргә каршы да түгел. Ләкин болай ук булыр дип берәү дә күз алдына китермәгән иде.

Совет дәүләтен яһүдләр җимерде, чөнки аларга «капканы» төбенә чаклы ачып куеп, «урыс еврейларын» СССР төрмәсеннән коткарырга кирәк булды. Яһүдләр Израильгә агылды, калганы монда калды һәм элеккеге куәтле дәүләтне эчке яктан таркатырга кереште. Әлбәттә, җимерекләр Израильнең үзенә дә бәхет китермәде: каннары, җаннары гасырлар буе урыс холкы белән сугарылган тугандашлары аларга бары тик кайгы-мәшәкатьләр генә алып килде. Палестина белән сугыштан һаман башлары чыга алмый бахырларның...

Әлбәттә, Барый үзе болай ук, бу рәвешле үк фикер йөртми, әлеге «сәясәт» Мөхәммәт аша колагына кергән сүзләр һәм нәтиҗәләр иде... Ул шулай дип уйлап бетерергә дә өлгермәде, аның машинасы артына чит ил машинасы килеп туктады һәм аннан Мөхәммәт үзе сикереп төште. Барый Мөхәммәтне күргәч, әллә нишләп китте! Ләкин бу хәлне ни дип юрарга да өлгермәде, тегесе йөгереп килеп, машина ишеген ачты һәм аптыравыннан катып калган дустын кочаклап, машинадан тартып төшерде.

«Нишләп йомырка баскан каз кебек утырасың монда, төш!—диде ул гөрелдәп көлә-көлә.

—Ә сиңа монда ни калган?

—Менә син киләсе дип ишеттем дә. Ярты сәгать элек кенә Садыйк Сираевич үзе шылтыратты.

«Садыйк Сираевичны Мөхәммәт кайдан белә?» дигән уй-сорау миен бораударга керешсә дә, үзе сөйләп бирер әле дигән өмет белән әлегә сүз катмый торырга булды.

—Соңгы арада авылга да кайтканың юк, онытгың,—дип кенә куйды ул.

—Авыл халкының синнән зарланганын тыңларга дип кайтыйм мыни анда!—дип, төрттереп алды Мөхәммәт.

Дустының бу сүзләреннән соң шартлатып җавап бирергә бик теле кычытса да Барый бу юлы дәшмәде, аны хәзер авыл түгел, үз язмышы күбрәк борчый.

—Мине монда ник чакырттылар икән, белмисеңме!

Тегесе көлеп җибәрде, кыяфәтенә караганда белә һәм бик яхшы белә иде. Бу исә Барыйга җиңеллек китерде, дусты дорфарак сөйләшсә дә үпкәләргә ашыкмады, аны игътибар белән тыңлаячагын белдереп, күзләренә карады.

—Сюрприз, хәзер үзең күрерсең, тик борчылма, бу очрашу синең файдага булачак.

Ул шулай дип әйтеп бетереп авызын ябарга да өлгермәде, дустының кесәсеннән әтәч кычкырган тавыш ишетелде һәм шуның артыннан ук музыка уйнарга кереште. Мөхәммәт ашыкмыйча гына куен кесәсенә тыгылды һәм аннан кесә телефонын алып колагына куйды:

—Да, мин тыңлыйм.

Барый аның кем белән сөйләшкәнен белмәсә дә дустының дулкынлануына караганда эфир дулкыннары юк кына кеше тавышын алып килмәгән иде. «Мин аңладым, борчылмагыз. Сез дигәнчә булыр!» дип, борчу катыш шатлыклы тавыш белән җавап бирүләре Мөхәммәтнең бик җитди кеше белән

сөйләшүен аңлата, тик ул әлеге иптәшнең «Садыйк Сираевич, Садыйк Сираевич!» дия-дия исемен кабатлап, Барыйга күз кыскалап куйса да, тегесе аның кем белән гәпләшкәнен һич төшенеп бетерә алмады.

—Садыйк Сираевич үзе шылтырата, бүген күрешеп булмый ди. Киләсе атнага инде. Үзем хәбәр итәрмен диде. Ә мин сиңа...

—Нинди Садыйк Сираевич? Габитов үзе шылтыратмагандыр ич!?

—Үзе шул...

Барый янә беренче мәртәбә сабакташына күтәрелеп карап куйды... Ышанмыйча аптырапмы, көнләшү хисләре беләнме—монысын бу мизгелләрдә икесе дә анык кына төшенеп бетерә алмадылар. «Алай, үзгәргән бу малай!»—дип уйлап куйды Барый. «Менә мин кемнәр белән эш итәм! Хәзер син лидер түгел, мин, председатель малае!»—ди иде шикелле аның карашы. Тик ике дус, ике сабакташ арасындагы бу дөньяви, дөресрәге, мин-минлеккә вә исәп-хисапка корылган, әмма бик тә мантыйклы халәт озакка сузыла алмады. Һәрхәлдә, авылда яшәп ятучы Барый Әкбәров шулай дип уйлады. Әмма дөньяның Садыйк Сираевичлары белән кесә телефоны аша гына сәламләшә торган шәһәр кешесе алай вакланып, уй-күңелендә чокынып тормады, ярды да салды:

—Син исеменнән үк котың алынып торган Садыйк Сираевич белән без күптәнге дуслар! Аның монда сине ни өчен чакыртканлыгын да мин бик яхшы беләм. Әмма мин сине дә яхшы беләм. Шуңа күрә сине махсус үзем чакырттым, әүвәл Садыйк Сираевич белән аерым сөйләшерсез дигән идем. Булмады бит менә. Очрашу—киләсе атнада. Кыскасы шул: абзый сине бик охшаткан!

—Кит әле моннан! Мине каян белсен ди ул?! Күргәне дә юк ич?

—Беләләр, туган, беләләр... алар барысын да белеп тора.

—ФСБ ашамы?—дип, беркатлы сорау бирде Әкбәров, чөнки әлеге оешманың үзе белән кызыксынганын филиал башлыгыннан бер ишеткән иде инде.

Мөхәммәт ирен читләре белән генә серле итеп елмаеп куйды да, нигәдер авыр сулап:

—ФСБ дан да хуже,—дип куйды. Өстәп тагын нидер әйтмәкче иде, тик тукталып калды, аннары Садыйк Сираевичның коттеджы капкасы ягына таба ымлап:—Әйдә, керәбез, үзең күрерсең,—диде.

— Да ты што! Хужа үзе югындамы!?

— Хуҗа булмаса, хатыны, кызы, малае өйдә.

«Шулчаклы тыныч, гади итеп кенә сөйләшә бу Мөхәммәт, әллә Садыйк Сираевичның кияве булырга йөри инде?»—дип тә уйлап бетермәде, тегесе аның фикерләрен укыгандай:—Бик шәп кызы бар аның, таныштырам!»—дигән булды. Мондый табышмак сөйләшү Барыйның кәефен үк җибәрә башлаган иде, ул дорфа гына:

—Үзең таныш!—диде.

—Мин бик танышкан булыр идем дә...

—Гөлчәчәк дисеңме?

—Причем монда Гөлчәчәк!

—Ничек причем?!

—Шулай причем... Ул кыз менә синең белән танышырга тели ди икән шул.

Барый дустына ачулы итеп карап алды: «Шаяртма!» янәсе.

— Чынлап, дустым, чынлап. Син монда мине гаепләп утырган булма, үзең сөйлә! Ничек итеп син Садыйк Сираевичның кызы белән таныша алдың?! Урманда ятып, авылда торып! Менә бу табышмак! Мин түгел, син үзең тел яшереп маташасың, дускай!

Мөхәммәтнең тавышында чак кына дустына үпкә дә сизелә, имеш, мин сиңа барысын да сөйләп, житкереп торам, эч серләремне синнән яшергәнем юк, ә син... ә син! Кыскасы, син шактый хәйләкәр дус булып чыктың әле диясе килә шикелле иде.

Дөньяда аңлашуның төрле чаралары бар: телләр белән, язмача, куллар, ымлыклар, күз карашлары ярдәмендә. Шуларга күнелләр аша аралашуны да өстәргә мөмкин, ягъни биотоклар ярдәмендә. Аңлашуның мондый төре үзара шактый якын кешеләр арасында гына була торгандыр. Мәсәлән, ыштансыз чактан ук бергә әүмәкләшеп, әвәрә килеп үскән авылдаш-яшьтәшләр арасында.

Барый да Мөхәммәтнең ни әйтергә теләгәнен шундук төшенеп алды һәм үзен гаепле сизгәндәй:

—Үзебез турында без идеаллар аша, калган кешеләр хакында аларның гамәлләре буенча хөкем йөртәбез,—дип куйды.—Әлбәттә сөйлим, дустым, синнән яшерен сер юк. Тик мин әлегә нәрсә сөйләргә икәнлеген генә аңлап бетермим. Билләһи!

—Садыйк Сираевичның кызы Әлфияне белмисеңмени?

—Әлфия?!

—Әйе, әйе, анда синең Гөлчәчәк белән төшкән фотокарточкаң да бар.

Барыйның аптыравы йөзенә үк чыгып, ул инбашларын сикертте.

—Алайса киттек, таныштырам,—дип, Мөхәммәт Барыйны тимер капкага таба этте. Аннары ул никтер кире уйлап, инде үзенә буйсынып, капкага кузгалган Барыйның жиңеннән тартты һәм бик житди кыяфәт белән:—Узган атнада урманда бер кыз белән танышып, аны Казанга кадәр илтеп куйдыңмы?

Барый, аптырап, тирә-ягына карады, тагын бер мәртәбә үзләре басып торган урыннарны күзләп чыкты һәм шулчак аның кыяфәтендәге гажәпләнү, аптырау ниндидер кызыксыну белән алышынды кебек.

—Так, так, Әлфия! Исемә төште, неужели ул, ул кыз... Садыйк Сираевичның кызы булган икән?!

—Булган гына да түгел, Садыйк Сираевичның берданбер сөекле кызы!

Мөхәммәт кинәт тагын да житдиләнеп китте, күренеп тора: дусты үзе дә аптырауда, ләкин аның аптырау галәмәте Барыйныкы шикелле яңалык ишеткәннән түгел, ә бәлки чарасызлыктан иде. Шулай да, ул үзен тиз кулга алды һәм кискен карарга килеп:

—Киттек моннан!—дип, Барыйның жиңеннән тотты.—Кирәк булса, үзләре эзләп табарлар әле, син кияү егете түгел. Просмотрга килергә монда!

Барый, карышмыйча, аның артыннан иярде, һәркайсы үз машинасына утырып, кузгалып киттеләр. Казанга борылган юл чатында туктарга килештеләр.

Әлбәттә, мондый карарга килер алдыннан Мөхәммәтнең башыннан мең төрле уй-фикер узды, егет, бигрәк тә соңгы вакытларда, һәр адымын ныклап уйларга өйрәнде: тормыш үзе өйрәтте. Авызын пешерә-пешерә өйрәтә бу тормыш!.. Чынлап та, адәм баласы үз хаталарында күбрәк өйрәнә. Бу ясалма теория, юкка акыл сату гына түгел, ул—Табигать кануннары. Табигать кануннарына каршы килеп кешелек дөньясы күпме хата-ялгышлар кылды инде, нәтижәсе һаман берүк: миллионнарча корбаннар, ачлык һәм хәерчелек булды. «Миллионнар үлеме—статистика, бер кешенең һәлакәте—фажига»,—дип әйтеп калдырган Черчиль мең мәртәбә хаклы бу очракта. Барый дустының язмышыннан фажига ясыйсы килми иде Мөхәммәтнең. Үзенең шушы жәтмә корбаны булуы житмәгәнмени!!! Хәер, корбан дип инде... Ләкин шулай да...

Әгәр Садыйк Сираевич Барыйны Әлфиясе белән бәйләп куярга уйласа, Гөлйөзем ни хәлләр кичерер? Аларның балалары бар бит әле. Һәм нигә ике тинтәк авылдаш малайлар аркасында ул жиләк кенә үбеп үскән урман кызлары

бәхетсез булырга тиеш ди?!. Ул үзе Гөлчәчәкне күзенә карап алдап йөри бит!.. Хәер, алдап дип инде... Һәрхәлдә, бүгенге көнгә чаклы егетнең әлеге йомгакның очына чыга алганы юк. Адәм баласы һәрвакыт күпмедер микъдарда эгоист. Үзен аклап соңгы чиктә ул барыбер саламга булса да тотынырга талпыначак...

Фу... Бетмәс-төкәнмәс уйлар ташкыны, аның башындагы уйлар кебек язгы ташуларда Ташсу елгасы да бу чаклы болганмый торгандыр, билләхи!

Ни әйтсәң дә кыюсыз, боламык егет түгел Мөхәммәт. Сиринә Самуиловнаның да күзенә карап әйтте ул беркөнне. Афәрин, әйтте егет әйтәсен. Әмма икенче көнне үк тормыш күсәге аның башына китереп тондырды, ул мингерәүләнеп калды.

Шулай чираттагы бер шимбәдә Мөхәммәт Бөгелмәгә кайтырга җыенды. Самолетка билетын да алдан ук алып куйды. Бер-берсе белән еш аралашканнан һәм еш кына Сиринә Самуиловнада куна да калганлыктан, алар арасында сер юк кебек иде. Ләкин Гөлчәчәк янына кайтырга җыенуын ул Сиринә Самуиловнага сиздермәде, яшерен сер итеп саклады. Хатын-кыз сизми ди мени сон! Тегесе моны белеп алып, ул көнне сәнгатькәрләр идарәсендә мөһим җыелыш билгеләттерде. Сүз филиал рәссамнарының Мәскәүдә узачак шәхси күргәзмә планын раслау хакында барырга тиеш. Мөхәммәтнең күргәзмәдә катнашырга теләве хакындагы гариза Идарәдә күптәннән ята, өстәвенә әлеге мәсьәлә моңарчы ук та хәл ителгән иде инде, чөнки ул бәйгедә беренче урынны яулап алган рәссам. Бәйге шартлары буенча исә беренче—өченче урыннар «автомат» рәвештә узарга тиеш диделәр. Әнә шуларны уйлап, Уразов билетын кире тапшырмады, аннан соң алдан хәбәр ителгән Гөлчәчәк тә көтеп тора бит. Бу хакта каяндыр белеп алган Сиринә: «Мәсьәлә бик җитди бит, бәлки катнашырсың»,—диде.

Бу сөйләшү җомга көн кичтән булды, эштән соң Сиринә Самуиловна аны ашыгыч рәвештә үз фатирына чакыртып алды.. Чакыртуының сәбәбе чынлап та җитди икән: Сиринә Самуиловнаның Чиләбедән дус кызы килгән, ул да сәнгать белгече. Изольда Сафаровна Сиринәгә караганда шактый яшьрәк булса да, үз-үзен тотышы белән бер генә дә дустыннан калышмый, хатын-кыз таланты (хатын-кызлык сәләте, Адәмнән аермалы буларак, Хәва ханымга өстәп иңдерелгән өстәмә талант) янына тормыштан килгән ясалма кыланышгамәлләрен дә кушып куйсаң, әле шактый яшь булуына кармастан, үз дигәненә ирешә ала торган ханымга охшаган. Шуның өстенә гаҗәп чибәр дә, каһәрең!.. Ни әйтсәң дә, матурлыгы ясалма матурлык түгел, зәвыклы хатын табигать биргән байлыгына бер генә артык буяу да өстәмәгән. Сиринә Самуиловна иртән торгач, Мөхәммәткә «чын йөзен» күрсәтмәс өчен тизрәк ванна бүлмәсенә бикләнеп, ясанырга, буянырга керешә, аннан бары йөз-кыяфәтен «сылагач» кына чыга. Әлбәттә, Сиринә Самуиловна Мөхәммәтне үзенә әлеге чибәр дустын күрсәтергә чакыртмагандыр. Ләкин егет тә сукыр түгел бит инде, кычкырып торган матурлыкка күзен йомып, үзен бүкән сымак тота алмый, килеп керешкә үк ул Изольданың чибәрлегенә соклануын яшерә алмады, сүз белән әйтмәсә дә бу фикере аның кыяфәтенә үк бәреп чыккан иде. Гөлчәчәк исемен ишетүгә болай да кара тутыл йөзе тагын да карангылана торган Сиринә Самуиловна Мөхәммәтнең кунак ханымга сокланып каравына игътибар итмәгәнгә салышты, киресенчә, Изольданың егетнең күңел шәрәфләренә хуш килүенә сөенде генә кебек. Хатын-кыз—мәңгелек табышмак. Яһүд белән татар катыш Сиринә Самуиловна исә—табышмакларның да табышмагы. Шуңа өстәп: «Сиринә Самуиловна елый белми торган хатын-кыз ул!»—дисәк, әлбәттә, моңа берәү дә ышанмаячак, чөнки һәркемгә мәгълүм аксиома—елый белмәгән хатын-кыз булмый ул дөньяда диярләр. Ләкин ни хәл итәсен, Сирина ханым чынлап та елый

белми һәм елый да алмый иде шул... Битендәге иннек-кершәненен күз яшьләренә чылануыннан куркып түгел, билгеле. Холкы белән, табигате белән шундый хатын ул. Хәер, бер мәртәбә ул да елаган икән. Һәм ул беренче мәртәбә Мөхәммәтне очраткан көн... Дөресрәге, егетнең үзен күргәч йөрәгенең кайсыдыр чите кысылып куйды куюын, тик менә рәссам егетнең «Урман кызы» әсәре белән танышып, аның кемгә багышланганын белгәч, кычкырып-кычкырып елады ул. Тик кайгы-борчудан түгел, шатлыктан елады хатын-кыз ул чакта. Шундый кешене очрату шатлыгыннан... Егетнең үз йөрәгендәге мәхәббәтен сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрә алуы сокландырды, хуштан яздырды кыз-хатын өммәтен! Гомере буе кешеләргә сәнгать әсәрләренең серен, мәгънәсен аңлатып һәм шуны үзенең һөнәре итеп сайлаган ханым-солтаным үзе дә бермәлгә югалып калып, табигатьнең шул гүзәл гармониясенә жаны-тәне белән гашыйк булды, йөрәгендәге көнчелек уты (бу шашкын ут ярты дөньяны мизгел эчендә көйдереп, ялмап алырлык куәттә иде) аның инде сүрелә барган күңел учагына ялкын элеп, һәр күзәнәгенә үтеп керде. Бу хәлләрнең сәбәпчесе, әлбәттә, Мөхәммәт Уразов иде... Хәнип Хатыйповичка ул яшьлеге, җүләрлеге белән кияүгә чыгып, тиз генә араларын өзгәннәр иде. Гаилә тормышы ызгыш-талашка барып житкәнчегә кадәр үк. Ләкин бу кушылу да эзсез генә калмады, икесе дә үлеп сөйгән кызлары инде үзе буйга житкән...

Сиринә ханым, яши торгач, бар нәрсәне дә хәл итә алырлык кодрәтле ханымга әверелде. Ул үзен бик көчле дип уйлый. Ләкин Мөхәммәт белән очрашкач, беренче мәртәбә үзенең мескенлеген, көчсезлеген тойды һәм шуңа гарьләнеп үлә язды. Гөлчәчәк атлы ниндидер бер авыл, кыргый урман кызы каршында да көчсез бит ул!.. Шул хис аны үтереп ташлады, барлыгын юкка чыгарып, салып таптый һәм бүгенге көнгәчә изеп-сытып тора. Әнә, бит... Мөхәммәт иртәгә тагын шуның янына жыена. Хәленнән килсә, Сиринә ханым аның фатирына бер олау фахишә кызлар кертеп тутырыр, ләкин Бөгелмәгә җибәрмәс иде...

Алар кич буе рәсем сәнгате хакында сөйләштеләр, төрле рәссамнарның альбомнарын актарып утырдылар. Кичке сәгать унберләр тирәсендә Сиринә ханымның фатирында телефон шылтырады. Телефонның теге очында Хәниф Хатыйповичның яшь хатыны Сиринә Самуиловнага кызып-кызып нидер аңлатты, сөйләде. Ул хатын Хәниф Хатыйповичка Сиринәдән соң кияүгә чыккан яшь хатын иде. Хужага янә депрессия булган, хатыны ярдәмгә көндәшен—Сиринә ханымны чакырып ята. Ул, тиз генә киенеп, кунакларыннан гафу үтенде дә, чыгып китте—аны подъезд төбендә Хәниф Хатыйповичның алты йөзле «Мерседес»ы көтеп тора иде инде.

*Ахыры киләсе санда.*



Рəзинə
Мөхияр

# УЙ КЕРДЕ—АЙ КҮРДЕ...

***

Бер сандугач булып...—
Шигырь шакый күңел тəрəзəсен,
Мөлдерəмə тулып.

## Күктə болыт

Күктə болыт, кузгалмыйча,
Бер урында катып калган,
Әйтерсең лə борчуларым,
Кайгыларым шунда салган—
«Сиңа авыр, көчең җитмəс»,
Дигəн кебек, күккə алган.

* * *

*Ахыргача барам*
М. Әгъләмов

Ахыргача барам, ахыргача:
Яуга чыккан атлар тукталмый.
Көрəшлəрдə янган көрəшчене
Мəкер, хөсет дигəн ук алмый.

Ахыргача барам, ахыргача:
Яуга чыккач—бары җиңүгə!
Көнчелектəн шашкан дошманнарның
Көч-куəте барыр шиңүгə.

## Рəхмəт, Аллам!

Рəхмəт, Аллам,
Миңа биргəн
Сынауларның
Барсы өчен!
...Тикшердеңме
Сабырлыгым
Чиген, көчен?!—
Бер-бер артлы
Сынау тездең...
Авыр... түздем.

Башкаларның
Чəчлəренə
Ябешмəдем.
Үз чəчемне
Берəм-берəм
Тартып өздем.
Рəхмəт, Аллам!
Миңа биргəн
Сынауларның
Барсы өчен.

* * *

Күрə башлар, бик күп күрə.
Ахырзаман: бар да түрə.

***

Тормыш мизгелләрен
Кемнәр тезгенләде?!.
Җаным тезләнмәде.

## Уй керде

Уй керде башыма,
Башыма уй керде,
Уй керде—ай күрде
Һәм шигырьгә төрде.

## Канатсыз кош

«Канатсыз кош син»,—димә,
Канатыма син тимә!
Үтә күренмәлеләр,
Тик миңа күренәләр.

Очам шул канатларда,
Теләмим дә атларга.

Очам җирдән югары
Күккә таба, юк, ары...—

Галәмнәрне иңлим мин,
Кеше кошка тиңдер дим.
Сындырма, син, канатым,
Сындырырга юк хакың.

## Нур сибәм

Су сибәм гөлләремә,
Гөлләремә су сибәм.
Гөлдәй шигъри юлларым
Ак нурлар итеп сибәм.

Ак нурлар итеп сибәм,
Йөрәкләргә юл сузам.
Ап-ак нурлы юллардан
Аккоштай йөзеп узам.

## Шөкер

Сынаулар бирәсең син, дөнья!
Мин риза, шөкер.
Башым исән булсын, рухым нык,
Калганы... төкер.

Сынадың, сыныйсың, сынарсың,
Нишлисең... шөкер.
«Сынмый бит» дип!—дошманнар
көйсен,
Әйтәмен зекер.

## Моңнар ява

Көй агыла
Моң тавына.
Карлар булып,
Моңнар ява.

Моңнар ява,
Йөрәк яна.
Янмас иде—
Тирән яра.

Яраларга
Моңнар ява.
...Йөрәгемне
Әйдә, яма!

***

Дөнья авыр,
Булсаң камыр...
Йөрәгеңне
Сагыш сарыр,
Булсаң да син
Артык сабыр.

**Редакциядән:**
*Бу айда шагыйрә, Чаллы педагогия институты профессоры Рәзинә Мөхиярнең юбилее. Аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!*



Альберт
Хәсәнов

# ҖӘНБӘТ ЫРУЫ

ПОВЕСТЬ

## Кәрван башы Әбү-Бәкер

Кече кызым Гүзәл, Яңа ел алдыннан гына, унике кадак авырлыктагы тагын бер малай алып кайтты. Нарасый баланың үә-үәсенә, тик имчәк баласыннан гына килә торган дөньяда бер татлы әчкелтем искә тәмам тансыкланыек. Бу тантаналы вакыйга бөтен гаиләбезгә сөенеч өстенә сөенеч, шатлык өстенә шатлык булды. Миндә оныклар байтак. Барысының да үз холкына тиң кушаматлары бар. Монысына «Миш-шәр!» дип тактым кушаматны. Атасы Буа мишәре булгач, улы да мишәр булмый кем булсын?!

Бу оныгыма да барыннан бигрәк үзем сөендем. Түбәм болытларга ашты. Кызымны да бүләккә күмеп бетердем. Түтәлдән генә казып алган шалкан кебек тыпырдап торган, сау-сәламәт бала алып кайтканы өчен. Юкса, ил өстендә Кара кош йөри, соңгы вакытта яшь аналар акыл һәм физик яктан сау-сәламәт балаларны сирәгрәк апкайта башладылар. Баланың, нарасыйның кайсы да татлы. Гарибен дә юынтык су белән чүплеккә чыгарып түгә алмыйсың. Бер утырып елыйсың да, бөтен жирен үбә-үбә карый, үстерә башлыйсың.

Ә таза-сау, сәламәт баланың нинди зур бәхет икәнен олыгая барган саен тирәнрәк аңлыйсың, сөенәсең. Тьфү, тьфү, күз генә тия күрмәсен үзенә дип, кабатлап кына торасың. Әйе, шулай туган сәгатеннән үк үсәм дип торган оныгым булгач, ул көннәрдә кая басканымны белмәдем. Әнисе дә терелеп бүлнистән кайткан көннәрендә үк мәчеткә йөгердем. Араларыннан иң сөйкемлесен, иң гыйлемлесен сайлап, мулла абзыйны алып кайттым. Сәдакасын да мулдан биреп, оныгыма Биктаһир дип исем куштырдым. Сөйгәндә, кулга алып яратканда кушу өчен «Миш-шәр!» кушаматын да көчендә калдырдым.

Баланың берсе дә еламый гына үсми. «Үә-үә» дип елавы—аның яшәү рәвеше. Анысына сөенергә генә кирәк. Әмма кадерле вә тансык

---

Альберт ХӘСӘНОВ (1937)—*язучы; «Сөенеч», «Кемгә сөйлим серләремне», «Кан үче» һ. б. китаплар авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Биктаһирыбыз кичләрен сыны катып елый, балакаем. Әнисе кулына мин аны болай да имезергә генә бирә идем. Ә хәзер улымны кулымнан төшермим. Күкрәгемә кысам. Әлли-бәлли итеп карыйм. Ә бала үзен кая куярга белми.

—Тансыгым, кай җирен авырта сон, кашкалы колыным, таем!—дим.

Зәңгәр сәдәф кебек матур күзләрен мина төбәгән сабый:

—И-и, дәү әтием, һич түзәр хәлем юк, эчем бик авырта,—дип, теле белән генә әйтми. Ә табибларнын сүзе бер:«Это все временно. Пройдет!»

Пройдет та пройдет, балага менә хәзер авыр. Түзәр хәле калмый, сыны ката. Андый чакта кинәш бирүчеләр күп була бит. Бүсере бардыр баланын, өшкерә белүче әбигә алып барырга кирәк, диләр. Институтта укыган елларымда, алай-болай «өчлегә», «икелегә» биреп стипендиядән колак кага күрмим тагын дип, марксизм-ленинизм тәгълиматларын да бик тырышып өйрәнгәнием. Ә башына төшкәч, башмакчы буласын. Кочагында нибары ике-өч атналык тансыгын ыңгырашканда атеистлык онытыла, егетләр. Әгәр сез дә чын егет булсагыз, мине шундук аңларсыз. «Әнә, чуваш Тумбарлысында, авыл кергәч тә бер ялгызы яшәп ятучы, бик оста өшкерүче чуваш карчыгы бар»,—диләр. Машина яллап, шунда чыгып китәбез. «Шөгердә бик оста өшкерүче татар әбие бар»,—диләр. Машинага улымнын йә әнисен, йә дәү әнисен дә утыртып анда барып кайтабыз. «Ин оста, ин шифалы өшкерүче әби Карабашта»,—дигәч, анда чыгып йөгерәбез.

Таксистлар да керә башладылар хәлебезгә. «Бик оста өшкерүче әбиләр Әлмәттә, Бөгелмәдә, Баулыда!»—дип, өйгә шылтыраталар. Аларга да ипле бит даими клиент белән эш йөртү. Әлмәткә барып кайту өчен өч йөз сорыйлар. Әбиләргә һич дәгъвам юк, өшкерүен бик тырышып өшкерәләр. Әмма бераз котәргә кушалар, бүсереннән менә бүген үк, шушы сәгатьтә үк котыла алмас, диләр. Ә мина улымны бу газабыннан бүген үк котылдыра торган өшкерүче әби кирәк. Шулай итеп, әйләнә-тирәбездә балалар өшкерүче бер әбекәй дә калмагандыр. Чувашы, мукшысы, маржасы, татары!

Әйтмәгәнем булсын, әллә аларнын өшкерү шифасы тиде, басылды, бетте аның эч авыртуы. Хәзер менә инде айларын тутырып, бер теш чыгарып утыра. Торулары Әлмәттә аларнын. Әнисе бераз ял итсен дип, ике-өч атнага үзебезгә алып кайтканыек. Әллә шул теш чыгаргангамы—бер кичне температурасы нык күтәрелде оныгымнын. Бер төн эчендә җиде үлдем, җиде терелдем. «Баланын баласы балдан татлы»—дип, бер дә юкка гына әйтмәгәннәр шул.

Тигез, житешле тормыш белән яшәгәндә, сау-сәламәт, көн саен бер һөнәрен арттыра барган баланы карау бетмәс-төкәнмәс шатлык вә сөенеч кенә. Биктаһирыбыз мин җыр көйләгәнне бик ярата булып чыкты. Җырга минем ул хәтле осталык юк. Мин ана «Зәңгәр шәл»дән: «Менә-ә сина-а, Галәви, ачкычларны-ы калды-рам. Өйгә-ә кара-ак кермәсен. Өй-не яхшылап сакла!»—дип җырлыйм. Шуны ике кат җырлап чыкканчы кочагымдагы бала изрәп йокыга китә. Бала әзрәк көйсезләнә башласа да, әнисе мина китереп бирә.

—Дәү әтисе, Галәвине җырла!—ди. Ни хикмәт, кин итеп тын алып, шушы җырны көйли башлауга, улым изрәп йоклап та китә.

Бүген инде җиде айларын тутырып килгән бик тансык оныгым Биктаһир турында шулай тәмләп, озаклап сөйләвемнен үз хикмәте бар. Тәрҗемәи хәлемә багышланган повестька кереш, ягъни увертюра булсын дип яздым мин аны. Оныгымны кочагыма алып йөргәндә, бишек җырлары җырлап тирбәткәндә, йә Ходаем, минем үземне дә кемнәрдер шулай кадерләгәннәрдер, төнге йокыларын калдырып бишектә тирбәткәннәрдер, кулларында күтәреп йөрткәннәрдер, дигән уйлар өере килеп биләде күнелемне. Алты дистәне тутырдым бит инде. Ходаемнын рәхмәте, узган ел Сабан туенда, түтәлдә качып үскән кыяр төсле түгәрәк Аксубай мишәре белән бил алыштым бит

әле. Күзем дә исән-сау. Янымнан озын ботлы чибәр кызлар узганда машина фарасы кебек яналар. Алар узган якка муенымны, остеохондроз кузгалганчы, борып озатып калам. Колакларым да «мә!» дигәнне бер чакрымнан ишетеп алалар. «Бир!» дигәнне генә ишетмәмешкә салышам, мыштым гына узып китмәк булам. Шөкер, әлегә аяклар да йөгерәләр. Шахмат тактасы артына утырсам да, көндәшем спорт мастеры ук булмаса, беренче разрядлыларга гына биреште юк. Матка ук булдыра алмасам, партияне пат белән тәмамлыйм. Хөрмәтлеләрем, бу мактануым түгел, эш менә нәрсәдә, 1937 елның шыксыз салкын декабрендә туып, мин дә сыным катып елаганмындыр. Сөте агып торган тулы күкрәген каптырырга әнием юк. Шыгыр-шыгыр бишектән алып биләүләремне алыштыручыларны, авызыма имезлек каптыручыларның мин берсен дә белмим. Аларга рәхмәт тә әйтә алмадым, мыскал игелек тә күрсәтмәдем. Хәзер менә алар рухына ара-тирә сәдака биргәлим. Ходай үзе кабул итсен дә, бу изге җаннарның рухына җиткерә күрсен.

Әйе, салкын төннәрдә кычкырып елап уянсам, мине кулларына алып юатучыларны, авызыма имезлек каптыручыларны, мамык шәлгә төреп, янәдән бишегемә салучыларны мин белмим. Шулай килеп чыккан инде. Чөнки мин алты көннән каравыл кычкырып ятим калганмын. Сез ышанмассыз да инде, әмма күз алдыгызга китерегез. Әнкәсеннән алтынчы көнне калган баланы карау, ай-һай, кыен булгандыр. Кендек кутырым да төшмәгән бала бит әле. И-и-и, аннарымы?! Мин күп тапкырлар кулдан кулга йөрдем. Алары хәтта үзем белә башлагач та булды. Чүплеккә илтеп ташлаган песи баласы кемгә генә килеп сыенмый?! Минем дә куены җылы, ышанычлырак бер җанга килеп сыенасым килгән, шундый ышанычлы җанны эзләгән чакларым күп булды.

* * *

Без—Җәнбәтнекеләр. Кушаматыбыз да шулай. Безнекеләрне «Җәнбәт җәвере—җиде табын», дип йөрттеләр. Җәнбәт бабамның җиде улы булган. Аларның берсен дә башка чыгармаган ул. Башлы-күзле иткәч, булган улларының барысына да ак өй салып, бер ат, бер тана биреп, барысын да үз утарында калдыра барган. Капкаларын ачып җибәрсәләр, алар ишегалдыннан бер көтү сарык чыккан. Утыз-кырык баш ат, ун-унбиш дөя асраган. Безнең нәселнең тәмам кызыл балчыгына төшеп сөйләсәң, ул болайрак. Җәнбәт бабам пәһлевандай көчле-куәтле, кырыс холыклы кеше булган. Җиде улының—җиде дусты! Авыл җыеннарында, җир бүлешкән чакларда аларга каршы чыкмаганнар. Җиде-сигез авылга баш үрәтник тә тарантаслы, рессорлы атын алар капкасына китереп бәйләгән, кунарга Җәнбәт бабайда кала торган булган. Казнага яхшы атлар үстереп биргән, үрәтник белән дә симез каз ботларын бер табында кимергәч, чымырдап утырган әче балны бер мичкәдән чөмергәч, Җәнбәт бабам бер улын да солдатка бирмәгән. Бабамның җиде килене бишәр бала гына тапкандыр. Аның нәсел-ыруы нык үрчегән, бик көчле булган. Мин—шунын бер очы гына. Минем әтием—җан дустым, акыллы кинәшчем—Габделбарый. Мин, заман кушканча, Бариевич йөрим. Әтием дөнья бәясе егет иде. Урыны җәннәтнең үзәк президиумында, хәтта Политбюросында булсын! Әтинең әтисе, ягъни минем бабам—Хәсән. Хәсән бабамның әтисе Әхмәтҗан. Аннары Әбү-Талип. Аннары Әбү-Җәнбәт.

Хәсән бабамның әтисе Әхмәтҗан күп бала үстергән. Әхмәтҗан бабамның бертуган абыйсы Әбү-Бәкер бер дә өйләнмәгән. Ул бик танылган, бик бай сәүдәгәр булган. Унбиш-егерме дөядән торган кәрван йөрткән. Иран, Әфганстан, Пакыстан, Һиндстан җирләренә кадәр барып чыгып, Казан каласына хуш исле чәй, дарчин һәм башка аш тәмләткечләр, кытай чынаягы, ефәк шәлләр, кәшемир яулыклар ташыган. Аның элекке Дөбъяз районы,

зур базарлы Алат авылында һәм Казанның үзендә берничә кибете булган. Кибетендә приказчиклары сәүдә иткәндер инде. Әбү-Бәкер агай бер сәяхәттән кайтып мунчалар керсә, бераз ял итсә, икенче кәрван белән тагын илләр гизәргә чыгып киткән. Кунакка, бераз ял итәргә ул һәрчак Дөбъяз районы Кече Солабаш авылына, күп балалы энесе Әхмәтжанга кайткан. Жәнбәт бабай бит Кече Солабашныкы. Ун-унике яшьләремдә, Дөбъяздан Таш-Кавал авылына кунакка кайтканда, Солабаштан чыгып бер урынга житкәч, әтием тарантасыннан төшеп тәһарәт алып, чыкылдап торган коммунист булса да, кыйбла якка карап, белгән догаларын укыр иде. Бу урынны сәрви, сирень, шомырт, балан агачлары бизи. Күптән ташланган йорт урыннары, моржа төпләре сизелә. Әти соныннан мина аңлатма биреп:

—Улым, бу жирләрдән узганда син дә тезләнеп бер дога кылырга онытма. «Жәнбәт жәвере—жиде табын» бабабызның утары урыннары бу!—дия иде. Мина соң, ул чакта ни беләм? Чыңгызхан, Александр Македонский ставкасы бу—дисәләр дә, мыскал да исем китмәгән булырые. Үсә төшкәч, дөнья таный башлагач, ул якларга бер кайтканыем. Жәнбәт бабам утары утырган жирләрне сөреп, солы чәчкәннәр. Йорт урыннары алай да төсмерләнә. Зур-зур ташлар, янган кирпечләр күренә. Солы басуы өстендә бик озак уйланып йөрдем...

Безнең Кече Солабашка беренче пианиноны да әлеге сәүдәгәр Әбү-Бәкер абзый алып кайткан. Бу—1851 еллар тирәсе. Солтан Габәшиләр дә безгә кардәш нәселләр, шәҗәрәләре «Жәнбәт жәвере—жиде табын»нан башлана. Бездә бит «Ж» хәрефе бик пачутта. «Жарар»,—диләр, «ярар», димиләр. «Жәнбәт жәвере»—«Жәнбәт явы»,—ягъни, көчле нәсел-нәсәпне аңлата.

Әтием Габделбарыйның әбисе Гайнижамал абыстай—мулла кызы—бик матур итеп пианинода уйнаган. Жәйге тын кичләрдә, көтүләр кайтып, малларны барлап абзарларга япкач, күрше-тирә киленнәре бәйрәмчәрәк киенеп, Әхмәтжан бабай өе алдына жыела торган булганнар.

—Абыстай, әргәнеңне тыңларга килдек, башка эшләреңне куеп торып, чак кына уйнамассыңмы? Йөрәкләрне өздереп, әллә нинди сагышлы моңнар агыла бит аннан,—дия торган булганнар. Киленнәрнең кич утырып үзләре чиккән батист алъяпкычлары астында—йә ике йомырка, йә чәй тәлинкәсе белән тары, карабодай, солы оны. Болары, хәзергечә әйтсәк, музыка тыңларга килүчеләрнең музыкант абыстайларына гонорарлары. Абыстайлары да ялындырып тормый. Төпләре исле гөлләр белән тулы, урамга караган өч тәрәзәсен дә төбенә кадәр ачып жибәрә. Житез бармаклары белән пианино клавишлары өстеннән йөгереп уза. Иген үстереп, күп итеп аяклы мал асрап яшәгән өч мәчетле татар авылы урамнарына моң агыла. Боларын мина әтием Габделбарый сөйли иде.

1863—1936 елларда яшәгән дин эшлеклесе Хәсәнгата Габәши, 1891—1942 елларда яшәгән Хәсәнгата улы композитор, педагог Солтан Габәши, 1941 елны туган, күренекле археолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты Солтан улы Рөстәм Габәши—бу нәсел дә «Жәнбәт жәвере—жиде табын» ыруының бер тармагы. Пианино моңнарын кече яшьтән үк тыңлап үскәнлектән, Солтан Габәшигә көйләр чыгаручы, профессиональ композитор булып китәргә бу фактор үзе үк зур этәргеч булгандыр. Бу затлы музыка коралында өч-дүртләп көйне әтием үзе дә бик йөгерек уйный, кушылып жырлап та жибәрә иде.

Әхмәтжан бабамның өлкән абыйсы Әбү-Бәкер агаебызның балалары булмаган. Гел кәрваннар куып йөргәнлектән, әллә өйләнергә дә өлгермәгән?! Фотосы исән әле. Ул бик ярау кеше булган. Кыска гына кара сакаллы, кысыграк күзле, бераз юанаеп килүче агайның өс-башы шәрык зыялыларыныкына охшаш, бик затлыдан. Кулында балдаклар. Куен кесәсенә салган сәгатьнең алтын чылбыры күренә. Үз балалары булмаганлыктан, Әбү-Бәкер абзый энесенең балаларын бик яраткан. Ә бер кайтуында энесе

Әхмәтҗаннан, тугыз-ун яшьләрендәге улы Хәсәнне, ягъни минем булачак бабамны, аңа арка кашучы малай итеп бирүен сораган.

—Курыкма да, борчылма да, балигъ булып җитешкән көннәренә үземнән зур өлеш чыгарып, йөреш маллы бай сәүдәгәр итәрмен. Казанда кибет ачып бирермен,—дигән. Безнең татарда арка кашыту бик табигый хәл. Бүгенгечә әйтсәк, массаж бит инде. Гел юлда, гел сәфәрдә, кайчак еш кына ачык һавада, шалашларда кунарга туры килгәнгә, Әбү-Бәкер агайның да аркасы кычытуы бик табигый. Арка кашудан да бигрәк, әлегә ун-унбер яшьләрендәге бабам Хәсән, кәрван ялга туктаган бер җирдә, самовар куеп, чәй кайнатырга тиеш була. Алай череп баеган Әбү-Бәкер агайның башка ялчылары да булгандыр. Әмма алар—ятлар. Алардан теләсә нинди этлекне, мәкерне көтәргә була. Эчәсе чәенә йоклаткыч салырга да күп сорамаслар. Ә бу малай—үз каның, үз нәселең. Хәсән бабам Һиндстан чәен чәйнектә үзе пешереп, беренче касә чәйне дә үзе эчеп күрсәтә торган булган.

Андый шартларда малай кеше тиз җитлегә. Ул тиз арада кәрванны барлап, малларга күз-колак була башлый. Безнең Хәсәновлар нәселенә нигез салучы Хәсән бабам Әбү-Бәкер агасы белән күп дөньяларны кичә, исәп-хисап эшенә төшенә, күп телләрдә сөйләшә: япон, фарсы, һинд телләрен белә. Кәрваннар куып Казанга, Мәкәрҗәгә шәрык товарларын ташыйлар.

Шулай берчакны мул товар төяп Әфганстан якларыннан кайтканда, Әбү-Бәкер агабыз кәрванына дала пиратлары, бүгенгечә әйтсәк, рекэт һөҗүм итә. Амудәрьяны кичкәндәрәк була бу фаҗига. Атыш, кырылыш, кан кою башлана. Юлбасарлар аларны алдан ук көтеп, сагалап торып, нык хәзерлек белән каршы алганнар. Кәрван сакчылары, дөя куучыларның күбесе, сатлык җаннар, шундук бандитлар, юлбасарлар ягына чыгалар. Атыш вакытында Әбү-Бәкер агабыз да һәлак була. Инде егерме тирәләрен тутырып килгән, кәрван башы булып йөргән минем булачак бабам Хәсәнне юлбасарлар әсир итәләр. Кул-аягын бәйләп үзләре белән алып китәләр. Бер кышлакка илтеп зинданга ябалар. Кем икәнен күреп торалар бит, бик зур күләмдә йолым билгелиләр.

Үземнең алты көннән ятим калган балачагыма җиту өчен, җәмәгать, бу вакыйгаларны, ярсу аргамакка атланып, аны бертуктаусыз камчылап язам. Аягына богау салгач, караңгы зинданга илтеп япкач, Хәсән атлы бабага йолым җибәргәнне көтеп ятарга гына кала. Ә бу чорларга Әбү-Бәкер агасы белән бергә байтак капитал туплап өлгергән булырга тиешләр. Әмма үзе юкның—күзе юк. Әбү-Бәкер абзыйның һәлак булуын белгәч, Казандагы туганнары сөенгәннәр генәдер. Кеше малына кызыгып, көнләшеп яшәүчеләр азмыни бу дөньяда? Ә бу байлыкларның хаклы варисы—Хәсәнне коллыктан ни дип йолкып алырга? Ятсын шунда сөяге черегәнче. Шушы яклардан узган Казан сәүдәгәрләре аша, үзен коткарырга акча сорап, туганнарына күп хатлар җибәрә бабам. Әмма Казаннан бер тиен дә килми. Ул арада, акча көтә-көтә дүрт ел узып китә. Тора-бара аның богауларын салдыралар. Далада куй көтә башлый, әлбәттә, башка көтүчеләр карамагында. Җирле халык—төрекмәннәр белән дуслаша. Җиде-сигез телдә бик иркен сөйләшкән бабам кышлакта балалар укыта. Җирле халык аны нык ихтирам итә. Ә йолым акчасы килми дә килми. Хәтта аның хәл-әхвәлен белешкән кеше дә юк.

Бабама—егерме дүртләр тирәсе, ул качарга ниятли. Дала сукмаклары ябык. Аны хәзер эләктерәчәкләр. Качсан, Амудәрья буйлап, боз өстеннән камышларга яшеренеп кенә качарга була. Шулай качып барганда, бабам бәкегә юлыга, суга чума. Чыга алмыйча байтак сәгатьләр азаплана. Бәхетенә, аны бер чабан төрекмән күреп ала. Ул аны коткарып өенә алып кайта. Төрле шифалы үләннәр төнәтмәсе белән дәвалый, аякка бастыра. Әмма Казанга бабам үпкә авыруы ияртеп кайтып төшә. Беренче эше итеп сәүдә эшләрен

тәртипкә китерә. Хәзерге Бауман урамы, «Татар ашлары йорты»на каршы ике катлы пулатта ул чакта ук кибет була. Бабам шунда баш приказчик булып, «йомшак алтын», ягъни затлы мехлар белән сәүдә итә башлый. Үпкәсе борчый башласа, төрекмән якларына, Амударья буйларына кымыз эчәргә баргалый. Аннары өйләнеп җибәрә. Беренче баласы, минем әтием Габделбарый 1914 елда, аннары әтиемнен бик яраткан сеңлесе Марзия апа туа. Тукай урамында, трамвай тукталышы белән янәшә генә, аскы каты таштан, өскесе юан бүрәнәләрдән салынган җыйнак кына ике катлы йорт бар иде. Ялгышмасам, бу йортның аскы катында 17 нче аптека иде. Бу йорт—Хәсән бабамның өе. Бай, житешле тормышта яшәгән булсалар кирәк. Әтиемнен: «асраулар, өй хезмәтчеләре тоттык, әтине эшенә пар ат жиккән тарантас белән килеп алаларые», дип сөйләгәне хәтеремдә. Хәзерге кара «Волга» дип укыгыз!

Бик укымышлы, кешеләргә бик шәфкатьле, бик юмарт бабам утыз сигез яшендә, һаман да шул үпкәсе шешеп, шушы йортта вафат була. Шундый бай башы белән аңа ярлы кызы димләмәгәннәрдер инде, хатынлыкка ярлы кызы алмагандыр. Бай кызлары бит алар байлыкның кадерен белмиләр, аларга булган байлыкны әрәм-шәрәм итү генә хас. Бабамнан өелеп калган мал-мөлкәтне бүлешергә «Җәнбәт җәвере—җиде табын» варислары күп табыла. Алай да, арада аек акыллылары да булган икән. Мал бүлешеп күп тарткалашсаң, Бауман (ул чактагы Проломный) урамындагы кибетнен дә кулдан ычкынып куюы бар. Нәселгә ят, чит затларны кертү дә мәслихәт гамәлләрдән түгел. Әллә нинди бозык затларга тап булуың ихтимал. Ә бабамның утыз ике яшьләрендә тол, ике канатсыз калган хатыны, минем әбием Васфикамалны тиз генә арада янә ике канатлы итәргә кирәк. Дүрт яшьлек улы Барый, ике яшьлек кызы Марзия бар-барын. Әмма аларның ни комачавы?! Малың мул икән, балалар йөк була димени?! Җәнбәтләләр—бабамның туганнары, ике бала белән яшьли тол калган киленнәрен тиз генә Ярулла абыйга кияүгә бирәләр. Бабамның туганнан туганы була ул. Мина сөйләүләре буенча, Ярулла абый бик мут кеше булган. Ырынбур ягыннан атлар да, сарыклар да китереп саткан. Сыраны да мичкәсе белән эчкән, марҗалар белән дә гүләйт иткән, акчага кәрт тә уйнаган. Бер тиен акчасыз йөргән чаклары да күп булган, Ырынбур якларыннан чабыш атлары китереп саткан, бай чакларында артыннан ияреп йөрүче хәер сораучыларга вак көмешләрне учлап-учлап та сипкән. Юкса, аны «Йомшак алтын» кибетендәге баш приказчик урынын саклау, мал-мөлкәтне тагын да арттыру нияте белән өйләндерәләр. Кая ул?! Мондый байлыкка чумгач, Ярулла абый гүләйт итүдән айнымый. Өстәвенә, нәкъ ике елдан соң әбием Васфикамал кинәттән вафат булып куя. Ярый абыйны балдызына, ягъни әбиемнең бертуган сеңлесе Бибикамалга өйләндерәләр. Төп максат—нәселгә ятларны кертмәү. «Йомшак алтын» кибетен кулдан ычкындырмау. Ярулла абый белән Бибикамал апа никахыннан Әнвәр абый белән Рауза апа туалар. Хәзер барысы да мәрхүм инде. Кеше баласы кемгә хаҗәт? Тукай урамындагы әлеге асты таш, өске каты юан бүрәнә йортта әти белән аның сеңлесе Марзия апага урын калмый. Аларны приютка илтеп тапшыралар. Әтием приютта танылган шагыйребез Мөхәммәт Садри белән бер бүлмәдә торган. Бу 1922—1926 еллар. Әтигә ун-унике яшьләр. Алар икесе дә шигырь язганнар. Бу ике «өметле яшь шагыйрьләр» янына Һади Такташ килеп йөргән. Аларга куен дәфтәрләре, карандашлар биреп китә торган булган. Һәр килгәнендә малайларга бирәр бөтен ак ипи дә кыстырып килгән. Ашау ягы приютта бик кысынкы иде, дип сөйләр иде әтием.

Әти белән Мөхәммәт абый гомер буе бик дус яшәделәр. Без Дөбъязда торганда, әти районның «Колхозчы» газетасы редакторы иде. Мөхәммәт абый

безгә бик еш кунакка кайта. Йә булмаса, тарантас җигеп, Казанга үзем килеп алам. Мөхәммәт Садриларга үзебез дә кунакка бара идек. Инде мин әдәбиятка килеп, байтак кына китаплар чыгаргач та, Мөхәммәт абый миңа исем-фамилиям белән дәшмичә: «Барый улы, балачак дустымның малае»— дип йөртә иде.

Тормышның көлкеле ягы күп аның. Әтиләр торган приют хәзерге Горький паркы каршындагы кызыл кирпечтән салынган зур йортта булган. Ул бина хәзер дә исән, хәзер анда хәрби госпиталь. Берараны бу йорт Татарстан коммунистларының Югары мәктәбе дә булып торды. Житәкче урыннарда эшләргә гыйлемең саерак дипме, әтине шунда укырга җибәрделәр. Үземә әни табу тарихымны алда язармын әле. Әни белән икәү шунда без әтинең хәлен белергә киләбез. Әни кучтәнәчкә күкәй пешереп, Казан кабартмасы салып баргандыр инде. Әти безгә бер капчык сохари киптереп куя. Үзләреннән калган ипи сыныкларының бер телемен дә әрәм итми. Ул чорларда ни дәрәҗәдә яшәү, тереклек итүебезгә үзе бер шәрех. Әти безгә нәкъ менә приютта үзләре яшәгән бүлмәгә туры килүе турында сөйләгәние. Хәл белергә Мөхәммәт тә килеп китә, приютта бергә яшәгән егерменче елларны бик рәхәтләнеп искә төшереп утырабыз, дигәние.

Кайчакларны, тырнак астыннан гел кер эзләгән кебек, ул заманның тетмәсен тетеп салабыз, әмма бу власть яшь буын, балалар турында нык кайгырткан. Приют яшеннән чыккач, әтине ФЗОга (фабрично-заводское обучение) күчереп, трамвай йөртүчелеккә укытканнар. Аннары ул Казан урамнарын дер селкетеп трамвай йөрткән. Төнге сменаларда трамваен чабыш аты кебек «камчылаган». Бар хутына җибәрсән, трамвай ул самолет урынына оча, дип сөйләрие. Очар инде бар, рельстан чабучы машина! Аларын инде энекәшләр белән бер-беребезгә күз кысышып кына тыңларыек.

Казан урамнарын дер селкетеп трамвай йөрткәндә, аны комсомолга алганнар, педучилищега керткәннәр. Аны тәмамлагач, мин туачак Дөбъяз районы Кече Кавал авылы җидееллык мәктәбенә директор итеп җибәргәннәр. Шунда ул әнием Шәрәфелбәнат белән танышкан. Әнием бик чибәр булган. Бу юлларны мин үземдә сакланган фотоларга карап язам. Ул Мәскәүдә яшәгән. Кистергән чәчле, шул заман модасында, бик затлы киемнәрдән. Әтием фатирга төшкән урта хәлле агайның кызы, җәйге ялга авылга кайткан булган. Әтием белән шулай танышканнар. Башта ук шуны искәртеп куйыйм әле. Әтием совет үстергән, аның кырыс вә сыйнфый тәрбиясен алган, җанытәне белән советка бирелгән зат иде. Аның яраткан җыры:

Итек, шинель, фуражканы
Без киябез бит аны.
Яшәсен совет власте,
Без сөябез бит аны!
Сикереп менә, сикереп төшә
Кызылармиец атларга.
Бүгеннән үк чыгып китәм
Совет илен сакларга—

иде.

Башыннан фуражкасын төшермәде. Кибеттә булмаса, тектереп киде. Хром итектән башка аяк киемен танымады. Кышын фетр, җәен хром итек киде. Тормыштагы көндәлек кимчелекләрне дә, хаерчелекне, нигә тотынсан, шул нәрсәнең житешмәвен дә ул власть гаебе итеп түгел, ә урындагы җитәкчелекнең булмаганлыгы, үз эшләренә салкын караву итеп кабул итте. Безгә дә—балаларына—шулай дип аңлатты. Коммунистлар партиясенең ялкынлы пропагандисты булып яшәде һәм шулай үлеп тә китте.

Әнием мандолинада уйнаган, матур тавыш белән җырлаган. Мина авырлы чакта, балама киертермен дип, йоннан бик матур күлмәкләр бәйләгән, чиккән. Нигәдер, күнеле сизепме:

Биек тауларның башында
Бригадирлар җир бүлә.
Бик яратып сөйгән ярлар,
Йә аерыла, йә үлә,—

дип җырлый торган булган.

Матур итеп чиккән күлмәкләрен, йомшак йоннан бәйләгән кофталарын мина киертеп шатланырга, мине кулларына алып үчти-үчти итәргә насыйп булмаган шул бәгыремә. Байтак еллар узгач, туганнарым мина аның тагын бер җырын җиткерделәр.

Үзем жылыйм, үзем җырлыйм,
Үзем карлыган җыям.
Эчем тулы утлар яна,
Яшьлегем белән түзәм,—

дип җырлаган ул.

Үләсен, мине ятим калдырасын сизде микән әллә җанашым, алтын алмам? «Әни!» дип әйтәсем, берәрсенең җылы кочагына барып сыенасым килгән минутларым күп булды тормыш юлымда.

Болай була ул. Бу кадәресен, бераз үсә төшкәч, мин әтидән бәйнә-бәйнә сораштым. 1937 нче елның кышы бик холыксыз килә. Инде декабрь уртасы, әле кар күренгәне юк. Салкыннар еш кына егерме-егерме биштән өстә булып ала. Юлга чыгыйм дисән, ни арба, ни чана җигешле түгел. Минекеләр бәбәй көтәләр. Декабрьнең шундый шыксыз бер кичендә, әнием тулгаклый ук башлый. Әти—коммунист, мәктәп директоры. Авылның иң алдынгы карашлы кешесе.

—Беренче һәм көтеп алган баламны кендек әбисе ярдәмендә тудырып торырга! Мин, коммунист башым белән!—дип ишек алдына арба җиккән ат белән кайтып керә. Аяк атлый алмаслык катлак, дангор-донгыр дип тормый. Әнине, бездән унике чакырымнардагы Мәмдәл участок больницасына алып чыгып китә. Дөрес, арба өстенә калын итеп йомшак печән түшәгәннәр, калын киезләр салганнар. Әнине дә җылы толыпка төреп утыртканнар.

Әмма алар басу капкасын чыгуга карангы төшә. Декабрьдә көннең озынлыгын үзегез беләсез, нибары бер карыш. Алар артыннан ук котырып буран чыга. Алар адашалар. Ул елларда Ильич утлары юк бит әле. Төннәрен, авылдан читкә ике адым китү белән, адашасын. Әтием, атын йөгәненнән җитәкләп, Мәмдәлгә тан алдыннан гына килеп керә. Ачы тулгаклары килгәндә, юлда әнием карга да төшеп-төшеп утырган булырга тиеш. Әти аларын ук әйтмәде. Бу кадәресе—әбием фаразы. Мин туганмын. Шыр кычкырып килеп чыктын якты дөньяга, улым,—дип әти сөйләде. Әмма больницада бик салкын булган. Бүлмәләренә ягылмаган. Мин тугач, әти әнине кире алып кайтып киткән.

Кышнын бу чорында авыл җирендә дә җылы почмаклар аз була. Мин яхшы хәтерлим, без үскән чорларда да, ин җылы итеп яккан өйләрдә дә, иртәнгә чиләктәге су чырый торганые. Авыл җирендә ин җылы җир—җылы итеп яккан мунча. Дер-дер килеп калтыранучы әниемне Габдрахман бабамның ак мунчасына кертеп салалар. Шунда, температура—ут эчендә, биш көн ята ул. Хәзерге заман булса, көчле антибиотиклар калап, терелеп тә киткән булырие, бәгыркәем. Алтынчы көнендә генә аңына килә.

—Баламны китерегез,—ди. Китерәләр. Биләүдән чишегез, ди. Чишәләр.

—Иреннәремә якын китерегез. Үбеп үлим,—ди. Китерәләр.

—Балама күкрәгемне каптырыгыз,—ди. Каптыралар.

—Бик якты хыяллар белән күтәргәнием сине, балам,—дип башымнан сыйпый.—Үләм, бәхил бул! Дөньялыкта бәхет белән, дәрәҗә белән яшә!—дип авыр тын ала.—Баламны ташлый күрмәгез!—дип пышылдый да, җан бирә. Мин һаман да имчәк кабып ятам икән әле. Әнием җан биргәндә,умарта корты, елан чаккандай, кинәттән чыр итеп елап җибәргәнмен. Әнием кая, нигә миңа ими бирмисез дигәндәй, сыным катканчы елаган чакларым күп булгандыр инде. Аларны кем санап, кем исәпкә алып торган...

Ал булганчы, гөлләр булсам,
Сулар сибәрләрие.
Сабый чакта үлгән булсам,
Сагынып сөйләрләрие,—

дип тә җырлыйбыз бит. Әнием исән калган булсачы... Ә Тәнребез башкачарак күрсәтмә биргән шул. Юк, хәерлегә юрамыйм мин моны. Әнием исән калсын иде...

—Улым, әниеннән алты күлмәк кенә калсаң да, алай елак бала булмадың,—дип, әтиемнең күп тапкырлар сөйләгәне булды. Ул бит мәктәп директоры, гел мине карап утыра алмагандыр. Ә менә бабам Габдрахман белән дәү әнием Маһруйбикәгә эләккәндер. Мин көйсезләнгәндә, ими сораганда кая керер җир тапмаган чаклары күп булгандыр. Җитмәсә, әнием мәрхүмә булгач, дәү әтием, дәү әнием белән әтием арасында кискен конфликтлар башлана...

Дәү әнием урта бармак буе гына вак куыклар, ягъни шешәләр табып алган. Менә шуларга кәҗә сөте салып, икесе дә икешәрне култык асларына салып тоталар икән. Кайнар да түгел, салкын да. Нәкъ менә кеше тәне температурасы. Мин елый, ашарга сорый башласам, авызына имезлек куеп, шул шешәне каптыралар икән. Салкынны каптырсаң, миңа салкын тиюе бар. Кайнарны бирсәң, авызым пешәр. Дәү әнием Маһруйбикә белән дәү әтием Габдрахман бер ел тулганчы мине шулай караганнар, авызымнан әлеге татлы шешәләрне өзмәгәннәр. Витамин-мазар җитешмәүне булдырмас өчен пешкән дөге, пешкән солы суы эчерткәннәр. Эчең катса, кара җимеш суы, эчең борса, шундук шомырт суы эчертә идек, дип сөйләрләрие. Ана сөтен бер тапкыр да татып карамагач, ничек рахит булмады икән миңа, дип тә уйлаганым бар. Болай хасиятләп карагач, ничек булсын инде ул рахит? Төнге йокыларын калдырып, мине туп кебек түгәрәк итеп тәрбияләгән дәү әтием Габдрахман белән дәү әнием Маһруйбикәгә мең-мең рәхмәтле мин. Әмма аларны исән чакларында бер әчмуха хуш исле һинд чәе, бер кадак татлы мармелад белән сыйлый алмавыма үкенәм. Чал чәчемне уып үкенәм шуңа, гәрчә гаеп миндә булмаса да. Сәбәпләре бик зурдан аның. «Тормыш якасыннан алып, инәсен ормыш», дип, юкка гына әйтмәгәннәр шул инде.

Дәү әнием Маһруйбикә дөньяның бер чибәре булган. Аларын миңа күрше карчыклары әйтә иде. «Чибәр хатын тоттым, яхшы ат җиктем, улым, син дә миңа охшарга тырыш»,—дигән сүзләрне исә ничәмә тапкырлар дәү әтием Габдрахманның үз авызыннан ишеттем.

## Эт каешы

Бик еш күрсәтте миңа бу тормыш азау тешләрен. Үз ихтыярымнан башка, нарасый хәлемдә кулдан-кулга, өйдән-өйгә күчеп йөрүләр аеруча күңелсез көннәр булып истә калган.

Шундый бер эпизод бүгенгедәй күз алдымда. Сугыш алды еллары инде бу. Миңа яшь ярымнар, ике яшьләр булырга тиеш. Без Дөбъяз районы Иске

Көек авылында яшибез. Ул елларны укытучыларны авылдан авылга, районнан районга бик еш күчереп торалар иде бит. Әтине мәктәп директоры итеп шушы авылга күчергәннәр. Май-июнь айлары булса кирәк, бик матур кояшлы көн. Мин туп кебек түп-түгәрәк малай, бик кыенлык белән генә тып-тып басып, өйалды баскычыннан жиргә төшмәк булам. Кулымда—өстенә вак тоз сибелгән ипи кыерчыгы. Аста, жирдә, жылы, тәмле сөт белән тулы жилене жиргә тияргә торган карт кәжә мин төшеп житкәнне көтә. Минем кулдан ипи алырга өйрәткәннәр аны. Бу акыллы жанның ап-ак бөдрә йонлы ике бәтие янында ук. Алар минем көндәшләрем. Әмма мин жиргә төшеп житеп, кәжәгә ипи кыерчыгын каптырам да, жылы сөт тулы имчәкләрне эләктерәм. Рәхәтләнеп, жиргә ятып имә дә башлыйм. Авызынны ачып торсан, имчәкләрне бөдрә йонлы бәтиләрнен эләктерүе бар. Шунда, баскыч төбендә үк ниндидер ике хатын да бар. Кемнәрдер инде алар?.. Мине сөяргә кергән күрше хатыннарымы, әллә башкалармы? Батист яулыкларынын бер чите белән күзләрен сөртә-сөртә, авыл хатыннары тын гына елыйлар.

—И-и, балакай, и-и бәхетсез нарасый!—дип кабатлыйлар.—Әнисе исән булса бу баланың!..

Минем аларда эшем юк. Мина шундый рәхәт, авызым тулы жылы сөт. Мина бүтән берни кирәкми. Кикерә-кикерә имәм. Дөнья матур, дөнья кин. Миннән күреп, карт кәжәнең ике бәрәне дә бер имине эләктермәкчеләр. Мин инде усалланып беткәнмен, тегеләрне этеп кенә жибәрәм. Ә кәжәкәй, изге жан, мин анын сөтен имеп туймыйча, баскан жиреннән кузгалмый. Шулай өйрәткәннәрдер инде. Бераздан имүемнән туктап, кәжә астыннан башымны чыгарып, елап торган хатыннарга гажәпсенеп карыйм. Ни дип елый икән бу бичаралар? Ни житми икән боларга? Әнә, көн нинди матур... Кояшлы...

Кан тартмаса, жан тарта дигәндәй, беләсезме, миндә, гомумән, кәжәләргә карата тирән туганлык хисе бар. Аларны туганнарымдай сөясем, ипи катысы белән сыйлыйсым килә. Көтүләренә кушылып, текә тау битләренә үрмәлисем килгән чаклар да була. Кәжә асраганыбыз юк. Асрасан, суярга туры килүе бар. Аларга мин пычак күтәрәмме сон? Аллам сакласын!

* * *

Тормыш ана хәтле дә ал да гөл булмагандыр. Әмма бер яшь тулгач, күрә башлый минем башкайлар күрмәгәнне. Дәү әтием белән дәү әнием мине: «Әти кәкәй!» дип әйтергә өйрәтәләр. Әти исә: «Дәү әти, дәү әни кәкәй!» дип әйтергә өйрәтә.

Дәү әтием Габдрахман белән дөньянын бер чибәре дәү әнием Маһруйбикә, әниемнен кырыгы узу белән:

—Барый кияү, син әле бик яшь. Янәдән өйләнерсең, яңа гаилә корырсын. Балаларын тагын булыр. Альбертыбызны безгә бир. Кызыбызның төсе бит. Үзебез үстерик,—дип, әтидән мине сорый башлаганнар.

—Кышкы катлакта жәһәннәм астындагы урыс бүлнисенә чыгып китеп, мәк чәчәгедәй балабызнын башына життен,—дип тә ычкындырганнар бугай. Тормыш булгач, бер-беренне гел мактап, башыннан сыйпап кына тормыйсың шул. Колачын жәеп, мине кочарга килгән әтиемә:

—Әти кәкәй!—дип әйткәннәрем хәтеремдә.

Әти мине кемгә дә булса бирәме сон, жүләр! Бала жанлы зат иде ул. Туган-тумача дигәндәй, гомеренен сонгы көненә хәтле жанын бирергә әзер булды. Ир кеше хатынсыз тора алмый. Әниемне жирләп, кайгылары бераз сүрелгәч, бер апага өйләнеп караган ул. Аны күрше Чуваш иле авылындагы мәктәпкә күчергәннәр, хужасыз йорт биргәннәр. Өйләнеп жибәрү белән приютта калган сеңлесе Марзия апаны, әни бер, ата башка туганнары Әнвәр

абый белән Рауза апаны алып кайткан. Минем белән дүрт бала, әти белән бишәү без. Мондый ала-кола төркем белән кем, нинди хатын торсын, егетләр, үзегез уйлап карагыз. Асия апа безне ташлап кача.

Институтта укып йөргән елларны мина Ташкент якларыннан бик җылы хат килде. Асия ападан иде ул. Бездән котылгач, Ташкент якларына киткән булган. Шунда бик әйбәт кешегә тормышка чыккан.

—Альберт, улым, мин сине үз балам кебек яратканыем. Менә хәзер дә оныта алмыйм. Бу турыда тормыш иптәшем Шәүкәт абыеңа да елый-елый сөйләгәнем бар. Бер җаен табып, берәр айга туры үзебезгә кунакка килеп чык. Өс-башынны да карап җибәрербез. Тормышыбыз җитешле. Сине бик күрәсем килә,—дип язылганые ул хатта.

Мәктәп директорының эше тавык чукып бетерешле түгел. Бигрәк тә безнең әти кебек эшенә муеннан чума торган кешенең. Эти мәктәптә чакта ат белән килеп, мине дәү әти белән дәү әни урлап китәләрие. Берәр атнадан, үзе белән участковый Хәбри абыйны да ияртеп, эти мине менеп ала. Аңарчы мине янәдән: «Эти кәкәй!» дип әйтергә өйрәтеп куялар. Дәү әтиемнең кызы өчәү—олысы Рәбига апа, аннары Мәрьям апай һәм минем мәрхүмә әнием Шәрәфелбәнат булган. Рабига апаларның Яңа бистәдәге өйләренә институтта укыган елларымда, татарда иң затлы ризыклардан саналган әлбә ашарга барып йөри идем.

Сугышны без, эти фронтта йөргәндә, Ташлы Кавалда уздырдык. Сугыштан соң, эти Дөбъяз райкомында эшли башлагач, безне үз янына алдырды. Бу—1948 нче еллар. Миңа унбер-унике яшьләр. Кече Кавалда дәү әтием Габдрахманның барын миңа оныттырганнар инде. Үз әниемнең үлүе турында да сүз кузгаткан кеше юк. Безгә, Дөбъязга Кече Кавалдан бер матур гына карт килеп йөри. Әни аңа бик ягымлы карый. Күкәй тәбәсе кыздырып, чәй куя. Эти аны үз авылына—Суыксуга җиткәнче ат белән озаттыра. Миннән! Бик сәер карт бу. Кече Кавалдан безнең Дөбъязга чаклы унсигез-егерме чакырымнар араны аягына чабата киеп килә. Дөбъязга, район үзәгенә керер алдыннан гына чабатасын салып, аягына штиблет кия. Чабатасын әрекмән арасына яшерә. Мин аны, тарантас җигеп, Суыксуга кадәр озатканда, әлеге карт, авылны чыгу белән, атны туктата. Йөгереп кенә әрекмән арасына кереп китә, аннан чабата киеп чыга, штиблетын төенчегенә төреп тыга. Мин әзрәк сизенәм, гади генә бер карт түгел бу бабай. Югыйсә, эти аны озатып куярга атын бирмәс иде. Бабай тарантас түрендә, ә мин, кучер буларак, козлада. Кулымда дилбегә, камчы. Унбер яшьләремдә генә булсам да, атны җилле тотам. Шулай сүз куешканнардыр инде. Шунда әлеге матур карт, улым, мин синең дәү әтиең, дип ник бер сүз ычкындырсын. Ничек йөрәге түзгәндер, җанашым. Алай да, вакыт-вакыт үрелеп, аркамнан сөеп куяр иде. Шулай да сизә идем, бу сөйкемле карт безгә кай ягы беләндер бик якын җан. Шулай булмаса, эти үзенең кара айгырын бирер, бар! Шунда соң, дәү әтием, җанашым, мин бит барын да беләм, шулай кирәк булгач нишлим соң, дип ник бер кочып алып, чал сакал баскан битеннән суырып үпмәдем икән, дип хәтта бүген дә бик үкенәм. Үзем дә оныклар үстерә башлагач, дөньяга карашлар үзгәрде... Ләкин кул чабудан файда юк, поезд инде күптән китте. Үкенечләрдән, үкенечләрдән, үкенечләрдән тора узган гомер. Бәлкем һәркемнеке дә алай түгелдер ул? Ә минеке шулайрак... Ләкин сагынычлы үкенечләрдән.

Әниемнең уртанчы апасы Мәрьям апа һәм аның ире Кәшиф җизни Мәскәүдә кибет тотканнар, алтын беләнме шунда, алка-йөзек, балдак-беләзекләр беләнме сәүдә иткәннәр. Балалары булмаган. Боларның гозер-тәкъдимнәре бөтенләй реаль җирлектә.

—Барый, җыйган малыбыз чутсыз. Ятларга калмагае дип кайгырабыз.

Балаларыбыз юк. Бир безгә Альбертыбызны уллыкка. Безгә зур юаныч булыр. Сина шуны документлап ышандырабыз: баланы карап үстерербез, укытырбыз. Бар мал-мөлкәтебезне ана яздырырбыз. Егерме яше булгач әйтербез: «Балакаем, син безнен улыбыз түгел. Әниен мәрхүмә. Әтиен исән. Бар, бәхетлебез, алдагы көненне үз әтиен белән күр. Картлыгыбызда безне дә ташлама»,— диярбез. Габделбарый, хөрмәтле киявебез, зинһар, бир бу баланы безгә. Үз каныбыз бит, бертуган, бер карында ялралган сенлебез баласы!—дип ялынганнар. Әти бирәме сон?!

Әти мәктәп эшләре белән мәшгуль булып йөргәндә Мәрьям апайлар да мине Мәскәүгә өч-дүрт тапкыр урлап киткәләделәр. Әти, жанашым, мине аннан да барып алып кайта. Анын үзенә дә әле нибары егерме өч яшь кенә. Поездда кайткан чакта әтинен:

—Улым, Мәскәүгә, Кәшиф жизниләренә бүтән китмисенме инде?—дигән соравына:

—Трактор алып бирсән, китмим,—дип шарт куеп утыруларым хәтеремдә. Ул чорларда трактор районга берәү. Малай-шалайнын аннан да ныграк исен китергән нәрсә юк инде авыл жирендә. Гөрелтәве генә ни тора. Ян-якка, әйләнә-тирәгә нинди тәмле әчкелтем ис тарата. Ә кузгалып китсә, аяк астында жир дер селкенә.

Бер сүз кузгаткач, әйтеп бетерим инде. Йөз дә ике яшьләрен тутырып, Мәрьям апаны Яна бистә зиратына быел гына жирләдек әле. Мине үз улы итәргә бик теләгән беренче ире Кәшиф жизни сугышта югалды. Яралыларны санитар поездында Мәскәү белән Ленинградтан Ташкент госпитальләренә ташыган. Сугыш башлангач, эвакуация белән Мәрьям апа да Казанга кайткан. Кәшиф жизнинен поезды бер тапкыр Казан аша узган. Яралыларны бушатырга Казанга кайткан Кәшиф жизни хатынын күрергә бер сәгатькә пропуск алган. Адрес буенча Мәрьям апа фатирын эзләп тапкан. Килсә, ишек бикле. Мәрьям апа хәрби заводта эштә. Кәшиф жизни кире вокзалга йөгерә. Килсә, состав кузгалып киткән. Саратовта гына үз составын куып житә ул. Әмма анда аны дезертир дип, «тройка» кулга ала. Хәрби чор, вак кына жинаять өчен дә беркемне дә кичермиләр, берәүгә дә ташлама да, шәфкать тә юк. «Тройка» Кәшиф жизнине атарга дип хөкем чыгара. Жизни бит поездын куып житкән. Шунын өчен генә нужәли атарлар икән? Хәрби трибунал архивы аша тикшерттек. Трибунал ана амнистия ясап, хөкемен егерме биш елга калдырган, Себергә озаткан. Егерме-унбиш елга карторгага хөкем ителүчеләрне Свердловскида жыеп алганнар да, алгы сызыкка, штрафбатка озатканнар. Кәшиф жизнәбез шунда хәбәрсез югалган.

• • •

Мин инде тел бистәсенә әйләнеп барам. Әмма әлегә әни юк. Әти өйләнеп кенә жибәрә алмый. Бер авызы пешкәч, шикләнә торгандыр. Артында озын койрыгы, ике яшьлек дегет чиләге булганга, ана иргә—кияүгә бик атылып та тормаганнардыр. Коммунист, мәктәп директоры башы белән, әтиемнен дә теләсә кемне аласы килмәгәндер.

Безнен Жәнбәтләр нәселеннән әтиемнен әтисе Хәсән бабамнын энесе Галимжан абый Ташкент тирәсендәге бер заставада командир иде. Ул бик каһарман кеше булган. Басмачылар белән аяусыз көрәшеп күп орденнар алган. Мина ике-өч яшьләр тирәсендә Галимжан абыйларга кунакка бардык. Үзе гаскәре белән тау араларында чик бозучыларны аулап йөргәндә, басмачылар заставага һөжүм итеп, анын хатынын, кызын суеп чыкканнар.

Галимжан абый мине алдыннан төшерми. Бүгенгедәй хәтеремдә, чалт иткән кояшлы мәйдан. Бездәгечә бүрәнәдән бурамаган, балчыктан сылаган өйләр.

Галимҗан абый баш өстенә җәймә корган, тал чыбыктан үргән креслода утыра. Җәймә күләгәсендә кояш ул кадәр кыздырмый, түзәрлек. Мин Галимҗан абый алдында карбыз ашыйм. Моңарчы күргән нәрсәм түгел, бик ошады ул миңа. Биленә озын кылыч таккан бер кызылармеец баштa безнең янга авызлыгын чәйнәп торган кара айгыр алып килде. Аңа атландырып, мине бер түгәрәк әйләндерде. Әнисез үсеп, кулдан кулга ияреп, мин эт каешына әйләнеп беткәнмендер. Куркып тормадым, айгырга шундук менеп атландым. Кызылармеец аннары ап-ак ат алып килде. Аңа атланып тагын бер түгәрәк әйләндек. Аннары баскан җирендә биеп торган бер алмачуар айгыр алып килделәр. Аңа да атланып карадым.

—Улым, айгырларның кайсын ошаттың?—дип сорады Галимҗан абый. Башта мин:

—Өчесен дә!—дидем.

—Оһо! Зәвык бар синдә!—дип көлемсерәп куйды Галимҗан абый. Аннары мин алмачуар айгырга төртеп күрсәттем.

—Улым, алмачуар айгыр—синеке!—диде командир абыебыз.

Галимҗан абыйда кунакта без ун көннәр генә торганбыздыр. Мине көн саен атка атландырып йөрттеләр. Күбенгәнче карбыз-кавын ашадым. Берничә көннән Галимҗан абый да мине әтидән уллыкка сорый башлады.

—Барый энем! Син бит минем якын туганым. Без—Җәнбәтнекеләр. Бир миңа уллыкка шушы малайны. Мин аннан бер дигән Кызыл Армия командиры ясыйм. Командарм Котовский, Маршал Тухачевский итеп үстерәм!

Галимҗан абый мине кулларына күтәрде.

—Йә, егетем, минем улым буласыңмы?

Мин инде андый хәлләргә күнеккән. Шундук спекуляция юлына бастым:

—Кылычыңны миңа бирәсеңме?

—Бирәм! Мә, так!

—Револьвертыңны да бирәсеңме?

—Бирәм.

—Алай булгач, булам синең улың!

Бу минутларда әтием ничек түзеп утыргандыр? Мин-хыянәтченең колак төбенә ничек берне тамызмагандыр? Аңа карап әти мине калдырмады. Галимҗан абый күп күчтәнәчләр биреп, безне поездга озатты. Вагонга керер алдыннан мине кочагына алды.

—Әтиең калдырмый, бирми бит. Юкса, үзеңнән бер дигән кавалерия генералы ясый идем инде. Алай да исән-имин үсә күр, шайтан малае. Күргән хәтле арада да күңелемне бик юаттың. Гомер онытмам инде сине,—диде. Вагонга да үзе күтәреп кертте.

## Әтине хатынлы иттем

Мин һаман әнисез бит әле. Моның нинди зур фаҗига икәнен миндәй әнисез калган нарасыйлар гына белә булыр. Шушыны раслау өчен бер мисал китерәм әле. Укучыларыма гыйбрәт өчен. «Ватаным Татарстан» газетасының Әлмәт—нефть төбәге буенча үз хәбәрчесе булып эшләгән елларымда, Алабуга балалар йортына, ягъни шул ук, әлеге дә баягы, детдомга, приютка барып чыктым. Бу чорларда сүзем үтемле агай бит инде мин. Ятим балалар янына ничек инде буш кул белән керәсең? Дипломатыма күп итеп конфет-печенье, өреп тутыра торган шарлар, куыклар алдым. Башта ук әйтеп куйыйм, «детдом», «приют» дигән сүзләргә мин хәтта бүген дә бераз шикләнү белән карыйм. Чөнки әтиемнең ата-ана назына, балам, дип иркәләү-сөюенә иң мохтаҗ чаклары шунда узган. Балалыгымның бер чатаграк чорында үзем дә чак кына эләкми калдым. Алла саклады инде...

Барып кердем. Бүлмәләр буенча йөртәләр мине, корреспондентны. Җәннәт эчендә яшиләр биредәге балалар. Һәр бүлмәдә идәндә дә, стеналарда да затлы келәмнәр! Бүлмәләрдә заманча җиһазлар, телевизорлар. Ашау-эчү, ризыкларның затлы булуы турында сөйләп тә торасы юк. «Әкият бүлмәсе»—чын әкият дөньясы! Ата-аналы балаларга мондый рәхәт тәтиме икән әле? Балаларның әле берсен, әле икенчесен алдыма алып сөям. Матурлар, көрләр, чисталар. Мина алар биргән, алдымны күмгән конфетлар минекеннән дә затлырак, кыйммәтлерәк, тәмлерәк. Әмма менә ни хикмәт, алдыма кайсы баланы алсам да, маңгаема төбәп:

—Абыем, син кемне алырга килден? Кемнен әтисе син?—диләр. Мондый сорауга минем җавабым әзер түгел. Чөнки андый сорауны көтмәгәнием. Аптырабрак, ык-мык торуымны күреп:

—Абыем, минем әтием бул! Абый, мин сине бик яратам. Ал мине моннан!—диләр. Өч-дүрт яшьлек балалар болар. Өс-башлары ал да гөл. Торган жирләре, әйткәнемчә, җәннәт. Әмма адәм баласы өчен үз өен, үз куышын белән, ярлы-бетәшкән, очын-очка көчкә-көчкә ялгап яшәгән булса да, үз гаилән, үз туганнарың белән яшәү тиндәшсез зур бәхет икән. Ә мондый теләк бу бичаралар өчен мәнге тормышка ашмастай хыял. Менә шулай, җәмәгать, хәлләр. Кайсы баланы алдыма алсам, шунысы:

—Син кемне алырга килден? Минем әтием бул, мин сине бик яратам!—диләр. Бер генә малайны, йә кызчыкны алып китәргә дә булыр иде. Бу турыда гаиләм белән дә сүз булганые. Мина анда көләч йөзле, кысык күзле, бик матур вьетнаммы, кытаймы малае бик ошаганые. Кочып-кочып алды инде муенымнан. Тәмам сырышты. Киткән чакта чак аерып алдылар. Шул малайны алып кайтып, үз улым итеп үстерергә ният бар иде. Әйе, берәр баланы алыр иден дә, алар бит анда йөзәү. Ил буенча... Ил буенча күпме?

...Мин һаман әнисез әле. Бер авызы пешкәч, өйләнгән хатыны ташлап качкач, әти дә башлы-күзле булырга бик ашыкмый ахры. Култык астына кыстырган портфелен бер дә төшерми. Ә минем өзелеп әниле буласым килә. «Күп балалы мәктәп директоры» дип даны чыккач, әти олы сеңлесе Марзия апаны Казандагы тегүчеләр хәзерли торган училищега урнаштырып кайтты. Кече сеңлесе Рауза апаны кире детдомга илтте. Янында унике-унөч яшьләрендәге Әнвәр абыйны гына калдырды. Мине карарга, яки мина бераз күз-колак булырга. Мин дә усал, телгә дә бик оста. Марзия апа белән Рауза апаның әйткәннәрен колагыма да элмим, тарткалашам, әрепләшәм, сугышам. Бар сүзгә тыгылганым, чаманы белми күп сөйләшкәнем өчен мина шул чакта ук «дәү әти» дигән кушамат тактылар. Мин Әнвәр абыйдан гына бераз шүрлим. Чөнки ул кеше-кара күрмәгәндә генә минем маңгайга шундый каты итеп чиертеп ала, корт чаккандай була.

—Әгәренки әләкли калсаң, «дәү әти», абый мәктәпкә төшеп киткәч, шушы нахал маңгаеңа тагын биш чикләвек кундырам,—дип кисәтә. Приютта үскән, юньләп тәрбия күрмәгән бу хулиганнан тагын ни көтәсең? Ике дә уйламый кундырачак. Әләкләшмим идем. Өстәвенә, мин аны бик ярата идем. Юк, Әнвәр абыйдан гына түгел, әтидән дә шүрли идем, чөнки ул, абау, кызу канлы кеше. Бер кызсамы?!

И-их, малайлар, минем шулхәтле әниле буласым килә. Чөнки Әни заты бернинди доллар, фунт-стерлинглар белән дә бәяли алмаслык олуг Бәхет ул! Моны әнисез нарасыйлар гына түгел, ана булу бәхетенә ирешкән әлеге изге затлар үзләре дә танырга тиешләр. Чөнки ул—Әни заты—һәркем өчен бер генә. Ә бер генә данәдәге теләсә нинди әйбергә бәя бирү бик кыен шул. Ана булу бәхетенә ирешүчеләргә бигрәк тә! Шушы алтын хакыйкатьне күпләр белми дә бугай...

Минем белән уйнап йөргән, борын төпләре куыклы, битләре чат кутыр,

өс-башлары минекеннән дә шапшаграк малайларны әниләре ничек кочып үпкәннәрен, һавада чөя-чөя, шап-шап сөйгәннәрен күрәм. Ә мин кемнән ким? Нигә минем генә әнием юк? Бу турыда мин әтидән болайрак уйлана башладым. Инициативаны үз кулыма алырга да ниятем бар. Бу турыда чынлап торып уйланам, планнар корам. Ятим балага акыл да иртәрәк инәме соң? Инә-инә! Ятимлек бик авыр йөк ул.

Без һәр көн иртән иртүк торып, әти, Әнвәр абый, мин өчәүләп мәктәпкә төшеп китәбез. Китмичә, мине кая куйсыннар. Өчәүләп бер буш йортта яшибез. Ул чакларда авылда балалар бакчасы юк. Әтидә портфель, Әнвәр абый кулында сумка. Бик сорагач, мина да йозагы ватык бер сумка табып бирделәр. Әтидән калышмыйм. Анынча кыланам. Урамда очраткан бар халык миннән кызык өченме:

—Улым, әтиең кем синең?—дип сорыйлар.

—Дилектор!—дим киерелеп.

—Ә син кем?

—Мин дә дилектор!—дим. Әти дә дилектор, мин дә дилектор,—дип раслыйм.—Икебез да дилектор.

Укыту сәгатьләре беткәнче мин көне буе мәктәптә «учительская»да буталам. Кайсы укытучы ияртсә, шунын дәресенә керәм. Әтинен: «Улым, беркая да китмә, мин дәрескә керәм», дигән сүзен еш ишетәм. Ул, директор буларак, укытучыларнын дәрес бирүләрен тикшерергә керә бит инде. Эше, вазифасы шул. Әти авызыннан шул сүзне мин дә тулы мәгънәсе белән эләктереп алдым. Укытучыларнын дәресләренә бик теләп керәм. Бераз рәсем ясап утырам, дәресен ошатмасам, чыгып та китәм. Ә еш кына, ике кулым өстенә башымны салып, рәхәтләнеп йоклап чыгам. Шунысы гаҗәп, мин йоклаганда, уяна күрмәсен дип, балалар класста тып-тын утыралар икән.

Тагын шунысы гаҗәп, бу юлларны мин бераз унайсызланыбрак, тартыныбрак кына язам. Мәктәпнең «учительская»сында көненә күп тапкырлар мине барысы да һавага чөя-чөя сөяләр. Мин ана күнегеп беттем. Менә шул чакта, барысы бер авыздан дигәндәй:

—Карагыз әле, бу малайнын мангай чәчләре уелып кергән, зур үскәч язучы булыр бу!—диләр. Нилектән шулай юраганнардыр? Гаҗәп бит, әй! Ә мин ул чакта язучынын кем икәнен каян белим? Белсәм дә, бик кирәгие мина язучы булу. Галимҗан абыйлардан кайтканнан бирле, кайда бичәүкә, йә чабата киндерәсе күрсәм, шуны аркылы-торкылы тәнемә урыйм. Көне буена ул чуалып бетә.

—Мин командир булам!—дим. Билемә Әнвәр абый ясап биргән агач кылыч тагып йөрим. Ә тәнемә портупея итеп аркылы-торкылы ураган киндерәләрдән әтием мине кичләрен пычак-кайчы белән кискәләп кенә арындыра. Кызыл Армия командиры була алмадым бит, әй, гәрчә кокардалы фуражка, галифе чалбар, шыгыр-шыгыр хром итек мина бик килешсә дә. Язучылык эшенә дә үзем дә сизми керешеп киттем шикелле. Ә профессиональ язучы дәрәҗәсе алганчы һаш-хлорны, ягъни аш тозын күп потлар ашарга туры килгәндер... Әмма үкенечкә түгел.

Ә мин һаман әнисез. Узган көзне әти директор булып эшләгән Чуаш Иле җидееллык мәктәбенә, Арча педагогия училищесын тәмамлап, озын толымлы бик матур апа килде. Өммегөлсем исемле. Ягымлы шундый. Озын толымнарын кулымда тотып, кыш эчендә анын алдында күп утырдым. Менә шушы Өммегөлсем апага кыш эчендә чынлап торып мәхәббәтем төште. Шушы апаны каерып алып әнием итәсем килә. Ләкин ничек? Нибары өч яшьлек ташбаш, яфрак колак башым белән менә шушы турыда иртә-кич тынмый уйлана башладым.

Әтине ФЗОда укыткан чакта ук фоторәсемгә төшерү эшенә дә

өйрәткәннәр. Фотосөючеләр түгәрәгенә йөргәндер инде. Авыл жирендә бик тә кирәкле бу матур һөнәрен ул гомеренен соңгы көннәренә хәтле ташламады. Фотоаппаратлары да күп иде. Шул ике ярым, өч яшьләремдә төшкән фото сакланган, әй. Аннан мина кин маңгайлы, бүрткән фасоль борчагыдай тулы битле, жәлпәк борынлы, зәп-зәңгәр зур күзле бер малай карый. Болай яшәү рәвеше начар булмаска тиеш анын. Башында бүрек, өстендә якалы пальто. Тик шул зәп-зәңгәр күзләрендә генә тетрәндергеч сагыш, моң сизелә. Әнисез булганга инде. Ай, бу әни дигән зат! Бер булмаса, долларга да алып булмый шул аны. Булганнарынын кадерен белегез, укучыларым!

1941 елнын бик матур кояшлы иртәсе, апрель ахыры, май башы. Атлаган саен «дәрескә кереп» туйганмындыр. Мәктәп ишегалдында уйнап йөрим. Ишек төбендә генә янгынга каршы куелган су белән тулы зур гына агач мичкә. Малайлар ясап биргән кәгазь корабларны бу мичкәдә минем күп тапкырлар йөздергәнем бар. Бу юлы, карасам, янымда гына, ямь-яшел чирәмлектә бик матур, берләре чуар-чуар, берләре сап-сары тавык чебешләре йөри. Мин боларны берәм-берәм сулы мичкәгә тутыра башладым. Үзем исә: «Йөзәләр! Йөзәләр»—дип шар ярам. Өч-дүрт көнлек чебешләр ничек йөзсеннәр инде? Алар түгел, аларны басып чыгарган чуар әнкәләре дә йөзә белми бит! Чебешләр шундук төпкә китеп баралар.

—Башын да бетмәде инде, тәре баласы, чукынган нәрсә!—дип, чебешләрнен хужасы Нуржиһан апа килеп житте. Ул—мәктәптә жыештыручы. Бер-бер усаллыгым тимәсә, алай дип үк каргамас иде. Ачуын китергән чакларым булгандыр. Бер минут тиктормас бер шыптый малай идем бит.

—Йә, Ходаем! Йә, Ходаем! Күр инде бу бәлане!—дип, бот чабып еларга кереште. Үземне дә мичкәгә генә саласы да, директор баласы бит. Мин үзем әлегә берни аңламыйм. Аптырашта. Ни дип елый бу Нуржиһан апа?

Тавышка, дәресен ташлап, әти йөгереп чыкты. Чыккан хутка ук мина указка белән берне сыптырды. Әйтәм бит, әти бик кызу канлы кеше иде. Эшнен болайга баруын, дилбегәнен көпчәккә нык чорналуын сизеп, мин чаж—«учительская»га ычкындым. Керү белән—чож өстәл астына. Анда эләксәм, мине эт өстереп тә таба алмыйлар. Бу юлы әтине дә тыешлы түгел. Урындыкларны тибеп кенә очырып, өстәлләрне урыннарыннан дуылдатып күчереп, мине өстерәп чыгармакчы була. Әмма тотарсын мине, бар. Тотмый гына торсын әле! Чөнки өстәлләр астында рәтен-жаен мин генә белгән сукмаклар, лабиринтлар бар. «Дәрескә керәм» дигәч тә, озын кышны шул лабиринтларда уйнап уздырдым бит мин. Өстәлләр астында аулак, мине беркем дә борчымый.

Әмма бу юлы әтинен, жанашымнын, ачуы тәмам ташып чыккан. Эләктерә калса, эш харап! Хәл критически ноктада. Шунда мин, егетегез, бер өстәл астыннан атылып чыктым да:

—Әни-и-и!—дип кычкырып, теге күптән күзем төшеп йөргән озын толымлы, матур апанын муеныннан ике кулым белән кочып та алдым. Әти мине жинел генә йолкып алырга, өстәлгә салып ярырга бик очынып килгәние дә, «Әни-и-и!» дип кочып алган матур апам:

—Иптәш директор!—дип башлап, бик күп сүзләр әйтте. Хәзер уйлыйм: педагогика фәненен балаларга каршы физик көч куллануны хупламавын, Макаренконын «Педагогик поэма»сын, нәрсә ярамаганны балаларга тел белән аңлатырга, төшендерергә киңәш ителгәнен, баланын нәкъ менә холкы формалашкан чорда физик көч куллануның аны рухи яктан гариpләндерергә мөмкинлеген искә төшергәндер ул сүзләр.

Бу матур апага мин исә сөлек булып ябыштым. Үзе дә мине кочагына ныграк коча төште.

—Бу олы юл юлбасары, чын бандит, тел белән әйткәнне аңлый торган

җанмы сон?—диде әти сукранып.—Җыештыручыбыз Нурҗиһанның сигез чебешен сулы мичкәгә батырган бит!—Әти кулындагы указкасын өстәлгә ыргытты да, ишекне тибеп кенә ачып бүлмәдән чыгып китте.

Әти дары булып кыза, әмма тиз кайтып төшә торган гөнаһсыз бер җан иде, җанашым. Бераздан ул янәдән әйләнеп керде. Ә мин әле һаман да матур апа кочагында. Әти хәзер йомшак тавыш белән:

—Улым, әйдә, өйгә кайтыйк. Ачуым басылды инде. Нурҗиһан апаны да ризалаттым,—ди.

—Юк, кайтмыйм мин синең белән. Өйгә кайткач, син мине брезент каешың белән ярасың.

—Кит инде, улым. Кайчан ярганым бар инде? Ят кеше алдында гомердә булмаган хәлләрне уйлап чыгарма инде, зинһар! Гөлсем апаң безнең турыда әллә ниләр уйлап куяр.

—Бер дә уйлап чыгармыйм. Сөтле чүлмәкне аударгач, әйбәтләп кенә ярдыңмы? Ярдың.

—Ул кичне сөтсез калдырдың бит. Ботка да пешерә алмадык. Бер-ике төшергәнмендер инде. Шуны да искә алып тормасаң, улым. Үзең дә бигрәк вакчыл инде.

—Кул сәгатеңне өстәлдән төшереп җибәргәч, бирдеңме кирәкне? Шыр кычкыртып...

—Ярар, ярар, улым. Бүтән бармак белән дә чиертмәм. Әйдә, өйгә кайтыйк. Синең белән генә түгел, өйдә синнән башка эшләр дә муеннан. Әйдә, киттек.

—Әнием безнең белән кайтса гына кайтам.

—Гөлсем апаң синең әниең түгел, улым. Син аны унайсыз хәлгә куйма инде. Бераз байый төшкәч, җәйге ял акчаларын алгач, Мәмдәл базарына чыгарбыз да, күңеленә иң охшаган апаны сайлап алырбыз.

—Миңа беркем дә кирәкми. Менә минем әнием. Син минем әнием бит?—дип эндәштем кочагында утырган матур апага. Матур апам да, әтием дә бик уңайсыз хәлдә—аптырашта... Минем аларда эшем юк.

—Менә минем әнием. Мин аны үзем таптым,—дип, Өммегөлсем апага сыенганнан-сыена гына барам.

—Әнием кайтмаса, мин да кайтмыйм. Аның белән калам. Шулай бит, әнием?

Башка чакта сүзгә кесәгә керүчеләрдән түгел иде әтием. Бу юлы ул да тамак кырудан ерак китә алмады. Баскан җирендә таптаныбрак торды да:

—Кич педсовет бит әле бүген. Мин өйгә кайтып тиз генә ашарга әзерли торам. Алайса, бергәләп кайтыгыз. Бездә кунак булырсыз. Көтәм,—диде.—Сез, иптәш Кәримова (монысы әниемнең фамилиясе), гафу итегез инде, әнә шундый беспардонный бала булып үсеп килә бу малай. Сез физик көч кулланмаска киңәш итәсез. Аны туры юлга чыгару өлкәсендә брезент каеш белән булмаса, тал чыбыгы белән бер яхшы гына ярсаң, бер дә зыяны булмас иде, дип саныйм.

—Тал чыбыгы, имеш! Фу! Кит әле!—дип, мин дә сүзгә кушылдым. Чөнки аны да татыганым бар. Әйтәм бит, әтиемнең вакыт-вакыт гөлт итеп кабына торган холкы белән, минем татымаган нәрсәм калмагандыр. Беркемгә дә бирергә теләмәсә дә, миннән туйган, тәмам гарык булган чаклары күп булгандыр инде бичарамның.

Ашарга әзерлим, дип, зурдан кубып, авыз тутырып сөйләве шуннан гыйбарәт аның. Кайта да керосинкада тозга ярып чикмәнле бәрәңге пешерә. Соныннан чәй бик тәмле була дип, бәрәңгегә тозны да мулдан тондыра. Өстәл артына түгәрәкләнеп утырып, шул «чикмәнле бавырсак»ны әти, Әнвәр абый, мин көнбагыш маенда йөздереп-йөздереп алып, сыпыртабыз гына. Кайчакларны бәрәңге арасыннан савытны юганда төшеп калган мунчалалар

да чыга. Аларны без иплэп кенә бер читкә алып куябыз. Безнең гаиләдә гаеп итеш булмады. «Чикмәнле бавырсак»тан соң, күп итеп кәҗә сөте салып, авызны пешерә-пешерә куе такта чәй эчәбез.

Күрше хатыннары кергкәндә, эти йомырка да пешерә. Аны да кабыгы белән. Шуна күрә инде олыгайгач та, сүз иярә сүз чыкканда: «Мин дөньяда ике ризык пешерә беләм: шуның берсе кабыклы бәрәнге, икенчесе, мин сина әйтим, парин, кабыклы йомырка»,—дип, шушы сүзләреннән үзенә бер тәм табып сөйләрие.

Ана карап, гел чикмәнле бәрәнге генә ашап тормыйбыз. Күрше хатыннары безгә еш кына чумар ашы кертәләр. Хәзерге яшьләр беләме икән? А-а-яй, егетләр, тәмле шулпа ул, чумар ашы. Ана ике-өч кашык катык катып җибәрсәнме! Сөзмә булса, тагын да әйбәт. Теленне йотышлы шулпа була инде. Газетаның үз хәбәрчесе булып эшләгән елларымда бер зур түрәдән интервью алдым.

—Сез инде бик күп илләрдә булдыгыз. Нинди генә затлы ризыкларны татып карамагансыздыр. Ә инде ул кара вә кызыл уылдыкларны кашыгы белән ашарга мөмкинлегегез бар. Шулай да ин яраткан ризыгыгыз нәрсә?—дип сорадым. Әлеге түрә—безнең як нефть корольләреннән берсе.

—Әйе, мина җир шарының барлык континентларында да кат-кат булырга туры килде,—дип килеште.—Ә ин яраткан ашым, минем беләсезме нәрсә? Куе итеп әче катык каткан арыш чумары. Кайларда гына булсам да, шушы ашны сагынып кайтам.

Кочагында утырган матур апаны, әти өчен әлегә иптәш Кәримованы үзебезгә тәки алып кайттым. Өстенә тастымал ябып, әти өстәлгә үзенең фирменный, чат тоз «чикмәнле бавырсагын» чыгарып куйган. Керосинка өстендә борыны китек яшел чәйнек кайнап утыра. Әтинең чәе дә әзер. Әмма мин бусагадан атлап кергәч:

—Әгәренки әни чыгып китсә, бәрәнгене дә ашамыйм. Хәдичә апа кайнар чумар шулпасы кертсә дә, кашык та тыкмыйм,—дип, әтигә кискен ультиматум куйдым. Әнисезлек мине тәмам туйдырды.

—Иптәш Кәримова да чыгып китмәс. Нигә китсен икән? Ризыктан өстен булу берәүне дә бизәми,—дигән булды әти дә. Без кулларны юып бәрәнге ашарга утырдык.

—Әнием, мин сине бик яратам. Мин сине беркемгә дә бирмим. Беркая да җибәрмим,—дип, өстәл янында әнине тагын бер кочып алдым, чытырдап ябыштым. Ана да артка чигенергә бер адым хут калмады. Бераздан ул:

—Оныгыз бармы соң?—диде.

—Булмыйча! Пакеты белән ташып кына торам,—диде әти.

—Атланмаегыз, ике-өч чи йомыркагыз?

—Барысы да әнә шунда, шкафта.

Әни алдына алъяпкыч ябып алды.

—Керосинкагыз артык төтенле икән. Тәрәзә кашагагызга, әнә, корым утырган. Су җылытып, чайкап эләрмен.

Анын бу сүзләрен әти дә, мин дә колакларны тырпайтып тыңладык. Бу мин тапкан әнинең бездә калырга ризалык бирүе түгелме соң? Ярабби! Әти дә:

—Керосинканың фитильләрен күптән караган юк. Кул житми, искергәннәр. Шуна төтенле булырлар. Хәзер алыштырып куям мин аны,—диде. Йөзендә шатлык билгесе. Әни исә, матурым, зур кыюлык белән:

—Алайса, чәй янына мин төче коймак пешереп бирәм,—диде.—Чәй төче коймак белән тәмлерәк.

—Төче коймак! Төче коймак! Ура, мин аны бик яратам,—дип хуплап кул чаптым мин. Әйтерсең, моңа кадәр мин чәйне гел төче коймак белән генә эчкәнмен.—Әнием, мин сине барыннан да күбрәк яратам!

Шулай итеп әниле булдым, әтине хатынлы иттем. Алар тиз арада аңлашып, тату гына яшәп киттеләр. Берсеннән котылсаң, яңа проблемалар туа. Үз әниемнең әтисе белән әнисе, Габдрахман бабам белән Маһруйбикә әбием болай да туктаганнар иде инде мине урлаудан. Әти аларны прокурорга чакыртып нык өркеткән. Яңа әнием аларның эзен бөтенләй суыту ягында булды ахры. Кече Кавалдан тагын да ерагаю ниятеннән без Кече Көек авылына күчендек.

—Кече Кавалда әбием, бабам бар, Мәскәүдә—Кәшиф җизнәй белән Мәрьям апам,—дип сөйләшеп утыруларымны әнием бер дә килештерми. Үз әнисе булганын онытсын, үгилекнең эзе дә калмасын дип тырышуы булгандыр инде үги әниемнең.

—Тапкан түгел, баккан кадерле,—дия иде ул. Мине дә үги түгел, тик үз баласы гына итәсе килгәндер.

Минем анда-монда эшем юк. Әниле булган көнне үк мин аңа без яшәгән өйгә каршы гына болыннан күп итеп юа, акбаш, кузгалак җыеп кердем. Мин ятимне кочагына сыендырганы өчен гомер эчендә күп бүләкләр бирдем. Укып чыгып, беренче хезмәт хакымнан бик кыйммәтле Һиндстан йон кофтасы бүләк иттем. Әниле булуның нинди зур бәхет икәнен әнисен бер җуеп, янәдән тапкан бала гына беләдер.

Күп тә узмады, сеңлем Гөлкәй туды. Казан университетын тәмамлагач, математик ире белән Мәскәү янындагы бер ябык шәһәргә җибәрделәр аларны. Шунда яшәп яталар. Мәскәүгә китап чыгарырга барган саен шунда кунак булам. Олы кызым, Гөлнарым, Мәскәүдә укыган чакта төп «база»быз алар булдылар.

## Мөмкин түгел иде

Нәкъ шулай! Ни кадәр генә боргалансам, сыргалансам да, миңа язучы булмый калу мөмкин түгел иде. Моңа әтинең тырышлыгы һәм мине чорнаган мохитнең тәэсире чиксез булды. Өченче-дүртенче сыйныфларда укып йөрим. Малайлыкның иң тәмле чоры бу. Әлегә өйдә дә эшләрнең авырларын кушмыйлар. Борынына да кызлар исе керә башламаган. Кызлар исе керсә, беттем, диген инде. Төнге йокыларыңнын тәме калмый. Синең күзеңә авылның гына түгел, ә дөньяның бердәнбер матурыдай күренгән берәр яшьтәшеңне, әйтик, күрше кызын ук үзеңә карата алырмынмы, дип йокыдан гына түгел, ашаудан каласың, валлаһи.

Әйе, әлегә малайлыкның иң тәмле чорын кичерәм, тәмам онытылып уйнау белән мәшгуль. Билдә—агач кылыч, кулда—калкан. Сугыш уеннары уйныйбыз. Чөнки экраннарга «Таһир һәм Зөһрә», «Чапаев» кинолары чыкты. Беренчесендә, чаж-да чож, кылыч белән чабышалар, икенчесендә, Анька-пулеметчица «Максимка» пулеметыннан сиптерә. Шушы киноларны клубта көн аралаш күрсәтеп торалар. Ә-ә, нәкъ минә малайлар киносының өченчесе дә бар—«Мы из Кронштата». Совет морякларының тиңдәшсез батырлыгы турында. Аны да үлеп яратып карыйбыз. Һәр өчесенең дә эчтәлеген яттан беләбез. Мин көн саен әтинең эш бүлмәсенә кереп, кинога акча сорыйм. Кинога егерме тиен алу өчен, мин аңа дүрт куплетлык шигырь язып керергә тиеш.

—Кая, шигыреңне күрсәт,—ди ул.

Ә мин әле өлгермәдем.

—Нәрсә турында языйм соң?

Әти, аңа каршы өстәлдә үк утырган үзенең җаваплы секретаре шагыйрь Самат абый Шакирдан:

—Бу яфрак колак нәрсә турында язсын?—дип киңәш сорый.

—Әнә, сыерчыклар килгән. Оя сайлыйлар. Яз шул турыда,—ди Самат абый. Һи-и, дүрт куплетлык шигырь чыгару минем өчен чүп ул. Шакмакка—такмакка корылган булса да, биш минутта гатувый. Әти, давай, кинога егерме тиененне!

—Бармы соң бу тишек борында бераз өмет?—дип сорый әти Самат абыйдан.

—Булыр төсле. Бу темага шома гына шигырь чыгару өчен минем үземә кимендә ике көн кирәк.

Әмма чын сәнгать кешеләре генә кичерә торган иҗади кризис периодлары миндә ул чакларда ук булып куя иде. «Әнә, бозау. Каһәр төшкере, сыер җилемен сөртергә дигән тастымалны чәйнәп тора. Шунын турында яз!»—дигән заказ да бирәләр. Без редакция бинасында ук яшибез. Бер-берсенә кушып салган җиде кисәктән торган озын йорт ул. Шул бинанын ике кисәген без билибез. Әйләнәсен биек койма белән корып алган ишек алдыбыз бик зур. Редакция аты белән бергә, сыер, тана, бозау, ангыра казлар, юып кына алган баскычынны шундук пычратып торучы тавык холерасы асырыйбыз. Әти холера дип атый аларны. Аяк астына туры килгәннәрен тибеп тә очыргалый. Болар өстенә, ике-өч айга бер итәк көчекләр табып торучы, Сарбай исемле ана этебез бар. Галәмәт усал!

Алпут утары түгел бит ул! Дәүләт учреждениесе! Канса да канис, редакция бу! Районнын—иң баш тәрбия үзәге! Ярамый безгә бөтен ишек алдын биләп, мал үрчетеп ятарга, дип әти еш кына сукранып та ала. Ул чорларда партия җитәкчеләренә сыер асрарга ярамый иде. Анын өстеннән жалу да язгалыйлар, сыер-бозау асрый, тавыклар тота, дип. Дүрт бала да, әти-әни үзләре, әнинен әнисе Шәрифә әбием дә безнең белән. Җиде кашык уйнатабыз өстәлдә. Мал тотмасаң, нәрсә ашарга соң?

Бозау әнинең тастымалын чәйнәп торганда, шигырь язу кайгысымы? Мин бозау авызыннан тастымалның калган өлешен йолкып өлгерергә ашыгам. Әтинең законнары кырыс. Егерме тиенне аннан җинел генә ала алмыйсың. Иҗади кризис кичергәнлектән, башында шигырь тумаса, анын янына Тукайның берәр шигырен ятлап керергә тиешсен. Ул үзе бу бөек шагыйребезнең йөзләрчә шигырен яттан белә иде. «Шүрәле»не сөйләргә ярата иде. «Шүрәле»нең татарчасын, русчасын, алманчасын мин дә яттан беләм. Русчасын, татарчасын кызларым да, оныкларым да беләләр. Дөнья әдәбиятының шедевры «Шүрәле»не кытай теленә тәрҗемә иттерергә җае чыгып тора. Кытайнын Шаньдун каласы университетында минем хайваннар, кош-кртлар дөньясына кагылышлы хикәяләр җыентыгым чыккан. Шул университетның «Институт Пушкинского языка» кафедрасы, ирле-хатынлы ике профессор тәрҗемә иткәннәр. Шушы араларда гына мина Мәскәүгә килеп чыккан кытай язучысы шалтыратты. Китабымны да алып килгән икән. Кунакка дәштем, киләм, диде. Безнең Лениногорскида ике кытай гаиләсе яши. Якыннан аралашабыз, кунакка йөрешәбез. Кытай, Шаньдун университеты белән эш йөрткәндә алар мина бик булышалар. Чөнки мин конверт тышына кириллица белән язган адресны, кытай почтальонкалары танымый бит. Адресны кытайча язарга туры килә. Хат алай тизрәк йөри. Телефон аша аралашу мөмкинлеге дә бар. Әмма вакыт аермасы ипсез. Бездә төнге ике булса, аларда иртәнге җиде. Менә шундый чакларны үзенең кытай фамилиясен русчага Мунин дип төзәткән кытай дустым ярдәмгә килә.

Минем үземә бөек Тукаебыз белән җитәрлек дәрәҗәдә горурлана белмибез кебек тоела. Бәлкем анын үзен һәм иҗатын артык яраткангадыр? Әмма Тукай дөньяда үзе дә бер генә, «Шүрәле»се дә! Белгәнемчә, Шүрәле образы дөньяда башка бер генә әдәбиятта да юк шикелле. Ә дөнья дигәнебез киң бит...

Әтидән мирас булып калган матур традицияне оныткан юк. Оныкларым электрон автоматлар белән уйнарга, йә «Макдональдс»ка барырга акча сорый башласалар, башта Габдулла Тукай агаларының берәр шигырен сөйләп күрсәтергә тиешләр. Рус мәктәбендә укысалар да, алар моны кыен эшкә санамыйлар. Ә менә Бөгелмәнең татар-төрек лицеен тәмамлап килүче олы оныгым Арыслан язучы булыр ахры. Ул бүген дүрт телдә сөйләшә, татар һәм рус телләрендә искитмәле матур шигырьләр яза. Мин аны әлегә бераз «авызлыклап» торам.

—Улым, башта укуыңны яхшыга тәмамла әле. Чыгарылыш сыйнфы бит. Шигырьләргә аннары тотынырсың, өлгерерсең дим. Башта ак шигырь белән мавыкты. Хәзер чыкылдап торган эчке ритмлы, музыкаль агышлы рифмаларга күчте. Мин түгел, лицейнең рус һәм татар теле укытучылары мактый аның шигырьләрен.

Язучы булып китми һич мөмкин түгел иде шул миңа. Безгә еш кына кунакка Мөхәммәт Садри, Гали Хужи, бар язучыларның котын алып торган бик усал тәнкыйтьче, ул чорларда «Кызыл Татарстан» газетасының әдәбият бүлеге мөдире Фәтхи Балыкчы кайталар. Ул безнең күрше, партиянең почетлы ветераны, Кышкы Сарайны алуда катнашкан Садыйк абыйның кияве. Соныннан озак еллар «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире булган Рәис абый Сабиров—күрше Мәмдәлнеке. Ләкин ул Мәмдәлдән алда башта безгә кайта. Кара айгырны җигеп, мин аны Биектау станциясенә барып каршы алам.

Безгә күрше генә «Кызыл юл» районы газетасын язучы Рафаил абый Төхфәтуллин чыгара. Ул елларда район газеталары өчен «Халыкара күзәтү»не Казаннан радио аша бирәләрие. Радиодан алучы булып бер кызый эшли. Гыйлеме дә, кругозоры да бик чамалы. Әйтик, чираттагы күзәтүдә радиодан «Халыкара империализмның башында—Америка президенты Дуайт Эйзенхауэр» дип бирәләр. Радиодан алучы кыз шушы исемне хатасыз гына яза аламы инде? Монарчы аңа таныш, ишеткәне булган исемме? Әтинең исә: «Эчке этләр министры Л. П. Берия» дип язып авызы пешкәне булды. Чак исән калды. Шуңа күрә ул миңа: «Кызыл Юл» районына шалтырат. Рафаил абыеңнан белеш, «Эйзенхауэр» ничек языла икән? Хата китә күрмәсен. Рафаил абыең язучы ул. Иплэп кенә сөйләш»,—ди. «Кызыл юл» районына көндезләрен бик теләп тә шалтырата торган түгел. Линиягә чыгып булмый, район үзәге белән миннән башка да сөйләшүчеләрнең чуты юк. Барлы-юклы бер линия булгандыр инде ул. «Әллү! Әллү!»не тамагың ярылганчы кычкырсаң да, сине линиягә кертмиләр. Кичке уннар тулгач кына сөйләшергә мөмкинлек туа. Рафаил абыйдан «Эйзенхауэр» сүзенең ничек дөрес язылышын аныклыйм. Бу бик матур кешегә, олы язучыга карата ихтирамым, мәхәббәтем шул чакта ук туды.

Мин, институт тәмамлап, Лениногорскига эшкә килгәч, Рафаил абый, гаиләсе белән Әлмәткә күченде. Чын мәгънәсендә дуслыгыбыз шунда башланды. Ул минем ике китабымны җәмәгатьчелек тәртибендә редакцияләп бирде. Язучылар берлегенә кергәндә дә тәкъдимнамәне беренчеләрдән булып ул язды. Минем әлеге берлеккә керүем үзенә күрә берәгәйле комедия булды. Ул турыда аерым бүлек язарга ниятлим.

Рафаил абыйның иҗатына багышлап үзем дә ике-өч зур-зур мәкалә бастырдым. Искитмәле матур кеше иде ул. Сугыштан нык имгәнеп, инвалид булып кайткан. Билендә һәрчак корсет йөртте.

—Башымда ат дагасы хәтле мина кыйпылчыгы утыра бит, энем. Башымның бер генә минут та диңгез булып шауламаган чагы юк,—дип сөйләрие. Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегенә җыелышка баргач, мин кунарга аларга керәм. Әтием кебек якын кеше бит. Елга бер уздырыла торган әдәби киңәшмә—ел

йомгагына баргач, мин Рафаил абыйны үзебезнен Дөбъязга кунакка алып кайтам. Бик теләп кайта. Житмәсә, анда анын яшьлек дусты Әгъзам абый Жәләлиев бар. Мәктәп директоры. Әгъзам абый татар театры тарихына кагылышлы бик күп мәкаләләр язып торган зат. Туфан дустым Миннуллин да, «Әлдермештән Әлмәндәр»енә исемне, Әгъзам абый күрше Әлдермеш мәктәбендә директор булып торган чакны, аларда кунакта булган чакта алган. Мин Казаннан алып кайткан кунакка барыннан да бигрәк әтием сөенә иде...

Мин бишенче класстан әтидә корректор булып эшли башладым. Жәмәгать тәртибендә, әлбәттә.

—Улым, бу санны бик жентекләп укып чык. Бер генә хата да кала күрмәсен. Мин райкомга менеп киттем әле,—дип, алдыма буяу исләре анкып торган, үзе редактор булган «Колхозчы» газетасын китереп сала. Әзерлисе дәресемне бер читкә куеп, карап чыгам. Газетада бирелгән материалларга кандала булып ябышам. Әтинен жаваплы сәркатибе Самат абый да укыган, штатлы корректорлары да бар. Әмма алардан сон да берәр хәреф хатасы табу минем өчен дәрәжә! Табам да!

Ә менә алтынчы класстан мин үземнен әтидә конюх, ягъни күнних, ат карауча булып тордым. Штатта, хезмәт хакы алып. Район авылларына чыгып, газетага материаллар тупларга, редакциянен башка хужалык эшләрен башкарырга дип, ана ат тоту каралган. Әти атларнын бер дигәннәрен, ягъни райкомнын беренче секретаре бахбайларыннан калышканнарын гына тотты. Безнен гаилә атка мөкиббән иде. Әти айгырлар ярата. Арада бик холыксызлары да очрый. Бер айгырыбыз уртанчы энемнен сул инбашын умырды. Икенче бер тиле айгырыбыз кече энемне тибеп очырды. Жене кагылудан куркып, энемне бер әбигә өшкертергә үзем алып йөрдем. Әтигә, коммунист башы белән, өшкерүчегә барырга ярамый. Ишетеп алсалар, шундук райком бюросына чакырачаклар. Анда күп сөйләшеп тормыйлар.

—Клади партбилет на стол!—дип кенә сөйләшәләр.

Әти дә, без, малайлар да, айгырлар яратабыз. Әни, жәй көнендә, безне дә төяп, Таш Кавалга кунакка кайта. Ана, кара тарантаска жигелгән алмачуар бия булсын. Янында колыны да йөгереп торсын.

Әтинен штатный күннихы—мин. Күннихнын хезмәт хакы ике йөз егерме сум. Әмма шушы хезмәт хакын бик азсынып, ана күннихлыкка берәү дә атлыгып тормый. Ул елларда бер капчык арыш оны алтмыш сумнар тора иде булса кирәк. Күннихлыкка егетләр алгалый ул. Тегеләре бераз гына эшлиләр дә, китәләр. «Сезнен бу хезмәт хакына дүрт капчык арыш оны алып була бит! Нигә китәсез, дивана башлар!»—дип әти аларны орыша.

Атын булгач, аны ашатырга-эчертергә, астын чистартып торырга да кирәк шул. Бер генә атна чистартма—тирес бөтен абзарынны баса.

Әтинен башында—каракүл күн бүрек. Өстендә, кыршылганрак булса да, күн пәлтә. Аягында—ак фетр. Ул елларны район житәкчеләре шундый мода белән киенә иде. Нигә ул гына калышып торсын әле?! Әмма бу киемнәр белән ат янына килә дә, атны жигә дә алмый бит инде ул. Атны рәхәтләнеп мин жигәм. Камыт бавын тартырга гына көчем житми. Аны әти белән икәүләп тарттырабыз. Әти каяндыр кайтса, аны каршы алып, тугарырга кирәк. Өйдән очып чыгып тугарам мин аны. Ат бит ул! Иртән мәктәпкә киткәнче үк, иртәрәк торып, салам турап, кайнар башак болгатып бирәм. Шундый чакта биябезнен тәкатьсезләнүен күрсән, әй! Гомер буе ач торган диярсен. Шундый чакта: «Кая тыгыласын! Суынсын бераз! Авызынны пешерәсен бит!»—дип, биямнен, йә айгырнын танавына төртеп-төртеп алам. Яратып инде. Унөч яшьлек малай бит мин ул чакта...

Әйе, унынчыны тәмамлаганчы, әтиемдә күнних булып тордым. Штатта. Уч тутырып акчасын алып. Аттестатлы булгач, университетка барып карадым.

Геолог булырга иде исәп. Рус теленнән сочинениене «өчкә» генә яздым. Конкурс көчле иде, калган имтиханнарны биреп тә тормадым. Барыбер уза алмам, дидем. «Шалтырап», үз-үземнән оялып, Дөбъязга кайтып төштем. Мин имтиханнар тотып йөргән арада, минем «акция»ләр нык үскән. Минем укырга керә алмавыма, әтидән дә болайрак сөенүче булдымы икән?! Улым, булганым, Ислетар лесхозына барып, редакциягә кыш чыгарлык утын хәзерләргә делянка сөйләшеп кайт. Йөз егерме—йөз утыз кубометрларсыз да кышлый алмабыз. Син кайтканны көттем. Казаннан илле рулон кәгазь алып кайтасы бар. Газета чыгарырга кәгазебез тагын ике-өч санлык кына калды. Иллэт болынынннан биш гектар болын сөйләштем. Киләсе атнада, редакция кызларын да җыеп барып, шул печәнне чабып кайтырсыз. Юкса, кышын ни ашатырбыз,—дип тезә генә минем алга бурычларны.

Университетка керергә маташып йөргәндә, Арча ягыннан килгән бер бик чибәр кызга күзем төште. Ул да керә алмады. Имтихан тота алмау хурлык бит ул. Оятыннан җир тишегенә керердәй буласың. Мондый кыен хәлдә безнең ул чибәркәй белән сүз алышу, аңлашу булмады. Бер-беребезне ошатуыбызны күзләрдән аңладык. Адресын гына аласы булган икән лә. Аңа да кыюлыгым житмәде. Димәк, алдагы сезонда очрашмый калмабыз әле. Аңа хәтле торса. Берәрсенең җылы кочагына чуммаса. Киләсе елда укырга керә алмасам да, барыбер эзләп табармын әле мин аны.

Бу кызга күзем төшүнең нәтиҗәсе шул булды: мин Дөбъязга маймыл сурәте төшерелгән галстук тагып кайттым. Дөбъяз халкы бик нәзберек, зәвыклы публика, андый купшылыкны бер дә килештерми.

—Барый малае укырга керә алмаган. Аны гына көтеп торалар, дип барган булгандыр инде. Тот капчыгынны! Ә муенына муенчак тагып кайткан. Күрсәң, тәгәрәп китешле,—дип көлүчеләр дә булды. Исем китте инде бик! Минем күңел түренә хәзер теге Арча ягы кызы кереп оялады. Әллә шул Арча ягына барып чыгып, бер айкап кайтыйммы, дип тә уйланам. Барсам, әлбәттә, табам инде. Укырга керә алмавым башка сукты. Әти исә:

—Улым, бу матур галстукны каян кулга төшердең соң? Колхоз базарыннан алдыңмы, әллә Бауман урамында сәүдә итә торган кытайларданмы? Казанга барганда тагарга миңа да биреп торырсың,—дигән булды. Әтинең тел төбен әлегә аңлап бетермим, әмма мине шулай жумалавының сере булырга тиеш. Мин дә бик тирәнгә кереп тормыйча, мәсьәләне кабыргасы белән куйдым:

—Унны бетергән башым, шундый галстук таккан муеным белән, мин синдә бер көн дә күнних булып тормыйм. Оялам. Бөтен Дөбъяз көлә миннән галстуклы күнних дип,—дип әйтеп салдым.

Көлмәслек тә түгел. Ул галстукны мин муеннан төшермим генә түгел, йоклаганда салырга да онытам. Арбага ике буш мичкә салып, Дөбъяз урамына җәйгән калтыр-колтыр шоссе юлдан дөбер-шатыр суга төшеп китәм. Минем муендагы төсле фасонлы галстукларны ул заманнарда бик танылган стилягалар гына тага иде.

Әти тиз төшенде минем халәтне.

—Улым, мин сине бүгеннән үк үземә завхоз итеп алам. Тик син эшендә генә кал,—диде. Редакция штатында завхоз урыны каралмаган. Вазыйфасы шул ук инде, ат карау. Әмма исеме—завхоз! Күнних түгел инде. Бигрәк тә безнен Дөбъяз аурасы, менталитеты өчен. Завхоз—дәрәҗәле эш урыны!

Кырт итеп өс-башны карадык. Егет кеше бит мин хәзер. Кулга «Победа» сәгате алып тактык. Шул сәгатьне беренче такканда әни:

—Улым, сәгатеңне бик саклап тага күр. Беренче таккан сәгатең нинди булса, хатының да шундый булыр,—дип кисәтте. Начар хатынга юлыкмагаем дип, ул сәгатьне озак еллар, бик саклап тактым...

Әти дә укытучы, әни дә укытучы. Ә нигә миңа да укытучы булмаска?!

Укытучы—авыл жирендә ин кадерле кешеләрнен берсе. Жәйге ялы гына да ни тора! Өч ай бит. Укытучы булырга хәл иттем. Документларымны Болак буендагы педагогия институтына илтеп тапшырдым. Тарих факультетына. Беренче имтихан рус теленнән, язмадан. Шунын белән кисәләр бит инде абитуриентларны. Ә мин рус теленнән курыкмыйм. Чөнки «Колхозчы» газетасы «Колхозник» исеме белән русча да чыга. Анын да штаттан тыш корректоры мин. Немецчәне дә яхшы беләм. Аны безгә Казаннан кайтып-килеп йөргән Гайшә апа укытканые. Бик төпле белем бирде ул безгә. Һенрих Һейне, Шиллер теленә мәхәббәт тәрбияләде. Алманча мин бүген дә яхшы беләм. Алар белән тәржемәчесез сөйләшәм. Бер елны Ромашкино нефть мәйданына Алманиядән кунаклар килгәние. Шунда бер төркемгә тәржемәче булып йөрдем. Укытучыбыз Гайшә апага рәхмәт! Анын унганлыгы нәтижәсе.

Теге чакта, университетка имтихан биргәндә, икебез дә провалга очраган бик чибәр Арча кызы һаман да күнелдә әле минем. Ошаганые ул мина. Берочтан аны да очратмаммы, дип йөрим.

Актлар залына йөзләп абитуриентны кертеп тутырдылар. Рус теленнән сочинение язабыз. Артыма борылып карасам, миннән өч-дүрт парта гына артта Арча кызы утыра. Менә сина мә!—Телепатия! Ул безләп карамаса, мин дә борылмаган булыр идем. Сәламләгәндәй итеп, авыз чите белән генә елмаеп алды. Үзем сочинение язам, Тургеневнын Базаровын мактыйм, үзем имтиханнан чыгу белән Арча кызына жайлап кына сүз кату планын корам. Планлы эш таркалмас, ди бит китап. Бәлкем, кулына ин кыйммәтле тундырма алып тоттырырмын, бәлкем, киногa кереп чыгарга тәкъдим ясармын. Имтихан арасында кайтып-килеп йөрергә исәбе булса, Арча поездына озатып куярмын. Мондый чибәрләргә вакытынны сарыф итсән дә, кесә расхуты чыгарсан да—стоит! Шундый ныклы вә төпле уйлар белән коридорга чыксам, Арча кызы озын буйлы, кин күкрәкле бер курсант кочагында. Алтын алка колакта, чибәр кызлар кочакта! Ачу килде, әлбәттә. Килмәскә сон! Нинди якты планнар корганыем бит.

—Әй-й-й! Казан хәтле Казанда Арча кызыннан чибәррәкләр дә табылыр әле,—дип юаттым үземне. Юатмыйча! Утырып еламам ич инде. Чыннан да шулай булып чыкты. Кызларнын ин чибәрләрен генә сайлап йөрдем мин, валлаһи. Кайберләренен фоторәсемнәрен әле дә саклыйм. Әмма шулар арасында ин чибәре минем гомерлек хәләлем—Мәдинәм-Гөлкәем. Вәләкин шунысы да бар, шушы яшькә житеп, анын мина өздереп кенә: «Яратам мин син холыксызны» дип әйткәне юк әле.

Мишәр әйтмешли, ошбу «йөрәк маем» да жинел генә төшмәде минем кулга.

Йөргән, сөйгән кызынны, гомерлек хәләлен булырдай ярынны көндәшләрен кулыннан, борын жимереп, кан коеп та алмагач, анын ни тәме дә, ни яме! Шулай булмыйча! Башкалар башкача уйласыннар, пажалыста. Үз фикерләрендә калсыннар. Әмма Мәдинәм-Гөлкәемне, «Мин тырышып хатлар язам, синен исендә дә югымны», ярты институт егетләре белән сугышып бетеп, үземнеке иттем. Үкенмим, дип әйтергә була төсле. Көнчелек галәмәте дә миндә колакларымнан гына түгел, түбәмнән ашкан. Мөхтәрәм Пушкин әфәнде дә Дантес белән хатыны Натали аркасында атышкан. Галәти булмаган физик көчен күрсәтү өчен циркларда да чыгыш ясаган бөек язучы Куприн әфәнде, аш өстәле артында матур гына сөйләшеп утырганда хатыны һәм китапларынын редакторы Даманскаяга берәр автор күбрәк игътибар күрсәтсә, кулына ике чәнечке алып, алардан штопор ясап, өстәлгә ыртыта торган булган. Кешелек сыйфатларыбыз арасында байтак кына тискәре якларыбыз булганга, бер сүз белән—Язучы, дип атамадылар микән безне, әй?!

## Вәт, малай, булды хәлләр...

Мин: «Язучы булмыйча, башка һөнәр иясе булырга мөмкин дә түгел иде»,—дип шар ярып әйтеп салганыем бит. Кем әйтмешли, ул шапырыну яшьлегем хатасы була язды бит, әй. Язучы булам, дип йөрсәм дә, сәгате суккач, мангаема салкын тир чыгарып, шиккә калдым. Булырмы соң бу егетлек миннән? Халыкка, укучыларыма әйтер сүзем бармы? Фикер иясеме соң мин? Язучылар берлегендә буш арба булмаммы? Мин бик хөрмәт иткән, өйләренә кунакка йөргән, соңыннан миңа Язучылар берлегенә әгъза булып керергә бик җылы рекомендация биргән Габдрахман Әпсәләмовка шулай бер заман: «Язучы булуы бик кыен, тема табуы да бәла, язганыңны басмыйлар»—дип зарланып алган идем.

—Альберт, энем, браткам!—дип гаҗәпләнде остазым минем бу сүзләремә.—Язучылыкка кем сине чакырып китерде? Кем бәйләп тота? Ташла да йөгәнеңне, әнә, яшел болынга кач. Койрык чәнчеп, рәхәтләнеп уйнакла!

Аның бу сүзләре миңа гомерлек сабак булды. Язучылык чире бер йоккач, тиз генә котыла торган чир түгел шул ул. Казанга килгән саен Габдрахман абыйларга сугылам. 1966 нчы елда яшь язучыларның зур семинары булганые. Мин Әпсәләмов җитәкләгән төркемгә эләктем. Шуннан дуслашып киткәниек. Остазымның хәләле Маһинур апа да якты йөз белән каршы ала. Килгән саен дипломатыма Алманиянең үзендә эшләнгән хатын-кыз бизәнү әйберләре тутыра. Ул елларда мондый әйберләр кибетләрдә юк иде әле.

—Мәдинәң театрларга бизәнеп барсын. Язучы хатыны әйбәт киенгән булырга тиеш. Безгә халык бик төпченеп карый,—ди. Лениногорскида театрлар елына бер, йә ике була. Аларына да йә бара аласың, йә юк. Маһинур апа ул чакта әле бакчага гына йөргән кызларыма да Винни Пух, Барби, тагын әллә нинди курчаклар биреп җибәрә. Мондый затлы әйберләрне аларга уллары Булат Мәскәүдән алып кайткандыр инде.

Мин килеп керешкә, Маһинур апа төче коймак өлгертә.

—Сыйлыйм әле үзеңне мишәр коймагы белән,—дип елмая.

—Габдрахман абый пианино өстенә коньяк куя.

—Барган чакта син тоткала бу әйберне. Мин менә бик тотар идем дә, бармый. Ярамый,—ди. Бер рюмканы салып алдыма ук куя. Мин оялам. Әмма кайнар коймакны вареньега мана-мана ялтыратам гына.

Аларга соңгы баруымда Габдрахман ага паралич сугудан терелеп кенә килә иде. Шундый матур, ачык йөзле агам ямьсезләнгән. Ятып торган җиреннән бүлмәгә таякка таянып кына чыкты.

—Күр инде, күр, бу паралич дигән зәхмәт мине нишләтте,—ди. Мин килгәнгә бик шат. Беренче соравы болай булды:

—Вакытың бармы?

Иртәнге ун-унберләр тирәсе бу. Бөгелмәгә билетны соңгы рейска, кичке тугызга гына алганыем. Ул елларда Бөгелмә аэропортына очкычлар көненә ун-унике рейс оча иде.

—Вакытым бар, бар,—дидем абзама.—Кумасагыз, кичке сигезгә кадәр кала алам.

Габдрахман ага өстәлгә бер кочак хат чыгарып салды. Барысы да китап укучылардан килгән.

—Алар бит минем хаста икәнемне белмиләр. Җавап көтәләрдер. Әпсәләмов тискәре кеше икән. Үмер эчендә бер хат яздым, шыңа да җавап язмады дип, мине орыша булырлар. Вакытың булгач, язый шуларның бер унына җавап,—диде.—Әнә, коньякны да тоткалап утыр. Карап тору өчен генә куелмаган ул.

Хатларның нинди эчтәлекләре генә юк. Кайсы акыллы киңәш, кайсы социаль мәсьәләләрдә ярдәм сораган. Үзләренең «мишәрстан якларыннан»:

«Бик инде писатель булырга келим, желанием кечле, къадан, нишек башлыйм? Выгодасы булырмы?»—дип язганнары да бар.

—Безнен мишәр шандай, шандай, выгодасыз эшкә алынмас,—дип елмая остазым. Мин костюмымны салып, урындык артына элдем. Җинемне сызганып, хатларга җавап язарга керештем.

«Габдрахман абый җанымда басып тора. Ул әле каты авырудан соң терелеп кенә килә. Аның әйтеп торуы буенча сезгә бу хатны яшь язучы Альберт Хәсәнов яза»,—дип башлап киттем. Бәлкем, ул хатлар кайбер укучыларның архивларында саклангандыр да. Ул көнне мин төп-төгәл алтмыш хатка җавап яздым. Араларында үзебезнең Лениногорскидан килгән хат та бар иде. Бу иптәш Мәскәүнең Ломоносов исемендәге университетның философия факультетын тәмамлаган. Философ! Акыл иясе! Хәйлә дигән нәрсәнең мыскалы да юк аларның миләрендә. Аларның берләре материяне беренчел дип, икенчеләре рухны алга сөрүчеләр. Араларында тормыштан үз теләкләре белән китүчеләр дә очрый. Бу философ мәктәптә балалар укыта икән. Туган якны тирәнрәк өйрәнү максаты белән аларны күрше-тирә авылларга походларга да алып чыгып китә. Походларда йөрү өчен ходовой гына җыр кирәк. Бер походка чыккач, бүкән өстенә утырганнар да, балалар белән бергә җыр чыгарганнар, көен дә тапканнар. Шуның өчен бу иптәшне район газетасында бик нык тәнкыйтьләп язып чыкканнар. Бу философның тәрбия ысуллары совет тәрбиясе калыпларына туры килми дип, эзәрлекли дә башлаганнар...

—Кайткач ук горкомыгызның беренче секретарына кер. Минем исемнән сөйлә. Бу кешене эзәрлекләмәсеннәр зинһар. Ә һәйкәл куйсыннар. Чын педагог—менә ул! Балаларны табигать кочагына алып чыгып, аларны хыял дөньясына чумдыра. Җыр чыгарганнар икән, рәхмәт кенә. Рәхәтләнеп җырласыннар. Шуннан кемгә зыян?! Рәхмәт әйтсәсе, кулын кысасы урында,—дип Габдрахман абый бу сүзләрне үзе әйтеп торды.

Кайткач, чыннан да горком секретарына кердем. Якладым ул абзыйны. Бу турыда сүз шуның белән тәмам булып торсын.

Габдрахман Әпсәләмов. Бу олуг зат белән аралашкан минутларым күңел түремдә матур хатирәләр булып саклана. Берчакны мин Казанга ял көнендә, кичке якта гына килеп төштем. Мондый чакта кая, кемгә барасың? Туганнар да, дус-ишләр дә барын бар. Әмма алар—дачаларындадыр. Кем дә булса бардыр әле дип, Язучылар идарәсенә киттем. Барсам, эш бүлмәсендә Зәки абый Нури утыра. Зәки абый белән дус булмаган кеше юктыр ул. Без аеруча дуслар. Бер чорны без аны үзебезнең Лениногорскидан ТАССР Верховный Советына депутат итеп күрсәттек. Мин аның ышанычлысы булып йөрдем. Белоруссия партизаны, Минск каласының почетлы гражданины, үзенчәлекле шагыйрь Зәки абыйның ышанычлысы булу үзе бер дәрәҗә! Мине ярата иде ул. Килгән чакта ярдәм сорап гариза яздыра. Яшьләр фондыннан. Яхшы номерларга урнаштыра. Сөйләшеп утырырга кичләрен үзе дә килеп чыга. Бу юлы Зәки абый хәл-әхвәлне дә сорашып тормады.

—Беркая да китмә! Шушы тирәләрдә генә бул. Бүген дустың Әпсәләмгә кунакка барабыз,—диде. Идарә каршына кара «Волга» белән Габдрахман абыйның улы Булат килеп туктады. Башта без остазымның Боровое Матюшинодагы дачасына машинага төяп ризыклар илттек. Икенче рейс белән язучылар килде. Шәүкәт Галиев, Нәби ага Дәүли булуын хәтерлим. Нәби ага немецлар кулында әсирлектә булган. Мин әдәбиятка килгән чорларда язучылар арасында аңа кырынрак, хәтта бераз мыскыллырак карау сизелә иде. Заман шаукымы. Әмма Габдрахман абый аңа бик җылы мөгамәләдә булды. Ихтирам итмәсә, чакырмаган да булырые. Зәки абый янында чыраеңны сытып утыра алмыйсың, уен-көлке сүзне сибеп кенә тора. Табын артында бик күңелле утырдык. Миңа урынны верандага җәйделәр.

—Безнең монда салкынчарак кичләрен. Өшемисенме?—дип Габдрахман абый яныма чыкты.—Салкынча булса, толып чыгарам. Хәлләрең ничек? Язып буламы?

«Сине соң язучы булырга кем чакырып китерде. Кыен булса, йөгенне ташла да, болынга кач»,—дигән сүзләреннән соң, мин бернигә дә зарланмыйм. Гомерлек сабак булды аның бу сүзләре.

—Ә Язучылар берлегенә керүең ни хәлдәрәк тора? Барлык документларың да әзерме? Рекомендацияләрең җитәме? Безнен мишәрдә: «Кала кала-кала да, губернага әйләнә»—диләр. Калмасын. Бар нәрсә дә үз вакытында кадерле. Минем рекомендациям дә иртәгә Союзда булыр. Шуннан соң да нүҗәли алмаслар икән?! Хәер, бик мөмкин. Мин хәзер—хаста. Сүзем үтми башлады»,—дип янымда утырды.—Тынла, алайса үзенә бер мәзәк сөйлим. Карендәшләремне борчымый-нитми генә үлим әле, дип тау куышына кереп яткан филне тычканнар кыерсыта икән. Филне тычканнар җәберләсен инде! Кеше ышанырлык хәлме, диген. Теге шайтаннар, филнең озын борыны эченә кереп оя корып, борын сенгерләрен кимерәләр икән. Үзем дә шул хәлдә бит,—дип Габдрахман ага көлеп куйды.—Иҗатымны, язган әсәрләремне тәнкыйтьләүчеләр күбәйде...

Мин шул көнне үк кайтып киттем. Икенче көнне сәгать уннарда, ул дәвердә Язучылар берлегендә җаваплы секретарь булып эшләгән Равил Фәйзуллин өйгә шалтыратты.

—Сиңа тагын бер рекомендацияне Габдрахман ага Әпсәләмовның тормыш иптәше Мәһинур апа идарәгә китереп үз кулы белән минем кулга тапшырды,—диде.

Минем Берлеккә керүем тарихта бер мәзәк булды ул. Яшьлекнең бер чорында керәсе, әгъза булып торасы килә анда, шайтан алгыры, инглизләр әйтмешли, чьорт побьюрый. Бүгенге яшьләр өчен бүген дә шулайдыр. Дәрәҗә бит! Аларга карата бик игътибарлы булырга кирәк. Шул ук вакытта Берлекне буш балластлар белән дә тутырырга ярамый. Әдәбиятыбызга керткән өлешләре пүчтәк кенә булса да, андыйлар төркемнәргә берләшәләр, корылтайлар вакытында үзләрен начар тоталар, күкрәк сугалар, әллә нәрсәләр даулыйлар. Берлеккә әдәбиятыбыз йөген төп тәртәгә җигелеп тарту өчен кергәннәрен оныталар. 2002 нче елның азагында, Язучылар берлегенең утырышына туры килдем. Шунда Берлеккә әгъза итеп Габдрахман ага Әпсәләмовның онукасы, ягъни Булатның кызы Альбина Булатовна Әпсәләмованы алдылар. Русскоязычная икән. Төкле аягы белән килгән коллегабыз булсын. Бүлеккә алуны сорап гариза язганчы, ул инде ниндидер әдәби премияләрнең лауреаты да булырга өлгергән. Арабызга буш балласт кермәдеме, дип шикләнергә урын юк. Болар өстенә, ул бабасы язган телне дә ныклап өйрәнергә теләге барлыгын әйтте. Ә менә мин Берлеккә алай шома гына кереп китә алмадым.

«Казан утлары»нда басылу—дәрәҗә. Ул синең язучы булып җитүеңне раслый торган фактор. Минем анда басылган беренче хикәяләрем «Яшь наратлар» белән «Гомер иткән нигез» иде. Аларны басарга Ибраһим абый Гази тәкъдим итте. Әмма журнал папкасында алар ничектер озаграк яттылар. Ибраһим абый мине очратып:

—Басылдымы синең теге ике хикәяң? Әллә мин күрмәдемме?—диде.

—Күренми шул әле,—дидем. Ул чакта Язучылар берлеге рәисе Ибраһим абый журналга шалтыратты.

—Ибрай вакытын кая куярга белми, дип уйлыйсызмы әллә сез анда? Яшь авторның ике хикәясен сайлап алып, кулымны куеп басарга тәкъдим иттем. Ә сез һаман да сузасыз. Бу санга ук кертегез,—диде дә, трубканы ташлады. Ибраһим ага шундыйрак холыклы кеше иде. Әмма классик! Зур талант иясе.

Аның белән дә әкәмәт хәлләргә тарып беттем.

Мин Вышкалар монтажлау конторында эшләгән чорларда, безнең Лениногорск сайлаучылары Ибраһим абый Газины РСФСР Верховный Советына депутат итеп күрсәттеләр. Наказлар да бирделәр әле. Китапханәбез юк, депутат булып сайлангач, китапханә салырга булышырсыз, диделәр. Хәзер бер дигән китапханәбез бар. Олуг шагыйребез Габдулла Тукай исемен йөртә.

Булачак депутатыбыз башта сайлаучылары белән очрашуга килде. Андый зур каләм остасы, Язучылар берлеге рәисе килгәч, шәһәр җәмәгатьчелеге шау итте. Ә мин аны каршы алырга да, беренче көнне Нефтьчеләр сараенда аның белән булган очрашуга да бармадым. Минем хәтта диссидент хәленә төшеп, оппозициядә торган чорым. Берсе артыннан берсе хикәяләр шапылдатуны туктаттым да, «Сукмаклар» дигән роман язып ташладым. Өч йөз алтмыш биш бит. Нәшрият исәп-хисабы белән унбиш табак! Илья Ильф, Петровлар стилендә, өлгереп житкән социализм шартларында яшәү рәвешебезгә карата ачы сарказм вә ирония белән. Роман басылмады. Халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Гамил абый Афзал очрашкан саен, ул бик көчле романыңны кайчан бастырасың инде, дип аптырата иде. Гамил абый, неподкупный мужик, начар әйберне мактамас. Менә шул романны, кулъязма хәлендә генә кулга төшереп, чираттагы Әдәби ел йомгакларында тетмәсен тетеп, тәнкыйтьләп чыктылар. Бәлкем өстән шулай кушкан булганнардыр. Югыйсә, мин анда кызыл җепкә урап, дөньялыкта олы тормыш юлына һәркем, кыска гына булса да, үз сукмагын салып чыгарга тиеш, дигән фикер үткәргәниием. Әйе, олы юлга үз сукмагыңны салып чыгарга кирәк. Кемдер салган сукмактан түгел. Шушы басылмаган әсәр өчен мине Лениногорск Солженицыны дип атадылар.

Югыйсә, Солженицын исеме тагарлык берни дә юк төсле тоела әсәремдә. Әмма япь-яшь башым белән андый ярлык алгач, мәрхәмәт юк инде миңа. Нәшриятка да юллар ябык. Подпольега күчеп, юрганымны башымнан бөркәнеп, өнемә кереп ятсам гына инде. Сүземнең очын истән чыгармыйм. Бу хәлләр нәкъ менә безнең калага депутатлыкка кандидат булып Ибраһим ага Гази килү алдыннан булды. Житмәсә, бергә аралашып яшәгән дустым, көнчелеген тыя алмаганмы, минем өстән Ибраһим абыйга аноним хат җибәргән. Каян сүзен, каян нахак бәлаләрен табып бетергән, унтугыз бит язган! Минем эшкә чыкмыйча атналар буе эчеп ятуым, дүрт-биш хатын алып аеруым, плагиат белән шөгыльләнүем, тагын әллә нәрсәләр турында. Хәтта: «Альберт Хәсәнов чит ил разведкасына хезмәт итмиме икән»,—дигән җирләре дә бар. Шушы иптәшнең минем өстән анонимка салуын мин белмим бит. Күрешкәндә елмаеп кулын бирә, дуңгыз. Кулак нәселеннән булуымны да онытмаган. Зәки абый Нури күрсәтте ул хатны миңа. Зәки абый тормыш сөючә, бик шат күңелле кеше иде.

—Минем турыда шундый онанимка язсалар, мин бик сөенер идем әле. Язгалыйлар, әмма болай ук тәэсирле түгел,—дип укытты ул аны миңа көлә-шаяра.—Әмма эшең кәкәй. Ибрай бу хатны, йөзен балан кагы капкандай, сытып укыды. Мә, разберис, синең яраткан партизаның, дип миңа сузды.

Соңыннан Ибраһим абый ул хатны үземә бирде. Әмма аңлашканчы әле биш пот тоз ашыйсыбыз бар иде.

Ибраһим Газины Лениногорск төбәгеннән депутат ясарга йөргән чорда безнең горком секретаре Ядкәр Гариф улы Шәфиков иде. Бик дус кеше. Лениногорскига икебез дә бер елны килеп, мин редакциядә эшли башладым, ә ул авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, совхозның бер бүлекчәсенә башлы итеп билгеләнде. Икебезне дә шунда ук комсомол шәһәр комитеты бюросына сайладылар. Шәфиков житәкләгән совхоз бүлекчәсендә малларны уңышлы кышлату турында мәкалә дә язганыем. Менә аны КПССның шәһәр комитеты житәкчесе итеп күтәрделәр. Беркөн кичтән ул шалтырата.

—Син бүген кичен башлыгыгыз белән очрашуга нигә килмәдең?—ди. Мин—ык та мык.

—Кичә өч җирдә очрашуда булдык. Ул агаегыз белән уртак тел табуы кыен. Үзен мактап бер сүз әйттерми. Кыскасы, минем бүген колхозларга чыгып китәсем бар. Без аны «Хрущев кунакханәсенә» урнаштырдык. Иртән йокыдан торышына каршына барып баскан бул. Бер алдына, бер артына төш. Башлыгың бит. Кирәге чыгып куюы да бар.

Ядкәр Гариповичка мин бит барын да ачып сала алмыйм. «Солженицын» булуымны да әйтә алмыйм.

—Хет үтер, булмый миннән,—дидем.—Яратмый ул мине-е-е-е! Аңлыйсынмы, яратмы-ы-ый.

—Син кем? Девка что-ли? Нигә дип ул сине яратырга тиеш? Менә мине яратучылар да күк йөзендәге йолдызлар хәтледер дип әйтә алмыйм, һич тә. Яшибез бит әле. Бу сиңа минем тарафтан житкерелгән дәүләт күләмендәге әһәмиятле парпоручение. Үтәми генә кара! Минем холыкны беләсең. Бюрода информацияң...

—Белүен беләм дә, Ядкәрь...

—Разговор окончен. Немедленно приступай к исполнению!

—Бездә «Хрущев йорты» дигән затлы-элиталы кунакханә бар. Аны Н. Хрущев киләсе булгач, махсус салып куйганнар иде. Анда хәзер дә иң зур кунакларны гына кертәләр. Көз айлары бу. Иртүк торып, шунда киттем. Аягым бер дә тартмый. Тауга каршы тегермән ташы тәгәрәтү миңа мең өлеш җиңелрәк булырые. Иртәнге җиде тулмаган әле. Барсам, Ибраһим абый бакчада йөри. Өстен яфрак баскан сукмак буйлап ике кулын артка куйган, каршы килә. Сәламемне алдымы-юкмы, хәтерләмим. Әмма коточкыч җирәнеп карады төсле миңа. Кунакханә биек таш койма белән әйләндереп алынган. Эчтәге хәлне ят күзләр күрмәсен өчен. Ишек алды тыныч. Аннан башка беркем дә юк. Бераздан моны иртәнге чәйгә дәштеләр. Кереп китте. Мине чакырмады. Мин тышта калдым. Анысы гына, чурт с ним санә, нимесчә әйткәндә—доннер веттер!

Бераздан горком егетләре белән горком машинасы килде. Ике-өч хезмәт коллективында булдык. Ә кичен янәдән Нефтьчеләр сараенда очрашу. Хәтта үз биографиясен, шәҗәрәсен дә юньләп белмәгән бер мокыт-обыватель булачак депутатының иҗатын каян чамаласын? Кандидатның иҗат юлын якыннан белүче буларак, төп чыгышны миңа ясарга куштылар.

—Татар совет әдәбиятының күренекле вәкиле, проза остасы, тәрҗемәче һәм актив җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Гази, ягъни Ибраһим Зарифулла ул Мингазиев 1907 нче елның 4 февралендә, Татарстан АССРның Кама Тамагы районы Иске Карамалы авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа,—дип башлап киттем инде. Бик яшьли ятим кала, дип тә өстәдем. Аннары иҗат юлы турында сөйләп киттем. Үзем бик яратып, онытылып укыган «Онытылмас еллар» романын, Татарстан нефтьчеләренең батыр хезмәтен, нефть чыккан якларда яңа кешеләр җитлегүен сурәтләүгә багышланган «Гади кешеләр» романын язды, дип сөйләдем. Андый чакта мактау сүзләре әйтми дә булмый. Депутатлыкка хөрмәтле кандидатыбыз Тукай премиясе лауреаты, ике тапкыр Почет билгесе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, дип тә әйттем. Ибраһим абый президиумда утыра бит. Трибунадан мактаганда миңа шул хәтле усал итеп карый, теше җитсә, шатырдатып чәйнәрие. Мин бит аның өчен сөйләмим, залда утырган кул чабучылар өчен сөйлим. Горком, горисполком кешеләре өчен дә.

Әлеге кичке очрашудан соң безне «Урал» ресторанына алып бардылар. Горком кешеләре мине Ибраһим абый белән рәттән утыртмакчы булалар. Мин мөмкин кадәр читтәрәк урын сайлыйм. Ибраһим ага исә, шуннан,

ерактан торып та мина: «Син, егетем, монда ни дип ияреп килдең инде?»—дип карый.

Шулай берчакны язучыларыбыз күрше Чуашстанга очрашуга барганнар. Бер кунак йортында чуаш кызлары Ибраһим аганы бик кыстыйлар икән. Көмештәй саф ангалабыздан авыз итмәсәгез, ап-ак капрон күлмәгегезне пычратып, муеныгызга салабыз дигәч, шул самогонны кабып, өч сәгать буена йотмый утырып, урамга чыгу белән түкереп ташлаган Ибраһим абый бит ул! Бу турыда бер күрешкәндә шагыйрь Сибгат ага Хәким сөйләгәние. Аннары Ибраһим абыйның үзеннән дә сорадым.

—Капрон күлмәкләрнең чыккан гына чагы. Ул күлмәкне портфелемнән алып кигән генә идем. Муеныңа салабыз дигәч, каптым шул ангалаларын. Ләкин йотмадым,—дип агай үзе дә раслады. Менә шушы, гомере буена бер рюмка тотмаган кешегә, жай табып кара! Жәмгыять, үз өстенә төшкән бурычын, нинди дә булса берәр олуг затны хөрмәтләгәндә, аңа күпме рюмка тоттыруы белән бәяләмәкче була. Шундыйрак заманнар килде бит. Ә бу очракта әлеге Олуг зат—Камил аек! Хәтта исен күтәрә алмый. КПССның шәһәр комитеты секретаре Ядкәр Шәфиков та агай белән шул жирлектә уртак тел тапмаганнар бугай. Шәфиков аны сыйламакчы булган, агай баш тарткан. Аның мыскал да капмаганын кем белсен?

—Егетләр, васыять итеп әйтәм, мин үлгәч, ягъни аягымны сузгач, мине зинһар зиратның корырак жиренә жирләгез. Юкса, миндә коточкыч рематиз бит,—дигән сүзләр дә аныкы. Галәмәт тә шаян телле юморист иде ул. Аның «Замана балаларын» тәгәри-тәгәри көлеп укыдык ич.

Ресторанда чакта, өстәлнең теге башында утырсам да, булачак депутатыбыз исәнлегенә рюмкалар тотканда, күзлеге аша мине усал мөгезләп:

—Нәрсә утырасың? Эч!—дип куя. Эчүен яшереп, кәнфитләнеп утыра, дип уйлый инде. Минем өстән язылган анонимкада мин бит «последний алкаш»—дип күрсәтелгән.

Ике көннән соң горком егетләре безгә бөтенләй иярми башладылар. Очрашулар тәртибен минем кулга тоттырдылар. Хезмәт коллективларыннан билгеле сәгатьтә килеп алалар, очрашудан соң кире китереп куялар. Очрашу вакытында сайлаучылар кайбер наказларын әйтәләр. Аларын да мин теркәп барам. Ара-тирә Ядкәр Шәфиков шалтырата. Күп сөйләшеп тормый.—Партиянең Лениногорск шәһәр комитеты сезнең эшчәнлектән канәгать,—ди дә, трубканы куя. Горком канәгатьтер дә... Әмма безнең арадагы үзара мөнәсәбәтләребез булачак депутатыбыз белән дөбер-дөбер кайнау ноктасына житте. Беркөн очрашудан кайткач, аяз күк йөзенә бихисап йолдызлар калыккан матур кичтә, кунакханәгә кереп китәр алдыннан, Ибрай абыем, күзлеген сөртә-сөртә:—Син, энем, чыннан да шома егет икәнсең, ничәнче көн минем тирәмдә ни дип бөтереләсең? Язучылар берлегенә керәсең киләме? Әллә китап чыгарып булмасмы? дип чуаласыңмы?—диде. Сүзләрен сирәк тешләре аша сыгып чыгарды.

Олы язучы, Язучылар берлеге рәисе, сиңа базар карчыгы түгел, тупас сүзләр әйтеп орышмас ич инде. Әмма минем өчен аның бу сүзләре бик тупас тоелды. Минем дә түземлегем соңгы чиккә житкән булгандыр.

—Ибраһим абый, авырга алма, яме. Сез мине сөймәгән кебек, минем дә сезне күрәсем килми. Коммунист буларак, горком кушканны үтәп йөрим бит. Үтәмәсиең дә, шушында яшисе бар. Бер поручение биргәниек, шуны да үтәмәде, диярләр. Сине озатып йөрергә алар куштылар. Шәфиков үзе кушты... Югыйсә, ике аягымның берсен дә...—дип тездем дә салдым.—Ибраһим абый, тәмам гарык мин сездән...

—Шулай мени-и-и!—дип сузды ул. Йөзе күзгә күренеп үзгәреп китте.—Ә мин тагын, пеләш бәрән... Син, зинһар, мине гафу ит. Әйдә, кереп, чәй эчик.

—Юк, юк, Ибраһим абый, чәйләп тораммы соң! Киттем, киттем...

—Юк, юк,—түгел. Бу юлы менә минем белән чәй эчәргә мин поручение бирәм. Анда бик яхшы бильярд өстәле бар. Бераз шар тәгәрәтеп алырбыз.

Икенче көнне безгә Шамил абый Бикчурин, Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җитәкчесе Әдип абый Маликов, минем ахирәт дустым Нәҗип Мадьяр кушылды. Ул кичне безгә кунакка кайттык. Мәдинәм-Гөлкәемнең әнисе Миңлесәрвәр әниебез күп итеп өчпочмак пешергәние. Кампаниясе шундый: бик күңелле итеп сөйләшеп утырдык. Ибраһим абый безгә фронтта дивизия газетасында эшләвен, сугышта күргәннәрен сөйләде. «Полуторка машинасында алгы сызыктан штабка тораташ булып каткан мәетләр түшәлгән юлдан кайтабыз. Бер урында кар көртенә чумдык. Буксовайт итә башладык. Зыр килеп бер урында әйләнеп утырган арт көпчәкләргә дә, кар астыннан гына өстерәп чыгарып, мәетләр тыгабыз».—дип сөйләде.

—Кемнәрнеңдер газизләре, бердәнберләренең гәүдәләре бит инде алар!—дидек без әсәрләнеп.

—Сугыш! Фронт! Алар турында уйлап торырга вакытың бармы?—диегез. Приказ үтәргә ашык. Үтәмәсәң—трибунал! Анда күп сөйләшеп тормыйлар. Алып чыгалар да, шалт маңгаеңа берне! Синең дә үле гәүдәңнең юл түшәргә китүе ихтимал,—дип куйды агабыз.

Аннары ул пианино артына күчеп утырды. Тукайның «Өзелгән өметен» уйнады.

И, мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасын, мин сүнәмен, аерылабыз ахырысы!

Очты дөнья читлегеннән, тарсынып күңелем кошы,
Шат яратса да җиһанга, ят яраткан Раббысы.

Булмадың алтын ярым, салкын ярым син дә минем.
Бер елмаюың берлә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә еглар вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыры тапкыр син,
Һәр ишектән серле углыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы.
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачысы һәм татлысы!

Шушы юлларны үзе пианинода уйнап әйтте дә, моңарчы бик кырыс күренгән Ибраһим агабыз, сулкылдап елап та җибәрде. Маңгаен, йөзен ике кулы белән каплап, инструмент өстенә сыгылып та төште.

—Шуңа күрә дә бөек Тукаебыз, дибез аңа. Әнә, нинди юллар язган. Татар поэзиясенең иң биек Олимпасы!

Үз тирәсенә бер ялагайны, бер куштанны якын җибәрмәгән гаять кырыс булып күренгән өлкән каләмдәшебез үтә дә йомшак күңелле булып чыкты.

—Сез, яшьләр, Тукаебызны укыйсызмы соң?—диде ул яшьләрен сөртеп.—Алдында Тукай томнарын тотмыйча, аларга атнага бер булса да күз салмыйча торып, талантлы әсәр язып булмыйдыр ул.

Аннары без тәмләп чәй эчтек. Ибраһим ага әниебезнең өчпочмакларын да мактап-мактап ашады.

Ибраһим абый безгә депутат булгач та килеп йөрде. Сайлаучылары наказ

иткән китапханә төзелеше белән дә даими кызыксынып торды. Казанга баргач, теге анонимканы да кулыма бирде.

—Саклама, яндыр,—диде.—Шуны язып утырганчы, матур бер хикәя язса, исеме әдәбиятка керер иде. Достоевский андыйларның йөзен бик белеп ачкан,—диде.

Ул дустым байтактан мәрхүм инде. Мин ана мыскал да үпкә тотмыйм. Урыны җәннәттә була күрсен. Алга табарак бик хәтәр бер әйбер әйтергә җыенам әле. Аның мәрхүм булуына мин дә сәбәпче түгел микән?

Ибраһим абый, сайлаучылары алдында отчет тотарга килгәндә, мин аны каршыларга Бөгелмә аэропортына барып баскач:

—Син, шома егетем, бу юлы да партпоручение үтәргәме, әллә мине күрәсен килеп, ихлас күнел белән килденме?—дип елмаеп, күз кысып, сорап куяр иде. Кичләрен ул җәяүле сәйранга чыгарга ярата. Шамил абый Бикчурин белән икәүләп, без аны Лениногорскиның әллә нинди почмакларыннан әйләндереп алып кайтабыз. Лениногорскида, Муса Җәлил белән бергә әсирлектә булган, аны күреп белгән Зиннур абый Мөхәммәдиев яшәде. Аны күреп сөйләшергә Гази абый Кашшаф та килгәләде. Зиннур абыйның истәлекләрен ул китабына да кертте. Зиннур абый шәһәр читендәгерәк баракның егерме квадрат метрлы гына бер бүлмәсендә биш җан булып яшәп, буровойда эшли. Әле тулысынча акланмаган. Горком кешеләре минем аның янына барып йөрүемне бер дә килештермиләр... Өстәл сукмыйча гына шелтә ясаганнары да бар. Зиннур абыйларга Ибраһим аганы да алып бардык.

—Җәлилне үз күзең белән күрдеңме? Аралаштыгызмы? Ниләр сөйләгәне хәтереңдә?—дип, бик җентекләп сораштырып утырганые.

*Ахыры киләсе санда*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



Ленар
Шәех

## СИН—МИНЕМ СЫЕНЫР КЫЯМ...

* * *

**Зәңгәр күкнең упкын-дулкынында**
**Тургай булып җаным атына.**
**Кайда, диеп мине сорамагыз—**
**Мин бәхетнең өске катында.**

**Бар йөрәгем кубарылып тибә,**
**Мәхәббәткә күңел талпына.**
**Әллә кайда, диеп уйламагыз—**
**Мин сөюнең өске катында.**

**Әллә кайда түгел, монда гына,**
**Мин хыялның уйнак атында.**
**Әйдә, бергә, сез дә соңламагыз—**
**Мин хыялның өске катында.**

**Ак болыттай ак уйларга чумып,**
**Басып торам дөнья чатында.**
**Кая китте, диеп сорамагыз—**
**Мин яшәүнең өске катында.**

### Җибәрмим

**Син генә, син генә**
**уемда.**
**Син миннән китәргә**
**җыенма.**

**Сөюдән тилергән**
**җүләр мин.**
**Беркая, беркая**
**җибәрмим!**

*Ленар ШӘЕХ – яшь шагыйрь; «Авылдан килгән мендәр» (2005) исемле китап авторы. Казанда яши.*

## Без икебез бербөтен

Алдагы юл өзелсә дә,
Хыяллар булса төтен—
Сүндермик без, сүрелдермик
Җанда яшәү өметен.

Әгәр дә иртәгә калса
Гомерем бер чеметем,
Белеп тор: син—минем җаным,
Бәхетем һәм өметем.

Без икебез бербөтен бит,
Без икебез бербөтен.
Син—минем сыеныр кыям,
Ә мин—синең бөркетең.

* * *

Ярым бушлык, ярым караңгылык,
Йөрәктәге тирән ярам кебек,
Шул ярамны учлап барам кебек,
Болай бару—соңгы чарам кебек...
Ярым бушлык, ярым караңгылык.

* * *

Корыган агачта сандугач
Төн куна. Ал таңны сагынгач,
Тилмерә, өзлегеп куя ул.
Тик таңның атмасын,
Үткәннең кайтмасын
Белә ул, сизә ул, тоя ул...

* * *

Сөюгә тулган җаным,
Сиңа кол булган җаным...
Ни кирәк сиңа тагын?..
Ни кирәк сиңа тагын?..

* * *

Сәгать саный...
Санасын ла...
...Беләм шәмнең
Соң мизгелдә
Мең талпынып
Янасын да...

## Еллар үтәр...

Еллар үтәр. Бәлкем, шунда гына
Барын аңларсың син—соң булыр,
Күзләремдә сүнгән моң булыр.

Еллар үтәр. Шашып давыллаган
Күңел дөньям инде тын булыр,
Тынуым да инде чын булыр.

Еллар үтәр. Хыялымда һаман
Синең күләгәле сын булыр,
Күккә карарсың син—соң булыр.



Радик
Фәизов

# КАРАК

ХИКӘЯ

Әйе, карак. Бәс алай икән, исемен аның әйтмибез. Әлегә шул Карак булып торсын. Ә болай, бүтән кешеләрдән әлләни аерылмый да ул. Утыз яшьләрендәге, уртачадан калкуырак буйлы, төз гәүдәле бер ир-егет. Киенүе дә кешечә. Галстугы да бар. Кара мыек җибәргән, болай күрер күзгә күркәм генә. Әгәренки урамда каршыңа очраса, бер дә шиккә калдыра торган адәм түгел.

Көзге көннәрнең берсендә Карак урам чатындагы күпкатлы йорт янына килде—җай гына атлап, эшлекле кыяфәт белән. Ул домоушник, йәгъни фатирлар басып йөрүче угры буларак, дөрестән дә эшкә килде. Иртәнге уннар. Күпчелек халык эштә, угрылар өчен иң уңайлы вакыт. Күнеленнән генә бер көй сызгырынып, баскычтан өченче катка күтәрелде, сул як ишек янына килде. Колагына «пышылдаучы» бирәү нәкъ менә шушы квартирада зур хәзинә булырга тиеш диде.

Тукталып, сагаеп калды, тыңлап торды Карак. Тиешенчә тынлык, тәртип булса да бераз шиктә, икеләнүдә торды. Чөнки янына килеп баскан ишек бик гади иде. Сары дермантин белән генә тышланган, бер катлы агач, хәтта эчтән күзәтү уемы да куелмаган, фәкыйрь ишек. Мондый ишек артында нинди генә хәзинә бар икән инде ул? Тик, аның тәҗрибәле бурлардан ишеткәне бар, алтынны чүп астына каплап куючылар да юк түгел. Юри ярлы-ябагайга сабышып... Карак шундый уйлар белән кесәсеннән хәйләле ачкычларын чыгарды, ишеккә орынды. Шунда тагын да гаҗәп хәл булды. Ишек акрын гына ачылып китте, ул бикле түгел иде! Хәзер инде безнең Карак тәмам аптырашта калды. Эш түгел инде—ниндидер ботка бу. Әллә югыйсә «пышылдаучы» теге—мәкерлеге йөзенә чыккан хатын, аны тозакка төшерергә уйлаганмы? Җинаятьче братларның тормышында төрле низаглар булып тора, кануннары бик кырыс.

Тик Карак кыю йөрәкле, уйлаган эшне ярты юлда калдырырга яратмый торган, тәвәккәл адәм иде. Җитмәсә, бик кызыклы хәл дә бит әле бу... Һәм ул ишекне акрын гына, бик шыпырт ачты да коридорга үтте. Залның да ишеге ярым ачык икән. Һәр мәлдә кире борылып таярга әзер булып, шунда

Радик ФӘИЗОВ (1931)—*прозаик һәм публицист; «Бәхет», «Дусларым», «Галәм кызы» һ. б. китаплар авторы. Арчада яши.*

күз салды. Ул инде чамалап алган иде, монда бернинди тозак юк, йә хуҗалар өлкән—хәтерләре «тишек чиләк», йә булмаса бик ашыгычлык белән, ни сәбәптәндер ишекләрен ачык калдырып чыкканнар. Дөнья булгач мондый мәзәк хәлләрнең дә булуы бик мөмкин.

Һәм ул залны күзли башлады.

Әһә, апаем, тукта әле, маллар бар монда! Әнә, түр тәрәзәгә затлы, зәвыклы пәрдәләр эленгән, стеналарда шактый кыйммәтле картиналар. Почмактагы тумбочкада япон телевизоры кукыраеп утыра. Сул як стена буенда искиткеч матур, көзгеле стенка. Аның киштәләрендә ниләр бардыр тагын... Шуларны уйлап ары таба үтмәкче генә иде, ун яктагы йокы бүлмәсенең ярым ачык ишегеннән галәмәт калын, карлыккан ирләр тавышы ишетелде:

—Кем бар анда? Кайсыгыз йөри?

Тәне буйлап, әйтерсең, ток йөгерде, колаклары шау итте Каракның. Әмма ул үзен тыеп калды—паникага төшмәде, алдын-артын карамый йөгерә дә башламады, аяк очларына гына басып чигенде, ишекне дә профессионалларча итеп, шыпырт кына япты. Бер дә ашыкмыйча гына, күңелле көй сызгырып, баскычтан түбән атлады. Кукиш вә мукиш, барып чыкмады бүген аның эше. Өйдә «карт кәҗә» бар икән. Ә аның белән «сөйләшү» Каракның планында каралмаган.

Баскычтан төшсә, анда бер әби басып тора. Култыксага сөялгән, хәл җыя, күрәсең. Карак тәҗрибәле карашын сирпеп алды. Табак битле, бик олпат гәүдәле баһадир әби бу. Өстендә инде модадан әллә кайчан төшеп калган хәтфә тышлы җакет, башындагы биниһая киң береты астыннан ак чәчләре күренеп тора. Җыерчыклар эчендәге зур күзләреннән карашы гамьле, таләпчән, горур. Менә мондый карчыклар куркуның ни икәнен белми торган, җиңенне өзәрлек нык холыклы булалар. Чүмәлә тиклем бу әбекәйнең янәшәсендә галәмәт зур ике сумка, аларда кәбестә, кишер, помидор, тагын әллә ниләр—бөтен бер склад. Ипле төягән бу әби.

Карак шома гына үтеп китмәкче иде дә, булмады. Әби аның каршысына басты.

—Улым, лифт эшләми. Мине үз квартирама гына мендереп куй. Йөгем бик авыр,—диде.

—Вакытым тар шул, әбекәй,—диде Карак.

—Бирермен мин сезгә вакыт тарны! Хәзерге яшьләр... Көпә-көндез трай тибеп йөрергә вакытлары бар, ә өлкән кешегә ярдәмгә дигәндә—юк. Ал кулыңа хәзер үк бер сумканы!—диде әби хәтәр төстә һәм шул ук вакытта күңелле дә итеп.

Каракның вакыты, чыннан да, дингез иде. Ул авыр сумкаларның берсен генә түгел, икесен дә кулына алды. Әби адымнары белән югары мендeләр һәм... өченче катта, нәкъ теге ишек кырына килеп тукталдылар. Ә ишек аз гына ачык та калган икән.

—Менә күрдеңме, улым. Ишекне дә бикләмичә чыгып киткәнмен бит мин. Хәтерләр китек шул хәзер, улым, хәтер капчыклары шыр тишек. Менә күр инде син бу карт чүмәләне!—диде әби күңелле итеп.

Ә Каракның күңелендә вак җеннәр йөгерешә. Ул сумкаларын куюга борылып чыгып китмәкче иде дә тагын булмады.

—Беркая да китмисең. Хәзер чәй куеп эчәбез. Камилә әбиеңнең фатирына кергән кешене чәй дә эчермичә чыгарып җибәргәне юк әле,—диде әби бәхәскә урын калдырмаслык итеп.—Өстеңне, туфлиеңне сал да, әнә түргә уз. Диванга утыр, телевизорны җибәр,—диде.

Һәм, гаҗәп хәл, Карак әбинең сүзләренә карышмыйча буйсынды. Анда хәзер угрылык дәрте сүнгән. Ул инде әбиләр белән өстәл янына утырып, кайчан чәй эчкәнен дә оныткан иде. Ике бүлмәле җыйнак фатир әйбәт

бизәлгән, чисталык-пөхтәлек. Тик монда барысы да гадәти, гади. Телевизоры да инде шактый иске, стенканың киштәләрендә дә бәллүр бокаллар, кыйммәтле савыт-саба түгел, ә барысында да диярлек китаплар икән. Калын-калын китаплар. Бу әбекәй зур гыйлем иясе, зыялы, күрәсең.

Ул арада әби кунакны кухняга чакырды. Өстәл тулы төрле кайнатмалар, тәмле ризыклар иде. Мондый сый-хөрмәтне инде күптән күрмәгән Карак бик кыстатып та тормады. Әбекәй үзе дә өстәл янында такылдап вакыт үткәрүне яратучылардан түгел икән. Сүзсез генә иркенләп чәй эчтеләр. Соныннан Камилә әби бәрәкәтле кулларын күкрәгенә кушырды, күзләрен каядыр еракка текәде.

—И, улым, агып китте гомерләр. Сиксәнне үтеп чыктым инде, тугызынчы дистәнең уртасына басып киләм,—дип сөйләде ул җай гына. Күрәсең, бераз эчен бушатасы килә иде.—Менә гомерем буена укыттым мин.—Техник университет студентларына математика гыйлеме бирдем. У-у, мин укытып чыгарган егетләр-кызлар! Аларның күбесе үзләре зур кешеләр инде, дәрәҗәле түрәләр. Цех начальниклары, завод директорлары, мин сиңа әйтим! Үз улларым-кызым да шулар арасында. Менә хәзер өйдә ялгызым кукыраеп утырам инде. Картымның вафатына да унике ел. Йа, Аллам, үтә дә китә икән гомерләр...—диде карчык моңаеп кына һәм тынып калды. Каракның күңелендә бу асыл карчыкны җәлләү хисләре кузгалып куйды.

—Ә ул улларның... ярдәмнәре тияме соң, Камилә әби?—дип сорады ул.

—Бик ярдәмле, һәркайсы үзенә чакыра. Тик мин бармыйм. Менә күрәсең, үз-үземне йөртәм бит әле. Үз көчеңдә булганда кеше бүтәннәргә салынырга тиеш түгел ул, улым! Бу фатирыма да гаҗәпләнмә. Бүлгәннән калганы гына бу. Зурысын оныгыма бирдем,—диде әби.

Беразга сүзсез калдылар. Яратып эчелгән чәйдән, тәмле ризыклардан Каракның бөтен гәүдәсенә талгын рәхәтлек йөгергән, аның торып китәсе дә килми, менә шушылай җылыда утырасы гына килә иде.

—Ә үзең нинди кеше соң син, улым? Гаиләң бармы? Кайда торасың? Мондый сәгатьләрдә ник җил куып йөрисең?—дип сорады әби.

Мондый сорауны көтә иде инде Карак. Кай ягы беләндер, каты, туры итеп сөйләшүе беләнме, бу әби аның инде күптән вафат булган үз әнисен хәтерләтте. Хәтта күңеле йомшап китте. Тик нәрсә әйтергә соң Камилә әбигә? Үзенең бер эчкече, фахишә хатын белән көн итеп ятканын, күптән инде фатирлар басып йөрүче бер угры, өтек икәнен сөйләп бирергәме? Ә нәрсә, курка торган карчык түгел бу—аңлый торган.

Һәм... Карак чак кына ачылып китмәде. Үз-үзен вакытында тотып кала алды:

—Эшсез калганнардан мин, әби, шуңа аптырап йөрү. Минем ишеләр күп бит хәзер,—дип кенә чикләнде.

Шунда йокы бүлмәсеннән баягыдан да калын, хәтәр тавыш ишетелде:

—Кем бар анда? Кайсысы йөри?

Дерт итеп китте Карак. Йөрәге кубып, урыныннан ук сикереп торды. Ялт итеп, курку белән, ачу катыш әбигә карап алды. Әллә аңа тозак корып утырамы бу карт чүмәлә?!

Ә әби исә көлеп җибәрде.

—Утыр әле, ашыкма!—диде ул тагын әмер биргәндәй.—Куркырлык берни дә юк. Минем карт тутый кошым ул. Ул шулай тавышланырга ярата. Тагын чәй ясыйм, алай эшсез булгач, тамагың бик тук түгелдер. Йә, Алла, бу дөньялар...

Карак утырды, кулларының калтыравын басарга тырышып, чәйгә үрелде. Хәзер кубарылып чыгып китү ахмаклык булыр, әбигә дә шик салыр иде. Ә аның телефоны әнә генә... Син чыгып та китәрсең, әби милициягә хәбәрен

дә салыр. Бер квартал юл үтмәссең, эләктереп тә алырлар. Алар да эшли белә хәзер... Ул чәй эчкән арада әби кулларын күкрәгенә кушырган көе, уйчан карашлы дәү күзләрен аңа текәп утырды. Нидер сизенде мәллә, карт богыл?!

Юктыр ахыры. Бераздан ул күзләрдә шәфкать чаткылары кабынды.

—Менә нәрсә, улым. Исемең ничек әле синең?—дип башлады әби.

—Хәмит,—диде Карак теленә беренче килгән исемне әйтеп.

—Менә нәрсә, Хәмит. Ә бит мин сине эшкә урнаштыра алам. Камилә әбиең укытып чыгарганнар кодрәтле кешеләр дип әйттем бит мин сиңа. Минем ул кодрәтлеләр белән телефоннан сөйләшеп алуым да җитә. Әйбәт кенә урынга урнашырсың, әгәренки теләгең булса...—диде әби һәм аңа тагын текәлеп, сынаулы итеп карап алды.

Менә мондый сүзне, мондый тәкъдимне һич тә көтмәгән иде Карак! Тирә-юньдәге адәмнәрдән, хәтта үзеннән дә күптән өметне өзгән һәм тирәяктагылардан бары тик шикләнү, нәфрәт, дошманлык кына көтә ала иде ул. Ә менә бу, моңарчы таныш та булмаган бер әби, аңа кайгырту, аның өчен борчылу күрсәтә. Аның сүзен тыңлап карасаң да ярый.

—Менә күрәсең, Хәмит, мин япа-ялгызым. Анысына түзәм дә инде аның, күнегелгән. Тик кичләрен тынычлыгым юк хәзер. Өске каттагы ир белән хатын эшмәкәрлеккә бирелеп киттеләр. Көндезләрен тын. Ә менә кичләрен кайталар да, шау да гөр. Дуслары килә, мәҗлес корып күңел ачалар, җырлыйлар, сикерә-сикерә бииләр. Барысы да минем баш өстемдә,—дип сөйләнде Камилә әби.

Тик Карак аны тыңламый иде инде. Ул шабыр тиргә батып утыра, үзенүзе эт итеп тирги. Бу әби хәтерсез, ә ул аннан да хәтерсез бүкән икән бит әле! Аңа бит әлеге фатирның адресын бирүче нәкъ менә дүртенче катны, шул эшмәкәрләрне күрсәткән иде. Аларда аерым йорт, коттедж салырга дигән мая башы булу ихтималын әйткән иде. Ә ул аңгыра баш, сарык, катларны бутаган. Ачыгавыз белән ачык ишеккә барып кергән. Шушы—инде акылыннан язып килгән әби кочагына! Китаплар, тутый кошлар арасына... Каракның башыннан Камилә әби сүзләре дә, аның кайгыртуы тудырган уйлары да шул мәлдә үк очып чыктылар. Җилелчә төтендәй генә таралып беттеләр. Аның күңелендә хәзер үртәлү генә калды, ачу кабарып чыкты.

—Рәхмәт, әбекәй, яхшы сүзеңә!—диде ул. Әмма рәхмәт хисе белән түгел, ә киная, зәһәр белән әйтте. Һәм урыныннан торып ишеккә атлады.

—Берәр ни уйлап чыгарсаң, кил тагын! Минем сүзне истә тотсаң,—дип кычкырып калды аның артыннан Камилә әби.

—Киләм әле мин, килмичә калмам!—дип кычкырды җавапка Карак та. Әлбәттә инде, үз максатын тотып. Хәзер инде ул уйчан адәм түгел, ә элеккеге угры иде. Сакчыл, игътибарлы, акыллы угры.

Алай да бер нәрсәне белми калды ул. Гомере буе кешеләр белән эш иткән, күпне күргән әйбәт психолог Камилә әби аны «тешләп», нинди адәм, нинди кош икәнен бик әйбәт абайлап өлгергән. Ул хәзер үк тиешле урынга хәбәр итсә, мондый хәбәрдән тиз генә җыенып, милиция егетләренең угрыны эләктереп тә алулары бик ихтимал иде. Тик тәҗрибәле педагог алай эшләмәде. Сабыр итәргә булды.

Ә тегенең күрәселәре бүген болар белән генә дә чикләнмәгән икән әле. Ул урамга чыгуга, һич көтмәгәндә, арттан яман итеп милиция машинасы улап җибәрде. Болай да үртәлгән, куркынган адәмнең коты алынды, дәррәү йөгереп каядыр качып китүдән үзен көчкә тыеп калды. Курка-курка гына артына борылып караса, анда ике милиционер колгадай озын буйлы бер егетне куа киләләр! Егет йортлар арасындагы нәни генә бакчаның тәбәнәк рәшәткәсе аша сикерде. Тик, озын аяклары да коткара алмады шул бахырны. Милиционерлар, каршысына төшеп, аны бакча уртасында эләктереп алдылар.

Җиргә егып, кулына богау салдылар. Якында гына көтеп торган машиналарына таба этә-төртә алып киттеләр.

Тетрәнеп күзәтте бу хәлләрне Карак. Әле генә теге егет тозакка төшкән бакчага кереп бер эскәмиягә утырды. Аякларының хәле киткән иде. Утырды да уйларга бирелде. Бик күңелсез уйларга. Кем булсын инде ошбу егет. Асылда аның үзе кебек бер бәхетсез, замана корбаны инде. Менә килеп әлекте, кулларына богау салынды. Күп тә үтмәс, тар читлеккә дә кереп утырыр... Әләгә, ул үзе дә килеп әләгә әле бервакыт. Ни хәтле сак булмасын, үзен остага санамасын, килеп әләкмәгәннәр бик сирәк... Бар, аңа дигән богавы да, читлеге дә бар. Ул моны белә, күңелендә йөртә. Куркуда яши ул. Үзалдына никадәр кәпрәймәсен, барыбер һәрдаим куркуда яши!

Каракның күкрәк түреннән, бик тирәннән ачы, хәсрәтле сулышы уфылдап чыкты. Аның да бу дөньяда берничдән курыкмыйча, иңбашларын җыермыйча, иркенләп яшәгән вакытлары бар иде бит! Яраткан эше, гаиләсе, җылы кочаклы хатыны, матур кызы бар иде... Моннан унике ел элек ул эшләгән заводны яптылар. Ул—югары разрядлы слесарь, эшсез калды. Шуннан очты бәхет кошы. Егет алтын кулларына эш таба алмады. Һәм бу куллар тора-бара, тәмам гаҗиз калудан, өметсезлектән шешәгә үрелделәр. Аннан инде нәүбәт гаилә таркалуга барып җитте. Аннан... үзе кебекләргә ияреп беренче кәсепкә чыгу, ул төркемнән аерылу, ялгыз кәсепчегә әйләнү...

Ул эскәмиядә утырды да утырды. Җир өстенә кичке караңгылык инде. Иңбашларда кичке салкынлык, ә күңелдә өметсезлек, караңгылык, караңгылык иде. Һәм кинәт аны сискәндереп, бөтен гәүдәсен кайнарлап, күңеленә бер яктылык нуры үтеп керде. Өмете, ышанычы әйләнеп кайтты. Күз алдына Камилә әби килеп басты. Җыерчыклар сарган түгәрәк йөзеннән, зур күзләреннән таләпчәнлек, ниндидер эчке шәфкатьлелек сирпелгән, укымышлы Камилә әби.

* * *

Берникадәр вакыт үтте. Көзнең сирәк очрый торган якты, матур бер иртәсендә Камилә әбиләр йорты подъездына Карак килеп керде. Баскычтан акрын гына югары күтәрелә башлады. Тик бу кеше инде карак түгел иде.

**Редакциядән:**

*Бу көннәрдә Радик ага Фәизовка 75 яшь тулды. Журналыбызның актив авторын олы юбилее белән котлыйбыз, аңа саулык-сәламәтлек һәм яңадан-яңа иҗади уңышлар теләп калабыз.*

Солтан
Шәмси



# АДӘМНЕ КЕМ КОТКАРЫР?

ТАРИХИ–ЭЗОТЕРИК БӘЯН

*«... Мифы являют собой картинные формы,
под которыми глубокие истины давались миру».*
Анни Безант

## Мифлар һәм тарих

Кешелек дөньясы хәтеренә уелып калган берәр җәмгыятьнең тарихын, үсеш юлын өйрәнергә тотынсаң, гадәттә, аның белән танышуны шушы кавемнән калган мифлар, риваятьләрдән башларга туры килә. Чыннан да, безгә мәгълүм «язма тарих» вакыйгаларны теркәп барырга керешкәнче, адәми зат үзе яшәгән дөнья турындагы мәгълүматларны, аны танып белүен киләчәк буыннарга нигездә мифлар, риваятьләр, әкиятләр рәвешендә тапшыра килгән. Буыннар бәйләнеше, җәмгыять туплаган белемнәрне саклау, аның этник-психологик бөтенлеген тәэмин итү шулай алып барылган. Һәр җәмгыятькә хас мәдәният, менталитет шулай барлыкка килгән.

Урта гасырлар караңгылыгыннан чыкканнан соң белемне, акылга таянып эш итүне, һаман үсә-ныгый барган фәнни фикерләүне үзенең төп таянычы итеп сайлаган кешелек дөньясы әле байтак заманнар мифларга, риваятьләргә адәми затның балалык чорында туган матур уйдырмалар, әһәмияткә лаек булмаган хыял җимеше дип карап килә. Шуңа да карамастан, фәннең төрле тармакларында эшләүче галимнәр, табынган фәнни принципларына тугры калып, дөнья халыкларының мифологик мирасын туплау белән шөгыльләнә. Бу мирас төрлечә классификацияләнә, анализлана, аның үзгәлекләре һәм уртак яклары билгеләнә. Шунысы кызык—торабара тупланган шушы мирасның һич көтелмәгән башка яклары да күренә башлый. Дөньяның әле бер, әле икенче тарафында эшләгән галимнәр мифларда-риваятьләрдә телгә алынган мәгълүматларның, коры хыял җимеше генә булып калмыйча, борынгы дәверләрдәге реаль вакыйгаларны чагылдыруын, аларның тарихи нигезе булуын күрә башлыйлар. Шулай атаклы немец археологы Генрих Шлиман тарафыннан борынгы грек шагыйре Гомерның «Илиада»сында сурәтләнгән Троя каласы табыла һәм җир астыннан казып чыгарыла. Ә бит моңа хәтле дөнья Троя каласын әдәби иҗат җимеше дип кенә кабул иткән була.

Мәшһүр Шумер цивилизациясенең беренче каласын эзләп табу да шулайрак килеп чыга. 1877 елда Гыйрактагы Басра шәһәренә Франциянең вице-консулы Эрнест де Серзек килеп төшә. Ул үзенең дипломат вазыйфаларын башкару белән генә чикләнмичә, илнең борынгы тарихы белән дә кызыксына башлый. Төрле

Солтан ШӘМСИ (1946) – *язучы; «Җаяүле буран», «Еллар эзе», «Низаглы йортта» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

якларга сәяхәтләр кыла һәм берничә елдан соң Тигр белән Евфрат елгалары арасында урнашкан бер җирдә борынгы кала калдыкларына килеп юлыга. Бу—шумерларның борынгы каласы Лагаш шәһәре була. Археологик казу эшләре барышында биредә Шумер патшаларының системага салынган, 20 меңнән артык балчык таблицалардан торган чөй язулы зур архивы табыла. Аларны уку борынгы Шумер дәүләтенең тарихын, яшәешенең бик күп якларын ачып сала. Ә бит бу шәһәр һәм архив табылганга кадәр галимнәр Шумер дәүләте турында сакланып калган төрле имеш-мимешләргә генә таянып фикер йөрткән булалар. Ә кайберләре гомумән Шумер цивилизациясенең яшәгәнлеген шик астына куялар. Шулай итеп шумерология дигән фәнгә ныклы нигез салына.

Инде борынгы грек мифологиясенә мөрәҗәгать итеп, бер сюжетны искә төшереп үтик. Кайчандыр борын-борын заманда Крит утравында Минос исемле патша хөкем сөргән. Кансыз һәм тәкәббер булган өчен аллалар аны җәзаларга булалар. Минос патшаның хатыны Пасифаяның уйнаш итәргә хирыслыгын белгәнгә, диңгез алласы Посейдон аның янына бик матур ап-ак үгез җибәрә һәм шушы мәхәббәттән Минотавр исемле адәм тәнле, үгез башлы, кеше ите белән туена торган бер бала туа. (Төрки телдә: Минотавр—Мин(ос) патша тауары-малы дигәнне анлата. Бу исә борынгы заманнарда Крит утравында төрки цивилизация вәкилләре яшәвенә ишарә булып тора.)

Бала үсеп җиткәч, атасы төзеткән Лабиринт дип аталган зур сарайда яши башлый. Лабиринтның коридорлары, бүлмәләре шундый катлаулы һәм серле-буталчык итеп төзелгән була ки, анда кергән кеше, чыгу юлын таба алмыйча, Минотавр корбанына әверелә. Минос патшага буйсынган күрше халыклар тугыз елга бер Минотавр өчен корбан итеп җиде егет белән җиде кыз бирергә тиеш булалар һ.б.

Әгәр дә 1900 елда Крит утравына бер эш белән Оксфорд музее (Англия) хезмәткәре, кырык яшьлек Артур Джон Эванс килмәгән булса, бәлки бу миф шулай шомлы бер миф булып яшәвен дәвам да иттергән булыр иде. Әмма тормышта «очраклылык» дигән серле нәрсә бар, шул кайвакытта вакыйгаларны бөтенләй үзгә якка борып җибәрә. Һәм шушы очраклылык аркасында Артур Эванс борынгы заманнарда яшәгән иң гүзәл цивилизацияләрнең берсе—Крит-Миной цивилизациясен ачуга ирешә. Шушы цивилизацияне өйрәнә-өйрәнә галим Критта кырык ел гомерен уздыра.

Бервакыт журналистлар аңа: «Ничек итеп сез казу эшләре башлауның беренче көннәрендә үк: «Мин Минотавр яшәгән сарайны таптым»,—дип әйтергә батырчылык иттегез. Ул вакытта сезнең карамакта моны исбатларлык бернинди дәлил дә булмагандыр бит?»—дигән сорау бирәләр.

Артур Эванс моңа каршы: «Мин тарихның Ариадна җебен тәшкил иткән мифларга ышандым»,—дип җавап бирә.

Чыннан да, мифта Минос патша кызы Ариадна сөйгән егете Тесейга, ул Лабиринт сараена Минотаврны үтерергә керер алдыннан, бер йомгак җеп бирә. Тесей сарай эчендә шушы йомгакны сүтеп йөри һәм, җеп буенча барып, адашмыйча аннан исән-сау килеш кире чыга.

Шулай итеп, сэр Артур Эванс өчен миф ярдәмче Ариадна җебенә әверелә.

Мондый очракларны тагын да искә төшерергә мөмкин булыр иде. Тик җитеп торыр, төп сүзгә күчәргә вакыт.

Ә сүзебез бер хикмәтле миф турында барачак. Кайбер диннәрнең төп чыганакларында, шулай ук борынгы цивилизацияләрдән сакланып калган кайбер язмаларда еш кына Җир тарихында булып узган ниндидер мөһим вакыйгалардан соң кешелек дөньясының эволюциясе бөтенләй башка юнәлештән китүе турында кинаяләр очрый. Вакыт ягыннан безгә якынрак торган Библия белән Коръәндә бу вакыйга Адәм белән Хәуваның яратылмышы һәм «юлдан язуы» (русчасы—«грехопадение») турындагы мифта тасвирлана. Классик диннәрнең төп Китапларында урын алган икән, димәк, бу миф, чыннан да, ниндидер мөһим вакыйгаларны чагылдыра торгандыр дип уйларга нигез бар. Мифта адәми зат нәселен башлап җибәрүче Адәм белән Хәуваның өстенә «гөнаһ кылу», «юлдан язу» булып төшкән нинди дөньякүләм вакыйга турында сүз бара соң? Бу тәрбия чарасы мисалында уйлап чыгарылган мифмы, әллә инде аның нигезендә ерак тарихта булып узган ниндидер вакыйгалар ятамы?

## Адәмнең яралтылуы

Библия белән Коръәндәге бу миф бер үк вакыйганы—Адәм белән Хәуванын яралтылу тарихын бәян итсәләр дә, алар арасында кайбер үзгәлекләр дә бар һәм алар күп нәрсә турында сөйли.

Библиядә адәми затнын яралтылуы түбәндәге сүзләр белән тасвирлана:

«И сказал Бог: сотворим человека по образу Нашему, по подобию Нашему; *(Бытие, 1: 26)*

«И сотворил Бог человека по образу Своему, по образу Божию сотворил его; мужчину и женщину сотворил их». *(Бытие, 1: 27)*

«И создал Господь Бог человека из праха земного, и вдунул в лице его дыхание жизни, и стал человек душею живою». *(Бытие, 2: 7)*

Коръәндә дә Аллаһ жир йөзендә тереклек иткән жан ияләрен бар кылганнан һәм жиде кат Күкләрне төзегәннән соң адәми затны яралтырга керешә.

Ул фәрештәләренә:

«Мин жир йөзендә (Адәмне) хәлифә итеп билгеләячәкмен»,—дип белдерә.

Фәрештәләр Ана:

«Без Сине мактап, Сине зурлап, Аллаһ кимчелекләрдән азат, дип торганда, жир йөзендә азгынлык кылачак һәм кан коячак бәндәнне хәлифә итеп куясынмы?»—диләр.

Аллаһ аларга:

«Мин сез белмәгәнне беләмен»,—дип жавап бирә. *(Коръән, 2 : 30)*

Тик сорау туа: «Без Син өйрәткәнне генә беләбез ...»,—дип торган фәрештәләр Адәмнең нинди зат буласын кайдан белгән? Ни сәбәпле анын турында алдан шундый фикер чыгарып куялар? Бу сорауга Коръән жавап бирми.

Инде «хәлифә» сүзенә игътибар итик. Бу очракта әлеге сүз Жирдә Раббыбызны алмаштыручы, Анын урынына калучы, Анын эшен алып баручы зат мәгънәсендә кулланыла. Бу Библиядә китерелгән «по образу Своему, по образу Божию» дигән мәгънәгә бик якын кебек. Шулай да «по образу Своему, по образу Божию» дигән гыйбарәне ничек анларга? Библия белән Коръән адәми затка хас шушы үзенчәлекне безгә житкереп ни анлатмакчы булалар? Нинди серле һәм илаһи сыйфатларга ишарәлиләр?

Адәми затнын илаһилыгы анын тән төзелешендә дә ап-ачык күренә. Безнен көннәрдә кешенен умыртка баганасы буйлап астан өскә таба жиде төп чакра урнашкан булуын белмәгән кеше инде бик сирәктер. Чакралар—кеше тәнендәге энергетик үзәкләрне тәшкил итә, алар чыгыр сыман гел әйләнеп тора. («Чакра» сүзе үзе үк «чыгыр» сүзеннән килеп чыккан—энергия чыгыры. Бу сүз, йога системасындагы башка бик күп терминнар кебек, безгә борынгы цивилизацияләрдә яшәгән бабаларыбыздан калган мирас булып тора. Санскрит теленә жайлаштырылып, алар бары тик бераз үзгәреш кенә кичергән. *(Бу хакта кара: Дефак Рахмати. Дети Атлантиды. К.,ТКИ, 1999).* Чакралар системасы кеше тәнендә барган энергия алмашу процессын көйләп тора, шулай адәми зат белән Раббыбыз арасында даими бәйләнеш, энергия алмашу тәэмин ителә.

Чакраларга сыйфатнамә бирә башлаганчы шуны искәртеп үтәсе килә. Кеше тәнендәге чакралар—анын рухи үсеш дәрәжәсен күрсәтүче баскыч басмаларын хәтерләтә. Нинди чакранын активрак эшләвенә карап, кешенен нинди үсеш баскычында торуын билгеләргә мөмкин. Бу хәл анын холкын-фигылен, дөньяга карашын билгели, яшәү рәвешенә зур йогынты ясый гына түгел, гомумән рухи-эмоциональ портретын күрсәтә.

Беренче чакра—атамасы «Муладхара», койрык урынында урнашкан. Бу чакранын сыйфатын билгеләүче төп сүзләр—дөньяда яшәвенне тәэмин итү, тырыш хезмәт аркасында тормышта тиешле минимумга ирешү. Бу баскычта торган кеше авыр хезмәт нәтижәсендә тотрыклы тормышка ирешә, шул сәбәпле анын тормышы тышкы дөнья йогынтысыннан азат була, ул үзен иминлек белән тәэмин итә. Андый кешедә: «Тормышта барысына да авыр хезмәт, зур тырышлык нәтижәсендә генә ирешеп була», дигән караш формалаша. Ул анын төп тормыш девизына әверелә.

Икенче чакра—атамасы «Свадхистана», киндектән түбәнрәк урнашкан. Анын

сыйфатын билгеләүче төп сүзләр—чәчәк ату, тормыштан ләззәт алу, бар нәрсәдән файдалану, максимумга ирешү. Үсешнең бу баскычында торган кеше тормыш биргән мөмкинлекләрдән күбрәк файдаланып, үзенең потенциалын ачарга омтыла, комфорт һәм матурлык мохитында яшәргә тырыша. Әлбәттә, андый кеше башкалар өчен шактый кызыклы шәхескә әверелә. Дөрес, бу омтылышларның кире ягы рәвешендә андый кешедә еш кына вакытны бушка уздыру, ялкаулык, секс, байлык, гел ләззәт алу белән артык мавыгу кебек сыйфатлар да калкып чыгарга мөмкин. Һәрхәлдә кешенең актив тормыш белән яшәве аңа зур тормыш тәҗрибәсе тупларга ярдәм итә, шул нигездә аның дөньяга карашлары формалаша. Андый кешенең карашлары нигездә «яшәп кал!» дигән тормыш фәлсәфәсенә кайтып кала.

Өченче чакра—атамасы «Манипура», кендектән югарырак урнашкан. Аны билгеләүче төп сүзләр—көч-куәт, идарә итү, ихтыяр көче һәм тәртип. Бу баскычтагы кешенең омтылышлары абруй казану, оештыру сәләте, максатчан тормыш алып бару, кирәк чакта кискен рәвештә «юк» дип әйтә белү, күнел дигән нәрсәгә таянып гамәл кылу, интуициянең көчле булуы белән билгеләнә. Әмма андый кешедә башкаларга басым ясау, аларны манипуляция объектына әйләндерү, хакимияткә омтылу, кырыслык, минминлек, рәхимсезлек, карьеризм чире белән авыру кебек сыйфатлар да күзәтелергә мөмкин.

Дүртенче чакра—атамасы «Анахата», күкрәктә урнашкан. Аны билгеләүче төп сүзләр—кешеләрне ярату, изгелек кылу, кешегә ярдәм итүдән тәм табу, үзенә авырлык китереп булса да, башкаларга ярдәм итү. Үсешнең бу баскычында торган кеше хәтта кеше сорамаган очракта да ярдәмне үзе тәкъдим итәргә мөмкин, чөнки башкалар өчен яшәү аның эчке ихтыяҗына әверелә. Бу—кешенең дөньядагы барлык җан ияләрен, һәртөрле тереклекне яратырга, аңларга-тоярга, аларга хөрмәт белән карарга, рәхимле булырга өйрәнә торган этабы. Бу чакраның йөрәк белән турыдан-туры бәйле булуы юкка гына түгелдер.

Бишенче чакра—атамасы «Вишудха», тамак тирәсендә урнашкан. Аның мәгънәсен ача торган төп төшенчәләр—иҗат, аралашу, хезмәт итү. Рухи үсешнең бу баскычында кеше үзе өчен бердәнбер дип санаган хезмәт итү өлкәсе таба, яңа нәрсәләр иҗат итеп, аларны дөньяга бүләк итәргә тотына. Әдәбият-сәнгать әсәрләре, фәнни ачышлар, тормыш-көнкүрештә куллану өчен уйлап чыгарылган төрле җайланмалар, механизмнар һ.б. Бу этапта кеше нәрсәгә тотынса да, аңа яңалык кертә, үзгәртә, яхшырта—һәр эшкә иҗади яктан килә, чын мәгънәсендә иҗатчыга әверелә. Шулай кеше Җиһанда үз мөстәкыйль язмышы белән яши торган нәрсәләр барлыкка китерә. Бер үк вакытта ул үзенең Раббыбыз энергияләрен җир йөзенә таратучы үткәргеч ролен уйнавын да тоя башлый. Әмма бу баскычта кешене кайбер хәтәр упкыннар да сагалап торырга мөмкин: үз ролеңне күпертү, бер өлкә белән артык мавыгып китеп, башка нәрсәләргә тиешле хөрмәт күрсәтмәү һ.б. Вишудха этабын кичерүче кешенең зур бәхете—аның иҗаты, үзе сайлаган өлкәдә тугрылык белән хезмәт итү. Бу сыйфат барлык иҗат кешеләренә хас булса да, бу әле һәр иҗат кешесе шушы баскычта тора дигән сүз түгел.

Алтынчы чакра—атамасы «Аджна», ике каш арасында, алардан бераз өстәрәк урнашкан. Аның мәгънәсен ачып сала торган төшенчәләр—гармонияле мөнәсәбәтләр булдыру, уртак эшчәнлек. Бу чакра кешенең «өченче күз»ен активлаштыра, күзгә күренмәгән Нәфис Дөньяларга үтеп керергә ярдәм итә. «Өченче күзе» ачылган кеше күрәзәчегә әверелә. Рухи үсеше Аджна баскычында булган зат бик аралашучан һәм ачык була. Әлеге этаптагы кеше төрле диннәрнең уртак нигезләрен күрә, фикри һәм идеологик чикләнгәнлекләрдән арына, бар нәрсәгә югарырак ноктадан карау дәрәҗәсенә күтәрелә; фәнне, динне һәм эзотериканы үзара тоташтырган, шулай ук сәнгать белән фәнне берләштергән уртаклыкларны тоя башлый. Аджна этабындагы кеше беренче карашка гаять чуар тоелган дөньяның нигезендә яткан уртак принципларны, закончалыкларны күрү баскычына күтәрелә. Табигый, мондый кеше инде тар белгечлеккә хөрмәт белән карый алмый, үзе бик күп өлкәләрдә эш күрсәтә, шул сәбәпле эшчәнлеге таркаурак төс ала. Әмма аның бәхете—чуар дөньяның нигезендә яткан төп принципларны аңлап яшәүдә.

Җиденче чакра—атамасы «Сахасрара», баш түбәсендә урнашкан. Бу чакрага

хас сыйфатлар—Галәм кануннарын тою һәм тормышыңны шулар нигезендә кору, кешене бәйләп, чикләп торган бар нәрсәдән арыну, яшәеш алдында сәҗдә кылу, аның агымында эрү, Раббыбызга тулысынча инану һәм үзенне Аның ихтыярына тапшыру. Бу баскычта Галәмнең бер өлешенә әверелгән шәхес аның яна сыйфатларын гәүдәләндерә. Кеше бу баскычта яшәеш агымында эрегән халәттә яши, бу—шәхестән бөркелгән гаҗәеп җинеллектә, аның үзе кылган эшләргә исе китмичә, аларга әһәмият бирмичә яшәвендә чагыла. Җиденче чакра активлашкан очракта кешенең аңы баш тирәсендә хәрәкәт иткән илаһи энергияләр белән иҗади мөнәсәбәткә керә. Бу процесс тора-бара кеше аңын Җиһанны бербөтен итеп күрү баскычына күтәрергә мөмкин. Әлбәттә, бу баскычта да кешедә бигүк камил булмаган сыйфатлар әле калырга мөмкин—тәкәбберлек, үз-үзен турында артык зурдан уйлау, җир тормышына өстән торып карау һ.б.

Монарчы сүз кешегә хас илаһи сыйфатлар турында барды. Чакралар системасы кеше белән Раббыбыз арасында агылган энергия алмашу процессын тәэмин итүче антенналарны хәтерләтә. Алда сыйфатланган җиде төп чакра кеше тәнендә урнашкан. Тик кешенең илаһи сыйфатлары моның белән генә чикләнми, ул тагын үтә дә әһәмиятле биш чакра белән коралланган. Гадәттә, алар турында тулы мәгълүматны чакралар системасын тасвирлаган китапларда табуы кыен, бирелгән очракта да аларның галәми әһәмияте ачып салынмый. Шул сәбәпле бу биш чакрага караган мәгълүматны дөньякүләм танылган контактёр Барбара Марсиниякның «Земля» исемле китабына таянып китерәбез.

Әлеге биш чакра адәм баласын рухи дөньялар белән тоташтыру вазыйфасын башкара.

Сигезенче чакра—баш өстендә, физик тәннән берничә сантиметрдан бер метрга кадәр арада урнашкан (төрле кешедә төрлечә). Ул кешене физик тәннән тыштагы күзгә күренмәгән үлчәмнәр, рухи дөньялар белән тоташтыра.

Тугызынчы чакра—ул безне Планетабыз Күзәтүчеләре һәм Остазлар, ягъни Планетар Иерархия белән тоташтыра. Шуңа күрә аны—Планетар чакра дип йөртәләр.

Унынчы чакра—ул кешене тагын да киңрәк дөньялар—Кояш системасына кергән планеталар белән бәйләү өчен хезмәт итә. Аны Кояш чакрасы дип атау гадәте бар. Бу чакра ярдәмендә кеше үзе аңлар дәрәҗәдә Кояш системасына кагылышлы мәгълүмат белән тәэмин ителә.

Унберенче чакра—бу чакра кешене Галактика киңлекләренә алып чыга, төрле йолдызлыклардан мәгълүмат алырга ярдәм итә. Шул сәбәпле аны кайчакта Галактика чакрасы дип тә атыйлар.

Уникенче чакра—аны Галәми чакра дип атарга мөмкин, чөнки ул адәм баласын безнең Галактикадан арырак урнашкан дөньяларга—Галәм киңлекләренә алып чыга, аны Раббыбыз белән тоташтыра.

Бер сүз белән әйткәндә, тышкы чакралар кешегә Галәмдәге төрле дөньялардан мәгълүмат алырга ярдәм итә. Әлбәттә, мондый рухи үсеш баскычына җитүчеләр җир йөзендә санаулы гына, чөнки безнең физик тәнебез мондый мәгълүматны кабул итү һәм эшкәртү, аны аңыбызга җиткерү өчен әле әзер түгел. Шулай итеп, тышкы чакралар аша безгә тапшырыла торган мәгълүмат кешенең аңастына туплана, адәми затның рухи үсеше шулай тәэмин ителә. Бирелгән мәгълүматның акылга үтеп керү-кермәве инде кешенең рухи үсеш дәрәҗәсенә бәйле. Кемгә үтеп керә, кемгә юк. Бу белемнәр күпчелек кешенең аңастында файдасыз капитал булып ята. Юкка гына җир йөзендә таралган рухи практикаларда кеше тәнен чистарту, чакраларның сизгерлеген арттыру рухи үсеш юлына баскан кеше өчен беренче һәм төп таләп итеп куелмыйдыр. Безнең тәнебез галәми нурланышларны, төрле тибрәнешләрне, алар аша төрле характердагы мәгълүматны кабул итә һәм аңыбызга, акылыбызга китереп җиткерә торган илаһи инструмент, гаҗәеп корал булып тора. Шундый катлаулы энергетика һәм «илаһи антенналар» белән коралланган адәм баласын ничек инде илаһи зат дип атамыйсың да, ничек ул Раббыбызның кечкенә бер копиясе сыйфатында күз алдыбызга килеп басмасын!

Кыскасы, адәми зат шушы чакралар—энергия чыгырлары системасы аша Галәм

һәм анда барган процесслар белән турыдан-туры бәйләнештә яши, аннан үзе аңлар дәрәҗәдә хәбәр алып тора. Китерелгән мәгълүматлар безгә адәми затның сөяктән, иттән, сенердән, кан һәм башка сыекчалардан торган кемсә генә булмыйча, Раббыбыз тарафыннан гаҗәеп сизгер һәм зур сәләтләргә ия илаһи зат рәвешендә яралтылуын ап-ачык күрсәтә. Образлы итеп әйтсәк, адәм баласы чыннан да, Раббыбыз мисалында, Аңа охшатып яралтылган зат булып чыга.

Коръәндә китерелгән «хәлифә» сүзе нәкъ шуңа ишарәле.

Библиядә: «И создал Господь Бог человека из праха земного...»,—диелә.

Коръәндә дә адәми затның балчыктан яралтылуы күп сүрәләрдә кабатлана.

Мәсәлән: «Сезне балчыктан яралтып, соңыннан мөддәт биргән дә Улдыр». *(Коръән, 6 : 2)*

«Хактыр ки, Без кешене зыңгылдап торган (саф) балчыктан ялалттык, рәвешле иттек». *(Коръән, 15 : 26 )*

Дин китапларында кешенең балчыктан яралтылган дип әйтелүен ул, чыннан да, балчыктан яралтылган икән, дип кабул итмәскә кирәк. Бу образлы итеп әйтү генә. Уйлап карыйк, нәрсә соң ул балчык? Балчык, туфрак—ул җир йөзенә таралган барлык минераллар чыганагы. Ә адәми затның тәне, чыннан да, төрле минераллардан, хәтта металлардан тора. Ә аларны без җир йөзенә таралган төрле үсемлекләр, җиләк-җимеш, яшелчә, төрле орлыклар һәм хайван, кош-корт итен ашап тәнебезгә туплыйбыз. Ягъни безгә бу матдәләр җирдә үскән, тереклек иткән күп нәрсәләр аша керә, шулай тәнебез үсә, формалаша. Уйлап карасак, без чыннан да балчыктан, туфрактан яралтылган кемсә булып чыгабыз түгелме соң? Шулай фикер йөртсәк, дин китапларында әйтелгән сүз дөп-дөрес булып чыга. Балчыкта, туфракта ниләр булса, адәми затта шуларның барысы да бар.

Яралтылган Адәм дөньяны танып белсен өчен, һәр нәрсәне атап чыгу ихтыяҗы туа. Библиядә бу эпизод болай тасвирлана:

«Господь Бог образовал из земли всех животных полевых и всех птиц небесных, и привел к человеку, чтобы видеть, как он назовёт их, и чтобы как наречет человек всякую душу живую, так и было имя ей.

Нарек человек имена всем скотам и птицам небесным, и всем зверям полевым». *(Бытие, 2 : 19—20)*

Коръәндә исә яралтылган Адәмне фәрештәләргә күрсәтер алдыннан Аллаһ ана дөньядагы бар нәрсәләрнең исем-атамаларын Үзе әйтеп, өйрәтеп чыга:

«Аллаһ Адәмгә дөньядагы бөтен нәрсәләрнең исем-атамаларын өйрәтте дә, аларны (атап чыгуны) фәрештәләренә боерды: «Әгәр дә уйлаганыгыз хак булса, ул белгән исемнәрне әйтеп бирегез,—диде». *(Коръән, 2 : 31)*

Фәрештәләр көтелмәгән сораудан хәтта каушап калалар:

«Сөбхәналлаһ! (Раббыбызга дан булсын!) Без Син өйрәткәнне генә беләбез. Шик юк, Син Үзең һәм галимсең, һәм хакимсең»,—диләр. *(Коръән, 2 : 32)*

Аллаһ кушуы буенча, Адәм фәрештәләргә дөньядагы барча нәрсәләрнең исем-атамаларын әйтеп чыга. Бу хәл фәрештәләр алдында аның дәрәҗәсен бик нык күтәреп җибәрә. Фәрештәләр Адәмнең бөтенләй үзгә зат булуына тәмам инаналар.

Библиядә Раббыбыз яралтылган Адәмне Җәннәт бакчасы—Эдемга урнаштыра һәм кайбер хәтәр нәрсәләрдән сакланырга кирәклеген кисәтеп куя:

«И заповедал Господь Бог человеку, говоря: от всякого дерева в саду ты будешь есть; А от дерева познания добра и зла, не ешь от него; ибо в день, в который ты вкусишь от него, смертию умрешь». *(Бытие, 2 : 16—17)*

Коръәндә бу вакыйга исә менә ничек тасвирлана:

«Без әйттек: «Ий, Адәм, син хатының белән бергә Җәннәттә яшәрсен, Җәннәтнең теләсә кайсы төшендә теләгәнегезчә ризык җыярсыз, ләкин менә бу агачка гына якын килмәгез. Бу агачның җимешен ашасагыз—икегез дә бозыклык юлына басарсыз». *(Коръән, 2 : 35)*

Игътибар итик: Библиядә бу җимешне ашау үлемгә китерер, диелсә, Коръәндә исә бозыклык юлына басарсыз, дип кисәтелә, ягъни анда сүз үлем турында бармый, ә туры юлдан тайпылып, золым, гөнаһ юлына басу хакында бара. Шулай итеп, без биредә мәгънәнең шактый үзгәреш кичеүен күрәбез. Бу үзгәрешнең сәбәпләренә

без әле тиешле урында жентекләп тукталырбыз.

Шуннан соң вакыйгалар барышына көтелмәгән бер зат килеп керә: Библиядә ул—Елан, Коръәндә—Иблис. Ни өчен Библиядәге Еланның Коръәндә—Иблискә әверелүе турында да алда жентекле сүз булыр. Вакыйгалар агышын тоткарламас өчен, әлегә мона тукталып тормыйк. Библия белән Коръән текстларын чагыштырып тикшерүне дәвам итик.

Библиядә: «Змей был хитрее всех зверей полевых, которых создал Господь Бог. И сказал Змей жене (Адама) : подлинно ли сказал Бог: не ешьте ни от какого дерева в Раю? И сказала жена (Адама) Змею: плоды с дерев мы можем есть, только плодов дерева, которое среди Рая, сказал Бог, не ешьте их и не прикасайтесь к ним, чтобы вам не умереть». *(Бытие, 3 : 1–3)*

Шушы урында Елан алдашу юлына баса, Адәм белән Хәуваны туры юлдан яздыру өчен хәйлә ятьмәсе корырга тотына:

«И сказал Змей жене (Адама): нет, не умрете. Но знает Бог, что в день, в который вы вкусите их, откроются глаза ваши, и вы будете как боги, знающие добро и зло». *(Бытие, 3 : 4–5)*

Инде Коръәнгә өстәмә рәвештә кертелгән бер эпизодка тукталыйк. Бу—сюжетка Иблиснең килеп керү эпизоды. Иблис элек Аллаһның иң зирәк, иң сәләтле һәм кодрәтле фәрештәләреннән (Архангел) була, шул сәбәпле ул үз дәрәҗәсен белеп эш итә.

Без инде күрдек, Аллаһ Адәмнән дөньядагы барлык нәрсәләрнең исем-атамаларын әйттереп чыгып, фәрештәләренә аның кем икәнлеген күрсәткән иде. Шуннан соң Адәм өчен гомер буе онытылмаслык бер вакыйга була—Аллаһ фәрештәләренә, Адәмнең өстенлеген танып, аның алдында сәҗдә кылырга боера. Барча фәрештәләр Адәмгә сәҗдә кыла, тик бер Иблис кенә мона риза булмый, каршы килә.

Аллаһ аннан: «Мин кушканны үтәмәскә ни сәбәп булды?»—дип сорый.

Иблис: «Мин аннан өстенрәк, чөнки мине уттан яралттың, аны исә балчыктан гына»,—дип җавап бирә. *(Коръән, 7 : 13)*

Шулай Аллаһ белән Иблис арасында каршылык барлыкка килә. Бу конфликтның сәбәпчесе Адәм. Кешелек дөньясы тарихында ифрат зур роль уйнаган бу вакыйгага да без әле алда анализ ясарбыз. Әлегә сюжетны дәвам итик.

Буйсынудан баш тарткан Иблискә Аллаһ әйтә: «Алайса, чыгып кит моннан. Син монда (Җәннәт бакчасында) калырга тиеш түгелсең. Кит! Син инде каргалганнар сафында». *(Коръән, 7 : 13)*

Шулай итеп, Адәм аркасында Аллаһ иң дәрәҗәле һәм зур кодрәткә ия фәрештәсе белән каршылыкка керә. Димәк, Раббыбыз адәми затны яралтканда ана зур өметләр баглаган, ул Аның өчен аеруча кадерле зат булган, дип уйларга нигез бар.

Аллаһ рәхмәтеннән коры калуның нәрсә икәнен Иблис бик яхшы аңлый, үзенә җәза киләсен дә яхшы белә, шуңа күрә Аның бу җәзаны беразга кичектереп торуын үтенә: «Миңа (Кыямәт көнендә) кешеләр яңадан терелгәнчегә кадәр вакыт бирсәнче»,—ди. *(Коръән, 7 : 14)*

Аллаһ риза була: «Бар, кит, син Кыямәт көненә кадәр яши аласың»,—ди. *(Коръән, 7 : 15)*

Җәзаның кичектерелгәнен белү Иблискә кабат өмет өсти, ул үзенең кул кушырып утырмаячагын, Аллаһка каршы көрәшәчәген ап-ачык белдерә:

«Син мине азгынлык юлына этәрдең, шуңа күрә мин дә Синә омтылучыларны юлдан яздыру өчен зур тырышлык куячакмын. Ант итеп әйтәмен ки, аларны аздыру өчен бер алларына, бер артларына төшәчәкмен, уңнан да, сулдан да котыртып торачакмын. Ахыр чиктә Син аларның күбесендә шөкер итү күрмәссең»,—ди. *(Коръән, 7 : 16–17)*

Аллаһ мондый оятсызлыкка түзеп тора алмый:

«Бар! Каргалып һәм мескенләккә төшеп китеп бар! Әгәр дә кем дә кем сиңа иярсә, Мин алар белән Җәһәннәмне тутырачакмын»,—ди. *(Коръән, 7 : 18)*

Иблис белән мөнәсәбәтен ачыклап бетереп, араны өзгәннән соң, Аллаһ Адәм белән Хәуваны Җәннәт бакчасына урнаштыра һәм, инде әйтелгәнчә, бакча уртасында үскән агачка кагылмаска куша, аның җимешләрен татып караудан тыя.

Коръәнгә өстәмә кертелгән шушы эпизодтан соң сюжет сызыгы кабат Библиядә тасвирланган эзгә төшә, Иблис, үз-үзенә тугры калып, иблислеген итәргә керешә. Ул Адәм белән Хәуваны үгетләргә, күнелләренә коткы салырга тотына.

«Раббыгыз бу агачтан файдалануны сез фәрештә яки үлемсез зат булмасын өчен тыйды бит»,—ди.—Аларны тәмам ышандыру өчен хәтта әле: «Мин сезгә яхшы нәсихәт бирүче»,—дип ант та итә. *(Коръән, 7 : 20—21)*

Коръәннең башка бер сурәсендә бу ант яна дәлилләр белән ныгытыла, анда Иблис: «Ий, Адәм, сина мәңгелек (тормыш) һәм чикләнмәгән хакимият агачын күрсәтимме?»,—дип, Адәм күнеленә тагын да ныграк вәсвәсә сала.

*(Коръән, 20 : 120)*

Игътибар итик: бу аятьләр мәгънә ягыннан Библиядәге: «... откроются глаза ваши, и вы будете, как боги, знающие добро и зло»,—дигән сүзләргә бик тә якын тора шикелле. *(Бытие, 3 : 5)*

## Адәмнең «юлдан язуы»

Мөнә без әлеге миф сюжетының иң четерекле һәм серле урынына килеп җиттек. Библиядә Елан Адәмнең хатыны аша эш итә, үгетләп, аны тыелган агач җимешен татып карарга күндерә, аннан шул ук җимеш белән Хәува Адәмнең үзен дә сыйлый.

«И увидела жена, что дерево хорошо для пищи, и что оно приятно для глаз и вожделенно, потому что дает ЗНАНИЕ; и взяла плодов его, и ела; и дала также мужу своему, и он ел.

И ОТКРЫЛИСЬ ГЛАЗА у них обоих, и УЗНАЛИ ОНИ, ЧТО НАГИ, и сшили смоковные листья, и сделали себе опоясания». *(Бытие, 3 : 6—7)*

Игътибар итик, китерелгән текстта без аңлашылмаган, шактый сәер янгыраган сүзләргә, гыйбарәләргә тап булабыз. Мәсәлән, тыелган агачның җимешен ашауның кешегә гыйлем бирүе. Моны ничек аңларга? Җимеш ашап кына гыйлем туплап булмаганны һәр кеше белә. Алай булса, кеше дигәнең гомер буе укып азапланыр идемени. Димәк, монда ниндидер сер яшерелгән. Җимеш—гади җимеш түгел, сүз монда бөтенләй башка нәрсә хакында бара булса кирәк.Аннан соң тагын бер сәерлек: бу җимешләрне ашаган Адәм белән Хәуваның «күзләре ачыла» һәм алар үзләренең «шәрә икәнлекләрен күрделәр», диелә. Нинди «күзләр» һәм нинди «шәрәлек» турында сүз бара соң? Монысы да аңлашылмый. Димәк, монда да ниндидер сер яшерелгән. Ә нинди сер? Бу мәсьәләгә дә без соңрак әле тукталырбыз. Әлегә сюжетны дәвам итик.

Күп тә үтми Адәм белән Хәуваның кыек эше Раббыбызга мәгълүм була, чөнки Ул Адәм белән Хәуваның үз шәрәлекләрен күрә башлауларын ачыклый.

Адәмнән сорый: «Не ел ли ты с дерева, с которого Я запретил тебе есть?»

Моңа каршы Адәм: «Жена, которую Ты мне дал, она дала мне от дерева , и я ел»,—дип җавап бирә.

Раббыбыз гаҗиз булып Хәувадан: «Что это ты сделала?»,—дип сорый.

Хәува исе дә китмичә: «Змей обольстил меня, и я ела»,—дип җавап бирә.

*(Бытие, 3 : 11—13)*

Адәм белән Хәуваны алдап юлдан яздырган өчен Раббыбыз Еланны каргый һәм җәзага тарта:

«И сказал Господь Бог змею: за то, что ты сделал это, проклят ты пред всеми скотами и пред всеми зверями полевыми; ты будешь ходить на чреве твоем, и будешь есть прах во все дни жизни твоей». *(Бытие, 3 : 14)*

Раббыбыз боерыгын үтәмәгән өчен Адәм белән Хәува да шулай ук Җирдә яшәргә, балалар үстерергә, тир түгеп азык табарга һәм үлгәннән соң җиргә күмелергә хөкем ителә. Шулай алар икесе дә Җәннәттән куыла, Җиргә төшерелә.

Библиядә тасвирланып, адәм балалары язмышында хәлиткеч роль уйнаган шушы вакыйгадан соң Раббыбыз, нәтиҗә ясагандай, әйтеп куя:

«Вот Адам стал как один из Нас, зная добро и зло; и теперь как бы не простер он руки своей; и не взял также от ДЕРЕВА ЖИЗНИ, и не вкусил , не стал жить вечно». *(Бытие, 3 : 22)*

Коръәндә дә бу вакыйганы тасвирлаганда шул ук мәгънә саклана:

«Вәсвәсә салып, ул (Иблис) аларны хәйлә белән алдады. (Тыелган) агач җимешен ашаганнан соң, аларның күзләренә оят җирләре чалынды. Һәм алар Җәннәттәге яфраклардан каплавыч үрергә тотындылар. Раббыбыз: «Мин сезгә ул агачка кагылырга ярамый, Иблис сезнең иң хәтәр дошманыгыз, димәдеммени?—дип аларны орышты»,—диелә.

«(Адәм белән Хәува) әйттеләр:

«Йа, Раббыбыз, үзебезне харап иттек. Әгәр безне кичермәсәң, ярлыкамасаң, һичшиксез, зарар күрүчеләрдән булырбыз»,—диделәр». *(Коръән, 7 :22–23)*

Аллаһ өчен Адәм белән Хәува ничек кенә кадерле булмасыннар, Ул аларны нинди генә зур өметләр баглап яралтмасын, мондый хыянәтне Ул инде кичерә алмый. Шуңа күрә кырыс һәм катгый карарга килә—Адәм белән Хәуваны Җәннәттән куарга була. Аллаһ аларга:

«Бер-берегезгә дошман булып (Җиргә) төшегез. Сезгә җир йөзендә билгеле бер вакытка чаклы яшәр өчен җай урын булыр. Шунда яшәрсез, шунда үләрсез, шуннан (Кыямәт көненә) чакырылырсыз».—ди. *(Коръән, 7 : 24–25)*

Бу инде Раббыбыз тарафыннан бирелгән вакыт төкәнгәнче, бер яктан, ир белән хатын һәм гомумән адәм балалары, икенче яктан, аларны даими котыртып, бер-берсенә өстереп торучы Иблис үзара гел дошманлыкта, каршылыкта яшәячәк дигән сүз. Икенче төрле итеп әйткәндә, Иблис коткысына бирелеп, Раббыбыз күрсәткән юлдан читкә тайпылган адәми затның Җирдәге тормышы шундый программа буенча дәвам итәчәк, дигәнне аңлата. Чыннан да, әгәр дә без гаиләдәге ир-хатын мөнәсәбәтләренә яисә тулаем кешелек дөньясы тарихына күз салсак, аларның язмышы шундый юлдан киткәнлен ап-ачык күрербез.

Ә бит адәми затны яралту эшенә керешкәндә Раббыбыз тарафыннан нинди гүзәл План төзелгән була! Барысы да уйланганча барганда, План тайпылышсыз тормышка ашырылганда кешене нинди бөек һәм гали язмыш көткән булыр иде! Әмма вакыйгалар барышына Иблис килеп кысыла һәм тарихи процесс үзгә юлдан китә. Газаплы һәм фаҗигалы юлдан дип әйтергә туры килә. Һәм бу озын юл Кыямәт көне (Хисап көне) белән тәмамланачак. Ул Көнне һәр адәм баласы кылган гамәлләре өчен Раббыбыз алдында хисап тотачак, җавап бирәчәк. Шулай чиксез эволюция чылбырында аның урыны, алдагы язмышы билгеләнәчәк.

Коръәндә Адәм белән Хәуваның яралтылу тарихы шундый сүзләр белән тәмамлана: «Шулай Адәм Аллаһ сүзен тыңламады һәм туры юлдан язды»,—диелә. *(Коръән, 20 : 121)*

Шушыннан соң җир йөзендә барган тарихи процесс адәми затның, Иблис коткысына бирелеп, «юлдан язу» күләгәсе астында дәвам итә. Ни кызганыч, адәми зат күп дәверләр үз язмышына килеп тыкшынган Иблиснең көчле басымын тоеп яшәргә мәҗбүр була. Хәер, монысы инде, мифларда урын алмыйча, язма чыганаклар һәм төрле тарихи ядкарьләр (артефактлар) аша безгә килеп ирешкән танышрак тарих. Алда сүз фәкать шул дәверләр хакында барачак.

## Серле төшенчәләр

Адәми затның яралтылуы һәм «бозыклык юлына басу» тарихын искә төшереп, аларның Библия белән Коръәндә ничек чагылыш табуын барлап чыкканнан соң без инде иркенләп фикер йөртә алабыз. Бу мифны беркем дә чын вакыйга дип кабул итми торгандыр. Бу—миф, ягъни булып узган нindидер мөһим вакыйгаларны әкияти рәвештә теркәп калдыру, шулай киләчәк буыннарга мәгълүмат, хәбәр тапшыру ысулы булып тора. Инде әйтеп үтелгәнчә, мифлар күп очракта реаль җирлектә туа, яисә нindидер хакыйкатьне гәүдәләндерә.

Форсаттан файдаланып, күренекле эзотерик Анни Безантның мифларга карата әйтелгән бер фикерен житкерәсе килә: «Миф несравненно ближе к истине, чем история, ибо история говорит нам лишь об отброшенных тенях, тогда как миф дает нам сведения о той сути, что отбрасывает от себя эти тени. Как вверху, так и внизу; и притом сперва вверху, а потом уже внизу». *(А. Безант. Эзотерическое*

*христианство. М., 2001.—С. 862).* Соңгы җөмләдәге «сперва вверху» гыйбарәсендә рухи дөньялар, «потом внизу»—без яшәгән матди дөнья, җир йөзендәге тормыш күздә тотыла, ягъни бар нәрсә дә әүвәл өстә—Күкләрдә, рухи дөньяларда башлана, соңыннан гына аска—матди дөньяга инә дигән фикер әйтелә.

Мәгълүматлар миф, әкият рәвешендә тапшырылгач, белемнәрне кешедән яшереп торырга омтылган көчләр дә артык борчылмый—кеше бит барыбер аның асылын аңламаячак, чөнки хакыйкать, кирәкле мәгълүмат бары тик миф, риваять, әкият киеменә киенгән хәлдә яши. Әкиятне исә кем житди кабул итсен. Арада берәр акыллы-зирәге табылып, асылын ача калса да хәвефләнәсе юк,—бер ике кеше барыбер әллә ни кора алмаячак.

Шулай да, адәмнең яралтылуы тасвирланган миф артында нәрсә ята? Библия белән Коръән кешелек дөньясы тарихында булып узган нинди вакыйгаларга ишарәли? Бу мифка бик кыйммәтле мәгълүмат салынган һәм аның гасырлар буе җуелмыйча халыкларга тапшырылып килүе күздә тотылган булса кирәк. Юкса аны берничә диннең Төп Китабында алай җентекләп тасвирламаган булырлар иде.

Мифта без мәгънәсе ачык булмаган берничә төшенчә-гыйбарә белән очрашабыз.

БЕРЕНЧЕСЕ—«А от ДЕРЕВА ДОБРА И ЗЛА, не ешьте от него; ибо в день, в который ты вкусишь от него, смертью умрешь». (Библия)

«Ләкин менә бу АГАЧКА гына якын килмәгез. Бу агачның җимешен ашасагыз,— икегез дә бозыклык юлына басарсыз». (Коръән)

Китерелгән өзекләрдә безгә «дерево добра и зла»ның нинди агач икәне аңлашылмый, гомумән шик туа—биредә гомумән сүз агач турында барамы, әллә башка берәр нәрсә күздә тотыламы? Коръәндә әлеге серле агач «бу агач» дип кенә бирелә. Алда без аны җинеллек өчен «тыелган агач» дип атарбыз. Тыелган агачта нindидер җимешләр дә үсә икән һәм аларны ашаган кеше вафат була (Библия), яки ул бозыклык юлына баса (Коръән). Шулай итеп, безнең өчен Җәннәт уртасында үскән бу агачның нинди агач икәнлеге дә, анда нинди җимешләр өлгерүе дә, ул җимешләрне татып караган кешенең ни сәбәпле вафат булуы яки нигә бозыклык юлына басуы да билгесез килеш кала. Ике-өч юллык дини текстта билгесез нәрсәләр артык күп түгелме соң?! Мәгънәне болай тирән яшерү нигә кирәк булды икән? Гадәттә, җимешләрне «алма» дип күз алдына китерү традициягә әверелгән. Көнбатыш сәнгатендә бу темага меңнәрчә картиналар иҗат ителгән. Алма бары тик алмагачта гына үсә ала. Тыелган агачның «ал-ма-гач» дип, ә кагылырга ярамаган җимешләрнең «ал-ма» дип аталуы да очраклы хәл түгелдер. Бу хәл мифның бик борынгы заманнарда төркиләр яшәгән цивилизация җирлегендә барлыкка килүе турында сөйләмиме? Библиягә ул «запретный плод» дип бары тик тәрҗемә ителеп кенә кертелгән. Бу бит шул ук кагылырга ярамаган, тыелган җимеш—«ал-ма» булып чыга. Димәк, Библиягә кергән кайбер мифларны яһүдиләр үзләренә хәтле яшәгән төрки цивилизациядән алган булып чыга.

Ул вакытта ни өчен алмагач «дерево познания добра и зла» дип атала? Сораулар артык күп һәм алар барысы да җавап көтә.

ИКЕНЧЕСЕ—«...и взяла (Ева) плодов его, и ела; и дала также мужу своему, и он ел. И ОТКРЫЛИСЬ ГЛАЗА У НИХ ОБОИХ, И УЗНАЛИ ОНИ, ЧТО НАГИ...» (Библия)

«Ниһаять, алар икесе дә (тыелган агач җимешен) авыз иттеләр. Шуннан соң АЛАРНЫҢ ШӘРӘЛЕГЕ АЧЫЛДЫ». (Коръән)

Тыелган агач җимешләрен авыз иткәч ачылган күзләр—ул нинди күзләр? Монарчы да Адәм белән Хәува сукыр түгелләр иде шикелле. Һәм алар нинди «шәрәлекне» күрү сәләтенә ия булдылар? Кыскасы, Библия белән Коръәндә серләр кат-кат яшерелгән.

ӨЧЕНЧЕСЕ—«в день, в который вы вкусите их, откроются глаза ваши, и ВЫ БУДЕТЕ КАК БОГИ, ЗНАЮЩИЕ ДОБРО И ЗЛО».

«И увидела жена (Адама), что дерево хорошо для пищи, и что оно приятно для глаз и вожделенно, потому что ДАЕТ ЗНАНИЕ». (Библия)

Шунысы да бар—тыелган агач җимешләрен ашау, күзләрне ачып, аларга нindидер «күрү» сәләте генә биреп калмыйча, адәми затны аллаларга хас нindидер

хикмәтле белемнәр белән дә кораллandыра икән. Әлбәттә инде, мондый агач жимешләреннән кем генә баш тартыр да, кем генә илаһи мөмкинлекләрдән файдаланмый калыр икән. Һәм Адәм белән Хәува Иблис корган шушы ятьмәгә килә дә керә.

ДҮРТЕНЧЕСЕ—Иблис: «Раббыгыз бу агачтан файдалануны сез ФӘРЕШТӘ яки ҮЛЕМСЕЗ ЗАТ булмасын өчен тыйды».

Иблис: «Ий, Адәм, сиңа МӘҢГЕЛЕК (ТОРМЫШ) һәм ХАКИМИЯТ АГАЧЫН күрсәтимме?»—ди. (Коръән)

Шулай итеп, Коръәндәге сюжетта Иблис Адәм белән Хәуваны Аллаһ әлегә яшереп торган серләрне ачып салуны ышандырып алдый. Бу серләр—үлемсезлеккә ирешү яисә хакимлек итүдән гыйбарәт. Икесе дә Жирдә яшәүче кешене бик нык ымсындыра торган нәрсәләр.

Адәм белән Хәуваның Планнан читкә тайпылуы Раббыбызны борчуга сала һәм бу хәл Библиядә ап-ачык теркәлгән:

«Вот Адам стал как один из Нас, зная добро и зло; и теперь как бы не простер он руки своей, и не взял также от ДЕРЕВА ЖИЗНИ, и не ВКУСИЛ, не стал ЖИТЬ ВЕЧНО»,—диелә. *(Бытие, 3 : 22)*

Шөбһәләнерсең дә! Үзенең аны илаһи гыйлемнәрдән дөрес файдалана белү баскычына күтәрелмәгән Адәм кулына вакытыннан иртә тыелган белемнәр, технологияләр кебек көчле корал килеп керү бик житди мәсьәлә. Егерменче йөз мисалы гына да моны бик ачык күрсәтте (атом-төш коралы, водород бомбасы, психотрон корал, Филадельфия эксперименты, Чернобыль һәлакәте һ.б.) Библиядән китерелгән соңгы өзектә «дерево познания добра и зла» икенче төрле гыйбарә—«дерево жизни» белән алмаштырыла. Аларның бер үк нәрсә икәнлеген без алдарак әле күрербез.

БИШЕНЧЕСЕ—Адәм белән Хәуваны «юлдан яздыручы» Елан булып тора. Ни өчен Елан? Елан үзе кем? Ни өчен ул Коръәндә Иблискә әверелгән? Бу үзгәреш нәрсәне аңлата?

Бу сораулар да жавап көтә. Аларга ачык жавап алмыйча, мифны да, адәми затның яралтылу тарихын да ахырынача аңлау мөмкин түгел. Аларны сюжет элементы дип кенә карау мәсьәләгә ачыклык кертми. Һәм без, моңа кадәр яшәгән күп буыннар кебек, асылы ачылмаган әкияти вакыйга белән канәгатьләнеп яшәргә тиеш булабыз. Әмма адәми зат өчен алай яшәү инде мөмкин түгел. Башка заман килде, өченче меңьеллыкның капкалары ачылды һәм кешелек дөньясы Яңа Дәвергә аяк басты. Бүген эзотерик (яшерен) белемнәрне үзләштерү, кешелек дөньясы тарихында яшәп килгән тирән серләрне ачып салу һәм шул нигездә алга атлау заманы килде. Адәми зат күп дәверләр буе үзеннән яшерелеп килгән чын тарихын белергә, Жиһанда үз урынын ачыкларга тели.

## Тыелган агачта («алмагачта») ниләр үсә?

Инде «дерево познания добра и зла», «дерево жизни» һәм Коръәндәге «мәңгелек (тормыш) һәм чикләнмәгән хакимият» агачларының нинди агачлар икәнлеген ачыкларга тырышып карыйк. Өстәп шуны да әйтәсе килә: борынгы чыганакларда, Ислам диненә караган кайбер хезмәтләрдә бу агач ни өчендер «богълай» (бодай) агачы дип атала. Ни өчен «богълай»—беркем дә әйтә алмый. Тик аңлашылмаса да, теркәлгән мәгълүмат яши бирә. Мифның бөтен хикмәте, төп вазыйфасы да шунда—ул кыйммәтле хәбәрне җуелудан саклар өчен уйлап чыгарылган һәм бу эш бик зирәк затлар тарафыннан башкарылган.

«Дерево познания добра и зла», «дерево жизни» гыйбарәләрендә ниндидер тирән мәгънә, сер яшерелүе сизелеп тора, «мәңгелек тормыш» һәм «чикләнмәгән хакимият» дигән төшенчәләр исә аңлаешлырак янгырый, ягъни Коръәндә төшенчәләр практик тормышка, гади кеше фикерләвенә яраклаштырып, шактый гадиләштереп бирелә. Моның сәбәбе—Коръәннең үсеш ягыннан гаять түбән баскычта торган жәмгыятькә иңүендә булса кирәк. Ислам дине барлыкка килгәндә гарәпләр әле Жаһилият дәверендә яшиләр, бу жәмгыять әле ыруглык чорыннан

чыгып та житмәгән була, шуңа күрә Библиядәге кайбер төшенчәләр Коръәндә шул җәмгыятьнең фикерләү дәрәҗәсен истә тотып житкерелә. Әлбәттә, бу чорда гарәп кабиләләренә катлаулы тәгълиматларны, бигрәк тә Жиһан, яшәеш серләренә караган эзотерик төшенчәләрне аңлату мөмкин булмаган. Моның ачык мисалын без 2 нче сурәнең 28 аятендә күрәбез. Анда реинкарнация теориясе (кабат гәүдәләнү, жанның Жиргә күп тапкырлар әйләнеп кайтуы) җиңелчә ишарә рәвешендә генә сиздереп кителә. Әлбәттә, мондый урыннарны эзотерик әзерлеге булган кеше генә аңлый ала, гади укучы аны бөтенләй күрми. Әмма бу тәгълимат Коръәндә чагылыш тапкан. Ул адәми затның рухи эволюциясен аңлатып бирә. Жирдә бер генә тапкыр яшәп адәм баласы ничек акыл, тәҗрибә, рухи потенциал туплый алсын да, ничек итеп изгелек баскычына күтәрелсен?!

Коръәннең беренчел максаты—Жаһилият чорында яшәгән, потларга, йолдызларга, тау-ташларга, аерым ыруг илаһларына һәм башка бик күп нәрсәләргә табынган, тормыш-көнкүрешләрендә гаять вәхши гадәтләр хөкем сөргән (мәсәлән, яңа туган кыз баланы тере килеш жиргә күмү гадәте), зиначылык, эчкечелек киң җәелгән җәмгыятькә югары әхлак өлгеләре бирү, шушы җәмгыятьнең рухи тормышын Аллаһ мисалындагы бөек идеалга юнәлтү, кылган гамәлләреңне шушы идеал югарылыгыннан торып бәяләргә чакыру, шуңа өйрәтү була. Шуңа күрә Исламда җәмгыять тормышын оештыру, кешеләр арасында гадел мөнәсәбәтләр урнаштыру мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирелә. Коръән беренче чиратта гарәп кабиләләрен Жаһилият караңгылыгыннан йолып алу максатын куя, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәр вәгазьләрендә, хәдисләрдә иске җәмгыять тәртипләре нык тәнкыйтьләнә, алар урынына яңача яшәү рәвеше, яңа тәртипләр, мөкәммәл яңа әхлак, яңа рухи идеаллар тәкъдим ителә. Ә инде Исламның йогынтысы дөньяга җәелә бару чорында шушы идеаллар—үзенне Аллаһның газиз баласы итеп карау, гадел яшәү һәм гамәл кылу, югары рухият һәм әхлак өлгеләре башка халыкларга да тәкъдим ителә. Дөрес, еш кына сөңге-кылыч ярдәмендә. Хәер, урта гасырларда башкача була да алмагандыр...

Шулай Ислам рухи һәм мәдәни үсеш ягыннан гаять артта калган гарәп дөньясын яңа баскычка күтәрү вазыйфасын үз өстенә ала. Жир йөзендәге караңгы бер төбәккә жан керә, нур иңә, үсешкә этәргеч ясала, бу төбәк акрынлап торгынлыктан чыга. Әмма без, Исламның бөек казанышлары белән горурланган хәлдә, аның белән янәшә торган башка диннәрнең, рухи тәгълиматларның да кешелек дөньясы үсешенә керткән өлешен күрә белергә тиешбез. Ахыр чиктә бит диннәр, рухи тәгълиматлар халыкларга, өлешләп-өлешләп, бер үк чыганактан иңә, бер үк вазыйфаны—адәми затны рухи дөньялар белән бәйләү, догалар аша Тәрбиячеләребезгә рәхмәтләребезне житкерү вазыйфасын башкара. Күрәсең, бер динне генә бердәнбер хак дин дип санау—жир йөзендәге рухи тәгълиматларның халыкларга иңү, дөньяга таралу закончалыкларын белеп житкермәүдән килә булса кирәк. Мондый караш фикер тарлыгына, чикләнгәнлеккә, бер динне икенчесенә каршы куюга, халыкларны бер-берсеннән аеруга, рухи үсешне тоткарлауга китерә. Кем генә моны илаһи эш-гамәл дип бәяләргә җөрьәт итәр икән?

Без сүз алып барган тыелган агач («древо познания добра и зла», «древо жизни») мәсьәләсенә «Библейская энциклопедия» дә ачыклык кертә алмый, мифны анализлау урынына түбәндәге цитата белән чикләнә: «...Плоды древа жизни после греха и изгнания из Рая не были полезны человеку, потому что он уже не мог вкушать их». Моны житди сораудан качу, дип кенә кабул итәргә мөмкин. Әмма яһүд, христиан һәм ислам диннәреннән ерак торган Көнчыгыш тәгълиматлары тарафдарлары, бу диннәрдән ерак булуларына карамастан, Адәм белән Хәуваның яралтылуы турындагы миф хакында гаять тирән һәм дәлилле фикерләр әйтәләр.

Мәсәлән, рухи практикалар остасы, шул хакта дистәләгән китаплар язган Лобсанг Рампа бу мифның асылын менә ничек аңлата (төгәллекне саклау өчен өзекне тәрҗемә итмичә генә китерәбез):

«Физиологи расчленяют человеческое тело и все сводят к массе плоти и костей... Они не открыли, да и не пытались открыть вещей более сокровенных, того, что индусы, китайцы и тибетцы знали за многие века до зарождения христианства.

Позвоночник является чрезвычайно важной частью организма. В нем заключен спинной мозг, без которого человек становится совершенно неподвижным, совершенно бесполезным существом. Но значение позвоночника гораздо серьезнее. В самом центре спинного мозга находится ствол, УХОДЯЩИЙ В ИНОЕ ИЗМЕРЕНИЕ. Это и есть тот ствол, по которому путешествует в случае пробуждения сила, известная под именем КУНДАЛИНИ. В основании позвоночника находится то, что на Востоке именуется ОГНЕМ ЗМЕЯ. Здесь находится сама ЖИЗНЬ.

У обычного жителя Запада эта великая сила пребывает в глубокой спячке, почти парализованная от бездействия. Собственно говоря, она чем-то и похожа на змею, свернувшуюся в основании позвоночника, змею огромной силы, которая по разным причинам не может в данный момент вырваться из заточения. ЭТОТ МИФИЧЕСКИЙ ОБРАЗ ЗМЕИ ИЗВЕСТЕН КАК КУНДАЛИНИ, и у пробудившихся людей Востока сила Змеи может воспрянуть по стволу спинного мозга, подняться до самого разума и дальше, дальше, в астрал (гади генә итеп әйткәндә, Астрал—рухи дөньяларның Жиргә якынрак торган катламын тәшкил итә—С.Ш.) Поднимаясь, эта могущественая сила активизирует все чакры или центры силы, такие как пупок, горло и прочие энергетические центры. Когда эти центры пробуждаются, человек преисполняется жизни, приобретает мощь и влияние.

Полностью контролируя эту силу Змеи, человек может достичь почти всего.

Итак, легенда (миф) гласит, что Ева поддалась искушению Змея. Иными словами, Ева каким-то образом узнала о Кундалини. Она смогла высвободить силу Змеи, в основании ее позвоночника, которая взмыла вверх по стволу спинного мозга, пробудив ее разум, и дала ей ЗНАНИЕ. А в легенде (мифе) сказано, что она вкусила ПЛОД ОТ ДРЕВА ПОЗНАНИЯ. Получив это знание, она получила СПОСОБНОСТЬ ВИДЕТЬ АУРУ, ИЗЛУЧЕНИЕ СИЛЫ, ОКРУЖАЮЩЕЕ ЧЕЛОВЕЧЕСКОЕ ТЕЛО. Она увидела ауру Адама, его мысли и желания, а у Адама, искушенного Евой, ПРОБУДИЛАСЬ ЕГО СОБСТВЕННАЯ КУНДАЛИНИ, и он тоже увидел Еву такой, как она есть.

Истина заключается в том, что один созерцал ауру другого, видя его обнаженную астральную форму, форму, лишенную телесной оболочки, и видел таким образом все его мысли, все желания, а ЭТО НЕ ДОЛЖНО БЫЛО ПРОИЗОЙТИ НА СТАДИИ ЭВОЛЮЦИИ АДАМА И ЕВЫ.

Когда Кундалини пробуждается в человеке, когда оживает Огонь Змея,—все молекулы тела, повинуясь силе Кундалини, выстраиваются в одном направлении. И тогда человеческое тело наполняется жизнью и здоровьем, приобретает могущество познания и может видеть все.

Существуют различные способы пробуждения Кундалини, но делать этого не следует никому, за исключением тех, кто достаточно развит, ибо громадная сила, власть и влияние на других, которое может дать полное пробуждение, могут быть использованы в недобрых целях. Однако Кундалини может быть пробуждена лишь частично и оживить определенные центры через любовь между супругами. В истинном экстазе близости многие молекулы тела выстраиваются в одном направлении, и тогда эти люди становятся людьми большой динамической силы...» (Лобсанг Рампа. История Рампы.)

Китерелгән өзектән безгә бөен күп нәрсәләр ачыклана. Шулай итеп, без «тыелган агачның» кеше гәүдәсен тотып торган умытка баганасы булуын, аның чыннан да, үсеп утырган агачны хәтерләтүенә инанабыз. Ә инде шушы гәүдәне астын-өскә әйләндереп куйсаң, кешенең чәчләре—агач тамырлары, ә төрле якка таралган нерв жепселләре—агач ботаклары булып күз алдына килә дә баса. Ә агачта нинди жимешләр үсә соң? Ул жимешләрне умыртка баганасы буйлап тезелешкән чакралар системасы, ягъни энергия үзәкләре, арка мие һәм нерв жепселләре тәшкил итә. Фәкать шушы «жимешләр» адәми затка күрү, авазлар ишетү, ис сизү, тою, тәм тату, төрлечә ләззәт алу мөмкинлеге бирә түгелме соң?

Чыннан да, без бары шушы «җимешләр» ярдәмендә генә эчке һәм тышкы дөнья белән бәйләнештә яши торган сизгер затка әвереләбез. Умытрка баганасында урнашкан шушы илаһи үзәкләр, нерв системасы һ.б. булмаса, кеше дигәнең бер ит бүкәненә әйләнер дә калыр иде.

Аллаһ та Адәм белән Хәуваны шушы «җимешләрдән» авыз итеп яшәргә чакыра: «Әй, Адәм, син хатының белән Җәннәттә урнашып, җаныгыз теләгән ризыкны җыегыз»,—ди.

Тик Җәннәт бакчасының нәкъ уртасында тагын бер агач үсеп утыра. Анысына кагылу, җимешләреннән авыз итү инде харам эш санала.

Аллаһ: «Бары тик менә шушы агачка гына кагылмагыз. Юкса, сез дә бозыклык юлына басарсыз»,—дип кисәтә. *(Коръән, 7 : 19)*

Эзотерик чыганакларда Раббыбыз тарафыннан яралтылган адәми затның әүвәл бөтенләй үзгә зат булуы һәм женес, секс дигән нәрсәне белмәве турында хәбәрләр бар. Эш шунда ки, без бүген яшәгән дөнья тарихи дәверләрнең эзотерик классификациясе буенча 5 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ булып санала (аны еш кына 5 нче Раса дип тә атыйлар). Ул Атлантида һәлакәтеннән соң үсеп чыккан дөнья булып тора. Ана хәтле жир йөзендә тагын дүрт КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ булып кичкән. 1 НЧЕ һәм 2 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯЛАРЫ (1 нче һәм 2 нче Расалар) әле женес дигән нәрсәне гомумән белмәгән һәм нәселен бөтенләй башка ысул белән дәвам иттергән. Адәми затның ир-хатын женесләренә бүленүе бары тик 3 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ (3 нче Раса) дәверендә генә барлыкка килә. Шул заманнан башлап адәм балалары нәселне хәзерге, безгә таныш ысул белән дәвам иттерәләр.

1 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ дәверендә адәми зат (аны әле кеше дип атап та булмый) бүгенге кешегә бөтенләй охшамаган, искиткеч зур капчыкны хәтерләткән бер көпшәк масса рәвешендә була. Ул дәвердә кеше бөтенләй башка шартларда яши һәм нәселен, күзәнәк кебек, икегә бүленеп дәвам иттерә. 2 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ дәверендә кешенең тәне инде бераз тыгызлана төшә, күпмедер дәрәҗәдә әгъзалары да формалаша, әмма бу вакытта да ул әле женесләргә бүленмәгән була. Нәселен тәнендә үсеп чыккан бөре рәвешендәге үсенте ярдәмендә дәвам итерә. Вакыты җиткәч, әлеге бөре тәннән аерыла һәм мөстәкыйль яши башлый. Адәми зат эволюциясенең бу баскычлары шундый ерак дәверләрдә булып кичкән ки, аларны хәтта күз алдына китерүе дә кыен. Шуңа күрә күп миллион еллар элек булган бу процесслар турында хәтта эзотерик чыганаклар да мәгълүматны бик саран бирә. Женес дигән нәрсә кешенең тәне формалашу һәм тыгызлану процессында гына барлыкка килә. Бу дәвер кешелек дөньясы тарихында ЛЕМУРИЯ ДӘВЕРЕ яки 3 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ дип атала.

Раббыбыз тарафыннан илаһи зат буларак яралтылган адәми зат үзендә женес дигән нәрсәне ачканнан соң аны сексуаль энергияләр биләп ала, ул бу эш белән чамадан тыш мавыгып китә һәм шул сәбәпле тәнендә барлыкка килгән түбән тибрәнешләр (вибрацияләр) аркасында ул үзенең элеккеге илаһи сафлыгын югалта. Шулай ул эволюциянең түбәнрәк баскычында торган хайваннар дөньясына якынлаша, аның «гөнаһ» һәм «бозыклык юлына басу»ы шуның белән аңлатыла. Аның Җәннәттән куылуы, Жиргә төшерелүе шуна бәйле. Бу очракта Җәннәт символик рәвештә—рухи дөньяны, Жир—физик дөньяны гәүдәләндерә.

Шулай итеп, хайвани үрчү юлына басуы аны рухият ягыннан шактый түбән баскычка төшерә, аның каравы адәми зат Илаһи Программаның башка өлешләрен үтәргә керешә—ул тәне тәмам тыгызланып җиткән, скелеты ныгыган, эчке тышкы органнары формалашкан баһадир гәүдәле зат буларак, матди дөньяны үзләштерү, анда тормыш кору, үз-үзенне саклый-яклый белү, яшәешнең серләрен ачу, тормыш тәҗрибәсе туплый-туплый, акылын үстерү баскычына күчә. Шуна күрә 3 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫН сексуаль яктан иң көчле һәм актив Раса булган һәм бу эш белән артык мавыккан, диләр. Жир йөзендәге негроидлар расасы 3 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫННАН калган халыклардан тора дигән караш та бар.

Җәннәт бакчасы уртасында үсеп утырган агачның авыз итү тыелган җимешләре—символик рәвештә адәми затның женес органнарын гәүдәләндерә. Фәкать шуларны

«татый башлау» кешене баштагы илаһи сафлыгыннан мәхрүм итә. Библиядәге «грехопадение», Коръәндәге «бозыклык юлына басу» шуннан гыйбарәт.

Әйе, умыртка баганасы төбендә коточкыч гайрәт, энергия посып ятканын адәми зат бик күп заманнар белмичә яши. Әйтелгәнчә, ул бу серне бары тик 3 НЧЕ КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ дәверендә женси тормыш белән яши башлагач кына ача. Сексуаль тормыш нәтиҗәсендә умыртка баганасы төбендә бөгәрләнеп яткан Елан-Кундалини уяна, шулай адәми затның чакралар системасы тулы көченә эшли башлый һәм бу хәл аның илаһи сәләтләре—«өченче күзе» ачылуга китерә. Шулай кеше Нәфис Дөньяны күрүче күрәзәчегә әверелә.

Бу хәл Библиядә түбәндәгечә теркәлгән:

«Но знает Бог, что в день, в который вы вкусите их, откроются глаза ваши и вы будете как боги, знающие добро и зло». *(Бытие, 2 : 5)*

Ә Коръән шушы ук фикерне Иблис сүзе аша житкерә:

«Раббыгыз бу агачтан файдалануны сез фәрештә булмасын яки үлемсезгә әверелмәсен өчен тыйды бит»,—диелә. *(Коръән, 7 : 20)*

Икенче бер урында Иблис Адәмне:

«Ий, Адәм, сиңа мәңгелек (тормыш) һәм чикләнмәгән хакимият агачын күрсәтимме?»—дип котырта. *(Коръән, 20 : 120)*

Шулай итеп, Елан-Кундалини дип аталган гайрәт, яна сәләтләр һәм гыйлем чыганагын эшкә җигеп, адәми зат Раббыбыз тарафыннан төзелгән Эволюция Планыннан читкә тайпыла, «гөнаһ» юлына аяк баса, вакытыннан алда илаһи мөмкинлекләргә, сәләтләргә ия була. Өлгермәгән аның мондый гайрәткә ия булуы нинди бәлаләргә китерү ихтималын Раббыбыз алдан күрә, шуна борчылып:

«Мин сезгә ул агачка кагылырга ярамый, Иблис сезнең иң хәтәр дошманыгыз, димәдеммени?»—дип Адәм белән Хәуваны шелтәли.

*(Коръән, 7 : 22)*

Шундый ук борчылу Библиядә дә чагылыш тапкан:

«И сказал Господь Бог: вот, Адам стал как один из Нас, зная добро и зло; и теперь как бы не простер он руки своей, и не взял также от дерева жизни, и не вкусил, и не стал жить вечно». *(Библия, 3 : 22)*

Әйе, Раббыбызның борчылуы табигый, чөнки рухи дөньяларга үтеп кергән зат инде «үлем» дигән нәрсәнең куркыныч түгеллеген, кеше жанының үлемсез булуын һәм вафатыннан соң фани дөньядан китүнең, киемне салгандай, физик тәннән чыгып, бары тик рухи дөньяга күчү генә икәнлеген белеп яши. Аң үсешенең мондый баскычка күтәрелүе, чыннан да, үлемсезлеккә тиң түгелмени?!

Адәм белән Хәуваның яралтылуы тасвирланган мифта без адәми зат эволюциясендә булып узган мөһим бер этапның чагылышын күрәбез, ягъни адәми зат рухи сафлыгын югалтканнан соң Нәфис Дөньяны гәүдәләндергән Жәннәт бакчасыннан куыла һәм матди дөньяны гәүдәләндергән Жиргә төшерелә,—шулай тупасрак тибрәнешләр мохитында яши башлый. Шушы миф аша диннәрне оештыручы көчләр кешелек дөньясына аның үсеш юлында булып узган кискен борылыш турында мәгълүмат тапшырып калдырганнар. Әчтәлеге аңлашылып бетмәсә дә, шушы миф аша мәгълүмат гасырлар буе киләчәк буыннарга тапшырылып килгән. Әлбәттә, аның асыл мәгънәсен бары тик эзотерик белемнәр белән коралланып кына ачыкларга мөмкин. Моңа исә бер дин кысаларында бикләнеп ятмыйча, Раббыбыз тарафыннан иңдерелгән рухи тәгълиматларны киң тарихи планда чагыштырганда һәм аларны бер чыганактан бирелгән диннәр дип караганда гына ирешергә мөмкин.

Инде кыскача нәтиҗә ясыйк.

Шулай итеп, без Жәннәт бакчасында үскән агачларда өлгергән жимешләрнең умыртка баганасында урнашкан арка мие, чакралар һәм нерв системасы булуын ачыкладык. Адәми зат бары тик шулардан файдаланганга («авыз иткәнгә») күрә генә үзен тере һәм сизгер-камил зат итеп тоя. Әмма Жәннәт бакчасы уртасында тагын бер агач үсеп утыра, аның жимешеннән авыз итү исә катгый тыела («үләсең» яисә «бозыклык юлына басасың»). Бу тыелган жимеш—умыртка баганасы төбендә бөгәрләнеп яткан Елан-Кундалини. Аның уянуы, умыртка баганасы буенча өскә,

баш миенә күтәрелүе адәми затка зур гайрәт өстәве, илаһи гыйлем ишекләрен ачуы («өченче күз» ачыла) мөмкин. Бу исә ул заманда әле тыелган, Раббыбыз вәкаләтендәге сер була. Адәмнең аны әле мондый серләрне ачып салу өчен әзер булмый. Әмма Елан-Кундалининың уянуы аркасында адәми зат үзендә бу сәләтләрне ача, тыелган серләрне белә. Шулай адәми зат җенси тормыш белән яши башлый, вакытыннан алда аның «күзләре ачыла», шул сәбәпле тән тибрәнешләре тупаслана, ул әүвәлге илаһилыгын югалта. Шуның нәтиҗәсендә аның үсеше башкарак юнәлештән китә. Бу Раббыбыз күрсәткән юлдан читкә тайпылу була.

## Елан нинди зат?

Без алдагы бүлекләрнең берсендә Библиядәге Еланның ни сәбәпле Коръәндә Иблискә әверелүен сорау рәвешендә калдырып, аңа җавап бирмичә алга киткән идек. Ниһаять, бу мәсьәләгә җентекләп тукталырга һәм аңа җавап табарга вакыт җитте. Чыннан да, бер үк вакыйганы сурәтләгән мифта Библиядә—Елан, Коръәндә исә Иблис хәрәкәт итә. Ни сәбәпле Коръәнгә Иблиснең Адәмне үзеннән өстен итеп танымавы, аңа сәҗдә кылырга теләмәве өстәмә эпизод рәвешендә кертелгән? Еланны миф сюжетына Иблис сыйфатында кертү нинди максатка хезмәт итә?

Бу сорауларга җавап бирү өчен безгә әүвәл Еланның кем икәнлеген ачыклап бетерергә кирәк. Чыннан да, Елан үзе кем соң әле? Әйе, без аны умыртка баганасы төбендә йокымсырап яткан көч-гайрәт, рухи кодрәт чыганагы—Кундалини буларак кабул иттек. Һәм болай аңлату, чыннан да, дөреслеккә туры килә кебек. Әмма ни өчен Кундалини Көнчыгыш тәгълиматларында Утлы Елан (Огненный Змей) символы белән сурәтләнә? Бу бит күз алдына китерү җиңел булсын өчен образлы итеп аңлату, символ аша күрсәтү ысулы гына. Ә асылда Елан кем? Ни өчен Кундалини—Елан символы аша аңлатыла? Моның сәбәбе нәрсәдә, тамырлары кая барып тоташа? Безгә хикәяләү барышында бу сорауларга да җавап бирергә туры киләчәк. Шунсыз мәсьәлә ахырынача ачыкланып бетмәячәк.

Әйе, Елан үзе кем? Ни өчен ул Библиядә башта ук серләрне белүче һәм хәйләкәр зат буларак билгеләнә? («Змей был хитрее всех зверей полевых, которых создал Господь Бог...»). Ни өчен аның урынына башка берәр җанвар, әйтик, төлке, болан, лачын, әтәч кебек кош-корт, җәнлек алынмаган? Ни өчен бу кыек эшне фәкать Елан башкара һәм Кыямәт көненә кадәр сузылачак озын дәверләрдә каргыш алган хәлдә яши? Бу очраклы хәл булырга тиеш түгел. Мифларга очраклы персонаж беркайчан да кертелми, анда һәр нәрсә ныклап уйланган, тирән мәгънәгә ия була. Димәк, монда даниндидер сер ята. Димәк, мифның без моңарчы тикшергәннән үзгә тагын бер яшерен катламы бар.

Моннан тыш без тагын бер сәерлеккә тап булабыз—ни өчен Библиядәге Елан күп гасырлардан соң ингән Коръәндә Аллаһка каршы көрәшүче, адәми затны Аннан аерырга тырышучы, бозыклык юлына тартучы Иблискә әверелгән? Библиядә без бит Еланны Раббыбызга каршы ачыктан-ачык көрәшүче сыйфатында түгел, бары тик Аның серләрен вакытыннан алда Адәм белән Хәувага ачып салучы хыянәтче рәвешендә генә күрәбез. Библиядә Елан бары тик хәйләкәр һәм мәкерле зат буларак кына сурәтләнә. Коръәндә исә без Иблисне башта Аллаһның ярдәмчеләре арасында, фәрештә сыйфатында күрәбез. Аның Адәм алдында сәҗдә кылмавына кадәр Аллаһ белән Иблис арасында бернинди дә каршылык сизелми. Ул Аллаһка тугры хезмәт итүче фәрештәләр сафында була. Елан белән Иблис арасында нинди бәйләнеш һәм уртаклык бар? Классик диннәрнең Төп Китапларына кертелгән бер үк мифта мондый әверелеш-метаморфоза ничек барлыкка килгән? Ул нәрсә турында сөйли, нинди зур вакыйгага ишарәли?

Дөресен генә әйткәндә, без алдыбызга мондый сорауларны куеп, бик катлаулы мәсьәләләр каршына килеп бастык. Болар гади укучыга йөз тотып язылган әсәрләрдә түгел, хәтта эзотерика фәне белән яхшы ук таныш укучылар өчен дә гаять катлаулы мәсьәләләр рәтендә тора. Ни өчен дигәндә, андый мәсьәләләрне аңлау өчен кешелек дөньясы тарихының бик ерак һәм күпчелек кешегә бөтенләй билгесез дәверләренә күз салу сорала. Өстәвенә диннәрдә, эзотерика өлкәсендә очрый торган Хәят Агачы

(Древо Жизни) һәм Елан (Змей) символлары Җиһаннын барлыкка килү процессын тасвирлаганда кулланыла торган символлар булып тора. Безгә аларнын да төбенә төшәргә туры киләчәк һәм мондый чокчыну безне гаҗәеп ерак дәверләргә алып керен китәчәк. Шунсыз Библиядә Еланнын нилектән тискәре персонажга әверелүен дәлилләү, ни өчен Коръәндә Иблискә әверелүен ачып күрсәтү мөмкин түгел.

* * *

Елан—дөнья халыклары мифологиясендә һәм эзотерика өлкәсендә зур урын алып торган төшенчә-символ. Елан ин борынгы символлар рәтенә керә, чөнки ул сөйрәлүчеләр классыннан, ә сөйрәлүчеләр Җирдә кошлардан элегрәк барлыкка килгән, кошлар исә имезүчеләрдән элек тереклек иткән.

Җир йөзендә таралган халыкларнын риваятьләре һәм мифлары ин борынгы заманнардан ук Еланны, бер яктан, куркыныч һәм кешегә дошмани зат буларак, икенче яктан, гакыл һәм зирәклек символы рәвешендә сурәтли. Еланнар еш кына сихер серләрен белүче, вакыйгаларны алдан күреп эш итүче гали затлар буларак телгә алына. Еланнын исемнәре дә гаять күп, ул төрле халыкларда, цивилизацияләрдә төрлечә аталган. Бу очракта әлеге исемнәрнен берничәсен генә санап үтик: Елан (Змий), Ут Еланы (Огненный Змий), Канатлы Елан (Крылатый Змий), Ак Елан (Белый Змий), Канатлы Ак Елан (Белый Крылатый Змий), Аждаһа (Дракон), Ут Аждаһасы (Огненный Дракон), Лу, Лүн, Нага, Балкучы Гакыл Аждаһасы (Сияющий Дракон Мудрости) һ.б. Бу исем-атамаларга әтрафлы анлатма бирә башласак, язмабызнын мифология өлкәсенә караган диссертациягә әверелеп китүе бик мөмкин. Шуна күрә кыскача шәрехләү юлын сайлау дөресрәк булыр шикелле.

Елан—шулай ук төрле мифологияләрдә һәм унай, һәм тискәре персонаж буларак яши. Ул әкиятләрдә кешегә ярдәм итүче, ана җир астында яткан хәзинәләрне табып бирүче сыйфатында тасвирлана. Еланнар җир асты патшалыгы хуҗалары. Алар кеше кыяфәтенә дә керә ала, хатын-кызга әверелеп, берәр ир-атка кияүгә дә чыгарга мөмкин. Әлбәттә, андый кеше еланнан зур зыян күрә, ябыга, сула, хәтта үлеп тә китәргә мөмкин. Шулай ук дөнья халыклары әкият-риваятьләрендә, мифларында елан кемне дә булса урлап китүче, ришвәт таләп итүче, чикләрне саклаучы, кемне дә булса йотып җибәрүче, корбанга кыз таләп итүче, ярдәмче, аздыручы һ.б. рольләрне башкара. Бер үк вакытта Елан—кабилә тотемы, нәселне башлап җибәрүче борынгы баба буларак та билгеле. Кыскасы, Елан әкиятләрдә, риваятьләрдә, мифларда тискәре зат буларак та еш сурәтләнә.

Әйтергә кирәк, мондый сыйфатлар мифологиянен түбән, примитивлашкан, аскы дөньяны тасвирлаучы катламына хас. Борынгы зур цивилизацияләр тудырган мифологияләрдә Елан илаһи зат буларак та урын алган, ул, әйтелгәнчә, гакыл һәм зирәклекне гәүдәләндерүче илаһи яки ярымилаһи зат ролен башкара. Тарих мәйданына монотеистик диннәр калкып чыгып, бер илаһка табыну концепциясе төп дини тәгълиматка әверелгәннән сон гына Еланнын дәрәҗәсе төшә, чөнки монотеистик диннәр бу образ белән көрәшә башлый. Һәм аны акрынлап тискәре образга әйләндерә. Нәкъ шул сәбәпле гакыл, зирәклек иясе булган Елан образы монотеистик диннәр таралмаган Көнчыгыш халыклары мифологиясендә сакланып калган.

Индуизм дине мифологиясендәге Нага—гәүдәсе елан, башы иясә, берничә башлы булганда, башлары кешенеке булган зат. Нагалар—ягерен гыйлемнәр белән коралланган гакыл ияләре буларак тасвирлана, алар теләгәндә кыяфәтләрен дә үзгәртә алган, диелә. Һинд чыганакларында нагалар—илаһи-зирәк еланнар, алар шулай ук Һиндстаннан төньяк-көнчыгышта яшәгән төркиләр белән дә тинләштерелгән. Әлеге чыганакларда бу кабиләләрнен Һинд ярымутравына арий кабиләләре бергә күчеп килгәнче үк яшәгәнлеге хәбәр ителә. Мондый күзаллаулар бик борынгы дәверләрдә барган катлаулы тарихи процессны үзенчәлекле чагылышы да булуы мөмкин. Чөнки борынгы һинд эпосындагы Ракшасаларнын, ягъни гаҗәеп көчкә ия алыпларнын Атлантидадан чыккан халыклар булуына эзотерик чыганакларда

ап-ачык күрсәтелә. *(Кара: Е.П.Блаватская. Тайная Доктрина, т. 1, кн. 2. Космогенезис.—С. 513. Изд-во «Сиринъ». М., 1993).* Төркиләрнең Атлантидадан чыгуы хәзер инде сер түгел.

Шулай итеп, без әлеге зирәк еланнар-нагалар Атлантидадан чыгып, сонрак Һиндстан халыкларының рухи җитәкчеләренә әверелеп киткән затлар булмады микән дигән фикергә килә алабыз. Мәсәлән, эзотерик чыганакларда монголларның Атлантлар Расасының иң соңгы 7 нче субрасасын тәшкил итүе ап-ачык күрсәтелсә дә, төркиләр хакында анда бер сүз юк. Төрки халыкларның борынгылыгы бик оста яшерелеп килә. Күрәсең, монголлар турында дөресен сөйләү артык зур зыян китерми торгандыр, ә менә кайбер даирәләр өчен төркиләрнең чын тарихын ачып салу һаман әле хәтәр нәрсә булып санала... Бәлки бик борынгы һәм мәшһүр халык булгангадыр.

Бу урында укучыларга бер өстәмә мәгълүмат бирергә булдым. Эш шунда ки, әлеге хезмәтне язып тәмамлаганнан соң, аны яңабаштан күздән кичереп, төзәткәләп утырган көннәрдә миңа мәшһүр язучы һәм тарихчы Морад Аджиның «Тюрки и мир: сокровенная история» дип аталган соңгы китабы белән танышырга туры килде. Ул да китабында гакыл һәм зирәклек гәүдәләнеше булган Нагалар мәсьәләсенә туктала. Фикерләребезнең якын булуы мине хәтта гаҗәпкә калдырды. Шуннан бер өзек китереп үтәм:

«Махабхарата», или «Великое сказание о потомках Бхараты»—это летопись древнего Индостана. Там есть страницы о нагах. Их родина, как следует из преданий, на севере... Наги сложили царскую династию, которая оставила реальный след в Северной Индии в начале 1-го тысячелетия. «Махабхарата» насчитывает восемьнадцать книг... Предания, которые легли в основу тех редчайших книг, сложились две с половиной тысячи лет назад и даже раньше, они связаны с пришельцами с севера....

Речь идет о культуре, абсолютно отличающейся от той, что была в Индии прежде. Но кем были прешельцы, герои древних преданий? Где их родина? И есть ли ответы на эти вопросы? А вот здесь мнения людей резко расходятся, здесь уже начинается политика! Кто-то отправляет их на Урал, кто-то—на Тибет. И никто—на Алтай! В этом проявляется удивительное корпоративное единство западной науки. Будто по чьему-то приказу, она ничего в истории континента не связывает с тюрками. Табу...

Но... исследователи, в том числе и западные, давно обратили внимание на то, что эпос древней Индии («Махабхарата», «Рамаяна») и ведийская литература часто описывает явления, видеть которые коренные жители Индии не могли. Даже теоретически. Например, неподвижную Полярную звезду и созвездие Большой Медведицы. А еще снег, лед и морозные ночи, тянущиеся месяцами.

В Индии та же Большая Медведица скрыта за горизонтом, ее не видно. Тем не менее ей посвящены поэтические послания... Не странно ли?

А кто, кроме выходцев с Древнего Алтая, который лежит как раз на тех широтах, мог видеть северное небо? С высоты Тибета такого не увидеть. Уральская версия еще менее состоятельна... «Махабхарата» удивительна тем, что описывает Алтай глазами очевидца.

По настоящему заинтересовать тюрколога могла бы самая первая книга «Махабхараты», она содержит сведения о нагах, их образе жизни. По существу, это древняя история Алтая, история тюрков, о которых других литературных сведений почти не сохранилось...

Индийские ученые абсолютно уверены, наги—это реальные исторические племена, пришедшие на север Индостана»

Буддизм мифологиясендә дә нагалар—яртылаш кеше кыяфәтендәге зирәк еланнар буларак билгеле. Кайбер галимнәр, мәсәлән, нагалар Һиндстанның арийларга кадәр барлыкка килгән мифологиясендә зур роль уйнаган, дигән фикердә торалар. Алай гына да түгел, кайбер буддологлар (Будда динен өйрәнүчеләр) буддизм дине арийларга читтән китерелгән дин дип санныйлар.

Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә—һинд мифологиясендәге зирәк еланнар-

нагаларның буддизм диненә бик хәерхаһ булулары да теркәлгән, хәтта кайберләре бу динне дөньяга таратучы сыйфатында тасвирлана. Әйтик, бер риваятьтә философ Нагарджунага «Праджня-парамиту» дип аталган дини сутра—трактатны бер зирәк Елан-Нага тапшырганлыгы бәян ителә. Бу Нага, кешеләрнең аны әлеге сутраны аңлау дәрәҗәсенә күтәрелүен көтеп, аны күп гасырлар буе кадерләп саклап килгән, диелә. Бу хакта М.Аджи менә нинди фикер әйтә: «Индийцы не скрывают, что у тюрков они взяли «Праджня-парамиту», ставшую фундаментом разноликой культуры Индостана. Своеобразной индийской Библией или Кораном. Это—древнейший сборник мудрости... Уже одним этим индийцы оказали великую честь мировой культуре, сохранив уникальнейшую святыню Алтая».

Һинд мифологиясендәге Шеша атлы зирәк елан Вишну-алланың бер исеме санала. Ул океанда яши, башка аллалар белән бергә, гөбедә май язгандай, тәүге океанны болгатуда катнаша һәм нәтиҗәдә коры жир, континентлар барлыкка килә.

Яңа Гаһедтә (Новый Завет) Гайсә пәйгамбәр Еланны гакыл иясе буларак телгә ала. Бер вәгазендә: «Еланнар кебек зирәк булыгыз...»—ди.

Борынгы Мисыр цивилизациясенә нигез салучыларның берсе—Гермес Трисмегист (Мисырда аның исеме Техути, Тот була)—бу мәдәниятккә алфавит, язу системасы, арифметика, геометрия, астрономия, вакытны билгеләү ысуллары, шашка уены һ.б. бик күп казанышлар керткән зат, мәсәлән, Еланны бөек рухиятка ия зат дип санаган. Әлбәттә, еланның үзен түгел, ә аның образы артында яшеренгән затларны. Ул үзе дә Мисыр аллалары рәтендә йөргән. Мисыр мифологиясендә ул һәрвакыт кулына язу әсбабы тоткан озын томшыклы ибис кошы рәвешендә сурәтләнә. Борынгы Мисырда Аждаһа—илаһ символы булган.

Шумер мифологиясендә өч төп алланың берсе Энки (ул жир йөзендәге тормышны кайгыртучы) символы—ике үзара үрелгән еланнар рәвешендә сурәтләнә.

Тибет мифологиясендәге хатын-кыз алла Лунмо башка аллаларны тудыручы Елан-Ана саналган.

Славян мифологиясендәге Ут Еланы (Огненный Змий) яртылаш кешегә охшаган елан рәвешендә тасвирлана.

Скандинавия мифологиясендәге Сигурд-баһадир аждаһа Фафнир белән сугыша, көрәш барышында аждаһаның каны баһадирның теленә чәчри һәм шуннан соң Сигурд гакыл иясенә әверелә, руналар укырга тотына, аңа сихер серләре ачыла, хәтта урта гасырларда яшәгән изге Франциск Ассизский кебек, кошлар телен дә аңлый башлый. Безнең татарда да телгә оста кеше турында: «Авызына елан төкергәндер монын, билләһи»,—дип юкка гына әйтми торганнардыр.

Шулай ук һиндлар белән тибетлыларның Нагалары да бернинди еланнар түгел—шушы халыкларны житәкләү өчен жибәрелгән Остазлар булуы шик уятмый. Алар тора-бара халык хәтерендә мифологик персонажга гына әверелгән.

Борынгы Греция мифологиясендә Афина шәһәре патшасы Кекроп—ярым елан, ярым кеше кыяфәтендә була. Аттика өлкәсенең беренче патшасы булып күтәрелгәннән соң ул үз биләмәләрен Кекропия дип атый. Ә елан-алла Офионей—аллалар шәжәрәсен башлап жибәрүче санала. Ул аллалар яшәгән Олимп тавының тәүге хужасы була. Соңрак аны Зевс—алла буйсындыра һәм үзе баш аллага әверелә.

Үзәк Америкадагы майялар цивилизациясендә дә еланнарга зур хөрмәт күрсәтелгән, анда кеше башлы елан-алла Йаш Чин культы булуы билгеле.

Австралиядәге кайбер кабиләләрдә Елан—Жиһанны яралтучы зат саналган.

Аккад мифологиясендәге Мутхуш—ялкынга төрелгән аждаһа рәвешендә сурәтләнә, ул баш алла Мардукның символы саналган.

Африкадагы догон кабиләсендә Жир шарын тозлы океан белән чолгап алынган түгәрәк-яссы формадагы жир дип күз алдына китергәннәр. Аны койрыгын авызына капкан коточкыч зур елан урап алган дип ышанганнар. Бу алла Жир белән идарә итүче алла саналган.

Монгол мифологиясендәге аждаһа Лу—төрле сулыклар , дәрьялар хужасы, шулай ук яшен уйнатучы зат саналган. Аны Лу-Тәңре дип атап йөрткәннәр.

Кытай мифологиясендәге зур һәм куркыныч елан Ман—еланнар патшасы саналган, император халатына аның алтын сурәте чигелгән, шулай Ман фатихасы

император хакимиятен саклый диган ышану яшәгән.

Инде үзебезнең төрки халыклар авыз иҗатына, мифологиясенә мөрәҗәгать итик. Алдан ук әйтеп куйыйк—төркиләрдә Елан, Ак Елан, Канатлы Елан, Зур Ак Елан—илаһи һәм зирәк затлар саналган, алар изгеләштерелгән, табыну, олылау объекты булып хезмәт иткән.

Күптән түгел «Мирас» (2004, № 3) журналында филология фәннәре докторы М.Бакировның «Болгарга тоташкан тамырлар» дип аталган мәгълүматларга гаять бай мәкаләсе дөнья күрде. Галим күләмле мәкаләсенең яртысыннан артыгын төркиләр, шул исәптән болгар бабаларыбызның рухи мирасында Елан-Сазаган образының ролен тикшерүгә багышлый һәм гаять кызыклы нәтиҗәләргә килә. Бу хезмәттә китерелгән фактлар безгә «Елан кем?» дигән сорауга җавап биргәндә дәлилләребезне тагын да ныгытырга ярдәм итә.

Элек «елан-сазаган» сүзенә игътибар итик. Еланы аңлашыла, ә «борынгы», «карт», «озак яшәгән» дигән мәгънәләрне аңлаткан «сазаган» сүзе ни өчен еланга тагыла? Әгәр дә без мәсьәләгә эзотерик яктан, кешелек дөньясына өлешләп бирелә торган илаһи гыйлемнәр ноктасыннан чыгып карасак, Еланның бик борынгы һәм гакыл-зирәклек туплаган символны гәүдәләндерүен күрербез. Бу эзотерикада еш кулланыла торган «Мудрый Змий» төшенчәсенә кайтып кала, димәк, төркиләрдә дә бу борынгы төшенчә яшәгән.

Инде төркиләр мирасында Елан образының чагылу очракларына тукталыйк (фактлар М.Бакиров хезмәтеннән алынды).

Борынгы Кытай язмаларында Үзәк Азия һуннарының Лун-сы (Елан-ләү гыйбадәтханәсе) дип аталган бинасында Тәңрегә багышлап корбан чалу, патшашаньюйларны җирләгәндә мәет өстенә елан-сазаган сурәте чигелгән кара ефәк җәймә ябу, аны шуның белән урап күмү гадәте теркәлеп калган.

Билге каган һәм Күлтәгин каберләре өстенә ләү-сазаган сурәте уелган ташлар куелган булган.

Төньяк Кавказда яшәгән вакытта савир-сувар кабиләләре муеннарына алтын-көмештән елан-сазаган сурәте төшерелгән бөти-амулет тагып йөргәннәр.

Болгариядагы Плиска шәһәре янындагы Аспарух хан каберлегендә елан-сазаган сурәте табылган.

Тагын бер кызыклы факт. Кыпчак кабиләләре канатлы Елан-Сазаган сурәтен тормыш-көнкүреш әйберләренә, коралларга, ияр якаларына төшерә торган булганнар. Ә кыпчакларның мәшһүр Шарукан ыруы, гомумән, турыдан-туры Елан-Сазаган исемен йөртә—сазаган-сарукан-шарукан. Шарукан—«сары елан» дигәнне аңлата. Сары—кояш төсе, гомумән, рухият, илаһилык төсе буларак билгеле.

Иртеш елгасы буендагы бер кабердә табылган көзгедә язылган сүзләрнең тәрҗемәсе болай янгырый: «Байбичә кояшыннан аерыла. Якла (каплачы) дошманнан, изге Лү». Биредә «Лү»нең елан-аждаһа булуы аңлашыладыр.

Төркмәнстанның Ашхабад шәһәрендәге Анау мәчете фасадына сары Елан-Сазаган сурәте төшерелгән.

Себердәге Аржан исемле курганда (Тыва) археологлар тарафыннан руник хәрефләр төшерелгән бронза аел табыла, анда «Лү» (Канатлы Елан) сүзе язылган була.

Чуаш мифологиясендә Күктә яшәүче Елан—Селен һәм Ут Еланы—Вери Селен турында күзаллаулар сакланган.

Елан-Сазаган, мифик зат буларак, Болгар дәүләте чорында гына түгел, хәтта Казан ханлыгы дәверендә дә җирле халык тарафыннан өлешчә изгеләштерелгән, дәүләт чикләрен саклаучы, яклаучы буларак күзалланган.

Казан ханлыгы гербында төшерелгән Канатлы Аждаһа-Сазаган сурәте дә безнең халык хәтерендә әлеге затның бик борынгыдан яшәвенә ишарәле кебек. Дөрес, ул руслар тарафыннан ясалган дигән фикер дә яши. Әмма русларның болгар-казанлыны Канатлы Елан-Сазаган белән тиңләве үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Димәк, гербны ясаганда алар бабаларыбызның бу затка хөрмәт белән каравын яхшы белгән.

Татар әкияте «Ак Елан»да—Ак Елан каһарман егеткә ярдәмгә килә, аңа

падишаһның төшен ничек юрарга кирәген әйтә, берничә тапкыр аны үлемнән коткара. «Еланнар патшасы Шаһмара» әкиятендә Ак Елан шулай ук унай роль уйный—каһарманга һәрвакыт ярдәм күрсәтә, ул ханны Ак Елан ите белән дәвалап үлемнән коткара. Шул ук әкияттә елан, күрәзәче сәләтенә ия зат буларак та ярдәм итә,—каһарман елан ите салып пешерелгән шулпаны ашаганнан соң кошлар һәм җәнлекләр телен аңлый башлый.

Төрки халыклар дастаннарында да Канатлы Елан-Сазаган культы эзләре сакланып калган. М.Бакиров язганча, кыргызларның мәшһүр «Манас» дастаны башыннан ахырына кадәр елан-аждаһа культы белән сугарылган. Ул хәтта кыргызларны яклаучы сыйфатында яуда да катнаша.

«Йөртешлек» дастанында да төп каһарманга теләктәшлек итүче еланнар патшасы—Ак Елан тасвирлана.

«Угызнамә» дастанының Истамбулдагы Топкапу китапханәсендә сакланган версиясендә адәмнәрне бәла-казадан коткаручы, дәвалаучы изге Елан-Сазаган сурәтләнә.

Кыскасы, сакланып калган мондый эзләрне төрки мәдәниятләрдә күп табарга мөмкин. Әмма үзебезнең Болгар дәүләте чорына караган бер сюжет аерым игътибарга лаек. Риваятьләр һәм легендаларда Алабуга каласы тирәсендәге соңгы чорларда шартлы рәвештә «Шайтан каласы» дип исем алган урында кайчандыр Канатлы Елан-Сазаган яшәве һәм аның күрәзәчелек итүче, шул сәбәпле кешеләргә зур ярдәм күрсәтүче зирәк зат булуы турында бәян ителә. Бу сюжет турыдан-туры Борынгы Грециядәге Дельфы шәһәре күрәзәчесен (оракулын) искә төшерә.

Билгеле булганча, борынгы заманнарда Фокида өлкәсенең көньяк-көнбатышында күтәрелгән Парнас тавы тарлавыгындагы бер аулак урында грек руханилары зур гыйбадәтханә төзиләр. Ул тау киртләченддәге бер тирән ярык өстенә төзелә, ярыктан кешене үзенчәлекле халәткә кертә торган ниндидер пар чыгып торган булган. Пар күтәрелгән шушы ярык өстенә өчаяклы биек утыргыч куелган, анда менеп утырган күрәзәче хатын-кыз (пифия) гозер белән килгән кешеләрнең сорауларына җавап биргән, күрәзәчелек иткән. Кояш алласы Аполлонга багышлап төзелгән бу гыйбадәтханә тора-бара ул дәвердә вак дәүләтләргә бүленеп яшәгән грекларның уртак дини үзәгенә әверелә. Ул үсә, кинәя, анда гаҗәеп зур театр, стадион, дәвалау үзәкләре булдырыла. Дельфы шәһәрендә сигез елга бер Аполлон-аллага багышланган Пифия уеннары дигән гомумгрек бәйрәме һәм ярышлары уздырыла.

Болар тарихта теркәлеп калган хәбәрләр, ә алар артында тагын нәрсә дә булса бармы? Моны ачыклау өчен без эзотерик (яшерен) белемнәргә мөрәҗәгать итәргә тиеш булабыз. Хәзер бу белемнәр ачыла башлады, шундый заман килде.

Дельфы күрәзәчесеннән сүз-хәбәр ишетү өчен тирә-як илләрдән дә килә торган булганнар. Хикмәт шунда ки, эзотерик чыганакларда бу гыйбадәтханәнең, һәлакәткә кадәр Атлантидадан китеп өлгереп, дөньяга таралган Остазлар тарафыннан төзелүе һәм дөньяны баса башлаган караңгылыкка күп гасырлар буе каршы торучы бер рухият үзәгенә әверелүе турында хәбәрләр бар. (Бу хакта әле алда сүз булыр).

Инде кабат Алабуга шәһәре янындагы «Шайтан каласы»на әйләнеп кайтыйк. Ул да борынгы заманнарда шундый бер рухият үзәге булмады микән? Анда күрәзәлек иткән Канатлы Елан-Сазаганның болгар бабаларыбыз арасында яшәгән берәр зирәк зат булуы бик ихтимал. Рухи ярдәм ул тарихка зур цивилизация буларак кереп калган халыкларга гына килми, кечерәк кавемнәргә дә даими рухи ярдәм инеп тора. Раббыбыз каршында адәм балалары тигез. Өстәвенә Тәрбиячеләребез җир йөзендәге халыкларга аң-белемнәрнең ти.ез таратылуын да күзәтеп торалар. Тарихның тирәнрәк катламнарына керсәк, безгә әле борынгы грекларның үз цивилизацияләрен 4 нче кешелек дөньясы вәкилләре булган атлантлар мирасына турыдан-туры таянып төзүләре кебек бүгенге фән кабул итмәгән серләр дә ачылачак. Дөрес, мондый карашны һинд-европачылык бастырыгы астында яшәгән рәсми тарих фәне әлегә танымый. Әмма бөек серләрнең ачылу заманы инде бусага төбендә басып тора. Хакыйкать барыбер торгызылачак, меңьелларга сузылган ялган барыбер фаш ителәчәк...

Борынгы цивилизацияләрдә изгелекнең иң югары дәрәҗәсенә күтәрелгән затларга Гакыл Еланы, Нага һ.б. исемнәр бирелгән.

Библиядәге «Иов китабы»нда китерелгән сүзләргә игътибар итик: «И был день, когда пришли сыны Божии предстать пред Господа; между ними пришел и сатана»,— диелә. *(Кн. Иова, 1: 6)*

Вакыйга Елан Җәннәт бакчасыннан куылганнан соң бара. Шуңа да карамастан Раббыбыз Сатана-Иблис (Елан) белән әле арасын өзеп бетермәгән. Дөрес, ул инде каргалган, Сатана кушаматы алган, әмма әле барыбер башка фәрештәләр белән Аның хозурына килүдән мәхрүм ителмәгән. Бу өзек Еланның ничек итеп Сатанага әверелүе турында сөйләмимени? Җиһанның барлыкка килүен тасвирлаган борынгы бер трактатта менә нинди сүзләр китерелә: «Иң әүвәл, Ана үзе Ата-Анага әверелгәнче, Ут Аждаһасы рәвешендә берьялгызы чиксезлектә гизде»,—диелә. Бирелә сүз Ананың, ягъни Җиһанны «тудырган», аны юктан бар иткән Иң Югары Затның, Җиһан идеясен практик яктан тормышка ашыра башлаганда, аны ярлтырга тотынганда илаһи энергияләрнең Ата-Ана рәвешендәге ике төргә бүленүе һәм бергәләшеп эшкә керешүе турында бара. Чыннан да, безнең планетабыз, хәзерге түгәрәк һәм тыгыз формадагы күк җисеменә әверелгәнче, башта бит озын койрыклы утлы газ-тузан массасы рәвешендә Галәм кинлегендә гизгән, ул койрыгын авызына капкан ут еланын хәтерләткән. Шул сәбәпле борынгы мифологияләрдә, шулай ук эзотерика фәнендә, койрыгын авызына кабып бөҗра хасил иткән еланны мәңгелек символы итеп кабул иткәннәр.

Шулай итеп, без алда китерелгән мәгълүматларга таянып, Еланның кешелек дөньясы тарихында нинди зур роль уйнаган зат булуын бераз ачыклый төштек кебек.Ул әкиятләргә, риваятьләргә, мифларга Елан, Канатлы Елан, Ак Елан, Ут Еланы, Гакыл Аждаһасы һ.б. исемнәр белән кереп калган булса да, бу символ артында кешелек дөньясы белән эш алып баручы төрле дәрәҗәдәге көчләр торуы шик уятмый.

Нинди көчләр—хикмәт менә нәрсәдә. Ә бит Җир эволюциясенең мәгълүм һәм бик ерак бер дәверендә планетабызга тышкы кыяфәтләре белән рептилияләрне хәтерләткән цивилизация вәкилләренең үтеп керүе һәм, адәми затның мөмкинлекләрен ачыклау өчен, аның белән төрле генетик тәҗрибәләр үткәрү фактлары да билгеле. Шушы тәҗрибәләр аркасында Раббыбыз тарафыннан адәми затка салынган кодлар һәм кешенең Эволюция Программасы шактый үзгәрешләр кичерә. Моны Раббыбыз тарафыннан адәми затка бирелгән илаһи сәләтләрнең байтагын тупас рәвештә кире тартып алу дип бәяләргә мөмкин. Чөнки шушы тәҗрибәләрдән соң адәми зат шактый примитивлашып кала. Шуңа күрә кайбер халыкларның Еланда, Аждаһада илаһ мисалы күрүе, икенчеләренең—алардан бик нык куркуы, аларны кара көчләр гәүдәләнеше дип кабул итүе бик табигый хәл.

Әлбәттә, бер илаһка инану тәгълиматына нигезләнгән диннәр барлыкка килгәч, алар мәҗүсилеккә тарткан Елан образы белән көрәшергә тотыналар.Әмма барыбер мифологиядә киң урын алган борынгы образ халыклар хәтерендә сакланып кала. Ә эзотерика өлкәсе аннан беркайчан да баш тартмады, чөнки эзотерика фәне, аның асыл мәгънәсен кыска гына аңлатып биргәндә, барлык диннәрнең нигезен тәшкил итә, ул ДИННӘР ДИНЕ булып тора. Барлык диннәрнең нигезендә илаһи серләр ята. Кешелек дөньясына иңә торган Илаһи Гакыл иң тулы рәвештә аерым диннәр аша түгел, ә эзотерик белемнәр аша житкерелә. Шуңа күрә һәр заманда бу яшерен белемнәргә тар даирә кешеләр генә ия булган. Әмма без хәзер кичергән Күчеш Дәверендә, Күк Капусы ачылып, аннан кешелек дөньясына күпләп мәгълүмат иңгән заманда алардан һәр кеше файдалана ала. Теләк кенә булсын. Шуңа күрә Тәрбиячеләребез: «Сез гаҗәеп заманда яшисез. Ачыгыз күзләрегезне, уяныгыз йокыдан, адәм балалары!»—дип безгә мөрәҗәгать итеп торалар. Бу безгә Күкләрнең, Раббыбызның ярдәм кулы сузуы. Аны кабул итәбезме? Ә бит янача һәм киңрәк караш белән яшәү генә адәми затка үсешенең яңа баскычына күтәрелергә, рухи эволюциясен дәвам иттерергә юллар ача.

*Ахыры киләсе санда*

Рафаэль
Мостафин



# ТОРМЫШ МИЗГЕЛЛӘРЕ

## Балан суы

—Синең белән авырлы вакытта кинәт кенә балан суы эчәсем килеп китте,— дип, сөйләгән иде бервакыт әни.—Авырлы вакытта була бит инде ул. Күнелен тели икән—берни эшләп булмый. Халыкта шундый сүз бар: «Авырлы хатынның җаны ни теләсә, шуны ашатырга кирәк. Югыйсә, баласы зәгыйфь тууы мөмкин».

Шул... Теләвен телим, әмма баланны кайдан алырга? Кыш уртасы, инде язга авышкан. Февраль ахырлары, март башлары. Сорашып-сорашып карадым күрше-тирәдән—берсендә дә юк. Кайсы кипкән алма, кайсы җиләк, кайсы карлыган кагы тәкъдим итәләр. Ә минем күңелем балан суын тели—теләсән ни эшлә! Әтиең дә Баулыны буеннан-буена айкап, эзләп карады—тапмады.

Шунда кемдер әйтте: «Булса, Зөләйха түтидә генә булыр. Ул баланны көздән җыеп киптерә». Киттем Зөләйха апаларга. Аңлаттым хәлемне. «Әйе,—ди, бар иде шул әзрәк. Иртәгә чормага менәсем бар, шуннан алып төшәрмен, килерсең.»

Юк, мин әйтәм, иртәгә хәтле түзәр хәлем юк, менә хәзер үк, шушы минутта ук кирәк. Көлде дә чормага менеп китте апакай. Күп итеп бирде. Алып кайттым да шикәр белән кайнатып, туйганчы эчтем. Шунда күңелем булды да инде. Югыйсә, синең берәр җирең камил булмас иде.

Рәхмәт Зөләйха түтигә. Авыр туфрагы җиңел булсын...

## Минем дөньяга килүем

Әти-әниләрем 1931 елда Баулының Фрунзе урамында, бер сукыр карт өендә торганнар. Әтием райисполкомда җир инженеры—землемер булып эшләгән, әнием гаилә тәрбияләгән.

2 май көнне әтием белән әнием кунакка барганнар. Ашаганнар, эчкәннәр. Әтием әзрәк салган, әнием исә аракыны авызына якын да китермәгән.

Кайтканда әнием бик авырлык белән генә, җай гына кайта икән. Әтием әйткән: «Күтәреп кенә алып кайтыйммы әллә үзеңне? Тизрәк булыр иде». «Кит аннан!—дигән әнием.—Дөньяда булмаганны. Үзем кайтып житәм, үз аягым белән»...

Шулай итеп әкрен генә кайтып җиткәннәр. Ә таң алдыннан әниемне тулгак тота башлаган. Әтием кендек әбиенә йөгергән. Әби шундук килеп җиткән, баланы кабул иткән, кендеген кискән. Шуннан соң әтием атын җиккән дә, күрше авыл Ак Буадагы фельдшерны алырга киткән. Фельдшер

да берсүзсез килеп житкән, икесен дә бик җентекләп караган. «Барысы да дөрес, барысы да тәртиптә», дигән. Мине бик мактаган. Туп кебек таза-түгәрәк, дигән. Бәхете булыр, дигән. Зур кеше булгач, мине исегезгә төшерерсез, дигән. Әниемне дә бик мактаган. Мондый матур хатын-кызлар сирәк була, дигән. Әзрәк салам кыстырган инде! Әтиемнең күнелен күрергә тырышкан. Әтием дә аны буш калдырмаган. Алдан алып, әзерләп куйган яртысын тоттырган да тарантаска утыртып, кире илтеп куйган. Тегесе салырга ярата торган булган.

## Миңа багышланган тавык

Ул елны яз Баулыга бик иртә килгән. Өченче май көнне әнием тәрәзәдән карап тора икән. Көн кояшлы, матур, искиткеч җылы. Чирәмнәр ямь-яшел, хәтта алмагачлар да чәчәк аткан. Мондый еллар сирәк була. Әнием моны минем бәхетемә юраган.

Шул ук көнне күрше хатыны тавык утырткан икән. Минем туганны ишеткәч, бер күкәйне кара белән буяп, миңа багышлаган. Тора-бара шул күкәйдән сап-сары, матур бер чебеш чыккан. Тап-таза булып үскән, менә дигән тавык булган. Беркөнне күрше хатыны тавыкны суйган, бик әйбәтләп йонын йолкып, эчен-башын чистартып, әниемә алып килгән. Әнием шул тавыкны пешереп, шулпасын миңа эчерткән, итен үзләре ашаганнар.

Хәзер әнием ул күрше хатынының исемен дә хәтерләми. Ә бит ул да миңа яхшылык кына теләгән. Мин үсүем белән аңа да бурычлымын!

Күпме булгандыр минем язмышымда шундый эчкерсез ярдәм итүчеләр! Халкым мине үстергән, тәрбияләгән. Мин дә халкым алдында бурычлы икәнлегемне тоеп яшим.

## Ике туган көнем

Һәркемнең туган көне бер генә була. Мин исә бу дөньяга килгән көнемне елына ике мәртәбә билгеләп үтәм: өченче һәм ундүртенче майларда.

Ничек алай булуы мөмкин, дисезме?

Әнием сүзләренә караганда, мин Баулы район үзәгендә өченче майда иртәнге якта дөньяга килгәнмен.

1931 ел—колхозлашу чорының иң кызган чагы. Әти районда җир бүлеп йөргән, вакыт ягы да бик кысан икән. Ә вакыт табып мине яздырырга загска килгәч, минем әллә кайчан туган булуымны әйтергә унайсызланган, шушы кайткан көнне, ягъни «14 май» дип яздырган.

Ике туган көнең булу бик җайлы икән. Өченче майда туганнарым, иң якын дусларым җыела. Өйдә генә гөрләшеп бәйрәм итәбез. Ә 14 май көнне, паспортта язылганча туган көнем килеп җиткәч, бәйрәм берникадәр рәсмирәк төс ала. Төрле оешмалардан, мәктәпләрдән шалтыраталар, котлаулар, рәсми очрашулар... Ул көнгә тантаналы кичәләр, банкетлар да билгеләнә...

Ләкин бу күренешнең икенче ягы да бар. Ике туган көнең булгач, ике кеше өчен эшләргә, җавап бирергә, икеләтә тырышырга да туры килә.

## «Җитди» сорау

1967 елның август аенда партия өлкә комитеты мине, ул вакытта әле яшь тәнкыйтьчене, авылларга, колхозчыларга татар совет әдәбиятының илле еллык данлыклы юлы турында лекцияләр сөйләргә җибәрде.

Эш күп, вакытым юк, дип карышып та карадым—тынлаучы булмады. Ул елларда тәртип бик каты иде. Обком—райкомга, райком колхоз парторгына

шалтырата: оештырыгыз һәм вәссәлам!

Авылга килеп төшәсен, парторг башын кашый. Нишләргә? Мәктәпләрдә уку елы әле башланмаган. Кырда кызу урак бара, ут капкан сыман чабалар. Кайда ул лекцияләр! Шуннан тота да фермага алып бара. Ять-яшь терлекче кызлар, сыер савучылар кызыл почмакка җыела. Яна кешене күргәч, җанланып китәләр, күзләрен ялтыратып, текәп-текәп карап алалар.

Лекция бетү белән парторг сораулар бирергә кыстый башлый:

—Йә, кызлар, кемдә нинди сорау бар? Активрак, активрак булыгыз... Яле, кем кыю?

Кызлар үзара пышылдашалар, пырх-пырх көлеп тә алалар, әмма сорау бирергә кыймыйлар. Парторг исә һаман кыстый, активлык таләп итә. Шуннан берсе, иң кыюы, ниһаять, тавыш бирә:

—Бер сорау бар иде дә...

—Йә, йә,—дип сөенә парторг.—Бирегез соравыгызны...

—И-и, лектор абый, сез үзегез семьялы кешеме сон?

## Берлинда очрашу

1967 елның март аенда Җәлил эзләре буйлап Германия Демократик Республикасының башкаласы Берлинга барган идем. Бу әле Германиягә беренче баруым (барысы биш-алты мәртәбә барырга туры килде).

Кичтән поезд белән килеп төштем. Каршы алдылар, яхшы отельгә урнаштырдылар. Икенче көнне якшәмбе көне туры килде, шәһәрне карарга булдым.

Берүзем Берлин урамнары буйлап барам. Мин дә монда беркемне дә белмим, мине дә белүче юк. Ничектер күңелсез булып китте,—ят җир, чит халык... Каршы очраган һәрбер немецка текәлеп карыйм: бәлки, Мусаны яки минем әтиемне шушы кеше үтергәндер... Шулай моңсуланып барган уңайдан кемдер саф татарча, бик ягымлы итеп: «Рафаэль абый! Исәнмесез!»—дип дәшмәсенме...

Күтәрелеп карасам, гражданский кием кигән берәү миңа мөлаем гына елмаеп карап тора. Якташым, Баулы кешесе булып чыкты. Мин аны танымасам да, ул мине белә икән. Германиядә хәрби хезмәттә... Ял көне рөхсәт алып, ул да шәһәр белән танышып йөри икән. Чит җирдә якташыңны очрату шундый күңелле булды—дәртләнеп киттем, күңелләр күтәрелде...

## Кадерле автограф

Җитмешенче елларда без Җәлилнең туган көнен үткәрергә Оренбургка барган идек. Без дигәнем—үзем, шагыйрь Ренат Харис һәм композитор Александр Ключарев (хәзер мәрхүм инде).

Безне бик җылы, чын күңелдән кабул иттеләр. Мәдәният сараенда зур кичә, мәктәпләрдә, китапханәләрдә, хезмәт коллективларында очрашулар үткәрдек. Ә озату көне килеп җиткәч, бәләкәй генә уңайсызлык килеп чыкты. Безне аэропортка хәтле озатырга теләүчеләр күп, ә такси машинасы бер генә. Шофер-таксист, бик үтенеп сорагач, әзрәк өстәмә түләү дә вәгъдә иткәч, бездән тыш тагы ике кешене утыртырга риза булды.

Кунакханәдән кузгалып кына киткән идек, ДАИ инспекторы машинаны туктатты. Юл кагыйдәләрен бозган өчен, шоферның хокукларын (правосын) алып калды. Әлбәттә инде, машина йөртүченең кәефе кырылды. Безгә дә уңайсыз—безнең аркада кеше хезмәт хакыннан колак какты бит! Аэропортка килеп җиту белән аңа аңлатма кәгазе язып бирергә булдык. Барысын да аңлатып, шоферның гаебе юк, без үзебез гаепле, дип яздык. Ахырдан, үзебезнең барлык «регалияләрне» күрсәтеп, кул куйдык.

Шофер татар кешесе булып чыкты. Без язган кәгазьне башыннан ахырына чаклы ашыкмыйча гына укып чыкты.

—Сез, чыннан да, Александр Ключарев буласызмы? Мин бит сезнең җырларны радио аша күп ишеткәнем бар... Ә сез атаклы шагыйрь Ренат Харисмы? Сез—Муса Җәлил турында язучы Рафаэль Мостафинмы? Нинди көтелмәгән очрашу! Мондый кыйммәтле автографны ДАИ кулына бирәмме соң! Правасы да чурт с ним! Үземдә саклыйм.

## Юлбашчы өй туена чаклы үлсә ни була?

Калабыздагы һәр йортның үз йөзе, үз тарихы бар. Менә бу, Париж Коммунасы урамы башында урнашкан биш катлы йортныкы да шулай. Теркәү кенәгәләрендә ул «Пар. Коммунасы, 4» дип язылган. Беренче карашка ук аның Сталин чорында салынганлыгы «кычкырып» тора: тәрәзә-түшәмнәре биек (өч метрдан да артык), юыну бүлмәләре һәм коридорлары иркен, фатирлары дүртәр-бишәр бүлмәле... Ләкин һәр бүлмәсендә дүртәр-бишәр кешеле гаилә яши. Шуңа күрә мондый коммуналь фатирларның хәлен күзаллау әллә ни кыен түгел: сасы щи исе борынны ярып торган тар бүлмәләр, бала биләүләре эленгән, иске сандык, тишек таз, җыен иске-москы тулган ярым караңгы коридорлар... Кемнеңдер бүлмәсеннән туктаусыз радио акырганы ишетелә. Уртак кухня бүлмәсендә әледән-әле низаг чыгып тора. Тик соңгы елларда гына картлар үлү, яшьләр яңа фатир алып башка чыгу сәбәпле бу йорттагылар да бераз иркенрәк сулыш ала башлады.

Йортны илленче еллар башында Казан елгачылары өчен салалар. Нигезен шактый зурдан кубып—Сул Болак урамыннан башлап, Гараж урамына хәтле (хәзер—Ник. Столбов урамы) казып, таш белән ныгытып куялар. Тик тиздән смета буенча каралган акча бетә, төзелеш туктатыла. Кат-кат үтенеп мөрәҗәгать иткәннән соң гына, Мәскәү тагы күпмедер «тамыза». Әмма бу сумма да йортның яртысын салырга гына җитә, калган өлеше шул—башланган да ташланган хәлендә—кала бирә. Житмешенче елларда гына бу урынга икенче, элеккесеннән шактый аерылып торган йорт төзелә. Аның инде тәрәзәләре дә таррак, түшәмнәре дә тәбәнәгрәк...

Төзелеш бик озакка сузылганга Обкомда утыручы җитәкчеләрнең ачуы килә. Төзелеш нәчәлнигын Ирек мәйданына чакырып бик каты «пешерәләр», йортны кичектергесез рәвештә нинди дә бәйрәмгә «сдавать итүен» таләп итәләр. Житмәсә шул арада бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин вафат була. Ул үлү белән архитектура алымнары да үзгәрә. Яңа юлбашчы Никита Сергеевич Хрущев «архитектура артыклыклары» белән көрәш башлый. Җитәкче абзыйларыбыз бу көрәштән читтә каламы соң? Өстән кушу буенча борыңгы классик стильдә, шактый купшы итеп проектланган йортны «гадиләштерәләр»: коринф стилендә бизәлгән колонналарны вәхшиләрчә җимерәләр, гипстан ясалган матур-матур ябыштырма бизәкләрне ватып чүплеккә ташлыйлар, әзер таш вазаларны зур чүкеч белән чәлпәрәмә китерәләр. Койма янында җыелган халык бу сәер күренешкә аптырап карап торганда, нинди дер күзлекле, зәңгәр берет кигән кеше—әллә рәссам, әллә архитектор—каршы килеп маташа: чүкеч астына керә язып җимерүне туктатырга тырышып карый. Әмма аңа игътибар итүче булмый.

Шулай итеп, тыштан «гадиләштергән», әмма эчтән шул көе калган шактый шыксыз яңа бер йорт пәйда була.

Ул гынамы соң әле! Обкомга чакырып «пешергәннән» соң башланган ыгы-зыгы вакытында начар сыйфатлы эремә аркасында яңа салынган кирпеч кәрниз ишелеп төшә. Ике эшче хатын һәлак була, берничә кеше имгәнә. Шулай итеп, йортның нигезе кеше канына манчыла...

Без (үзем, хатын, аның әнисе, ике бала) бу йортның беренче катында чирек гасырга якын яшәдек. Балалар үсеп, мәктәп, аннан югары уку йортын тәмамладылар. Каенана вафат булды, улыбыз өйләнде... Сиксәненче еллар ахырында гына башка фатирга—шәһәр читендәге яна йортка күчтек.

Беренче карашка, гомер кичергән фатирыбыз алай начар да түгел иде кебек. Өч бүлмәле, аерым кухнясы... Бездә шактый еш булгалаган Хәсән ага Туфанга йортның Тукай яшәгән районда урнашуы аеруча ошый иде. Чыннан да, тәрәзәдән Печән базары мәчетенен җимерек манарасы күренеп тора (соңыннан аны торгыздылар), шунда ук—атаклы «Көфер почмагы», Тукай яшәгән Болгар һәм Амур номерлары, ул еш кереп йөргән беренче татар китапханәсе... Гомумән, яшәвебезнен беренче елларында шәһәрнең бу өлеше чагыштырмача аз үзгәргән иде. Шул ук ике катлы кирпеч биналар. Аста кибет яки келәт, өстә хуҗалар үзләре яшәгән. Дөрес, иске хуҗаларның калса да, бик азы гына калгандыр. Кибетләрнен дә күбесе ябылып, торак йортларына әверелгән. Ә болай, тыштан караганда—барысы да Тукай заманындагыча...

## Тормышның кире яклары

Һәрнәрсәнең унай ягы белән беррәттән кире ягы да була. Шул кире яклар чиктән ашып китсә, унаен күмеп тә китә ала. Безнең йорт белән дә нәкъ шулай булды.

Беренче «Сталин бишьеллыклары» вакытында, кайчандыр кайнап торган Печән базары урынына, нәкъ безнең тәрәз каршына зур гараж салалар. Анда пассажир автобуслары тора. Шәһәр үсеп автобуслар саны арта төшкәч, алар гаражга гына сыймый башлый, урамга ташып чыга, тротуарга менеп, артларын безнең тәрәзәләргә терәп улап торалар. Зәңгәр төтен белән урам тула, сасысына түзәр хәл калмый иде. Аеруча иртәнге дүртләрдә-бишләрдә, йокының ин тәмле чагында... Туктаусыз дерелдәүдән пыялалар коелып төшкән чаклар булды.

Бервакыт каршыбызда яшәүче өлкән яшьләрдәге эшче абый, түзәр хәле калмагач, төн уртасында йөгереп чыгып, автобус шиннарын пычак белән тишкәли башлый. Сакчы кеше телефон аша милицияне чакырта. «Җинаятьчене» кулга алалар, тилеләр йортына илтеп экспертиза ясыйлар. Акылы камил икәненә ышангач, күпмедер штраф салып кайтарып җибәрәләр.

Якын-тирәдәге малай-шалай бу коточкыч «филләр» белән үзләренчә көрәшеп карый—автобус тәгәрмәчләре астына кадак каккан такталар тыга, шешә кыйпылчыклары ташлый. Әмма алай гына заман техникасын җинәм димә...

Мин исә алар белән кулымдагы бердәнбер корал ярдәмендә—каләм тотып «сугыштым». Йортта яшәүчеләр исеменнән өлкә комитетына да, шәһәр Советына да, Мәскәүгә Үзәк Комитетка да яздым. Мин мөрәҗәгать итмәгән газет-журнал калмагандыр. Нәтиҗәсе исә һәрвакыт диярлек бертөсле була: хатларымны кире гаепле кешеләрнең үзләренә җибәрәләр иде. Шулай да, ун ел чамасы «сугышканнан» соң, максатыбызга ирештек: гаражны шәһәр читенә, яшәү кварталларыннан читкә күчерделәр.

«Уф, Алла»,—дип, тын алырга өлгермәдек, икенче бәла килеп чыкты—янәбызда җәелеп яткан Кабан күле тәмам пычранып, сасып бетте. Су керү яки көймәдә йөрүне әйткән дә юк инде, кышын чаңгыда да йөреп булмый башлады. Черек, үле суда боз катмый, катса да тишек-тошыклы, уалучан була икән. Әмма иң авыры яз көне, боз эрегәч башлана иде. Сасысына түзәр хәл юк. Башлар авырта, күңел болгана, косасы килә. Шулай да шәһәр хуҗаларының моңа «башлары авыртмады». Алар бит Кабан күле янында тормыйлар!

Менә шунда инде мин «Кабан күле серләре» исемле китабымны яза башладым да. Дөресрәге, башта китап язу уйда да юк иде, күлне коткару өчен

«сугыша» башладым. Бу көрәшкә дә бер ун ел гомеремне сарыф итәргә туры килде. Шулай да көрәш бушка китмәде: Кабан күленә сасы сулар агызуны туктаттылар, төбен чистарттылар. Күл янадан саф сулыш алып, элекке хәленә кайтты дисәң дә була. Һәрхәлдә инде сасымый башлады.

Монысы да артта калды дигәндә генә, башка тагы бер бәла килеп төште: астыбыздагы подвалны су басты. Сәбәбе дә бик ачык: өебез астындагы подвалдан файдаланып калын-калын пар торбалары үткәрделәр.Төзелеш кагыйдәләре буенча, бу—катгый рәвештә тыела, чөнки өйнең нигезе бозыла, ватык таш аша су саркып керә башлый. Өебез түбәндә, күл буенда булганга күрә, нәкъ шулай булды да. Су, пар торбаларына тиеп, кайнар буга әверелеп, безнең идәнгә бәрә иде. Эссе дымнан фатирда тын алыр хәл калмый, җиһазлар бүртеп чыга, китап-кульязмалар күгәрә иде. Хатын үпкә авыруы белән авырый башлады, балалар да төчкерә-төчкерә алҗып бетәләр иде. Врачлар: «Аларда да астма авыруы булуы ихтимал, тизрәк фатирыгызны алмаштырыгыз»,— диделәр. Башка чара калмагач, шулай итәргә туры килде.

## Кара ипигә итек мае ягып...

Хәзер без гаиләбез белән Адоратский урамы янындагы яңа йортта яшибез. Саф һава, тынлык, иртәнге сәгатьләрдә тәрәзәдән елмаеп кояш карый. Бәхеткә түзәрлек түгел! Гомер ахырында булса да, без дә кешечә яши башладык, ичмасам! Яңа урында шул күзгә ташланды: сәрхүш-мәрхүш, исерекбашларның бөтенләй диярлек булмавы. Элекке урында яшәгәндә, алар көне-төне тәрәз каршында чуалалар иде. Эссе дым тынны кысканга күрә, без кыш көннәрендә дә тәрәзәләрне һәрвакыт диярлек ачык тота идек. Шуңа да аларның барлык «алтын сүзләре» өйгә аермачык ишетелеп тора иде.

«Алтын» дигәндә, беренче чиратта сүгенү сүзләрен истә тотам. Башкасын булдырмасалар да, монысын булдыралар алар! Ике сүзнең берендә—«ананны». Анысы да әле татарча түгел—татары-урысы бергә—урысча сиптерә: «матперемат». Таң тишегеннән башлап кара төнгә чаклы.

Нәрсә турында иртә таңнан торып сөйләшәләр иде соң алар? Юк, хатын-кызлар турында түгел. Акча турында да түгел. Сәясәт яки мәдәниятне әйткән дә юк. Һаман да шул бердәнбер, иң кадерле, газиз хәмер турында. «Ярты» дисәгез, «ярты» сирәк эләгә андыйларга. Күбрәк җыен әшәкене эчәләр иде: йә «зәңгәр ут» коньягын (денатуратны алар шулай дип атыйлар), йә иң арзанлы ислемай, йә тормоз сыекчасын. Чәчкә сылый торган «Кармазин»ны аеруча яраталар. Мин дә ул сыекчаны баш кычытканнан кулланганга, улым: «Әнә синең «Кармазин туганнарың» («Братья Кармазиновы») килгән,»—дип шаярта иде. «Туганнар» исә «Кармазин» булмаганда, теләсә ни кулланалар иде. Хәтта итек маеннан да баш тартмыйлар иде. Үз күзем белән күрмәгән булсам, ышанмаган булыр идем: кичтән ипи телеменә калын итеп сылап куялар. Төнгә кайнар батарея өстендә калдыралар. Иртән үткен пычак белән карасын кисеп ташлыйлар да... Эчемлеге дә, закускасы да бергә була шунда!

Нинди затлар иде соң алар? Әйтүе шактый кыен. Ни авыл, ни шәһәр... Бик яшь тә, әллә ни карт та түгелләр... Ни татар, ни урыс... Гел урысча сүгенүләрен әйткән идем инде. Сөйләшүләре дә күбрәк русча иде, гәрчә араларында татарлар да байтак булуына карамастан. Кеше дисән—кеше түгел. Хайван дисән—нинди хайван шулай җыен агу эчеп, көн саен пычракта аунап ята алсын?

Араларында аталы-уллы ике кеше бар иде. Атасы ара-тирә булса да нидер эшләп акча таба (аны заманында алтын куллы оста булган дип сөйлиләр иде). Улы исә беркайда да эшләмичә, тумыштан диярлек эчә башлый. Шулай бер заман атасы акча юнәтеп «ярты» алып кайта. Рәхәтләнеп берүзе «сындырырга» гына торганда, улы кайтып керә. Сыйланырга тели, әлбәттә.

Ләкин атасы бирми. Сугышып китәләр. Шунда улы кул астына эләккән пычак белән атасын бугазыннан чала. Милиция килеп җиткәнче чыгып качу турында түгел, тизрәк аракыны чөмереп кую турында гына кайгырта. Кулга алалар, хөкем итәләр. Шул китүдән башка әйләнеп кайтмый.

Шул ук өердә ике «ахирәт дус» бар иде. Торулары да, йөрүләре дә, эчүләре дә—гел бергә. Бервакыт көзге кичне караңгы урам буйлап кайтып килгәндә, берсенең аягы таеп, (сәрхуш баштан, әлбәттә) торба салыр өчен казылган канауга килеп төшә. Канауда исә яртылаш су тора. Сәрхуш куркуыннан акыра-бакыра башлый, куллары-аяклары белән бәргәләнә-чәбәләнә. Икенчесе исә эче катып көлә. Берсе көлгән арада икенчесе, пычрак су йотып, тончыгып үлә...

Ул сәрхушләрнең теңкәгә тигәннәре... Балаларны кечкенә чакта үзләрен генә тышка чыгару юк. Мәктәпкә барганда да озатып куябыз, каршы алабыз. Бервакыт кисәтү ясаган идек—шул ук кичне тәрәзәгә стакан белән тондырдылар. Кышның зәһәр суыгы иде, атна буе яна пыяла артыннан чаптым.

Шулай да ул сәрхушләрдән бездән бигрәк үз туганнары җәфа чигә иде. Мәсәлән, берсенең анасы—шундый да ипле, тыйнак татар карчыгы—баласын кеше итәргә теләп, гомер буе ике-өч урында җыештыручы булып эшләде. Иртә таңнан торып кара төнгәчә эшли иде. Ә улы, әнисе эшләгән акчага дуңгыз урынына эчеп, беркайда да эшләмичә, типтереп йөри иде. Анасының хезмәт хакы җитмәсә, өйдәге җиһазларны сатып эчә. Тора-бара өйләрендә берни калмады—кыйшайган өстәлләренә чаклы чыгарып сатты. Әнисе бердәнбер таушалып беткән кышкы пәлтәсен җәйнең ин эссе көннәрендә дә киеп йөри иде. Өйдә калдырса—бетте баш, кышка яланөс калачак...

Максим Горький да үз заманы сәрхушләре турында язган. Әмма алар бүгенгеләр белән чагыштырырлык түгел—нинидер горур кыяфәтле, ирек сөючә. Кеше турында кайгырталар, фәлсәфә коралар... Безнең сәрхушләр исә бер дә горурланып тормыйча, кайдан нәрсә «чәлдерү» турында гына хыяллана беләләр... Ана кеше үз кызын очраган берәүгә «ярты» бәясенә сатсын әле! (Ул чакта «ярты» 3 сум 62 тиен тора иде.) Горький мондыйларны очратмаган булса кирәк...

Ә бит революциягә чаклы Татар бистәсендә эчүчеләр бик сирәк булган. Андый кешегә җирәнеп караганнар. Хәтта татар зиратында күмергә дә теләмәгәннәр. Совет чорында шәһәрнең бу өлеше нинидер татар Гарлемына әйләнгән.

Йортлары тузып-таушалып хәрабә хәленә калды... Урысча аларны хәзер «трущобы» дип кенә йөртәләр. «Уңайлыклар»—бар да ишек алдында. Сасы, такта бәдрәфләр, куркыныч помой чокырлары... Суга ярты чакрымдагы колонкага барырга кирәк. Яшьләр моннан таю ягын карый—чак кына кеше рәтлеләре фатир алып күчеп китә. Җыен карт-коры, гарип-гораба, сәрхуш-мәрхүш кенә калды анда.

Нәни балалар елдан-ел аз туа—бәби караган яшь ананы бик сирәк очратырга була. Татар бистәсе шайтан арбасы сыман үлемгә табан тәгәри.

Хәзер инде иске йортларның күбесен җимерделәр. Әмма яңа йортлар бик аз төзелә. Татар бистәсе шул хәрабә хәлендә кала бирә...

**Редакциядән:**

*Күренекле әдәби тәнкыйтьче һәм публицист, «Казан утлары» журналының элеккеге баш мөхәррире Рафаэль Мостафинга бу айда 75 яшь тулды. Аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, яңа иҗат уңышлары, ныклы сәламәтлек телибез!*



Мөдәррис
Вәлиев

# КҮҢЕЛ ТӘРӘЗӘБЕЗДӘ УТ СҮНМӘСЕН

*«Мәгариф» нәшриятын төзү турында карар республикабыз тормышының катлаулы һәм хәлиткеч чорында кабул ителгән иде... Аны гасыр башында Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан замандашлары оештырган «Мәгариф» нәшрият-матбага ширкәтенең дәвамчысы сыйфатында кабул итү табигый дип саныйм. Балаларыбызга туган телдә белем һәм тәрбия бирү кебек гаять мөһим бурычны гамәлгә ашыруда ирешкән казанышларыбызны «Мәгариф» нәшриятының күпкырлы эшчәнлегеннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.*

**Минтимер ШӘЙМИЕВ,**
***Татарстан Республикасы Президенты***

*«Мәгариф» нәшрият-матбага ширкәте Беренче рус революциясе тәэсирендә туган һәм 1906 елның ахырында ачылган иң алдынгы нәшриятларның берсе була.*

**Әбрар КӘРИМУЛЛИН,**
***академик***

*Әдәбият һәм сәнгать елы тәсбихендә мөһим буын-төймәләр күп. Тукай, Җәлил, Фатих Әмирхан юбилейлары, татар театры һәм «Мәгариф» нәшриятының 100 еллыклары, «Казан утлары» журналының 1000 нче саны—арада аеруча затлылары. Бу—үткәндәге мәдәниятебез генә түгел, бу—безнең мәдәниятле бүгенгебез.*

**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
***академик***

Китапның тормышыбыздагы урыны күптән мәгълүм: ул аштагы тоз шикелле, житеп бетмәсә йә артыбрак китсә генә сизелә. Артыгын кулланучылар булган кебек, аннан башка—ягъни тозсыз, китапсыз—тора алучы бәндәләр дә бар.

Ләкин гасырлар дәвамында «китап сүзе» дигән төшенчә тормыш тозы булган, һәртөрле кануннардан олы саналган һәм, бәхеткә, ул әле дә асылда шул сыйфатын, вазифасын саклый диярлек.

Һәр яңа буын өчен китап—ташка уелып калган күбәләк сурәте кебек; ул—аккан гомер, калган хәтер елъязмасы. Шул ук вакытта китап—Җанның мәңгелек әйләнештә булып, тәннән тәнгә күчүенә материаль дәлил дә.

Китап сүзен олылауда аны иҗат итүгә һәм «ташка бастыру»га көч куйган

Мөдәррис ВӘЛИЕВ (1953)—*«Мәгариф» нәшрияты директоры, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты доценты, филология фәннәре кандидаты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

шәхесләр хезмәтен югары бәяләү чагыла. Беренче китапның Күктән иңгәнлегенә инану—шуның ачык мисалы.

«Ин элек Сүз булды, Сүз—Илаһныкы иде, Сүз—Илаһ иде... Сүз адәми зат рәвешенә керде һәм безнең арада яши башлады»,—Коръәнгә кадәрге китапларның берсе шулай ачыла.

Коръәннең үзендә Сүз көчен раслаучы нигезләмәләр мәгълүм. Аларның берсе («Бәкарә» сүрәсе, 117 айәт), Аллаһның «Бул!» дип әйтүе белән, Күкләр һәм Җирнең барлыкка килүен бәян итә. Китап сүзе Аллаһ сүзенә тиңләнә («Нәхел» сүрәсе, 2 айәт).

Дарвин теориясенә ышанып, «маймылдан азган» затны ике аягына торгызып бастырган көч—[эш-гамәл коралы] күсәк дип белсәк, хакыйкатьтә адәм баласының беренче көч-коралы Сүз булган. Сүз фани дөньяны тәртипкә салу һәм туздырып ташлау, хәрәкәткә китерү һәм тынсыз калдыру тылсымына ия.

Китапка гомер бирүдә өстенлек (һәм шул хезмәтне данлау-хөрмәтләү, матди бәһаләү), әлбәттә, аны кәгазь битенә төшергән кешегә,—без, наширләр, «автор» дип кенә йөртә торган илаһи затка—әдипкә яисә галимгә тия. Ул шулай булырга тиеш тә. Аллаһның үзе белән тиңләшергә омтылып: «Бул!» дип «кенә» яна дөнья хасил итү һәм ана тереклек иңдерү—илаһият, илһам кодрәте түгелмени. Хәтта Коръәндәге «Шөгарә» (ягъни шагыйрьләр) сүрәсе әлеге дәгъвага ишарә булып аңлашылмыймыни.

Шул ук вакытта китапның бишеге нәшрият икәнлеген, аның «бишектә чакта ук көлеп ятуы» редактор-нашир тырышлыгына да [еш кына бик нык] бәйле булганлыгын яшереп калу мөмкин түгел. Берәр татар язучысының үз әсәрен китап рәвешенә китергән редактор, нашир турында сүгенмичә әйтелгән фикерә кул очыбызда гына юклыктан, Лев Толстой сүзенә колак салыйк. «Иманым камил: тәҗрибәле һәм намуслы редактор әсәрнең уңышын һәрвакыт алдан билгели ала»,—дигән ул.

Редакцияләү төшенчәсе латинча redactus—«тәртипкә китерелгән» сүзе белән бәйле. Ягъни редакторның төп вазифасы автор текстын «тәртипкә китерү» генә булып аңлашыла кебек. Әмма без, авторларыбыз белән бергә, әлеге «тәртипкә салу»ның никадәр күптармаклы, четерекле, җаваплы һәм саваплы эш икәнлеген беләбез.

Төрки-татар дөньясында редакторны, гарәптән алынма сүз белән, мөхәррир дип атау гадәте бар; мөхәррир исә бер үк вакытта язучы-автор мәгънәсен дә аңлата. Шул рәвешле, әлеге төшенчәдә автор белән редактор бергәлеге, бербөтенлеге чагыла шикелле.

...Бүген, заман керткән төзәтмәләрне гомумиләштереп, редактор—китап бизнесы белән шөгыльләнүче фирма/ширкәтнең мөһим бер буыны, дияргә мөмкин.

Дөрес, инглиз теленнән кергән busieness сүзе Рус илендә яшәүчеләр колагына һәм күңеленә әлегә беркадәр ят булып ишетелә. «Чуртан кушып» кына (по щучьему велению) баеп китү хыялы бу кавемнең «милли» холык-фигылен билгеләүче сыйфатларның берсе түгелмени? Базар икътисады дигәнен дә гавам үзенә таныш, мәшһүр «Печән базары», «калхуз базары», «спекулянт» төшенчәләре аша кабул итте. Шуңа күрә баштагырак дәвердә бизнес—эш яки шөгыль түгел,—җинел юл белән табылган мал, ә бизнесмен—эшкуар, товар җитештерүчедән бигрәк, аны әвеш-тәвеш китерү юлы белән баерга омтылучы алыпсатар булып аңлашыла, һәм еш кына гамәлдә дә шулайрак булып чыга иде.

Хәер, моннан йөз ел элек, Тукай заманында да таныш-охшаш хәл түгелмени:

*Сатучылык итә бездә мөхәррир,*
*Әдип исме аңар тагылыр-тагылмас...*

Хәлбуки болганчык суда балык тоту дәвере узып бара; инде нәшрият бизнесы да [әгәр киләчәкне уйлап, намуслы табыш алуга йөз тоткан булса] эшне акыл белән оештыру һәм, «Йосыф китабы»нда ук әйтелгәнчә, «сезгә, безгә файдалы» нәтиҗәгә ирешү мәгънәсендә аңлашыла.

Классик рәвештәге нәшрият—күгәргән, шыгырдап кына әйләнә торган структура-төзелеше, нафталин исе анкучы штат-вазифалары һәм пәрәвез сарган эш тәртипләре белән—тарихка китеп бара. Якын киләчәктә аны заманча технология белән коралланган, җәһәт-оператив идарә ителә торган, эшне оешкан төстә башкара алырлык җыйнак, иҗади җегәрле хезмәт коллективы алыштырыр. Кайчандыр очраклы килеп юлыккан, көн узсынга гына «селкенеп йөрүче» адәмнәр белән кәнфитләнеп тормаслар. Яшерен-батырын түгел, куәтле дәүләт предприятиеләренең яңа шартларга җайлаша алмавына, хәтта күтәрәмгә калуына әнә шул «авыраяк»лар да сәбәпче. (Әлбәттә, бу хәл нәшрият-матбага эшенә генә хас түгел.)

Яңа буын нәшрият хезмәткәре—эш-максатны тулаем, бербөтен итеп аңлый, белә һәм башкара алырлык зат. Фикер һәм гамәл кыюлыгын көтелмәгән зирәк чишелеш табуга юнәлтә алу—аның төп сыйфаты.

Гомумән, бүгенге һәм якын киләчәк редакторының үсеш перспективасы шул юнәлештә—акыл хезмәтенең оештыру-эшлеклелек активлыгы белән тулылануы рәвешендә күз алдына килә. Тик бу—наширлекнең зыялылар һөнәре икәнен онытуы бәрабәренә башкарылмаска тиеш.

Болай искәртү һич очраклы түгел. Хакимият «шомагур»ларга йөз тотып, акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләрне читкә тибәрсә, һөнәр осталарын югалтса, икенче яктан, чиновниклар һәм җинаятьчел төркемнәр басымыннан туеп, чын белгечләр үзләре читләшсә, нәшрият-матбагачылыкның (бигрәк тә яклаучысыз милли китапның) киләчәге нинди булыр? Аңа наданлыгын куштанлык белән капларга азапланган, ялгыш кына эләккән кәнәфие өчен дер калтырап торучы «эшем кешеләре» кулында калу яный.

Дөрес, Совет дәверендә дә гади редакторның мөстәкыйльлеге, иҗат кешесе, инициативалы оештыручы һәм җитәкче сыйфатында ачылу мөмкинлеге шактый чикләнгән иде. Аңа китап язучының ярдәмчесе, хәтта тәрбиячесе итеп карадылар һәм авторның хезмәтенә генә түгел, үзенә дә «күз-колак булу» вазифасын йөкләделәр. Сәяси уяулык редакторның һөнәри осталыгын, «житлеккәнлеген» билгеләүдә төп критерийларның берсе иде. Шуңа да карамастан, ул заманның идеологик диктаты һәм партия әшнәлеге хәзерге акча диктатыннан, кыргый «иснәшеп» табышудан, яраклашудан хәвефсезрәк булгандыр шикелле...

Фани дөньяда адәм баласын оптимизм яшәтә. Килер бер көн, барысы да үз эзенә төшәр: алыпсатарның урыны базарда булыр, мөхәррирлек белән шул эш өчен туган талантлы затлар шөгыльләнер әле, дип өметләник!

* * *

Мәгълүм ки, редакторның, нинди төр (жанр) кульязма белән эш итүенә карап, мәшәкатьләре дә үзгә. Әйтик, фәнни китапта, эксперимент шартлары тулы һәм ачык итеп бәян ителмәү сәбәпле, мәгълүматның 60 процентка кадәр өлеше җуелуга яки бозылуга дучар ителә, имеш. Һәм бу—үз фикерен язма рәвештә дөрес итеп белдерә алмаган автор хикәяләвеннән генә өзелеп төшкән «җимеш» түгел, әдәби тел сафлыгы өчен үзе белгәнчә көрәшүче редактор хезмәтенең дә «казанышы» дип санала.

Дорфа әдәби (бу сүзләрнең янәшәлеге үк сәер!) эшкәртүгә дучар ителгән, «дөресләп» язылган хезмәтнең, үзенә хас йөзе төссезләнүе өстенә, мөһим акцентлары һәм нечкә мәгънә төсмерләре югалырга мөмкин. Нәшрият халкы арасындагы «таяк ул—яхшылап редакцияләнгән чыршы» дигән кинаяле сүз шундый очракларны күздә тота.

Чиктән чиккә ташлануның икенче төре—китапны, янәсе, редактор «диктаты»ннан азат итү, турыдан-туры басмаханәгә (типографиягә) илтеп тапшыру. «Җүләр балыклар»ның нәкъ шулай фәлсәфә куертып, «нәшрият ташмаңгайлары»н хурлап язган мәкаләләре татар матбугатында да күренгәләде.

Ул чактагы «кыюлык»ларны күздән кичереп, күпмедер акларга тырышкандай булса да,—янәсе, редакцияләү текстны яхшырту өчен түгел, ә бәлки сату мөмкинлеген арттыру максатында кирәк икән,—наширләрдән бигрәк китап сәүдәгәрләре «быргычы»сына әйләнә барган «Книжное обозрение» дә, ниһаять, «Русия китап

бастыру эшенең 90 нчы елларда яулаган азатлыгы, кызганычка күрә, муртайган, «тез өстенә куеп» нәшер ителгән китаплар басымы астында оятка калды», дип таный башлады.

Ләкин китапның «беренче тормышы»на илтифатсызлыкның киләчәктә киңрәк колач алу ихтималына бер ишарә: нәшрият эше буенча рус теленә тәрҗемә ителгән чит ил китапларында кульязманы редакцияләү этабына бөтенләй диярлек әһәмият бирелми. Аларда китап бастыруның техник һәм технологик мәсьәләләрен хәл итү юллары гына тасвирлана. Әйтик, танылган инглиз авторы Джон Пикокның «Нәшрият эше» исемле хезмәте рус телендә дә кат-кат басылып чыкты. 400 биттән артык күләмле бу әсбап текстны җыю һәм битләргә салу, бастыру, төпләү һ.б. турында тәфсилләп аңлата. «Материалны редакцияләү» дигән берләнбер бүлекчә шундый калын китапта нибары 2 бит урынны алып тора.

Редактор хезмәтенең үзенчәлекләре турында соңгы елларда «үзебезнекеләр» язган китаплар да юк диярлек. Шуңа күрә, Мәскәүдәге танылган нәшрият-китап эше белгечләре тарафыннан төзелгән «Предпринимательство в книжном деле» дигән һөнәри белешмәлек беркадәр өмет уяткан иде. Ләкин әлеге саллы хезмәт икенче битеннән үк диярлек бары тик китап сәүдәсе хикмәтләрен өйрәтүгә күчә. Чөнки Русиядә дә шундый «алга китеш»: китап бизнесы дигәндә, әзер продукцияне сату гына күздә тотыла (гәрчә бу эш—китап базарын өйрәнү, яңа басманы «базарга этәрү» кебек мәсьәләләр үзенчә бик мөһим).

Кыскасы, китапны нәшер итү һәм сату проблемасы «тавык беренчелме әллә йомыркамы» дигән мәңгелек бәхәскә тартым...

Чагыштырмача күптән түгел (90 нчы елларда), нәшрият эшен «демократияләштерү» шаукымы белән, иске стереотиплардан тиз генә котылырга, ягъни кульязмаларны рецензияләп һәм редакцияләп (димәк, укып та) маташмаска дигән директивалар «төшкән» иде. Әсәре өчен автор үзе җавап тотсын, янәсе. Шуннан файдаланып, кайбер шома наширләр, редакторларны кыскарту, рецензентларны урап узу юлы белән, чыгымнарны киметеп, китапның укучыга барып керүен тизләтмәкче,—нәшрият эшенә тотылган акчаның кызурак әйләнешенә ирешмәкче булдылар.

Автор исәбенә генә түгел, автор редакциясендә дә чыккан басмалар ул чакта дөньяны басып киткән иде, алар әле дә булса күзгә чалына.

«Демократик» дип саналган илләрдә авторлар өчен һәртөрле «өйрәткечләр»нең күпләп нәшер ителүе, махсус журналлар бастырылуы, курслар оештырылуы мәгълүм. Алар язу кәсебе белән акча эшләргә дә өйрәтәләр. Бәлки, шундый әсбапларны яхшы үзләштергән автор үз китабының редакторына без күнеккән күләмдә «кара» эш калдырмый торгандыр. Мәсәлән, Калифорния университетында язучылык осталыгына өйрәтүче Джеймс Фрэйның «Даһи романны ничек язарга» һәм «Даһи детективны ничек язарга» дигән «нәсыйхәт»ләрен бүген рус телендә укып [һәм гамәлдә файдаланып] була.

Тик «мич башы» авторлары шунысын килештермәскә мөмкин: мондый әсбаплар китапны язарга гына түгел, басылып чыкканнан соң аны укучыга җиткерү мәшәкатен дә үз иңенә алырга өйрәтәләр... (Җәяләр эчендә искәртеп китик: татар язучылары арасында да химаячеләр ярдәмендә китап чыгарып сата алган һәм хәтта табышын яңа китабын бастыруга сарыф итүчеләр бар инде. Шунысы гына сәер: мондый тәвәккәл затлар, кулга акча керү белән, ни хикмәттер, китабын «туры эчәк»тән—хосусый нәшрият яки типография аша «автор редакциясендә» генә чыгару ягын карый.)

Автор редакциясендә дигән искәрмәне җитди нәшрият гадәттә мәҗбүрән—гарип җөмләләр, ятышсыз фикерләр өчен җавап бирәсе килмәгәндә яки дуамал автор белән сатулашып туйганда куллана. Гәрчә, кайбер газитләрнең автор сафсатасы яки реклама бирүче намуссызлыгы өчен җаваплылыктан качарга маташуы кебек үк, сәнгатьчә эшләнеше түбән китапка «автор редакциясендә» (ягъни арткы ишектән) юл ачу да хупланa алмый.

Әсәрне нәшриятка кадәр автор каләме белән редакцияләү турында сүз барганда, аның хикмәтле, гыйбрәтле яклары күп. Аларның кайберләрен Ф. Хөсни кебек күренекле әдипләребез үз иҗатлары мисалында ачалар иде.

Гомәр ага Бәширов бер мәкаләсендә болай язган иде:

«Кайбер авторлар, яңа әсәрләрен редакциягә тапшырганда:

—Тел ягын үзегез рәтләрсез инде...—дип әйтәләр, имеш.

...Бу бит, әйтик, тегүченең тегеләсе материяне аннан-моннан гына кискәләп, тегеләй-болай гына күкләп бирүе:

—Тегүен үзегез тегәрсез инде...—дию кебегрәк».

Әйе, иң беренче нәүбәттә нәкъ менә автор үз хезмәтенә тәнкыйть күзе белән карап, аны «нечкә иләктән иләп» чыгарга—редакцияләү ләззәтен татырга тиеш. (Җәяләр эчендә, классик мисалны—Л. Толстойның ике мең биттән торган «Война и мир» романын алты тапкыр яңабаштан эшләп чыгуын искә төшерик.)

Рус әйтмешли, «каләм белән язганны [соңыннан] балта белән дә юнып булмый».

Китап язучының төп чирен, табиб шикелле, «теленне күрсәт әле» дип кенә дә билгеләп була.

Татар теле—халкыбыз кебек үк, уңган-тапкыр, сабыр-горур, сыгылмалы-аһәңле тел. Аның китап сүзенә әйләнгән чагында «балта белән юнылу»ына юл куймау—нәшрият редакторының намус эше.

* * *

«Каләм белән язганны...»

Каләм белән кәгазьгә язылган текст та, ниһаять, тарихка китеп бара. Таш китап гасырын күптән оныткан кешелек дөньясы инде мәңге шулай булыр кебек тоелган кәгазь-катыргы китаптан да аерылырга тора сыман.

Хәтта галәм белән кызыксыну күпмедер сүрелеп, космонавтларны исемләп санаудан туеп, җирдә—үзебез тереклек иткән даирәдәге технология өермәсе безне бөтереп, ияртеп китте.

Компьютер «кулы» белән хәрәкәткә китерелгән бүгенге системалар арасында китап нәшер итү дә актив урын ала. Нәтиҗәнең тизрәк күзгә күренүе кебек яклары белән бергә, китапның рәвеше-булмышы да үзгәрә, янара. Кайчакта эчтәлеген күз-акыл-хыял иңли алмастай булса да, әле тышкы кыяфәте белән китап тулаем традицион—өч үлчәмле булып кала иде. Ә компьютер «тегермәне»ннән әйләнеп чыккач, без аны танымый торабыз: ул шул ук, без белгән китап та, түгел дә кебек.

Инде байтак еллардан бирле безне электрон мәгълүмат чыганаклары (иң күнегелгәне—телевизор) белән куркытып килделәр: янәсе, менә шул «явыз тартма» өйдән һәм күңелләрдән китапны кысрыклап чыгарачак. (Бер философның «Кешелек тарихында ике зур ачыш бар: берсе—китап, икенчесе—[аны кысрыклап чыгарган] телевизор» дигән сүзләрен кулланырга яраталар.)

Чыннан да, бүгенге буын яшьләренең бер өлеше, Толстой яки Дюма әсәрләренең кино вариантын күреп, аларның башта каләм белән язылганын белмәве ихтимал. Өстәвенә, китап битләрендәгедән кызыклырак, тәэсирлерәк булып тоелучы виртуаль каһарманнар, видеоэффектлар, «күрмәгәннең күрәсе килгән» нәрсәләр, «тартма» эченнән саркылып, тормышыбызны төрлеләндерде, тәннәрне чымырдатырлык кичерешләргә «баетты». Гогольнең [«Вий» әсәрендәге] кара табут саклап утыручы «философ»ы сыман, һәр төнгә тагын ни булыр икән дип, шөбһәләнеп, әмма тагын да көчлерәк экстрим-агымга, «шок терапиясе»нә өметләнеп керәбез... Бразилия «күбек-кино»ларындагы кебек, тормышыбызда да өн белән төш буталуыннан «кайф» алабыз—кәефләнәбез...

Мәгәр түрдә кукраеп утырган телевизор, кайчандыр шул урыннан тарихка күчкән самавыр шикелле, бик озак юандырмас, «тыелганга татлы» тоелган телемавыгулар да бер узар. Яшьләр күңелен бүген үк башка, кызыклырак нәрсәләр били, һәм, мәгълүм Фәтхулла хәзрәттәй, һәр яңалык белән көрәшү дә—нинди генә изге нияттән башкарылмасын—житди нәтиҗәгә китермәс. Татар яшүсмерләренең «Ялкын» журналындагы «кайф»-сәхифәләр, «Сабантуй» балалар газетасындагы «Виртуаль дөнья» күрсәтә, кисәтә: милләтнең киләчәген түбәтәй астына яшереп, яулык бөркәндереп кенә үстерергә ярамый.

Безнең алга, нәшрият [гомумән, фән, мәгариф, мәдәният] өлкәсендә дөньядан артта калмас өчен, компьютер технологияләренә җәһәтрәк ия булып, аларны

халкыбызның рухи сәламәтлеген саклауга, фикер аеклыгын һәм мөстәкыйльлеген яклауга, зиһен мускулларын үстерүгә юнәлтү бурычы килеп басты. Кешелек хәтерен буыннан буынга тапшыру вазифасы, ниһаять, балчык, папирус һәм кәгазь битләреннән компьютерларның электрон миенә [гипертекст «сырлары» булып] «уелырга» тора икән, мона милли әзерлек чараларын күрә башларга, татар җәмгыятен алдагы кискен үзгәрешләрдә башкалар аяк астында тапталып, бүтән милләтләр үсешенә чимал сыйфатында гына калудан сакларга кирәк.

Билгеле булганча, китаплар төп ике төргә бүленә: (1) укып күңел ачу, хисләнү/ләззәтләнү өчен язылганнарына һәм (2) белем-мәгълүмат алу максатына хезмәт итүчеләргә. Беренчеләре телевизор тартмасына сыеп бетә язган кебек, соңгыларына компьютер хәтерендә урын алу иплерәк булачак. Шуңа күрә энциклопедияләр, уку-укыту әсбапларының кәгазьдәге варианты белән компьютер версиясе [электрон дәреслекләр] инде хәзер үк янәшә яши башлады. Әлеге «параллель дөньялар» беренче очратта бала-яшүсмер күз алдында пәйда булып, аның аңында «кисешергә» һәм бер-берсен тулыландырырга тиешләр.

Күрәсез, текстны «тәртипкә салу» хикмәтләре турында тәмләп кенә сөйләшеп торган арада, иртәгәсе көн редакторы алдында яңа, кызыклы перспективалар ачылып килә. Алар, бәлки, урта гасырлардан соң әллә ни үзгәреш кичермәгән баш тартмасына сыеп ук бетмичә, безне бераз гына куркыта да торгандыр, әмма, янә халык зирәклеген искә төшерсәк: кул курка, күз эшли. Юк, «күз курка...»ны мин юри генә саташтырган булдым: чыннан да, безнең заманда, «куркак» кул әле икеләнеп калганда, тәвәккәл акыл күзе инде алдан күреп, ничек эшләргә икәнен белеп тора.

Иншалла, татар китабының—татар теленең компьютердагы юлы озын һәм бәрәкәтле булачак,—аякка алдан киеп куйыйк.

* * *

Китап, аның авторы һәм нашир арасындагы икътисади, кануный мөнәсәбәтләр турында сүзгә керешкәндә, күпләргә таныш бер әкият искә төшә.

Чүлмәк эчендә мең ел тоткынлыкта яткан «җен карты»н чыгарып, үз башына бәла алган мәхлук турында ул... Якты дөньяга чыгу белән, коткаручысының муенына менеп атлана да аны интектерә башлый әлеге «камытаяк». Ашаганда гына түгел, йоклаган чагында да җилкәсеннән төшәргә җыенмый. Бу афәттән котылыр өчен, шактый вакыт сарыф итәсе, акыл-хәйлә көчен эшкә җигәсе була...

Тел төбе аңлашыладыр: үзе дөньяга чыгарган китап та кайчакта нашир муенындагы шундый «камыт»ка әйләнә. «Тудырганчы» шактый «тулгак тотарга», байтак капризларын үтәргә туры килгәннән соң, инде аны кемгә-ничек-ни бәягә сатып җибәрү, тупасрак итеп әйткәндә, анардан ничек котылу турында баш ватасы була...

Китапны нәшер итүгә тотылган чыгымнан бигрәк, аны сатудан әйләнеп кайткан керем һәм (әгәр булса) табыш зурлыгы нәшриятны гына түгел, авторны да кызыксындыра. Язучы үз хезмәтенә лаеклы каләм хакы (гонорар) ала алсын өчен, күләм белән тираж «дөрес», акылга муафыйк булырга тиеш. Басманың тышкы кыяфәте генә түгел, эчтәлеге дә укучы ихтыяҗына туры килү шартын инде әйтеп торасы юк. Кыскасы, китапның кибет киштәсендә күпме вакыт ятачагы байтак факторларга бәйле.

Милли китап сәүдәсенә һәм, киңрәк алганда, икътисадына кагылу белән, сөяк эчендәге җелек кебек, «урыс баеса, чиркәү сала, татар баеса—[хатын өстенә] хатын ала» кебек, халкыбызның үзәнкыйфть рәвешендәге фикер-фәлсәфәсе искә төшә.

Объектив хәл шундый: русча басмаларның тиражы зур, хакы да шактый югары (гәрчә Көнбатыштагыдан 3-5 мәртәбәгә арзанрак). Русия нәшрият эшендәге икътисади анализ һәм фаразлау нигезендә, бездә кыйммәтле китапны алмыйлар дигән караш инкяр ителә. Чыннан да, бәясе арзан булмаган затлы альбомнар, дини әдәбият, рус телендәге балалар китабы кибет киштәсендә тузан эчеп ятмый. Шул ук вакытта рус телендәге басма продукциянең актив сатылуын, рус китабы наширләренең әллә ни көч куймый «череп баю»ын әлеге телдә укучыларның күп

булуы белән генә аңлатырга тырышу дөрес булмас иде. Дәреслек өлкәсендә (чагыштырмача төшемле секторда) кәсеп итү максатын куйган нәшриятлар, мәсәлән, төрле алымнар кулланып, Русия киңлегендә сатып алучыларны «аулыйлар». Аларның тәҗрибәсе күрсәткәнчә, хәерче ата-аналардан һәм укытучылардан бигрәк, җирле мәгариф түрәләрен сатып алу нәтиҗәлерәк.

Кыскасы, китапны хәтта кыйммәт бәягә сату бәясе дә куелган хезмәтне акламый, аның үсеше илдәге инфляция темпларыннан артта калып бара.

Яхшы кәгазь, күптөсле бизәлеш, үзенчәлекле формат һ.б. тулаем үзкыйммәтне арттыра икән, үз илендә икенче сортлы саналган милләтнең тыйнак язучысы китабын шул телне аңлар-аңламас ярлы укучысына ничек сатмак кирәк?

Совет чоры нәшрият эшендә коммунистик идеология алгы планда булса, бүген китап сәясәтен билгеләүдә төп рольләрнең берсен акча «идеологиясе» уйный. Коммерция, бизнес кебек икътисади төшенчәләрнең рухи өлкәгә басымы көннән-көн ныграк тоела. Асылында уңай бу үзгәрешләрнең тискәре ягы—китап базарын, табыш артыннан куып, кыргый инстинктларны уятуга йөз тоткан әдәбият биләвендә. Әлбәттә, заманы нинди—укучысы шундый, укучысы нинди—китабы шундый, дип фикер йөртергә мөмкиндер. Үткән гасырның 90 нчы елларында байтак ватандашларыбыз азгынлык, һәртөрле ырым-шырым белән тулы басмаларга, ягъни моңарчы «тыелган» темаларга ябырылган булса, инде ул дулкынның сүнүгә баруын күреп торабыз. Шулай да, ни аяныч, ул чордагы кыргый базар «җимешләре» аша халкыбызның рухи сәламәтлегенә үтеп керергә өлгергән зыян—авыр сызланулар һәм «югалган» буын проблемасы булып кайтачак әле...

Әйе, бүгенге укучы кичәгедән үзгәрәк, аның таләп-ихтыяҗлары тотрыклы түгел, кыйбласы үзгәреп тора. Кызганыч, әлегә бар үзгәрешне дә гел яхшыга таба гына дип әйтүе кыен. Әйтик, зур тиражлар заманы узды. Йөзәр мең данәдә татарча матбугат тарату, шундый ук санда балалар китабы чыгару өчен тырышып йөрүләр һәм шуңа ирешүләр турында сагынып сөйләргә калды. Инде, кем әйтмешли, калын китап чыгару да—бик «нечкә эш».

Икенче яктан, моны тискәре күренеш дип кенә бәяләү хаклы микән? Бүген зур тираж белән басылган кайсыбер газит яки китапның милләткә, аның зиһененә, әхлагына файдалы булуы икеле-микеле уйлар тудыра. (Дөрес, кайбер «нашир»ләр, беркатлы каләм иясенең күңелен күрер өченме, бүтән хәйлә беләнме, китапны, янәсе, 50, хәтта 100 мең данәдә басылган итеп күрсәтәләр. Аннары бу «кәмит» язучының библиографиясенә «сары май» булып ята.)

Урман күп кутәрүчедән курыкмый дигәндәй, аз тиражлы басмалар белән эшләргә өйрәнү нәшрият икътисадын тотрыклы итүдә зур роль уйный. Ихтыяҗ туу белән, китапның тулырак версиясен өстәмә тираж белән бастыру мөмкин. Авторның «сихер догалары»на [булачак китапны, имештер, күренекле галим, танылган язучы хуплаган, аны «көтәләр», «ябырылып алачаклар», ул «нәшриятка искиткеч табыш китерәчәк»] «саңгырау» булырга туры килә. Гомумән, авторны нашир белән бер дәрәҗәдә җаваплы итәргә кирәк: ул үз китабына бәйле проблемалар, чыгым һәм [булса] табыш турында белеп торсын.

Шундый вазгыятьтә автор белән «идарә итү», укучыны «яктыга» юнәлтү, ягъни һәр китапның үз укучысын/сатып алучысын алдан күрү—редактор, наширнең изге бурычы. «Китап директоры» (редактор) базар кануннарын аңларга тиеш. Табышка гына йөз тоту—бигрәк тә милли әдәбият, фәнни басмалар өлкәсендә—караңгы почмакка илтеп терәгән кебек, дәүләт ярдәменә таянып, абстракт «халык»ка кирәкле, шүрлектә тузан җыеп ятасы китапларны тиражлау да—бер генә сәгатькә баеп, акчасын ничек туздырырга белмәгән хәерче психологиясе чагылышы ул. «Хәерче акчасын арзанлы товар бетерә» дигән әйтем нәшрият хезмәтенә дә кагыла...

* * *

Китап бизнесын оештыруның хуҗалык рәвешенә игътибар итсәк, нәшрият, басмаханә һәм китап сәүдәсе бүген дәүләтнеке генә түгел. Аерым кешеләр (физик затлар), хосусый предприятие яки фирмалар (юридик затлар) аларның бер тармагы белән шөгыльләнеп ята яки тулаем колачларга омтыла. Татарстан Милли

китапханәсе мәгълүматлары буенча, мәсәлән, 2004 елда безнең республикада басылган 157 исемдәге әдәби китапның 90 ы, ягъни яртысыннан артыгы дәүләти булмаган нәшриятларда дөнья күргән (сүз, аңлашыла ки, аларның сыйфаты турында түгел, саны турында бара)...

Мантыйкый яктан, әлегә дәүләт карамагындагы нәшриятларының хәле әйбәтрәк булырга тиеш кебек. Әмма, мәгълүм сәбәпләр аркасында, дәүләт предприятиеләренең эшчәнлеге, хосусый фирмаларныкы белән чагыштырганда, күп яктан оттырышлы булып чыга. «Калхуз—дингез, без—парахут» формуласын белмәүчеләр сәерсенерлек күренеш: дәүләт нәшриятының хәле аерым басмаларга нәкъ менә дәүләт заказы саклануга бәйле рәвештә катлаулана. Чөнки Русия—«борчаны да дагалаучы» зирәкләр иле: дәүләт заказын «дөрес бүлү» өчен әллә нинди арадаш структуралар оештырып, һәртөрле «бәйге»ләр үткәргән булып, «мәгълүм сәбәпләр»не эшкә җиккәч, көтелгән нәтиҗәнең киресенә ирешү юлын табарга мөмкин. Мондый хәл нәшрият эшчәнлегенә генә карамый, билгеле. Ил белән шулай. «Кемдер алдый, кемдер алдана» торган базарда тереклек итәбез. (Коррупциягә каршы көрәшүнең ни-нәрсә икәнлеген күз алдына китерә алмаган килгән кеше булса, ул узган гасыр ахырында Кызыл мәйданнан провинциаль калаларга таралган «уймак астына яшерү» уенын—чынлап та уеннан уймак чыгарган афераны хәтеренә төшерә ала).

Шагыйрь әйтмешли, «акча исе килми» башласа, милли әдәбият һәм дәреслек (ягъни бюджет «бәлеше») тирәсендә «конкуренция» калмаячак. Китап битен акча санагандай капшаучы коммерсант-наширләр төшемлерәк бүтән эш эзләп китәр, «дөрес итеп бүлүче»ләр (алар өчен дә борчылмаска була) яна кәсеп табар... Нәтиҗә шул гына: идеология, мәгърифәт өлкәсендә дәүләт, башын комга яшергән тәвә кошы шикелле, матди авырлыклардан куркып (яки аларга сылтап), үз өстеннән җаваплылыкны төшерсә, бу — асылда илнең, милләтнең киләчәге турында кайгыртудан баш тарту булачак һәм юньлегә илтмәс дигән гап-гади фикер белән килешергә туры килә.

Юк, һичкем (шул исәптән нәшрият-матбага өлкәсендә дә) акчаны санамаска, канунны санламаска өндәми, бигрәк тә шәхси эшмәкәрләр тәгәрмәченә таяк тыгарга уйламый. Сүз бары тик, мәсәлән, кануннар яки рецептлар җыентыгы, орфография сүзлеге һәм мәктәп дәреслеге кебек үтә житди басмаларны нәшер итүгә җаваплы карашны югалтмау турында гына бара. Бигрәк тә «кыргый базар» этабында. Яшерен цехта куылган ялган «аракы» берничә алкашнең башына җитәргә мөмкин, «әштер-өштер» ясалган надан дәреслек исә бөтен бер буынны агуларга сәләтле.

Күргәнебезчә, хәтта китап сәүдәсе өлкәсендә дә «базар» бәяләре халык җилкәсенә өстәмә йөк булып төшә. Бүген, статистика мәгълүматлары буенча, Русиядә басылган китапларның 15 проценты гына кибет киштәсенә барып җитә икән. Калган өлеше, димәк, башка юллар белән тарала. Социаль юнәлешле һәм милли телдәге әдәбият белән сәүдә итүнең механизмы, системасы юклыктан, ата-аналар, балалар, студентлар мохтаҗ булган басмаларның бәясен берничә тапкыр арттырып сатучыларга юл ачыла. Яшерен-батырын түгел, дәүләт китап сәүдәсе шулай ук, артык хезмәт куймыйча, «милли-социаль» әдәбият тирәсендә «кул җылыту»дан тайчынмый.

Шул ук вакытта халык та, нәшриятлар да, рәхмәт укый-укый, алыпсатарлар кесәсен калынайтуга өлеш кертә булып чыга. Һәр авылда аракы кибете ача алганда, ни өчен бу мәсьәләне хәл итә алмыйбыз икән? Бездә дәүләт китап сәүдәсе системасы саклап калынды дигән мифик горурлык хөкем сөрә.

Нәшриятлар бу хезмәтнең нәтиҗәсеннән икътисади зыян гына күрә торган, дәүләт ярдәме белән бәясе арзанрак итеп куелган социаль эчтәлекле китапларны биш бәясенә сату мөмкинлеген тудырудан кемгә файда? Дәүләткәме, авторгамы, әлегә китап алудан бизмәгән укучыгамы? Сатучы алган табыш китап бастыру һәм таратуны үстерүгә китәме, халыкны агарту проблемасын хәл итүгә тотыламы?

Милли китап нәшер итү һәм аны сату мәшәкатьләре әлегә сыек сумалага баскан саесскан хәленә тартым шул: койрыгын куптарып алса, томшыгы ябыша...

Бу мәсьәләдә, «базар» кануннарына каршы килеп булса да, [ипи, сөт, ниһаять, шул

ук хәмер бәясе кебек] дәүләт көйләвенә өметләнәсе килә. Дәүләт хисабына чыгарылган милли китапны «куелган» бәя белән чыгарырга һәм [җәмәгатьчелек ярдәме белән] тәгаен билгеләнгән процент өстәп кенә сату шартын куярга мөмкин. Шулай ук дәүләт ярдәме белән дөнья күргән милли басмаларны авыл һәм мәктәп китапханәләре аша тарату-сатуны оештыру да—«феодаль-кыргый базар» дәверендә—рациональ юл булыр кебек тоела. Эстәгән кешегә китапның иң туры юлдан барып җитүенә дә, аны сатудан килгән азмы-күпме керемнең мәгърифәт йортларына бер терәк булуына да ирешер идек, бәлки. Һәм, алда әйтелгәнчә, һәр китапның интернет-китапханә аша иң ерак авылларга да барып җитүен тәэмин итү шулай ук халыкны мәдәни наданлыктан саклап калуның перспективалы, нәтиҗәле бер юлы булып күз алдына килә.

* * *

Русиядә китапны кулына тотып та карамаучылар саны «демократия» елларында бер ярым тапкырга (23 проценттан 34,2 процентка) арткан. Әллә нигә бер «ачып караучы»ларны да кушсаң (тагын 39,5%), укымаучылар өлеше 73,7 процент, ягъни дүрт кешенең өчесе булып чыга. Русиядә бүген 16 яшькә хәтле бер миллион ике йөз мең кеше укый-яза белми икән. Үзебезнең милләт көзгесенә карасак, андый статистика мәгълүм түгел, анализ белән шөгыльләнүче юктыр, күрәсең. Шулай да матбугатыбыз, китап басмаларыбызның ничек таралуыннан, югары уку йортындагы кавемдәш студентларның белем дәрәҗәсеннән азмы-күпме хәбәрдар кеше, Тукайга ияреп: «Халкыбыз шул бик надан»,- дип уфырырлык... (Гомумиләштерүгә дәгъва итмичә үткәрелгән бер ачы тәҗрибә: татар студентларының байтагы, мәсәлән, кешенең галәмгә беренче тапкыр кайчан очканлыгын якынча булса да белми, милли мәдәни мохиттан Азат Аббасов, Саҗидә Сөләйманова кебек шәхесләрнең кайсы өлкәдә танылган булуын әйтә алмый.)




*«Мәгариф» нәшрияты китапларыннан бер тамчы.*

Наширләр, милли газета-журнал редакцияләре, авторларыбыз—язучылар, галимнәр кемгә йөз тотып эшли? Кирәкме соң безнең хезмәт?

Илдәге һәртөрле реформалар, шул исәптән мәгариф өлкәсендәге «инновацияләр», мондый көнгә китердеме? Халыкның гомуми белем дәрәҗәсе кимү нинди зур икътисади һәм социаль проблемалар китереп чыгарасын бик яхшы аңлыйбыз лабаса!

80 нче еллар ахырында, үз илендә китап укуның торышы турында сөйләгәндә,

президент Рональд Рейган: «Америкага афәт яный!»—дип белдерә. 1989 ел «яшь укучы елы» дип игълан ителә, бу юнәлештәге чаралар, гаилә, мәктәп, китапханәләрне җәлеп итеп, мәдәният эшлекләләре, сәясәтчеләр, эшкуарлар, матбугат һәм телевидение чаралары, нәшриятлар катнашлыгында оештырыла. Шул ук елны АКШта Гаилә белеме фонды төзелә, ул аз укыган ата-аналар һәм балалар белән эшли. Конгресс Китапханәсе янындагы милли һәм халыкара дәрәҗәдә китап пропагандалаучы Китап үзәге (махсус хөкүмәт агентлыгы)—АКШ Белем бирү департаменты һәм Америка китапханәләр ассоциациясе белән бергәләп—1996 елдан башлангыч мәктәп балалары өчен махсус «Укы-яз-хәзер» дигән милли (дәүләткүләм) программаны гамәлгә ашыруга керешә. Президент хатыны («беренче леди») Милли Китап фестивалендә хуҗабикә—шәрәфле рәис сыйфатында катнаша.

Франциядә һәр өлкәнең мәдәният идарәсендә китап уку буенча киңәшче штаты бар икән. 1989 елдан башлап илдә «Уку бәйрәме» уздырыла, анда бихисап мәдәни идеяләр тормышка ашырыла. Франция энтузиастларының «Урамда китап уку»ы кебек, Норвегиядә—«Китап кибетендә уку», Испаниядә «Китап бүләк ит, роза бүләк ит» дигән даими акцияләр халыкны җәлеп итә. Германиядә мондый сәясәтне Немец Уку фонды дигән махсус оешма аша башкаралар. Нидерландта һәр елның мартында Балалар китабы атналыгы үткәрелә, өч иң яхшы балалар китабын 25 мең баладан торган жюри ачыклый.

Әле кайчан гына «дөньяда иң күп укучылар иле» сыйфатында саналган Русия—базар сәүдәгәрләре, кеше талаучылар һәм аларга «түбә» (русчасы крыша) булып гомер уздыручылар мәмләкәте генә булып калмасын өчен, бездә дә уку культы, белем сәясәте турында кайгыртырга вакыт житкәндер, шаять.

Шөкер, Татарстан хөкүмәте, алда әйтелгәнчә, махсус карар белән, милли һәм социаль әһәмиятле әдәбият нәшер итүне дәүләт яклавында тота. Китапханә фондларын яңарту өчен, һәр елны матди ярдәм күрсәтелә. Нәтиҗәле файдалана белмәсәк тә, 1992 ел Татар китабы елы дип игълан ителгән иде. Татарстан Милли китапханәсе республика һәм Русиядәге милли диаспора белән эшләүче китапханәчеләрнең «акыл казаны»на әверелде. Ул инде егерме елга якын үткәреп килүче «Ел китабы» конкурсы укучы белән автор һәм нашир арасын якынайта (форсаттан файдаланып, укучыларыбызга һәм китапханә хезмәткәрләренә рәхмәт әйтик: балалар китабы өлкәсендә һәр елны беренчелекне «Мәгариф» нәшрияты чыгарган басмаларга бирәләр).

Шулай да, күңел тәрәзәбездә ут сүнмәсен дисәк, китапны халыкка җиткерү өлкәсендә игътибардан читтә калган яисә, кабат-кабат күтәрелеп тә, әлегәчә чишелеш тапмаган мәсьәләләр барлыгын онытмаска тиешбез. Бигрәк тә Әдәбият һәм сәнгать елының мөмкинлекләрен игелекле гамәлләргә юнәлтәсе иде. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин белән [«Казан утлары»нда басылган] тирән эчтәлекле әңгәмәсендә Президент Минтимер Шәймиев: «Төп чара—чын әсәрне, эстетик кыйммәте һәм тәрбияви әһәмияте булган талантлы әсәрне халыкка җиткерүнең үтемле ысулларын табу...»,—дип кисәтә.

Чыннан да, без—олы мәдәни тарихлы, мәгърифәтле, китаплы халык, дип күкрәк кагу гына җитми, һәр зыялы милләттәшебезнең катнашында тарихи мәгърурлыкның бүгенге чынбарлыкта раслануына ирешик. Әдип язган әсәр, галим һәм мөгаллим төзегән дәреслек—Китап Сүзе уңдырышлы туфракка төшкән таза орлык булсын, аның шытымнары милләтебезнең башкалар арасында дәрәҗәсен сакларлык, арттырырлык нәтиҗә бирсен иде.

Хезмәтебез менә шул чакта гына чын иҗат ләззәте һәм кылган гамәлеңнән канәгатьләнү хисе алып киләчәк.

Үз көнебезне кабат Г. Тукайга нисбәтән карасак, моннан нәкъ йөз ел элек ул болай дип язган: «Милләтнең тәрәккыйсенә (алга китешенә) вә башка милләтләрнең аяклары астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә саваплы вә хәерле бер эштер».

Равил
Фәйзуллин

# ӘЙДӘҮЧЕ

*(Тәүфикъ Әйдинең күптомлыклары чыгу уңаеннан)*

Кайчак уйлап куясың: адәм баласы нилектән язу эшенә тотына икән? Дөньяны танып белүдә минем үзгә карашым, ачышым бар дипме? Тирә-юньне бүтәннәр күрә алмаганча образлы-сурәтләү сәләтен раслау өченме? Сүз тылсымы белән Жир йөзендә Матурлык арттырып Гаделлеккә көч өстәргә теләвеме аның? Күңеле уйнаклавымы? Язу эше, әллә аерым бер затларга гына бирелгән илаһи инстинктмы?.. Иҗат—бөтен нечкәлекләрен беркайчан да, беркем дә ачып бетерә алмаслык серле процесс, жанның үзгә халәте; шуна күрә иҗатчыда әлеге саналганнарның өлешчә һәркайсы да булырга мөмкин. Кешелек дөньясы безгә кадәр тудырган бихисап китаплар хәзинәсенә баксаң, әлеге сорауларга дәлил-җавапларны күпләп табарга була.



Әсәр, әйтик, шигырь, көтелмәгәндә, үзеннән-үзе җиңел генә туарга мөмкин. Икенче бер әсәрнең, хәтта кыска гына әсәрнең дә, газаплы кичерешләр аша, еллар дәвамында язылуы да бар. Кемнең ничек килеп чыга! Ярты гасыр буе диярлек язучылык иҗаты белән шөгыльләнгән кеше буларак каләмдәшләрнең төрлесе күрелде: фидакарь затларны да, көнлекчеләрне дә, талантларын исраф итүчеләрне дә, аз сәләт белән күпне дәгъвалаучыларны да... Арада сирәк булса да үтә зирәк, киләчәкне күзаллап, гомеренең һәр сәгатен, язган һәр сүзен, һәр җөмләсен, гомумән, һәр кылган гамәлен үзе инанган иҗтимагый максатка юнәлткән язучылар да булды. Мәшһүр милләттәшебез Тәүфикъ Әйди әнә шундыйлардан иде. Ул нәрсә өчен язганын тәгаен аңлап, язганыннан нинди нәтиҗә чыгарга мөмкинлеген анык фаразлап иҗат итте.

Тәүфикъ Әйдинең тормыш һәм иҗат юлы җиңелләрдән булмады. Яратылышы белән зыялы һәм әдип зат булса да, шушы табигый барлык-булганлыкны дөньялыкта раслар өчен ана биниһая көч, хезмәт куярга, «вакыт эчендәге вакытны табып» хәят кичерергә туры килде. Барысын да юклык ноктасыннан—нульдән башларга туры килсә дә, ничек тә юл ярырга, җинелмәскә, максатка ирешергә! Моның өчен Вакыт—озын гомер кирәк. Ә Вакыт дигәннәре санаулы... Алтмыш еллап гомер кичереп, аның күпме өлешен чын иҗатка багышлый алды икән Тәүфикъ? Күпкә җыелмыйдыр. Башта Кояш астында яшәү өчен хокук һәм урын даулау (ятимлек, качаклык, төрле мәктәпләрдә, төрле телләрдә белем эстәп йөрүләр), соңрак Ходай биргән сәләтнең ия-хуҗасы нәкъ ул икәнлеген эш белән раслау (китапханәче, эшләп укучы студент, укытучы, милиция хезмәткәре, журналист...) һәм, ниһаять, җан теләгән иҗат белән шөгыльләнеп, уй-фикерләренне дөньяга җиткерү (ирекле профессиональ язучы)... Бу тормышта, ир-ат буларак, тормыш арбасын тартасы, балалар үстереп, аларны кеше итәсе дә бар бит әле! Татар язучыларының бөтенесе диярлек, классик сүзләренчә, «без тормышның төбеннән күтәрелдек» дип әйтә ала. Белүемчә, Тәүфикъ Әйди гомеренең фәкать азак елларында

гына төп вакытын чын иҗатка бирә алды. Шулай да...

Тәүфикъ Әйдинең «Сайланма әсәрләр»ен янә актарып-карап чыгасың да «эшләп тә күрсәткән икән егет!» дип сокланып куясың. Унбер томлык хезмәт. Романнар, повестьлар, фәнни-популяр очерклар, юлъязмалар... Соңгы елларда күптомлыклар (күбрәк өч-биш томлыклар) күренгәләсә дә, әлегә унбер томы чыккан язучыбыз юк шикелле. Күләм дигәннәре күп нәрсә белдерсә дә, әлбәттә, хикмәт күләм-санда түгел, иң мөһиме—хезмәтләрнең мәгънәви көчендә, кирәклек дәрәҗәсендә, тарихи-иҗтимагый әһәмиятендә.

Дөньяда талантлы язучылар да, яхшы әсәрләр дә җитәрлек. Татар әдәбиятында да шулай бу хәл. Һәр һәйбәт әсәр кеше күңеленә тәэсир итми калмый. Димәк, ул әсәр үзенең тууын аклаган... Хәтер—хәтәр нәрсә, аннан качып булмый. Төрлечә искә алына элгәргеләр: кайберләре—фәлән исемдәге әсәре белән хәтергә килә, кайберәүләре—үзләре кызык шәхес буларак күз алдына баса. Ә менә кискен хәлләрдә, рухи сынауларда, тормыш һич тә «мәгънәсез, уен-көлке» булмаганда, бигрәк тә халык язмышы, киләчәк турында уйланганда, сирәк әсәрләр, сирәк шәхесләр искә төшә. Т. Әйди—әнә шул сирәк әдипләрнең берсе инде.

Әгәр, Тәүфикъ Әйди иҗатының төп асылы, әһәмияте нидә, дип сорасалар, җавабым бер: мәгълүм бер чорда татар дигән халыкның дөньяда барлыгын раслауда үзеннән саллы өлеш кертә алуында. Татар—аның бәгырендә. Күпләр үз туган телен дә оныткан заманда, Т. Әйди халык киләчәген—үз балаларының язмышына тиң итеп карый белде. Дәрдемәнд сүзләре белән әйтсәк, «татарлыкта татар угълы татармын» булып калды. Иҗатың ихлас икән, анда һәммә нәрсә ярылып ята. Т. Әйди хезмәтләреннән—мәкаләме ул, юлъязмамы—исемнәренә генә игътибар итегез. «Без тарихта эзлебез», «Бәхет бары туган илдә», «Төрки нигезне ныгытыйк», «Язмышыбыз үз кулыбызда», «Себер үзебезнеке», «Аһ, туган каумем газиз!», «Өмет—бары үзебездә»...

Инде томлыкларның төзелү тәртибе, эчтәлекләре турында берничә сүз әйтеп китик. Томлыкларның күбесе берничә әсәрдән гыйбарәт. Берсе, әйтик, сәяхәтнамәләр; берсе—мәшһүр шәхесләр турында тупланма; берсе—мәкалә-очерклар җыелмасы... Зуррак күләмлеләре, бу очракта романнар (алар өчәү), аерым томлыклар итеп бирелгән. Җөмләдән романнар турында берничә сүз. Т. Әйди—четерекле, күпләр кузгатырга базмаган темаларга алынды. Менә 90 нчы елларда дөнья күргән «Елан угы» романы (икенче том). Вакыйгалар үткән гасырның егерменче елларына карый. Аннотация-аңлатмада болай язылган: «сәяси детектив төсендә язылган бу әсәрдә милләттәшләребезнең Төркстанга революция экспортлауда катнашуы, сыйнфый көрәшне куертуның җирле халыкларга да, яңа битлек кигән колонизаторларга хезмәт итүче татарларга да бәхет китермәве, яңа фаҗигаләргә генә юл ачуы гәүдәләндерелә. Татарларның Төркстанда да ике тарафка аерылып, большевиклар һәм «басмачылар» сафында үзара көрәше, кан коюы тарихи саташу, адашулар нәтиҗәсе буларак сурәтләнә».

«Иблискә ришвәт» романы (өченче том) икенче дөнья сугышы вакытында немецларга әсир төшкән татар хәрбиләре турында. Мәгълүм булганча, өченче Рейх җитәкчеләре алардан Идел-Урал легионы төзеп, Советларга каршы көрәштерергә ниятли... Фаҗигаи хәлләр, гыйбрәтле язмышлар... «Нинди җир ул Ватан? Сатлыклар кемнәр? Татар хәрбиләре ни өчен легионга кергән? Әсирләрнең алман халкы белән бәйләнешләре нинди була?»—Автор әсәрендә әнә шундый сорауларга җавап эзли. Бишенче томга кергән әсәрләр—фәнни-популяр хезмәтләр җыелмасы. Анда «Гөлчәчәкләр иләндә кара болыт» (Болгарстан), «Дунай буендагы кардәшләр» (Румыния), «Исәнме, Гагаузстан!», «Оҗмах утравы» (Кипр-Кыбрыз) исемле язмалар тупланган. «Үткән һәм бүгенге заман, гореф-гадәтләр һәм мәдәният, вакыйгалар һәм шәхесләр, ерак җирләрдә яшәп яткан милләттәшләребез һәм кардәш төрек халыклары»—Т. Әйдинең бу томдагы «иҗат кишәрлеге» әнә шулар. Мәшһүр милләттәшләребезгә багышланган очерк-мәкаләләр кергән томлыкның аңлатмасына күз салсаң, анда бик ачык әйтелгән: «Бу китапта Шәркый Төркстан, Үзбәкстан, Себер, Идел-Урал буйларында яшәүче милләттәшләребез сурәтләнә. Алар бу тарафларда кайчан тамыр җибәргән? Нигә шундый чиксез киңлекләргә таралган? Саннары күпме? Башка халыклар арасында нинди урын билиләр? Ят һәм кардәш милләтләр белән мөнәсәбәтләре нинди? Горурланырлык казанышлары бармы? Автор әнә шундый күп кенә сорауларга җавап эзли, табышларын укучылары белән уртаклаша». Әйе, бу—Тәүфикъ Әйди стиле. Төпле, бөртекчән Тәүфикъ стиле.

Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттах тиккә генә болай язмагандыр: «Татарстаннан читтәге татарлар турында җентекләп, тәфсилләп һәм даими рәвештә Тәүфикъ Әйди яза... Кем турында гына сөйләмәсен, автор һәр эшнең, һәр профессиянең асылына төшенеп, үзе тасвирлаган шәхесләрнең социаль, тарихи һәм профессиональ мохитен күз алдына китереп бастыра. Шунлыктан Тәүфикъ Әйди әсәрләренең тәэсир итү, ышандыру көче зур».

Язучының яртылаш язылып тәмамланмыйча калган хезмәтләренең берсе— монарчы беркайда да басылмаган «Ак җилкән» әсәре. «Сайланмалар»ның дүртенче китабына кертелгән ул. Әсәрдә—20—30—50 нче елларда системалы рәвештә юк ителгән милли интеллигенция һәм алардан соң килгән «югалган буын» язмышы, һәм дә «курпы» булып калыккан яшь милли хәрәкәт хәлләре... Әйе, соңгы чор татар Ренессансы лидерларының берсе буларак Т. Әйдинең бу теманы күтәреп чыгуы табигый иде һәм көтелә дә иде. Шунысы игътибарга лаек: ул бу әсәрне үткән гасырның 80 нче еллар уртасында, партия диктатурасының бик ныклы чорында ук яза башлаган. Тема бик катлаулы һәм четерекле. Моңа тотыну өчен какшамас иманлы, курыкмас йөрәкле булу кирәк.

Башка томлыкларга килгәндә (санап китүемнең сәбәбе шул: бу мәгълүматлар, бәлки, кемнәргәдер томлыкларга юл күрсәткеч ролен үтәр), алардагы әсәрләрнең урнаштырылу тәртибе мондый: алтынчы том авторның Алмания, Эстония, Әстерхан яклары турында сәяхәтнамәләре; җиденче том тулысынча Төркиягә багышланган; «Ах, туган каумем газиз!» дип исемләнгән сигезенче том чит якларда яшәп иҗат итүче мәшһүр милләттәшләребез турында; тугызынчы томда Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан турында язмалар; унынчы том янә атаклы милләттәшләребез турында; унберенче том—төрле елларда көндәлек матбугатта чыккан мәкаләләр җыелмасы.

Язучы кеше, тумыштан талантлы булу белән бергә, үз заманындагы һәр үзгәрешләргә үтә сизгер, аның «күңел локаторы» һәр нәрсәне тота алырга тиеш. Бу сизгерлек, бәлки, талантның бер үзәк өлешедер дә әле. Хәзер дөньяда бер караганда табигый, икенче яктан сәеррәк тә процесслар бара. Шуның берсе— глобальләшү галәмәте. Кодрәтле җиһангирләрнең Кешелек Болынын тоташ сөреп, үзләренә хас бертөрле үлән-чәчәк (ягъни җәмгыять) булдырырга йөз тоткан дәвердә, икътисади яктан көчсезрәк, сан ягыннан азрак байтак халыклар ничек итеп үз йөзен, үз тарихын, үз генын саклау турында хәвефләнеп уйлана хәзер. Бу, әлбәттә, безгә дә кагыла. Мондый очракта, гадәттә, «мөтәпәйгамбәрләр»—«милләт аналары, милләт аталары» пәйда булучан. Шагыйрь әйтмешли, «кемдер, дин! ди, кемдер, мин! ди». Әлбәттә, исән-имин калуга булышкан һәр юл, һәр ысул, һәр идея файдалы. Әмма, ни генә булмасын, иң әүвәл нигез тамырларыңның ныклыгын, аларның яшәү көче дәрәҗәсен ачыклау фарыз. Бу очракта безнең өчен төп юл—төрки бердәмлекне ныгыту. Тәүфикъ Әйди моны бик күп акыллы башларга караганда алданрак тойган, аңлаган, гамәл кылган булып чыкты. Әдип иҗатын аркылыга-буйлыга карап-өйрәнеп чыксаң, моңа тиз инанасың. Ул кызыксынмаган, өйрәнмәгән берәр төрки халык бар микән? Дөресрәге, ул аяк басмаган төрки җирләр (ә ул җирләр иксез-чиксез!) калды микән? Мәсәлән, аз санлы гагауз дигән халык турында юньләп белә идекме? Ишетеп белсәк тә, алар тормышы хакында сирәкләребез хәбәрдар иде. Тәүфикъ Әйди янача «ачып» күрсәтте безгә ул халыкны. Әлбәттә, үзебезгә дә сабак, гыйбрәт алырлык иттереп... Зуррак санда исәпләнгән үзбәк, казах, әзәри, кыргыз кебек халыклар турында язуын әйткән дә юк. Ул алар белән нык аралашып, «тел-лөгать алмашып» яшәде, рухи тормышлары турында һәрдаим язып килде, атаклы кешеләрен үзенең хезмәтләрендә сурәтләде, аркадаш каләмдәшләренең әсәрләрен, турыдан-туры тәрҗемәләп, татар укучысына җиткерде. Иң мөһиме: уртак рухи байлыкны—тарихны, мәдәни ядкәрләрне туганнарча бәрәкәтле файдаланырга, үстерергә чакырды. Бу җәһәттән телебезне баету юнәлешендә үз иҗатында игелекле үрнәк тә күрсәтте: йөзләрчә төрки тамыры булган уртак сүзләрне әдәби әйләнешкә кертте, аларны янәдән тел хәзинәбезгә кайтарды.

Һәр чорның үз көе, үз җыры дигәндәй, әдәбият та бик нык үзгәрешләр кичерә хәзер. Эчтәлеге һәм иҗтимагый әһәмиятлелеге ягыннан гына түгел, шәкли-формалар үзгәрү ягыннан да. Әйтик, традицион жанрлар бер-берсенә керешеп, үзара синтезлашып яңалары туа, язу стиле торган саен лаконик төс ала бара. Үз вакытында Лев Толстойлар фаразлаганча, дөньяны танып белергә өйрәтә торган информация-

белешмәгә бай әдәбият туды. Тәүфикъ Әйди бу хәлне дә күпләргә караганда алданрак тоемлаган булса кирәк. Тарихи даталар, исемнәр, саннар, атамалар һ. б. кирәкле белешмә-хәбәр бихисап аның әсәрләрендә. Укучылар, бигрәк тә яшьрәк буын өчен әһәмияте зур андый язмаларның. Кемнедер эстон яки латыш язучылары кызыксындыра, кемгәдер Кытай яки Төркиядәге татарлар турында мәгълүмат кирәк... Рәхим итеп, Тәүфикъ Әйди әсәрләренә мөрәҗәгать ит, кирәксенгәннәреннән байтагын табарсың...

Әйе, Тәүфикъ Әйди бөтен дөнья буйлап татарны барлады, асыл зат ул-кызларын күтәрде, яшь буыннар үрнәк итәрлек маяклар эзләде. (Хәзерге вакытта нәтиҗәле эшләп килүче Бөтендөнья татарлары Конгрессы миссиясе инде!) Ул яхшы мәгънәдәге чын милләтче иде. Кемгәдер, бәлки, парадокс булып тоелыр: асылда, чын милләтче генә чын мәгънәдәге интернационалист була ала. Үз баласын юньләп багып тәрбия итә алмаган кеше ничек итеп бүтәннәр баласын сөя алсын, үз милләт-кавемен кадерли белмәгән адәм ничек башка халыкларны хөрмәтли алсын! Җентекләбрәк укып карагыз Әйди әсәрләрен: татар кешесе турында яза, үзе бүтән милләт вәкилләрен—казакъмы ул, эстонмы, немец яки японмы—нинди ихтирам күрсәтеп бәян итә! Шигарь формасында булмаса да, язучы-әдипнең төп эчке фикере шул: бу дөньяда халыкларыбызда булган иң яхшы сыйфатларны үзләштереп тату яши белик, үз милли йөзебезне югалтмыйча, киләчәк буыннарга уртак хәзинәбезне баетып калдырыйк! Ул әйтерсең лә безнең халыкның ЮНЕСКОдагы бер вәкиле. Чынлыкта да, Тәүфикъ Әйди, шартлар булган очракта, берәр зур илдә татарның вәкаләтле илчесе булып торырлык иде: буй-сын, килеш-кыяфәт, белем-интеллект, сабыр холык, чама хисе... Бәлки, ул чакта рәсми даирәләргә ошап та бетмәгәндер, әмма факт: Т. Әйди өендә чит республикалардан, чит илләрдән килгән әдипләр еш була иде. Күрәсең, илгизәрләрдә формаль очрашулардан тыш зур эрудицияле әдипләр белән ачыктан-ачык аралашу ихтыяҗы зур булгандыр. Әлбәттә, андый очрашулар эзсез үтми. Мәсәлән, 1989—1990 елларда Эстониядә Татар әдәбияты, Татарстанда Эстон әдәбияты көннәре узуында Т. Әйдинең өлеше зур дип уйлыйм мин.



*«Казан утлары»нда төрек әдибе Яхъя Акъэнгин белән очрашу истәлеге. Арткы рәттә сулдан беренче— Тәүфикъ Әйди. 29 апрель, 1991 ел.*

Күп йөргән—күп белгән, диләр. Күп белгәннең, әлбәттә, фикерләве дә колачлырак, тогәлрәк, дөреслеккә якынрак була. Әгәр без авыз тутырып татар әдәбияты дибез икән, ул инде, табигый, бөтентатар әдәбияты булырга тиеш. Һәр төбәктә яшәүче татар—Себердә яки Пенза якларында яшиме ул, Нижгар яки Ногай далаларында гомер кичерәме, аның үз итеп укырлык әсәрләре булырга тиеш татар әдәбияты хәзинәсендә. Бу—безнең өчен, язучылар өчен иң җитди, иң мөһим проблемаларның берсе. Татарстанның халык язучысы, халык рәссамы яки артисты булу бер нәрсә, ә син менә бөтен татар халкының абруйлысы булып кара! Тормышка ашкан очракта, тарихи да, саваплы да, шөһрәтле дә миссия була инде ул. Тәүфикъ Әйди әсәрләрен укыганда, мондый уйлар күңелгә еш килә.

Талант—Табигать бүләге. Иҗат кешеләре, алда әйтелгәнчә, үзләре бер дөнья тудырырга сәләтле, гаҗәп кызыклы, кабатланмас токым. Араларында төрлесе бар. Күзәнәкләренә нарциссылык сеңгәннәре дә җитәрлек. Андыйлар, гадәттә, халык язмышы, милли идея, иҗади миссия кебек «вак» нәрсәләр белән изаланып тормый: яздым—бетте! Калганы—алкышлар көтү... Иҗади эгоизм... Дәүләте, зур матди һәм рухи маясы булган халыкларга андый «иркәләр», сәерләр дә төстер... Французлар

Франсуа Вийонны да бөек ясаганнар. Ә безгә? Безнең язмыш, безнең юл бүтәнрәк, шактый ук бүтәнрәк шул... Тәүфикъ Әйди, боларны яхшы тоеп, халыкның егет улы буларак, аңлы рәвештә авыр юл сайлады. Уйлылар һәм күңеле нечкәләр өчен заманы да авыр иде. Демократия юк дәрәҗәсендә, рухи маяк—утопик һәм фальшь; асылда, берне сөйләп, икенче төрле гамәл кылып яшәгән заман. Хакыйкатьне ярып әйткәннең башыннан сыйпамыйлар. Күз-колак булучылар һәрвакыттагыча көчле һәм сизгер. Тәүфикъ Әйдинең тормыш рәвеше һәм иҗаты да һәрчак игътибар үзәгендә булды. Талкучылар да җитәрлек иде... Кайбер «бөек»ләр Сүз кодрәтен үз җанына нирвани халәт тудыру чарасы санаганда, Тәүфикъ Әйди Сүзне халыкның үзаңын үстерүдә бөек көч булганын раслар өчен яшәде. Аның өчен хак-тугры сүзнең кешеләр күңеленә барып ирешүе, гамәл-хәрәкәткә китерелүе кыйммәт иде. Язучының сүзе, белгеле, аның әсәрләрендә, басма китапларда, көндәлек матбугатта—газета-журналларда. Милли матбугатыбызны пропагандалауда Т. Әйдинең хезмәте әйтеп бетергесез зур. Эшчәнлегенең зур өлешен, бәлки әле иң күп вакытын алган өлешедер әле ул. Хәтерлим, 60 нчы еллар урталарында, җәйләрен, аркасына биштәр тулы газета-журналлар төяп, ул Чуваш, Мордовия, Мари якларында велосипедка утырып сәяхәтләр кылып йөрде, татар матбугатын таратты, халыкны үгетләде, өндәде... Мондый акцияне фәкать фидакарьләр генә эшли ала. Матбугат таратучы сыйфаты мәгънәле бер шөгыль булса, асылда, ул әлеге халыкларның яшәеш хәлләрен, үткәннәрен, бүгенгеләрен өйрәнде, тарихи яссылыктан карап аларның милләт буларак рухи потенциальләрен ачыкларга тырышты. Һәр халыкның тарихы үзе бер онытмаслык мисал-гыйбрәт бит! Үз халкыңның киләчәге өчен җан атып көрәшкәндә, һәр нәрсәнең—һәр вакыйганың, һәр фактның кирәге чыгуы бар...

Тәүфикъ Әйди турында язганда, үзеннән-үзе дигәндәй, шәхеснең җәмгыятьтәге урыны, роле турында да еш уйланылды. Без үскәндә,—үткән гасыр урталары була инде ул,—шактый еш сөйлиләр иде бу хакта. Тарихи вакыйгалар фонында шәхеснең ролен кечерәйтебрәк аңлаталар иде. Шәхес культының «чәчәк аткан» заманы югыйсә... Бәхәссез хакыйкать: теләсә нинди чорда да, билгеле бер шартлар булганда, әгәр бөтен җанын-тәнен, бар җегәрен бер максатка юнәлдерә икән, бер генә кеше дә (бер генә данә кеше дә!) күп эшли ала бу дөньяда! Тәүфикъ Әйдинең тормыштагы гамәлләре моңа мисал. Минемчә, Т. Әйди иҗатының, бу очракта мирасының, рухи мәгънәсе, икенче төрле әйткәндә, язылмаган васыяте шул: татарны фәкать татар үзе генә яклый-саклый ала; шуның өчен дә таралып яткан бу халык яһүдләр кебек тупланырга тиеш; иң әүвәл, милләтнең асыл затларын барлап, алар аша халыкның хакыйкый урынын дөньяга таныту зарур. Бу максатка милли идеяне (аңсыз ни халык, ни дәүләт, ни киләчәк юк) үстереп кенә ирешеп була. Аны үстерүнең бер ышанычлы чыганагы—ана телендәге матбугат. Ягъни татар телендәге басмалар—китаплар, газета-журналлар. Соңгы гасырларда халкыбыздагы дәүләтчелек геннарын югалттырмауда басма сүз, борынгыларча әйтсәк, китап сүзе төп рольләрнең берсен үтәп килде. Тәүфикъ Әйди киң катлауга, бигрәк тә яшь буынга, әнә шуны аңлатырга тырышты да. Бу җәһәттән милләтпәрвәрлеге, сәяхлеге белән аны күпмедер дәрәҗәдә Рәшит казый (Габдрәшит Ибраһимов) белән дә чагыштырып буладыр. Классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимов үзенең фамилиядәш адашын заманында «тарихи кыңгырау» дип бәяләсә, Тәүфикъ Әйдине исә без «тарихи бер төен», «Милләтнең ышанычлы, нык бер төене» дип әйтә алабыздыр. Т. Әйди үзе дә Рәшит казый турында сокланып язды, тормышы мажаралар, кыю гамәлләр белән тулы шәхес турында бүгенге укучыларга шактый мәгълүмат бирде. Ә андый шәхесләр Т. Әйдинең иҗат картотекасында дистәләп җыйнала. Татар җирендә туып-үсеп, төрки дөньяның мәшһүр галиме исәпләнгән Габделбари Баттал, Кытайда Мао-Цзедун даирәсендә югары пост биләгән Борһан Шәһиди... Моннан ун еллар элек Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, Тәүфикъ әле үзе исән чагында болай дип язып чыккан иде: «Т.Әйди кадерле шәхесләребезне бергә туплап сурәтләп, укучыларда милли горурлык хисе тәрбияләүдә җитди өлеш кертеп килә. Ул берчакта да коры, буш сүз сөйләми, фикерләрен, йомгакларын катгый дәлилләр белән сиплэп, ныгытып бара».

Тәүфикъ Әйди ниятләгәннәренең күбесен тормышка ашыра алмый китеп барды. Алда әйткәнемчә, табигатьтән бирелгәнне раслауга күп вакыты китте. Таяну ноктасыз башлаганнар язмышы. Юнәлеш анык булса да, юллар сикәлтәле, урау. Максатка ирешү юлында күпмедер дәрәҗәдә компромиссларга да барырга туры килә. Безнең чор каләм ияләре идеологик кайбер канун-тәртипләр белән исәпләшми булдыра алмый иде. Әйтик, фәлән төбәкнең, фәлән авылның үткәнен-бүгенгесен

язар өчен генә дә җеп очы ин әүвәл райкомнар, парткомнарга тоташа иде. Журналистның, язучының ак кәгазьдәге каләме белән бергә партия күзе ияреп барды. Бу нәрсә, табигый, Т.Әйдинең дә кайбер мәкалә-очеркларында, репортаж-юльязмаларында чагылыш тапмый калмады. Язучының кайбер юльязмаларында һәркем күрә алган, шулай ук төрле энциклопедия-сүзлекләрдән, белешмә-проспектлардан алынган мәгълүматлар артыккарак китә. Илләрне-җирләрне беренче барып күргәндә, андый «Америка ачу»лар буладыр ул. Бигрәк тә чит илләргә «тимер пәрдә»нен яна ачыла башлаган дәвердә... Хәер, беренче кичерешләрне, сабыйлар сүзе шикелле, дөресрәк була дип тә әйтәләр. Бу очракта безнең әдәбиятка хас мәгърифәтчелек традицияләренең яшәвен дә искә алырга кирәктер, мөгаен.

Тәүфикъ Әйди, күпләребез шикелле, журналист язучы. Яшәү һәм иҗат җепләребез көндәлек матбугатка бәйле. Бу урында «журналист язучы» төшенчәсенә ачыклык кертеп узыйк; күпләрнең бу тәгъбиргә үз стереотип карашы бар: журналист язучылар алар—көндәлек тормышны оператив яктыртып, мәкалә, очерк, документаль хикәя-повесть һ. б. язучы каләм ияләре. Нигездә, дөрес. Әмма бүтән төрдәгеләре дә бар газета-журналларда эшләүче әдипләрнең. Алар, галәттә, тирән белемле, оптимистик фикер йөртүче зур язучылар. Аларның күбесе тереклек итү хакына матбугатта ялланып эшләргә мәҗбүрләр (әйтик, татар халык шагыйре Илдар Юзеев, пенсиягә чыккач та, соңгы көннәренә кадәр диярлек редакцияләрдә эшләде). Тәүфикъ Әйдигә килсәк, ул журналларда эшләүче галим язучы иде. Әсәрләрендәге тормышка карата дәлилле тарихи караш, фәннилек, документальлек, фәлсәфи анализ шуны раслый. Язучыларыбыз арасында милләт исеменнән халыкара трибуналардан чыгыш ясый алырлык шәхесләр күп түгел. Т.Әйди Европа һәм Азиянең шактый илләрендә булып, төрле дәрәҗәдәге фәнни конференцияләрдә, симпозиумнарда чыгышлар ясады. Фәнни яктан нигезле, тарихи фактларга бай чыгышларын ишетеп, матбугатта, бигрәк тә төрки дөнья матбугатында басылган хезмәтләрен укып, галим-голәма аның фикерләре белән санлашырга мәҗбүр иде.

Т.Әйдинең байтак еллары Матбугат йортында узды. Кайбер редакцияләрдә («Татарстан» журналы, «Заман» газетасы) күпмедер хезмәт куйса да, гомеренең бастырып төп эшләгән урыны «Казан утлары» журналы булды. Күп көч куйды ул анда. Уникe елдан артык эшләү дәверендә, шаблонрак сүз белән әйтсәк, якты эз калдырды. Журналның кайбер рубрикалары, әйтик, «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә», «Чит илләрдәге милләттәшләребез иҗаты», турыдан-туры Т.Әйди инициативасы белән булдырылды, һәм ул материалларны туплаучысы да күп чак үзе булды. Һәм, әйтергә кирәк, Тәүфикъның күпчелек үз әсәрләре дә шушы журналда басылды, халыкка ирешеп танылу алды.

Танылу димәктән, әйтергә кирәк, үзенә тиешле бәя-хөрмәтне алмыйча, аны тоеп сөенү ләззәтен күрмичә китеп барды Тәүфикъ Рамазан улы. Бу урында олуг галимебез Миркасыйм Госмановның «Табышмакка әверелгән истәлек» дигән язмасындагы берничә юлны китереп узу урынлы булыр: «...үзе исән чакта гомум эшчәнлеге, конкрет иҗаты тиешле бәһасен ала алмаган, бәлки мәгълүм көчләр тарафыннан шәхесе гел кыерсытыла, эзәрлекләнә килгән, мәгәр шундый авыр шартларда да үз иманына тугрылыклы булып кала алган Тәүфикъ Әйди иҗаты алдында без һаман бурычлыбыз. Моны аңлый белү безнең ан дәрәҗәбезнең күрсәткече булыр».

Мин үзем Тәүфикъ Әйди белән кырык еллап белешеп, аралашып яшәгән кеше. Шуның ун елга якыны «Казан утлары» журналы редакциясендә якын хезмәттәшлектә үтте. Табындаш әшнәләр булмасак та, күп мәсьәләләрдә фикердәшләр идек, сынауларда бер-беребезгә таяна алырлыгыбызны тоеп яшәдек. 2001 елның язында, хастаханәдә каләмдәшләре арасыннан иң соңгы күрешкән кеше дә мин булдым шикелле. Хушлашыр алдыннан мин ишеткән иң соңгы сүзләре мондый иде: «Халкыбыз да безнең кырку шул, Равил...» Кырку... Бу сүзнең төп-төгәл мәгънәсен аңлап та бетермәдем ул чак. Хәзер дә тулысы белән аңлыйм, беләм дип әйтә алмыйм. Нинди мәгънәләр салып әйтте икән ул сүзне? Монысы инде ачылмаслык мәңгелек сер. Кырку... Тәүфикъ Әйди дигәч, еш искә төшә бу сүз. Сискәндерә дә, шомландыра да, уйландыра да ул мине... Андый чакларда әдипнең китапларын кулга алам, борчыган сорауларыма җаваплар эзлим.

Мәхмүт
Әхмәтҗанов

# ГАМИЛ АФЗАЛ ИҖАТЫНДА СӘЯСӘТ

Һәр иҗат әһеленең ничек, нинди шартларда шәхес булып формалашуы аның иҗатында да чагыла. Бәхәс юк, әмма большевистик режим хөкем сөргәндә язучылар «партиянең социаль заказын» үтәп, цензурадан куркып, эчке дөньяларын яшерәләр иде. Бу хәзерге заман «ачышларында» да үзен сиздерә. Күпләр үзләренең «мулла оныгы» булуын, туган-тумачаларының репрессия корбаннары икәнен ачыктан-ачык әйтә башлады. Һәм мондый хәл аларның иҗатларында шактый сизелә. Бигрәк тә сәясәткә бәйләнешле әсәрләрдә ачык күренә. Шул ук вакытта кайбер шагыйрьләр: «сәясәт—ул пычрак өлкә, шуңа күрә аның поэзия белән уртаклыгы булырга мөмкин түгел», диләр. Минемчә, мондый шагыйрь нәрсә ул сәясәт икәнне белми, яки бу өлкәгә аның «теше үтми».

Ленинның: «сәясәт бит—ул сыйныфлар, дәүләтләр, кешеләр арасындагы мөнәсәбәт», дигән сүзләре бар. Димәк, җәмгыятьтә яшәп, аның кагыйдәләреннән, таләпләреннән читләшеп булмый. Күптән түгел менә бер Татарстан халык шагыйренең әле генә дөнья күргән җыентыгына бәяләмә язарга туры килгән иде. Очрашкач ул болай диде: «Иҗатымның төп юнәлеше—лирика, ә сез сәяси якка басым ясагансыз». Бәхәскә керми генә мин аңа болай дидем: «лириканы күбебез ярата. Әмма коры хисләнүләрнең файдасы нәрсәдә икән?» Шагыйрь бәхәсләшмәде, тыныч кына юлын дәвам итте...

Шуны гына искә төшерү дә җитә—коммунистлар үз хакимлеге вакытында язучыларның иҗатына бик зур әһәмият бирә, аны күзәтә, «социаль заказлар»ын яшереп тә тормый иде. Шул ук вакытта иҗат кешеләренә уңай эш шартлары тудырырга да тырыша иде.

Менә шушы кечкенә керештән соң, бу язмабызның герое Гамил Афзал иҗаты турында фикерләребез белән уртаклашмакчы булабыз. Форсаты да бар—күптән түгел Татарстан китап нәшрияты Татарстанның халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Гамил Афзал сайланма әсәрләренең өчтомлыгын бастырып чыгарды. Бу очракта сүз нигездә әлеге китапларда тупланган әсәрләр тирәсендә барачак. Әмма аңа кадәр шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә күз салсак, дөрес булыр. Югарыда, язучыларның иҗаты аларның нинди шартларда шәхес булып формалашуына бәйләнгән, дигән идем бит.

Өчтомлыкның икенче томында «Юл башы» дигән истәлек басылган. Аның белән танышып чыккач шул билгеле булды: Гамилнең бабасы Афзал, чыгышы белән ярлылардан булса да, көн-төн эшләү хисабына шактый мал җыя. Улы Гыймадетдинне (шагыйрьнең әтисен) башка чыгарганда, аңа җил тегермәнен биргән, беразакча өстәгән. Димәк, узган гасырның 30 елларын күз алдында тотсак, Гыймадетдинның кулак булачагы көн кебек ачык, дип кистереп әйтә алабыз... Минемчә, нәкъ әнә шул нәрсә Гыймадетдин Афзалетдин улын тирән уйга сала, һәм ул, Себергә озатылу перспективасын яхшы аңлап, Көньяк Урал якларына юл тота (бу чакта Гамилгә 9 яшь була, малай әнисеннән 3 яшьтә ятим кала). Туган авылы Такталачык (Актаныш районы) белән гомерлеккә хушлаша...

Яңа урынны булачак шагыйрь болай тасвирлый: «1931 елның август ае. Менә без Магнитогорскида инде, бик озын баракта торабыз. Тормыш шартлары авыр». Күп нәрсәләрнең сәбәпләрен ул әле белми. Ә чынлыкта бирегә күчеп килүчеләрнең иң зур күпчелеге—«эксплуататор сыйныф вәкилләре»—кулаклар. Нинди генә уй-

мотив белән күчеп килмәсеннәр, аларны мактап телгә алырга була. Бу чакта уннарча миллион «эксплуататор сыйныф калдыклары» ГУЛАГта «гомер кичерә». «Коммунизмның кара китабы»нда әйтелгәнчә (М., 2000 ел) СССРдагы барлык гигант төзелешләр төрмәдә «сәясәт өчен» утыручылар кулы белән (ә ГУЛАГта даими рәвештә 13-14 миллион кеше утырган) төзелгән. Әлеге китапка керешне Политбюро карары белән большевистик режим вакытында репрессияләнгәннәрнең эшләрен карау комиссиясе җитәкчесе итеп билгеләнгән А. Н. Яковлев язган. Табигый, аның куллары аша миллионнарның «гаепләнү документлары» үткән.

Әмма да ләкин шагыйрь Г. Афзал шактый затлардан аермалы буларак, большевистик режимның илгә, халыкка никадәр зыян китерүен дөрес аңлаган һәм бу нәрсә аның иҗаты буенча кызыл җеп булып сузыла. Кайберәүләр әле бүген дә: «совет власте безгә белем бирде, һәммәбезне кеше итте», диләр. Әмма «капитализм кочагында яшәгән» японнарның 80 проценттан артыгы югары белемле икән, «белемне социализм гына бирә» дигән тезис белән килешүе кыен. Шул уңайдан югарыда телгә алынган А. Н. Яковлевка сүз бирик әле: «По сладкопениям о справедливости, братстве, равенстве был создан механизм с фашистско-большевистской идеологией... Когда спускаешься шаг за шагом в подземелье, полное человеческих костей и крови, то былая романтика улетучивается, как дым на ветру. И никакие достижения—будь то ликвидация неграмотности, полеты в космос и многие другое—никак не могут оправдать той свирепости, с которой уничтожался человек, уничтожался физически и духовно» *(А. Н. Яковлев. «По мощам и елей». М., 2000).*

Беркемне дә гаепләргә, кемгәдер үпкә белдерергә җыенмыйм. Әмма күпләрнең әле дә рәсми рәвештә илдәге «кызыл террор» вакытында эшләнгән вәхшилекләр хакындагы чыганаклар белән таныш булмавы сәер тоела. ГУЛАГ «тормышы» хакында рус телендә шактый китаплар чыкты. Татар телендә алар бик аз—Г. Тавлинның, А. Гыйләҗевның, И. Салаховның романнарын гына искә төшерергә була.

Гамил Афзал иҗаты белән киң җәмәгатьчелек яхшы таныш. Мин, мәсәлән, аның һәр китабын көтеп алам, яратып, күңел биреп укыйм. Моның бер төп сәбәбе шунда түгел микән: Гамил Афзалның шактый әсәрләре «сәяси эчтәлек белән» сугарылганнар. Ә бу өлкә мине бик кызыксындыра... Шуңа күрә бу очракта шагыйрьнең күпкырлы иҗатының сәясәткә кагылганнарына гына тукталмакчы булам. Сүз дә юк, әсәрләрнең сәнгатьчә югары кимәлдә булуы—шулай ук бик мөһим.

Шагыйрь поэзия дөньясына яңа гына аяк баскан вакытта үзенең «иҗат программасын» болайрак күзаллый:

*Күзләремнең нурын,*
*Йөрәгемнең моңын*
*Кураема салып җыр итәм.*
*Йөзем аклыгы да,*
*Күңелем шатлыгы да*
*Минем өчен шаян җыр икән.*

Бу өзек әлеге Сайланма әсәрләрнең I томыннан алынды. Томның яртысы—223 шигырь—«Лирика» бүлеген тәшкил итә. Әмма аларның да күпчелегендә «сәяси юмор» «чәчәк ата». «Үзем булып калдым» шигыре түбәндәгечә башлана:

*Гувернантлар карап үстермәде,*
*Француз сүзен өйрәтмәделәр.*
*Дугаларга кыңгыраулар тагып,*
*Ярминкәгә шартмәделәр.*

«Минем 100 тулгач язачак» шигырен дә елмаймыйча укып булмый. Рәхмәт шагыйрьгә, димәк, безнең дә 100 ел гомер котәргә хакыбыз бар, дип куясың...

Лирик шигырьләр арасында тарихка, тарихи шәхесләргә кагылганнары күңелне аеруча тарта. Татар халкы тарихына багышланган әсәрләрне сәясәткә бәйләнгән дисәк, һич тә арттыру булмас. «Болгарлар» дигән күләмле әсәр, «Болгар бәете»,

«Сөембикә сылу», «Салават Юлаев», «Шәехзадә Бабич», «Алтын бөртек», «Сарматлар» кебек шигырьләрне укыганда кемнең җаны тыныч калыр икән?

Китапның икенче яртысы, әйткәнебезчә, юмор-сатирага бай. Җәмгысы—250 шигырь. Аларның шактые халыкка бик таныш, чөнки сәхнәләрдән яңгырап, газета-журнал битләрендә күренеп күпләрнең күңелен яулады. Бу шигырьләрнең әхлаксызлыкка каршы булулары аеруча әһәмиятле. «Өф-өф итеп», «Юкка-барга», «Мыек борам», «Кызыл балчык» промартелендә», «Әкрен генә барган көйгә», «Мәүҗидәттәй», «Безне картайткан, йөзне саргайткан өч нәрсә» һәм башка уннарча шигырьләрне яттан белүчеләр дә аз түгел...

Шулай да авторның диапазоны күпкә киң, ул аерым шәхесләрне «тешләп» кенә калмый, иҗтимагый өлкәне дә колачлый. Болар, нигездә, җитәкче постына үрләгән урта куллар:

*Ул өч сәгать нотык сөйли алды,*
*Өч стакан суны чөмереп.*
*Ул һәрвакыт «алгы сафта» барды,*
*Өстәлдән өстәлгә йөгереп.*

1968 елда иҗат ителгән бу шигырь («Үрләттек») болай тәмамлана:

*Ул хәзер шәһәрдә, биектә,*
*Безләрне кубызда биетә:*
*Ел буе шелтәләр яудыра,*
*Сүгәргә чакыртып алдыра.*

Большевистик режим хөкем сөргәндә туган төбәгең, мәсәлән, республикаң, аның мәркәзе хакында язу, сөйләү искиткеч хәтәр нәрсә иде. Украинаның иң күренекле шагыйре В. Сосюра «Минем Украинам» дигән дүрт куплетлы шигыре өчен партиядән куылды. Сталин исән булмагач, атуын атмасалар да, китапларын басмадылар, кыскасы, ачлыкка дучар иттеләр. «Тартай арбасы» дигән кечкенә шигыре өчен Ш. Маннур да күп газаплар күрде. Шундый ук хәлгә С. Баттал да дучар булды... Шагыйрьләр үз әсәрләрендә «бөек рус халкын», партия җитәкчеләрен, Мәскәүне мактап телгә алу «ярышлары» оештырдылар. Катнаш никахны мактау бисмилла дәрәҗәсенә житкерелде, шул хакта янадан яна җырлар язылды. Казанга конференция, киңәшмәгә килүчеләрне партия өлкә комитеты секретарлары: «Казан җиренә аяк басуыгыз белән сезне котлыйбыз, үзегезне туган төбәгегездәгедәй хис итегез» дип каршы алалар, Татарстан турында ләм-мим сүз әйтелми иде. Чөнки «совет халкы интернационализм рухы белән сугарылган», ә андыйларга, аңлашыла ки, милли хисләр ят күренеш...

Г. Афзал соңрак, демократия җилләре исә башлагач, «Татар халкын яратам» дигән шигырь язды. Анда мондый юллар бар:

*«Татар халкын яратам» дип әйтү*
*Баш китәрлек хәтәр сүз иде.*
*Һәр ярыкта ач кандала кебек,*
*Озын колак, очлы күз иде.*
*«Туган халкым» дигән егетләрне*
*Ай күрде, кояш алды.*
*Якадан борып алды да*
*Илтеп дәрьяга салды.*

Миңа халык язучысы, демократ фикерле Гомәр ага Бәширов белән 15 ел буе якын күрше булып яшәү бәхете тиде. Моның өчен язмышыма чиксез рәхмәтлемен. Гомәр ага «кызыл террор» чорын кичергән кеше. «Бервакыт,—диде ул,—«Совет әдәбияты» журналы хезмәткәрләреннән бер үзем торып калдым. Хезмәткәр берике көн эшкә килми икән, аның Черек күл базында иканенә төшенәсен. Ләкин аның кайдалыгы белән кызыксынып булмый, «озын күзләләр» шундук «тиешле урынга» хәбәр итәчәкләр, «әнә ул халык дошманын яклый», диячәкләр. 1937-1938

еллар мәхшәрен ничек исән-имин үткәргәнбездер, күнел әле дә ышанып житми. Ул чакта гаиләм белән—4 кеше—Акком асты урамындагы бер бүлмәле фатирда яшәдек. Төнге 12-1 гә кадәр күзгә йокы керми, Кәримә (хатыным) пәрдә читеннән генә «кара козгыннарнын» кайсы якка юл алуын карый. «Аллага шөкер, бүген дә безгә туктамадылар»,—ди. Һәм тик шуннан сон гына йоклап китә идек».

Шул заманны искә төшереп Г. Афзал болай ди:

*Сталин сурәтен күтәреп йөрдек,*
*«Ура» кычкырдык, барабан кактык,*
*Эч тулы шатлык иде,—ди.*

Гамил Афзалны «татар-башкорт мөнәсәбәтләре» дә борчый. Актанышны Башкортстаннан Сөн елгасы гына аерып тора. Бу ике тугандаш халык гомер-бакый дустанә яшәгән, патша золымына каршы бергә көрәшкән. Жир-су күп, бүләсе берни дә юк. Әмма татар белән башкортнын дус яшәвеннән, димәк, нык көчәеп китүеннән урыс түрәләре уттан курыккандай курыкканнар. Нәкъ бүгенге кебек! Патшабикә Анна Иоановна башкорт кызларын татар егетләренә бирүне тыя торган фәрман чыгарган. «Татар күбрәк санлы, шуна күрә ул башкортны йотып бетерәчәк» дигән примитив ялган даими күпертелеп торган. Кызганычы шул—әлеге провокация кармагына кабучылар әле дә бар... Сонгы елларда бу хәтта көчәеп тә китте.

Югыйсә монa бер генә объектив сәбәп тә юк. Әмма башкорт галимнәренең бер төркеме Россия президенты В. В. Путинга махсус хат белән мөрәжәгать итте һәм анын тулы тексты матбугат битләрендә басылып чыкты. Анда төп фикерләре мондый: «татарлар гомер-гомергә бөек Туран дәүләте төзү уе белән яндылар. Аларнын бу дәүләтенә Кавказ мөселманнары, Казахстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Башкортстан керергә тиеш иде. Әмма бу омтылышка һәрчак урыслар каршы чыкты, ә без аларнын ышанычлы союзниклары булдык. Бу мәсьәләдә без бүген дә Мәскәү белән бер сафта». Башкорт шовинистларынын бу пычрак пасквиле дөнья жәмәгатьчелегендә жирәнү хисләре генә уятты. Бу беркемгә дә сер түгел—Башкортстан татарларынын хокукларын чикләү юнәлешендә, хөкүмәт дәрәжәсендә күпкырлы үзмаксатчан эш алып барыла. Бу хакта Мәскәүгә туктаусыз хатлар ява. Хәтта пикетлар үткәрелә. Әмма Үзәк мыек та бормый, чөнки башкорт түрәләренен явыз эше анын сәясәтенә бик нык туры килә. Г. Афзал бу хакта менә нәрсә ди:

*Идел-Урал буе дала иде,*
*Татар-башкорт игезәк бала иде.*
*Хәзер башкорт эте өреп тора,*
*Иван дәдәй сөенеп, йөреп тора.*

Сәясәтне «мөгезеннән тотып», әдип болай дип тә өсти:

*Бүлгәлә дә хакимлек ит,*
*Мәкерле кара йөрәк.*
*Татар-башкорт арасына*
*Чөй кагу сиңа кирәк.*
*Бертуганнар дошманлашып,*
*Ызгышып торсын икән,*
*Бүрек салып, бөгелә-сыгыла*
*Сиңа баш орсын икән...*

Халык Мәскәү алдында куркып-тетрәп торсын өчен, аны милләтчелектә гаепләү даими бүкәйгә-куркыткычка әверелде. Узган гасырнын 30-40 елларында татар ижат әһелләренен ин каймагы—яртысыннан артыгы юк ителде. Алар арасында энциклопедик белемгә ия булган кеше—әнкәйнен якын туганы—Нигъмәт Хәким 1937 елнын 3 августында Мәскәүдә Любянка базында атылды. Янәсе, ул 1919 елда Себердә Тубылга карый торган Еланлы авылы укытучысы авызыннан «Идегәй»

дастанының тулы нөсхәсен язып алган, димәк, татар феодалларын идеаллаштырган... Ә урысларда андый югалту 10 проценттан артмый...

Шагыйрь урыс империясе кысаларында (СССРның урыс империясе булуы беркемдә дә шик тудырмый...) көн иткән халкыбыз язмышын болай тасвирлый:

*«Панисламист» идем, «пантюркист» идем,*
*Себер юлларында сөргендә йөрдем,*
*Киндер күлмәк кидем, кәләпүш кидем,*
*Ясаклар түләдем, төрмәләр күрдем.*

Империя үзенең колонияләрен теләгәнчә изә. Ташкентта булганда, үзбәк кышлакларына да бардым. Аларның ишек алдыннан ук пахта-мамык басулары башлана. Студентлар, мәктәп укучылары яңа елга кадәр пахта җыю белән шөгыльләнәләр. Ә Ташкент кибетләрендә товарның һич тә Казандагыдан артык булмавын күреп, гаҗәпләндем. Хәер, бу аңлашыла да, 5 миллион тоннадан артык җыелган мамык иң элек Мәскәүгә, Ивановога, Ярославльгә һ. б. шәһәрләргә озатыла. Мондый күрсәтмәне СССР Госпланы бирә... Алма-Атада да шундый күренешкә тап булдык. Ун миллионнарча куй, эре мөгезле хайван асраган Казахстанның башкаласы Алма-Ата кибетләрендә ит юк, аның өчен казах дуслар да Мәскәүгә оча икән...

Бер шигырендә Г. Афзал болай ди:

*Безнең шәһәр бакчасында скрипкә, думбра шул,*
*Безнең нефть акчасына*
*Мәскәү тамак туйдыра,*
*Алтын ташлар куйдыра.*

Шагыйрь тулысынча хаклы. Елына 100 миллион тонна нефть чыгарган республикабызда нефть эшкәртү заводы булмау аңлы рәвештә алып барылган сәясәт иде. Беренчедән, эшкәртелмәгән нефтьнең хакы түбән, икенчедән, бензин сорап, Госпланга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә ул «сездә нефть чыга, димәк, сезгә ниндидер ташламалар булырга тиеш» дип уйламый да. Нефть эшкәртү заводлары Мәскәүдә, Рязаньда төзелде.

Россия халкы революциягә кадәр дә авыр тормышта яшәгән. Төп халык эчкән, аңа дингез тубыктан булган. Ә башкалар җирсезлектән интеккән. Революциядән соң авыл халкын, мәсәлән, колхоз җавапсызлыкка өйрәтте: икмәк күпме генә үсмәсен, бөртегенә кадәр дәүләткә тапшыргач, халык әкренләп намуслы эшләүдән туктады. Комбайн, трактор кар астында кала икән, җәл түгел, чөнки алар аныкы түгел! Ә Даниядә һәммәсе дә урынында. Укыганым бар: аэродромнарның очу полосасы арасында аз гына җир кала һәм аның һәр сантиметры уңыш бирә икән... Европада Голландия дигән ил бар. Аны күбрәк Нидерланды дип йөртәләр. Безнең телгә күчерсәк, Түбәнлекләр иле дигәнгә туры килә. Чыннан да, җирнең шактый өлеше (Голландиянең мәйданы—41,2 мең кв. км., халкы 15 миллион чамасы) дингездән түбәнрәк җирләргә туры килә. Алар дингезнең эченә кереп буа буганнар да, суын насослар белән суыртканнар—коры җир ясаганнар. Әмма дингез суы барыбер әлеге җирләргә үтә икән. Шул суны янадан дингезгә куу өчен тәүлек буе җил көче белән эшли торган 20 мең насос куелган. Элек дингез төбе булган җирләрдә хәзер бөтен җир шарын тәэмин итәрлек күләмдә тюльпан-лалә чәчәкләре үстерелә!

Безгә дә Европа халыкларыннан, «Азия драконнары»ннан өйрәнәсе иде дә бит. Әмма әлегә алгы планда—эчү, урлашу, кеше үтерү. Шуңа күрә шагыйрь үзенең түбәндәге сүзләре белән тулысынча хаклы:

*Халык эшләп тапкан дөнья малы*
*Тау-тау булып ята кадерсез.*
*Урын юк бит, кая куйыйк аны,*
*Әйдә, ятсын, дисез хәзер сез.*

Кызганыч, мондый хәл бүген дә дәвам итә. Кайберәүләр, Россиянең үз юлы бар, көнбатыш стандарты безгә ярамый, диләр. Бу инде «ата казыгыз йомырка саламы?»—дигәнгә туры килә. Ф. Тютчевның: «Россию умом не понять, аршином не измерить»,—дигән сүзләрен искә төшерергә яратучылар бар. Әмма ни өчендер әлеге шигырьне тулысынча китермиләр. Ә шагыйрь бит, Россия патриоты буларак, әгәр хәлләр унай якка үзгәрмәсә, Россия яшәүдән туктаячак, дигән. Һәм монда да әлләни яналык юк—дөньяда бер генә империя дә сакланып калмаган. Аларның иң озак яшәгәне—Рим империясе (510 ел). Инде Россия, империя буларак тарала икән, бу әле урыс халкы бетә дигән сүз түгел. Күз алдында: икенче бөтендөнья сугышыннан соң Бөек Британия, Франция, Италия, Португалия, Бельгия, Голландия империяләре таркалды. Метрополияләр, башка юл юк икәненә инангач, кан түкми генә колонияләренә ирек бирделәр. Без мона искиткеч шатланган, колонияләреннән колак каккан метрополия халыклары ачлыкка дучар булырлар, димәк, властьларга ныклы басым ясарлар дип өметләнгән идек. Әмма бөтенләй башкача килеп чыкты—элекке метрополия халыкларының тормышы күпкә яхшырды. Чөнки колонияләрдә зур армияләр, чиновниклар тотасы юк. Хәзер андый кайгы бетте. Ә бүгенге урыс империясе, гадәттәгечә, колонияләрен буйсындырып тоту өчен зур армия тотарга мәҗбүр. Тик файдасы гына юк... Шагыйрь дә әле күптән түгел булганнарны болай искә төшерә:

*Россиядә чират, чират, чират.*
*Сүгенә-сүгенә чират тора ир-ат.*
*Гомер буе ашау өчен ызгыш—*
*Рәхәт инде социалистик тормыш!*

Кем ничек кенә уйламасын, планнар кормасын, чынбарлык шуннан гыйбарәт—без Урыс империясенең үзәгендә урнашкан. Димәк, Россия дә, Татарстаныбыз да—безнең Ватан. Киләчәктә иҗтимагый үсеш законнары нәрсәләр майтарыр—әлегә билгесез. Әмма әнә шул шартларда халкыбызны саклап калу—безнең төп бурыч. Нык борчылырга урын бар: миллион ярымлы Казан халкының иң зур күпчелеге урысча гына сөйләшә, татар әдәбиятын, сәнгатен белми. Менталитеты да безнеке түгел. Һәм мона әлләни гаҗәпләнәсе дә юк: кызларыбызның—44, егетләребезнең 42 проценты—ятлар кочагында. Алар өчен милләт юк, алар—«пролетар интернационалистлар». Кыскасы, бүгенге татар зыялыларын иң борчыган нәрсә—халкын саклап калу.

Югарыда әйтелгәнчә, тел бетү белән шул халык үзе дә бетә. Дөрес, аерым очракларда «тел аксаса да», милләт саклана. Мисалы—яһүдләр. Моннан ике мең ярым еллар элек Рим империясе Израиль-Иудея илен басып ала. Шуннан соң халык бөтен дөньяга тарала. Әмма әлеге дәүләтнең зыялылары югалып калмыйлар, «яңа шартларда ничек яһүд халкын саклап калырга?» дигән мәсьәләне тикшерү өчен югары дәрәҗәдәге раввиннар (дин әһелләре) һәм тар-мар ителгән армиянең җитәкчеләре яшерен киңәшмә үткәрәләр. Проблеманы һәрьяклап тикшергәч, тиешле карарлар да кабул ителә. Күренекле немец язучысы, милләте белән яһүд булган Лион Файхетвангер үзенең бер әсәрендә әлеге яшерен корылтай кабул иткән карарларның кайберләрен бәян итә. Менә шуларның бер-икесе: 1. И син, яһүд кешесе, кайда гына яшәсән дә, шуны бел: синең илең бар, вакыты житкәч, син үз ватанына кайтырсың. 2. И син, яһүд кешесе, кайда гына көн итсән дә, һәр яһүдне якын туганың кебек күр һәм аңа һәртөрле ярдәм ит.

Моны беркем дә кире кага алмас—яһүдләр үзара бик дуслар, бер-беренә ярдәм итүне изге бурычлары итеп саныйлар. Бүген дә аларның рәсми булмаган оешмалары һәр шәһәрдә бар. Алар сәясәт белән шөгыльләнми, үзара ярдәм итү, (мәсәлән, яшь гаиләләргә чын мәгънәсендә ачык йөз күрсәтү, һәрьяклап булышу)—аларга бик хас. Мина үз гомеремдә яһүдләр белән шактый аралашырга туры килде. Бер генә яһүднең дә милләттәшенә зыян китерү очрагына тап булмадым. Нәтиҗә шул: яһүдләрдә милли үзаң искиткеч югары—бездә нәкъ киресенчә! Бу исә аларга тарихи ватаннары булган җирдә икенче бөтендөнья сугышыннан соң Израиль дәүләтен

аякка бастырырга юл ачты. Хәзер бу ил якын Көнчыгыштагы иң көчле дәүләт. Шуның бер төп сәбәбе—төрле илләрдәге яһүд байлары (бигрәк тә АКШ, Англия, Голландия, Франция миллиардерлары) Израильгә зур күләмдә даими рәвештә матди һәм сәяси ярдәм күрсәтә. Әйе, бу дәүләтнең шактый зур проблемасы бар—мәйдан бик кечкенә: 6 миллион яһүд халкы 14 мең кв. км. җирдә яшәргә мәҗбүр.

Әйе, безнең—бүгенге татарларның—иң «йомшак ягы»—милли үзаңның искиткеч дәрәҗәдә түбән булуы. Әмма бу «элекке авырулар»ның дәвамы гына... Бервакыт миңа күренекле казан тарихчысы, «Казанские татары» дигән китап авторы—профессор Н. Воробьев белән пароходта Уфага барырга туры килгән иде. 4 көн буе бу зур галим белән күп нәрсәләр хакында фикер уртаклаштык. «Казан татарлары язмышы» мәсьәләсен ул үзе күтәрде һәм болай диде: «сездә, Казан ханлыгын басып алган өчен, урысларга үпкә хисләре бардыр. Моны аңларга була. Әйе, безнең халык та ак канатлы фәрештә түгел. Ләкин тарихи үткәннәрне кире кайтарып та булмый. Үч алу теләге дә перспективасыз һәм мәгънәсез. Чөнки татарларның яртысы катнаш никах төзегән. Татарстан—СССРның уртасындагы бер нокта гына. Чынбарлык шуннан гыйбарәт. Юл бер генә—дустанә мөнәсәбәттә яшәү... Инде үткәннәргә килсәк, Казан ханлыгының язмышы татарларның үзләренә бәйләнгән. Татар морзаларының шактые үз теләге белән Иван Грозный ягына чыга. Андый хәл булмаса, урыс патшасы Казанга һөҗүм итмәс иде. Әстерхан ханлыгы да Казанны дус күрмәгән. Себер татарлары, Кырым турында да шул ук сүзләрне кабатларга булыр иде... Алтын Урда туктаусыз эчке ызгышлар аркасында җимерелсә, Казан ханлыгының язмышы шуны кабатлау гына иде»,—диде профессор һәм күпсанлы мисаллар китерде. Аның фикерләре шик тудырырлык түгел иде.

Әмма гаҗәбе шул: бүген дә агай-энеңең бер өлеше теге замандагы хаталарны кабатлый. Мәскәүгә донос артыннан донос яза, туктаусыз судлаша... Боларның һәммәсе дә милләтебезнең язмышы кыл өстендә торган вакытта дәвам итә!

Г. Афзал шул уңайдан Бөтендөнья Татар Конгрессына багышлап шигырь яза. Анда мондый чакыру бар:

*Биек тауга менеп, ташка басып,*
*Кычкырасым килә өмматкә:*
*Таралышмыйк инде читкә качып,*
*Җыелыгыз туган төбәккә!*

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң борынгы цивилизация үзәге булган Мисыр иле Бөекбритания колониясе булудан туктый, бәйсезлек ала. Шул уңайдан яңа республиканың беренче президенты Габдел Насыйрга журналистлар мондый сорау белән мөрәҗәгать итә: «Президент әфәнде, сез эшне нәрсәдән башламакчы буласыз?». Ул болай дип җавап бирә: «Иң мөһим, иң авыр бурыч—кешеләр аңында йөзәр еллар буе формалашкан коллык психологиясен бетерү».

Әйе, безгә дә яшәргә, алга карарга кирәк. Г. Афзалның программасы исә болайрак:

*Җиң сызганып, билне буып,*
*Җирне тазартасы бар.*
*Хуҗа булып, кеше булып,*
*Иман яңартасы бар.*
*Тазарткач барасы юлны,*
*Илне сугарасы бар.*
*Күңелдәге күндәм колны*
*Куып чыгарасы бар!*

—ди шагыйрь. «Олы талант иясе булган Гамил Афзалга, рәхмәт!» дия-дия аның якты рухы алдында хөрмәт белән башыбызны иябез.



# Фатих Урманче

## «ФӘРЕШТӘЛӘР САНАП БАРА КҮЗ ЯШЕН...»

Моннан биш еллар элек без: «Дөнья әдәбиятында Сөембикәгә багышланган ике генә поэма мәгълүм»,—дип язып чыккан идек. Шуларның беренчесе—XVIII йөз урыс классицизмы вәкиле тарафыннан язылган «Россия»да. Ул беренче мәртәбә 1779 елда зур форматлы һәм 288 битле аерым китап буларак нәшер ителә... Шуннан соң ике гасырдан артык вакыт уза һәм XX гасырның сиксәненче еллары ахырында татар шагыйре Әхмәт Рәшитнең «Сөембикә» поэмасы дөнья күрә... Соңгы елларда Сөембикә ханбикә язмышы белән бәйле поэмалар исемлегенә Зиннур Мансуровның «Ике еглау» әсәре дә өстәлде.

### Поэманың тарихи нигезе һәм эчтәлеге

Әсәрнең «Башлам» дип аталган кереше түбәндәге юллар белән ачыла:

*Җиде икълим чиген иңләп иңрәү йөри,*
*иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.*
*Мәшрикъ якны тоташтырып мәгърип якка,*
*кара-каршы ике бикәч еглаша.*

«Башлам»ның эмоциональ яңгырашына, югары шигъри стиль белән бәйләнгән борынгы архаик сүзләргә һәм гыйбарәләргә игътибар итсәк, сүз, күрәсең, бик күптән булып узган трагик вакыйгалар хакында барадыр, дигән нәтиҗәгә киләсең. Һәм, чыннан да, шагыйрь өчен беренчел җитди чыганак ролен борынгы урыс әдәбиятының классик әсәре дип саналган «Игорь полкы турында сүз» («Слово о полку Игореве») поэмасы үти. Анда исә сүз кенәз Игорь Святославичның (1150-1202) 1185 елда кыпчакларга каршы мәгънәсез, нәтиҗәсезлеге үзеннән-үзе күренеп торган яуга чыгуы, тулысынча тар-мар ителүе һәм әсирлеккә эләгүе турында бара. Бер айдан соң ул әсирлектән качып котыла. Әнә шул 1185 елда булып узган тарихи вакыйгалар турында сөйләүче поэма борынгы урыс әдәбиятының иң гүзәл һәм иң әһәмиятле әсәре дип санала.

Кенәз Игорь әсирлектә әлләни авыр шартларда яшәмәгән булса кирәк. Аны саклап тору да күз буяу өчен генә оештырылган булырга тиеш: югыйсә ул бер айдан соң ук качып котыла алмаган булыр иде... Икенчедән, әсирлеккә кенәз үзенең олы улы Владимир белән бергә эләгә һәм... аны шул тоткынлыкта калдырып кача. Ә кенәз улы атасының кан дошманы булган (?) Көнчак ханның кызына—кыпчак кызына—өйләнеп, 1187 елда ук туган иленә әйләнеп кайта.

Поэманың тарихи нигезләрен тәшкил иткән әлеге вак-төяк вакыйгалар турында

уйлана башласаң: бәй, бу бит XVII—XVIII йөзләрдә Европада киң таралыш тапкан водевиль сюжеты түгелме соң?—дип уйлап куярга мәҗбүр буласың... Теләсәң-теләмәсәң дә, борынгы урыс әдәбиятының тарихын һәм теориясен тирәнтен белгән, киң эрудицияле танылган галим О. В. Твороговның әсәрнең тарихи нигезләре турындагы түбәндәге сүзләренә мөрәҗәгать итәргә туры килә: «Игорь полкы турында сүз» поэмасы урыс-кыпчак мөнәсәбәтләрендәге бер очраклы күренеш-эпизодны гына чагылдыра. Аның иҗтимагый һәм тарихи әһәмияте дә шуның белән генә билгеләнә. Шулай булгач, әлеге поэманы күкләргә чөеп мактарлык урын да калмый кебек...

Поэманың икенче персонажы-героинясы Ярославна—кенәз Игорьның икенче хатыны, заманында кыюлыгы, батырлыгы, венгрларга һәм кыпчакларга каршы 12 сугышта катнашып чыныккан «кенәз галицкий» Ярослав Осмомысл (?—1187) кызы. Ире кенәз Игорьның мәгънәсез яуга чыгып, кыпчаклар тарафыннан тар-мар ителүе һәм әсирлеккә эләгүе турындагы хәбәр Ярославнага килеп ирешкәч, ул тирән кайгыга бата, борчыла, елый. Шушы уңайдан «Слово»да Ярославна елавының кыска гына, китапта нибары бер бит тирәсе, тексты китерелә. Байтак урыс галимнәре фикеренчә, шигъри-стилистик яктан бу елау борынгы урыс язма әдәбияты традицияләреннән шактый ерак тора. Аның поэтикасы, әдәби-шигъри үзенчәлекләре тулысынча урыс фольклоры традицияләренә нигезләнә. Кыска гына вакытка булса да (бер ай!) сөекле иреннән аерылган Ярославна Җилгә, Днепр суларына, Кояшка мөрәҗәгать итеп, алардан әсирлектә интеккән иренә ярдәм күрсәтүләрен үтенә.

Ә инде Зиннур Мансуров поэмасында киң чагылыш тапкан Сөембикә ханбикә елауларына килсәк, алар безнең тарихи хезмәтләрдә, проза, шигырь, пьеса һәм башка әсәрләрдә киң һәм тирән чагыла. Тик биредә шуны әйтү зарур: бу ике елауның тарихи нигезләре бер-берсеннән нык кына аерылып та тора. Искәртелгәнчә, Ярославна елавының тарихта булу-булмавы әлегә хәтле ачыкланмаган. Сөембикә елауларының исә конкрет тарихта булганлыгы һәм хәзер безгә мәгълүм рухта янгыравы документаль төстә расланган: алар 1564-1565 елларда Мәскәүдә язылган «Казан тарихы»нда киң чагылыш таба.

Ярославна елавы белән Сөембикә елауларының тарихи нигезләре генә түгел, тарихи-иҗтимагый, хәтта конкрет мәгънәләре дә капма-каршы. Ярославна күбрәк үз язмышы турында түгел, әсирлеккә эләккән ире Игорьның авыр хәлдә калуы хакында борчыла, кайгыра, елый. Әдәби-эстетик яктан югары дәрәҗәдә торган бу елау да күңелне тетрәндерә... Тик кенәз Игорьның, үзенең олы улын Кончак хан кулында калдырып, өенә кайтып киткәнен ачыклагач, күңелгә: бу кенәз шунда, Кыпчак илендә, кәеф-сафа корып арыгач, үз өенә кайтып киткән булса кирәк, дигән уй килә...

Сөембикә елауларына килсәк, биредә инде мәсьәлә бөтенләй башкача куела һәм кабул ителә. Сафа Гәрәй 1549 елда ук һәлак булгач, Сөембикә ил башында, үзара талашып-сугышып-үтерешеп торган түрә-морзалар арасында, берүзе кала. Нәкъ әнә шул сәбәпләр белән бәйле рәвештә, Иван IV Казанга махсус гаскәр җибәрә. Нәтиҗәдә Сөембикә үзенең икенче туган иле булган Казаннан, Казан ханлыгыннан, аны ихлас күңелдән яраткан халкыннан мәңгелеккә аерыла.

Шулай итеп Ярославна белән Сөембикә елаулары үзләренең тарихи нигезләре ягыннан да, иҗтимагый-тарихи мәгънәләре белән дә бер-берсеннән принципиаль аерылып тора. Ничек соң шагыйрь Зиннур Мансуров әлеге ике елауны бер шигъри әсәр, бер поэма эчтәлеге итеп ала алган? Ничек ул аларны берләштергән? Әгәр без биредә әнә шул—житди, катлаулы, соң дәрәҗәдә каршылыклы сорауга җавап бирә алсак—поэманы дөрес аңлаганбыз булып чыга.

Поэма баштан ахырга хәтле, үзәк өзгеч аваз буларак, югары стильдә язылган. Ул Борынгы Шәрык, урта гасырлар төрки-монгол һәм Алтын Урда чоры төрки-татар дастаннары рухында янгырый. Шагыйрьне югарыда яктыртылган тарихи вакыйгаларның берсе дә кызыксындырмый кебек. Тик тагын махсус әйтеп үтик: «кебек» кенә! Чынлыкта шагыйрь аларның барысын да бик яхшы белә. Тик аны кызыксындырган төп мәсьәлә, ике асыл затның—Сөембикә ханбикә белән кенәзбикә Ярославнаның—ачы язмышы. «Кереш»тә бу хакта түбәндәгечә яза:

*Ике якта гомер сөргән чит-ят затлар:*
*берсе—Идел, берсе Дунай буенда.*
*Илләрендә көйләп-көйләп илерәләр,*
*үзәк өзгеч аһ-зар бардыр бу моңда.*

*Кенәзбикә, килешмәүчән килендәштәй,*
*ханбикәдә танып ала көндәшен...*
*Итәк тотып энҗе-мәрҗән җыйган төсле,*
*фәрештәләр санап бара күз яшен.*

Поэманың композицион төзелеше дә, эчтәлеге дә, шигъри образ-символлар системасы да катлаулы. Шуларның барысын да аңлау өчен, без югарыда кыскача сөйләп чыккан тарихи фактларны да, «Игорь полкы турында сүз» поэмасын да, «Казан тарихы»н да, Сөембикә һәм Ярославна язмышлары белән турыдан-туры бәйләнгән башка күп санлы чыганакларны да яхшы белергә тиешбез. Чөнки З. Мансуров поэмасы күрсәтүенчә, шагыйрь ул чыганакларның барысын булмаса да, иң зур күпчелеген җентекләп өйрәнеп чыккан. Һәм бу Сөембикәнең поэмадагы беренче монологыннан ук ачык күренеп тора: «Егла, халкым, әйдә егла халкым, минем белән бергә еглачы. Ходайдандыр бүген хадимәңә тәкъдирләнде яңа юл башы... Килененне, илем, килешенеп, канлы туйга калым иттеләр,—еглаганда... Казан нигезендә салып калдырылган эт көләр...»

Сөембикә монологының баш өлешенә бераз тукталганнан соң шагыйрь Казан халкының ханбикәне нинди кайгы-хәсрәт, елау-сыктау белән озатуына күчә:

*Чәчен йолкып, битен тырнап, кулын чәйнәп,*
*бузлый-бузлый еглый барча кыз-кыркын.*
*«Мәҗүсидәй хәттин ашып мавыкмагыз!*
*Җитәр!»—диеп ник бер сәед кычкырсын.*

Авторның бу сүзләре дә тарихи вакыйгаларның турыдан-туры чагылышы булып яңгырый. Танылган тарихчы Һади Атласи бу хакта язып калдырган иде. Сөембикәнең әйтеп бетергесез авыр хәлдә калуын шундагы һәркем күрә, йөрәгебәгыре аша уздыра: «Аның болай булуы бөтен сарай кешеләренә тәэсир итеп, андагы кешеләрнең берсе дә егламый калмады. Сарайның сөйкемле хатыннары, матур кызлары ачы тавыш илә еглыйлар, битләрене тырныйлар, сачларын йолкыйлар, кулларын чәйниләр иде»... Кыскача күзәтелгән күренешләрдән аңлашылганча, шагыйрь үз әсәрен иң көчле, тәэсирле, иң югары стилистик ноктадан башлап, укучыны тулысынча үз ихтыярына буйсындыра. Һәм аны поэманың ахырына хәтле «ычкындырмый».

Янәдан Ярославна елавына әйләнеп кайтсак, З.Мансуров аны «Слово»да бөтенләй булмаган күренешләр, кичерешләр хисабына нык кына киңәйтә. Нәтиҗәдә «Слово»да аз гына сурәтләнгән Ярославна образы югары дастани-эпик дәрәҗәгә күтәрелә.

З.Мансуров поэмасында урын алган Ярославна елавының беренче өлешендә үк түбәндәге сүзләр дә бар: «Иләмәннәр белән киңәшмичә, качып киткән кебек ашыктың. Көнчел күршең Көнчак ханга барып, өрми генә утлы аш йоттың»... Танылган урыс галимнәре академик Д.С.Лихачев, О.В.Творогов, В.П.Адрианова-Перетц, Л.А.Дмитриев хезмәтләреннән билгеле булганча, кенәз Игорь әсирлектә булганда, «өрми генә утлы аш йотып» яшәми, әлбәттә. Югарыда искәртелгәнчә, кенәз Игорь элегрәк тә якын дусты булган кыпчак ханы Көнчак белән тагын да якынрак мөнәсәбәтләргә кереп, аз гына соңрак аның якын туганына әверелә. Димәк, Ярославнаның поэмада китерелгән әлеге сүзләре тарихи чынбарлыкка берничек тә туры килми. Урыс кенәзлекләре белән Кыпчак даласы хөкемдарлары арасында мәңгелек каршылык, конфликт, үзара сугышып, бер-беренне кырып ташлау теләге генә хөкем сөргән икән дип уйлау да һич тә дөрес түгел. Кыпчаклар

Игорьга каршы да баш күтәрми. Дөресен әйткәндә, беркемгә дә кирәкмәгән сугышны кенәз Игорь үзе башлый. Ул елларда күп санлы урыс кенәзләренең һәм кенәзлекләренең иң зур хатасы—алар еллар-гасырлар буе тәхет өчен бер-берсе белән сугышып интегәләр. Урыс кенәзләренең төп кайгы-хәсрәте кыпчак яулары түгел, ә бәлки аларның үзара тәхет өчен сугышып торулары була. «Слово»ның төп тарихи-иҗтимагый мәгънәсе дә кыпчакларга каршы сугышка чакыруда түгел! Ә бәлки үзара ызгыш-талашны, тәхет өчен бетмәс сугышларны туктатып, күрше кыпчаклар белән тыныч-тату тормыш коруга чакыру. Әле сөйләнгән тарихи вакыйгаларнын Киев Русе өчен коточкыч нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген шагыйрь З.Мансуров та бик яхшы аңлый һәм болай ди: «Җинелүнең ачы яше җемелдидер сәргаскәрен җуйган атның эзендә. Угъланнары язмышыннан угаланып, ачулана бөек кенәз үзе дә».

## Ике бикә диалогы

Поэманың нигезен тәшкил иткән тарихи вакыйгалар ничек кенә барып, аларның нәтиҗәләре нинди генә булса да, шагыйрь З.Мансуровның төп максаты һич тә тарих сөйләү түгел. Әдәби иҗатны сәясәт алыштыра алмаганын ул бик яхшы аңлый. Шуңа күрә тирән фаҗигагә дучар булган ике бикәгә дә: Сөембикәгә дә, Ярославнага да бердәй үк тирән ихтирам белән карый: аларның мөлаем образларын гәүдәләндерә. Бу үзе исә ике бикәнең диалогларында аеруча ачык күренә. Бигрәк тә сүз алар түккән күз яшьләре турында барганда. Сөембикә кенәзбикәгә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

*Аһ-зарларны бергә очраштырды—*
*әллә дөрестән дә Җир тармы?!*
*Миңа тиңдәш булып еглар өчен,*
*Ярыслауна, яшең җитәрме?*

Еглау—еглау инде ул! Бөтен дөньяны кайгы-хәсрәт, рәнҗү, инрәү басканда—туктаусыз еглау, яшь түгү—Адәм баласының хәсрәтен беркадәр «юып бара торган» бердәнбер чарасы булып кала; анын кайгысы туктамаган күз яшьләрендә эри башлыйдыр сыман. Моны яхшы аңлаган Ярославна Сөембикәгә түбәндәгечә җавап бирә: «Безгә инде, бикәм, шулай язган—азрак көлеп, күбрәк егларга. Әмма синең кебек горур затлар җебеп җавап бирмәс юк-барга. Тыеп тоткан күпме хәләл яшең сабыр бәгыреңдә тулгаклый... Ачылуым өчен ачуланма—толны кыен чакта тол яклый».

Әмма тора-бара шагыйрь, ике бикә тарихына, аларның язмышларында булган аерымлыкларга тирәнрәк үтеп керә; теләсә-теләмәсә дә, Ярославна белән Сөембикә бәхетсезлекләре, фаҗигаләре бер үк дәрәҗәдә түгел; түккән күз яшьләре дә. Шуңа күрә ике бикә арасындагы диалог кискенләшә бара. Сугыш алдыннан урыс кенәзләренең үзара мактанып-шапырынуын искә төшереп, Сөембикә түбәндәгечә җавап бирә: «Борын чөеп, бакчы, сөнге кадый кыпчак даласының читенә. Очлым белән Донны эчеп кую анын өчен, имеш, чүп кенә». Сөембикәнең болай кырыс җавап бирүе конкрет тарих фактлары белән тулысынча аклана: бер гаебе булмаган Сөембикәне бердәнбер улы Үтәмеш Гәрәй белән гомерлек тоткынлыкка алып китәләр. Баласын анасыннан тартып алып, көчләп чукындыралар; Александр Сафакиреевич дип яңа—христиан исеме—кушалар; туган иленә, халкына, Ислам диненә чиксез нәфрәт рухында тәрбиялиләр...

Үзенең яраткан ханбикәсен кызганып, инрәп, ил, халык, ханлык, дәүләт, Казан каласы елый... Сөембикә язмышының иң авыр, хәсрәтле мизгелләрен сурәтләүгә күчкәч, шагыйрь бер мәлгә Ярославнаны онытып та җибәрә кебек. Эчтәлеге һәм эмоциональ яңгыраш ягыннан бу өлеш нәкъ менә безнең көннәрдә иҗат ителгәндәй, заманча яңгырый. Елау текстлары нигезендә ханбикәнең талантлы дипломат һәм сәясәтче булуы хакында да шикләнмичә сөйләргә мөмкин.

Ханбикә елауларының безгә билгеле булган оригиналь текстлары шагыйрь Зиннур Мансуров өчен дә иң җитди чыганакларның берсе булгандыр дип уйларга тулы нигез бар. Әлеге елаулар ханбикәнең тирән хәсрәтле кичерешләрен, кайгысын,

мон-зарын, эчке халәте рухиясен тирәнрәк анларга ярдәм итә. Аларнын урысча текстлары Сөембикә заманнарыннан әлләни ерак булмаган 1564-1565 елларда Мәскәүдә язылган китапта урын алган. Һәм, ниһаять, мәсьәләнең иң мөһим ягы: ханбикә елаулары З.Мансуров поэмасының үзәген, иң югары ноктасын, кульминациясен тәшкил итә. Тарихи чыганакларны хәтерләтеп, поэмада ханбикә елавы түбәндәгечә башлана:

*Ярдәм итче, Сафам, мөмкин булса,*
*Аллаһыдан җибәрт иштирак*!*
*Җырлау өчен ят та ярап тора,*
*еглаганда якын иш кирәк.*
*..............................*

Алга табан ханбикә елавының мәгънәсе һәм эмоциональ яңгырашы тагын да көчәя, тирәнәя. Һәрвакыт мәет эзләп йөреп, үлем, һәлакәт, фаҗига символына әверелгән козгын образы килеп керә: «Козгыннарның көтмим кызгануын, ярдәм өмет итмим чит ымнан. Кемгә сөйлим, жанкач, үксез углын аерылмый әле сөтемнән»... Сөембикә Казанда чыннан да ялгыз калган. Ана ярдәмгә килердәй беркем юк. Нугай Урдасыннан яки Кырым ягыннан ярдәм сорау мөмкинлеге дә калмаган. Казан ханлыгы чикләрен зур һәм көчле урыс дружиналары саклый. Кырымнан ярдәм алып киләм дип Казаннан үзенең 300 яугире белән юлга чыккан Хан гвардиясе башлыгы Кошчак углан, урыс дружиналарының берсенә юлыгып, юкка чыгарыла. Гвардиянең төп өлеше яу кырында ятып кала. Исән калган 46 гаскәрине, шулар белән бергә Кошчак угланны да, Мәскәүгә алып китеп, православиега көчләп кискен баш тарткан өчен, җәзалап үтерәләр... Әнә шундый бөтенләй ялгызлык шартларында калган Сөембикә соңгы чарага мөрәҗәгать итеп, салкын гүрдә яткан сөекле Сафа Гәрәенә ялына башлый: «Ялыгудан гажиз ялгызлыгым синең ялгызлыкка кушылсын,—ятимәнне алдыр ятагына, жаннарыбыз игез кош булсын. Ничә алтын анда ишек бавы—үткәр мине гүрен түренә!.. Еглап ташкан зарлы Идел аша алып китәр безне зур көймә». Сөембикәне Мәскәүгә сатып җибәрү... Бу ифрат та четерекле мәсьәлә, дөресен әйткәндә, әлегә хәтле ачыкланып бетмәгән. Иван Грозный җибәргән илчелек казанлылар алдына бик авыр шартлар куя. Шуларның иң фаҗигалесе—ил башында утырган ханбикәне һәм аның сабый улын Мәскәүгә «шөһрәтле тоткынлыкка» озату. Казан түрә-морзалары Иван IV илчелеге белән озак бәхәсләшәләр, килешү шартларын бераз гына булса да йомшартуны үтенәләр. «Әгәр казанлылар мин куйган шартларга риза булмасалар, мин якын арада Казанга каршы рәхимсез сугыш ачачакмын»,—дип кисәтә Иван Грозный. Нәтиҗәдә, Казан түрә-морзалары, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, Иван IV куйган шартлар белән килешергә мәҗбүр булалар. Һади Атласи язуынча, «Августның 11 көнендә казанлылар Ходайкол углан, Мурали бәк, Аңкилде абызны Шәехгали янына җибәреп, Үтәмешгәрәй илә Сөен-бикәне урысларга тапшырачак идекләрен белдерделәр». Казан түрә-морзалары Мәскәү патшасына ышаналар һәм Казанны, ханлыкны исән саклап калу өчен, Сөембикә белән Үтәмеш Гәрәйне Мәскәүгә озаталар! Нәкъ бер елдан соң, үзенең изге вәгъдәсен онытып, Иван Грозный Казан ханлыгына каршы сугыш ача! ..

З.Мансуров поэмасында Ярославна болай ди: «Ничә меңле гаскәр саклап тора гайрәт чәчәр Казан кальгасын. Олугларың патша калгеннан нигә шулай куркып калган соң? Мәгърур таудай басып торган калаң батып бара, әнә, аһ-зарга. Ханбикәсен биреп җибәрүче кавемеңне ничек аңларга?» Кенәзбикәнең әнә шундый кискен соравына ханбикә дә шундый ук кырыс җавап бирә: нишләп әле ул—Ярославна—үзенең калерле ирен кайгыртып өзгәләнеп елаган вакытында Сөембикә кавеменә шундый ямьсез шик ташлый?

Акрынлап ханбикә көндәлек тормышның вак-төяк мәсьәләләрен икенче яссылыкка күчерә. Аның фикерләре һәм сүзләре киң фәлсәфи-дини ышануларга нигезләнә башлый. Поэмада хак мөселман хатыны буларак гәүдәләнгән Сөембикә

*Иштирак – булышлык.

мәсьәләне Аллаһы Тәгалә тарафыннан күптән билгеләнгән Язмышка күчерә. Ике бикә арасындагы диалог кискенләшә, һәм моны, һичшиксез, Сөембикә оештыра. Чөнки, ни әйтсәң дә, ханбикә—поэманың әйдәп баручы персонажы: «Күнелемдә урын калдырмадым нахак яла, кинә, кер өчен. Гаепләсәм сөйгән милләтемне, хаксыз әйтсәм—телем корысын. Аллаһыга ярсып әләклимме, кемгә шикаятьләр языйм соң,—килен булып төшкән ятим илдән «Талак!» әйтеп куса язмышың?!»

## Поэмада Мәрьям-ана образы

Билгеле булганча, бу дөньяда аларның кайгы-хәсрәтен уртаклашырдай, аларга ярдәм кулы сузардай һичкем калмагач, Адәм балалары Аллаһы Тәгаләгә, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәй Хәзрәти Мәрьям-анага мөрәҗәгать итәләр. Әсәрнең төп персонажлары һәрьяктан югары дәрәҗәдә торган бикәләр булгач, Хәзрәти Мәрьямнең аларга ярдәмгә килү теләге дә табигый. Сөембикә белән Ярославнага ул түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

*Канны юып булмый кан-яшь белән,*
*кан-яшь тамган җирдә гөл үсми.*
*Кенәзбикә, болай кызгандыру*
*синең кебекләргә килешми.*

Билгеле булганча, Ислам тәгълиматы, димәк, Коръән дә, берәр кеше бу дөньядан китеп, гүр иясе булгач, озак, бигрәк тә бертуктаусыз көннәр-айлар-еллар буена елау-сыктауны, күз яшьләре түгүне һич тә хупламый. Чөнки туктаусыз елау әрвахның рухын рәнҗетә, аның тынычлыгын боза, дип уйланыла.

Әмма поэма персонажлары нәкъ әнә шул юлга басалар. Мәрьям-ана вәгазенә карата Сөембикә: «Күздән яшең ничек чәчрәп чыкмас, сабырлыклар тулып ашканда?!»; Ярославна: «Тирәнәя хәсрәт дәрьялары, буаларын тырнап ачсаң да»,—дип җавап бирәләр. Ике бикәнең бәхәсләре, сабырсызлыгы, рәнҗешләре куерып киткәч, Мәрьям-ана Исламның төп таләпләренә, төп өйрәтүләренә тукталып, болай ди:

*Туган халкы өчен бәхет даулап,*
*сез генәме шулай җан аткан?..*
*Гарше-көрси мотлак һәрнәрсәне*
*үз тәкъдире белән яраткан.*

Мәрьям-ананың тыныч, сабыр, ышанычлы вәгазьләренә карамастан, ике бикәнең берсе дә тынычлана алмый. Хәл-әхвәлләр бик кырыс; күңел кыллары ахыр чиккә хәтле тартылган—менә-менә өзеләм дип тора... Шушы уңайдан Ярославна, кырыс сүзләр әйтеп, болай ди: «Вәгъдә сүзен кемнәр башлап боза—белә булыр аны Ул гына». Кенәзбикәнең бу сүзләренә ханбикә тагын да кырысрак җавап бирә: «Хәләл халкым хакын хаклар өчен миннән тагын күпме хак кирәк?» Икенче төрле итеп әйткәндә, Мәскәү патшасы күп гаскәр җыеп, Казанны яулап алырга, җимерергә, ватырга, юкка чыгарырга дип килгәндә, казанлылар, күрәсең, мәчеткә килеп, дога кылганнар, Хак Тәгаләдән ярдәм сораганнар. Әмма бу ялвару-догаларның, гыйбадәт кылуларның бернинди уңай нәтиҗәсе булмаган. Шуңа шаккатып, Сөембикә Мәрьям-анага зарлана: «"Татар иле авып барган чакта, Хак йортына ничек килмә ди?" Илчесенең биш мең фәрештәсе, юк, барыбер ярдәм кылмады».

Ә инде Казандагы ул еллардагы вәзгыятькә килсәк, андагы өстен катлам вәкилләре, түрә-морза-угланнар, үзара сугышып-көрәшеп, бер-берсен төркем-төркеме белән илдән куып, үтереп, төрле һәм зур гөнаһларга батып беткәннәр иде инде. Сөембикәнең кырыс сүзләренә Хәзрәти Мәрьям, бик хаклы рәвештә, шундый ук кискен сүзләр белән җавап бирә: «Үтәмисез фарыз кануннарны—уның берсен генә булса да». Әмма әле күптән түгел генә илбиләүче-хөкемдар булып, үз ил-милләтенең мөстәкыйльлеген саклап калу өчен байтак һәм мөһим адымнар ясаган

Сөембикәнең дә һич тә үз фикереннән кире кайтасы килми. Анын күнелен: тагын нинди корбан кирәк ханбикәдән?—дигән фикер борчый. «Вөҗданымны сыгып вөҗүдемнән, нинди бушлык изә бу җанны? Әллә инде, халкым, сине саклар фәрештәләр гаип булганмы?!»

Алга таба поэмада фикерләү тулысынча диярлек дини-фәлсәфи яссылыкка күчерелә. Нәкъ әнә шуна күрә Хәзрәти Мәрьямнен Сөембикәгә фәлсәфи-дини нигездә җавап бирүе тулысынча табигый яңгырый: «Бер гөнаһтыр—хаким үз халкынын язмышында уйнап көн күрсә, мен гөнаһтыр—башка кавемнәрнен туфрагына бәла китерсә».

Поэманың дәвамыннан күренгәнчә, Мәрьям-ананың кырыс-кискен гаепләүләреннән сон Сөембикәнен дә рухи халәте ярыйсы ук кискен үзгәрешләр кичерә. Хәзер инде анын сүзләре рәнҗү-үпкәләү, ниндидер ризасызлык белдерү булуга караганда, күбрәк ялыну-ялвару-үкенү кебегрәк яңгырый башлый: «Казанымнын кузлы казнасында әллә, чынлап, азман эт бармы? Өч-дүрт ахмак кылган гөнаһ өчен Аллаһ безне һәлак итәрме?»

Бирелә, Сөембикә сүзләрендә берничә фактик хата киткән. XVI гасырнын уртасына табан Казанда һәм ханлыкта тик бер генә азман эт булган дип уйлау, хәтта бик йомшартып әйткәндә дә, сабыйларча беркатлылык, әлбәттә. Шулай ук Сөембикәнен «өч-дүрт ахмак кылган гөнаһ өчен» дигән сүзләре дә тарихи дөреслектән ярыйсы ук ерак тора. Казан хөкемдарларынын сәясәте бөтенләй башка юлдан бара. Сафа Гәрәй 1546 елда өченче мәртәбә Казан тәхетен яулап алгач, Казан түрә-морзаларыннан, танылган дипломат һәм сәясәтчеләрдән: Чура Нарыков, Бау бәк, Кадыш бәк һ.б. байтак кешеләрне кылычтан уздыра. Хан әзәрлекләвеннән куркып, 76 кеше, нигездә түрә-морзалар, Мәскәүгә качып китеп, Иван Грозный хезмәтенә күчә. Үзара көрәш, ызгыш-талаш Сафа Гәрәй һәлак булганнан сон да дәвам итә. 1551 елнын көзендә Иван Грозный тарафыннан Шаһгали сонгы тапкыр Казан тәхетенә утыртылгач, коточкыч вакыйгалар булып уза. Бик тә чикләнгән сәясәтче һәм дипломат булган Шаһгалине Казанда яратмыйлар гына түгел—күрә алмыйлар! Бер төркем түрә-морзалар арасында Иван IV вәкилләре булган Дмитрий Палицкий белән Шаһгалине үтереп, башкаланы бу әшәке затлардан коткарырга кирәк дигән хәбәр тарала. Мондый сүз-фикерләр Шаһгали колагына да килеп ирешә. Шаһгали Казаннын танылган түрә-морзаларын үз өенә «кунакка чакырып», 70 кешене үтерттерә.

Сөембикә ханбикәне рәнҗеш-ризасызлыкларыннан арындыру өчен Хәзрәти Мәрьям ана бик көчле сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Уфтанулар тулы үткәннәрне уйлар дәрәҗәдә анлы сез. Инде ничә халык юкка чыкты—нигә бер дә сабак алмыйсыз?»

## Мәхшәргәчә дәвам итәр микән?

Поэманың сонгы бүлегендә Сөембикә берүзе кала. Ярославна тик бер урында гына берничә сүз әйтеп куя. Һәм бу анлашыла да. Үзенен тирән тарихи әчтәлеккә ия булган зур монологын—елау-сыктавынын дәвамын—ханбикә түбәндәгечә башлый:

*Мәхшәр көнгә тикле җитәр микән,*
*Ярыслауна, безнең түземнәр?..*
*Зинһар өчен, тыңлап торма мине—*
*кардәшләргә әйтер сүзем бар.*

Һәм чыннан да, билгеле булганча, Сөембикәне Казаннан алып киткәндә, анын бөтен дөньясы, күнеле, бәгыре, үзәге гомерлеккә сузылачак кайгы-хәсрәт белән тулган була... Кайбер чыганаклар күрсәтүенчә, Казан котылгысыз һәлакәт алдында калгач, Казаннын олугларыннан Сөембикә яклылары анын янына килеп, ана «Шаһгалигә кияүгә чыгып, ике якны да тынычландырасы иде»,—диләр... Тиреннәнрәк уйлап карасан, бирелә бит шаккатырлык бернәрсә дә юк! Сөембикә, үзе җитди сәясәтче һәм дипломат булarak, Петр Серебряный да шундый ук акыллы

кеше булырга тиеш дип кабул итә һәм аның сүзләренә тулысынча ышана. Дөресен әйткәндә, бирелә мәсьәлә Сөембикәдә генә дә түгел бит әле! Казанның олуглары да, Казан халкы да Иван Грозныйга һәм аның илчесе әйткән сүзләргә тулысынча ышаналар; аларны житди дәүләт эшлеклеләре дип кабул итәләр. Ул елларда, тулы бер ил һәм халык язмышы хәл ителгәндә, кычкырып торган алдау юлына басарга мөмкин дип кем уйласын! Кызганычка каршы, урта гасырлар өчен гадәти булганча, Сөембикәне Мәскәүгә гомерлек тоткынлыкка алып киткәч, Русиянең беренче патшасы үзе биргән вәгъдәләрне тулысынча оныта...

Талантлы дәүләт эшлеклесе буларак, Сөембикәнең Петр Серебряный сүзләренә ышануы да, Һ.Атласи әйткәнчә, тыштан гына булгандыр, һәрхәлдә, Зиннур Мансуров поэмасының дәвамы нәкъ әнә шундый фикерләр уята. Сөембикә, үзенең рәнҗүле шәхси кичерешләреннән беркадәр ераклашып, ил, халык, тарих, язмыш турында уйлана башлый: «Галәмемнең оят гамәлләрен белеп бетермәсен көндәшем. Егламыйча әйтим уйлаганны, син дә туктап торчы, күз яшем!..» Әнә шундый үзенчәлекле керештән соң ханбикә төрки-татар ил-дәүләтләренең тарихи язмышларын күзәтүгә күчә: «Гомер сөрә җирдә ничә кавем, бардыр алар йөзләп, меңләп тә. Зекер әйтмәс идем: зирәк акыл күбрәк, диеп, безнең милләттә. Вакланыша торды алыплары киртә булып калкыр тау саен. Татарымның, ахры, тәкъдиренә тәдбир* салынмаган тәгаен».

Ханбикәнең бу сүзләре дә тарихи дөреслеккә туры килә: Казан ханлыгы яшәгән дәвердә (1438-1552) Бөек Болгар чоры Алып-Алпамыш-Алпамшалары инде күптән юкка чыккан була. Һәм бу хакта без Алыпларга—зур гәүдәле кешеләргә—багышланган риваять-легендалар, дастаннар нигезендә генә түгел, ә бәлки конкрет тарих вакыйгаларына таянып та сөйли алабыз. Күренекле тарихчы-археолог А.Х.Халиков Идел-Чулман Болгарстаны яшәгән дәверне (IX-XIV йөзләр) алыплар чоры дип атаган иде. Һәм бу чыннан да шулай. Тулаем алганда, болгарлар монгол яуларына каршы 50 ел буена көчле көрәш-сугышлар алып баралар. Бу сугышларда халыкның абруен казанган алып-батырлар да актив катнаша, әлбәттә!

Тик шуны да истә тотырга кирәк: Иван Грозный Казанга каршы яу чапканда, Казанда һәм ханлыкта алып-батырлар гомумән булмаган икән, дип раслау да тарихи дөреслеккә бөтенләй үк туры килеп бетмәс иде. Булган алар, алыплар да, батырлар да! Югыйсә Иван Грозный 150 меңлек гаскәре белән Казанда калган 30 меңлек гаскәрне җиңә алмыйча, җиде атна буена интекмәгән булыр иде.

Алга табан шагыйрь Сөембикә фикерләрен төрки-татар тарихының тагын да тирәнрәк, тагын да борынгырак катламнарына «алып кереп китә»:

*Бөек Туран рухын туры тотып,*
*селкетмичә сыңар кашын да,*
*көчен туплый алмый төрки кавем*
*зурдан купкан дошман каршында.*

Биредә шагыйрьнең «Бөек Туран рухы» дигән сүзләренең XVI гасыр вакыйгаларына нинди мөнәсәбәте бар соң?—дигән тагын да четереклерәк һәм катлаулырак сорау калкып чыга. Автор үзе бу сорауга бернинди дә җавап бирми. Шагыйрь З.Мансуров кына түгел, байтак галимнәр дә әлеге сорауга ышанычлы җавап таба алганы юк. Димәк, безнең үзебезгә уйланып карарга туры киләчәк.

Төрки халыклар фикеренчә, тураннар—борынгы төркиләр. Борынгы Шәрык мифологиясе мәгълүматлары буенча, кайчандыр тураннар һәм иранлылар арийлар дип аталган бер үк халык булган. Аларның икегә бүленеп, Иран һәм Туран дип атала башлавы Зәрдөштлеккә нигез салучы пәйгамбәр Заратуштра (борынгы грек телендә—Зороастр; төрки телләрдә—Зәрдөшт) исеме белән бәйләнгән. Аның эшчәнлеге б.э.к. XII-X гасырларга карый. Борынгы төркиләр тарихының иң тирән белгече Л.Н.Гумилев фикеренчә, Шәрыктә яңа дин буларак барлыкка килгән Зәрдөштлекне кабул итү-итмәүдә бик зур каршылыклар килеп чыга. Нәтиҗәдә яңа

*Тәдбир—алдан күреп эш йөртү.

динне кабул иткән арийлар—иранлылар, борынгырак аллаларга табынучылар—тураннар дип атала башлый. Урта Азия һәм хәзерге Әфганстан җирләрендә урнашкан Туранда Ормузд-Ахура Маздага табынудан баш тартып, Диюләргә табынуларын дәвам итәләр. Бәлкем, нәкъ әнә шуңа күрәдер, төрле үзгәрешләр кичергән Дию образы әле хәзергә хәтле төрки халыклар мифологиясенең төп персонажларыннан берсе булып кала бирә... Төрле мифологик мәгълүматларга караганда, б.э.к. XII-X гасырларда Туран белән Иран арасында көчле һәм һич бетмәс сугышлар булып тора. Бу илләрнең чиге дип Сыр-Дәрья елгасы санала. Әнә шул сугышларда төркиләр гаскәре белән җитәкчелек иткән Афрасиаб—җиңелмәс юлбашчы—яугир буларак таныла. Төрек, әзәрбайҗан, үзбәк, төркмән халыклары мифларында Афрасиаб—Иранннан чыккан персонаж—төрки халыкларның шәҗәрәсен башлап җибәрүче, төркиләрнең патшасы, баһадиры, төрле кабиләләрнең юлбашчысы; Иранны яулап алып, 12 ел буена шунда хөкемдарлык итә... Афрасиаб исеме татар әдәбияты классиклары С.Сараи һәм Котб әсәрләрендә дә очрый.

Туран рухы мәсьәләсенә болай киң тукталуыбыз төрки-татар халыкларының Туран иле дәверен төркиләрнең иң борынгы һәм иң дәһшәтле чоры булган дип күзаллаулары белән аңлатыла. Шагыйрь З.Мансуров та шундый ук карашлардан чыгып фикер йөртә булса кирәк.

Алга таба поэмада сүз нигездә дини һәм мифологик ышанулар турында барса да, автор борынгы төркиләр тарихын да һич тә читләтеп үтми. Әйтик, түбәндәге юлларда:

*Кояш чыккан чакта базмас идем,*
*җәрьат итеп әйтәм—кич инде:*
*кардәшләрең белән көрәшүгә*
*бирдең, түрк, иң күп көчеңне.*

*Шан-шәрәфле нәсел шәҗәрәбез*
*башлангандыр изге ант илә.*
*Үчләнүне синең угланнарың*
*уйлап тапкан, Олуг Атилла!..*

Бу бөек тарихи шәхеснең исеме төрки-татар телләрендә Атилла, Европа телләрендә һәм төрле энциклопедияләрдә Аттила дип языла. Атилла (?-453)—һуннарның хөкемдары, ханы, Евразиядә яшәүче күп санлы герман һәм төрки-татар халыклары эпосының һәм язма әдәбиятының катлаулы, каршылыклы, нык кына мификлаштырылган серле-сихерле каһарманы. Моның конкрет сәбәбе Атилла чорындагы һәм аның турыдан-туры катнашы белән оештырылган, дөньякүләм әһәмияткә ия булган тарихи процесслар белән аңлатыла: сүз II-V гасырлардагы халыкларның бөек күчеше турында бара.

Европа халыклары Атилланы, беренчедән, үзләрен Рим империясе коллыгыннан азат итүче дип санасалар, икенчедән һәм, моның капма-каршысы буларак, аларның—европалыларның сансыз күп гөнаһлары өчен үз аллалары тарафыннан җибәрелгән җәза, бәла-каза дип кабул иткәннәр. Әнә шуларның барысы бергә Атиллага искиткеч зур дәүләт төзү мөмкинлеген бирә. Ул төзегән дәүләт-илне еш кына Халыклар союзы дип атыйлар.

Атилла бу дөньядан киткәч аның тарафыннан төзелгән һәм Евразиянең төп өлешен биләп торган дәүләт акрынлап таркала. Әмма Атилла төзегән дөньякүләм ил юкка чыкса да, атаклы полководецның мификлаштырылган образы Евразия халыклары аңына тирән үтеп керә һәм төрки-татарларның риваять-легендаларында, Скандинавия халыклары сагаларында, инглиз-саксоннарның «Старшая Эдда», көньяк германлыларның «Нибелунглар турында җыру» кебек дастаннарында, язма әдәбият әсәрләрендә мең ярым ел буена сакланып, безнең көннәргә хәтле килеп җитә.

Зиннур Мансуров Атилла дәүләтенең таркалуын төрки кардәшләрнең үзара үчләнүе белән аңлата. Мәсьәләгә билгеле бер яссылыктан якын килеп караганда, ул күпмедер дәрәҗәдә хаклыдыр да. Ә инде тирәннәнрәк уйлап карасаң, хаким даирә вәкилләренең байлык, җир, кенәзлек, ханлык, ахыр чиктә—тәхет өчен үзара

даими көрәшеп-сугышып торуы—төрки илләр өчен генә хас күренеш түгел. Боларның барысы да Урта гасырларда да, аннан элегрәк тә һәм соңрак та байтак илләрдә булып торган, һәм әле хәзер дә дәвам итә...

Ә инде Атилла һәм ул төзегән дөньякүләм дәүләтнең язмышына әйләнеп кайтсак, ул барыннан да элек тарихның үз закончалыкларына буйсына: беренчедән, Атилла эшчәнлеге белән бәйләнгән вакыйгалар халыкларның бөек күчеше дип аталган зур тарихи процессның билгеле бер дәверенә нокта куя; икенчедән, Атилла һәм Көнбатыш һун дәүләте үзләренең төп бурычларын тулысынча башкарып чыгалар. Нәтиҗәдә Евразия тарихында Рим империясе колбиләүчелегеннән азат ителгән илләрнең тарихы принципиаль үзгәрешләр кичерә. Европада феодализм, берничә гасырдан соң Янарыш Ренессанс дәверләренең башлануы—боларның барысын да «якынайтуда» һуннарның һәм Атилла сәясәтенең дә роле аз булмагандыр!

Хәер, әле генә китерелгән фикерләрнең кайберсен поэма тексты да дәлилли. Сөембикә тарафыннан әйтелгән «төркиләрнең үзара үчләнүе» хакындагы сүзләргә Ярославна болай дип җавап бирә: «Кардәшләрен ашар каракошка каргыш төшми бугай, ханбикәм. Ярославның соңгы васыятен искә алсам, күпме кан йотам. Әйткән кенәз: туган белән туган сугышмаска тиеш моннан соң!..» Тик биредә шуны гына искәртеп үтәсе бар: «Ярославның соңгы васыяте» турында безгә «Слово»ның үзендә дә, поэмага багышланган дистәләрчә фәнни хезмәтләрдә дә бер сүз дә табу насыйп булмады, һәм бу гомумән мөмкин дә булмагандыр. Чөнки Ярослав Осмомысл (?-1187)—Ярославнаның әтисе, XII гасырда, гомере буена урыс кенәзләренең үзара орыш-сугышларын оештыручы буларак, шул бәрелешләрнең иң зур күпчелегендә турыдан-туры катнашкан тарихи шәхес. Димәк, әлеге сүзләрне кенәз Ярослав исеменнән әйттереп булмый. Мәсьәлә, күрәсең, башкачарак хәл ителә. «Слово»ның үзендә дә, ана багышланган хезмәтләрдә дә «Святославның алтын сүзе»—«Золотое слово Святослава» дигән, байтак галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән гыйбарә бар. Нәкъ әнә шул үзенең «алтын сүзе»ндә Святослав, бик ямьсез төш күргәннән соң һәм Игорьның әсирлеккә эләгүен ишеткәч, кенәзләрне үзара көрәшмәскә, ә бәлки куркыныч дошманнарга каршы сугыш өчен берләшергә чакыра.

Тик, Сөембикә, автор ихтыяры белән булса кирәк, үзенең тарихи-фәлсәфи фикерләрен дәвам итә: «Сезнең өчен, ахры, ашы кыйммәт, баштан ашканда да ил эше. Туемсызлык йоткач туганлыкны, ауган, әнә, Җучи олысы».

Әйе, шагыйрь дә, ханбикә Сөембикә дә билгеле бер дәрәҗәдә хаклы, әлбәттә. Тик конкрет тарихның аерым шәхесләр ихтыярына гына буйсынмый торган үз закончалыклары булуын да онытмаска кирәк. Гомумән, Җучи олысы—Алтын Урда «ауды», «юкка чыкты» дип әйтеп тә булмыйдыр. Безнең көннәрдә Алтын Урданың варисы—Мәскәү дәүләте—Московское государство дип санала. Гомумән алганда исә бүген үзләрен Алтын Урданың бердәнбер варисы дип игълан итәргә тырышучы ил-дәүләтләрнең саны байтак (бу хакта киңрәк мәгълүматларны карагыз: Рафаэль Хаким. Метаморфозы духа.—Казань, 2005).

Шуңа карамастан, Сөембикә ханбикәнең түбәндәге сүзләре тарихи дөреслеккә тулысынча туры килә: «Гарьсезләрең дала горурлыгын сатты юк-бар бүләк хакына; мескенләнеп сорау мисалында Мәскәүләргә китте хат кына.Ияр юлла, имеш, быргы җибәр—теләндегез даулап һәммәсен: кәгазь, буяу, кургаш, көбә, акча, зәгъфран, бүрек, кадак һәм лачын...» Бу сүзләрнең тулысынча тарихи дөреслеккә туры килүен аңлау өчен, нугай бәк-морзаларының урыс кенәзләренә язган сансыз күп хатларын һәм аларга әлеге кенәз-боярларның җавапларын карап чыгу да җитә. XIX гасырның сиксәненче елларында әлеге хатларның тулы текстлары том-том булып басылып чыга. Шул хатларның текстлары белән танышкач, чыннан да шаккатасың: нугай түрә-морзаларын, күрәсең, вак-төяк бүләкләрдән башка бернәрсә дә кызыксындырмаган... Әнә шундый хәлләр белән бәйле рәвештә акрынлап З.Мансуров поэмасына Ахырзаман галәмәтләре белән турыдан-туры бәйләнгән дини-мифологик образ-персонажлар өермәсе бәреп керә:

*Алтын чире йоккан кылтык ханың*
*ашамаган... бакыр казаннан.*

*Шундый җимнәр белән Дәҗҗәл үзе*
*сезнең ышанычны казанган.*

Биредә безне һәм, уйларга кирәк, укучыларны да кызыксындырганы—Дәжҗал исеме. Дәжжал—гарәпчә алдакчы, ялганчы; арамей телендәге даггала сүзеннән, шул ук ялган, «ялган мәсих»—ялган коткаручы-мессия; борынгы гарәп һәм Ислам мифологиясе персонажы. Христиан динендәге Антихристка туры килә. Коръәндә телгә алынмый. Дәжжал турында хәдисләрдә һәм дөнья бетү—Ахырзаман белән бәйләнгән дастан-кыйссаларда сөйләнелә. Мөселманнарның карашлары буенча, Дәжжалның эш-гамәлләре Иблис белән дә бәйләнгән; Адәм балаларын юлдан яздыручыларның соңгысы: халыкка ул үзен чыннан да коткаручы, Гайсә пәйгамбәр яки Мәһди дип игълан итәчәк. Легендалар буенча, Дәжжал үзенең төп вазифасын үтәүгә керешкәнче, һинд океанындагы утрауда тимер кадак белән кыя-ташка кадакланган килеш гомер итә. Мәгълүм кыйсса сюжетына кайвакыт Дәжжалга гына хас сыйфатлар белән бәйле мәгълүматлар да килеп кушыла: аның гәүдәсе—кызыл, маңгаенда—ялгыз күз, шунда ук каф хәрефе яки кяфер сүзе дә язылган икән. Ислам тәгълиматы буенча, дөнья бетәр алдыннан Дәжжал бөтен җир йөзендә, Мәккә белән Мәдинәдән тыш, үзенең куркыныч хакимиятен урнаштырып, үз юлындагы барлык мәчетләрне җимереп, мөселманнарны туган җирләреннән куып җибәрәчәк. Дәжжалның хакимияте 40 көн, икенче бер хәбәрләр буенча—40 ел дәвам итәчәк. Шуннан соң Мәһди чыгып, Сүриядә яки Фәләстыйн иленда Дәжжалны үтерәчәк. Әлеге вакыйгалардан соң, Исрафил пәйгамбәр, сурына өреп, үлгәннәрнең барысын да кабереннән кубарачак, кыямәт көне житүен хәбәр итәчәк.

Күрсәтелгән шигъри-эстетик алымнарны дәвам итеп, алга табан шагыйрь, Сөембикә исеменнән, болай ди:

*Яманатлы Мәсих ямаулыгын*
*ташып торган җасус ямчылар.*
*Шуның өчен бит ул һәрбер заттан,*
*Газраилне узып, җан сорар!..*

Мәсих урысча сүзлекләрдә ал-Масих-мессия, яһүд халкы карашларында Дөнья бетәр алдыннан киләчәк идеаль патша, аллалар белән кешеләр мөнәсәбәтләрендәге арадашчы; христиан дини-мифологик системасында—Иисус Христосның үзгәртелгән, «яңартылган» исеме. Коръәндә һәм Ислам тәгълиматында әл-Мәсих—шулай ук Иса пәйгамбәрнең, Иисусның билгеләмәсе, гадәттә аның исеме алдыннан куела һәм Коръәндә кат-кат кабатлана (3:45-46). Ислам белгечләре күрсәтүенчә, әл-Мәсих термины Иса пәйгамбәргә багышланган хикәятләрдә, Мөхәммәд галәйһиссәламнең хыялый күзаллауларында, Исаның Жиргә икенче тапкыр килүе, аның Мәхшәр галәмәтләрендә катнашуы турындагы мәгълүматларда да очрый. Әд-Дәжжал да кайвакыт әл-Мәсих әл-Каззаб (ялган коткаручы) һәм әл-Мәсих әл-Дәжжал дип тә атала.

Югарыда поэмадан китерелгән өзектән күренгәнчә, әл-Мәсих исеме З.Мансуров поэмасында әле генә күрсәтелгән әл-Мәсих әл-Каззаб (ялган мессия) һәм әл-Мәсих әд-Дәжжал мәгънәләрендә кулланыла, һәм, объективлык ягыннан әсәрдә бик тә урынлы яңгырый. Чөнки, конкрет тарихтан билгеле булганча, урыс самодержавиесе, Иван Грозныйдан башлап, хәтта аннан күп элегрәк тә, үзләренең чит-ят, беркайчан урыс аягы басмаган, гөрләп чәчәк ату дәрәжәсендә торган илләрне яулап алу эшләрен әл-Мәсих—Иисус Христос исеменнән башлыйлар һәм дәвам итәләр. Бу өлкәдә Православие иерархлары, митрополит-архиепископлар, бернинди гөнаһтан курыкмыйча, хәлиткеч роль уйнап, кенәз-патшаларны даими котыртып торалар. Хәтта Сөембикәне тоткынлыкка алып китәргә дип килгән кенәз Серебряный да ханбикәгә түбәндәге сүзләр белән дә мөрәжәгать итә: «Ханбикә илаһи күкләрдә яшәүче, барлык патша-падишаларның хәлләрен билгеләүче безнең бөек аллабыз Иисус Христос (әл-Мәсих әд-Дәжжал—Ф.У.) тарафыннан кулга алынды».

## Йомгак

Поэманың соңгы битләрендә Ислам тәгълиматы яки шуңа якын торган персонаж исемнәре, дини-ислами лексика тагын да мөһимрәк урын ала башлый: Газраил, Кисекбаш, Тәсбих, монафыйкъ, һиҗрәт кылу һ.б. Без бу сүзләргә махсус тукталып тормыйбыз. Тик Ахырзаман белән турыдан-туры бәйләнгән тагын бер генә дүртьюллыкка игътибар итеп үтәбез. Төрки-татар түрә-морзаларының үз илхалыкларына каршы юнәлтелгән вакчыл, мәгънәсез сәясәтенә тукталып, шагыйрь Сөембикә ханбикә исеменнән бүгенге көндә дә заманча яңгыраган сүзләр әйттерә:

*Аңа кадак, имеш, моңа Казан—*
*Мәхшәргәчә тынмас ул сәүдә.*
*Тамчы яшем шундый авыр булып*
*ятса икән гарше үлчәүдә...*

Мәхшәр сүзе Сөембикәне мәңгелек тоткынлыкка алып китү көннәрен гомуми яссылыкта ярыйсы ук төгәл билгели. Дини ышануларда исә аның конкрет билгеләмәсе дә бар. Аңлатмалы сүзлек аны түбәндәгечә билгели: «Мәхшәр көне—Ислам диненчә, янадан терелгән кешеләрнең теге дөньяда җыелу көне». Китерелгән өзектәге гарше үлчәү гыйбарәсе дә турыдан-туры Ислам Тәгълиматы һәм Ахырзаман турындагы күзаллаулардан килә. Күрсәтелгән сүзлек аңа түбәндәгечә аңлатма бирә: «Гареш—дини ышану буенча Алла тәхете урнашкан иң югары кат; күк».

Шагыйрь, поэмасының «Бетем»ендә иң югары әдәби-эстетик дәрәҗәдә торган шигъри алымнарга мөрәҗәгать итеп, бәгыреңне тетрәндерерлек, үзәкләреңне өзәрдәй сүзләр таба. Бер гыйбарә белән әйткәндә, «Бетем»—гомум Җиһан, бөтен Дөнья еглавыннан торадыр сыман. Урыслар аны Вселенский плач дип әйтәләр. Биредә шагыйрь безнең өчен күптән табигый яңгыраган гыйбарәләр белән бергә, капма-каршы мәгънәләрдә булганнарына да мөрәҗәгать итә. Шуларның кайбер мисалларын китереп үтик: «Кавышырга өмет итеп кыямәттә карурманда Сак белән Сок яшь сыга»; «Кардәшләрнең яше сыймый каберенә—гаҗизлектән үкси Аксак тимер дә»; «Сабый төсле сыктый һаман Явыз Иван, ауган ханлык тәхетенә утырып...»; «Ике бикәч көн-төн еглый ике ярда, яраларга тамып тора күз яше...»

Тулаем алганда, Зиннур Мансуровның «Ике еглау» поэмасы—хәзерге татар шигъриятенең генә түгел, ә гомуми татар поэзиясенең дә иң югары әдәби-эстетик таләпләренә тулысынча җавап бирердәй әсәр!

**Редакциядән:**

*Филология фәннәре докторы, профессор Фатих Ибраһим улы Урманчиевка шушы айда 70 яшь тула. Аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, иҗат уңышлары һәм сәламәтлек телибез!*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

**САННАР МАГИЯСЕ** – Санннарга мистик мәгънәләр бирү бик борынгыдан килә. Борынгы кешеләрнең санау системаларындагы "түшәм" ("бик зур") саннарны: 3, 7, 10, 12, 40, 60 һ.б.ны "башка сыйдыру" кыенлыклар тудырган һәм аларга гайре табигый мәгънә бирә башлаганнар. Электә так саннар аеруча зур көчкә ия дип санаганнар.

Пифагор, мәсәлән, бер санында Алланы күрә. Ике – яман башлангыч, өч исә – гармония символы. Борынгылар өч грация хөрмәтенә өч тапкыр эчеп куйганнар, сихерне кайтару өчен өч тапкыр төкерә торган булганнар. Алар фикеренчә, дөньяны өчәүләп Юпитер, Нептун һәм Плутон идарә иткән. Диана дигән алиһәнең өч чырае булган имеш. Корбан китергәндә корбан савыты тирәсендә өч тапкыр әйләнгәннәр һ.б. Христианнардагы Триада (Өчлек яки Өчләмә – Алла, Изге Тын һәм Алла Улы Христос) турындагы күзаллауга да борынгы саннар хорафатының йогынтысы шиксез.

Бекташилар тарикатендә 4 саны, мәсәлән, шәригатьне, тарикатьне, мәгърифәтне һәм хакыйкатьне, 12 саны – унике имамны, ә 32 саны кеше йөзендәге тәкъдирне күрсәткән җыерчык һәм сызыклар санын белдерә дип ышаналар.

Гомумән, 3, 7, 9, 12, 40 изге саннар булып исәпләнгән. "Бәхетле" 12 саныннан соң "бәхетсез" 13 саны киткән, 666 саны антихрист ("ерткыч") саны булып исәпләнгән (чөнки залим император Нерон исеменең санча кыйммәтләре суммасы 666 га тигез) һ.б.

Тагын кара: ***Иман китерү.***

**САРК ӘШ-ШИГЫРЬ** г. – Шигырь урлау, шигъри плагиат. Шагыйрьләр дөньясында плагиат мәсьәләсенең озын гына тарихы бар. Гомумән, язма әдәбиятка кадәр үк җырчы-шагыйрьләр (акыннар) арасында бер-берсенең иҗат җимешләреннән файдалану таралган булгандыр. Алтын Урда шагыйре Сәйф Сараи шигырь урлаучыларны түбәндәгечә сыйфатлый: "Кеме башканың шигырен "мәнем" дир, Кеме хәлвә кеби шалкан чүбен йийр (ашар)".

Гарәп әдәбиятында "Сарк әш-шигырь" мәсьәләсенә беренче булып Әбү Һилал әл-Гаскәри (вафаты 1005 елда) игътибар иткән. Аның күпсанлы мисаллардан торган күзәтүләреннән түбәндәге нәтиҗәләр чыга (Г.Э. фон-Грюнебаум буенча):

1.Элек кемдер кулланган мәгънә һәм мотивларны файдалану котылгысыз; Гали хәлифә үк: "Әгәр сөйләмдә кабатланулар булмаса, сөйләм теле инде күптән корыган булыр иде,"-дигән.

2.Гомумән, авторларга башка кешедән алынган мәгънәне үз сүзләре белән бирү, үрнәктәге телбизәкләрне кабатламау хәерле, яки аларга башлангыч үрнәкне камилләштерергә һәм телбизәк чараларын яңартырга кирәк. Шушы таләп үтәлгән очракта соңгырак автор, әлеге мәгънәгә нисбәтән, элгәренә караганда зуррак хокукка ия була.

3.Хәйләкәр автор башкалардан күчергән алынмасын оста яшерә. Плагиатны яшерү (*ихфа ас-сарк*) ысуллары түбәндәгеләр: а) мәгънәне шигырьдән прозага күчерү; б)прозадан алынган мәгънәне шигырьгә күчерү; в)алынган мәгънәне башка максатларда куллану (мәс., тасвир урынына панегирикта куллану).

4.Алынма куллану түбәндәге очракларда килешми: а)автор мәгънәне сүзгә-сүз

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

диярлек алса яки аны яраксыз контекстта кулланса; б)мәгънәне яки контекстны бозса яки әлгәрләренең иҗади уңышын теләсә нинди ысул белән начарайтса.

5.Шул ук вакытта кайбер мәгънәләрнең барлык акыллы кешеләр өчен мөштәрәк (уртак) булу ихтималы да бар һәм ул гади кеше башына да килергә мөмкин (2 нче һәм 4 нче пунктларга карата).

6.Аерым очракларда соңгырак авторлар әлгәрләре тапкан мәгънәне яңадан уйлап чыгарырга да мөмкин. Ләкин әл-Гаскәри фикеренчә, мондый материалны куллану хупланмый.

Плагиат мәсьәләсен Ибн Рашик (1064 яки 1070 елда вафат) тагы да җентеклəбрәк тикшерә. Аның уйлавынча, гадәттән тыш үзенчәлекле сыйфатлар, оригинальлек кенә плагиат объекты булырга мөмкин. Шуңа күрә антитеза яки каламбур кебек оригиналь табышларны урлау һәм үзләштерү гади чагыштыруларны урлауга караганда хурлыклырак. Әгәр мәгънә вакытлар узу белән гомумкулланылышка кергән икән, аңардан һәркем файдалана ала. Әйтик, бер үк чорда яшәгән шагыйрьләр бер үк бәйрәм тантанасын тасвирлаганда да охшашлыклар һәм тәңгәллекләр килеп чыгуы ихтимал. Вәзен (үлчәү, ритм) һәм кафия (рифма) таләпләре дә еш кына төрле авторларда тәңгәллекләргә сәбәп була. Әгәр шагыйрь элек уйлап чыгарылган мәгънәне шомартып, энҗе бөртегедәй камил хәлгә китерә икән, аның бу мәгънәгә хокукы күбрәк дип санала. Икенче яктан исә, башка шагыйрьләр аңардан уздырганчы оригинал югарырак бәяләнә. Кагыйдә буларак, мәгънәгә авторлык хокукы әүвәлгерәк шагыйрьгә бирелә (ул *әүлә би-л-мәгънә* дип атала), әгәр шагыйрьләр замандаш булсалар, мәгънә аны остарак, матуррак итеп әйткән шагыйрьнеке дип исәпләнә.

Габделкәрим бин Ибраһим әл-Нахшади мотив бөтенләй башка сүзләр белән кабатлап әйтелгән очракта да мәгънә үзләштерүне сарк дип саный. Әүвәлге шигырьне сүзгә-сүз диярлек кабатлаган очракта гына плагиат була дип караучылар да булган.

Башка авторның шигырен үз шигырендә цитата рәвешендә кабатлауны Ибн Рашик *тадмин* дип атый һәм аны плагиаттан аера.

XII гасырларга гарәп тикшеренүчеләренең сарикага карашлары төзек бер система булып оешалар. XIII гасырда фарсы авторы Шәмс-и Кайс бу системаны аңлаешлы сүзләр белән бәян итә. Ул сариканы дүрт төргә бүлеп тикшерә, болар: 1)башка авторларның сүзләрен аз гына үзгәртеп яки үзгәртмичә генә үз әсәреңә кертү (*интикал*-урын алмаштыру); 2)композицияне (тәркиб) һәм контекстны яки функцияне үзгәртеп, мәгънә һәм ләфызны алу (*салх*); 3)мәгънәнең сүз формасын гына үзгәртеп, аны үз контекстында һәм шигърияттнең шул ук төрендә куллану (илмам); 4)мәгънәнең үзен генә алып, аны шигърияттнең башка жанрында файдалану (*накыйль*-бер җирдән икенче җиргә күчерү).

Ибн Рашик, үзенең замандаш шагыйрьләре ирешкән уңышларны тану белән бер үк вакытта, бу казанышлар "ары киткән саен начаррак" дип тә әйтә.

Шулай да гарәп шигъриятендә яңалыкка омтылыш башкаларга ияру һәм күчерү дигән нәрсәне кысрыклап чыгара алмаган.

**САРЫ ТӘРЕ ЯВЫ** *тар.* – Монгол-татар империясенең бөек ханы Арыг-Буга 1259-60 елларда Иерусалимга оештырган яу. Яуның максаты "Алла табутын мөселманнардан азат итү" булган. Христиан рыцарьлары котыртуы буенча оештырылса да, папа тарафдарлары ягыннан вакытында ярдәм булмаганлыктан, бу яу уңышсызлыкка очрый. 1260 елда монголларның Кит-Буга гаскәрен мәмлүкләр тар-мар иткәннәр.

**САФУРА БУРАНЫ** – Рәбгузи кыйссаларында язылганча, Муса пәйгамбәрнең хатыны Сафура ком чүлендә чыгарган каты буран.

**САХИБ КЫЙРАН** *г.* – 1.Патша эпитеты, җиңүче мәгънәсенә ия. 2.Бәхетле кеше (Шәрык астрологиясе буенча *Мөштәри* белән *Зөһрә* йолдыз, ягъни Юпитер һәм Венера планеталары бер йолдызлыкта кушылышта вакытта яки Зөһрә йолдыз белән Кояш бергә туры килгән чакта туган кеше, бәхет йөзлеге белән – "күлмәкчән" туган кеше). Бу эпитет монгол ханнарына, *Искәндәр Зөлкарнайга* һәм махсус *Тимерләнгкә* бирелгән. Бу исемне төрек солтаны *Явыз Сәлимгә* карата куллану да очрый.

**СӘГАТЬ** *г.* — "Казык" дигән гарәп сүзеннән. Вакытны күләгә озынлыгына карап үлчи торган Кояш сәгатендә унөч казыкнын берсе һәм ике казык арасы (Р.Әхмәтьянов). Хәзерге татар телендә: **1.**Вакыт берәмлеге-тәүлекнең егерме дүрттән бер өлеше. Ләкин "Кисекбаш китабы"нда *"бу сәгать"* сүзе "хәзер, шушы мизгелдә" (русча: *сейчас*) мәгънәсендә кулланылган: *"Ол дию әйтер: бу сәгать сәни ййиам"*. **2.**Вакыт үлчәү җайланмасы. Электә *сәгать* сүзе татар телендә фәкать вакытны гына белдергән, ә вакыт үлчәү җайланмасын *сәгатьләмә* дип атаганнар. (Ш.Мәрҗанидә сәгатьнамә дигән термин очрый: "Хәзерге көндә миндә аның үзе ясаган әстерләбе һәм көррәсе саклана. Үзе төзегән *сәгатьнамәсен* күрдем". Биредә сүз вакыт үлчәү җайланмасы, бик ихтимал, күчереп йөртелмәле "кояш сәгате" турында бара торгандыр.)

Вакытны үлчәү өчен герле сәгатьне Көнбатышта уйлап тапканнар дисәләр дә (XIII гасырда архитектор Виллард де Коннекур альбомында күрсәтелгән примитив механик сәгать яки 1313 һәм 1321 еллар арасында Данте Алигъери үзенең "Илаһи комедиясен"дә тасвир иткән ниндидер тәгәрмәчле һәм суга торган вакыт үлчәү җайланмасы), эшкә яраклы сәгатьне беренче тапкыр Шәрыктә суфилар (Җәләлетдин Руми тарафдарлары-мәүләвиләр XVI гасырда) кулланган булуы турында хәбәрләр бар, чөнки намаз вакытларын төгәл белү Исламда аеруча мөһим. Нәкый Исәнбәт Казан ханнары Гәрәйләр (монда Сәхип, Сафа һәм Үтәмеш Гәрәйләр XVI гасырның беренче яртысында биш тапкыр ханлык иткәннәр) диванханәсендә "гарәби зур сәгатьләр" торуы турында яза. Ләкин шулай да без Исәнбәт файдаланган чыганакта "гарәби" сүзе түгел, бәлки "гарби" (көнбатыш) сүзе язылган булу ихтималын да кире какмыйбыз. Әмма сәгатьнең Казанга Кырым ханлыгы һәм Төркия аркылы (мәүләви суфиларның үзәге шунда) кергән булуы бик мөмкин. Ә Явыз Иван заманнарында Россиядә бай йортларда алтын-көмештән һәм тау бәллүреннән (хрустальдән) ясалган ком сәгатьләре генә таралган була.

Татар диалектында *сәгатьләмә печин*-күк чәчәк (василек посевной). Ул арыш басуында үсә, чәчәге сәгать угы кебек кояш артыннан борылып бара.

Татар теленең Темников сөйләшендә (Мордва республикасы) *"дөн сәәт"*-төнге унике сәгать, төн уртасы.

Тагын кара: ***Кояш сәгате, Сәгату мөнәббиһ.***

**СӘГЫЙ КЫЛУ** *г.* — Хаҗиларның Мәккәдә *әс-Сафа* һәм *әл-Мәрва* таулары арасын 7 тапкыр йөгереп үтүе, хаҗ һәм гомрә гамәлләренең берсе. Бу йоланың килеп чыгышы турында төрле фикерләр яши. Бер версия буенча, әлеге тауларда Адәм галәйһиссәлам белән Һава ана ял иткән һәм сәгый шуның истәлегенә кылына. Икенче версия буенча, Ибраһим пәйгамбәр Аллаһыга табынганда аның каршысына Иблис килеп баскан һәм Ибраһим аңардан йөгереп качарга мәҗбүр булган икән. Ләкин аеруча киң таралган фикер буенча, сәгый йоласы Сафа һәм Мәрва таулары арасында үзенең сусаган баласы Исмәгыйльгә су эзләп йөргән Һаҗәр ана газаплары истәлегенә кылына. Сәгый йоласы Исламга кадәрге чорда шушы тауларда торган *Исаф* һәм *Нәгыйлә* исемле потларга табынуның чагылышы гына дигән фикер дә бар.

Хәзерге вакытта сәгый кылу урыны Мәккә шәһәренең 400 метрлар чамасы озынлыктагы төп урамына туры килә ("100 великих сокровищ" китабы буенча).

Сәгый кылу хаҗның мөһим элементы булып, вәҗиб гамәл саналса да, сәгый кылмау хаҗны яраксызга чыгармый, фәкать корбан китерергә туры киләчәк.

Русча чыганакларда бу термин *"сай"* рәвешендә очрый.

**СӘДДЕ ЧИНИ** — Бөек Кытай стенасы (дивары). Риваятьләрдә сөйләнә торган Искәндәр Зөлкарнәин төзеткән буа белән тәңгәлләштерәләр. Чынлыкта бу стенаны безнең эрага кадәр Кытай императоры Цинь (Чин) илнең төньяк-көнбатыш чикләре буйлап төзергә кушкан. Аны ябашы Ментйән җитәкчелегендә төзи башлаганнар дип исәпләнелә. Ул 4 мең км чамасы озынлыкта, биеклеге 6,6-10 м, киңлеге-5,5 м. Дивар яңа эрага кадәр IV-III гасырларда күчмә халыклар һөҗүменнән саклану һәм Көнбатышка кәрван юлларын тәэмин итү өчен төзелгән. Нурихан Фәттах язганча, аның җирле атамасы — *Чан чин.* // *Ул заман Сәдде Чин артыннан яәҗүҗ-мәҗүҗләр, бәни әсфарлар көтелә иде.* Җамал Вәлиди.

Тагын кара: ***Сәдде Искәндәр, Йәәҗүҗ-Мәәҗүҗ халыклары.***

**СӘЕД, СӘЕТ** г. — Хөкемдар, әфәнде, аксөяк мәгънәсендә. Исламга кадәрге чорда Гарәбстанда кабилә башлыгы. Коръәндә сәед сүзе *Йахйа* пәйгамбәргә карата кулланылган. Кайбер хәдисләргә караганда, Мөхәммәд Пәйгамбәр үзен сәед дип атаудан тыйган.

Сәед — Мөхәммәд Пәйгамбәрнең оныгы *Хөсәеннән* килә торган нәсел кешеләренә бирелгән титул. Сәедләр озын чәч йөртү һәм яшел чалма кию хокукына ия. Ә Пәйгамбәрнең беренче оныгы *Хәсән* нәселен *шәрифләр* дип атаганнар. Казан ханлыгында да хөкемдарларга якын торган сәедләр сыйныфы Пәйгамбәр нәселеннән дип исәпләнгән.

Сәедләр хәзер дә мөселманнар арасында абруйлы затлар булып санала. Ләкин күпчелек Шәрык илләрендә бу термин үзенең башлангыч мәгънәсен җуеп, "әфәнде" мәгънәсендә кулланыла башлаган.

*Сәйидә* — затлы нәселдән булган хатын-кыз.

*Садат* — *сәед*-нең күплек саны шәкеле.

**СӘҖҖАДӘ** *г.* — Намаз кылганда җәелгән келәм, намазлык.

*Сәҗадә* язылышы да очрый.

**СӘЛАМ БИРЕШҮ** — *Сәлам* сүзе, гомумән, исәнлек, иминлек мәгънәсендә булып, адәмнәргә исәнләшү, сәламәтлек һәм иминлек теләү, сәлам бирү өчен хезмәт итә.

Мөселманнар бер-берсе белән очрашканда һәр ике тараф берьюлы сәлам бирсә, сөннәт гамәл үтәлгән булыр. Бер тараф соңга калса, аңа нисбәтән бу гамәл сәлам алу, сәлам кайтару, җавап бирү исемендә булып, фарыз эш хисапланадыр. Рәсүл Әкрәм хәдисендә: "Башлап сәлам бирүче яки башлап сәлам хатлары язучы тәкәбберлектән бизүче, тәкәбберлектән пакьләнүче" диелгән. Туганың яки дустың, мөэмин кардәшең тарафыннан сәлам хаты килә икән, каршы җавап язу ул кешегә тиеш була. Бер мөбарәк хәдистә: "Адәмнәрнең саранннары сәлам бирүдә саранлык кылганы" дип тә әйтелгән. Әхмәтһади Максудиның "Шәригать хөкемнәре" китабында: "Сәлам биргән кешегә, йә бер сүз әйткән кешегә, җавап бирмичә йөзегезне читкә бормагыз,"-диелгән.

Сәлам бирү "Әссәламегаләйкем", "сәлам (тәнвин белән) галәйкем", "Әссәлам галәйк", "сәламгаләйк" кебек җөмләләр белән табыладыр. Соңга калган тараф (сәлам кайтаручы, алучы, җавап бирүче) "Вәгаләйкемәссәлам", "Вәгаләйкәссәлам" рәвешендә әда кыла. Боларның һәрберсе дөрес, ләкин һәркем өчен иң яхшысы — "әссәламегаләйкем" булыр. Әгәр дә "Әссәламегаләйкем вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатү" дисә, бигрәк тә яхшы (Р.Фәхреддин).

Сәлам бирүдә билгеле бер тәртип (нәүбәт) булмаса да, әднияйдән, ягъни иң түбәннән әгълиягә, ягъни иң югарыга, гадәти адәмнән әфзалга, үзеннән курку ихтималы булган кешедән андый ихтимал булмаганга башлап бирелүе хуш күрелә. Шуңа күрә кечекләр олугларга, узгынчылар туктап торганнарга, җайдаклар җәяүлеләргә, азлар күпләргә башлап сәлам бирәләр. Күп халык арасыннан берәр кешенең сәламе бар кеше өчен дә җитә, әмма һәркайсы үзе әда кылса яхшы.

Мөселман кешенең үзенең карендәшеннән киселешеп өч көннән артык торуы хәләл түгел. Мондый кешеләрнең иң яхшылары башлап сәлам биргәне булыр. Хәдис.

Ирләр-ирләр белән, хатын-кызлар хатын-кызлар белән кул кысышып күрешергә тиешләр. Әгәр хатын-кыз ир кеше белән кул кысышып сәламләшергә тели икән (яки киресенчә булса да), бу тыелган гамәлләргә керә (ягъни мәкрух тәхрими гамәл була). *Мосафәхә* — кул кысышу. Бу сүзнең асыл мәгънәсе — уч йөзен уч йөзенә каршы кую.

Намаздан соң: "Такаббәл Аллаһ" дип кул кысышу Пәйгамбәребезнең сөннәте санала (кара: *Тәкабел*).

Шәригать галимнәре хөкем мәҗлесендә, дәрес мәҗлесендә, Коръән уку вә зикер мәҗлесләрендә, хотбә һәм азан вә икамәт тыңлана торган вакытта, табигый хаҗәтләр үтәүче кешеләр арасында, мунча вә хаҗәтханә кебек урыннарда вә гомумән мәшгуль кешеләр арасында сәлам мәкруһ диләр.

Очрашкан вакытта сәлам сөннәт булган кебек, аерылышкан вакытларда да сөннәт. Хәтта язылган сәламне укыган чакта да сәлам әйтеп җавап бирү тиешле диләр.

Югарыда әйтелгәннәрдән тыш, ишарәт белән — мәс., баш ию, кулны авызга һәм

маңгайга тидереп, баш иеп олылау кебек сәлам бирү дә бар, анысы *таманна* дип атала.

**СӘЛӘМ** *г.* – Киләчәктә биреләчәк малга алдан акча түләп кую төсендәге сәүдә; кредитка сәүдә итү. ("Гарәпчә-татарча-русча алынмалар" сүзлеге буенча.) "Рәсүлулла кешеләрне үзләрендә булмаган нәрсәне сатудан тыйды, ләкин *сәләмгә* рөхсәт бирде." (Ягъни, әйтик, җимешләрне пешмәстән элек киләсе бер яки ике еллык уңышын сатуга рөхсәт итте.)

**СӘЛӘФ** *г.* – Үткән замандагы (борынгы) кеше. Коръәндәге мәгънәсе ачык булмаган (мөтәшабиһ) аятьләрне аңлатмыйча гына, Аллаһ сүзе дип кабул итүчеләрне *сәләфчеләр* дип атыйлар. //*Әбҗәд, һәүаз көтүбе сәләфтә бармы-юкмы?* Гаяз Исхакый. *Сәләф гасыры.*

**СӘЛБИ** *г.* – Кире, тискәре; негатив. //*Иҗаби вә сәлби* – уңай (позитив) һәм тискәре (негатив). *Бунлар* (Гаяз Исхакыйны теге яки бу яктан искә төшереп торулар-*А.Т.*) *һич булмаганда сәлби бер фаидә бирәләр.* Җамал Вәлиди (1913). *Сәлби җавап. Сәлби караш.*

**СӘМАГЪ, СИМАГЪ** *г.* – Ишетү, тыңлау. 1.Хәдис гыйлемендә һәм гарәпләрдә китап культурасында хәдисләрне һәм бөтен-бөтен әсәрләрне тапшыру ысулын белдерә. Мөхәддис хәтере буенча яки язудан хәдиснең текстын укый һәм бу вакытта үзенең элгәренә һәм сөйләүчеләр чылбырына (иснад) таянуын әйтә. Шәкерт исә хәдисне исендә калдыра, аны кычкырып кабатлый. Материалның дөрес үзләштерелүенә ышанганнан соң, мөхәддис шәкертенә хәдисне башкаларга тапшыру хокукын (иҗазәт) бирә. 2.Суфичылык терминологиясендә әһәмиятле төшенчә. Тышкы ритмга ияреп, күңелдән Аллаһ исемнәрен әйтеп һәм мистик шигырьләр көйләп символик хәрәкәтләр ясау – экстазга (җәзебкә) керү алымы. Бу мәҗлесләргә музыкантларны һәм җырчыларны гади халык арасыннан чакырганнар. Соңга таба сәмаг(ъ) ныклап әзерләнгән тамашага әйләнеп киткән. Гади кешеләр моны Аллаһы бәрәкәтен алу дип кабул иткәннәр.

Мәүләвия тарикатендә төп сәмагъ "Айыны шәриф" дип атала. Хәзерге вакытта Төркиядә Конья шәһәрендә ел саен декабрь аенда "Айыны шәриф" үткәрелә, ләкин хәзер инде ул дини мәрасим булудан бигрәк, тамашачыларны җәлеп итү өчен оештырылган шоуны хәтерләтә (Әлфинә Сибгатуллина буенча). Сәмагъта катнашучыларны "сәмагъ-зән" дип, ә сәмагъ мәрасимнәрен үтәгәндә җитәкчелек итүчеләрне "сәмагъ-зәнбашы" дип атаганнар.

Тагын кара: ***Ракс, Сәйер, Сәүмага.***

*Дәвамы киләсе саннарда*

# «ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ АТАСЫ»

Татар театр сәнгате – XX гасыр дөнья мәдәниятенең тирән игътибарга лаеклы аерылгысыз өлеше. Быел аңа 100 ел тула. Төрки телле халыклар сәнгатендә иң беренчеләрдән диярлек барлыкка килгән бу театр бүген инде бай тарихы, зур казанышлары, олуг шәхесләре белән дөньякүләм танылды. Халкыбыз хаклы рәвештә горурлана ала: татар театры һәрвакыт гомумкешелек кыйммәтләрен алга куйды, демократик идеяләргә хезмәт итте. Аның сәхнәсеннән бервакытта да милли дошманлык, сугыш, конфронтация идеяләре пропагандаланмады, шәхес иреген чикләү, кысу, кыерсыту, шулай ук көч культы, порнография, җенси азгынлык кебек түбән омтылышлар макталмады. Әгәр милли сәхнә сәнгате халык өчен чын мәгънәсендә тәрбия мәктәбе булып үскән, үзенең эшчәнлеге, ирешкән казанышлары белән дөньякүләм танылу алган икән, бу уңышларда, һичшиксез, татар театрының атасы, режиссер һәм актер Габдулла Кариевның да өлеше гаять зур.



Габдулла Хәйрулла улы Кариев (Миңлебай Хәйруллин) элеккеге Чистай өязе Колбай Мораса авылында, 1886 елның сигезенче (яңа стиль белән егерменче) маенда дөньяга килә. Унике яшенә кадәр туган авылында белем алганнан соң, 1896 елдан күрше Такталы авылы мәдрәсәсендә укый башлый. Гаҗәеп сәләтле, зирәк, унике яшендә ук Коръәнне яттан белгән шәкерткә Такталы мәдрәсәсе мөдәррисе Зариф мулла: «Мужик исеме йөртмәсен», – дип, Габдулла исеме бирә. Шуннан соң Миңлебай Хәйруллин халык арасында Габдулла Карый буларак таныла.

Такталы мәдрәсәсен 1904 елда тәмамлаганнан соң Габдулла Уральск шәһәрендәге мәдрәсәгә укырга керә. Биредә ул Габдулла Тукай, Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин кебек заманның күренекле шәхесләре белән таныша һәм аралаша. Ә 1907 елда инде Габдулла Түбән Новгород шәһәрендә «Сәйяр» артистлары белән очраша һәм тормышын мәңгегә татар театры белән бәйли. 1911 елның декабрь аеннан, ягъни «Сәйяр» труппасы Шәрык клубына штатка алынганнан соң, Габдулла Кариев гомеренең ахыргы көннәренә кадәр Казанда яши.

Татар театр сәнгате турындагы күп кенә хезмәтләрдә, гәзит-журнал мәкаләләрендә, мәдәният әһелләре арасындагы сөйләшүләрдә «Кариев мәктәбе», «Кариев традицияләре», «Кариев мәктәбе традицияләре» кебек сүзләр шактый еш кулланыла. Шулай күп кабатланса да, бүгенгә кадәр бу тәгъбирне һәркем үзенчә аңлый. Чөнки Кариев мәктәбенең принциплары, үзенчәлеге, закончалыклары турында әлегәчә язылганы булмады. Дөрес, кайбер хезмәтләрдә Г. Кариев традицияләренә кагылган фикерләр әйтелә, аерым үзенчәлекләре күрсәтелә. Әмма алардан чыгып кына Кариев мәктәбен тулы күзаллау, аның төп сыйфатларын, үзенчәлекле якларын тану мөмкин түгел.

Габдулла Кариев – театр сәнгатенең төрле өлкәләрендә мәктәп тудырган шәхес. Шуңа күрә гомумирәк булган «Кариев мәктәбе» терминын «Кариевның актерлык мәктәбе», «Кариевның режиссура мәктәбе» кебек төшенчәләргә бүлеп карау дөресрәк булыр.

Татар актер кадрларын үстерү, милли башкаручылык мәктәбе тудыру - театр

сәнгате үсешенең беренче бишьеллыгында Г.Кариев үтәгән төп бурычларның берсе булып тора. Милли театр труппалары дөньяга килү белән үк, аның үзәгендә тормыш дөреслеге, хис, кичереш дөреслеге принципларына нигезләнгән реалистик сәнгать үсә башлый. Татар театрының әйдәп баручы иң көчле артистларның берсе буларак бу юнәлешне Г. Кариев үзе җитәкли. Әлбәттә, аңа бик җиңел булмый.Чөнки ул да тигезләр арасында беренче генә, аның да башкалар шикелле үк махсус театраль белеме юк. Әмма шулай булса да табигать тарафыннан бирелгән олы талант, зур тырышлык, аналитик акыл, армый-талмый үз өстендә эшләү үзенекен итә. Нәтиҗәдә, театр сәнгате өлкәсендә тиңдәше булмаган бөек шәхес тәрбияләнә.

Киң җәмәгатьчелек алдында Г. Кариев иң элек актер сыйфатында таныла. Г. Камал, Г. Исхакый, Я. Вәли әсәрләрендә «Сәйяр» труппасы эшчәнлегенең беренче елларында ук ул иҗат иткән Кәрим («Бәхетсез егет»), Хәмзә («Беренче театр»), Әхмәтҗан («Бүләк өчен»), Мөхәммәтҗан Хафиз («Безнең шәһәрнең серләре»), Сираҗетдин Туктагаев («Банкрот»), Закир («Мөгаллим»), Садыйк бай («Оят яки күз яше») кебек образлары аны тиз арада татар сәхнә сәнгатенең иң алдынгы сафларына алып керә, милли характерлар остасы итеп таныта. Аларда Г. Кариевның драматик таланты, күлкеле персонажлар тудыру мөмкинлекләре ачыла. Ә инде Надиршаһ (Н. Нәриманов, «Надиршаһ»), Городничий (Н. Гоголь, «Ревизор»), Президент (Ф. Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Әлмансур (Г. Гейне, «Әлмансур») кебек дөньякүләм танылган рольләрне башкарып артист үзенең киң колачлы, иркен сулышлы, масштаблы трагик образлар тудыра алуын исбатлый. Аның иҗат офыклары шул кадәр киң ки, хәтта аны чикләрдәй роль бөтендөнья классик драматургиясе мирасын тулысынча барлап чыкканда да табылмас кебек тоела.

Татар театры туган елларда Г. Камал иҗатының чәчәк атып килгән чагы. Шушы ук чорда Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, Ф. Халиди, Я. Вәли кебек әдипләрнең дә яңа әсәрләре бер-бер артлы язылып тора. Көндәлек тормыштан алынган вакыйгаларны, прототипларын урамда очратырга мөмкин булган геройларның уй-кичерешләрен, хис-хыялларын сурәтләгән көнкүреш драмаларын сәхнәләштерү реалистик алым куллануны, тормыш дөреслеге саклануны сорый. Шушы ук вакыт аралыгында, хәтта бераз алдарак та, Н. В. Гогольнең, А. Н. Островскийның, А .П. Чеховның аерым әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә башлый. Милли әдипләрнең пьесалары һәм рус классик драматургиясе үрнәкләреннән төзелгән репертуар татар режиссура сәнгате үсешенең беренче чорында нигез хезмәтен үти.

Тәүге чорда бердәнбер профессиональ «Сәйяр» труппасы күчмә хәлдә яши. Әлегә труппаның режиссеры Г.Кариевның даими эш урыны да юк, спектакльне әзерләү өчен шартлары да җитәрлек түгел. Репетицияләр тимер юл вагоннарында, кунакханә бүлмәләрендә үткәрелә. Труппаның үз декорацияләре дә, аерым образларга атап тегелгән киемнәре дә, әзерләнгән бутафорияләре дә, реквизитлары да юк. Спектакльләр урындагы әзер декорацияләрдән сайлап җиһазландырыла. Артистлар үз киемнәрендә уйныйлар. Мондый шартларда костюмнарның ансамбльлеге, яктырту, музыка, театраль шау-шулар куллану турында уйлау да мөмкин түгел. Шуңа күрә Г. Кариев бар көчен, энергиясен артистлар белән эшләүгә, аларны сәхнә хадимнәре итеп тәрбияләүгә, иҗатларын киңәйтү-үстерүгә юнәлтә. Г. Кариев татар режиссурасы үсешенең беренче этабында әйтәсе фикерләрен сәхнәнең төрле сурәтләү чаралары, аерым режиссура алымнары кулланып түгел, бәлки бары тик артистлар үенына гына таянып тамашачыга җиткерә.

Мәскәү художество театрының әхлак принципларын эшләгән К. С. Станиславский кебек үк, Г. Кариев артистларда югары гражданлык, әхлаклылык сыйфатларын тәрбияләү эшен даими алып бара. «Татар театры атасы» салган әнә шул нигездә халыкның яңа сәнгате төзелә. «Артист өчен театр – тормыш мәгънәсе!» Үзенең көндәлек тәрбия эшендә Г. Кариев менә шушы девизны маяк итеп ала. Аңа үз һөнәрен бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән, җәмгыять алдындагы югары миссияне аңлаган иҗатчылар кирәк була. Ачлык, ялангачлык, бертуктаусыз янау, куркыту

шартларында труппа эшен дәвам иткән Г. Кариев сәнгать өчен үз-үзләрен аямый торган, авыр, ләкин мактаулы хезмәтләренең халыкка кирәклеген тойган артистлар тәрбияләү максатына ирешә. «Татар театры атасы»ның шушы юнәлештәге системалы хезмәте нәтиҗәсе буларак, «Сәйяр» труппасында бик көчле артистлар үсеп чыга. Башка беркем дә булдыра алмаганча кешенең талантын күрә белгән, даими эзләнүдә булган, халык арасыннан талантлы шәхесләрне табып труппага җәлеп иткән Г. Кариевның нәкъ менә реалистик театр актерларын, сәхнәдә «кеше рухының тормышын» гәүдәләндерә алырга сәләтле психологик портрет осталарын тәрбияләве гаять мөһим. Аның тынгысыз кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә татар театры чагыштырмача тиз арада С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Болгарская, Ф. Ильская, Н. Таждарова, Н. Арапова, К. Тинчурин, З. Солтанов, К. Шамил, Камал I, Камал II, Г. .Мангушев кебек тиңдәшсез актерлар йолдызлыгына әйләнде, һәм алар уйнаган күп кенә спектакльләр, бизәлеше һәм костюмнары ярлы булуга карамастан, реалистик режиссураның төп таләбенә — ансамбльлелеккә — җавап бирә иде.

Татар режиссурасы үсешендә Г. Кариев чишкән иң зур проблемаларның беренчесе нәкъ менә үз профессиясенең бөтен нечкәлекләренә кадәр төшенгән артистлар тәрбияләү, хис-кичереш дөреслегенә, табигыйлеккә, гадилеккә, тормышчанлыкка нигезләнгән башкару мәктәбе тудыру була да. Ул хәл иткән икенче зур мәсьәлә — милли тамашачы булдыру, психологик реализм театры принципларына нигезләнеп, тирән, игътибарлы тынлыкка һәм «дүртенче стена» артында барган вакыйгаларга теләктәшлек күрсәтергә сәләтле милли тамашачы тәрбияләү. Мондый проблема театр эшлеклеләре алдында театр барлыкка килгән көннән үк тора. Алдынгы идеяләрне пропагандалау мәсләген тоткан театр үзенең эшчәнлеген прогрессив зыялыларга, киң катлам демократик публикага юнәлдерә һәм ялгышмый..

Икенче мәсьәлә белән өченчесе дә тыгыз бәйләнгән. Монысы заманча спектакльләр тудыру, аларны кую принципларын булдыру һәм урнаштыру. Ислам дине кагыйдәләрендә тәрбияләнгән тамашачы массасын, аның күңеленең иң нечкә кылларына кагылып, заманның иң кискен проблемаларын күтәреп кенә театрга җәлеп итәргә мөмкин иде. Шуңа күрә дә заман темаларына куелган спектакльләрнең төп үзенчәлекләре актуальлек, көндәлек тормыштан алынган материалга таяну булды. Реалистик театр игълан иткән чынбарлыкны «тормышның үз формалары» ярдәмендә чагылдыру принцибы киң катлам публиканың театрга килүен тәэмин итте дә инде.

Шулай итеп, заманча спектакльләр тудыру проблемасы — беренче этапта Г. Кариев чишкән зур проблемаларның өченчесе. Шуңа күрә дә «Сәйяр»нең 1907 — 1911 еллардагы репертуарын жентекләп караганда, заман темасын яктыртмаган спектакльләр анда бик аз табылыр. Бу чорда тәрҗемә әсәрләр чагыштырмача сирәк куела. Куелганнарының да күбесе татарның үз тормышына якынлаштырып, «түбәтәй кигертеп» сәхнәләштерелә. Заман темасына багышланган спектакльләр проблемасын чишүнең төп юлын Кариев милли драматургияне үстерүдә күрә һәм игътибарын шуңа юнәлтә. Бу очракта да режиссер хаклы булып чыга. Замандашлары Г. Камал, Г. Исхакый, Я.Вәли кебек авторларның пьесалары нәкъ менә режиссер күзаллаганча, халыкка аңлаешлы, күңелгә якын, сәхнәгә кую өчен уңай булалар. Татар режиссурасы үсешенең беренче чорында бу авторларның әсәрләре күбрәк сәхнәләштерелү һич тә очраклы түгел һәм әлеге әсәрләр турыдан-туры тормыш тәңгәллекләре театры принциплары нигезендә уйналалар да. Г. Кариев куйган «Бәхетсез егет» (Г. Камал), «Ачлык кушты» (Я. Вәли), «Низамлы мәдрәсә», «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» (С. Рәмиев) кебек спектакльләрдә вакыйгалар «бүген, хәзер, монда», тамашачылар күз алдында үтә торган чын тормыш күренешләре тәэсирен калдыралар. Аларда труппа тормышның үзенә мөмкин кадәр якын килергә, төп-төгәл «тормыш кисәге» репродукциясен күрсәтергә омтыла. Тамаша драма сайлап алган чынбарлык фрагменты барышында булган барлык вакыйгаларны «тормышның үз формалары» ярдәмендә имитацияли. Биредә информация ни кадәр дөресрәк, ни кадәр нечкәрәк — шул кадәр яхшырак. Ә актерларның бурычы — пьесадагы герой кичергәннәрнең барысын да мөмкин булган кадәр чынлыкта кичерү.

Спектакльләр барышында әйләнә-тирәдәге чынбарлыктан алган күзәтүләрне Г. Кариев билгеле бер идея концепциясенә буйсындыра һәм аларны эстетик яктан оештыра. Ә иҗат ителгән образлар табигате, характерлар төрлелеге башкаручы актерның шәхси тәҗрибәсе тирәнлегенә, режиссерның сурәтләнгән тормышны ни кадәр яхшы белүенә бәйле. Алда билгеләп үтелгәнчә, тормышчан театрда иң мөһиме — чынбарлыкны дөрес, төгәл гәүдәләндерү, аңа мөмкин булган кадәр якын килү. Нәкъ менә шушы принципны төгәл саклаганга күрә дә Г. Кариевның иң яхшы спектакльләрендә барысы да «тормыштагыча» була. Рампа янында күзгә күренми торган «дүртенче стена» үсеп чыга, ә аның артында тормыш үзе — театр шартлылыгыннан азат тормыш бара. Табигать күренешләрендә сәхнә мәйданы киң, офыкка кадәр сузылган, бүлмәләр, кешеләр яши торган бүлмәләр шикелле уңайлы, акшарланган мичләр җылы булып күренү зарур. Тәрәзәгә яңгыр бәреп яварга, морҗада җил уларга мөмкин һ. б. Шундый детальләрдән, төсмерләрдән тере сәхнә атмосферасы барлыкка килә. Монда, аерым төсле таплардан, сызыклардан, ноктадардан төзелгән сурәтләрдәге кебек, бөтен нәрсә, әйтерсең, үзара бәйләнеп бара: актерның салынган иңбашлары, ярым ачык ишектән саркылган яктылык, идәнгә ташланган уенчык, җилнең морҗада эчпошыргыч улавы — барысы да гомуми атмосферага «хезмәт итә», бердәй рухта була, тәгаллек хисе тудыра.



*«Сәйяр» труппасы. 1909 ел.*

Югарыда китерелгән тасвирлама нинди дә бер аерым спектакльдән түгел. Бу — Г. Кариев спектакльләренең гомумиләштерелгән образы. Ул Кариев театрында бердәм рухтагы тулы күренеш оештыруда һәр көнкүреш детале, һәр сәнгать чарасы нинди әһәмияткә ия икәнлеге, «кеше рухының тормышын» сәхнәдә гәүдәләндерүче актерның алар белән ничек бәйле булуы турында сөйли.

Революциягә кадәр Г. Кариев җитәкләгән татар театры башлыча реалистик театр, турыдан-туры тормыш тәңгәллекләре сәнгате буларак үсте дип билгели алабыз. Башыннан ук ул реалистик драматургиягә, ягъни «тормышның үз формаларында» чагылдырган драматургиягә нигезләнде. Шул вакытта ук дөнья сәхнәләрен яулап алырга өлгергән Л. Андреев, М. Метерлинк, Г. Гауптман, Г. Ибсен, К. Гамсун, А. Блок һәм башкаларның символик драмалары әлегә күптән түгел генә барлыкка килгән милли театр эшлекләре өчен буй җитмәслек югарылыкта иде. Ә татар драматургиясендә шартлы-метафорик театр алымнарын кулланып язылган бердәнбер әсәр — Г. Колахмәтовның «Ике фикер» пьесасы, патша цензурасының тыюы нәтиҗәсендә, сәхнәгә барып җитми. Шулай итеп, милли драматургия сәхнәне шартлы театр идеяләре белән туендыра алмый, ә яшь режиссура әлегә мондый проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә әзер булмый. Бу шартларда «татар театрының атасы» Г. Кариев сайлап алган реалистик сәхнә сәнгате моделендә үсү юлы тулысынча мантыйклы һәм закончалыклы була. Шуңа да милли режиссерларның революциягә кадәрге чорда хәл иткән барлык мәсьәләләре тормышчанлык театры, психологик реализм принциплары белән тыгыз бәйле була.

1911 елның декабрь аеннан «Сәйяр» труппасы Шәрык клубы штатына алына.

Шушы вакыттан татар театры үсешенең икенче этабы башлана. Штатка алу — гастрольдә йөргәндә артистларга даими эш хакы түләнү, иҗат өчен өстәмә мөмкинлекләр ачу гына түгел, бәлки татар режиссурасы, гомумән, татар театр үсешенә яңа шартлар булдыру дигән сүз дә. Ниһаять, режиссер Г. Кариевның да даими эш урыны була, репетицияләр гел бер урында уздырыла, нәтиҗәдә спектакльләрнең сыйфаты яхшырганнан яхшыра бара. Инде җәмгыять тарафыннан шактый танылу алган милли театр режиссураның сәнгать чараларын үзләштерүне дәвам итәргә мөмкинлек ала. Акрынлап аның спектакльләренә музыка килеп керә, герой белән аның әйләнә тирәсендәге «әйберләр дөньясы»ның бәйләнеше арта. Тиздән һәр постановканы үзенчә, аерым бизәү гамәлгә кертелә. Ансамбльлелек таләпләренә сәхнә костюмы да буйсындырыла. Шул рәвешчә татар сәхнә сәнгате яңадан-яңа режиссура чараларына байый. Милли сәхнәләштерү сәнгате үсешенең икенче чорында татар театрының репертуары сизелерлек киңәя. Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, И. Богданов, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек чордаш драматургларның ул вакытта еш куелган әсәрләре белән беррәттән сәхнәгә чит ил һәм рус авторларының пьесалары да чыга. Революциягә кадәр булган өч труппада — «Сәйяр», «Нур», «Ширкат» труппаларында А. Н. Островский, Ф. Шиллер, Ж.-Б. Мольер, Н. В. Гоголь, С. Найденов һ. б.ларның әсәрләре куела. 1912 елда «Сәйяр»гә Г. Кариев чакыруы буенча татар театрының беренче художнигы Сабит Яхшыбаев килә. Хәзер инде Г. Кариевның реалистик режиссурасы спектакльләрнең бөтенлегенә омтыла.

1912, 1915 елларда татар театрының тагын ике труппасы — «Нур» һәм «Ширкат» төзелә. Татарның беренче артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжская, соңрак Ш. Шамильский һәм М. Мутиннар да режиссерлык эшенә алыналар. Әмма «Сәйяр» труппасы җитәкчесе Г. Кариев бу өлкәдә үзенең беренчелеген саклый.

Татар режиссурасы үсешенең икенче чорында зур классик драма үрнәкләрен сәхнәләштерү проблемасы туа. Бу мәсьәләгә үтә җитди якын килеп, үз иҗатына соң дәрәҗәдә таләпчән Г. Кариев дөнья классикасы әсәрләрен кую өчен рус режиссерларын чакыруны кагыйдә итеп ала. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1913 – 1917 елларда «Сәйяр»дә П. Громов, Н. Михаленко кебек режиссерлар эшли. Репертуардагы бу зур үзгәреш Г. Кариев иҗатын яңа алымнарга, сүрәтләү чараларына баета. Шушы ук чорда Г. Кариев режиссура мәктәбенең төп принциплары формалаша.

Сәнгатьтә реалистик юнәлеш тарафдары Г. Кариев сәхнәдә тормыш вакыйгаларын бөтен байлыгы, тулылыгы белән күрсәтүгә омтыла. Шуңа күрә ул куйган спектакльләрдә сәхнә бизәлеше һәрвакыт тормыш дөреслеге принцибына туры килә. Труппага С. Яхшыбаев кабул ителгәч, дежур декорацияләрдән котылып, һәр спектакль өчен махсус бизәлеш әзерләргә мөмкинлек туа.

Сәхнә бизәлешенең нинди булуына карамастан, Г. Кариев иҗатының барлык чорларында да сәхнәдә гәүдәләндерелгән геройларның эчке дөньялары игътибар үзәгенә куела.

Озак еллар Г. Кариев «Сәйяр»нең җитәкчесе һәм сайлап куелган директоры, ә В. Мортазин-Иманский режиссеры булып исәпләнәләр. Шулай булса да труппада төп режиссерлык эшен Г. Кариев алып бара. Алар башкарган вазифаларны, бүгенге көнгә күчергәндә, баш һәм чираттагы режиссерлар эшенә тиңләп булыр иде.

Татар театрының милли драматургиядән башка үсүе мөмкин түгеллеген яхшы аңлаган Г. Кариев репертуарга татар әсәрләрен күбрәк кертүгә зур игътибар бирә. «Сәйяр» труппасы үсешенең беренче бишьеллыгында язылган милли пьесалар аның репертуарга ихтыяҗын тулысынча диярлек канәгатьләндереп килә. Ләкин труппа даими эш урыны белән тәэмин ителгәч һәм «Нур», «Ширкәт» труппалары да төзелгәч, татарча пьесалар җитмәү нык сизелә башлый. Атна саен куелган спектакльләр өчен яңадан-яңа әсәрләр кирәк була. Бер үк пьесаларның төрле труппаларда уйналуы да аларның матди хәлен яхшыртуга алып бармый. Бу хәлдән чыгу юлын эзләп, режиссер, моңарчы куелырга рөхсәт булмаган барлык әсәрләрне туплап, — алар барысы егерме икегә җыела — матбугат эшләре идарәсенә җибәрә. Шушы пьесаларны куярга рөхсәт сорап, гариза да яза. Шулай акрын-акрын татар театры репертуары

Г. Камалның «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», Ф. Әмирханның «Яшьләр», «Тигезсезләр», М. Фәйзинең «Галиябану», К. Тинчуринның «Соңгы сәлам», «Беренче чәчәкләр» кебек сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары әсәрләр белән тулылана.

Г. Кариев татар халкының күп кенә танылган драматурглары белән тыгыз элемтәдә була, кемнең нинди әсәр язуын, пьесаның чама белән кайчанрак тәмамланасын алдан белеп тора. Тормышта очраган кызыклы характерлар турында драматургларга сөйли, яңа темалар күрсәтә. 1914 елның бишенче гыйнварында «Йолдыз» газете аның «Милли театр хакында» исемле шактый күләмле мәкаләсен бастыра. Бу хезмәтендә автор милли драматургларның азлыгы, алар иҗатына тиешле игътибар, рухи һәм матди ярдәм кирәклеге турында яза.

Башка шәһәрләрдә яшәүче драматурглар да аның игътибарыннан читтә калмый – ул алар белән дә хәбәрләшеп тора. Әгәр нинди дә булса әсәрнең уңыш белән баруы ишетелсә, шунда ук авторга хат белән мөрәҗәгать итә. Җибәрелгән пьеса Г. Кариевны канәгатьләндерсә, ул репертуарга кертелә. Г. Каривның Ш. Камалга «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен куярга рөхсәт биргәне өчен рәхмәт юллап, пьесаны көтеп калуын әйтеп язган хаты сакланган. Шундый ук хат алышу М. Фәйзи белән дә булганлыгы билгеле.

1917 елның җәендә пьесалар кытлыгын бетерү өчен Г. Кариев халык тормышыннан алынган пьесаларга конкурс игълан итә. «Кояш» газете битләрендә басылган конкурс шартлары режиссерның драма әдәбиятына карашын, таләпләрен аңлау өчен мөһим документ булып торалар.

Конкурс яхшы нәтиҗәләр бирә. Ул моңа кадәр билгеле булмаган берничә язучы белән таныштыра. 1917 елның 14 августында «Сәйяр»дә Фәтхи Бурнашның «Адашкан кыз» драмасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы була. Бераздан соң Миргазиз Укмасиның «Наместник урыны өчен көрәш», Әхмәд Мөнирнең «Солтан Фатыйх» пьесалары сәхнәгә күтәрелә. Танылган язучылардан Мирхәйдәр Фәйзи, Шәриф Камал конкурска үзләренең яңа әсәрләрен тәкъдим итәләр.

Г. Кариевның татар драматургиясенә күрсәткән аеруча зур хезмәте -К. Тинчуринны «Сәйяр»гә кабул итүе һәм аны сәхнә хезмәткәре итеп тәрбияләве. Труппага өйрәнчек актер итеп алынган К. Тинчуринның артист, режиссер, драматург буларак тәүге адымнары ихлас күңелле, таләпчән Г. Кариев күзәтүендә ясала. Октябрь революциясеннән соң «татар театрының атасы» үзе төзегән театр мәктәбе традицияләрен, атап әйткәндә, режиссура мәктәбе принципларын инде сәхнә сәнгатен тирәннән белүче, шәхес буларак та өлгереп җиткән К. Тинчуринга тапшырып калдыра.

Революциягә кадәрге «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларының режиссурасы «Сәйяр»нең сәхнәләштерү сәнгате башлап җибәргән эстафетаны дәвам итә һәм параллель рәвештә үсә башлый. Уфада «Нур»ны оештыручы С. Гыйззәтуллина-Волжская да, Оренбургта «Ширкәт»не төзегән В. Мортазин-Иманский да «Сәйяр» труппасында тәрбияләнгән кешеләр. Шуңа күрә дә С. Гыйззәтуллина-Волжская 1912 елдан, ягъни труппасы эшли башлаган көннән үк, Г. Кариев кебек, режиссураның сәнгать чараларын үзләштерүгә керешә һәм үзенең сәхнәләштерү эшчәнлеген татар режиссурасы үсешенең икенче этабыннан башлый. Ә яңа оештырылган «Ширкәт»нең режиссерлары В. Мортазин-Иманский һәм М. Мутин алдында бу проблема тормый. Чөнки революциягә кадәрге татар драматик труппаларының өченчесе дөньяга килгәндә инде режиссураның сәнгать мөмкинлекләрен үзләштерү процессы соңгы стадиясенә кадәр җитеп бара. В. Мортазин-Иманский Г. Кариев һәм С. Гыйззәтуллина-Волжская белән беррәттән милли репертуарны баету өстендә эшли. Татар драматургиясенең классик үрнәкләре дип танылган әсәрләрдән М. Фәйзинең «Галиябану»ын, Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен һәм башкаларны беренче булып сәхнәләштерү шәрәфенә «Ширкәт» труппасы ия була. 1915 елдан башлап татар мәдәниятенең өч үзәгендә – Казанда, Уфада һәм Оренбургта – бер-берсенә ярдәм итеп һәм баетып өч труппа эшли. Һәм «Сәйяр», «Нур» һәм «Ширкәт» режиссерларының тәҗрибәсе алга таба татар театрының сәхнәләштерү сәнгатенең бердәм хәзинәсендә туплана.

Татар театрының беренче сәхнәләштерүче-режиссеры булып хаклы рәвештә Габдулла Кариев санала. Югары культуралы, заманы өчен тирән белемле, татар профессиональ театрын оештыруның иҗтимагый һәм сәяси әһәмиятен яхшы аңлаган кеше булуы өстенә, ул шул ук вакытта искиткеч зур актерлык талантына, оештыру сәләтенә, бик яхшы режиссер һәм педагог сыйфатларына ия була.

Тормыш хакыйкате принципы Г. Кариевның актерлык һәм режиссерлык эшчәнлегендә төп принцип була. Шуның өстенә, режиссерлык тәҗрибәсендә ул һәрвакыт драматик материалны нигез итеп ала һәм аннан читкә тайпылмыйча, аны мөмкин булган кадәр тулы итеп сәхнәдә гәүдәләндерергә тырыша. Әмма образларның чишелешендә ул беркайчан да драматик материал белән генә чикләнми. Тормыш аның өчен бетмәс-төкәнмәс байлык, иҗат потенциалының алыштыргысыз чыганагы булып тора. Әгәр аның эмоциональ хәтерендә эш өчен кирәкле материал булмаса, ул пьесада тасвирланган мохит кешеләре арасына чыгып китә. Персонажларның реаль прототипларын җентекләп өйрәнгәннән соң гына ул эшен яңадан дәвам итә. Үзе күзәтүчән кеше буларак, ул үзенең актерларын да шуңа өйрәтә. Актерлар белән эшләгәндә Кариев шәхси тормышыннан кызыклы эпизодлар турында сөйли, әдәби тәңгәллекләр китерә, теге яки бу башкаручының ролендә берәр деталь килеп чыкмаганда, ахыр чиктә, күрсәтү алымнарын файдалана.

Реалистик юнәлеш режиссеры буларак, Г. Кариев сәхнәдә «тормыш кисәген» бөтен тулылыгы белән гәүдәләндерергә омтыла. Шуңа күрә аның спектакльләрендә сәхнә бизәлеше һәрвакыт тормыш хакыйкате принцибына туры килә: әйтик, әгәр бу интерьер икән – ул көнкүрештәге кебек ышандырырлык, артык вак детальле түгел, әлбәттә, чөнки күчмә театр шартлары купшылыкка мөмкинлек бирми. Сәхнәдә һәрвакытта диярлек актерларга уен барышында зарури әйберләр генә була. Милли режиссура үсешенең беренче чорында Г. Кариев куйган спектакльләр нигездә камера характерында булалар. Ләкин масштаб, тышкы бизәлеш ничек кенә булмасын, эшчәнлегенең барлык этапларында да Кариевның игътибар үзәгендә персонажларның эчке дөньясы була. Һәр геройның психологиясен, характер үзенчәлекләрен, эш-гамәлләре акланышын төптән тикшереп, ул тирән реалистик, психологизм тулы сәхнә әсәрләре тудыра.

Әгәр Габдулла Кариевның спектакльне эшләү ысулын тасвирлап карасак, беренче чиратта аның иң элек актер булуы һәм режиссурага актер иҗаты күзлегеннән каравы турында әйтергә кирәк. Спектакльне куюга керешкәндә Кариев күбрәк персонажларның характеры, язмышлары һәм үзләрен тотышы турында уйлый, драматик материалны тормыштан алынган күзәтүләр белән тулыландыра. Шуннан соң бөтен актерларның рольләрен уйнап күрсәтеп, аларны персонажларның эчке логикасы буйлап үткәрә. Кариевның режиссурасы гадилеккә, фикер төгәллегенә, тормышчанлыкка, дөреслеккә омтылышы белән аерылып тора. Аның спектакльләрендә мизансценалар ике төп таләптән чыгып төзелә: актер мәнфәгате һәм тормыш хакыйкате.

Г. Кариев, спектакль барышында рухланып, кабынып китүчән, импровизацияләргә бик тартым актер буларак, репетиция процессына да зур җанлылык һәм темперамент кертә. Ул әзер, эшкәртелгән план белән труппага сирәк килә. Шуңа күрә аның репетицияләре башта әкрен темпта барган шикелле. Ләкин бу озакка сузылмый. Әкренләп вакыйгаларга кереп китеп, рухланып һәм башкаларны да рухландырып, Г. Кариев актерларны тиешле иҗат халәтенә китерә. Бу этапта инде Г. Кариев актерларга ирек бирә. Режиссерның ихтыяр көче һәм фантазиясе белән хәрәкәткә китерелгән актерлар яңадан-яңа кызыклы детальләр, җайланмалар тәкъдим итәләр. Спектакльне куючыга башкаручылар уйлап тапканнарны сайлап алып ныгытырга гына кала. Әгәр репетициянең барышы тоткарланса, тукталып калса, шундук бер-бер артлы актерлар урынына уйнап күрсәтү, чын-чынлап тормышчан, көчле төсмерләр, чишелешләр, мизансценалар тәкъдим итү башлана. Шулай куәтләндерелгән иҗат процессы яңа көч белән дәвам итә, булачак спектакльнең аерым өзекләре, пәрдәләре туа. Ләкин кайвакытта репетицияләрдә иҗат чаткысы кабынмый, спектакльгә әзерлек

әкрен, сүлпән бара. Мондый очракларда Г. Кариевның берәр кичектергесез эше «исенә төшә», һәм алга таба репетиция процессын В. Мортазин-Иманский (ә ул труппадан киткәннән соң К. Тинчурин) алып бара. Г. Кариевның әйдәп баручы актер В. Мортазин-Иманский белән хезмәттәшлеге үзенчәлекле бер режиссерлар коллегиясе тәшкил итә, гәрчә беренчесе рәсми рәвештә труппаның җитәкчесе, сайланган директоры, ә икенчесе – режиссеры булып исәпләнә. Бу коллегия аларның озакка сузылган: 1907 елда Түбән Новгородта башланган һәм В. Иманскийның труппадан китүенә, ягъни 1915 елның җәенә кадәр дәвам иткән хезмәттәшлеге нигезендә барлыкка килә. Труппада хәлиткеч тавыш бирү хокукына Г. Кариев ия була, әмма ул иҗат мәсьәләләрен берүзе, башкалар белән киңәшләшмичә сирәк хәл итә. Бигрәк тә труппага яңа кешене кабул итүгә җаваплы карый. Революциягә кадәрге «Сәйяр» өчен актерлар сайлап алу һәм актер ансамбле булдыру, оештыру нәкъ аның тырышлыгы нәтиҗәсе.

Труппаның спектакльләре ансамбльнең тигез хокуклы әгъзаларының иҗади бердәмлеге, сәхнәдәге аралашуы нигезендә тудырыла. Труппада «премьер»лар да, аеруча өстенлекле актерлар да булмый, драматик материал таләп итмәсә, барысының да бер актерга буйсынуы да булмый. Пьеса үзе таләп иткәндә генә ансамбль «солист һәм хор» принцибында төзелә. «Сәйяр»гә биш ел тула дигәндә труппаның актерлар коллективы бөтенләй диярлек ансамбльлелек таләпләренә җавап бирә. Һәр актерның да репертуарда үзенә генә хас урыны була. Бу урын аның сәләтлелек дәрәҗәсе белән билгеләнә. Артистларның эчке мөмкинлекләрен белү труппа режиссерларына рольләрне дөрес бүлүдә ярдәм итә. Ә бу үз чиратында, спектакльдә ансамбль булдыруга, аның идеяләрен, эчтәлеген тулы чагылдыруга булышлык итә.

Тиешле драматургия булмый торып театрның үсә алмаячагын бик яхшы аңлаган Габдулла Кариев театр репертуарын төзүгә гадәттән тыш нык игътибар бирә. Иң әйбәт драматургларның нәрсә язганнарын һәрвакыт белеп тора, аларга аерым характерларны тудыруда ярдәм итә, темалар күрсәтә. Г. Кариев актерларда даими рәвештә югары сәнгати һәм эстетик принциплар тәрбияли. Алар яңа театр бинасын төзү өчен фундамент ролен үтиләр. «Артист өчен театр – яшәү мәгънәсе». Үзенең тәрбия эшендә режиссер Кариев шул девизга нигезләнә.

Г. Кариевның режиссура гына түгел, ә гомумән татар театрының барлыкка килүендәге һәм үсешендәге ролен бәяләп бетерү дә кыен.

Яшәгәндә үк ул үз халкының бөек таланты буларак кабул ителә. Аның сәхнә эшчәнлегенең 5 еллык юбилеен бәйрәм итү көнне бирелгән адреста түбәндәге сүзләр очраклы түгел:

«Бу көннәр татар халкы сезнең биш сәнә буенча «Сәйяр» труппасын ялыкмый идарә кыйлуыгызны, татар театрын тәрәкъкый юлында күрсәткән корбанлыгыгызны, тагы татар театры гамәлендә моңа кадәр Нәзыйрсыз артистлык талантыгызны тәкъдир кылып, сезне «татар театрының атасы» дип исемли» Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм башкалар имзалаган бу юллар (барлыгы житмешкә якын кеше кул куйган) татар халкының алдынгы эшлеклеләре Г. Кариевны ни кадәр югары бәяләүләрен һәм яратуларын күрсәтә.

Г. Габдулла Кариев, пәйгамбәрләр шикелле үк, бу дөньяга аерым миссия өчен китерелгән шәхес. Аның гомеренең төп бурычы – татар театрын тудыру, юнәлешен билгеләү, баштагы үсеш баскычларын уздыру булгандыр. Шушы миссияне үтәгәннән соң, ул бик иртә, бары тик 34 яшендә (бусы да пәйгамбәрләр яше диярлек) дөньядан китә. Китә, ләкин ул башлаган эш, аның тормышының мәгънәсе – татар театры кала. Шуңа күрә җир йөзендә татар халкы яшәгәндә Габдулла Кариев исеме дә онытылмаячак.

**Гали АРСЛАНОВ,**
сәнгать фәннәре докторы,
Татарстанның атказанган фән эшлеклесе

# РУХИ БИЕКЛЕК

Әйе, барыбызга да яхшы мәгълүм: драма әсәрләре, әлбәттә, сәхнәдә уйнау өчен языла. Алай гына да түгел—драматург тамашачыга житкерергә теләгән төп фикер нәкъ менә театр сәхнәсендә бөтен тулылыгында ачыла, режиссер табышлары, артистлар уены, декорация һәм музыка ярдәмендә залда утыручыларның жанын-рухын биләп ала.
Ләкин шул ук вакытта диалог-монологлар рәвешендә язылган пьесаның әдәби текст буларак та укучыга зур тәэсир ясавын һич онытырга ярамый. Әле бит язылган драма әсәрләренең барысы да сәхнәгә куелмый һәм куела да алмый. Теге яки бу театрның традицияләренә, режиссерларның мөнәсәбәтенә бәйле аз әсәрләр генә спектакль буларак дөньяга чыга. Шуңа да драматургиянең торышы, әдәби процесстагы урыны, аерым авторлар ижаты турында сүз алып барганда без, беренче чиратта, китаплар, журналлар аша укучыга килеп ирешкән пьесаларны күздә тотабыз.




Ю. Сафиуллин исеме театр сөючеләргә яхшы таныш. Үткән гасырның житмешенче елларында драматургияга килгән авторның «Әллә өйләнергә инде?..», «Ни булган бу ирләргә?», «Алмазбулат», «Ләйсән ире Хәсән», «Пар канат», «Идегәй», «Йөзек һәм хәнжәр» кебек пьесалары төрле театр сәхнәләрендә уңыш белән барды һәм бүген дә күпсанлы тамашачыларның алкышларын яулауны дәвам итә. Аның «Менә без дә үсеп життек... «(1983), «Пар канат»( 1997) жыентыклары да тиз арада үз укучысын тапты.

Ю. Сафиуллинның яна китабына («Әллә өйләнергә инде?» ТКН. 2004) төрле елларда язылып, тамашачының ихтирамын яулаган пьесалары белән бергә, төрле сәбәпләр аркасында үз вакытында китап сөючеләргә килеп житә алмаган комедияләре һәм соңгы еллар сәхнә әдәбиятында яна сүз буларак кабул ителгән трагедияләре туплап бирелгән. Алар сурәтләнгән тормыш материалы, күтәрелгән тема-проблемалары белән генә түгел, бәлки жанрлары, үзенчәлекле геройлары, сәнгати сурәтләүдәге табышлары белән дә аерылып торалар.

Һәрбер яңа китап ул—әдипнең ижат биеклеген барлау, нәтиҗәләр ясау һәм житди уйланулар жимеше булып тора. Әлеге жыентык та драматург эзләнүләренең юнәлешен, әдәби тәжрибәсе, осталыгы артуын, сәхнә үзенчәлекләрен тирәнрәк үзләштерә баруын сизәргә, тоемларга мөмкинлек бирә. Пьесаларны инләп үтә торган төп сыйфат милли эчтәлек белән бәйле. Ю. Сафиуллин—жаны-тәне белән милләтпәрвәр шәхес. Ул һәр әсәрендә халкыбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен тирәнтен борчылып яза. Милләтебезгә хас унай күренешләр өчен шатланып, аны алдагы буыннарга да үрнәк итеп куйса, рухи-мәдәни үсешебезгә комачаулый торган сыйфатларны күреп аның жаны әрни, аларны әдәби чаралар ярдәмендә тәнкыйтьли, ирония белән көлә яисә сарказм аша фаш итә ул. Шуңа да әлеге пьесалар, вакыт-урын ягыннан төрле елларны һәм чорларны чагылдырсалар да, гаять заманча янгырыйлар.

Заманчалык. Әлеге төшенчә Ю. Сафиуллин ижатына хас башка үзенчәлекләрне дә үз эченә ала: төрле жанрларда бердәй тигез, көчле ижат итүе; пьесаларының жанр ачыклыгы; сәхнә закончалыкларын яхшы белүе; конфликт-каршылыкларның төрлелеге; сурәт чаралары, алымнарының бай төсмерләре булу; укучы-тамашачы белән бергә нәкъ менә заман куйган сорауларга жавап эзләве;

Юныс Сафиуллин. Әллә өйләнергә инде? — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2004 ел.

үз чоры сыйфат-билгеләрен туплаган образ-характерлар, ә иң яхшы әсәрләрендә әдәби типлар иҗат итүе һ. б. Җыентыкка туплап бирелгән пьесаларның бишесе комедия, берсе—әкият-пьеса, икесе трагедия жанрына карый. Әйтергә кирәк, Ю. Сафиуллин—драматургиянең төп өч жанрында да актив эшләүче аз санлы авторларның берсе. Үзенең драматик коллизияләр тудыру осталыгын ул «Пар канат» җыентыгында күрсәткән булса, әлеге китаптагы комедияләрендә көлүнең төрле алымнарыннан иркен файдалана. Узган йөзьеллыкның җитмешенче еллар башында язылган «Ур-тура, сатирик», «Буйдак ир һәм танышлары» пьесалары әдипнең сәнгати фикерләү үзенчәлеген, тормышка актив позициясен күрергә, аңларга ярдәм итә. Торгынлык елларының идеологик һәм цензура басымын, социалистик реализм кысаларын тойган хәлдә Ю. Сафиуллин яшәп килгән системаның кимчелекле якларын шактый усал тәнкыйть утына тота. «Ур-тура, сатирик» комедиясенең герое Сатирик әйткәнчә, аларны чәчәкләр, йолдызлар һәм балыклар турында гына язарга мәҗбүр иткәннәр. Автор совет идеологиясенең, «типиклыкны яклау» дигән булып, бериш геройларны бертөрле вакыйга-хәлләргә куеп сурәтләүне таләп итүеннән дә ирония белән көлә.

Шартлылык алымнары драматургка совет җәмгыятенең кешене бер шөрепкә әйләндерүен, совет-партия җитәкчеләренең чикләнмәгән хокукларга ия булуын бөтен барлыгында ачу мөмкинлеге бирә. Автор, А.С.Пушкинның «Балыкчы һәм балык турындагы әкият»енә ияреп, яңа дөнья сурәтли. Әлеге шартлы-фантастик күренешләрдә торгынлык елларының партия-совет җитәкчеләреннән көлү иң югары ноктасына җитеп, ул системаның яраксызлыгын, иҗтимагый үзгәрешләрдән артта калып, абсурдлык дәрәҗәсенә җитүен фаш итә. Бирелә көлү комедиянең төп сыйфаты буларак алга чыга.

Драматургның «Буйдак ир һәм танышлары» комедиясе күптармаклы, киңпланлы булуы һәм ирләр белән хатын-кызлар мөнәсәбәтен шактый җентекле, ачыктан-ачык сурәтләве белән игътибарга лаек. Пьеса эчтәлеген көнкүреш вакыйгасына гына кайтарып калдыру, аны бик нык тарайту булыр иде. Яшәешнең моңа кадәр читтә калып килгән якларын сәхнә яктысына чыгарып, драматург тормыштагы әхлаксызлык, имансызлык күренешләренең сәбәпләрен үткән, бүгенге, киләчәк бәйләнешендә эзли. Вакыйга-күренешләр, нигездә, «Чын мәхәббәт бармы ул?» «Азгын ирләр, әхлаксыз хатын-кызлар каян килә?» «Бозыклыкның чиге бармы, аннан ничек котылырга?» кебек сорауларга җавап табуга бәйле үстерелә.

Автор кызыклы сәхнә алымына—«уен»га мөрәҗәгать итә. Пьесадагы вакыйгалар артист Буйдакның инглиз драматургы Шекспир язган атаклы «Отелло» трагедиясе буенча репетиция ясау күренешләре белән кушылып, бәйләнеп бара. Беренче планда—иң түбән инстинктларга йөз тотып, һәртөр ялган, мәкер аша үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы хатын-кызлар, икенче планда—фаҗигале мәхәббәт тарихы—яраткан Дездемонасын көнчелектән үтергән Отеллоның рухи газапланулары. Әлеге бөеклек һәм түбәнлекнең үрелеп баруында беренчеләрнең—заман геройларының—бөтен бушлык-мәгънәсезлекләре, әхлаксызлыклары тагын да тулырак ачыла.

Хатын-кыз язмышы татар әдәбиятында төп темаларның берсе булып тора.

Ю. Сафиуллин сурәтләгән хатын-кызлар исә үзләренең әхлакый тотнаксызлыгын ирләр белән тигез хокуклы булу дип аңлатырга тырышалар: тарталар, эчәләр, никахсыз килеш теләсә кемнең муенына асылынырга торалар. «Мескен татар хатынының гына күрмәгәне калмый. Кайчан без дә сезнең белән бер хокукта булырбыз икән? Әллә христиан диненә күчәсе инде?» диючеХаным өчен бернинди әхлакый кыйммәтләр юк. Үз рәхәте өчен теләсә нинди түбәнлеккә барырга әзер хатын бурыч, җаваплылык төшенчәләренең мәгънәсен аңламый һәм, иң кызганычы, аңларга да теләми.

Драматург әлеге яман күренешнең сәбәпләре турында уйлана. Аның берсе Шекспир әсәренә бәйле ачыла. Трагедиягә бәя биреп, Буйдак болай ди: «Шекспир, Дездемонаның үлемендә төп гаепле кеше дип Ягоны—әйе, явызлыкны иблиснең үзеннән дә остарак эшли торган көнбатыш кешесе Ягоны—күрсәтә». Пьесаның янача куелышында Яго хатыны урлаган кульяулыкның татар милли бизәкләре белән чигелгән булуы, әдәби деталь буларак, «халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре Көнбатышның көчле йогынтысында таркала,

югала, кими» дигән фикергә китерә. Икенче яктан, халыкчан яшәү рәвешенең югалуы чит гадәтләрнең үтеп керүенә, әхлаксызлыкның артуына китерә. Билгеле инде, бар гаепне Көнбатышка гына аудару дөрес булмас иде. Автор тагын бер сәбәпне эчүчелекнең артуында күрә. Әлеге афәт милләт тамыры булган авылга да үтеп кергән. Әнә бит Саниянең авылны тизрәк онытып, шәһәрләшәсе килүендә дә исерек әтисе китергән җан газапларыннан котылу теләге ята.

Пьесадагы көлдерә дә, елата да торган конфликт оптимистик рухта чишелә. Моңа кадәр апасы Лига-Ләмиганың сүзләрен сөйләп килгән Сания үз асылына кайта һәм Ханым белән Лигага кем булуларын йөзләренә карап әйтә. Шагыйрьнең Сания каршында тезләнгән хәлдә кулыннан үбеп: «Милләтебезгә хыянәт итмәгән асыл ярларыбыз!» дигән артык купшы янгыраса да, автор позициясен төгәл аңлата. Драматург хатынкызларны, гомумән, халкыбызны әхлакый түбәнлектән саклап калу юлын үзебезгә хас яшәү рәвешенә, ата-бабадан килгән сыйфатларга, йола-гадәтләргә тугры калуда, аларны тапшыруда буыннар арасында өзеклек килеп чыкмауда күрә.

Шулай да тормышның җитди проблемалары куелган бу пьесага җыйнаклык, жанр ачыклыгы җитеп бетми. Балалы хатын, Карт ир, Карт хатын, Усал егет, Телсез егет кебек образларны кертү, алардан ниндидер фикерләр әйттерү берниндидә яңалык, ачыклык алып килми. Ханым һәм Лиганың әдәпсезлеге аркасында шәхси фаҗигаләре сиземләнсә дә, чишелештә ул чагылыш тапмый. Әсәрнең жанры комедиядән бигрәк трагикомедиягә тартым. Вакыйгалар барышында берничә тапкыр Шагыйрьнең шигъри юллары яңгырый. Төп геройларның эш-гамәле белән әлеге юллар арасында бәйләнеш ачык түгел. Сания аны кыз-кыркын язмышы белән бәйле дисә, Буйдак ул шигырьдә «фаҗига, үкенү һәм тагы әллә ниләр» күрә. Асылда исә шигырь дип атавы да кыен булган, сәнгати яктан гаять йомшак чыккан әлеге тезмәләрдәге «чәчәкләр ага» сүзләре җиде ятларга, читләр кулына киткән хатын-кыз язмышын аңлата диелсә дә, алар укучыны да, тамашачыны да ышандырмый. Чөнки әлеге фикер вакыйга-күренешләрдән, характерлар яшәешеннән үсеп чыкмый.

Ю. Сафиуллинның «Ләйсән ире Хәсән», «Әллә өйләнергә инде?..» комедияләре үз вакытында театр сәхнәләрендә уңыш белән барды һәм күпсанлы мәкалә-рецензияләрдә авторның табышлары белән бергә, аерым кимчелекләре дә күрсәтелде. Әлеге пьесаларда яшәешкә шактый тирән үтеп кергән мещанлык, башкалар хисабына яшәү, байлык артыннан куу кебек күренеш-сыйфатлар тәнкыйтьләнә. Җыентык исеменә үк чыгарылган «Әллә өйләнергә инде?..» комедиясендә, Әхмәт исемле 32 яшьлек егетне өйләндерү мәсьәләсенә бәйле, ике төркем арасында комедиячел конфликт оеша: һәркайсы егетне үзләре теләгән кызга өйләндерергә тели. Пьесада укучы-тамашачының игътибары, билгеле инде, кәләшлеккә кандидатлар булган Лена белән Гөллигә юнәлтелә. Әйтергә кирәк, әлеге геройлар аерым сыйфатлары белән генә бирелә, алар канлы образлар буларак ачылып бетмиләр. Рәйсәнең сенлесе Лена—җилбәзәк кыз, әлегәчә күбрәк апасы хисабына яшәп, ул киләчәге турында әллә ни уйланмый да. Булачак иренең кем булуы аның өчен мөһим түгел: теләк-капризларын үтәсен дә, матди яктан җитеш булсын. Ахырда Ленаның үзе артыннан йөргән егет белән апасыннан качып китүе, эш-гамәлләренең көтелгән нәтиҗәсе булып тора. 18 яшьлек Гөллине исә драматургның яратып, үз итеп сурәтләве сизелеп тора. Яшь булуына карамастан, ашсуның рәтен белә, рухи сафлыгы, күңел матурлыгы белән ул Әхмәтнең игътибарын җәлеп итә. Гөллинең «тышкы матурлык—чуклы тай, ә эчке матурлык—күктәге ай» дип сөйләнүендә үк аның акылы сиземләнә.

Комедиянең төп герое булган Әхмәт вакыйга-күренешләрдә билгеле бер үсеш-үзгәреш кичерә. Баштарак ул шактый беркатлы, ваемсыз, үзен теләсә ничек алдаларга, түбәнсетергә юл куючы буларак күренә. Әмма болар тышкы чагылыш кына икән. Монологында аның чын йөзе, рухи дөньясы ачыла: «Мин дә бит җан иясе! Бармы менә бу җир йөзендә бер генә парсыз бөҗәк? Судагы кондызлар да, күктәге кошлар да парлы-парлы. Ни өчен әле мин генә ялгыз яшәргә тиеш? Минем дә бит һәркем кебек мәңге яшисем килә: балаларымда, оныкларымда... «Әлеге тыйнак, оялчан егет матур яклары белән ачыла. Ул тырыш, булдыклы, гадел, баш-

каларга ярдәмчел һәм гаять ихтирамлы. Үзе әйткәнчә, «таш белән бәргәнгә аш белән генә җавап кайтаручы» егет нәкъ менә әхлакый сыйфатлары белән хөрмәт уяткан Гөллине үзенең яры итә.

Көнкүреш комедиясенә хас булганча, вакыйгалар бик җинел хәл ителә. Әхмәт белән Гөллинең үзара килешүе көрәш интригасын, каршылыкны юкка чыгара. Рәйсә белән Лена да шактый тиз үз максатларыннан кире чигенәләр.

Алай гына да түгел, Рәйсәнең Әхмәткә дип бүләк тотып чыгуы, аның килешергә, уртак тел табарга омтылышы булып аңлашыла.

Драматург халыкчан җор тел белән яза. Иркен кулланылган сүз уйнату алымы көлкеле ситуация тудырырга, геройларның характерын, теләк-омтылышын ачарга ярдәм итә. Рифмалы сөйләм, мәкаль-әйтемнәр, билгеле шигъри юлларны үзгәртеп әйтү, әдәби детальләр һ. б. чаралар комедиячел интриганы баета, пьесага җинел пафос өсти.

Драматург сайлаган тормыш материалын, билгеле, яңа дип булмый. Әмма аның табышы кызыклы ситуацияләр тудыруда һәм комедиячел образлар иҗат итүдә. Югарыда искәртелгәнчә, Ю. Сафиуллин геройлары чорның үзенчәлекле типлары дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәгәннәр. Шулай да эш-гамәле белән һәрдаим үз-үзен фаш итүче Рәйсә, энесенә ярдәм итәм дип йөреп, асылда «бүрәнә аркылы бүре куучы» чая Һәдия, аның кунакка кайткан ахирәте, бер үк сүзне күп тапкырлар кабатлаучы Сара башкалардан аерылып торучы образлар буларак хәтердә кала.

Комедия жанры безнең драматургиядә (аерым чорларны исәпкә алмаганда) әйдәп баручы ролен үти, театр репертуарларының яртысыннан күбрәген алып тора. Шулай да XX гасырның җитмешенче елларында, идеологик басымның көчәюе нәтиҗәсендә, социаль-иҗтимагый, сәяси проблемаларның читтә калуы, тыелган темалар барлыкка килү белән комедия жанрындагы эзләнүләр кими. Ә инде 90 елларда хәл уңай якка үзгәрә. Җәмгыятьтә барган үзгәрешләрнең көтелгән нәтиҗәләр бирмәве, яшәештә әхлаксызлык, миһербансызлык күренешләренең киң тамыр җәюе, бюрократизмның көчәюе сәбәпләрен эзләү әлеге жанрның активлашуына китерә. Т. Миңнуллин, З. Хәким, И. Юзеев, Ф. Яруллин, Д. Салихов, М. Гыйләҗев, Р. Батулла һ. б. драматурглар иҗатында һәртөр рухи түбәнлек, тар мәнфәгатьләр белән яшәү, дәрәҗә алдында баш ию һ.б. сыйфат-күренешләр көлү объекты итеп алына. Шулар арасында Ю. Сафиуллинның «Сукбай артистлар» комедиясе үзенчәлекле хәлләргә мөрәҗәгать итүе белән аерылып тора. Спектакль куярга Кукмарага барырга җыенган бер төркем артистлар белән көтелмәгән хәл була. Көчле давыл аларның автобусын Африка ярларыннан ерак булмаган бер утрауга илтеп ташлый. Шуларга бәйле рәвештә автор ике төр проблемаларны укучы-тамашачы каршына куя. Берсе—артистлар тормышы, икенчесе—Татарстанның бәйсезлеге мәсьәләсе. Шул рәвешле көнкүреш мәсьәләләре сәяси сораулар, бәхәсләр белән үрелеп китә. Бер яктан, артистлар уены сурәтләү объекты булса, икенче яктан, уен алымы, ягъни артистларның дөньякүләм билгеле «Дон Кихот», «Отелло» әсәрләре геройлары булып уйнау күренешләре, үзләрен шулар хәленә куеп караулары, яисә аларның эш-гамәлен татар тормышы белән бәйләп карау сәнгать әһелләренең җәмгыятьтәге урынын тулырак ачарга булыша. Вакыйгалар үстерелеше дөньяга карашы белән аерылып торган Шәрәф Рәшәнең башкалар белән бәхәс-каршылыгына нигезләнә.

Артистларның үз тормышларыннан канәгатьсезлеге Россиядә урнашкан идарә системасыннан, бу илдә халык мәнфәгатьләренең һәрвакыт икенче планда калуыннан, урыс булмаган милләтләргә кимсетеп караудан ризасызлык булып үсә. Шуңа да артистлар автобусының иркенле утрауга эләгүе һәм шунда үзара мөнәсәбәтләрне җайга салып, тыныч-тату, килешеп яшәү омтылышы—үзен «суверен дәүләт» дип игълан иткән Татарстанга метафора булып тора. Бер яктан, утраудагы иркенле, тыныч тормыш Россиядәге һәртөр законсызлыкка, башбаштаклыкка капма-каршы куела. Икенче яктан, Шәрәфнең «шартлатып коммунизм, йә капитализм» төзү теләге башкаларда яклау тапмый. Артистлар урнашкан алан үзе икегә бүленә: бер якта—бүре сурәте төшерелгән байрак күренеп торган гамакта Шәрәф һәм Гөлназ, икенче якта—Россия флагы эленгән автобус белән янәшә Татарстан флагы җилфердәгән шалашта башкалар яши. Шул рәвешле мөнәсәбәтләр сәяси төсмер ала. Драматург татар җәмгыятендә мөстәкыйльлек

мәсьәләсендә барган тартышны ачык күзалларга ярдәм итә. Берәүләр, Шәрәф кебек тулы мөстәкыйльлек таләп итсә, икенчеләр Россия дәүләте составында милләт мәнфәгатьләрен яклауны һәм саклауны алга сөрә, өченчеләр исә, шофер Наглый кебек, бернинди суверенитетны да кирәксенми. Нәтиҗәдә, Татарстанның сәяси тормышындагы кебек үк, уртадагылар фикере өстен чыга. Алар әлеге утрауны ташлап туган җиргә кайтырга булалар. Автор милләтпәрвәр Шәрәф язмышын хәл итүнең кызыклы, шул ук вакытта көтелмәгән юлын тапкан. «Россия таралса гына кайтам» дип торучы Шәрәфкә шаккатырлык яналык әйтәләр—Россия президенты итеп Шәймиев куелган! Димәк, илнен таркалуы турында сүз дә була алмый. Хатыны Шәрәфкә телефоннан болай ди: «Ельцин безгә суверенитетны яртылаш кына биргән иде, ә Шәймиев, Россия президенты булуга, аны безгә тулаем бирде!» Күргәнебезчә, көнкүреш вакыйгалары белән башланган пьеса сәяси утопиягә әверелә. Әлеге хәлләрдән сон, Шәрәф тә туган иленә кайтырга була. Пьесада чынбарлык күренешләре фантастик хәлләр, хыял агышы белән үрелеп бара. Төп герой буларак вакыйгаларны бер үзәккә туплап торучы Шәрәф Рәшәнең исеме дә игътибарга лаек. Белгәнебезчә, рәшә ул—мираж, хыялдагы әйбернең күзгә күренүе. Автор герой исеменә анын хыялый булуын чыгарган һәм бу пьесаның жанры белән дә тыгыз бәйләнгән.

Драматургның балалар өчен язылган «Алмазбулат» пьеса-әкияте сәхнәдә иң күп уйналган әсәрләреннән санала. Нигезендә яхшылык һәм явызлык көрәше яткан бу пьеса—татар балалар драматургиясендәге иң яхшы әсәрләрнең берсе. Әкияти сюжет ярдәмендә автор кешелек җәмгыятенең мәнгелек кыйммәтләре турындагы карашларын укучы-тамашачы алдына куя. Вакыйгалар барышында алар милләт язмышы белән үрелеп, рухи ядкарьләр, тел, милли сыйфатлар, гомумән, халык буларак яшәешебез турында җитди уйлануга китерә. Сюжет нигезенә салынган вакыйга-күренешләрне серле курай үзара бәйләп, тоташтырып тора. Әлеге уен коралы кеше күнелендә моң булса гына телгә килә икән. Вәзир һәм анын якыннары исә моң төшенчәсен анлаудан мәхрүм. Чөнки халыкның күпгасырлык фаҗигале тарихын, кайгы-хәсрәтен, шатлыккөенечен, теләк-омтылышын, рухи тормышын, матурлыкка ышанычын, ямьсезлеккә нәфрәтен—барысын, барысын үзенә сеңдергән әлеге сүзнең мәгънәсен асылда сүз белән анлатып булмый, аны тоярга, сиземләргә генә мөмкин. Ул кеше җанының төпкелендә туа һәм күнелнең ин нечкә кыллары аша янгырый.

Әлеге пьеса-әкият туган телгә, туган җиргә, ата-анага мәдхия булып тора. Кеше буыннарда сакланып калган үткәне, явызлык-гаделсезлеккә баш имәгән бүгенгесе һәм өмет-ышаныч тулы киләчәге белән көчле. Әкияти сюжетка корылган пьеса бүген дә заманча янгырый. Яшь укучы-тамашачы күнелендә милли үзаң уятуы, яшәештәге матурлыкны күрергә, анларга өйрәтүе, кеше көченә, рухына дан җырлавы белән киләчәккә атлый.

XX гасырның 90 еллар уртасында башланып киткән чечен сугышы бер якка да тынычлык һәм җиңү китерми. Киресенчә, җир йөзеннән юк ителгән авыллар, меңнәрчә корбаннар Россиянен үзенә дә бары афәт кенә алып килә. Күп халыкларның канлы ярасына әверелгән чечен сугышы темасына татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Ю. Сафиуллин мөрәҗәгать итә. Драматург «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедиясендә сугыш вакыйгаларының, кайтаваз буларак Татарстан җиренә килеп, кеше язмышларына гаять зур йогынты ясавын үзенчәлекле вакыйгалар, кабатланмас геройлар аша сурәтли.

Беренче күренешләрдә үк, чеченнарда әсирлектә булып, аннан холыклары бозылып кайткан Линар белән Рәсимнең гаять тотнаксызлыгы, әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел таба алмаулары көрәш-бәрелеш интригасы тудыра. Шунын өстенә Линар белән анасы Мөслимә арасында җитди каршылык барлыгы ачыклана. Ана белән улның бер-берсен каргашулары ук гайре табигый булып, бәрелешнең шактый тирәнәюен күрсәтә. Алдагы күренешләрдә Линарның чечен җиреннән кайткан Ханияне көчләргә омтылуы каршылыкны башка яссылыкка да күчерә. Шул рәвешле, бер яктан, егетләр белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында, икенче яктан, Россия армиясендә командир приказын үтәп, чечен авылларын җимергән, кулларына корал тотып каршылык күрсәтүчеләргә генә түгел, бәлки хатын-кыз һәм бала-чагаларга каршы да

танкта барган Линар һәм Рәсим белән йорт-җирләрен, сөйгәннәрен югалтып, туган иленнән—Чечен җиреннән, качып китәргә мәҗбүр булган Хания һәм Разия арасында конфликт оеша. Боларга өченче төр каршылык—төп геройлар көнелендә барган рухи көрәш—үрелеп бара. Авторны аеруча Линар белән Рәсимнең җан бәргәләнүләре, тыныч тормышта үзләренә урын таба алмаулары борчый. Пьесаның «Йөзек һәм хәнҗәр» дип аталуы да, символик мәгънә алып, шуңа ишарә итә. Йөзек—яшәү билгесе, мәхәббәтне, тормышта тынычлыкка өстенлек бирүне аңлата. Хәнҗәр исә—үлем, кайгы-хәсрәт алып килүче, дошманлыкка илтүче төшенчә. Үзен көчләргә теләгән Линарга каршы көрәшкәндә Хания сөйгәне, чечен егете Абрек бүләк иткән йөзекне югалта. Пьесадагы вакыйгалар әнә шул йөзекне эзләү фонында бара. Монда башкалар белән бергә Линар да актив катнаша. Егетнең мәхәббәт, тынычлык символын эзләве көнелендәге психологик тартышка, җанына тынычлык эзләвенә, «чечен синдромы»н җиңеп, гонаһларыннан арынып, тыныч тормышка кайту өчен үз-үзе белән көрәшенә метафора булып тора.

Пьесадагы хәрәкәт һәм каршылыклар чор проблемаларын калкытып куя, аларның чишелеш юлларын эзләү белән үстереләә, баетыла. Сугыш афәтен, тоткын-әсирлек газап-әрнүләрен күргән егетләрнең бүгенгесе һәм киләчәге белән бергә, драматург милләт язмышы турында уйлана һәм борчыла. Сан ягыннан кимелгән, милли рух шактый йомшаган халкыбызның киләчәге нәрсәгә бәйле соң? Таяныч-нигез булып ни тора ала? Әлеге сорауларга җавап Фәрхад абзыйның эш-гамәлләрендә табыла. Тамырлары белән татар дөньясына бәйле бу кеше чечен кызына өйләнә һәм ул халык язмышын үз язмышы итә. Акылы, тырышлыгы белән сәүдә эшендә зур байлык туплый, хөрмәт казана. Көнелендә милли рух саклаучы буларак, Линар, Рәсим кебек егетләрне тоткынлыктан азат итүгә зур ярдәм күрсәтә. Әмма сугыш аны барлык мал-мөлкәтеннән мәхрүм итә. Шулай булса да ул өметышаныч хисен җуймаган. Тормыш каршылыкларына каршы торырдай нигез итеп ул үз-үзенә хыянәт итмәүне саный. Фәрхад абзый, көнелендәге ачу-ярсуны басып, чечен мәхшәреннән кайткан Линар, Рәсим кебекләргә чын күңелдән ярдәм итү теләге белән йөри: Казахстан белән сәүдәне җайга сала; авылда тире эшкәртү фабрикасы ача; чечен сугышында катнашкан егетләрне туплый, тыныч тормышка җайлаша алсын өчен шартлар тудыра. Аның фикеренчә, һәр үзгәрешнең, янарышның нигезендә акыл, белем, әхлак һәм байлык ятарга тиеш.

...Хәзерге татар драматургиясендә барган эзләнүләрне Ю. Сафиуллин иҗатыннан башка күзаллап булмый. Ул үзенең пьесалары ярдәмендә кешеләрне һәм, гомумән, җәмгыятьне чиста, әхлаклы, матур итү теләге белән яши. Аның драма һәм трагедияләрендә генә түгел, бәлки комедияләрендә дә яшәештәге каршылыклар, бозыклыклар өчен җан сыкравы ачык сиземләнә, авторның яшь аралаш көлүе алга чыга. Пьесаларында эчке драматизм, беренче карашка ачык күренеп тормаган эчке агым бар. Әдип чынбарлыкны чагылдыруның янадан-яңа юлларын эзли. Әгәр аның 1970—1980 елларда иҗат ителгән әсәрләрендә йорт, нигез образы үзәктә торса, соңгы елларда милли үзән, татар язмышы, туган җир алгы планга чыга. Драматург шартлы-метафорик күренешләрне, символик образларны да әсәрләр тукымасына уңышлы кертеп җибәрә.

Ю. Сафиуллинның яңа җыентыгы аның заман проблемаларына үзенчәлекле якын килүен, яшәеш каршылыкларын ачуда яңа юллар эзләвен һәм, гомумән, тормыш күренешләрен сәнгати аңлавының тирәнәюен күрсәтә.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

# Б

**БӘШӘР** (Бәшәрев) Рәшит Гаффар улы (7.10.1949, Кукмара р-ны Яңил а.), шагыйрь. Казан ун-тын (1972) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсны (1989, Мәскәү) тәмамлый. 1972-77 елларда Лениногорск р-ны мәктәпләрендә укыта. 1979 дан Яр Чаллы шәһәре пр-тиеләрендә, район газетасы редакциясендә эшли. 1991-95 елларда «КамАЗ» нәшрияты (Чаллы ш.) мөхәррире. 1996-2000 дә «Аргамак» ж-лында татар прозасы һәм поэзиясе бүлеге мөхәррире, җаваплы сәркәтип. Әсәрләре 1965 тән басыла башлый. Балаларга атап язылган, аларны кечкенәдән үк намуслы, кешелекле, ихлас булырга, хезмәтне яратырга, табигатьне сакларга, аны баетырга, тереклек дөньясы б-н дус булырга чакырган «Әйлән-бәйлән» (1975), «Бәйрәм» (1977), «Яшел океан» (1981) исемле шигырь җыентыклары, Себер табигатенең хозурлыгы турындагы «Ак әкият» (1986), әкият-легендаларда сөйләнгән Зөһрә кыз турындагы «Ай кызының зәңгәр чиләге» (1990) исемле поэма китаплары авторы. «Иртәгә дә яшисе бар» (1989) җыентыгына тупланган повестьларында Б. яшүсмерләрне тәрбияләү проблемаларын яктырта; кайвакыт тормышта чын дөреслек булып күренгәннең дә ялган булып чыгуын фаш итә. Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге бүләк иясе (2000).

Әсәр.: Сандугачлы бишек. К., 2000; Җиләк малай. Чаллы, 2002; Кояшлы яңгыр. К., 2003.

Әд.: Дунай Ф. Чабатасы түрдә түгел: // Мәдәни җомга. 1998. 2 окт.; Сафин Ф. Күңелдәге кызыл миләшләр // Казан утлары. 1999. N10.

Г.М.Габделхакова.

**БӘШИРОВ** Гомәр Бәшир улы (7.1.1901, Казан өязе, Арча волосте Яңасала а.—7.5.1999, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның халык язучысы (1986). Авыл мәдрәсәсендә укый, 1919 елдан укытучылык итә. 1920-24 тә Кызыл Армия сафларында; 1920 дә Сиваш—Перекоп өчен барган сугышта катнаша. 1924 тә армия хезмәтеннән кайткач Эчке эшләр халык комис-тының Казандагы берьеллык махсус мәктәбендә укый, соңыннан 1929 га кадәр Арча кантоны милиция органнарында эшли, 1932 дә Балтачта һәм Дөбъязда халык тикшерүчесе, халык судьясы хезмәтен башкара. 1932 дән Казанда: «Кызыл Татарстан» г-тасы хәбәрчесе (1936 га кадәр), «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы сәркәтибе (1938 гә кадәр). 1941 дә Татарстан дәүләт нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире, 1941-42 дә (Г.Кашшаф һәм И.Гази б-н бергә) «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы сәркәтипләренең берсе, 1942-44 тә ТАССР ХКС каршындагы Радиолаштыру һәм радиотапшырулар комитетында баш мөхәррир.

Б. әдәбиятка 1930 еллар башында килә. 1930-40 нчы елларда Г.Разин булларак танылa. «Канлы бармаклар» исемле беренче хикәясе 1931 дә Мәскәүдә «Ударниклар» ж-лында басыла. Б.ның алдагы иҗатына да хас булганча туган ил темасын яктырткан «Соңгы сугыш» дигән беренче китабы 1934 тә Казанда нәшер ителә. Әдипнең сугышка кадәрге иҗат биографиясендә иң күренекле урын тоткан «Сиваш» повесте (1937) Кызыл Армия сугышчыларының 1920 дә Сивашны кичкәндәге сугышчан батырлыклары турында. Б. совет халкының немец фашист илбасарларына каршы героик көрәшен чагылдырган «Намус» (1947; рус теленә тәрҗемәсе «Честь», 1949) романын сугыш барган көннәрдә язуга керешә. Шул чор татар авылын сурәтләп, автор үз халкының бай рухи дөньясын ачып бирә. Романның төп герое—фидакарь, көчле рухлы, кешелекле, эчкерсез Нәфисә—сугыштан соңгы татар әдәбиятында иң уңышлы хатын-кыз образларыннан берсе. Роман татар укучылары арасында гына популярлык казанып калмый, СССР халыклары телләренә дә тәрҗемә ителә һәм 1951 елда СССР Дәүләт бүләгенә лаек була. Төрле елларда романның рус телендә унлап басмасы (1 млн.нан артык гомуми тираж

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2005 ел, 4 санынnan басылып килә.*

6-н) дөнья күрә, инглиз, француз, немец, испан, кытай, венгр, поляк, чех, болгар һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. 1960-70 еллардагы «җепшеклек» чоры – Б. иҗатында әһәмиятле яңа этап. Бу елларда татар әдәбияты шактый гына иҗади биеклеккә күтәрелә, язучылар, узган чор әдәбияты проблемаларын кабат күздән кичереп, яңалыкны яктыртырга омтылалар, әдәби эзләнүләр тирәнрәк, киңрәк колач ала. Яңа шартларда Б., «Туган ягым – яшел бишек» (1967; рус теленә тәрҗемәсе «Родимый край – зеленая моя колыбель», М., 1972) повесте б-н революциягә кадәрге үткәнгә мөрәҗәгать итеп, үз балачагы чорының татар авылы тормышын хәтердә яңарта. Повесть өчен халыкның элекке рухи яшәешен чынбарлыктагыча сурәтләү хас. Бу әсәр татар әдәбиятында яңа күренеш иде, чөнки 1917 елдан алып элекке тормыш чиктән тыш берьяклы, кагыйдә буларак, тискәре яктан гына яктыртылды. Б. үзенең повестенда революциягә кадәрге татар авылының күп гасырлардан килгән традицияләргә, гореф-гадәтләргә, белемгә омтылу, китапка хөрмәт б-н карау кебек мәңгелек кыйммәтләргә нигезләнгән бай рухи тормыш б-н яшәвен сурәтли. Икенче яктан, Б. замандашларының рухи-әхлакый асылына игътибар юнәлтә. «Намус» романы б-н «Туган ягым – яшел бишек» повестеның логик дәвамы булып «Җидегән чишмә» (1977) романы тора. Әлеге әсәрендә Б. бу проблеманы кешенең аны чолгап алган табигать б-н мөнәсәбәте аша ача. Әдип фәннитехник алгарыш заманында кешеләрнең үз-үзләрен тотышын әхлакый яктан бәяләгәндә моңа бик әһәмиятле, хәтта хәлиткеч фактор итеп карый. Ул татар әдәбиятында беренчеләрдән булып табигатькә сакчыл караш мәсьәләсен күтәреп чыга. Аның фикеренчә, табигать байлыкларына битараф булу – кеше язмышына да салкын карау дигән сүз. Бу проблемада милли аспектның да йогынтысы бар – роман геройларының табигатькә мөнәсәбәте милли менталитетка бәйле үзенчәлек б-н аңлатыла.

Б. күп еллар дәвамында халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм өйрәнү буенча эшчәнлек алып бара. Ул туплаган һәм әдәби яктан эшкәрткән халык әкиятләре, җырлары, мәзәкләре күп томлы «Татар халык иҗаты» басмасында, «Мең дә бер мәзәк» (1963; рус теленә тәрҗемәсе «Тысяча и один мээк», 1989), «Туган тел мәзәкләре» (1995) китапларында дөнья күрде. Соңгы елларда иҗат ителгән «Күзге ачы җилләрдә» (1984), «И язмыш, язмыш» (1990, Г.Тукай исем. дәүләт бүләге, 1996), «Сарут» (1990) повестьлары гуманистик идеяләр б-н сугарылган, аларда тормыш, бүгенге көн турында уйланулар зур урын алып тора, кискен социаль проблемалар күтәрелә. «Гыйбрәт» (2000) романы вакыт, авторның үзе турындагы уйлануларга нигезләнә. Әдипнең әлеге әсәре тәмамланмый калды.

Әдәби иҗаттан тыш Б. җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, 1953-58 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. ТАССР ЮС (1951-55), ике чакырылыш СССР ЮС (1954-62) депутаты булды. Күп кырлы иҗтимагый һәм иҗади эшчәнлеге өчен Ленин ордены, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Октябрь Революциясе, Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнде.

Әсәр.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1981-84.

Әд.: Җәләлиева М. Гомәр Бәширов. К., 1959; Ахунов Г. Җир һәм күңел җырчысы // Әдәби язмышлар. К., 1970; Камалов Б. Халкым үстергән Алып // Заман. 1996. 5 янв.; Мустафин Р. Зелёная колыбель Гумера Баширова // Вечерняя Казань. 1981. 7 янв.

Ф.М.Мусин.

**БӘШИРОВ** Фәрит Кәрим улы (30.11.1958, Арча р-ны Шекә а.), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1981). 1984-2003 елларда Татарстан фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. 2004 елдан ЖЧЖ "Матбугат йорты" полиграфия-нәшрият комбинатында эшли. Хезмәтләре 20 йөз башы татар прозасын өйрәнүгә, бүгенге көн әдәби процессы мәсьәләләренә, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, К.Тинчурин һ.б. иҗатларына карый.

Хезм.: Сөйлә, каләм! К., 2001; XX йөз башы татар прозасы. К., 2002.

*Дәвамы киләсе саннарда*

* * *

Исәнмесез, «Казан утлары»ның ару-талу белмәс хезмәткәрләре! Күпме еллар язарга талпынып та, сезгә хат юллый алмадым. Менә инде 1000 нче санығыз чыгу форсатыннан файдаланып, сезгә уңышлар теләп язарга булдым. Яшьтән үк шигърияткә гашыйк булып үстем һәм үзем дә шигырьләр язам. Соң булса да уң булсын дип, 1000 нче санығыз чыгу уңаеннан язылган шигыремне җибәрәм. Миннән сезгә кечкенә генә бер күчтәнәч булсын иде ул.

Меңенче кат чыктың менә бүген.
Меңенче кат халкың шатланды.
Мин дә менә ачам битләреңне,
Күпме мәгънә синнән алынды.
Күпме кеше белән таныштым мин,
Күпме дуслар җыйдым янымa.

Укыган саен синең битләреңне,
Якыная бардым халкыма…
Һич картаям димә, яшь әле син.
Әйләнсеннәр сәгать уклары.
Миллионлаган укучылар сиңа
Телим бүген, «Казан утлары»!

**Раушан КАГИРОВ,**
Чирмешән

* * *

Каршымда «Казан утлары»ның җан җылысы да, рухи байлык та булган, татарның шундый кешеләре бар һәм булган бит дип горурлану хисләре дә уята торган 1000 нче һәм 1001 нче саннары ята.

1000 нче санны чыгуны түземсезлек белән көтеп алдым. Ничек чыгарырлар икән, янәсе. Ничек кенә чыккан әле! Искиткеч! Шулкадәр оста итеп никадәр бай, бәһасез материал туплау мөмкин булган. Бу эшкә күп көннәр генә түгел, төннәр дә сарыф ителгәнен аңлау кыен түгел. Бер стена газетасы чыгаруга гына да атналар китә иде заманында.

Һади Такташ, Гадел Кутуй, Шамил Госманов, Хәсән Туфан һ. б. олы шәхесләребез яңадан туган кебек булган. Александр Ключарев, Мирхәйдәр Фәйзи турындагы язмаларны һәм Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган мондый тупланманы башка беркайда да таба алмыйсың. Ибраһим Газиның «Тургай картаямы икән?» дигән хикәясе күңелләрне тетрәндерсә, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Галиябану» этюды шул 60-70 нче еллардагы авыл сәхнәсенә кайтара да куя... Гомумән, журнал бөтен катлам укучылары өчен дә кызыклы, беркемне дә битараф калдыра торган түгел. Рәхмәт сезгә.

Инде Рәйсә Юсупованың 1001нче сандагы «Ак сагыш иясе» исемле очерк-хатирәсенә тукталасым килә. «Зөбәйдә—адәм баласы», «Әни килде» спектакльләренең чыгу вакыты безнең яшьлегебезгә, татар театрының иң югары ноктасындагы уңышлары чорына туры килде. Мин ул вакытта шушы әсәрләрне иҗат иткән кешенең йөрәге нинди икән, их, бу язучыны күрсәң иде дип уйланып йөргәннәремне хәтерлим. Инде белдем: менә нинди кеше булган икән ул Шәриф Хөсәенов! Мин «Әни килде» спектаклен Качалов театрында да һәм соңгы куелышын Камал театрында да карый алмадым. Миңа элек караганымның гына бозылмыйча, матур булып истә калуы кирәк иде. Ул труппа бүген, кызганычка каршы, юк инде.

«Ак сагыш иясе»... Бәхетлеме кеше? Бу сорау гомере дәвамында һәркемнең үз-үзенә бик күп мәртәбәләр бирә торган соравыдыр. Нигә соң Шәриф Зөлфәне, Зөлфә Шәрифне үз вакытында, бер-берсенә бик кирәк чакларда юата алмаган, хәлләрен белмәгән? Ә яраткан кешеләр гүрләргә керсә, телефон да, почта да эшләми, хәбәрләр килми... Нигә соң Шәрифнең өзелеп язган шигырьләрен Зөлфәгә Рәйсә ханым тапшырырга тиеш, нигә Ул аларны үзе тапшыра алмаган? Их, без, кешеләр! Никадәр җан җылылары көеп көлгә әйләнә йөрәктә. Исән чакта кадерләребезне белер өчен гыйбрәт булсын иде бу язма.

Рәйсә ханым Юсуповага бик рәхмәтлемен. Тапсын иде ул, исән булсын иде Зөлфә.

Журнал битләрендә күңелләрне айкап чыгарырлык, берничә мәртәбә укыйсы килерлек әсәрләр дөнья күрә икән, шул түгелме бәхетнең бер өлеше?..

**Фирдәвес ГӘРӘЕВА.**
Казан.

## Мирза Мәхмүтовка 80 яшь

Дөньяның бик күп илләрендә узган халыкара конференцияләрдә инглиз, гарәп, немец, рус телләрендә тирән эчтәлекле докладлар ясаган татар галимнәре бик тә сирәктер. Россия Мәгариф академиясенең, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов әнә шундый шәхес.

Аның китаплары, сүзлекләре, төрле гыйльми җыентыкларда, газета-журналларда дөнья күргән саллы-саллы мәкаләләре генә дә 600 гә якын.



М. И. Мәхмүтов җитәкчелегендә 40тан артык кешенең кандидатлык диссертациясе, 10нан артык галимнең докторлык диссертациясе язылды һәм якланды.

Ул 1926 елның 1 маенда Мордовиянең Ләмберә районындагы Алтар авылында эшче гаиләсендә туа. Яшьтән ятим кала. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, тракторчылар курсында укый. Үзбәкстанның Сәмәрканд өлкәсендә механизатор булып эшли. 1944 елда армия сафына алына, хәрби мәктәпләрдә—механик, аннары хәрби авиация техникгы һөнәрләрен үзләштерә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыш тәмамлангач 12 ел буена хәрби частьларда хезмәт итә, шул чорда кичке эшче-яшьләр урта мәктәбен дә тәмамлый, читтән торып укып, Мәскәүнең бер югары уку йортында немец телен өйрәнә. 1950—1955 елларда Совет Армиясенең Чит телләр хәрби институтында тыңлаучы була. Гарәп һәм инглиз телләре тәрҗемәчесе-референты белгечлеге ала, хәрби хезмәтен Рига шәһәрендә дәвам иттерә.

Шуннан соң 1956 елда ул Казанга килә, КДУда гарәп һәм татар теле укыта башлый. Фәнни эшләр белән дә шөгыльләнә. 1958 елда, утыз ике яшендә, аны Татарстан мәгариф министры итеп билгелиләр. 1976 елга кадәр ул шушы вазифаны башкара, үзен оста җитәкче, булдыклы шәхес, зур галим итеп таныта. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» (1963), «Мәктәпләр өчен русча-татарча сүзлек» (1967, 1975, 1991) һ. б. китаплары дөнья күрә. Татар тел белеме буенча—кандидатлык (1966), педагогика буенча докторлык (1972) диссертацияләре яклый.

Тынгысыз галим, эшне оста оештыра белә торган кеше ул Мирза Исмәгыйлевич. Казанда Россия Мәгариф академиясенең Махсус урта белем бирү институтын (17 ел буена аның директоры булды), Татар—Америка региональ институтын оештыручы да ул иде. Соңгысында ул 1992—1995 елларда директор булып та эшләде. 1996 елдан М. И. Мәхмүтов Татарстан Фәннәр академиясенең иҗтимагый-икътисади фәннәр бүлегенең академик-сәркатибе вазифаларын башкара.

*Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Дәүләт бүләге лауреаты академик, «Казан утлары»ның редколлегия әгъзасы Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтовны 80 яше белән ихлас күңелдән котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез!*

## Индүс Таһировка 70 яшь

Индүс Ризакъ улы Таһиров 1936 елның 24 маенда Шөгер районының (хәзерге Лениногорск районы) Иске Шөгер авылында туган.



Әлмәт шәһәрендә урта мәктәп тәмамлый. 1958—1963 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый, һәм шунда ук аспирантурада кала.

1967 елда диссертация яклап (Казанда совет власте урнашуның үзенчәлекләре анализлана), тарих фәннәре кандидаты була. Докторлык диссертациясендә исә (1979 елда яклый) 1917-18 елларда Идел-Урал төбәгендә барган милли азатлык хәрәкәте тикшерелә.

43 еллап гомере Казан дәүләт университеты белән бәйле. 1980 елдан алып—профессор. Хәзерге заман Ватан тарихы кафедрасы мөдире.

И. Таһиров—күренекле галим, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1994), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1989), Республикабызның Дәүләт премиясе лауреаты (2001). Ул—«Бәйсезлек баскычлары» (1994), «Татарстан һәм татар халкы тарихына караган очерклар» («Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век»), 1999), «Татарстан һәм татар халкы милли дәүләтчелеге тарихы («История национальной государственности татарского народа и Татарстана», 2000) кебек милли тарихыбызны тергезүдә мөһим роль уйнаган китаплар, күп санлы мәкаләләр авторы. «Газета һәм журналларда басылып чыккан язмаларымның төп идеясе—татар халкының бәйсезлеккә хаклы булуын исбат итү һәм шул бәйсезлеккә ирешүнең кайбер юлларын эзләү, ачыклау булып кала»—дип язды Индүс Таһиров. Аның күп кенә мәкаләләре, тарих фәне белән сәясәт фәне чигендә язылып, кайчакта публицистикага да үтеп кереп, көннең иң кайнар нокталарына төбәлә. Моны «Бәйсезлек баскычлары» дигән китапка кергән мәкаләләрнең исемнәреннән дә чамалап була: «Татар нинди милләт?», «Курчак автономиядән—бәйсезлеккә», «Бәйсезлекнең берничә шарты», «Федерация булганмы, бармы, булачакмы?», «Азатлык безгә барыбер киләчәк» һ. б.

И. Таһировка бик сирәк тарихчы галимнәргә эләгә торган бәхет тәтеде: ул, шундук тарихка әйләнеп барган мөһим вакыйгаларның үзәгендә кайнап, тарихның үзен ясауда катнашты. 1992 елда Бөтендөнья татарларының беренче Корылтаенда башкарма комитет рәисе булып сайланды һәм әлеге вазифаны ун ел буе башкарды, 1998—2002 елларда Россия Федерациясе татарларының милли-мәдәни мохтарияте рәисе булды. Россия һәм Татарстан арасында 1991-92 елларда барган сөйләшүләрдә, Татарстан делегациясе житәкчесе урынбасары буларак, тигез хокуклы Шартнамә төзелсен дип зур тырышлык куйды.

И. Таһиров—1995 елдан алып Татарстанның халык депутаты.

*«Казан утлары» коллективы журналның актив авторын юбилее белән котлый һәм ана туган халкын сөендергән янадан-яна уныш-казанышлар тели.*

Хәнәфи
Бәдигый

## «Дедовщина»

**Менә сиңа чертовщина:
Кырмыскалар оясында
Башланган «дедовщина».**

**«Дедлар» самогон төшергән,
Яшьләрне тотып өшкергән,
Сотниклары яшергән.**

**Баш кырмыска белмәгән,
Яраннары күрмәгән,
Беркем җавап бирмәгән.**

**Ике меңне үтергәннәр,
Җиде меңне имгәткәннәр,
Дәшкәннәр—үкенгәннәр.**

**Күпләре качып котылган,
Байтагы кабат тотылган,
Болар бар да «йотылган».**

**Берәү имгәтеп ташлангач.
Кыңгыр эшләре фашлангач,
Мирдә зур суд башлангач—**

**Сотниклары—сытылган,
Яраннары—отылган,
Кырмыскабаш—котылган.**

**Ояда тәртип тыштан,
Башлыкта—яңа ыштан,
Башлармы яңабаштан?.**

---

## ИГЪТИБАР! КОНКУРС!

### «Яңа дәвер кешесе»

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызнын мең санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меңнәр белән язылды. Яна меңьеллыкка—яңа дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яңа дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөрриятка, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Кыскасы, «Казан утлары» журналы, яңа хикәяләргә ачык конкурс игълан итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:


**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елнын декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**



*Фронтовик язучылар. Сулдан уңга—Хатип Госман, Әдип Маликов, Әмирхан Еники, Нәби Дәүли, Әхмәт Исхак, Гомәр Бәширов. 1985 ел.*



*Галим Миркасыйм Госманов.*



*Нури Арслан һәм Фаил Шәфигуллин. 1979 ел.*



*Шагыйрә Зәйнәп Сәгыйдә һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллин. 1978 ел.*



*Язучы Вакыйф Нуруллин.*



*Әлмәт төбәге язучылары. Сулдан уңга— Шамил Бикчурин, Мәхмүт Хәсәнов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал. Үткән гасырның 70 нче еллары.*





### ГАРӘП ИЛЛӘРЕ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШ

1 апрельдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Якын Көнчыгыш илләренә рәсми визит кысаларында, Согуд Гарәбстаны Корольлегенең Җиддә шәһәрендә Ислам конференциясе оешмасы генераль сәркатибе Әкмәледдин Ихсаноглы белән очрашты.

Фикер алышканда М.Шәймиев 2006 ел—Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүен (аның кысаларында Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулу иң мөһим вакыйгаларның берсе булуын) хәбәр итте. Ихсаноглы, үз чиратында, танылган татар шагыйре иҗаты белән таныш булуын әйтте. Президент Ислам конференциясе оешмасы башлыгына Казанда XIX гасыр уртасында типографик ысул белән нәшер ителгән Коръәннең беренче басма күчермәсен тапшырды.

3 апрельдә Минтимер Шәймиев рәсми визит белән Кувейтта булды. Ул Кувейтта вакыфлар һәм ислам эшләре министры, юстиция министры Абдулла Мәатүк Әл-Мәатүк белән очрашты. Кич белән исә «Сальва Сабах Әл-Әхмәд» үзәге бинасында Татарстанның икътисади мөмкинлекләрен тәкъдим итү булды. Анда сүз «Идея» технопаркы, «Алабуга» үзгә икътисади зонасы, «КамАЗ», «Татнефть» акционерлык җәмгыятьләре эшчәнлеге турында барды.

Мәатүк Әл-Мәатүк әфәнде үзенең чыгышында: «Татарстан һәм Кувейтта үзара аңлашып күп милләтләр яши, бу яктан безнең илләр арасында охшашлык чагыла»,—дип билгеләп узды.

### ТУГАН ТЕЛ ХАКЫНА

Март ахырында ике көн дәвамында Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының IV Бөтенроссия корылтае барды. Анда Россиянең 35 төбәгеннән 500 гә якын делегат катнашты.

Соңгы биш елда сәясәт үзгәрде, татар теле һәм әдәбиятын укыту өлкәсендә методик яңалыклар барлыкка килде. Милли мәгариф мәсьәләләрен уртага салып сөйләшү, киңәшләшү өчен Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты һәм ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы чит төбәкләрдә ана телен укытучыларны, мәгариф һәм милли оешмалар җитәкчеләрен корылтайга җыйды.

Корылтай эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, ТР Дәүләт Советы Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, депутатлар, югары уку йортлары җитәкчеләре катнашты.

Фәрит Мөхәммәтшин үзенең чыгышында: «Россия күптеллелеге, күп мәдәниятле, күпмилләтле булуы белән бай. Кызганыч, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы туган телдә белем бирү буенча бернинди хисап алып бармый»,—дип чит төбәкләрдә татар теле, татар мәгарифе язмышы өчен борчылуын белдерде.

Утырышта катнашучылар тарафыннан Россиядә татар милли мәгарифенең торышы, Россиядә татар милли мәгарифенең актуаль мәсьәләләрен хәл итүдә милли оешмаларның мәгариф органнары белән уртак эшчәнлеге, төбәкләрдә татар әдәбиятын укыту өлкәсендәге проблемалар һәм күп кенә башка мәсьәләләр күтәрелде, илдә татар теленең хәле хакында кискен фикерләр дә ишетелде.

Корылтайда Татарстан Президенты Указы нигезендә милли мәгарифне үстерүдәге, татар телен, мәдәният һәм әдәбиятны пропагандалаудагы казанышлары өчен Омск, Пенза, Ульяновск, Мәскәү һәм Уфаның кайбер укытучыларына «Татарстан Республикасының атказанган укытучысы» исеме бирелде.

### ТАРИХТАН САБАК АЛЫП

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Россия Дәүләт Думасының 100 еллыгына багышлап, «Россия парламентаризмы: тарихи тәҗрибә һәм хәзерге үсеш тенденцияләре» дигән конференция үткәрелде. Аның эшендә Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Россиядә парламентаризм

үсешенең зур әһәмияткә ия булуын ассызыклады, конференциядә катнашучыларга (алар Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре һәм күрше республикалар парламентлары вәкилләре) Президент Минтимер Шәймиевнең котлавын ирештерде.

Төп докладны ясаган академик Индус Таһиров Россиядә парламентаризмның катлаулы үсеш юлын бәян итте. Татарстан парламенты үсешенә Федераль үзәк тарафыннан киртәләр дә куелган очраклар булуын искәртте.

Россия Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары Владимир Пехтин: «Россиядә Дума 1906 елны оештырылган, аның эшчәнлегендә мөселман татар депутатлары да актив катнашканнар. Х. Атласов, Г. Мусин, С. Максудов, С. Алкин, Ф. Туктаров, Г. Еникеев, К. Хәсәнов һәм Дәүләт Думасындагы башка мөселман татар депутатлары абруй казанганнар»,—диде.

Конференциядә шулай ук Россия Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары Олег Морозов, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле урынбасары Владимир Зорин, РФ Дәүләт Думасының Җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты рәисе Владимир Мокрый, Мари Иле Республикасы Дәүләт Җыелышы Рәисе Юрий Минаков чыгыш ясады.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК

Татарстан вәкиллекләре эшчәнлегенең мөһим юнәлешләре, төрле төбәк һәм территорияләр белән сәүдә-икътисад элемтәләрен булдырудан тыш, урыннардагы татар диаспоралары белән хезмәттәшлек итүне дә күздә тотып билгеләнә.

Казан Кремлендә ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов үткәргән киңәшмәдә республиканың чит илләрдәге һәм Россия төбәкләрендәге вәкиллекләре алдында шундый бурыч куелды.

Май аенда узган киңәшмәдә шулай ук ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, халыкара мәсьәләләр буенча ТР Президенты каршындагы дәүләт киңәшчесе—ТР Президентының Тышкы элемтәләр департаменты директоры Тимур Акулов, ТР сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министры Хафиз Салихов катнашты.

Татарстанның чит илләрдәге һәм Россия төбәкләрендәге вәкиллекләре эшчәнлеге турында сөйләгәндә Юрий Камалтынов алар эшенең мөһим юнәлеше—урыннардагы татар диаспоралары белән үзара аралашу һәм ярдәмләшү икәнлеген ассызыклады. «Узган ел бик әчтәлекле булды, сез Казанның 1000 еллыгына багышланган чараларда актив катнаштыгыз,—диде ТР Президенты Аппараты җитәкчесе.—Моннан тыш, Татарстан вәкилләре Бөек Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм итүдә дә катнашты. Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгән агымдагы ел Татарстанның даими һәм тулы вәкаләтле вәкиллекләре игътибарыннан читтә калмаска тиеш. Сез күрсәтелгән чаралар кысаларында республиканың дәрәҗәсен күтәрүдә ярдәм итәргә тиешсез»,—диде ул.

Узган елда Татарстанның чит илләрдәге вәкиллекләрендә җитәкчеләр алыштырылды. Киңәшмә барышында Ю. Камалтынов яңа билгеләнгән кешеләрне атады. Алар—Татарстан Республикасының Казакъстандагы тулы вәкаләтле вәкиле итеп Татарстанның элеккеге мәдәният министры Илдус Тарханов, ТРның Әзәрбайҗандагы даими вәкиле—«Татинвест» холдинг компаниясе вәкиллегенең элеккеге башлыгы Наил Зарипов, ТРның Төркия Республикасындагы тулы вәкаләтле вәкиле—Төркиядә ТР вәкиленең элеккеге урынбасары Радик Гыйматдинов, АКШта ТР вәкиле—элек Кипрда ТР вәкиле булып эшләгән Равил Нигъмәтҗанов. Ул шулай ук Брюссельдә Татарстан вәкиллеге ачылу мөмкинлеге турында да белдерде.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Татарстан язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми җыелышы булып узды. Анда башкалабыз Казанда, республикабызның шәһәр һәм районнарында, аерым алганда, Әлмәт һәм Чаллы төбәкләрендә, шулай ук чит өлкәләрдә яшәп иҗат итүче каләм әһелләре катнашты.

Әдәби хисап җыены быел яңачарак оештырылды: көннең беренче яртысында шигърият, проза, публицистика, балалар әдәбияты, драматургия, әдәби тәнкыйть, рус әдәбияты остаханәләрендә аерым жанрлар буенча махсус әзерләнгән докладлар тыңланды һәм узган елда газета-журналларда, китап нәшриятларында дөнья күргән әсәрләр, театрларда куелган пьесалар, гомумән, милләт, мәдәният, тел, мәктәп язмышына кагылышлы көнүзәк мәсьәләләр турында фикер алышу булды. Әйтик, шагыйрьләр катнашында үткән сөйләшүдә республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребезгә игътибарны көчәйтү зарурлыгына да игътибар юнәлтелде, бу уңайдан Айдар Хәлим, Шәүкәт Гаделша, Мөдәррис Әгъләм, Нәҗибә Сафина үзләренең уй-фикерләре белән уртаклашты.

Жанрлар буенча әзерләнгән докладларны Ркаил Зәйдулла, Камил Кәримов, Рафис Корбан, Дания Гыйммранова, Мансур Вәлиев, Лилия Газизова сөйләде. Утырышларны остаханә җитәкчеләре алып барды.

«Казан» милли мәдәният үзәгендә үткәрелгән пленар утырышны Татарстан

Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов ачып җибәрде. Иң әүвәл ул ике җыен арасында вафат булган әдипләребезне бер минут тынлык белән искә алырга чакырды. Идарә рәисенең исәп-хисабында узган елгы әдәби тормышыбызда байтак эшләр башкарылуы бәян ителде. Эш-гамәлләр, чыннан да, аз түгел. Әлбәттә, бу хисап киләчәктә язучылар алдында торган зур эшләрне дә күзаллау булды.

Фикер алышуда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин, рус әдәбияты остаханәсе җитәкчесе Лилия Газизова, «Мәдәни җомга» газетының баш мөхәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, Балтач районы үзәгендәге урта мәктәпнең XI сыйныф укучысы Гөлфия Закирова һ.б.лар катнашты. Чыгыш ясаучыларның гамендә, әлеге дә баягы, ил-көн, мәдәният, тел, мәктәп мәсьәләләре иде. Аерым алганда, хәзерге шартларда әдәбиятка булган мөнәсәбәт, мәктәпләрдә татарча укытуның кысыла баруы, милли матбугат басмаларын алдыручыларның елдан-ел кимүе унаеннан каләм әһелләре үзләренең борчылуларын белдерде. Чыгышларда китап сәүдәсенең ныклы нигезгә куелмавы, шул рәвешле, аның киләчәккә төбәлгән зур тәрбияви максатлар үтәлешен куркыныч астына куюы уртак фикер буларак яңгырады.

Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева үз чыгышында Язучылар берлеге эшчәнлегенең хисап елында җанланып китүен билгеләп үтте, рухи тормышыбызга кагылышлы әһәмиятле мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә чакырды.

«Язучыларның хәле, гонорарлар, проблемалар, юбилейлар хакында онытмыйбыз,— диде ул.—Республикабызда үз зыялыларын, үз язучыларын әйбәт хәлдә яшәтү өчен мөмкинлекләр бар. Сез дә, үз нәүбәтегездә, редколлегияләр эшен яхшырту аша, сыйфатлы иҗади җимешләр бирергә тырышыгыз».

Аннары Зилә Вәлиева шагыйрә Фирая Зыятдиновага бирелгән "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнең таныклыгы һәм билгесен тапшырды (аны ире язучы Фарсель Зыятдинов кабул итеп алды), каләм әһелләренең шактый четерекле сорауларын җаваплады.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе исә җыелышта катнашучылар алдында каләмдәшләре Адлер Тимергалин, Зәки Зәйнуллин, Илдус Гыйләҗев, Ләбиб Лерон, Дания Заһидуллинага берлекнең Г. Исхакый, Һ. Такташ, Ф. Хөсни, Ж. Вәлиди исемендәге бүләкләрен тапшырды. Әлеге исемле премияләрнең билгеләре бу бүләккә элегрәк лаек булган язучыларга да бирелде.

Әдәби хисап җыенында Татарстан Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Разил Вәлиев катнашты.

Иҗади елга йомгак ясалды, әмма әдәби тормыш дәвам итә. Каләм ияләрен алда зур иҗат һәм оештыру эшләре көтә.

## ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ—2005

Март аенда «Яңа татар пьесасы—2005» бәйгесенең җиңүчеләре игълан ителде. Хәбәр иткәнебезчә, бәйгегә пьесалар псевдоним астында бирелгән иде, авторларның чын исемнәре җиңүчеләрне бүләкләгәндә, ягъни Театр көнендә генә ачыкланды.

Шулай итеп, 62 пьеса арасыннан «Иң яхшы комедия» номинациясендә беренче һәм өченче урыннарны «Алты кызга бер кияү» һәм «Син мине күрәсеңме?» пьесалары белән Туфан Миңнуллин алды. Икенче урынга «Бакча карачкылары» пьесасы белән Зөләйха Минһаҗева лаек булды.

«Иң яхшы драма әсәре» номинациясендә беренчелекне «Легионер» пьесасы белән Зөлфәт Хәким алды. Икенче урында—«Олуг ханның фәрманы» пьесасы белән Эсфир Яһудин, өченчедә—«Сөю газабы яки, ташлама мине» дип аталган әсәре белән Флёра Тарханова.

Жюри шулай ук кызыксындыру премияләре дә булдырган иде. Ул премияләргә Илгиз Зәйниев («Күкләр елмаеп караса»), Хәбир Ибраһим («Нәфига ханым»), Эльмира Шәрифуллина («Гомер бер») һәм Җайсыз кеше («Алма бакчасында алтын бар») лаек булды.

Җиңүчеләр 100, 75 һәм 50 мең сум күләмендә акчалата премияләр белән бүләкләнде. Җиңүче әсәрләр махсус альманахта басылып чыгачак. Шул ук көнне «Яңа татар пьесасы—2006» бәйгесенә дә старт бирелде. Анысында жанрлар буенча чикләүләр булмаячак.

## МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ ВИЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ БУЛДЫ

Татарстан Фәннәр академиясе президиумының чираттагы утырышында күренекле тарихчы галим, язучы, академик Миркасыйм Госманов академиянең вице-президенты итеп билгеләнде. Ул үзенең эшчәнлегендә гуманитар фәннәр юнәлешен игътибар үзәгендә тотачак. Шушы ук утырышта Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе, академиянең мөхбир-әгъзасы Ренат Мөслимов геология һәм нефть ятмалары эшкәртелеше буенча фәнни советның рәисе итеп тәгаенләнде. Президиум әгъзалары Фәннәр академиясенең А.Адо, Г. Камай, Х. Мөштәри исемендәге бүләкләрен дәгъвалаучылар конкурсын үткәрү турында карар да кабул итте.

«Казан утлары» редакциясе журналыбызның редколлегия әгъзасы Госманов Миркасыйм Габделхәй улын яңа вазифасы белән котлый, җаваплы эшендә яңа уңышлар, саулык-сәламәтлек тели.

## КИЛЕШҮ

Татарстан Җәмәгатьчелек палатасы һәм «Татмедиа» агентлыгы хезмәттәшлек турында килешү төзеде. Ана Җәмәгатьчелек палатасы рәисе Илгиз Хәйруллин һәм агентлыкның генераль директоры Марат Моратов кул куйды.

—Сез, журналистлар, социаль-иҗтимагый, икътисадый мәсьәләләрне киң яктыртасыз. Җәмәгатьчелек палатасы да шундый ук максат белән оештырылды. Ул халык белән дәүләт арасында арадашчы ролен үтәргә, җәмәгатьчелек теләген хакимияткә ирештерергә тиеш. Безнең алда торган зур бурычларны үтәүне мәгълүмат чараларыннан башка күз алдына китерә алмыйм,—диде Илгиз Хәйруллин үз чыгышында.

Килешүгә кул кую тантанасында Президентның Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча идарә җитәкчесе Александр Терентьев, мәгълүмат чаралары җитәкчеләре һәм Җәмәгатьчелек палатасы әгъзалары катнашты.

## ӘМИРХАННАР КИЧӘСЕ

13 март көнне Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында татар әдәбияты классигы, прозаик, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның тууына 120 ел тулуга багышлап «Чәчәкләр китерегез миңа...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

Бу бик үзенчәлекле кичә башыннан ахырына кадәр спектакль рәвешендә барды. Тинчурин театры артистлары тамашачыны Әмирхан яшәгән чор атмосферасына алып керергә тырыштылар. Яшь Фатихның әтисе Зариф хәзрәт белән мөнәсәбәте, Тукай белән сөйләшүләре һәм Хәят образының прототибы булган Шәмсениса исемле туташны очратуы сәхнәләштерелде. Тукайның «Туган авыл», «Китмибез» шигырьләре, «Әллүки» җыры яңгырады. «Тигезсезләр», «Фәтхулла хәзрәт», «Хәят» телевизион спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин Фатих Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләделәр. Тамашага килүчеләр арасында Әмирханнар нәселеннән булганнар да күп иде.

Кичәдә шулай ук галим Равил Әмирхан тарафыннан язылган «Әмирханнар» дигән китап та тамашада катнашучыларга тәкъдим ителгән иде.

## РАХЛИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында күренекле дирижер, педагог, Татарстан дәүләт симфоник оркестрына нигез салган Натан Рахлинның тууына 100 ел тулуга багышланган музыка фестивале булып узды.

Фестивальдә танылган музыка белгечләре Георгий Кантар, Жанна Дозорцева, дирижерлар—Украинаның халык артисты Федор Глущенко, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Вадим Венедиктов, Татарстан, Казакъстан һәм Россиянең халык артисты Фуат Мансуров, пианиночылар—СССРның халык артисты Николай Петров, Россиянең халык артисты Алексей Наседкин катнашты.

Фестиваль кысаларында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашында түгәрәк өстәл дә үтте. Анда Натан Рахлин исемендәге фестивальне даими үткәреп барырга, киләчәктә аны дирижерлар конкурсы белән баетырга карар кылынды. Маэстроның иҗатына багышланган китаплар чыгару кирәклеге искәртелде. Симфоник оркестрыбызга репетицияләр үткәрер өчен аерым бер зал булдыру тәкъдиме әйтелде. Түгәрәк өстәлдә Натан Рахлинга Казанда һәйкәл кую турында да сүз булды. Дирижерның оныгы скульптор Григорий Лысенко һәм аның хәләл җефете Элла булачак һәйкәлнең проектын инде эшләгәннәр. Һәм ул Казанда куела калса, алар авторлар буларак, тиешле түләүгә дәгъва кылмаячаклары, иҗат эшләрен шәһәребезгә бүләк итәчәкләре турында әйтте.

## ФОТОКҮРГӘЗМӘ— ДӨНЬЯГА ТӘРӘЗӘ

Казандагы «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә «Казан фотографиясе. Портретка штрихлар» дигән күргәзмә ачылды. Ул шәһәр фотографлары җәмгыятенең 110 еллыгына багышлана. Күргәзмә Мәдәният министрлыгы һәм «Татмедиа» агентлыгы тарафыннан оештырылды.

«Әлеге эшләрнең күбесе Казан һәм казанлыларга, Татарстан башкаласының 1000 еллыгына багышланган. Аларны Париж, Мәскәү, Истанбул, Анкара, Малайзия һәм Сүрия тамашачысы да карады һәм югары бәяләде. Якын көннәрдә безнең фотографлар күргәзмәсе Һиндстанга юл алачак,—диде күргәзмәне ачканда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева. —Фотокүргәзмә—Татарстанның зур мөмкинлекләрен чит илләрдә тәкъдир итүнең бик отышлы ысулы. Мин осталарыбызның күргәзмәсен Анкарада ачтым, һәм аны Төркиянең бик күп мәдәният әһелләре тамаша кылды. Алар безнең республика турын-

да сөйләүче күргәзмәне зур кызыксыну белән карады».

«Чор портреты» дигән төбәк IV фотоконкурсының нәтиҗәләре дә билгеле. Анда 53 авторның 940 эше күрсәтелде. Иң популяр номинацияләр «Шәһәр тормышы» һәм «Дөнья хатын-кыз күзлегеннән» икәне ачыкланды. Конкурста Фәрит Гобәев, Рифкать Якупов, Рөстәм Мөхәммәтҗанов, Михаил Козловский, Эдвард Хәкимов һ.б. иҗаты югары бәя алды.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында моңарчы Казан дәүләт университеты доценты вазыйфаларын башкарган әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Әлфәт Закирҗанов Язучылар берлеге рәисе урынбасары итеп расланды.

### ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫН ТУПЛАГАН CD-ДИСК

Күптән түгел «Ак калфак ансамбле җырлары» дип исемләнгән CD-диск дөнья күрде.

Әлеге җыентыкта музыка белгече-фольклорчы Геннадий Макаров тарафыннан 10-15 ел дәвамында тупланган йола җырлары, этник көйләр һәм бәетләр һәм үзе иҗат иткән көйләр, ансамбльнең 2002 һәм 2005 елларда башкарган әсәрләре урын алган.

А.Алиш исемендәге балалар иҗаты йорты каршында эшләп килүче «Ак калфак» фольклор ансамбле Алсу Еникеева тарафыннан 1995 елда оешкан. Ул «Сөембикә варислары» дип исемләнгән Халыкара төрки-татар балалар иҗат фестивальләрендә катнашып, беренче дәрәҗә дипломнарга һәм махсус призларга да лаек булды. Ансамбль Төркиянең Измир, Измит, Анкара һәм Истанбул шәһәрләрендә дә чыгыш ясап, үзен танытып кайткан инде.

### «ЗЫЯЛЫЛАР» КЛУБЫ КИЧӘСЕ

Россия Галәттән тыш хәлләр министрлыгының конференцияләр залында Мәскәүнең «Зыялылар» клубы әгъзаларының чираттагы очрашуы узды.

Кичәне танылган журналист, язучы, клубны оештыручы һәм аның җитәкчесе Нәзифә Кәримова үзенчәлекле итеп әзерләгән иде.

Кичә бер төркем җәмәгать эшлеклеләренә (шул исәптән атаклы кардиохирург Ренат Акчуринга) «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләрен тапшырудан башланды. Аны Татарстанның Россиядәге Вәкиллегенең вәкил урынбасары Алмаз Фәйзуллин тапшырды. Аннары кунаклар алдында Татарстанның халык артисты Клара Хәйретдинова, Россиянең атказанган артисты Наилә Фатехова чыгыш ясады. Татарстанның атказанган артисты Роза Хәбибуллина татар җырын оста итеп башкаручылар арасында конкурс үткәрде.

### РӘХМӘТ ХАТЫ

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә керткән лаеклы өлеше өчен язучы **Камалов Хисам Нуретдин улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык унышлы хезмәте өчен язучы, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире профессор **Фоат Галимулла улы Галимуллинга** «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен Мамадыш районының Кече Кирмән урта гомуми белем мәктәбе директоры **Рафаил Шәкүр улы Газизовка** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Зыятдинова Фирая Гали кызы** 22 май көнне вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кабан күле янындагы Зәңгәр мәчет. **Гомәр Зәйнуллин** фотосы.


*Тышлыкның дүртенче битендә:* Шагыйрә **Фәүзия Солтан**.

# Яңа китаплар



Тукай...: **Дөнья халыклары Тукай турында.** Төзүчесе Р. Акъегет (Рөстәм Фәйзуллин).—Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.—222 б. Тиражы—2000 данә.

Китапта дөнья халыклары вәкилләренен—әдипләрнен, жәмәгать эшлеклеләренен, галимнәрнен Тукай шәхесе һәм ижаты турындагы фикерләре туплап бирелгән. Аларнын байтагы беренче мәртәбә басыла. Шигъри яки чәчмә формада фикер әйтүче авторларнын саны ике йөзгә якын, шуларнын йөзләбе төрле милләт вәкилләре. Рус М. Горький, казакъ М. Ауэзов, кыргыз Ч. Айтматов, украин П. Тычина, итальян Д. Жерманетто, гарәп С. Жамал, балкар К. Кулиев, француз Л. Арагон, төрек М. Өнәр... Әлбәттә, татар шагыйрьләренен Тукайга багышланган шигырьләре дә китапта лаеклы урын алган. Тукай турында шулай кыска формада фикерләр тупланмасы булган китап әлегә беренче мәртәбә дөнья күрә.



Наис Гамбәр. **Ачык калган тәрәзәм...** Шигырьләр. —Казан: «Рухият» нәшр., 2006.—208 б. Тиражы—1000 данә.

Әдәби даирәдә Наис Гамбәр житди тәнкыйтьче, тәжрибәле мөхәррир, яхшы шагыйрь булып саналды. Гомеренен сонгы елларында күбрәк шигърият өлкәсендә эшләде. Күләм ягыннан шигырьләре әлләни күп булмаса да, алар шагыйрьнен аерым почерк-стиле, дөньяны үзенчә фәлсәфи-сурәтле итеп күзаллавы белән аерылып торалар. Бу басмага Н. Гамбәрнен мона кадәр чыккан ике китабында («Баш очымда—Кояш», «Күзләрем яфрак коя») һәм көндәлек матбугатта басылган шигырь бәйләмнәреннән сайлап алынган шигырьләр тупланган.

Китапка кереш сүзне шагыйрь Рәдиф Гаташ язган.



Фәүзия Солтан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)